ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2005



# Tatarstan Respublikası Prezidentı UKAZI

## 2005 yılda Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət büləkləren birü turında



*Z. Ğıymayıv*



*R. Minğalimov*



*Ş. Şərifullin*

Tatarstan Respublikası Prezidentı qarşındağı Ğabdulla Tuqay isemendəge Dəwlət büləklərе komissiəse təqdimnəren qarağannan son, qarar birəm:

2005 yılda Tatarstan Respublikasının Ğabdulla Tuqay isemendəge Dəwlət büləklərеn tübəndəgelərgə birergə:

1. Rəssam **Ğıymayıv Zəfər Foat ulına**—Tatarstan Respublikasının ədəbiət həm sənğət eşleklelərе portretları əçen;
2. Şağir **Minğalimov Rəstəm Ğali ulına**—"Dərt çülməge" şiğri cıyıntığı əçen (Qazan, Tatarstan kitap nəşriatı, 2003 yıl);
3. Kompozitor **Şərifullin Şamil Kamil ulına**—"Mənəcətlər" həm "Awıl kəylərе" xor konsertları əçen.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

*Qazan, Kreml', 2005 yıl, 26 aprel'.*

Казан утлары
Qazan utları

2005

6

(992)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир— 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары— 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге—43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Галәмнәрне урап кайткан кеше сыман... *Шигырьләр* ........ 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Иманыңнан бер язсаң... *Роман* ........ 11
Бикә РӘХИМОВА. Күңел игүчеләр. *Шигырьләр* ........ 77
Шәүкәт ГАДЕЛША. Туган якта—ук атканда... *Шигырьләр* ........ 82
Камил КӘРИМОВ. Мин әнигә бик кирәк!.. *Хикәя* ........ 86
Рәшит ГАРИФ. Сөйләде җилләр. *Шигырьләр* ........ 94
Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Яран гөле. *Шигырьләр* ........ 97

ПУБЛИЦИСТИКА

Назиф МИРИХАНОВ. Хезмәт тәме яки шәҗәрә җебе ........ 100

ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"

Алсу ШӘМСУТОВА. "Тарих таный—иҗатына җаннарын салганнарны..." ........ 120

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар прозасында яңа романтизм ........ 132

ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ........ 142

МАНСУР ХӘСӘНОВКА 75 ЯШЬ

Фидакарьлек ........ 145

ТАРИХ

Рөстәм МӨХӘММӘТШИН. Ишми ишан капкасы ........ 148

"Татар энциклопедиясе" битләреннән ........ 154

МӘСЬӘЛӘГӘ БЕР КАРАШ

Фоат ВӘЛИЕВ. Энциклопедик "эт борчагы" ........ 158

ХӘТЕР

Ләбибә ИХСАНОВА. Бу хатлар—заман көзгесе ........ 162

КИТАП КҮЗӘТҮ

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Чын хикәяләр ........ 168

ӘБРАР КӘРИМУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Ирек ҺАДИЕВ, Наҗия АСЫЛКАЕВА. Татар фәне тарихында эзе тирән ........ 173
Әбрар КӘРИМУЛЛИН. Татар басма китабы тарихы сәхифәләреннән ........ 178

Котлыйбыз! ........ 182
"Казан утлары" архивыннан ........ 184
Берлекнең яңа әгъзалары ........ 186
Безнең календарь ........ 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": Р. МИР-ХАЙДАРОВ. Роман "Двойник китайского императора" (начало); рассказ К. КАРИМОВА, стихи Л. ШАГИРЗЯН, Б. РАХИМОВОЙ, Ш. ГАДЕЛЬШЫ, Р. ГАРИФА, Х. БАДИГИ.
"Публицистика": Н. МИРИХАНОВ. "Труд в радость или нить родословной".
Дискуссия "Герой нашего времени": статья А. ШАМСУТОВОЙ о состоянии современной татарской литературы.
"Литературная критика": статья Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ "Новый романтизм в татарской прозе".
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"К 75-летию М. Хасанова": "Самоотверженность".
"История": статья Р. МУХАМЕТШИНА "Последний мударрис древнего медресе".
"Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Память": Л. ИХСАНОВА. "Эти письма—зеркало нашего времени".
"Книжное обозрение": М. ВАЛИЕВ рецензирует книгу Р. Карами "Сорванный цветок".
"К 80-летию А. Каримуллина": И. ХАДИЕВ, Н. АСЫЛКАЕВА. "Глубокий след в истории татарской науки"; А. КАРИМУЛЛИН. "Со страниц истории татарской печатной книги".
В номере отмечаются 70-летие А. Хасанова и 75-летие М. Файзуллиной.
Из фотоархива журнала.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Сабантуй в деревне"—работа художника М. САМАКАЕВА; поэт Д. ГИСМЕТДИН.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": R. MIR-HAIDAROV. Novel "The Double of the Chinese emperor" (Beginning); story by K. KARIMOV, verses by L. SHAGIRZYAN, B. RAHIMOVA, Sh. GADELSHY, R. GARIF, H. BADIGI.
"Publicism": N. MIRIHANOV. "Labour for pleasure or thread of parentage".
Discussion "Hero of our time": article by A. SHAMSUTOVA about the state of modern tatar literature.
"Literature critics": article by D. ZAGIDULLINA "New romanticism in tatar prose".
"Science": A. TIMERGALIN. "Dictionary of nation".
"To 75th anniversary of M. Hasanov" "Total dedication".
"History": article by R. MUHAMETSHIN "Last mudarris of an ancient medrese".
"Pages from "Tatar encyclopedia".
"Memory": L. IHSANOVA. "These letters are Mirror of our time".
"Book review": M. VALIEV reviews the book by R. Karami "Thwarted flower".
"To 80th anniversary of A. Karimullin" I. HADIEV, N. ASYLKAEV. "Deep trace in History of tatar science"; A. KARIMULLIN. " From pages of history of tatar books".
In this magazine are celebrated the 70th anniversary of A. Hasanov and 75th anniversary of M. Faizullina.
From photo-archive of magazine.
New members of the Union of writers
Diary of public-cultural life.
On our covers: "Sabantuy (Holiday of plow) in village" — work of artist M. SAMAKAEV; Poet D. GISMETDIN.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.05.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А–374. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



## Лена Шагыйрьҗан

# ГАЛӘМНӘРНЕ УРАП КАЙТКАН КЕШЕ СЫМАН...

(ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН)

### Хакыйкать

**Сулар ага, еллар ага, гомер ага...**
**Җир үзе дә бер искерә, бер яңара.**
**Үзгәрәләр кешеләр дә, нигезләр дә,—**
**Бертөрлелек сыя алмый бу дөньяга...**
**Һәммә җисем сайланышта, үзгәрештә.**
**Тик бер нәрсә кала мәңге бер рәвештә:**
**Ул—ХАКЫЙКАТЬ!—Бүгенгеме,**
**кичәгеме—**
**Аерма юк!**
**Без табынган бу изгелек ни зурлыкта?**
**Без соң аның бөтенеме, кисәгеме?..**
**Тик хакыйкать бүленмәгән өлешләргә—**
**Ваклап булмый аны алтын-көмешләргә!**

### Без хатын-кызлар ич...

**Без хатын-кызлар ич...**
**Яшьлектә генә ул**
**Кычкырып көләсең,**
**Үкереп елыйсың—**
**Беркемнән яшереп тормыйсың.**
**Күңелең шар ачык—**
**Чаршау да, пәрдә дә**
**Кормыйсың...**
**Яшь чакта тормышың**
**Төп-төгәл, түгәрәк.**

Лена ШАГЫЙРЬҖАН —*шагыйрә, тәрҗемәче, публицист; "Мәлдерәмә күңел", "Иман алифбасы", "Ышанам йөрәгемә", "Гомер сарае", "Бәҗра вә Хәҗрә" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Ә үзең—
Гөлләрдән яралган
Бер гамьсез күбәләк...
Без хатын-кызлар ич...
Яшьлектә генә ул
Өлеш юк, бүлеш юк,
Шобага салыш юк,
Җирәбә тотыш юк,
Үлчәүләр тип-тигез—
Отылу, отыш юк...
Без хатын-кызлар ич...
Бүгенге ул нәрсә—
Без алга, иртәгә
Йөз тотып яшибез.
Бүгенгә дәшмибез.
Кайвакыт сагаеп,
Саргаеп китсәк тә,
Яисә өметләр
Киселсә кисәктән,
Юк әле бирешү,
Бөрешү эшмени!
Без кабат дөрлибез,
Янәдән яшьнибез.
Без хатын-кызлар ич,
Көтәбез,
Ышанып яшибез!..

## Хәтереңдәме?..

Хәтереңдәме, мин ул көнне матур идем,
Син яраткан шаян күлмәгемне кидем.
Без ул көнне төнгә ялгап бәхет кичтек,
Мин—Ләйләсе, син—Мәҗнүне идең Җирнең...

Хәтереңдәме, без ул көнне Мәхәббәтнең
Икебез дә хуҗасы һәм... колы идек.
Шул изге хис каршысында бала идек,
Балалыкны рәнҗетмәслек олы идек...

Хәтереңдәме җитәкләшеп очкан чаклар?
Ә каеннар озаграк бездән саклар
Истәлеген ул язларның. Яфраклары
Берәм-берәм әкият сөйләр безнең хакта...

Ә бүген без икебез дә гади инде,
Очалмадык йолдызларга, калдык җирдә.
Бу дөньяда ничә яфрак, саргаешып,
Әкият сөйли икән мәңге тынмас җилгә?..

## Асылташ

Бер әкият әйләндерде минем башны,
Эзләп тап, дип, хикмәтле шул асылташны:
Китерер ул, диде, сиңа бик зур бәхет,
Каурыедай, тылсымга бай асылкошның...

Шактый гомер уйлап аны иза чиктем.
Ул һәр яктан миңа серле нурын сипте.

Сихерләнеп, аны озак эзләдем мин,
Тапмасам да, өметемне өзмәдем мин.

Асылташ ул җирдә ятмый—анысын беләм.
Алданганмын, дип, үземнән-үзем көләм.
Еллар узды... Онытылды серле таш та,
Әкият тә борчымады мине башка...

Әмма күңел кайчак балкып-балкып китә:
Шул асылташ, ахры, һаман мине көтә...

## Бер уйлаганда...

Бер уйлаганда, бер уйлаганда,
Гаҗәп тә соң тормыш дигәнең:
Әйләнә дә кала түшәмгә
Кичә басып йөргән идәнең...

Бер уйлаганда, бер уйлаганда,
Сәер дә соң кеше дигәнең:
Ярдәм сорап килсәң, күз йома
Кичә генә дус дип йөргәнең.

Бер уйлаганда, бер уйлаганда,
Кызык та соң бу дан дигәнең:
Булып чыга шома урындык
Кичә алтын тәхет дигәнең...

Бер уйлаганда, бер уйлаганда,
Ярылып яткан ялгыш дигәнең
Мөһерен сугып, раслый да куя
Берәүләрнең язмыш дигәнен...

## Ышанам йөрәгемә

Ышанам йөрәгемә:
Ышанган кебек кешегә
Моңлы җыр кирәгенә—
Сандугач булып кунарлык
Кабере тирәгенә...
Ышанам йөрәгемә:
Ышанган күк Мәхәббәткә—
Тереклек терәгенә.
Ияртеп алып менәрлек
Йолдызлар төбәгенә.
Ышанам йөрәгемә:
Ышанган күк әниләрнең
Изге җыр-теләгенә,
Тирбәткән чакта сабыен
Салып ак беләгенә...
Ышанам йөрәгемә:
Ышанган кебек дусның да
Үзеңнән зирәгенә.
Гомер юлларын кичкәндә
Сыналган сирәгенә.
Ышанам йөрәгемә:
Ышана белсә үзе ул
Тик туган җиргә генә.

Җырласа һәм җылый белсә
Ил белән бергә генә.
Тик шуңа күрә генә мин
Ышанам йөрәгемә!

## "Уел" көе

*Сугышта хәбәрсез югалган*
*Фатыйх абыема багышлыйм.*

Үзәкләрне өзеп, үкси-үкси
"Уел" көе агыла үзәннән.
Кем булыр бу ялгыз өзгәләнгән,
Яшь китереп безнең күзләрдән?

Кем булса да булыр, җыр—үзе бу,
Хәтер җепләренә уралып,
Агыла да агыла тын бушлыктан,
Күксел офыкларга юл алып.

...Әни белән шулай бала чакның
Йолдызлы бер җәйге төнендә
Тыңлап торган идек без бу көйне,
Хәйран калып, капка төбендә...

—Әй, кызым, ди, әни, шушы җырны
Фатыйх абзаңнан да остарак
Җырлаганын белмим беркемнең дә,
Гомере генә булды кыскарак...

Сузып-сузып җырлар иде, мәрхүм,
Бигрәк иркен иде сулышы,
Өзелепләр калды ярты юлда,
Каян гына чыкты сугышы!..

Әй ул көннәр, күпме газиз ирләр,
Әрәм булды ла соң, бәгырьләр.
Уелып-уелып "Уел" гына ага,
Җырлар озын—кыска гомерләр...

Хәбәр булып гүя үткәннәрдән,
Агыла да "Уел", агыла.
Әллә кайта безгә сәлам булып,
Әллә китә Фатыйх абыйга...

## Намусыңа синең таянам

*Язгы боз ястык калынлыгы булса да ышанма.*
Мәкаль

Язгы бозмы, көзге бозмы ул—
Намусыңа синең таянам...
Ярылмасмы чатнап ышаныч,
батырмасмы алдап яңадан?..

Язмыш ташкыннарын үтәрлек,
ышанырлык нықмы күперләр?
Таеп түгел, хәтәр алданып,
упкыннарга очты күп ирләр...

Утлар-сулар кичәр юлыңда
һәр басманы үзең салмыйсың...
Тәвәккәлләр китсә артыңнан,
ышанычлы изге җанмы син?!

Хыянәткә әгәр тарысак,
кем коткарыр безне яңадан...
Язгы бозмы, көзге бозмы ул—
Намусыңа синең таянам...

## Һай, бер гомер генә җитәмени...

Һай, бер гомер генә җитәме соң
Йөрәктәге сөю хисенә?!
Терелермен кебек үлгәч тә мин,
Мәхәббәтем төшеп исемә...

Һай, бер гомер генә җитәме соң
Күңелдәге безнең моңнарга?!
Калсаң икән мәңге бу дөньяда
Былбыл сайрауларын тыңларга...

Һай, бер гомер генә җитәме соң
Һәммәсен дә әйтеп бирергә?!
Ниләр генә эшләп китим икән,
Килү өчен кабат бу җиргә?!.

## Фәрештәләр кыры

Фәрештәләр кыры... Кыяр-кыймас
колак салам: әллә былбыл җыры?..
Канатларым җәеп, бастым сакка.
Кара белән язып куйчы акка:
Зинһар, чүпли күрмә, пычратма,
Таптый күрмә берүк—безнең хакка!!
Шайтан халкы тулса, таптап изәр,
Барча кошлары Ходайның бизәр...
Зинһар, шайтаннарга
капка ачмасыннар,
Фәрештәләр өркеп качмасыннар!..
Кара белән язып куйчы акка:
Таптамагыз, зинһар, безнең хакка!
Канатларым җәеп, бастым сакка...

## Галәмнәрне урап кайткан кеше сыман

Ник бу, кайчак, йөзләреңә тел белән дә
әйтеп булмый торган сагыш төсе чыга?
Ник текәлеп уйга калдың күк чәчәккә,
Галәмнәрне урап кайткан Кеше сыман?

Җир шарының үзенә сыеп бетмәс кебек
нинди сагыш йөрәгеңә тулды кереп?
"Гади бер гөл" диеп йөргән могҗизаның
ачтың мәллә кинәт бер-бер мәгънә-серен?

Беренче кат күргән төсле ник текәлдең,
ни эзлисең минем дымлы күзләремнән?
Нинди бер көй табыйм икән икебез өчен
әйтелмичә калган моңлы сүзләреңнән?..

Юк, һич үбеп туфрак-җирне үксемисең
ут-сулардан исән чыккан ир төсле син.
Күзләреңнән танып алдым шул мизгелдә
Галәмнәрне урап кайткан Җир Кешесен...

## Көзге Казан

Беренче кат күргәндәге сыман,
Тора-тора серләләнә бара—
Язым белән җәем узган Казан,
Күзләремне каршы алган кала...

Әллә инде яңарамы кабат,
Әллә үзем яңарамны шулай?..
Юкса—күктә йөзә шул ук кояш,
Кабанында йөзә һаман шул ай...

Әй, Казаным, шигъри казан күк син,
Бертуктаусыз ташып-кайнап торган.
Җәең—гөлләр чиккән шигъри җәймә,
Кышың—шигъри юллар сырган юрган...

Яшьлек үткәчтен дә яңару бар.
Көзге яңгырлар да яңарталар.
Күңелдәге язгы кыңгыраулар
Көзге җырларымны яңгыраталар...

Яшьлегемнең дәртле Казаным
Гүя кире миңа кайтып бара...
Язларыма шаһит булган шәһәр,
Күзләремә гашыйк булган кала...

## Яшәү көне

Һәркөнне дә яшәмисең аны
кайнап-дөрләп, шаулап-гөрләп кенә.
Һәркөнне дә эшләмисең аны
янып-көеп, пешеп-тирләп кенә...

Андый көннәр—илһам уянганда—
чын бәхетле Яшәү көне була.
Андый чакта күңел, башак кебек,
иҗат орлыклары белән тула.

Мин ул көнне чынлап азат булам
тормышның вак мәшәкатьләреннән.
Таң нурлары эзләп сихерләнәм
хәтта кичнең ал шәфәкъләреннән.

Яшәү көнем—нәкъ яңадан туу,
бу—сүз түгел баллы-төчеләрдән.
Тик ул көнне мине табалмассыз,
качам мин битараф кешеләрдән.

Һәм берзаман, гап-гади бер көнне
мин урамга чыгам, узып чорны,—
Өләшергә һәрбер очраганга
Яшәү көнем бүләк иткән җырны.

***Редакциядән:***

*Бу айда күренекле шагыйрә һәм публицист, журналыбызның актив авторы Лена Шагыйрьҗан олуг юбилеен каршылый. Күпсанлы укучылар һәм редколлегия исеменнән аны тәбрик итәбез, иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез.*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Рауль Мирхәйдәров**

## ИМАНЫҢНАН БЕР ЯЗСАҢ...

РОМАН

### I БҮЛЕК

*Ертык Закир, рэкет, Форштадт, Төрек Госман, Истанбулдан кайткан энҗе муенса, чибәр Нурия-Нора, алып-сатар юл күрсәтүчеләр, Страсбургтагы аукцион, Марк Раушенбах джаз-оркестры, диңгезче киемендәге татар егете "Скорцени"*

—Бу челләне әйтер идем, көне буе тын алырлык булмады, шөкер, кичкә бераз сүрелә төште, юкса, тын алырлык түгел иде, җил дә чыкмакчы, бүген, мөгаен, айванда гына йоклармын инде,—дип эндәште бакчадагы караңгылыкка карап, эре гәүдәле, мәһабәт кыяфәтле ир-ат.

—Эсселектән интеккән диярсең,—караңгылыкка күмелгән бакчадан тыйнак кына көлеп куйган хатын-кыз тавышы ишетелде.—Бүлмәңдә ике кондиционер улап утыра, бүлмә саен шулар... Сүндереп йөрмәсәм, тун киеп йөрер идең бугай. Җитмәсә, машинаңа да япон кондиционеры куйдыргансың. Теге ялагаең Халтаев мактанып туя алмый, беркемдә дә андый яңа нәрсә юк имеш. Фирмасы гына ни тора, дигән була. Исемен онытып җибәрдем...

—"Хитачи" ул,—дип куйды Мәхмүтов, ләкин хатынының сүзенә кушылмады. Элеккеге хатыны исенә төште. Зөһрә ире белән болай иркен сөйләшергә, күршесен, милиция начальнигын ялагай дип әйтергә җөрьәт итмәс иде. Ул җиңел генә урыныннан күтәрелде дә самавыр янында кайнашучы Мияссәрәне яхшырак күрү өчен зур айванның—Урта Азиядә бакчада корылган сәкене шулай айван дип йөртәләр—икенче ягына күчеп утырды. Җитез хәрәкәтле, зифа сынлы хатынын читтән күзәтеп утырырга ярата ул. Яратмаслык та түгел, тал чыбыгыдай сыгылмалы Мияссәрәгә әле беркем дә утыз бишне бирми, ул шулхәтле чибәр һәм яшь күренә.

Хәер, хатыны белән чагыштырганда тазарак, бераз симезрәк кебек тоелса да, аның әле көче ташып торган чагы, хәрәкәтләре җитез, гәүдәсенең һәр чалымында көч-куәт тәгаенләнә. Шуның өстенә, аның үз-үзен тотышында, һәр ымында аксөякләргә генә хас ниндидер затлылык та бар, шунлыктан аны үзе югында еш кына Дирижер дип тә әйткәлиләр иде. Әмма аны Дирижер дияргә батырчылык итүчеләр даирәсе

---

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ (1941) — *язучы, рус һәм татар телләрендә чыккан өч дистәгә якын китап авторы. Аның "Иртәләгән сагыш", "Кара аксөякләр" ("Карга короле"), "Һәрнәрсәгә—акчалата" романнары, "Игълан буенча танышу" повесте, байтак хикәяләре "Казан утлары" журналы битләрендә дә дөнья күрде. Мәскәүдә яши.*

бик тар булып, ул кушамат аңа ябышып кала алмады. Чынлыкта аны бик үтемле итеп Хуҗа дип кенә йөртәләр иде.

Мәхмүтов ирексездән хатирәләргә бирелгәнен сизми дә калды. Бик күптән, моннан утыз еллар элек, аны, әле ул чакта япь-яшь инженерны һич көтмәгәндә партия эшенә чакырдылар. Күктән төшкән бәхет булып күренгән бу тәкъдимнән башта ул каушап та калган иде, әмма аның ризалыгын сорап тормаячакларын да яхшы белә иде. Дөресен генә әйткәндә, аның үз һөнәреннән һич тә аерыласы килми, төп хыялы районда оста күпер төзүче булып танылу иде. Үз гомерендә өченче күперен төзеп ятучы инженер өчен хыялның иң югарысы, кәттәсе иде ул.

Райкомда эшләү ниндидер билгесезлек белән куркыта, анда Алланың кашка тәкәләре сыман өстен ниндидер бүтән сыйфатларга ия, башкача уйлый белүче кешеләр генә эшлидер сыман тоела. Ул чын күңеленнән алар компаниясенә ятышмаячагына, төп эше күпер төзү икәнлегенә ышана иде.

Иртәгә яңа эшкә чыгасы дигән көнне бердәнбер костюмын тагын бер кат чистартып, үтүкләп алды. Коммуналканың кысан бүлмәсендә элеккеге хуҗалардан калган, сыдырылып, чатнап беткән көзге каршына басып, үзенә таләпчән караш ташлады, аннан исә каушаганлыгы, югалып калганлыгы йөзенә чыккан бер кемсә карап тора иде.

“Шушындый мескен кыяфәтең белән син дә хакимияткә үрлисеңме?”—дип үзен үчекләп алгандай итте, әмма яшь һәм үткен акылы яңа эшнең элеккесеннән кай ягы белән аерылып торуын аңлап алган иде инде.

Күпер төзү эшендә ничек киенүең, үз-үзеңне ничек тотуың, ни рәвешле сөйләшүең, боерыкны ничек бирүең әллә ни әһәмияткә ия түгел, иң мөһиме—инженерлык белемең, осталыгың иде. Алардан башка күпер төзеп булмый.

Юк, ул чакта ук инде яңа эшенең нигезе нәкъ менә шунда гына дип күңелен беркетеп куймаган иде, теләсә кайсы башка эштәге кебек, анда да төрле серләр тулып ятадыр, тере кешеләр белән эш итү уен түгел. Әмма ләкин табигатьтән бирелгән үткен акылы, үзе әле аңлап бетермәсә дә, ниндидер бер мөһим нәрсәне эләктереп алганын сизенми калмады. Костюмын бер читкә куеп көне буе көзге янында әвәрә килде, максаты “үз йөзен” булдыру, ягъни яңа эштә үзенә генә хас йөрү рәвеше һәм хәрәкәтләр белән күренү иде. Икенче көнне иртән башын югары тотып, ышанычлы адымнар белән райкомның парадный ишегеннән килеп кергәндә ул инде бөтенләй башка бер кеше иде, һәрбер хәрәкәтендә, ымында үзенең хаклыгына нык ышану ярылып ята иде. Читтән карап торган берәүгә ул теләсә нинди мәсьәләне бер селтәнүдә хәл итә алырдай кеше булып тоелыр иде, чөнки һәр хәрәкәтеннән көч вә дәрт ташып тора иде.

Ул бакча түренә, самавыр янында кайнашучы Мияссәрәгә күз ташлап алды. Калай торбадан озын ялкын телләре ургыла, алар яктысында хатынының йөзе чагылып китә, буй-сыны тагын да сыгылмалырак, зифарак булып күренә, хан-атлас дип йөртелүче затлы тукымадан тегелгән күлмәге исә ялкын телләре белән бергә төрле төсләргә, төсмерләргә кереп уйнаклый иде.

Әйтерең бармы, болар барысы да бер тылсымлы дөнья булып тоела иде. Караңгы төн, шылт иткән тавыш та ишетелмәгән тынлык, һәр куагы, агачы каралган, матурлап киселгән бакча һәм ут яктысында төрле төсләргә кереп уйнаклаучы күлмәк кигән чибәр хатын. Самавыр менә-менә кайнап та чыгар, табын янына дәшәрләр... әмма аның бу ләззәтле мизгелләрне озаккарак сузасы килә иде.

Уйларына, тәнендә сулкылдаган рәхәтлеккә бирелеп, ул тирә-ягында ни барын онытып җибәргән кебек иде, самавыр торбасының җиргә төшеп киткәне генә куе һәм тыгыз тынлыкны бозып, күк күкрәгәндәй булып ишетелде.

—Кулыңны пешермәдеңме?—беренче сүзе шул булды. Ярарга тырышыбрак әйтелде бугай, әмма бу аның ихтыярыннан башка килеп чыкты һәм ул үзенең йомшарып китүенә уңайсызланып та куйды. Ир кеше хатын-кызга үзенең мөнәсәбәтен ачыктан-ачык сиздерергә тиеш түгел. Аның үзен кайчандыр шулай өйрәткәннәре кебек, ул инде күптән башка чыгып, үз гаиләләре белән көн күрүче улларында да шул сыйфатны тәрбияләргә тырыша иде.

Ул көнне аңа бик мөһим ике хәбәр килеп иреште. Внешторгтан килгән ашыгыч телеграммада Страсбургта үткәреләчәк аукционда район ат заводының чиста нәселле атлар сәүдә күргәзмәсенә катнашырга чакырылуы әйтелгән иде.

Икенчесе—Ташкенттан алынган яшерен депеша—киләсе атнада аның үзенең Үзәк Комитетта, идеология секретаре янында булырга тиешлеген искәртә иде.

Бусы Страсбургтагы аукционда өченче тапкыр катнашу булачак. Французларның шәхси чакыру җибәрүен ул яхшыга юрады. Димәк, аның ахалтекин токымлы атларын һәм гарәп чабышкыларын Европада да күреп алганнар, бәяләгәннәр. Башкалага ни өчен чакыруларын да чамаламый калмады, әлбәттә. Республика делегациясенең XIX бөтенсоюз партконференциясеннән кайтканына инде өч айдан артык вакыт узды, шул вакыттан бирле төрле дәрәҗәдәге кабинетларда бер сорауга җавап эзли бирәләр: кемнәр соң алар матбугатта коррупциядә гаепләнгән делегатлар?

Рәсми җавап әлегә юк, әмма һәрнәрсәдән хәбәрдар күршесе, полковник Халтаев бер атна чамасы элек җеп очын чыгарды. "Бер нәрсәне төгәл беләм,—диде ул,—моннан өч ел элек Әнвәр Абидович Тилләхаҗиев урынына килгән яңа секретаребыз шундый ук эшләр өчен җавапка тартылачак. Дөрес, аның колачы элеккегедән нык калыша икән".

Депешаны алгач, райком секретаре үзенә бәлки өлкә партия оешмасын җитәкләргә тәкъдим итәрләр, дип тә уйлап куйды. Әмма бу сизенүдә шатлык хисе юк иде. Их, моннан бер җиде ел элек тәкъдим иткән булсалар, дип көрсенеп куйды ул һәм кәгазьне сейфка яшерде. Самавыр кайнаганны көткән арада аның яңа вазифа турында уйлыйсы килми, хәтта Страсбургка бару да артык кызыктырмый иде инде. Һәм кинәттән, бөтенләй уйламаганда, көтмәгәндә дигәндәй, беренче тапкыр Көнбатыш Германиягә сәфәре исенә төште. Аукцион курорт сезонының иң кызган чагында Висбаден дигән шәһәрдә үткәрелгән иде. Шифалы суларда дәваланырга бөтен дөньяның акча капчыклары җыелган чак. Дөрес, ул мәшһүр Висбаденны түгел, ә бары тик Мәскәү аэропортына төшеп утырган вакытны гына исенә төшерде.

Очыш атна азагына туры килеп, ул депутат бүлмәсендә берүзе генә булып чыкты. Әмма ярты сәгатьләп телевизор янында вакыт үткәреп азапланган арада бүлмәне ниндидер шома егетләр басып алды. Иркен холлны алар күз ачып йомганчы яхшылап төрелгән тартмалар, әрҗәләр, төеннәр, бәйләм-бәйләм итеп бәйләнгән кавын тәлгәшләре белән тутырып та ташладылар. Ахырдан шулай ук яхшылап кәгазьгә төрелгән үтә зур нәрсәләрне кертеп куйдылар. Аларның артык сак кылануларына караганда, бу төеннәрдә ватылучан, уалучан әйбер булырга тиеш иде. Тагын бераздан бүлмәне искиткеч матур роза чәчәкләре тутырылган әрҗәләр күмеп китте. Депутат бүлмәсендә аларның баш әйләндергеч хуш исе чайкала башлады.

Мәхмүтов кизү торучы хатыннан башкалага берәр делегация-фәлән бармыймы дип белешеп карады. Тегесе исә ирен чите белән сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды һәм хөкүмәт членнарыннан берсенең баруын әйтте. Ерактагы башкалага ул һәрвакыт шундый багаж белән юл тота икән.

Очкычка утырыр вакыт җитте, әмма министр күренмәде, шул ук шома егетләр аның байлыгын күз ачып йомганчы самолетка төяп тә куйдылар. Аукцион турындагы уйларына бирелгән Булат Мөэминович хөкүмәт члены турында бөтенләй онытткан иде инде. Әмма ул тагын үзен искә төшерде, самолеттан трапны алган вакытта гына килеп җитте. Ул кәнәфигә чумуга лайнер очыш сызыгына килеп тә басты. Тагын бер ярты сәгатьтән хөкүмәт әгъзасы бөтен салонны яңгыратып борын сызгырта, "зур дәрәҗәләр биләүче" адәмнән тирә-якка авыр махмыр исе тарала иде.

Һава лайнерының тәгәрмәчләре җиргә тиюгә үк "бөегебез"нең күзләре ачылды һәм самолет аэропорт бинасы янына якынлаша башлауга ул пилотлар кабинасына чумды. Анда кораб командиры белән нәрсә хакында сөйләшкәннәрдер, анысы безгә нәмәгълүм, ләкин ул сер дә берничә минуттан билгеле булды.

Мәхмүтов тәрәзә янында утыра иде. Табигый ки, бинага якынлашып килүче самолетны каршы алырга ашкынган ун-унике кешелек төркемне абайламый калмады. Араларында таныш кешеләр да бар иде кебек. Республиканың Мәскәүдәге даими вәкиллегендә эшләүчеләр иде бугай алар. Әйе, нәкъ шулар. Кайчандыр вәкиллек кунакханәсендә төн үткәрергә туры килгән Мәхмүтов аларны шунда ук исенә дә төшерде. Каршы алучылардан бераз читтәрәк унлап хөкүмәт "Чайка"сы һәм алар арасына ниндидер могҗиза белән килеп эләккән "Мерседес" та бар иде. Һәм ул бу машиналарның нәкъ менә Ташкент рейсына мөнәсәбәтле икәнен дә аңлап алды.

Бер хөкүмәт әгъзасы өчен күбрәк түгел микән дип уйлап куйды Мәхмүтов, ләкин шикләре бик тиз арада таралды. Лимузиннар, чынлап та, Ташкент рейсын көткән булып чыкты.

Беренче булып траптан хөкүмәт әгъзасы төште, аңа каршы алучылар ташланды, ләкин ул аларның берсе белән генә сәлам алышты да калганнарына очкычның йөк бүлегенә

таба күрсәтте, аннан инде йөкне бушата башлаганнар, әрҗәләрне, тартмаларны, төеннәрне трап янына тәртип белән тезәләр, аларга йөкнең хуҗасы үзе җитәкчелек итә иде.

Бик саклык белән генә читкәрәк алып куелган сәер, серле әйберләр дә пәйда булды. Һәм кинәт ул серле төенчекләрнең берсен төргән кәгазьнең ертылганын күреп алды. Аның эчендә идәнгә куела торган зур ваза күренеп китте. Ләкин гаҗәпләндергәне ваза түгел, ә аның тышында сурәтләнгән кеше булды. Бәйрәм көннәрендә хезмәт ияләре портретын урамнарга күтәреп чыга торган ил җитәкчеләреннән берсе иде анда.

Багаж хуҗасы бу җитешсезлекне бик тиз күреп алды һәм вазаны тиз арада яңадан төреп тә куйдылар. Һәрбер тартмада, төендә һәм тюкта хат конвертын хәтерләтүче ак катыргы кисәге дә бар иде.

Мондый операцияләрне бер генә тапкыр башкармаганлыгы сизелеп торган “дәрәҗәле адәм”нең хәрәкәтләренә күз иярми иде. Чәчәкле тартмаларның берсен чыгарулары булды, ул аннан катыргы бирканы тартып алды, анда күчтәнәч алучының фамилиясе язылган икән, кычкырып фамилияне әйтте. Кара “Чайка” вәкиллек хезмәткәрләре янына килеп туктады, алары исә җитез генә багажникны тутырдылар, вазаны сакланып кына машина салонына тапшырдылар. Ак катыргы биркалар өзелә торды, чираттагы фамилия яңгырады, машиналар берәм-берәм бүләк өләшкән урынга килә торды. Боларның барысына алты-җиде минут вакыт китте. Бу сәер тантананың инде күптән гадәткә әйләнгәне сизелеп тора иде. Соңгы “Чайка”га хөкүмәт әгъзасы үзе дә утырды, аңа соңгы вазаны тапшырдылар. Күрәсең бу кыйммәтле бүләкне ул үзе тапшырырга һәм барып җиткәнче аны кочаклап утырырга тиеш иде.

Җентекләп оештырылган бу мәрәкәне салонның ул утырган ягындагы тагын өч-дүрт тәрәзәдән күзәтеп булыр иде, әмма самолеттан чыгарга чакыру көтеп, мазаланып утырган юлчылардан аңа игътибар итүче булмады.

Ләкин ул тагын бер кат ялгышты, самолетны югары түрәләрнең шәхси шоферлары гына көтми иде. Әгәр ул башын күтәреп бинаның икенче катындагы тәрәзәләргә күз салган булса, анда гражданский киемдәге ике елгыр кешене дә абайлаган булыр иде. Алары килеп туктаган һәр машинаны иплән кенә фотога төшереп баралар, моны исә ак катыргы кисәге ачылып, аннан югары дәрәҗәдәге түрәнең—юмарт бүләкләр алучының фамилиясе күренгән мизгелдә эшлиләр иде.

Ташкенттан алынган депеша аны уйларыннан арынырга мәҗбүр итте. Шунысы сөенечле, әле уйланырга тулы бер атна вакыт бар. Аның инде күптәннән үз тормышындагы, аеруча соңгы еллардагы вакыйгаларны бер җепкә тезеп, тәртипкә салып карыйсы килә иде.

Мияссәрә кайнап торган самавырны сакланып кына сәке янына алып килде.

—Сабыр ит, булышыйм,—диде ире һәм астыннан арык суы агып торган тәбәнәк сәкедән төште, самавырны ашъяулык өстенә—дастарханга алып куйды. Табын әзерләнгән өстәлне үзбәкләр дастархан дип атый.

—Бүген мин сезне танымыйм,—дип шаян елмайды Мияссәрә, иренә үзбәк гадәтенчә “сез” дип дәшеп.—Әллә перестройка дигән нәрсәләр безнең якларга да килеп җитте инде. Әгәр ул безнең ирләребезне шулай үзгәртә икән, мин аны ике куллап якларга риза.

—Карлыгачым минем, сәясәтне ирләргә калдыр инде. Әйдә, чәй салып җибәр, юкса тамагым кипте,—дип аның шаяруына кушылды хуҗа. Сәер, беренче хатыны белән мондый мөгамәлә мөмкин түгел иде. Ләкин аның шәрекъта аеруча кыйммәт бәяләнүче башка сыйфатлары бар иде. Зөһрә беркайчан да аңа каршы әйтмәде, беркайчан да аның эшләренә катнашмады. Үлүе дә сабыр, тыныч булды. Яман чир аны бер ай эчендә коры сөяккә калдырды, бернинди врач-табиблар ярдәм итә алмады.

Булат хатынының кулыннан хуш исле чәй салынган касәне алды. Һай Мияссәрә! Аның кулы тигән һәр нәрсә балкый, ялтырый башлый, ә чәй пешерүен әйтәсе дә юк! Мөгаен, мактаулы кытай вә япон хатыннары да аның осталыгыннан көнләшер иде. Өйдә урнашкан гадәт кагылгысыз, ничек кенә арыган булмасыннар, кичке, соңгы чәйне бары тик самавырдан гына эчәләр алар. Чәй янында шаян сүз куера, Булатның хатынына ягымлы, бернинди шаярусыз иркәләү сүзләре әйтәсе килә, әмма тагын үзен тыеп кала. Хатыныңны яратырга кирәк, әмма иркәләп бозарга ярамый. Өлкәннәрнең киңәше, васыяте шундый.

Һәм ул моннан унике ел элек көтмәгәндә Мияссәрәгә өйләнгән чакларын исенә төшерде. Икенче елын буйдак булып йөри иде инде. Малайлар үсеп җиткән, өчесе дә

Ташкентта укыйлар. Ләкин өйдә дә, бакчада да эш тавык чүпләп бетерерлек түгел. Үзен тәрбияләп торуга, унайлыкларга өйрәнгән Булат хатынын югалтуны бик авыр кичерде. Шәрекъгә ялгыз яшәгән ир-атны өнәп бетермиләр, шунлыктан монда буйдаклар юк диярлек. Бигрәк тә яшьрәкләр арасында. Шуңа күрә аның шәхси тормышы күпләрнең күзенә шырпы булып керде бугай. Ни әйтсәң дә райком секретаре бит. Шәрекъгә күп нәрсәгә күз йомарга мөмкиннәр, әмма әхлак мәсьәләсендә, йолаларны саклауда беркем дә битараф калмый.

Дөрес, кыз-кыркынның, хәтта бик яшьләрнең дә үзенә игътибарлы караш ташлауларын сизми түгел. Әмма алардан берсе дә ул көткән кеше булып чыкмый, җан тартмый иде. Буйдак булып күпме йөргән булыр иде, билгесез, әмма очраклы рәвештә бер туйда катнашу аның тормышында барысын да пыран-заран китерде дә ташлады. Нык кына соңарып, инде кәләшне алып кергән вакытта гына килеп җитте ул. Туйның иң кызган чагы, кәләшнең ахирәтләре бер-берсен алыштыра-алыштыра кунаклар алдында бии башлады. Кияү йортындагы ыгы-зыгыны күз алдына китерерлек түгел. Шунлыктанмы, аны тиз генә күреп алмадылар, хәер, ул үзе дә бик күзгә ташланырга теләми иде. Сиздермичә генә биючеләр арасына үтте дә, соклануына тыела алмыйча дәртләнеп кул чабарга тотынды. Кәләшнең дус кызларыннан берсе—шәһәрчә киенгәне—аеруча тырыша иде. Аның сыгылмалы, дәртле хәрәкәтләренә күз иярми. Табигый ки, иң көчле алкышлар да аңа яңгырады.

—Искиткеч, шаккатмалы хәл, борынгы көйләрне никадәр нечкә тоемлый икән бу кыз!—диде ул янында басып торган кешеләрнең берсенә.

—Чынлап ошыймы? Ошаса яучы җибәрергә соң түгел әле,—диде әңгәмәдәше кинәт җитдиләнеп.

Ул югалып калды, ничек җавап бирергә дә белмәде. Шул арада аны хуҗалар күреп алды. Шәрекъгә туйлар таңга кадәр дәвам итә, һәм шулай итеп, соңга калган дәрәҗәле кунагыбыз иртәнгә хәтле рәхәтләнеп күңел ачты, киткәндә ул инде күзенә ташланган кызның Мияссәрә исемле булып, яучы җибәрергә тәкъдим иткән кешенең бу кызга әтисе ягыннан туган тиешле икәнлеген дә белә иде инде.

Үзбәкләрдә кияүгә бик иртә, унҗиде-унсигездә үк чыгалар, ә егерме дүрт яшьлек Мияссәрә, күпләр уйлаганча, сазаган кыз санала иде инде. Табигый ки, кызның әти-әниләре, туганнары Мияссәрә язмышы өчен чын-чыннан борчылалар, гаиләдәге иң сөйкемле баланың язмышы алар өчен әрнеткеч ярага әйләнгән иде. Еллар үтә тора, кияүләр күренми. Район җирендә һәр егет исәптә. Бәлки яучы җибәрү турында сүз каткан аганың фикер төбендә нинди дер яшерен мәгънә дә булгандыр.

Шәрекъгә өйләнү үтә дә четерекле, нечкә эш. Мәхмүтов тә тәкъдим ясарга ашыкмады. Кире каксалар нишләрсең? Бу инде синең авторитетың өчен урамда күсәк белән орудан да яманрак булачак. Шул ук вакытта башкалар ярдәменә дә таянырга теләми иде. Бер-ике тапкыр Мияссәрә эшли торган культура йортына барып кайтты. Шәхси мәсьәләләр турында сүз кузгатмасалар да, райком секретареның юкка килмәгәнлеген, аның игътибарының культура учагына юнәлтелмәгәнлеген кыз бала аңламый калмады, әлбәттә.

—Сез килеп йөри башлагач, безнең культура йорты чып-чынлап чәчәк ата башлаган иде,—Мияссәрә әле хәзер дә шулай дип шаяртырга ярата. Аның онытканда бер дигәндәй, сирәк-мирәк кергәләп йөрүен "кыз белән йөри" дип әйтеп тә булмас иде, ләкин Мияссәрәнең хәтерендә болар барысы да нәкъ менә аның янына килеп йөрү, аерым игътибар булып саналган икән.

Мондый килеп-китеп йөрүләр күпмегә сузылыр иде, билгесез, әмма монда да хәлиткеч рольне галиҗәнап очраклылык уйнады булса кирәк. Район партия конференциясенә әзерләнеп йөргән көннәр иде ул. Табигый ки, культура йортын тиешенчә бизисе, әзерлисе бар. Һәм Мияссәрәгә көн саен диярлек райкомга, димәк ки, аңа—секретарьга шалтыратырга, киңәшергә туры килде. Райкомнан башка гына күп мәсьәлә хәл ителерлек түгел. Шундый сөйләшүләрнең берсеннән соң ул үзе дә аңламый калды, трубканы куяр алдыннан хыялындагы яшерен серне кинәт кенә ярды да салды:

—Мияссәрә, ә сез миңа кияүгә чыгар идегезме?

—Сез нәрсә, бөтен эшне шулай телефоннан гына хәл итәсезме?—дип гаҗәпләнде Мияссәрә.

Ул бер мизгелгә телсез калды, кызның үз өстеннән шулай ярым шаяртып көлүен көтмәгән иде. Һәм аны бары тик шул шаяру гына коткара ала да иде инде.

—Әйе, шулайрак шул, сезгә кызлар белән мөнәсәбәтнең кабинет ысулы ошыймы? Хәзер бик күпләр язмышларын компьютерларга, никахлашу конторалырына тапшыра дип сөйлиләр. Миңа менә телефон да җитә.

—Кызык, сез дә заман рухында эш итәсез, прогресстан артта калмыйсыз икән,—дип көлеп җибәрде Мияссәрә.—Тиешенчә ячылар җибәрсәгез, бәлки уйлап карармын... Миңа калса, сезнең ышанычыгыз юк түгел кебек...—диде ул иркәләнгәндәй иттереп. Аңлаган кешегә аңларлык сүзләр иде.

Озакламый алар тыйнак кына туй үткәрделәр, котларга туган-тумача да якын танышлар гына җыелды. Шәрекъта икенче тапкыр өйләнүне артык кумпайтмыйлар. Яңа гаиләсеннән уңды ул, Мияссәрә белән аңлашып, дус яшиләр. Еш кына ул үзенең яшьләрчә дәртле, дәрманлы булуын хатынынннан күрә. Чөнки Мияссәрәгә көчле, үз бәясен белүче, җиңел сөякле булып күренәсе килә, ә бернигә карамастан, шат күңел саклау, үзеңнән көлә белү кебек сыйфатлар Мияссәрәдән күчте. Элегрәк ул шаяруларны кабул итми, аларны җитәкче кешегә килешми дип саный иде.

Ике уллары, Хөсән белән Хәсән үсеп килә, әле менә икесен дә "Артек"ка җибәрделәр.

—Кәефең күтәрелер көннәр дә булыр икән,—диде Мияссәрә чәй сала-сала,—атна буе сөмсерең коелып йөрдең. Начальниклар өчен авыр вакытлар житте шул. Халыкның рәнҗеше чиктән ашкан, бөтенесен чыгарып селкергә ашыгалар, әйтә алмый калырмын дип куркалармы. Еллар буе телсез-чукрак булып яшәгәч, кешечә аңлаша да алмый башладылар бугай.

—Әйе, заманасы...—дип башлады ул, әмма нилектәндер тукталып калды.

—Гластность заманасы,—дип исенә төшерде Мияссәрә яңа чыккан урыс сүзен һәм тыйнак кына көлеп куйды.—Истә калдырырга вакыт, үзгәртеп кору башланганга дүртенче ел. Алай-болай трибунада чакта оныта күрмә тагы, анда әйтеп торучы табылмас. Гафу итмәсләр үзеңне.

—Онытмам,—дип шаяртты Мәхмүтов.—Анда мин һәрвакыт кәгазьдән укыйм бит.

Әмма бу шаярту һавада асылынып калды. Мияссәрә дә, Булат Мөэминович та сүзне дәвам итәргә ашыкмадылар.

—Үзгәртеп кору... хәбәрдарлык...—диде ул бик озак торганнан соң уйчан гына.—Мин кем соң, мин бит башкалар ихтыярын башкаручы гына. Очы белән күккә терәлгән пирамиданың нигезендәге бер таш, чыгырдагы винтик. Миңа кирәк хәтлесен генә белгертәләр.—Ул бушаган касәне хатынына сузды һәм тагын дәвам итте.—Мин үземне хатадан хали, гаепсезмен дип әйтергә җыенмыйм, ләкин шунысын да онытмыйк, бер генә чара да югарыдан күрсәтмә булмыйча эшләнми, иң вак детальләренә хәтле өстәгеләр белән килештерергә туры килә. Хәер, болар гына миннән җаваплылыкны төшерми төшерүен. Шәхси хуҗалыклардагы мал-туарны бетерүне мин уйлап чыгардыммы, йөзем бакчаларын мин кистеммe, яшелчә түтәлләренә, нәниләрнең уен мәйданчыкларына мамыкны мин чәчтемме? Йөз меңнәрчә шәһәр кешеләрен кар төшкәнче мамык басуларында мин тотаммы? Халыкны бутифос белән мин агулыйммы? "Ярамый", "тыела", "рөхсәт ителми", "кушылмаган" кебек меңнәрчә боерыкларны мин бирәмме?!

—Сездән дә бирелә шул,—дип куйды Мияссәрә. Ләкин Булат Мөэминович инде аны ишетмәде, кемдер тыңлыймы-юкмы, анысы мөһим түгел, ул бары сөйләргә, эчен бушатырга кирәклеген генә белә иде инде, иреннәре арасыннан җавапсыз калачак кәлимәләр агылды да агылды.

—Халык мине власть, дип саный, миңа ышана. Барысы өчен дә мин җаваплы янәсе. Өстәгеләр дә төртеп күрсәтеп тора, әнә, имеш, ул аңлап җиткермәгән, таякны артык бөккән...

—Ни дисең, Аллаһы Тәгалә сезне шулай үҗәт һәм тырыш итеп яраткан инде,—дип куйды Мияссәрә. Ләкин ул аның төрттерүен колагы яныннан гына үткәреп җибәрде. Иң мөһиме күңелдәгесен әйтеп бетерү иде, чөнки мондый сүзләрне трибунадан сөйли алмыйсың.

—Әйе, без инде хәзер винтик булырга теләмибез,—дип житди генә әйтеп куйды Мияссәрә.—Ләкин, үзегезне ул хәтле гаепләргә ашыкмагыз, безнең район өлкәдә начарлардан түгел. Тилләхаҗиевны кулга алганнан соң иске гвардиядән үз вазифасын саклап калган бердәнбер кеше дә сез. Димәк, яңа җитәкчеләр дә сезгә ышана.

Ул бик озак кына эндәшми утырды һәм тагын әйтеп куйды:

—Мондый әңгәмәгә тартканым өчен гафу ит, хатынының күкрәгенә ятып елаган ир-атны аңламыйм, ә яхшы сүзләрең өчен рәхмәт. Әйе, күп нәрсәдә гаепледермен. Шунысы әйбәт, сине үз эшләремә катыштырмадым.

—Юкка,—дип аның сүзен бүлдерде хатыны.—Обком секретаре булмагае, хет патша булсын, әмма Әнвәр Тилләхаҗиев белән дуслыгыгыз миңа ошамый, дип бер генә тапкыр әйтмәдем ләбаса. Үлгән атасының сөякләренә дә тынгылык бирмәгән бит, уйласаң чәчләрең үрә торыр, кабердә ун пот алтын яшереп сакласын әле. Ә халыкка Коръән хәдисләре белән яшәүче саф мөселман булып күренмәкче, дога укымыйча өстәл янына да утырмаган, дип сөйлиләр. Өлкәнең ата коммунисты изге булган, имеш.

Мәхмүтов чын күңелдән көлеп җибәрде. Аның болай тугарылып, озаклап көлгәнен Мияссәрәнең күптән ишеткәне юк иде инде. Иренең көлүе аны сөендерде сөендерүен, әмма ул аның сәбәбен аңлап бетермәде һәм үпкәләгәндәй сорап куйды:

—Әллә берәр нәрсәне ялгыш әйттемме?

—Юк, кадерлем, кызганычка каршы, барысы да шулай шул. Мин бары тик Тилләхаҗиевны күз алдына китердем. Синең ни әйткәнеңне ишетсә нишләр иде икән? Вәт котырыныр иде. Аның серкәсе су күтәрмәгәнен белмисең бит.

—Беләсем дә килми. Тупас, икейөзле кеше ул. Кәефеңне бозмас өчен сөйләгәнем генә булмады, район үзешчәннәрен Заркентка алып барганда бию ансамблендәге ике кызга күзе төшкән. Ике ялагаен, Халтаев шикеллерәк бәндәләрен җибәргән. Мин җилнең каян искәнен бик тиз аңлап алдым, хәер, ул наданнар яшереп тә тормадылар, мескен кызларга аеруча хөрмәт, хәерхаһлык күрсәтәләр имеш... Мин аларның кулларын кыскарттым, кыланышларыгыз хакында Мәскәүгә язам, дигәч, шыр җибәрделәр тагы. Аларны Ташкент белән генә куркытып булмый. Анда барысы да дуслары, әшнәләре. Җае килсә, ул уйлап та тормыйча хәтта Рәшидовның үзенә аяк чалыр иде.

—Андый нияте бар иде аның,—дип раслады Мәхмүтов һәм тагын көлеп куйды.—Ул да сине бер күрүдә яратмады, кемгә өйләнәсең, дип теңкәмә тиеп бетте. Шәрекъ кызлары кебек алдыңда бөтерелеп йөрмәгәненә ачуланма, яшь бит әле, өйрәнер, житмәсә мондый олы дәрәҗәле кешене беренче тапкыр күрүе, дип чак котылдым...

—Мондый да ялагай икәнегезне белми идем әле,—дип көлеп куйды Мияссәрә. Баһадир гәүдәле ире янында бөтерелүче, ачуыннан шартларга житкән Кәтүк күз алдына килде.—Мин беренче күрүдән үк кем икәнен белгән кебек, ул да мине беренче күрүдән үк таныган икән. Нишләп соң киңәшенә колак салмадыгыз?—Мияссәрә елмаеп иренең күзләренә карады.

—Бәлки самавырны яңартып җибәрербез, җырлап утырганда күңеллерәк бит,—диде Булат. Аның хатыны белән башланган бу сөйләшүне туктатасы килми, чөнки инде байтактан болай ачылып сөйләшеп утырганнары юк иде. Һаман эш тә эш, эш тә эш... Кунак-төшем, бала-чага кайгысы... Вакыт житкереп булмый. Шушылай каракаршы утырып гәпләшүгә ни житә... Бүгенге чәй эчү Мияссәрәгә дә ошый иде булса кирәк, ул да җиңел генә ризалашты. Булат сикереп торып самавырга ябышты.

—Ярдәмчем минем,—дип пышылдады Мияссәрә һәм аннан читкәрәк тайпылды.

Төн, тынлык, якындагы һәм ерактагы дуваллар артында бер-бер артлы утлар сүнде, хәтта Халтаевларның һәрчак шау-шулы ишегалдыннан да тавышлар ишетелми иде инде.

—Беркем дә комачауламый, ничек рәхәт,—дип куйды Мияссәрә.—Юкса, өйгә керергә өлгермисең, әле аннан, әле моннан чапкын килеп житә, райком дежурные сугыла, йә булмаса ашыгыч депеша китерәләр. Табын янына гына утырасың, безнең дастарханга берекәән диярсең, дустың Халтаев пәйда була, койма ярыгыннан карап торган диярсең... Мин инде сезнең тавышны оныта башлаган идем. Беренче тапкыр туйганчы сөйләштем ичмасам.

—Син хаклы, Мияссәрә, без тормышыбызда нәрсәнедер югалтып барабыз бугай. Гафу ит, бу минем сине санга сукмавымнан түгел, әллә нинди борчулы, ыгы-зыгылы заманда яшибез. Өйгә кунакханәгә кайткан кебек йокларга гына кайтам, монда да ялгыз калырга ирек бирмиләр, яткан ятагыңа диярлек килеп керәләр бит. Әле Зөһрә исән чагында ук безнең өй райком филиалына әйләнгән иде инде, кич димиләр, төн димиләр, киләләр дә керәләр. Әйтерсең, мин тере кеше түгел, миңа да ял итәргә, гаиләм, балаларым белән аралашырга кирәк түгелмени?! Мондый кичләрне ешрак булдырыр өчен нәрсәнедер үзгәртергә кирәк булыр.—Мәхмүтов әллә нишләп кенә дулкынланып куйды.

—Рәхмәт. Бик тә яхшы булыр иде... балалар белән... бөтен гаиләбез белән кич

утырулар,—дип хыялларына бирелгәндәй сузып кына әйтеп куйды Мияссәрә.

—Беләсеңме,—дип елмайды Булат, аның кәефе күтәрелгән иде,—үз йортыңда теләсә нинди конференцияләргә, пленумнарга, тагын әллә нинди сүз боткасы куерткан җирләрдәгегә караганда күбрәк нәрсә ишетеп була икән. Сүз уңаеннан, бездә әллә нинди фәнни-тикшеренү институтлары тулып ята, ә Америкадагы Гэллап институты кебек иҗтимагый фикерне өйрәнүче оешма юк. Юкса, безнең матбугат даими рәвештә аларның мәгълүматларыннан файдалана. Андый оешмадан башка гына дөньяны күзаллавы, дөрес карарлар кабул итүе бик читен бит. Бер чиктән икенче чиккә ташланмас өчен монда да, Мәскәүдә дә шундый оешма булдыру зарур. Ул сулар һава кебек кирәк. Әгәр андый оешма булса, мин сиңа аның бездәге вәкиле вазифасын ышанып тапшырыр идем. Синең бик әйбәт килеп чыгар иде ул.

Мияссәрә дәшми, яңакларына йөгергән алсулыктан аңа бу сүзләрнең ошаганын гына чамаларга була.

Көтмәгәндә Мәхмүтовның күзе сәгать телләрен шәйләп алды, вакыт соң иде инде. Хәер, бу йортта беркайчан йокларга иртә ятмыйлар анысы.

—Соңлаганбыз, кадерлем, соңлаганбыз без бүген, ә миңа иртәгә "Коммунизм" колхозына барасы. Шофер Госман таң тишегеннән килеп керер, син торып азапланма, юл уңаеннан берәр чәйханәгә сугылырбыз, чәйне шунда гына эчәрбез. Кызыл күпер янында, су буендагы чинарлар астына сыенган шундый бер чәйханәне беләм мин. Берәр җаен табып сине дә алып барырмын әле. Безнең районда аннан матур башка җирне мин белмим.

Булат хатынына ярдәм итмәкче булып урыныннан күтәрелде, әмма Мияссәрә ягымлы елмаеп аны туктатты:

—Мәшәкатьләнмә, мин үзем,—диде ул.—Йокы алдыннан бар, саф һава сулап кил, ә урынны мин, әйткәнеңчә, монда, ачык һавада, сәкедә генә җәярмен.

Булат Мөэминович җилкапканы ачып урамга чыкты да күкрәк тутырып кичке һаваны сулады. Төнге урам буп-буш, күк йөзендәге тулган ай нуры аны буеннан-буена җете ачык төсләргә манган. Тынлык. Бакчалар яныннан чылтыраучы арык тавышы күңелле музыка булып яңгырый. Мәхәллә инде байтактан, моннан ун-унбиш еллар элек үк төзелеп беткән иде. Бөтен җир куе яшеллектә. Дәрәҗәле район бу. Төзелеш өчен җирне теләсә кемгә бирмәделәр. Күптәнге йола буенча, һәркем өе каршындагы юлны карап тора, арыктан су сиптерә, кичләрен берничә тапкыр су сибүчеләр дә бар. Шунлыктан, һава җиләс, сулыш алулары иркен. Ә Мәхмүтовның башыннан өйдә булган сөйләшү китми, әле ул үзен һаман хатыны белән гәп куерткандай хис итә иде.

—Менә сиңа Мияссәрә!—дип куйды ул соклануын яшерә алмыйча.

Хәтерендә тагын истәлекләр яңарды. Моннан җиде еллап элек булыр, нәкъ менә шушындый җәйге кичләрнең берсендә, соңлап кына туйдан кайтып килешләре иде. Кәефләре әйбәт, рәхәтләнеп ял иттеләр, күңел ачтылар. Хәсән белән Хөсәнне тапканнан соң Мияссәрә тагын да чибәрләнеп киткән иде. Ул чибәрлек күпләрнең күзенә ташланган икән, туйда да шулай булды. Биергә чыккан Мияссәрәдән ир-ат халкы күзен алмады диярлек. Яңа өлгереп җиткән, менә-менә кияүгә чыгарга торган кызлар да аның янында төссезләнеп, ямьсезләнебрәк калды кебек.

Юл буе алар яшь вакыттагыча шаярышып, көлешеп кайттылар. Мияссәрә хәтта арттан берәрсе килми микән дип берничә тапкыр борылып карарга мәҗбүр булды.

—Берәрсе ишетеп торса, райком секретарыгыз бигрәк бала-чага кебек кылана ди күрмәсеннәр тагын,—диде ул.

Шул чакта Булат ярымшаяртып сораган иде:

—Син нишләп миңа, тол калган иргә кияүгә чыктың соң әле?—дигән иде. Җавапка ул сез бит яшьләрдән дә яшьрәк, әнә туйда ничек барысын да уздырып биедегез кебегрәк шаян сүз ишетергә теләгән иде. Әмма Мияссәрә дулкынлануын тыя алмады, сорауны тагын ишетергә теләгәндәй, кабатлап куйды:

—Нишләп мин сезгә кияүгә чыктым?—һәм уйлап та тормыйча, инде байтактан күңелендә әзер җавап йөрткәндәй, бер тында әйтте дә салды:—Чөнки сезне халыкта Күпер Булат дип йөриләр.—Һәм аның бу сүзләрне аңлап җиткермәвеннән курыккан кебек, ашыгып тезә башлады:—Сез беренче тапкыр мәдәният йортына килеп кергәч, моның нәкъ менә минем янга килү икәнен бөтен күңелем белән аңлап алдым мин. Ул чакта әле алга таба ниләр булыр дигән нindидер уйларым, өметләрем димме, берсе

дә юк иде, ләкин шулай да, сезнең килү мине бик дулкынландырды, мин сезнең икенче тапкыр килүегезне көтә башладым. Һәм кинәт кенә телефоннан ясалган тәкъдим. Ул мине сөендерде дә, куркытты да. Никадәр генә кыю булып, заманча булып күренмим, миндә дә бит шәрекъ психологиясе, әле дә ул йөктән арынып җитә алганым юк, шул ук вакытта мин үз язмышымны үзем хәл итәргә хакым юклыгын да белә идем, сезнең кебек дәрәҗәле кеше белән язмыш җепләрен бәйләү мәсьәләсендә бигрәк тә. Бөтенесен дә гаилә җыелышы димме, туган-тумача хәл итте. Берәүләр яклады, икенче берәүләре каршы төште, бәхәс кызып кына килгән чагында кышлактан бабам Сәгъдулла килеп төшмәсә, бәхәснең ничек бетәсе дә билгеле түгел иде. Ә бездә бабай сүзен аяк астына салмыйлар.

Дөресен әйтим, безнең гаиләдә сезнең кушаматны белмиләр иде. Шул чакта бабам алар кышлагында ике күпер төзегәнегезне, Делбер суы аркылы күпер булмаганлыктан ничек иза чигүләре, яз саен ташуның күперне алып китеп җәфалавы турында сөйли башлады. Ә сез төзегән күперләр һаман тора, иң куркыныч ташуга да бирешмиләр икән. Шулай ук күрше кышлакта сез төзегән күпер турында да тәмләп сөйләде. Өмәгә барган булганнар икән. Күпер салу җиңел эш түгел шул. Карасу елгасында, "Коммунизм" колхозында салынган зур һәм иң матур күпер хакында да бәйнә-бәйнә әйтте. Иң яраткан күперегез булып, аны нык мазаланып, зур авырлыклар белән салгансыз, ди. Әле шуның өчен чак кына эштән дә алмый калганнар, имеш.

Сәгъдулла бабам сез майтарган эшләр турында, сезнең үзегез хакында шулкадәрле кабынып, яратып сөйләде, миңа калса, туган-тумача монда ни өчен җыелганын да оныта башлаган иде инде. Сүзен бабам мондый сүзләр белән төгәлләде:

—Әгәр оныгыма яучыны шул Күпер Булат җибәргән икән, мин каршы түгел. Ә инде өлкәнрәк дисәгез, зыян юк, минем әтиемнең дә икенче хатыны яшь иде, Аллага шөкер, биш бала, шул исәптән, мине дә тәрбияләп үстерделәр. Күперне ышанычлы, төпле кешеләр генә сала ала, шикләнмәгез.

Шулай итеп сезнең белән минем язмыш хәл ителде дә куйды.

Күңел төбеннән калкып чыккан бу хатирәләрне искә төшерү аңа рәхәт иде һәм ул авыз эченнән генә "Күпер Булат" дип куйды.

"Әгәр миннән җир йөзендә нәрсә дә булса кала икән, алар шул күперләр булыр да ахрысы",—дип фикер йөртте ул. Күперләр турында уйлану аңа күңел рәхәтлеге бирә, күперләр, юл үткәргечләр, акведуклар, дренажлар үзенең гомерлек мәхәббәте, яраткан нәрсәләре булыр дип ул кайчандыр башына да китерми иде бит.

Әле райкомга эшкә кучкач тә үзенең төзелеш бүлегенә эләгә алмавына үкенгән иде, анда ул барыбер шул күперләр белән бәйле булыр иде. Әмма вакансия пропаганда бүлегендә генә иде. Әле дә исендә, ул үзе төзи башлап та тәмамлый алмыйча китәргә мәҗбүр булган күпер төзелешенә качып-посып диярлек көн саен барып йөрде, объектны сафка тапшырганчы яңа прорабка киңәшләр биреп торды. Ул чакта аңа бу тормышындагы соңгы күпер булып тоелган иде.

Ләкин, бәхеткә, барысы да башкача килеп чыкты. Бервакыт аңа инде пропаганда бүлеге мөдире булып эшләгән чагында тау битендә урнашкан еракта бер кышлакка барырга туры килде. И ул якларның матурлыгы! Нәкъ менә мактаглан Швейцария күренешләре инде. Әмма барган чакта шофер бик ерактан уратып барды, ул әйткәнчә, бердәнбер күперне ташу алып киткән икән. Ул күпер булган урынны күрсәтүләрен сорады. Бер тапкыр күз ташлауга ук күпернең бу урында беркайчан да нык булмаячагын да аңлап алды. Һәм менә шул чакта анда яңадан күпер салучы җене уянды да.

Райкомда да, өйдә дә көтүләренә карамастан, ул колхозда калды һәм өч көн буе колхоз җитәкчесен яңа күпер төзергә үгетләде, бик яхшы урын тапканлыгын, проектны да бушка, бернинди волокитасыз үзе әзерләп бирәчәген әйтте, авылда җыен җыеп, тәки халыкны үз артыннан ияртте. Шулай итеп, көзгә беренче күпер әзер дә булды. Әнә шул чактан башлап, ерак кышлакларда күперләр, акведуклар, оригиналь юл үткәргечләр салу гадәткә керде.

Вакытлар үтеп ул райком секретаре вазифасында расланганда халык аның нәрсәгә хирыслыгын бик яхшы белә иде инде. Беренче эше итеп ул юл идарәсендә эшләүчеләрне куып таратты, анда эшен яхшы белгән кешеләр пәйда булды. Район биләмәләрендә кечү-күпер булмаган кышлак калмады, шуның өстенә, күперләр вә гайре җайланмалар хыялны эшкә җигеп, чын-чынлап яхшы зәвык белән эшләнә иде. Эштән алуга сәбәп була язган Карасу күперенә килсәк, аның хакта хәтта

"Архитектура" журналында һәм кайбер башка махсус басмаларда мактап язып та чыктылар, өлкәгә килгән туристларның фотоаппаратлар асып күперне карарга килүе бер йолага әверелде.

"Иртәгә Карасуны күрермен,—дип уйлап куйды ул һәм аңа алдагы бу очрашуны көтүдән тагын рәхәт булып китте.—Кирәк бит, Кызыл күпер..." Уйлары Мәхмүтовны тагын әллә кайларга алып кереп китте. Бу исем күпергә очраклы рәвештә ябышып калса да, аны беренче булып кем шулай әйткәнен ул хәтерләми, ләкин мәгънәсе чынчынлап дөрес иде. Күпернең терәк баганаларына кызыл төстәге таш сайлаганда әле ул халыкның күперне дә кызыл дип атаячагын башына да китерми иде. Туристлар исә күпер атамасында үзләре аңлаганча ниндидер тирән революцион мәгънә эзлиләр. Хәер, кем белә, бәлки, күпер бу якларда яңа тормыш башлануын белдерүче символ буларак кабул ителәдер дә.

Булат рәшәткә тотылган тәрәзәләре шар ачылган ташпулатлар яныннан акрын гына атлый бирде. Тау итәгеннән исүче талгын җилдә кичтән мул итеп су сибелгән яфраклар лепердәшә. Алар арасында да үзгә тавышлар бар. Күккә ыргылган көмешсыман тирәкләрнең эре яфраклары шавында үзгә мәгънә, үзгә яңгыраш, ниндидер көй бар. Аларны инде бернинди бүтән шау-кыштырдау белән дә бутый алмыйсың. Кичке салкынча һава тәэсир иттеме, Булатның бөтен тәне рәхәт иңрәү белән сулкылдый, йокыны кул белән алып ташладылармыни.

Һәр өй янында диярлек арык буендагы агач асларында эскәмия, арада арка терәве куеп ясалган бик уңайлылары да очрый. Алар йә койма, йә биек тимер капка төсенә буялган, кайберләрендә хуҗалары онытып калдырган, көрпәч дип йөртелүче мендәрчекләр дә очрый. Карагай бүрәнәләрдән юнып, ун-унбиш кеше рәхәтләнеп сыярлык итеп ясалган олы эскәмия аеруча күзгә ташлана иде. Арыкка терәлеп диярлек торган бу утыргыч, әйтерсең, узган-барган юлаучыларны ял итәргә чакыра. Булат та ирексездән сүзсез чакыруны кабул итте һәм эскәмиягә чүмәште. Әмма кесәсендәге сигаретка тыгылыр алдыннан балакларын сызганып, аякларын талгын челтерәүче арык суына батырды. Озын-озак эссе көндә җылынган су инде суынырга өлгергән, таманча салкынлыктан тәндәге бөтен күзәнәкләргә рәхәт сулкылдау тарала иде. Күзеңне йом да, таңга хәтле изрәп утыр... Күрше йортлар янындагы буш эскәмияләргә күз төшерәтөшерә ул инде бик еракта калган студентлык еллары хатирәләренә бирелде.

Мәскәүдә уку насыйп булды аңа. Мәскәү елгасы аръягындагы бистәдә торды. Анда да илленче елларда нәкъ менә мондагы кебек бер-ике катлы йортлар, һәрберсе янында диярлек бакча, капка төпләрендә эскәмияләр иде. Аннан соң аңа Оренбургта өч ай буе диплом практикасы үтәргә, Җаек суы аша күпер салуда катнашырга туры килде. Торыр бүлмәне ул шулай ук шәһәрнең борынгы сәүдәгәрләр төбәгендә, Аренда дигән бистәдә тапты. Анда гел татарлар гына яши һәм ул торган урын үзбәкләрдәге шикелле үк мәхәллә дип атала иде. Әле хәзер дә хәтерендә, аны Заһид хәзрәт мәхәлләсе дип йөриләр иде. Кичләрен ул "Топольләр" дип аталган паркка йөрергә чыга торган иде.

Арык ярлары буена утыртылган көмешсыман тирәкләрнең яфраклар шавы аңа нишләптер ерак Оренбургта калган, бер башы белән далага барып тоташкан паркны хәтерләтте.

Акрын гына челтерәүче талгын су сигарет төтенен үзенә тарта, агым белән ярышырга теләгәндәй сыек төтен арык өстендә тибрәлә, әмма көчләр тигез түгел, агым су акрын гына аны йотып бетерә бара. Буш эскәмияләр кызыклы чагыштыруга китерде. Мондый гаҗәеп төндә Мәскәү бистәсендәге эскәмияләрнең, табигый ки, әгәр исән булсалар, буш булуы шикле. Кайчандыр ул яшәгән Оренбургтагы Аренда бистәсендә дә шулайдыр. Һәр икесендә эскәмияләр гашыйкларның кавышу урыны иде. Монда да биек дуваллар артына поскан һәр йортта Ромео белән Джульетта яшендәге егет-кызлар яши, әмма хәтта исерткеч хуш ис чыгарып миндаль чәчәк атканда да, алмагачлар ак күбеккә баткан сихри төннәрдә дә мондагы эскәмияләр буш булачак. Чөнки монда башка йола, башка гадәтләр, башка әхлак кагыйдәләре. Монда гашыйкларның таңны бергә каршылауларын очрата алмассың. Һәм ул үзенең сирәк-мирәк культура йортына кергәләп йөрүен очрашу дип атаган Мияссәрәне исенә төшерде. "Тагын райком гаепле" дип елмаеп куйды һәм урыныннан күтәрелде, әмма арык яныннан китәсе килми иде.

"Сәер төн, нишләптер күзгә йокы керми—дип уйлап куйды ул өйгә таба

кузгалганда.—Юкса, көн нинди авыр булган иде бит. Бөтен мәхәлләне диярлек йөреп чыктым. Элек Мәскәү бистәсендә яисә Оренбургта каравылчылар шакылдавык тотып шулай төне буе кварталдан кварталга йөри торганнар иде. Мин дә бүген авылдашларымның төнге йокысын саклаучы булдым бугай".

Күзгә йокы кермәү, тамырларында уйнаклаган көч вә дәрман аны чыннан да гаҗәпләндерә иде. Юкса, кичә генә йокысыз авыр төн үткәргән иде. Төне буе бер үк төш кереп җәфалады. Имеш, ул үзенең яраткан Карасу күпере буйлап ашыга, кулларында чәчәк бәйләме, каршы ярда аны Мияссәрә көтеп тора, кул изи, ашыктыра. Әмма күпернең уртасына килеп җитүгә күпер җимерелә һәм ул аста ургылучы Карасуның саргылт дулкыннары кочагына оча. Болар барысы да акрынайтылган кино күренешләре сыман кабатлана, ул куркудан чалшайган йөзне дә, артка каерылган кулны һәм ычкынып киткән чәчәк бәйләмен дә күрә, хәтта тирән һәм шау-шулы тарлавыктан ургылып тауларга кадәр барып җитүче, кыялар арасында бәргәләнүче коточкыч курку авазын—кайтавазны да ишетә. Ул салкын тиргә батып уянды, бернәрсә дә аңламыйча өстенә ишелеп төшкән күренешләрне алып атарга теләде, әмма яңадан бастырылып йоклап китте, яңадан астында җимерелеп баручы күпер сайгаклары буйлап Мияссәрәгә каршы атлады. Бары тик таң атканда гына авыр йокыга талды.

Өйгә җитеп килгәндә генә тагын бер нәрсәгә игътибар итте: төнге мәхәллә буйлап ике сәгатьләп йөрүгә карамастан, бер генә патруль мотоциклы да, кизүлектә йөрүче бер генә милиционер да очрамады. Югыйсә, Халтаев никадәр ышандырган иде, имеш Раимбаев дигән бәндәне кулга алганнан соң район көнен дә төнен дә милиция тарафыннан җентекләп саклана. Дөрес, бер атна чамасы элегрәк ул өйләдән соң мәхәлләне карап йөрүче гражданский киемдәге ике кешене очраткан иде анысы. Һәм аның уйлары тагын яңа проблемаларга кереп китте.

Республикада Мәскәүдән тикшерүчеләр эшләвен, аларның мамык, каракүл, анаша сатып баеган, ришвәткә һәм вазифа җинаятьләренә баткан яшерен миллионерларны дер селкеткәнен ул яхшы белә иде, хәер, ул беркемнән дә сер түгел иде инде.

Бик күпләрне тәшвишкә төшергән көннәр иде ул, дәрәҗәле кешеләрнең байтагы тыныч йоклый алмый, бәлане кайсы яктан көтәргә белми интегә. Шул ук вакытта оешкан җинаятьчелекнең Урта Азиядә һәм Казакъстандагы яшерен миллионерларны әле прокуратурага кадәр үк исәпләп чыгарганы мәгълүм булды, эссе якларга берниндиаяу белмәгән башкисәрләр агыла башлады. Алар һөҗүмнәрен бөртегенә кадәр исәпләп, нигезләп оештыралар, ашыгасы юк, бер уңышлы операциядән дә җинаятьчеләр таң калдырырлык калҗа эләктерәләр. Алар яшерен миллионерның гадәтләрен, гаиләсенең, күршеләренең көнне ничек үткәрүләрен озаклап өйрәнәләр, яшерен рәвештә төшерелгән йөзләрчә фоторәсемнәрдән досье әзерлиләр. Мондый житди әзерлеккә итальян мафиозилары да көнләшерлек иде. Еш кына алар милиция формасы киеп, тентү үткәрергә ялган рөхсәт кәгазе тотып киләләр, ашыкмыйлар, кабаланмыйлар, һөнәрмәндлектә үзләрен көнләшерлек тыныч тоталар.

Хәзер инде бу җинаятьчеләрнең яшерен миллионнар туплаган байтак адәмне капчык селкегәндәй тотып селкегәне мәгълүм, шунысы гаҗәп, таланганнардан берсе дә хакимияткә жалоба белән килмәгән, юкса, төнге талаучыларның күбесенең кулында хәтта ялган карар да булмаган. Бандитлар миллионерларның яшәү рәвешен генә түгел, психологиясен дә җентекләп өйрәнгәннәр, аларның шикаять белән килмәячәкләрен дә төгаен белеп эш иткәннәр.

Боларны ул җилнең кайсы яктан исүен бик тиз чамалаучы Халтаевтан да ишетеп белә иде. Әмма Раимбаев вакыйгасы аны тәмам шаккаттырды.

Колхоз рәисе Раимбаевны райбашкармага күрше районнан күчергәннәр иде. Моның яңа сикереш өчен трамплин гына булуын да күпләр чамалаган иде инде. Эшчән, житез, көче ташып торган, һәрнәрсәне мөгезеннән эләктереп алырга яратучы бу депутатның бик яшьли үк түрәләр тарафыннан "иркәләнеп" үстерелүе, югарыда йонлы куллары булуы да ачык тоемлана иде. Раимбаев райбашкармада бер ел да эшләргә өлгермәде, аны тикшерүчеләр чакырып алды. Чакырып алдылар да нахак юллар белән җыйган сәрмаясын дәүләткә кайтарып бирүен таләп иттеләр, хәтта төгәл суммасын әйттеләр. Раимбаев бик озак тарткалашты, барысын да кире какты, әмма колхоз бухгалтеры һәм мамык заводы директоры белән күзгә-күз очраштыргач, күлмәген күтәреп тикшерүчеләргә корсагын, кайнар үтүк белән яндырылган канлы эзләрне күрсәтте һәм барысын да төкми-чәчми сөйләп бирде.

Көзге урак өстендәге караңгы төннәрнең берсендә Раимбаевларның капкасында кыңгырау шалтырый. Мамык җыйган көннәрдә район башлыклары кайчагында таңга кадәр утыра, шунлыктан ул бер шикләнмичә, кунак килгән дип белеп, капканы ачып җибәрә. Яше әле кырыкка да җитмәгән бу кеше куркаклардан түгел, шуның өстенә, ишегалдында ике овчарка да бар. Ләкин ул нишләптер этләрнең өрмәвенә игътибар итеп тормаган.

Йолдызлы погоннар таккан, милиция киемендәге җиделәп кеше килеп керә. Үзен аеруча иркен тоткан берсенең иңнәрендә хәтта полковник погоннары булган. Керәләр дә болар, исәнләшәләр, ярдәм сорап килгәнлекләрен әйтәләр. Бернәрсәдән дә шикләнмәгән Раимбаев бүре буар этләренең тып-тыныч булуларына игътибар итмәстән (ә алар инде күптән агуланган булган), төнге кунакларны өенә чакыра. Килеп керүгә үк чал чәчлесе тентү үткәрергә дигән карар чыгарып күрсәтә һәм янындагы капитанга пүнәтәйләр чакырырга куша. Барысы да ашыкмыйча, кабаланмыйча, төпле итеп, закон кушканча итагать саклап башкарыла. Капитан ике пүнәтәй алып керә, алары исә тын гына бер якка барып чүмәшәләр. Лейтенантларның берсе сорау алу беркетмәсенә теге яки бу әйберне ничек язарга кирәклеген "полковник"тан сорый-сорый нәрсәләр алынганын җентекләп яза башлый. Өйдә табылган нәрсәләр, ә алар шактый күп була, аларны канәгатьләндерми күрәсең. "Полковник" папкасын ачып ниндидер кәгазьләр укый да баш әйләндергеч дәрәҗәдәге астрономик суммадагы акчаны дәүләткә кайтаруны таләп итә. Әмма ут-суларны кичкән Раимбаев үзен алып китүгә үк әлегә пүнәтәйләр янында утырган хатынының бөтен өлкәдәге туган-тумачага шалтырата башлаячагын белә; шулай итеп барысы да җайга салыначак, моның ише полковникларны гына күргән бар, дип уйлый. Милләтләренә караганда, болар җирле хокук сакчылары, үзебезнекеләр, өлкә үзәгеннән яисә Ташкенттан килгәннәрдер. Иң мөһиме, алар Мәскәүнекеләр түгел.

Талаучылар йорт хуҗасы куркып калыр, барысын да чыгарып салыр дип көткәннәр булса кирәк, ләкин ике сәгать буе интеккәч, аның үз ирке белән алтыннарын вә акчаларын бирмәячәген аңлагач, алар битлекләрен салырга мәҗбүр була. Вакыт ашыктыра. Хатынын анадан тума чишендереп, авызын-кулын бәйләп идәндәге паласка ташлыйлар, аяклары арасына электр кайнаткычы тыгып куялар.

—Башлавын синнән башлыйбыз, әгәр акчаларны бирмәсәң, хатыныңны электрга тоташтырабыз.

Хатынының авырга узган чагы.

Раимбаевның күлмәген умырып төшерәләр, кулларын-аякларын бәйләп диванга чалкан салалар һәм корсагына электр үтүге куялар. Ул шунда гына боларның бандит икәнен, эшнең уен-муен гына түгел икәнен аңлап ала. Барысын да чыгарып бирергә туры килә. Акчаларын бирә, әмма бу хакта беркемгә дә сөйләми, ай буе диярлек янган җирләрен дәвалап өйдә ята. Ярты елдан соң Мәскәү тикшерүчеләре кулга алгач кына бу коточкыч вакыйгалар өскә калкып чыкты һәм Халтаев милициягә районны җентекләбрәк сакларга боерык бирде.

Халтаев яшәгән ихатага килеп җитәрәк ул туктап калды, милиция башлыгы йорты чын мәгънәсендә алып булмаслык крепостьны хәтерләтә иде. Койма өстендә өч кат чәнечкеле тимер чыбык җитми дә, почмакларында автоматлы сакчылар баскан манаралар юк.

Үз ишегалдына кайткач та әле ул бик озак бернинди максатсыз арлы-бирле йөренде, өйгә кереп кайбер кәгазьләрне алып чыкмакчы, караштырып утырмакчы иде, тик хатынын уятудан курыкты. Җәйге кухняга кереп газ плитәсендә су кайнатып алды, чәй пешерде дә Мияссәрә урын җәеп куйган айван-сәкегә барып утырды.

—Нәрсә булды соң әле минем белән, тик торганда истәлекләр кичәсе килде дә чыкты,—дип ачы елмаеп куйды ул. Чәйнек бушаган иде инде. Уйлары исә яңадан бик еракта, үткәндә калган истәлекләргә барып тоташты.

Сабый чактан ук тәрбияләнгән балалар йортлары искә төште, язмыш дәфтәрендә аңа шундый дүрт йорт сынавын узарга язган икән. Дөресен әйткәндә, ул бары тик соңгысын гына яхшы хәтерли. Анысы инде балалар йорты түгел, интернат санала һәм унъеллык мәктәпне дә ул шунда тәмамлады. Детдом балаларыннан бик азына гына урта белем алу бәхете тәти. Аларга бер генә юл бар—җиде еллык мәктәптән соң һөнәр училищесы яисә ФЗӨ мәктәбе. Булат исә балачагыннан ук китапка, белемгә тартылды. Моны сукыр кеше генә күрмәскә мөмкин иде. Ул яктан язмышка

зарланырлык түгел, тормыш юлында гел яхшы кешеләр очрап торды, нәкъ менә алар һөнәр училищесыннан коткарды да. Чоры өчен шактый хәвефле, шактый куркыныч гамәл иде бу.

Аның әтисен утыз бишенче елда кулга алдылар, ләкин ул чакта күпләргә тагылган маддә буенча түгел. Ул бәлки, чыннан да, яңа тәртипләргә каршы булгандыр. Хәзер моны ачыклау мөмкинлеге юк диярлек. Бохараның соңгы әмире Сәет Алимханның баш салым җыючысы булып хезмәт иткән әтисе, һәм табигый ки, совет власте урнашкач, бөтен өстенлекләреннән мәхрүм калган. Басмачылар хәрәкәте башлангач, Җунаид-хан кул астында кылыч тотып сугышмаса да, алар белән яшерен элемтәдә торган. Шуның өчен аны атып үтерделәр дә. Ачлык, ялангачлык, җимереклек... Кешеләр кая барып бәрелергә белми. Шул елларда гаилә пыран-заран килә, әнисенең Кашгария якларына чыгып китүенлеге генә мәгълүм, үзенең тагын сеңлесе һәм нәни энесе булганлыгын да хәтерли. Аңа ул вакытта биш яшь тулган иде инде.

Җиде сыйныфны туган телендә тәмамласа да, ул сигезенчедән башлап рус интернат-мәктәбендә укыды. Кешеләр белән җиңел аралашучан, һәрчак ягымлы һәм үткен акыллы, шаян холыклы үсмер егет интернатның "сөйкемле сөяге", иң яхшы укучысы булды, мәктәпне медаль белән бетерде.

Дүртенче сыйныфта укыганда, сугыш елларында ук, гәрчә мондый типтагы башка интернатлардагы кебек чәчләрен алганда баш түбәсендә тәре калдырмасалар да, ул үзенең башкалардан аерылып торган ниндидер махсус йортта тотылуын аңлаган иде инде.

Мәктәптә чыгарылыш кичәсе булыр алдыннан аны интернат директоры— Төркестан хатын-кызларыннан беренче большевик саналучы Инкыйлаб Рәхимовна чакырып алды. Хәзер аның исемен тарих дәреслекләрендә еш очратып була. Сөйләшү бик озакка сузылды.

—Булат...—дип башлады ул һәм нәрсәнедер хәл иткәндәй тукталып калды, уйлануы, дулкынлануы йөзенә чыкты.—Менә син инде үсеп җиттең, мөстәкыйль тормыш юлына аяк басачаксың... Синнән яхшы кеше, яхшы белгеч чыгачагына ышанам мин. Сиңа һичшиксез укырга кирәк, акылың үткен, башың эшли, туган ягыбызга, халкыбызга файда китерерсең, дип беләм. Тик менә анкетаң... Мондый анкета белән сине бер институт та укырга кабул итмәстер. Мин сине алдагы язмышың турында сөйләшергә чакырдым... Безнең үрнәк саналучы интернатка алу өчен Кокандтагы балалар йортындагы танышларым, аларны мин партиядә бергә эшләгән еллардан беләм, синең атаңның исемен үзгәртеп яздылар. Мәхмүтов бездә Рәсәйдәге Иванов кебегрәк киң таралган фамилияләрдән. Алар синең "дело"ңны кан чиреннән күптән вафат булган фамилиядәшеңнеке белән махсус рәвештә бутап җибәрделәр. Өстебезгә нинди куркыныч алганыбызны аңлыйсыңдыр, дип беләм. Заманалар авыр, теләсә кайдан дошман эзләү дәвам итә, шунлыктан мин сиңа хәзер үк институтка барып керергә киңәш итмәс идем. Армия яшең җиткән. Хезмәт итеп кайт. Аннан соң икеләнеп тормыйча укырга кер, өстебезгә алган куркыныч тәвәккәллекне, өметебезне акла. Иң яхшысы—моннан ераккарак, Мәскәүгә үк кит. Армиядә хезмәт иткән, укып йөргән арада нәрсә дә булса үзгәрер, берәр вакыт баланың атасы өчен җавап бирмәгәнлеген дә аңларлар әле.

1949 ел иде бу.

Хәтерендә армия хезмәте истәлекләре уйнап алды. Мәскәү янындагы Кунцевода хезмәт итәргә туры килде аңа. Хәзер инде ул яклар шәһәр эчендә калды. Илле өченче елның мартында, Сталинны күмгәндә Кызыл мәйданны камаган гаскәр сафында да булырга туры килде. Башкалар кебек ул да яшьләрен тыя алмаган иде. Армиядә Саня Кондратов исемле егет белән дуслашты, өч ел буе казармада караватлары янәшә булды, солдат хезмәтенең ачысы да төчесе дә алар өчен уртак иде. Нәкъ менә шул Кондратовтан аңа күпер җене күчте дә бугай. Бергә хыялландылар, төзүче инженерлар институтына да бергә керделәр, имтиханнар тапшырганда ул Мәскәүдә, Арбатта аларның өендә дә яшәп алды әле.

Кондратов хәзер танылган күпер төзүчеләрнең берсе, Дәүләт премиясе лауреаты, илдәге иң зур күперләрнең байтагы аның катнашында төзелде. Хезмәттәш дустының фамилиясе матбугатта еш очрый.

Студент чагында партиянең XX съезды булып узды. Ул инде байтак нәрсәдән хәбәрдар, күпне белә, күпне аңлый иде. Мәскәүдә яшәү эзсез узмый. Съездан соң хәтта ул деканатка барып, үзенең шәхси "дело"сындагы буталчыклык турында сөйләп

бирергә дә җыенган иде. Ләкин Кондратов туктатып калды, сабыр итәргә кушты. Булат яхшы укый, иң катлаулы техник фәннәр дә аңа бик җиңел бирелә. Укытучылар еш кына аңа "Сездә табигатьтән килүче инженерлык фикер йөртү сәләте бар" дип кабатлыйлар. Диплом алгач аны кафедрада калдырасы иттеләр, ике-өч елдан кандидатлык диссертациясе дә яклый алган булыр иде. Күперләрне субай нигезләрдә төзү турында якланган диплом эшенә бик җитди проект оешмалары да игътибар иткән иде. Әмма ул бернинди кызганусыз ымсындыргыч мөмкинлекләрдән баш тартты, күңеле, бөтен барлыгы туган якларына ыргыла иде.

Җан тартмаса, кан тарткандыр. Туган якларында булмаганга сигез ел узган иде. Дөрес, Мәскәүдә якташлар күп, алар белән аралашып яши, беренче номерлы медицина институтында укучы Зөһрә белән дә шулай танышкан иде.

Бик күптән, һай, бик күптән булган икән шул болар: Мәскәү, Сталинны күмү, Кунцеводагы казарма, анда ул барысы 1072 тапкыр төн кунган икән. Башка бик күпләр кебек, ул да армиядәге көннәр вә төннәр санын санап бара иде. Аннан соң Оренбургта практика, ярым ташландык "Топольләр" паркы. Сирәк очрый торган Нора исемле кыз белән йөрү. Хәзер инде ул аның кыяфәтен төгәл генә күз алдына китерә алмый, бары тик исеме генә хәтергә уелып калган, юкса, ул аны Форштадтка кадәр озата һәм бу шактый кыюлык сорый торган гамәл иде. Чөнки иң башкисәр ышпана яши торган төбәк ул, шуның өстенә, Нора да теләсә кемнең күзе төшәрлек иде. "Топольләр"да чакта үзенә кырын караучыларны сизә иде ул, әмма язмыш аңа мәрхәмәтле булды, әллки аны кастеттан яисә финкадан шул Нора саклап калгандыр да, Форштадтагы иң хәтәр Ертык Закирның ул ни теләсә шуны эшләргә әзер икән дип ишеткәне бар иде. Норага ошый иде ул... тагын бер-ике айдан инженер буласы, укуы Мәскәүдә, зур төзелештә башлык буласы кеше, Форштадт ышпанасы түгел инде.

Үрмә гөлләр һәм вак розаларга чолганган карт имәннән Халтаевлар ихатасына илтүче юлга куе караңгылык сеңгән, җәйге кухня да тоташы белән шул шомлы караңгылык астында. Чәйнек бушаган булуга карамастан, аның газ кабызыр өчен генә ул караңгылыкка керәсе килми. Тәненә төнге салкынлык йөгерде, ул буй-буйлы калын пижамасына үрелде, андыйлар инде күптән модадан чыкты, бары тик Урта Азиядә генә аны һаман иң кәттә киемнән саныйлар иде бугай.

"Илле җиде яшь тә тулып китте, тормышны үткән дип санарга мөмкин,—дип моңсу сүрәнлек белән уйлап куйды ул.—Инкыйлаб Рәхимовнаның зур юлга озатуы әле һаман кичә генә булган кебек... Минем өчен башлары белән җавап бирергә җыенган, миңа ышанган, өметләнгән кешеләрнең ышанычын аклadыммы икән?"

Үз-үзенә бу сорауны моннан җиде еллар элек биргән булса, мөгаен, уйлап та тормыйча горурлык хисе белән "әйе" дип җавап биргән булыр иде. Әмма соңгы җиде елда мондый ышану кимегәннән-кими бара иде инде.

Язмышында хәлиткеч адым ясарга этәргән мәрхәмәтле Инкыйлаб Рәхимовна, нишләптер, беркайчан да аның хәтереннән җуелмады. Ничек кенә баш ватмасын, буталчык уйлануларында, хәтер төпкелендә казынуларда ул мантыйкка сыешлы эзлекле бер фикер оештыра алмый интекте. Ул чактагы сурәтен төгәл хәтерләми инде, бары тик көмешләнә башлаган, европача китәрелгән чәчләре һәм гасабилык беленеп торган нечкә озын бармакларындагы папирос кына күз алдына килә, шул сурәт аны еллар буе эзәрлекли. Әйе, махсус интернат директоры тәмәке тарта иде, монысы хәтергә яхшы уелган. Ләкин аңа Мияссәрә белән бүгенге сөйләшүдә ерак балачакта калган шул карт коммунист хатын да катнашты кебек тоела, шушы сәер хәлне аңлый алмый интегә иде.

"Инкыйлаб... Инкыйлаб..."—дип куйды ул һәм күңелен шатлык хисе биләп алды, уйга салган табышмакка җавап тапты кебек. Инкыйлаб "революция" дигән сүз ләбаса, димәк, Революция Рәхимовна килеп чыга. Чүл эссесе бөркелеп торган бу якларда да революция дигәнең кешеләр күңелендә тирән эз калдырган, аңа бөтен йөрәге белән ышанганнар да аз түгел. Әнә, Мияссәрә дә бүген берничә тапкыр "инкыйлаб" дип кабатлады түгелме соң, үз язмышында хәлиткеч роль уйнаган карт большевик исеме, шулай итеп, яңа заманда яңача яңгыраш тапты бугай.

Ташкентта Ленин музееның алагаем олы филиалын ачу тантанасын телевизордан күргәндә ул инде байтактан райком секретаре булып эшли, Югары Совет депутаты иде. Репортерлар интервью алган кешеләр арасында Даниярова да бар иде. Ап-ак чәчле, начар гына киенгән һәм ярым бөкрәйгән карчыкны ул бик тиз танып алды.

Шунысы да истә, ветераннар алтын йөгертелгән бронза тоткалар куелган калын һәм биек имән ишекләр, мәрмәр һәм хрусталь белән балкучы мәһабәт залларда үзләрен уңайсыз хис итәләр иде бугай, шома паркет идәндә алар боз өстендә йөргәндәй сакланып атлыйлар һәм бай туганнарына мәҗлескә килеп эләккән хәерчеләрне хәтерләтәләр иде. Хәер, аларны экранда озак күрсәтеп тормадылар да, ветераннарны аларның эшен дәвам иттерүчеләр, үзләренең гөнаһларын һәм хаталарын юу өчен юлбашчыга бөек храм төзеткән, түшләрен киереп атлаучы агайлар вә ханымнар кысрыклап чыгарды. Кешелек тарихында шулай барысы да яңадан кабатлана: элек гөнаһларын юу өчен соборлар һәм мәчетләр төзетсәләр, хәзер юлбашчыга зиннәтле вә тәкәббер филиаллар коралар.

Экранда Даниярованы күргәндә ул чак кына "Әнием!" дип кычкырып җибәрмәде. Интернатта бик күпләр аңа шулай дип эндәшә иде, ә инде аның өчен, Инкыйлаб апа, мөгаен, чынлап та әни кебек булгандыр да, чөнки ул аңа үзенең ышанычын һәм мәхәббәтен, күңел җылысын башкаларга караганда күбрәк бирде, аның хакына тормышын куркыныч астына куйды. Дулкынланудан аның йөрәге кысылды, күзләре яшьләнде.

Ул чакта әле Зөһрә исән иде, аның күрше бүлмәдән хатынын чакырасы, аңа үзенең ятимлек еллары, үзләре өчен әнигә әйләнгән карт большевик Даниярова турында сөйләп бирәсе килде, әмма нәрсәдер туктатып калды. Телевизордан Инкыйлаб апаны күрү тәэсирендә иртәгә үк Ташкентка шылтыратырга, кайда яшәвен ачыкларга кирәк булыр, дип күңеленә беркетеп куйды. Монда алып килермен, хатыным, балаларым белән таныштырырмын, гомеренең соңгы көннәрен монда үткәрер. Соңлап булса да, өметләре акланганны белсен. Хыялы шундый иде.

Әмма икенче көнне яңадан эш мәшәкатьләре басты, көндәлек ыгы-зыгы китте, беркая да шылтырата алмады. Ә бер ярты елдан газеталарда Инкыйлаб Рәхимовнаның вафаты хакында матәм белдерүе басылып чыкты. Әле дә исендә, шул кичне ул чамасын белмичә эчте дә эчте; урыс гадәтенчә Революция Рәхимовнаны искә алу гына түгел, үзенең аңа карата хыянәтен шәраб белән күмәргә теләү дә иде бу. Никадәр кызганыч булмасын, үзенең мөнәсәбәтен ул башкача аңлата алмый иде инде. Үкенү хисе бүген дә йөрәген кыса, бәгырен телгәли.

—Сатлык җан,—дип куйды теш аралаш айван-сәкедә утырган кеше һәм як-ягына каранып алды. Мәһабәт имәннән төшкән күләгә сулга таба күченә төшкән, ай яктысы җәйге кухняны ак нурга манчыган, айваннан хәтта газ плитәсе дә аерымачык күренеп тора иде. Әмма аңа хәзер чәй кирәк түгел иде инде. Аңа оят иде, ул хәтта ирексездән як-ягына каранып алды; нишләп безнең күңелебез, җаныбыз богаудагы кебек, нишләп без тирә-якка шикләнеп карыйбыз соң әле, дип, моңсу гына уйлап куйды ул. Хәтта төннәрен, япа-ялгыз калганда да як-ягыбызга карамыйча булдыра алмыйбыз, үз уйларыбыздан куркабызмы? Аның инде бик күптәннән болай уйланганы юк иде. Соңгы тапкыры Мәскәүдә институт тәмамлаган көннәрдә Саня Кондратов белән утырганда булды бугай. Ничек шулай бөтенесе дә юкка чыккан соң әле? Фикер алышмыйча, бәхәсләшмичә, сүз көрәштермичә генә яңа идеяләр тумас бит. Уйлары тагын Мияссәрәгә әйләнеп кайтты, нәкъ менә ул фикерләрен шулай чуалтып ташлады түгелме. Тагын тәне эсселе-суыклы булып китте. Әгәр хатыны белән сөйләшмәгән булса, Инкыйлаб Рәхимовнаны искә төшергән булыр иде микән?! Ай-һай! Һәм узган еллар дәвамында беренче тапкыр укытучысының сурәте ап-ачык булып күз алдына килеп басты. Менә ул ишек яңагына сөяләп интернат ашханәсенә карап тора имеш. Булат Мөэминович аның җентекләп юылган, күкрәгенә бант бәйләнгән ак кофтасын, бәрхет сыман йомшак, шәрекъча зур, якты күзләрен күргән кебек булды, ул күзләрдә мәңгелеккә олы кайгы яшеренгән кебек тоела иде. Аның карашы ашап утыручы кызлар һәм малайларның башлары өстеннән шуып үткән дә, каядыр еракка төбәлгән, нечкә озын бармаклары юк-юк та битенә төшкән чәчләрен рәтләп куя. Нәрсә хакында уйлый икән ул, моңсу карашы еракладан нәрсә эзли икән? Мөгаен, авыр язмышлы бу малайлар һәм кызлар кем булып үсәрләр, өметне акларлармы, мин хыялланган изгелек һәм гаделлек җәмгыятен төзи алырлармы, дип уйлыйдыр ул.

"Хәзер инде мин кайчандыр үземә тормыш юлын ачкан Инкыйлаб Рәхимовнадан яшь ягыннан өлкәнрәкмен, әгәренки аның өметләрен акладым дип расласам, күңелемә авырлык алган булыр идем,—дип уйлый ул.—Хәер, миннән генә түгел, бик күпләрдән күңеле бизгән булыр иде". Тагын Ленин музее филиалын ачу тантанасы исенә төште. Карт большевикларны мәһабәт заллар да, варислары саналучы кукрайган түрәләр дә

сөендерми, моны гап-гади тамашачы да бик тиз сизеп алырлык иде шул. Ул гына да түгел, алар арасында хәтта упкын тоемлана, алар бер-берсен аңламыйлар кебек иде. Шунлыктан тантана ветераннардан башка гына дәвам итте дә булса кирәк.

Ике иякле симез ленинчылар,
Мин үлсәм дә сезнең сафта булмам...—

Ул елларда яшь шагыйрь Александр Файнберг шулай дип язган иде бугай.

Хыялында гына булса да аның белән сөйләшеп карар өчен ул интернат ашханәсе ишеге янында басып торган Данияровоны хәтереннән җибәрмәскә тырышты, әмма... вакыт узган шул инде, үткәнгә кайтыр юллар юк...

Үткәннәрдә казынуда ниндидер ачы тәм булуга карамастан, ул бәхетле иде, чөнки күп еллар узганнан соң интернатта тарих укыткан укытучысының газиз һәм якты сурәтен күңелендә яңарта алды. Бу үз гомерендә беренче тапкыр иде бугай.

Туган портына кайтып туктаганнан соң гәүдәсенә ябышып каткан кабырчыклар, суүсемнәрдән вә гайре хәшәрәтләрдән арынырга теләгән кораб кебек, ул да бүген үзенә карата аяусыз иде, чистарынырга, күңелне, хәтерне сафландырырга кирәк иде.

Көтмәгәндә, тагын Нора исеме калкып чыкты, ул аны бүген арык янындагы көмешсыман тирәкләр шавы астында бер исенә төшергән иде инде. Хатирәләрдән хәтта йөзенә кызыллык йөгерде, ярый әле моны хет күреп торучы юк. Нораның чибәр йөзен никадәр тырышса да, хәтеренә китерә алмавы гына түгел, аның турында уйлаганда гаделсезлеккә юл куюы да күңелен кыра иде. Нора... Модистка. Хәзер инде андый сүз дә юк бугай, ул чорлардан соң колакка чалынганы булмады. Хәзер күбрәк чит ил әйберләре, фирменный чүпрәк эзләп чабулыйлар. Аның үзенә дә еш кына райпотребсоюз рәисе Сәлим Хәсәновичка баш иярга туры килә, Ташкенттагы киленнәре җанга тия, әле велюр пәлтә, әле кайры тун, йә булмаса твид костюм кирәк имеш.

Нора... Чынлыкта исә, паспортындагыча әйткәндә, Нурия иде ул, ләкин алай эндәшкәнне яратмады. Бервакыт өйләренә, әти-әнисе белән таныштырырга чакырды. Егетнең киләсен белгән әни кеше телеңне йотарлык бәлеш пешергән иде. Шул чакта ул кызына Нурия дип эндәште дә инде. Дөрес, Булатның үзенә дә Нурия дигән исем якынрак, әмма аңа Нора дигәне дә ошый. Чибәр кызларга андый гына иркәләнү килешеп кенә тора. Бер карасаң, Нора исеме аңа чат ябышкан иде шул. Оренбургның Советская урамындагы иң купшы "Люкс" мода салонында эшләүче кызга башкача эндәшеп тә булмас иде.

Пыяла витриналары белән балкып утыручы салон ул елларда Оренбургның мода үзәге иде. Дөрес, аны бизәгән рәссам әлләни баш ватып тормаган, витриналарны Тулуз Лотрек стилендәгечә битләренә челтәр каплап изрәгән чибәркәйләр белән тутырган. Чия төсендәге хисчән иреннәр, озын бармаклы, кызыл тырнаклы иркә куллар күзгә ташлана, хәтта ул бармаклардан кан төсендәге лак тамып торган сыман тоела башлый иде.

Төнге тынлыкта ул кинәт кенә биек үкчәләр шакылдаганны ишеткән кебек булды, Нора шундый баш әйләндергеч биек үкчәле түфли кия торган иде. Йә яннан, йә арттан, йә алдан ерыклы тар юбка модалы санала. Андый киемле кызлар турында "Баруын гына кара, аяклары белән язамыни!" диләр иде. Мондый стиль хатын-кызлардан аерым бер йөрү рәвешен булдыруны таләп итә, моның өчен исә чын-чынлап талант кирәк булып, ул һәркемнең дә кулыннан килми торган иде.

Күзләре төнге бакчага текәлсә дә, аның карашы бик еракта калган үткәннәргә кереп баткан, колагында аның белән очрашуга ашыгучы Нораның түфли шыкылдавы яңгырый. Ул аны башка беркем белән дә бутамый иде. Ул Нора белән бәйле кадерле истәлекләрне хәтеренә төшерергә тырышты, йөзенә тагын моңсу елмаю кунды, чөнки борынына сирень исләре килеп кергәндәй булды.

Оренбург дигәч тә сирень исенең борынны кытыклый башлавы очраклы түгел. Ул бәхетле язда Булат һәркөн Норага фарсы сиреньнәре белән ландыш чәчәкләре алып килә иде. Ландышны кызлар үлеп ярата, моңа "Ландышлар" җыры да сәбәпче булгандыр әле. Кайда гына барма шул популяр җыр яңгырар иде. Күптән, бик күптән булган икән шул болар!

Менә, имеш, ул Совет белән Киров урамнары чатындагы афиша тумбасы янында басып тора, соңга калудан мәңге арына белмәс Нораны көтә. Аның йөзен исенә

төшерергә тырышып карады, ләкин хәтер сандыгы ачылмады, кызның йөзен күрергә теләгән саен, анысы битен әле генә бүләк ителгән сирень чәчәкләре белән каплый иде. Ул аның йомшак күкрәк тавышын, көлүен ишеткән кебек була, дулкынланудан йөрәге талпынып тибә башлый... Әмма тансык йөзне күрә алмый, кыз аңа карамый... Хәтеренең көчсезлегенә үртәлеп, ул карашын аска күчерә һәм очлы борынлы, лак белән ялтыратылган "лодочка" туфлиләрне, кара төстәге челтәр оекларга чумган төз аякларны ап-ачык күрә, моннан утыз ел элек тә алар хәзергечә модалы санала иде. Тагы... Юка кытай габардиныннан тегелгән озын юбка. Аның һәр ике ягыннан ерыклар калдырылган, бер ягында ерык зур төймә белән төгәлләнә. Караш өскә үрмәли. Анда нindидер җиңел металлдан ялтыратып ясалган зур аеллы киң каеш. Нәкъ шундый каешны ул үткән атнада гына Ташкенттан кайткан, модалы киенергә яратучы килене ндә күргән иде. Нәкъ менә шул килене моданың соңгы яңалыклары белән танышып торырга ярдәм итә дә инде. Караш тагын югарырак күтәрелә һәм Нораның җилкәчекләр куелган ачык алсу төстәге кофтасына тап була, хәзер Мияссәрә дә шундыйракны кия. Нора кофтасындагы перламутр төймәләргә, түшендәге кара муар бантка хәтле ачык хәтерләүче Булат аларда әллә ни аерма күрми, аерма бары тик елларда—арада яткан утыз елда гына.

Әйтерсең, рекордлы биеклекне яуларга җыенган һәм соңгы мөмкинлеге калган сикерешче, ул дулкынлануын баса алмыйча карашын тагын да өскәрәк күтәрергә җыена. Алда тагын уңышсызлыкмы? Юк, аның йөзе урынында бушлык түгел анысы, хәзерге авангардист рәссамнар төшергәнчә, нindидер минут саен алышынып торучы эре сызыклар, чалымнар гына. Аның чибәр йөзне, өске ирене янына кунаклаган нәни миңне, елмаеп караган дымлы күзләрне күрәсе килә. Ай, Нораның көлгән вакытта күзләренең ничек балкуын күрсәгез иде сез, очкыннар чәчри, әллә нинди тылсымлы яктылык, шатлык очкыннары бөркелә башлагандай була. Телисеңме-теләмисеңме, әнә шул шатлык дулкынында йотыласың.

Мондый минутларда ул ирексездән аңа таба якыная, чиста сулышын тоя, кызый исә башын артка ташлап елмаюын белә. Гомерендә иннек белмәгән алсу иреннәреннән күзләреңне алып булмый. Кайчагында ул көлүен тыя алмыйча, үзе дә белмичә тел очын чыгара һәм өске тешләре буенча үткәреп ала, бу гадәте аны әллә нинди яклауга, саклауга мохтаҗ яшүсмер кызга охшатып калдыра һәм Булатның йөрәгә кысыла, күзләре дымлана. Урамнан үткәндә теләсә кемне борылып карарга мәҗбүр итүче зифа буйлы, чибәр кыз чыннан да мине сайлады микәнни дип уйлый Булат.

Ул сакланып кына карашын алсу кофтадагы муар бант-күбәләктән ала һәм нәфис муенда еллар үтү белән инде табигый ялтыравыгын югалта башлаган энҗе муенсаны күрә. Бу энҗе муенса алар гаиләсендә иң кадерле нәрсәдән саналып, буыннан-буынга, әбиләреннән оныкларына күчеп бара икән. Моны да Булат белә иде инде. Менә хәзер Нораның чираты җиткән. Кыз моңа әйтеп бетергесез шат. Мөселманнарда энҗе теләсә нинди бриллиант-гәүһәрдән өстен санала. Монысы да мәгълүм иде.

Еш кына ул: "Энҗе муенсам кайда икән?"—дип шаярта, күзләренә ясалма курку чыгара һәм ашыгып муенсасын эзли башлый. Булат та шул уенга кушыла, җилкапка янында хушлашканда, муеныннан үбеп колагына пышылдый:

—Тикшерик әле, энҗе муенсаң урынында микән?—ди.

Булат Мөэминович ышанычын югалткан иде инде, тагын уңышсызлыкка очраудан шикләнә-шикләнә, ихтыяр көчен җыеп, карашын кайчандыр Нораның бабасы Истанбулдан алып кайткан энҗе муенсадан аера, һәм менә сиңа могҗиза, күз алдына Нора килеп баса.

Ләкин аның күзләрендәге шаян елмаю, ирен читләрендәге җиңелчә көлемсерәү юкка чыккан. Андый чагын кайда күргәне бар соң әле аның? Тырышсаң, барысы да күз алдына килә икән.

Оренбург вокзалы... Пассажирлар ташкыны буып өлгермәгән борынгы перрон, тимер юлдан ерак түгел парк... Аннан тынлы оркестрның вальс уйнавына хәтле ишетелеп тора. Ташкенттан Мәскәүгә таба үтүче скорый поезд, әр-яңа вагон һәм... аның баскычында Булат. Акрын гына кузгалып тизлеген арттыра баручы поездга ияреп кыз атлый да атлый, аларның куллары бер-берсенә ябышкан диярсең. Менә шул чакта Нораның күзләре әнә шундый моңсу иде. Югыйсә, кайгырырга сәбәп тә юк иде бит. Барысы да сөйләшенгән, аңлашынган. Булат яңа елга кайтачак, кулына диплом алгач, яз көне аны үзе белән алып китәчәк. Барысы да вәгъдә белән беркетелгән иде түгелме соң?

Кызлар күңелен алдый алмыйсың, язмышларына янаган һәлакәтне үк булмаса да, ниндидер фаҗигане кыз күңеле шул чакта ук тоемлаган, шунлыктан аның кулларын ычкындырмаган, поезд аны кызның кайнар кулларыннан йолкып диярлек алып китте бит. Мәскәүгә барып җиткәнче Нораның моңсу карашы күз алдыннан китмәгән иде. "Нишләп моңланды соң әле ул?" дип ваемсызланып уйланган иде Булат. Аны алдарга уенда да юк иде, чын күңеленнән кәләшем дип атый иде бит.

—Нора, бәгърем, гафу ит...—дип пышылдады Мәхмүтов ирексездән.

Әгәр ул бүген Инкыйлаб Рәхимовнаны искә төшереп, аңа хыянәт иткәнлеген, үзенең гаебен танымаган булса, Нораны искә алуы да шикле. Арык янында бары тик үткәннәрдән күңелле һәм матур мизгелләрне генә искә төшереп ләззәтләнмәкче иде. Чөнки яшьлектә барысы да матур, җиңел, барысы да романтика томанына төренгән, хыял канатларында уйнаклый торган була. Яшьлеккә барысы да сыйган, "Топольләр" паркы да, иң модный саналган "Чия бакчасы" көен дөбердәтеп уйнаучы Марик Раушенбахның джаз оркестры да, җиз торбалар һәм саксофоннар тантанасы да... Анда Эллингтонның моңсу-дәртле "Кәрван" көе яңгырый. Аны башкарганда Оренбург джазменнарының кумиры, шәһәрнең беренче дендие Раушенбах саксофонда үзе уйный иде. Начальство киткәч, парк ябылыр алдыннан борынгы парк өстендә рок-н-ролл авазлары тетри, сәхнәдә һәм бию мәйданчыгында нәрсәләр булганлыгын белү өчен барысын да үз күзләрең белән күрергә кирәк. Ялганларга кирәк түгел, үзеңне барыбер алдый алмассың, арык янындагы эскәмиядә хәтердә менә шушы күренешләр генә яңарды бит, хәтта Нораның—кәләшеңнең йөзен дә күз алдына китерә алмадың.

—Нинди пәслек,—дип куйды ул кабахәтлекне, түбәнлекне аңлатучы борынгы сүзне искә төшереп. Әмма өстенә алган бу гаепне кире кагу, аклану теләге юк иде. Хәтта Ертык Закир турында да җансыз бер нәрсәне искә төшергәндәй генә уйлап алды. Ә бит ул чакта бөтенләй башкача иде, четерекле иде. Хәтердә казыну исә тагын бер кат сатлык җан булуны, хыянәтне тануга китерәчәк, Данияровага карата кебек үк булмаса да, алдан уйлап эшләнмәсә дә, барыбер кылган гамәлләре хыянәткә тиң булыр иде.

Кеше тормышында хыянәт өчен җавап тотар көннәрнең шиксез килеп җитәчәге билгеле. Җәзасы күңел тынычлыгын югалту гына булса да, хисапны бары тик үз-үзеңә генә бирергә туры килсә дә, бик авыр хөкем ул.

Бүген шундый көн, дөресрәге, төн булды. Ул моны аңлый һәм җавап тотудан качу сәбәпләрен дә күрми, артка таба юллар юк, болай да артык күп чигенелгән иде инде.

"Бар яктан да үзем гаепле",—дип уйлады ул бакчага күз салып. Монда барысы да аның кулы белән утыртылган, тәрбияләнгән, үстерелгән; буш вакыты булса бакчада казыну яраткан эше, әмма вакыт дигәнең беркайчан да җитми. Бакчаның шушылай каралган, тәрбияләнгән булуында исә, әле бит йөзем бакчасы да, кура җиләге утыртылган аерым кишәрлек тә бар, аныкыннан бигрәк, бакчачы Хәмракол әкәнең хезмәте ята. Ихатада бер унбиш еллап эшли инде ул. Сабыр, ярдәмчел һәм диндарга охшаган бу карт аларның бакчасына кайчан, ничек, нинди шартларда килеп эләкте соң әле? Берчак шуны исенә төшерергә тырышып караган иде, булдыра алмады, сорашыр, белешер кешесе юк, ул чакта Зөһрә вафат булган иде инде. Бакчачы турындагы уйлар күңелләләрдән түгел, ул чәйнекне алды да җәйге кухняга таба китеп барды. Куәтле имәннең күләгәсе тагын да сулга табарак авышкан, газ плитәсе янында яп-якты, хәтта ут яндырып торасы юк. Чәй кайнаганчы ул Халтаевларга чыгучы капкага барып терәлгән сукмак буйлап йөрергә тотынды, әйтерсең, милиция начальнигының ишегалдына бәреп керергә һәм горилланы хәтерләтүче күршесеннән үзенә бакчачы итеп Хәмракол әкәне кем урнаштырганын сорарга тели иде. Ул барысын белә, тәгаен белә торгандыр.

Чәйнек кайнап чыкканны ишетүгә ул кухняга кайтты. Бүген Халтаев белән дә, бакчачы белән аңлашырмын, дип тынычландырды ул күңелендә кымырҗып утырган кортны һәм айванга әйләнеп кайтты. Чәй эчсәң баш ачыла, уйларга җиңелрәк була, өстәвенә, майлы пылаудан соң тамак кибеп интектерә иде.

Үткәннәр чәнечкеле тимер чыбык шикелле авырттырып аның җанына шул хәтле нык ябышкан иде ки, ул алардан берничек тә котыла алмады. Тагын күз алдында Нораның моңсу йөзе, бер мизгелдә сүрәнләнеп, сүнеп калган күзләре, эсселектән яргаланган иреннәре пәйда булды. Әйтерсең, ул аны нәрсәдәдер сүзсез генә битәрли иде. Юкса, тормышта аннан да шаян, шук бүтән бер кызны да очратканы булмады. Вокзалдагы хушлашу мизгелләрендә алда торган ниндидер бәлане сизенепме, аның

күзләре сүрелде, йөзендәге балкыш сүрәнләнде. Әле дә исендә, ял көннәрендә Җаек буена кызынырга төшкәч, ул аннан күзләрен йомуын үтенә һәм битенең эчтән яктыртылган кебек тоелучы балкышына сокланып ята иде. Аның яңакларындагы алсулыкның чынлыгын тикшерергә теләгәндәй, битләренә кагыла һәм шунда гына аның бернинди иннек-кершән ягынмаганын исенә төшерә торган иде.

Дөрес, Нора күзен йомып озак ята алмый, түземе җитми һәм шаярып акланырга тотына, имеш, аның да аны күрәсе, исендә калдырасы килә, "Син бит китәсе кеше", дип котыртырга тотына. Ничек кенә тырышмасын, күзен кайчан ачачагын чамалый алмый, һәрвакыт ул әллә нинди бер көтелмәгән мизгелдә була иде. Норaның күзләре дөньяга нииндидер могҗиза көтеп, тирә-якта ачыш асарга әзерләнеп, зур булып ачылып карыйлар. Бу караштa яшьлекнең мәңге кабатланмас чисталыгы, тормышта әле бернинди бәла-казага очрамаган, алдауны, ялганны белмәгән кешенең рухи сафлыгы чагыла. Әнә шул караш күңелендә назлы кызгануга охшаш хис уята, үзендә андый хис тә булыр дип башына да китерми иде ул. Тирә-яктагы чынбарлыкка караш ташлап алганнан соң киң ачылган күзләр ачык бер яктылык белән балкый башлый, йөзе тагын да матуррак, камилрәк булып тоела иде. Бүген ул һичьюгы хәтерендә шул йөзне кабат күрергә тели иде. Ләкин хәтер дигәнең аңа буйсынмады.

—Үзеңә күрә таман,—дип моңсу гына уйлап куйды ул.

Ачыктан-ачык әйтик дисәк, мөгаен, бүген Ертык Закирны, чегәнннеке шикелле куе, дулкынланып торучы кара чәчле, таза, базык гәүдәле егетне дә искә алырга кирәк булыр иде. Дүрт елын Тын океанда, диңгезче хезмәтендә калдырып кайткан егет туганда ук тельняшка киеп тугандай булып тоела, ул аны беркайчан да салмый иде шикелле. Сәер кушаматы исә йөзенә язып куелган, әмма сул яңагындагы бу ертык яра аның шактый ук сөйкемле йөзен артык ямьсезләми дә иде. Ертык дигән кушаматны әле флот хезмәтенә киткәнче үк алган егет Форштадта һәм, табигый ки, бөтен шәһәрдә иң абруйлылардан санала, бик күпләр аның белән дуслашырга тели иде. Дөрес, флотта аны башкача, "Скорцени" дип йөртә башлаганнар. Моңа тышкы охшашлыгы белән битендәге яра гына түгел, чиксез кыюлыгы, куркусызлыгы да сәбәп булган иде. Диңгез десантчылары арасында абруй казану авыр нәрсә, әмма ул тыныч көннәрдә хезмәт итеп тә күкрәгенә орден тагып кайтты. Ниндидер хәрби өйрәнү вакытында командирының тормышын саклап калган икән.

Читтән караганда бераз эрерәк тоелса да, Мәхмүтов үткен күзле, күзәтүчән егет иде. Армиядә хезмәт итү һәм дүрт ел буе Мәскәүдә хөр студент тормышының тәмен тату эзсез үтмәгән. Оренбургның гап-гади бер провинция икәнен ул бик тиз чамалап алды. Хәер, джаз, яңа биюләр һәм яңа мода монда да килеп җиткән иде инде, алар яшьләрнең тышкы кыяфәтен танымаслык үзгәрткән. "Топольләр"дә бу аеруча күзгә ташлана иде. Бию мәйданчыгын кап урталай бүлгәннәр диярсең, бер якта бөтен ил буенча "стиляга" дип даны чыккан яңа модага иярүчеләр биесә, залның икенче яртысында иске модага ябышып ятучылар таптана. Болары күбрәк ир-ат затыннан. Хатын-кыз кавеме яңалыкка тиз ияләшүчән, алар бер-берсеннән калышырга теләми, араларында аерма әллә ни сизелми кебек, әмма күзәтүчән кеше монда да ниндидер төсмерләр абайламый калмас иде.

Күз алдына китереп карагыз, бер якта зәңгәр төстәге, әйтеп бетергесез дәрәҗәдәге тар чалбар, аягына калын каучук табанлы туфли, өстенә шакмаклы күлмәк кигән егет торса, икенче яктагысының чалбары кулың киселерлек итеп үтүкләнгән вә чамасыз киң булыр, һәм, табигый ки, моңа изүе кендегенә хәтле үк ычкындырылган ап-ак күлмәк өстәлер, эчтән диңгезчеләр тельняшкасы күренеп торыр. Аларның һәркайсы каршы яктагыларның киемен мәгънәсез һәм ямьсез санар.

Яшьләр арасында менә шундый күчеш, сыныш хөкем сөргән чорда үтәргә туры килде диплом практикасын Булатка Оренбургта.

Шуның өстенә, бу якларда хакимлек иткән әхлак кагыйдәләрен вә йолаларны да истән чыгарырга ярамый. Ул чакта барыннан да элек көчкә табыналар һәм холкының никадәр ирек сөючән, баш бирмәс булуына карамастан, Нора теге яки бу егет белән йөрүдә дә ирекле түгел иде. Сүзен беркайчан да җилгә очырмый торган Форштадт ышпанасының янавы, куркытуын санга сукмау өчен никадәр үзсүзле, текә холыклы булырга кирәклеге дә аңлашыладыр. Чибәр Нора Форштадтта яши, шулай булгач, ул бары тик Форштадт егетенеке, ягъни мәсәлән, Ертык Закирныкы гына була ала. Моңа аларның иманы камил иде. Мәсьәләнең башкача хәл ителүен алар бөтен Форштадт

өчен хурлыкка санар иде. Форштадт намусын алар күз карасыдай саклый, үзләре Норага битараф булган хәлдә дә Ертык Закир өчен гомерләрен дә жәлләмәс иделәр. Хәзерге төшенчәләр буенча наив бер нәрсә кебек. Әлбәттә, шулай. Әмма ул елларда бер Оренбургта гына түгел, меңнәрчә башка җирләрдә дә гаиләләр әнә шул язылмаган кагыйдәләр нигезендә барлыкка килде, араларында чын бәхетлеләре дә аз түгел иде.

Әгәр дә "Люкс" салонының иң чибәр модисткасы Нора, аңлавыгызча, яңа моданы башлап йөрүчеләрдән, аны тормышка үткәрүчеләрдән булса, Закир төп мәгънәсендә аның киресе иде. Үлем куркынычы янаса да, пистолет көпшәсе төбәп торсалар да Закирга беркем дә, беркайчан да тар зәңгәр чалбар кигерә алмас иде. Тельняшканы салу турында, гомумән, сүз дә булырга мөмкин түгел. Моны ул флотка хыянәт итү дип санар иде. Ким дә түгел, артык та түгел. Сөйгәненең нинди юбка, нинди кофта киюе әллә ни мөһим тоелмый, ләкин шулай да, дус кызлары арасында аның аерылып торуы күңеленә хушлык бирә иде. Иптәшләре: "Кара, әнә гүзәлең Нора килгән, тагын һуш китәрлек күлмәк кигән",—дисәләр, башы күккә тигәндәй була. Кызның кием-салым белән мавыгуына ул каршы түгел, хәтта "гомерең буе бәрхет белән кеш киеп йөрерсең" дип ант иткәне дә булды. Флот хезмәтеннән соң Төньякта, алтын приискаларында эшләгәндә шундыйрак җыр ишеткән иде ул. Кеш тун ук булмаса да, аннан ким саналмаучы кара көрән төлке туны алып кайтты. Бу тунны аңа кәләшеңә бүләккә дип тайгадагы бер аучы биргән иде. Аның да шактый ук гыйбрәтле үз тарихы бар. Аучыны тулай торакта блатнойлардан коткарып калды Закир. Юкса, картны үтергәнче тукмарлар, Себердә кыш буе җыйган кыйммәтле тиреләрен дә талап алган булырлар иде.

Закир Нора белән тимер юлчылар сараендагы кичәдә танышты. Нора унынчы класста укый, ә Закир хәрби өйрәнүләрдә күрсәткән кыюлыгы өчен ялга кайткан иде. Әле тагын бер ел чамасы хезмәт итәсе бар. Аларның мөнәсәбәтләре баштан ук ябышып китте, дип әйтеп булмас, кыз хат язарга вәгъдә итмәде, истәлеккә фотосын бирмәде. Ләкин кыз хакында диңгезче егетнең күзе төшкәнен аңламады дип әйтеп булмый, әлбәттә. Аңа көн саен диярлек гашыйк булалар иде. Шуңа күрә, гаҗәпләнмәде дә, сөенмәде дә. Форштадта яшәп, "Топольләр"дә яшьли бөтерелә башлаган кызның күрше урамдагы Ертык Закир турында ишеткәне бар, флотка киткәнче озаткалап йөргән Светлана Соколянская дигән ахирәтен дә белә иде. Ертык Закир кебек абруйлы егетнең үзе белән сөйләшкәндә югалып калуы, дулкынлануы ошый иде аңа, табигый ки, күп кызларның көнләшеп карауларын да сизми калмады, әлбәттә.

Чапаев белән Оружейная урамнары чатында, кайчандыр чәй белән сәүдә иткән, Истанбулдан энҗе муенса алып кайткан бабалары төзеткән борынгы таш йортта яшәүче кара күзле, зифа буйлы укучы кызга башын югалтырлык дәрәҗәдә гашыйк булу өчен Закирга ун көн җитеп ашты.

Нораның фоторәсемен барыбер тапты, үзе белән алып китте, тапмаса Әхмәтшин да булмас иде. Язарга артык һәвәс булмаган егет берничә тапкыр хат та язды, әмма Нора аларның берсенә дә җавап бирмәде.

—Кайткач, кирәген бирәм әле мин аның,—ди иде караңгы чырай белән "Скорцени" кысан кубриктагы иптәшләренә, ләкин карават янында баш өстенә элеп куелган фотоны алып куймады.

Закир гражданкага нәкъ ике елдан соң өйләнеп кайтты, элеккегесе кебек үк нәкъ яңа ел алдыннан. Һәм тимер юлчылар сараендагы балда нәкъ элеккечә Нора янына килеп басты. Әйтерсең лә ике ел булмаган да, узмаган да. Кыз, гадәттәгечә, ахирәтләре, таныш егетләре арасында иде. Ләкин "Скорцени" аларны күрмәгән дә кебек аны биюгә алып чыгып та китте. Нора янында күз ачып йомганчы бушлык хасил булды, әле генә тирәсендә бөтерелгән егет-җиләнне җил очырып алып киттемени. Нора әле яңа вәзгыятьне аңлап җиткермәгән, моны көндәшләренең чираттагы бер мәкере дип уйлап баш вата иде, әмма ахирәтләренең берсе күзен ачты, гап-гади итеп аңлатты да бирде:

—Әхмәтшин кайтты бит,—диде ул аңа сабыйга әйткәндәй итеп.

Әхмәтшин үзе армиягә алынган таксопаркка өйләнеп кайтты. Тын океан флоты командованиесе кыю диңгезче тәрбияләп үстергән коллективка рәхмәт әйтеп, аның батырлыгы, ни өчен орден белән бүләкләнүе турында хат та җибәргән иде. Аны геройны каршылагандай каршы алдылар, монысы инде Закирны бөтенләй гаҗәпләндерде, юкса ул үзе кылганнарны батырлык дип сөйләп йөрмәс иде.

Нәкъ шул көннәрдә иң соңгы модельдәге "Волга" кайтарткан шәһәр комитеты гаражыннан чем кара "ЗИМ"ны таксопарк балансына күчергәннәр икән. Горкомда

жиде ел чамасы йөрсә дә, гел бер кулда булганлыктан, әле шактый әйбәт хәлдәге "ЗИМ" таксопаркта шактый бәхәс кубуга сәбәп булган, аны дәгъва кылучылар хәттин ашкан. Менә шунда Әхмәтшинны искә төшерәләр дә, ул коткаручы фәрештә шикелле була. Машинаны орденлы кызылфлотчыга бирү турында сүз чыккач, бу карарга парткомда да, профкомда да каршы төшмиләр.

Унган бригадага эләккән иде, төньяктан "Скорцени" шактый калын кесә белән кайтты. Җай килсә, анда бер елда кайчакта ун елда да эшләп булмаслык акча төшерәсең. Башын югалтырмын дип тормады, акчасын беркем белән дә бүлешмәде. Хәзер генә ул ярым пышылдап рэкетчы дип сөйләгән булалар, чынлыкта рэкет әллә ни гомерләрдән бирле бар, бары тик чит илдән кергән яңгыравыклы исеме генә юк иде. Әле армиягә киткәнче үк, аңа, авызыннан ана сөте дә кибеп бетмәгән егеткә, мәңге онытылмаслык бер вакыйганың шаһиты булырга туры килгән иде.

"Топольләр"дә биюләр башланырга әле шактый бар, вакыт үткәрергә дип, ул бильярдныйга кереп чыгасы итте. Ишек төбендә Форштадтның өлкәнрәк егетләрен очратты. Аларның күбесе белән Закирның мөнәсәбәте киеренке, чөнки яшь бүре баласы сыман ул Форштадт өерендә үз урынын булдырырга тырыша, ә монда урынны җиңел генә бирмиләр иде. Ләкин бүген ул кызрач егетләрне танымады, аларны, әйтерсең, алыштырып куйганнар, алар югары дәрәҗәле рәсми кешене озатып йөргәндәй, нәкысрәк бостон костюмлы, озын буйлы, аксыл чырайлы егетнең һәр сүзен йотып баралар иде.

Закир Төрек Госманны күреп белми, әмма аның шушы арада төрмәдән чыгарга тиешлеген ишеткән иде. Аның белән бик очрашасы да килеп тормый, чөнки киләчәктә Форшадтта үз урынын булдырырга һәм тоткан дәрәҗәсен беркем белән дә бүлешергә теләми иде. Күңелендә шундый шөһрәт сөючән уйлары бар иде аның. Әмма чигенергә, каядыр читкә китәргә соң иде инде, алар чак кына маңгайга маңгай бәрелешмәделәр, ул да башкалар белән бергә кул бирергә мәҗбүр булды.

—Их, Госманның кайтканын юасы иде бит,—дип куйды әле кичен генә кәрт уйнаганда соңгы ыштанын салырга мәҗбүр булган Колга Федька.

Егетләрнең кесә ягы такыр иде бугай, беркем дә дәшмәде. Закирның акчасы бар иде барын, ләкин ул аларны сыйларга җыенмый, чөнки аларны үзе өчен абруй санамый, сыйласаң, иң яхшысы, әнә яшьтәшләрең янында бул. Төрек Госман да аңа ошамады; дуамал карашлы шушы "үләксә"дән бөтен шәһәр куркып торсын әле, дип уйлап куйды ул.

—Үзем сыйлыйм,—диде кинәт Госман һәм ашыкмый гына кесәсеннән "Казбек" чыгарды һәм ябык кулы белән җәйге буфет ягына күрсәтте. Такта-фанердан оештырылган андый буфетлар элек бөтен ил буенча сибелгән иде.

Чакыру үзенә кагылмаган кебек Закир бер читкәрәк китте, исәбе бильярдныйда калу иде, ләкин Госман аның ни уйлаганын сизде булса кирәк, көтмәгәндә аңа атап эндәште:

—Нәрсә, Ертык, әллә мин кайтканга шатланмыйсыңмы?—диде. Тавышы тигез, хәтта ягымлы сыман, сүзләре дә гадәти кебек, әмма Закирның эчендә нәрсәдер куырылып килде, каны каткандай булды, блатнойларның бер-берсен Төрек белән куркытулары юкка түгелдер, мөгаен.

"Беркатлы лох түгел бу, түгел, кайтуга ук минем хакта да белешеп өлгергән",—дип уйлап куйды Закир Госман белән янәшә атлаганда. Күрәсең, аның яшерен ниятләрен дә җиткергәннәрдер, хәер, ул аларны яшереп тә тормый иде.

Җәйге буфет янында буш өстәлләр юк диярлек, пыяла тәрәзә янында халык мәш килә, шәраб белән аракыдан тыш, мичкәле сыра саталар. Шау-шулы дусларын буш өстәл табып утырткач, Госман Закирга таба борылды:

—Әйдә, миңа булышырсың,—диде дә буфетның арткы ишегенә таба китте.

Ишек шар ачык иде, әмма ул бушаган шешә әрҗәләре белән томаланган булып чыкты. Госман аларны эчкә таба тибеп җибәрде. Тавышка хатыны белән кулдаш булып эшләүче буфетчы йөгереп чыкты.

—Әссәламәгаләйкем, Шакир абзый, мөгаен, мине сагынып беткәнсеңдер инде,—дип шат тавыш белән эндәште Госман һәм пеләш башлы, юан гәүдәле адәмне кочаклап та алды.

Закирга алар күптәннән таныш булып тоелды.

—Кайтып життең, димәк,—диде тегесе артык шатлану хисләрен сиздермичә, үзе

калтыранган кулларын кая куярга белмичә интекте, алъяпкычының кырыен бөгәрләп маташты.

—Булды, кайттым,—дип раслады кунак,—беренче эшем итеп, дусларым белән синең янга килдем. Туган якка кайтуны юарга кирәк бит. Әйдә, тиз генә мәтәштереп ал, безнең танцыга житешәсе бар. Гүзәлкәйләр көтеп арыгандыр…

—Нәрсә бирим?—диде югалып калган буфетчы.

—Без алтау. Димәк, өч шешә аракы, кабымлык күбрәк булсын, эчтә бүреләр улый, соңрак кеше башына икешәрдән сыра. Яңа мичкәдән, кысласын да онытма.

Шакир абзый ялт итеп кухняга кереп китте һәм шундый ук тизлек белән поднос тотып килеп тә чыкты. Кабымлык мулдан иде: эре итеп туралган колбаса, сыр, ысланган майлы жәен кисәкләре, тозлы кыяр. Әржәдән өч шешә аракы килеп чыкты. Кабымлыклы подносны ул Закирга тоттырды, шешәләрне Госманның үзенә бирде. Акча түләгәндә кирәк булуым бар дип уйлаган Закир беразга гына туктап калды, әмма Госман акча урынына буфетчыга татуировка белән чуарланып беткән кулын гына тоттырды һәм битараф кына "рәхмәт" дип куйды, ашыкмыйча ишеккә таба атлады.

Саранлыгы, комсызлыгы телдән төшмәгән Шакир абзыйны мондый хәлдә күреп, Закир телдән калды, шулай да ишегалдына чыккач Госманнан сорыйсы итте:

—Ә акча?..

—Нинди акча?—дип гаҗәпләнде Госман.—Сдача алмадың, дип әйтмәкче буласыңмы?

Закир элеккедән дә битәр югалып калды, кайчандыр кәсебен трамвайда кесә карагы булып башлаган, соңрак кәрт уенында танылган шулер Госманның житез бармаклары күз ачып йомганчы буфетчының кесәсенә йөзлек акча, ягъни базар телендәгечә әйтсәк, "аякчу"ны шудырып өлгерде микәнни, дип уйлап куйды.

Ниһаять, Госманга да барып житте. Закирның бу кадәр дә "пешеп житмәгән" булуын көтмәгән иде ахрысы, шаркылдап көлеп жибәрде, кулындагы шешәләр бер-берсенә бәрелеп зеңли башлады. Хәтта алар төшеп ватылырлар кебек тоела иде.

—Ну, көлдердең син мине, Ертык, мәңге онытмам,—диде ул көлүен тыярга тырышып һәм куллары белән күз читләрен сөрткәләп. Аннан шешәләрне Закир кулындагы ирләрчә җайсыз-уңайсыз тотылган подноска куйды һәм өстәп әйтте:—Исеңдә тот, мин түгел, ә ул миңа үлгәнче бурычлы.

—Нәрсә, әллә кәрт уенында оттырган идеме?

—Карыйм, карыйм, жүләр икәнсең әле син, Ертык. Житмәсә, Форштадтта барысын үз астыңа алмакчы буласың. Энкәнең өчен симереп каткан Шакирга акча түләмәкче булгач, сиңа нигә ул өстенлек, хакимлек?

—Ә син ни эшли аласың аңа, син бит сәүдә инспекторы да, мент та түгел!

—Бик күпне эшли алам,—диде Госман артык жәелеп тормыйча. Ирennәре арасында цингадан бозылган кара тешләре күренеп китте. Аңлата башлады.—Мәсәлән, кулыңа монтировка тоттырып сине арткы бүлмәсенә жибәрә алам. Ике минутта өч әржә аракыны ватып чыгу ни тора. Ә бит аны аңа беркем дә списать итмәячәк.

Менә шунда гына Әхмәтшин тупас һәм ертлач буфетчының Госман алдында тәгәрәп йөрүенең сәбәбен аңлап алды. Дефицит сыраны Шакир абзый өстәлгә үзе китереп бирде һәм арты белән чигенгәндә, ялагайланып, Госманны теләсә кайсы вакытта килергә чакырырга да өлгерде. Ишегалдында булган сөйләшүне исенә төшердеме, Төрек кинәт гасабиланып чинап жибәрде:

—Сдача кайда?

Аннан башканы көтә дә алмаган буфетчы хәтеренең тишек иләккә әйләнүенә зарлана-зарлана яхшылап бөгәрләнгән ике йөзлек чыгарып сузды.

Форштадтка чын хужа кайткан. Закир моны шул көнне бөтен тирәнлеге белән аңлап алды да инде. Һәм нәкъ шул көнне "жиңел" тормыш романтикасының нәрсә икәненә төшенде, аның ахыр чутта кая илтеп чыгарачагын да күз алдына китерде.

Флотка, армия хезмәтенә чакырылу белән дә уңды ул.

Монда сурәтләнгән вакыйгалардан соң берничә ел үткәч, Төрек Госманның кайтуын "Топольләр" паркында, Шакир абзый янында бәйрәм иткән компаниядә катнашучылар коралланып Актүбәдәге ювелир кибетен басарга маташканда эләктеләр. Клим белән Колгасар Федьканы кибет түбәсендә атып үтергәннәр, аларны

Госман каплап торырга тиеш булган, калганнары төрле срокка тагын төрмәгә эләкте.

Алтын табучылар артеле тирәсендә Госман кебегрәк кешеләрнең, хәзергечә әйтсәк, рэкетирларның бөтерелүе "Скорцени"ны гаҗәпләндермәде.

Тайгада алтын эзләргә ул флотта чакта, демобилизациягә бер ел калып килгәндә үк язылган иде. Өч дус берләшеп эшләргә карар бирделәр. Аларның табышуы, бер-берсен аңлавы да табышмак булып калды. Өч дусның сыйфатлары бер-берсен тулыландыра, баета иде кебек. Колька Шугаев, мәсәлән, армиягә киткәнче үк алтын-көмеш белән эш итәргә өлгергән. Карабах егете Саркис Овенян алыптай таза гәүдәле, көче ташып торган баһадир иде. Каптеркада аңа тәки ярашлы парад мундиры таба алмадылар. Нинди ген бирер карамадылар, барысы да кысан иде. Юкса, флотта кәрлә кешеләр хезмәт итә дип тә әйтеп булмый. Өйгә кайткач, Одессага барып, флот исталегенә махсус заказ белән форма тектерәм, дип шаярта иде ул. Ничек итсә итте, интендантларның җелегенә үтеп бетте, шулай да кайтыр алдыннан офицерлар белән генералларга гына бирелә торган парад мундиры өчен материал алуга иреште. Булдырды егет.

Җай гына эшләп ятучы артель артык кечкенә түгел, барысы илле ике кеше булып, барысы да шушы ук коллективта эшләп ятучы биш уголовникка ясак түлиләр икән. Шым иткән кеше дә юк. "Агайлар"га түләргә кирәклеге, ул гынамы, шактый мулдан ычкындырырга кирәклеге беренче получканы алганда ук аңлашылды. Акча алырга баракка лагерьның карт бүресен ияртеп пахан үзе килгән иде. Тагын биш минуттан авызыннан каргыш вә янау сүзләрен ургыта-ургыта бaрактан чыгып очачагын күз алдына китермәгән булгандыр ул.

—Менә бу кирәкмиме сиңа?—дип сорады Саркис блатнойның борын төбенә бала башы зурлыгындагы йонлы йодрыгын куеп.—Хәләл акчамны синең белән бүлешсәм, гомерем буе үземне каргап яшәячәгемне аңлыйсыңмы син?

Кылт итеп Закирның күз алдына куркудан калтыранучы симез буфетчы килеп басты; юк, аңа охшарга теләми иде ул, әгәр мондый хәл була калса һәм ул Форштадттагы берәрсенә барып ирешсә, Ертыкның кемгәдер ясак түләвен белсә, аңа хәтта бер генә шкет та сәлам бирмәячәк иде.

Шугаев тыныч булып кала алды, нәфрәтен, ачуын йөзенә чыгармады.

—Монда һәрвакыт шулай булган, бу—тайга законы...—диде ул салкын гына, ләкин дусларын үгетләп маташмады. Озак кына тын торгач өстәп әйтте:—Сакланырга туры килер, блатнойлар бунт күтәргәнне яратмый. Һәм тимер караватъ янындагы стенадан бүрәнәгә кадакланган тактаны каерып алды, аннан көпшәсе киселгән мылтык—обрез килеп чыкты.—Кирәге чыгар әле дип, вездеход йөртүче Жоркадан алган идем, ул аны кайдадыр карт уенында откан булган.

Себер егете Шугаев аз сүзле, әмма ышанычлы, таянырлык кеше иде. Дүрт ел буе диңгез десантында хезмәт итү моны бер генә тапкыр расламагандыр. Аларның берсе дә флот туганлыгыннан шикләнми, һәм шунлыктан булса кирәк, үзләрен артык кыю тоталар иде.

Әгәр аларның алтын прискасындагы тормышын берәр язучыга яки кинорежиссерга сөйләсәң, мөгаен, үтә дә мавыктыргыч китап яисә кинофильм килеп чыгар иде. Йә калам, йә бетәм дип яшәү, туктаусыз көрәш ел буена туктамады. Шугаевның салкын канлылыгы һәм чыдамлыгы да, Әхмәтшинның блатнойлар гадәт-йоласын белүе һәм башбирмәс кыюлыгы да, Овенянның шаккаттыргыч көч-гайрәте дә, бер-берсенә сүзсез ышанулары да, кыскасы, азмы-күпме тормышта туплап өлгергән бар тәҗрибәләре кирәк булды. Уголовниклар алар арасына чөй кагарга бер тапкыр гына тырышып карамады. Шугаев янында бигрәк тә озак бөтерелделәр, Себер егете икәнен кат-кат исенә төшерделәр, ят диндәге кяферләрдән аерылса, ясактан азат итәргә дә вәгъдә бирер карадылар. Ләкин диңгезчеләр арасындагы бердәмлекне какшата алмадылар, флот аларны чын-чынлап туганлаштырган иде инде.

Берничә тапкыр төннәрен дөрләп янган бaрактан сикереп чыгарга да туры килде, обрез тотып, дусларының йоклаганын да саклап утырган чаклар булды. Ә көннәрдән бер көнне әбәт ашап утырганда кинәт, җан өшеткеч сугыш башланып китте. Ул чакта драгада механик булып эшләүче усал һәм мәкерле бандитны Овенян кулыннан могҗиза белән генә йолкып алдылар, юкса җан тәслим кыласы иде. Үлмәде, эт кебек, яңадан аякка басты. Ләкин ул инде исәпкә керми иде. Аның бандитлык гомере шуның белән тәмамланды. Өч кешегә каршы дүртәү калды. Артельдәгеләр ачыктан-ачык

аларны якламый, ләкин гаиләләрен исән-аман асрау уе белән йончыган Себер мужиклары диңгезчеләргә теләктәш, күп чакта алдан кисәтеп куялар, блатнойлар оештырырга маташкан мәтәвек хакында хәбәр бирәләр иде. Икенче обрез белән ике көпшәле винчестерны да алардан сатып алдылар. Акча мул төшә, диңгезче егетләр, бәлки, икенче елга да калган булырлар иде, әмма чираттагы амнистия якынлашып килгәнлеге мәгълүм, уголовниклар түземсезләнеп ярдәм көтә. Алар теләсә нинди кабахәтне дә үз даирәләренә алырга риза, чөнки диңгезче егетләр аркасында артель кулдан ычкына башлаган иде.

Закир биш елдан соң Оренбургка әнә шундый тормыш тәҗрибәсе туплап әйләнеп кайтты. Биш елда байтак сулар акты, Форштадт та үзгәрде, ышпаналар сирәгәйде. Берәүләре ул ил хәзинәсенә алтын эзләп йөргән якларга сөрелде, икенче берәүләре исерек сугышта пычакка кадалып гомерен очлады, өченчеләре төрмәләрдә һәм бәрелешләрдә сәламәтлекләрен бетереп, кан төкереп, һәм иң мөһиме—әйләнә-тирәдәгеләргә йогынтысын югалтып, тынычланып калды. Ләкин яшь җилкенчәкләрдә нинди дер бозыклык эзе, көзге әтәчләргә хас ертлачлык бар иде әле, үсмерләр арасында элеккеге Форштадт егетләренең маҗаралы кыланышлары легенда булып йөри, байтагының йөрәгендә яклау таба иде. Караклык, усалларча талау, шантаж кебек нәрсәләр яшьләрне артык кызыктырмый инде, ә менә баш бирмәс “егетлек”, кыю хулиганлык элеккечә югары бәяләнә иде әле. Бу даирәдән биш ел аерылып торса да, киң күңелле, ачык чырайлы, бу якларның Робин Гуды буларак танылган Ертык Закирның исеме онытылмаган иде.

Приискаларында җеп өзәрлек хәле калмыйча алтын юдырганда, кулына винчестер тотып иптәшләренең йокысын уголовниклар һөҗүменнән саклап озын-озак төннәр үткәргәндә ул туган шәһәрендәге абруе хакында башына да китерми, яраннары һәм тән сакчылары арасында, ниндидер бер президент сыман, һәр боерыгының сүзсез башкарылуына ирешкән Төрек Госман шикелле буласы да килми. Андый киләчәк кызыктырмый иде аны. Себердә калуы да акча җыю, кайтып йорт сатып алу янсә төзү һәм яхшы гаилә тормышы кору теләгеннән иде.

Нораның аңа төрмәгә ризык ташуын, аннан хатлар көтеп ятуын да теләми иде ул. Әле дә хәтерендә, моннан ун еллар элек, әле ул мәктәптә укып йөргән чакта, күрше урамдагы Әлфия исемле кыз асылынып үлде. Барысы да юктан гына кебек, кибеттә чиратта торганда аңа кемдер “бур сөйрәлчеге” дип әйткән имеш, кыз шуны күтәрә алмаган. Юкса, Әлфия яшьлеге белән ялгышкан бер бичара, аны аңлар дәрәҗәдә булганмыни?! Заманында Аркан кушаматлы Шамил аны тәмам сихерләгән. Форштадтагы Төрек Госманның элгәресе булган бу егет аңа кулыннан бар нәрсә дә килүче куәт иясе булып тоелган. Әнә шул куәт иясе утызга да җитә алмады, кыска гомеренең дә өчтән бере төрмәләрдә һәм лагерьларда үтте. Закир үзенең гомерен шулай мәгънәсезгә яндырырга теләми. Төшендә ул үз йортын, хатынын, балаларын күрә, хатыны булып бары тик Нора гына тоемлана иде.

Ул блатнойлар тормышына кереп батмавына, төзәтеп булмаслык хаталар эшләп ташламавына, “Топольләр”дәге теге кичәдә Госманның чын йөзен таный алуына сөенә, язмышына рәхмәтле иде. Төрек уголовниклар дөньясында иң югары баскычта, закондагы бур булып, андыйлар бөтен илдә бармак белән генә санарлык. Закир кемнедер куркытып, дер калтыратып ашап-эчүне, мәҗлес коруны күз алдына китерә алмый, дусларны исә бары тик хәләл акчага гына сыйларга ярый, дип белә һәм моның киресенә аны беркем дә ышандыра алмас иде. Хәтта бурдан, каракган тартып алынганы да аңа шатлык китермәс иде, монысын да яхшы белә.

Ике ел эчендә мәктәп баласы Нора бар яктан килгән чибәр һәм сөйкемле кызга әйләнде дә куйды. Яшьлегендә ышпана арасында үз урынын табарга ашыккан Закир кебек үк, ул да институтка барып тормады, мода өлкәсендәге сәләтенә таянып, үзен шул юлда табарга омтылды. Аның тумыштан килгән ниндидер үтә затлы зәвыгы, сиземләү сәләте бар, куллары алтын иде. Тырышлыгы җитәрлек. Модистка өчен болар иң асыл сыйфатлар. Баш июче ләр, артыннан йөрүчеләр хәттин ашкан булса да, кияүгә чыгу уе юк иде әле.

“Теләгемне белдерим генә…”—ди торган иде ул бу яктан бәхетләре чамалырак ахирәт кызларына күзләрен шаян елтыратып.

Аңа укымышлы егетләр, студентлар, яшь инженерлар һәм, табигый ки, Раушенбах тирәсендә бөтерелүче джазменнар күбрәк ошый, бу стилягалар ялан саен “Люкс”ка

киләләр, нидер тектерәләр, кыскарталар, таманлыйлар. Яңа ел кичәсендә үзенә гашыйк булган диңгезче егеттән исә ул, океан исе сеңгән, мәгънәсен аңлап бетерерлек булмаган берничә хат алса да, аны тәмам онытып, ул хатларга җавап бирү турында уйлап та карамаган иде. Закирның дуслары аңа еш кына сәлам тапшыралар, хәтта яныйлар, койрыгыңны бик болгап йөрмә, тиз кыскартырбыз дип кисәтәләр, менә Ертык кына кайтсын, ул тар балаклы җилбәзәкләреңне акылга утыртыр, диләр иде. Әмма яшьлеге белән ул боларның берсен дә җитди кабул итмәде.

Һәм менә Закир өйләнеп кайтты. Аның җитди ният белән кайтканын Нора бик тиз сизеп алды. Моңарчы янында бөтерелгән егетләр күз ачып йомганчы юкка чыкты. Төньяк белән арасын тулысынча өзеп кайтып, яңа ел кичәсендә Норага менә дигән төлке тун бүләк иткән көннән башлап, аның янында, әйтерсең, ниндидер бушлык хасил булды. Дөрес, аны хәзер дә биергә чакыралар, әмма аларның мөнәсәбәтендә нәрсәдер үзгәрде, күзләре элеккечә елтырамый, ә кызыйга үзенә сокланып карау, колагына бер-бер артлы төрле комплиментлар пышылдау ошый иде.

Бервакыт биюләр туктап торган арада ул оркестрның җитәкчесе Раушенбахка зарланып та алды, кияүгә чыкмаган тол хатын хәлендә калдым инде диде. Һәрнәрсәгә көлебрәк карауучы Марик уйлап та тормыйча әйтте дә салды:

—Нора бәгырькәем,—диде ул,—син бит хәзер тамгалы, сиңа "Закир кызы" дигән тамга салынган. Син шаһиншаһның сөекле кәнизәге кебек, аз гына чама югалтуга ул егетләрдән күз ачып йомганчы турсык, ягъни евнух ясыйлар да ташлыйлар. Закир белән шаярырга ярамый. Дөрес, джазменнарга аның мөнәсәбәте әйбәт, бусы синең аркада бугай, кич саен аның өчен "Аргентина тангосы"н уйныйбыз, күрәм бит, ул аны бары тик синең белән генә бии. Билләһи, алдамыйм, шактый матур күренәсез, шулай булгач, буйсын инде син, кызый,—диде дә үзен көтеп торучылар янына, сәхнәгә ашыкты.

Закирга аның мөнәсәбәте ике төрлерәк иде: бердән, аңа егетнең салон янына җиде урынлы чем-кара ЗИМда килеп туктавы ошый. Яңгырлы көннәрдә бигрәк тә. Лакланган кәттә машинаның эченә чумганда ул хатын-кызларның үзенә көнләшеп карап калганлыгын сизмимени. Шулай ук, аның игътибарлы карашын тою да күңелгә җылылык бирә, ул теләсә кайчан ярдәмгә килергә әзер, тынычландыра белә, аңлый ала. Яшьләр арасында үзен бәйсез тота алуы да күңеленә хуш килә. Ул чакларда моңа ирешү җиңелләрдән түгел иде. Үзенең болар өчен "Закир кызы" дигән тамгага бурычлы булуын да яхшы аңлый ул. Раушенбахның Закир тамгасын кыска һәм кискен итеп әйтә белүе аны гаҗәпләндерде. Ләкин тамга маңгайда гына түгел иде шул, ул үзен аяклары тышауланган кебек хис итә башлады. Әле яңа гына унтугыз яшь тулган кызның хөрлек яратучы җаны бернинди ирексезләүне кабул итә алмый, көчләп тагылган игътибар ятьмәсеннән ничек булса да котылырга тели иде.

Ошамаган яклары да күп. Закирның Себердән алып кайткан җүләр акчага отставкага чыккан әллә нинди бер интенданттан БМВ маркалы трофей мотоциклы сатып алган, шуңа утырып өйләре яныннан тырылдып уза да китә, уза да китә. Башка эше юк диярсең. "Топольләр"гә дә шуның белән килә, утырып йөрик дип җанына тия. Кыз мотоцикл дигән нәрсәне күрәлмас дәрәҗәгә житте, аның өчен драндулет дигән сүздән башкасы юк иде.

Ярый, бик әйбәт сакланган БМВга күз йомыйк, ди. Гәрчә ул мотоциклны да, мотоциклчыларны да сөймәсә дә... Болардан бигрәк аны башка нәрсә үрти. Закир паркка гитара күтәреп килә, ул көнне бию мәйданчыгында күренми диярлек, читтәге берәр аллеяда тирәсенә дусларын җыеп утыра бирә. Мондый кичләрдә ул Закирны күралмый башлый, аның янындагы дусларын исә ышпана дип кенә җибәрә, юкса арада юньле генә кешеләр дә була. Закир яхшы уйный, тавышы да матур, моңлы иде. Ник болар кызда нәфрәт тудыра соң, дип гаҗәпләнергә генә кала. Хәзерге буын яшьләре ышанмас та, монда сурәтләнгән чорларда гитараны түбәнлек билгесе, мещанлык атрибуты дип саныйлар иде. Кемдер хакында "Ул гитарада уйный икән", дисәләр, мондый бәя теләсә кемне аяктан егарлык иде. Көлке түгелмени? Ул гынамы, урыслардагы Машенька, Даша, Катя, татарлардагы Сәрия, Гөлйөзем, Мәрфуга кебек сөйкемле исемнәр дә борынгы булып тоела, авылчалык, колхозчылык билгесе булып санала иде.

Шул сөймәгән гитарасын рәхәтләнеп йомычкага әйләндерер иде Нора. Закир шул уен коралы белән аны аз да түгел, ким дә түгел, бөтен дөньяда хур итә кебек тоела. Ул

чактагы төшенчәләр буенча, гитарада уйнавы Закирны, кая инде ярату, хәтта аралашырга лаек булмаган түбән кешеләр янына алып ата иде. Тагын биш-алты елдан гитараның иң дәрәҗәле уен коралына әвереләсен, илаһи очышка күтәреләсен каян белсен ди ул! Гитара сәхнәдән оркестрларның бөтен җиз-бакырын очырып төшерәчәк әле. Раушенбах кебек саксофонда соло сызгыртса, яисә Глеб Кастоян шикелле трубада уйнаса, инде һич югы, Тәлгать Ямбулатов шикелләрәк итеп ялтыравыклы бәрмә коралларда дөмбердәтсә бер хәл иде. Юк шул. Ул берничә тапкыр шуларга өйрән дип тәкъдим итеп тә карады, Марик та Закирның музыкага искиткеч сәләтен раслап тора, ләкин егет кире үгез кебек катты да калды, гитараның җанын аңламауда гаепләде әле.

—Гитара җаны? Шул мещан уен коралында җанмы?—дип усал көлгән иде кыз ул кичне.

Җитмәсә, ягында ертык җөй. Кәефе начар булганда ул бары тик шул җөйне генә күрә дә иде.

Тагы... Киенүен генә кара. Хурлык бит. Монда да шул искелек калдыгы гитара шикелләрәк. Үгет-нәсихәткә, катгый таләпләргә колак салды салуын, кием-салымын бераз үзгәртте дә, Форштадтагы ахириләреннән нык аерыла башлады, ләкин Раушенбах даирәсенә, аның дусларына охшарга бик ерак иде әле. Ә инде тельняшка турында ул ишетергә дә теләмәде, аңа якынлашканда күлмәгенең өстәге төймәләрен бераз эләктерә башлады, бары тик нык ачуланганда гына иң соңгы сәдәфкә хәтле барып җитәр һәм "Инде канәгатьләндеңме?" дип сорар иде.

Кыскасы, алар алтын приискасындагы кебек үзара сугыша бирделәр, бары тик винчестер гына җитми иде.

Юк, хыялында сөйгәнен мондый итеп күз алдына китерми иде Нора, китерми иде...

Көннәрдән беркөнне Раушенбах аны "Топольләр"дә Мәскәүдән диплом практикасына килгән ике егет белән таныштырды. Ул елларда халыкның бүгенгечә күченеше башланмаган иде әле, Оренбургта газ ятмалары табылмаган чак булып, хәтта отпускыда каядыр барып кайту да олы вакыйга санала иде, һәм табигый ки, ерак башкаладан ике егетнең килеп төшүе игътибарсыз калмады. Мәскәү егетләре дигәнебез исә Булат Мәхмүтов белән аның аерылгысыз дусты Саня Кондратов иде.

Арбатта тәрбияләнеп үскән үткен егет буларак, Саня беренче кичтә үк оркестрда уйнаучы музыкантлар белән танышып алды, аларны уртак кызыксыну—музыка берләштерә иде. Саня һич иренмичә Олег Лундстрем оркестры (аның хакында кеше ышанмаслык имеш-мимешләр күп йөри иде) һәм Александр Цфасман турында сөйләп ташлады. Джазның Ленинград мәктәбе, анда патша булып утыручы Вайнштейн һәм әле көчен сынап кына карауччы джаз аранжировщигы Кальварский турында да сүз чыкты. Кыскасы, Кондратов барысын да белеп сөйли, Арбатта да, институтта да ул джаз фанаты санала, яхшы гына фонотекасы бар, яңа дусларына ул аннан өлеш чыгарырга да вәгъдә итеп өлгерде. Шулай итеп, алар беренче көннән үк "Топольләр"дә шактый күренекле кешеләргә әйләнделәр.

Әгәренки ул көннәрдә Закир шефлыкка алынган колхозга җибәрелмәгән булса, ике практикантның килеп төшүе Нораның язмышында берниндн чагылыш тапмаган булыр иде.

Раушенбах паркта аларны үтеп барышлый гына таныштырды. Соң иде инде, биюләр беткән, халык тарала башлаган. Алар бер-берсен юньләп күреп тә өлгермәделәр. Әмма тагын бер көннән, якшәмбе иде бугай, Марикның туган көне булды. Оренбург джаз сөючеләренең кумиры аны үзенчә "бик олы юбилей" саный, хәер, монысы шаярту гына булса да, провинциаль шәһәр өчен Раушенбахның туган көне чын-чынлап истәлекле һәм мөһим бер вакыйгага әйләнде, бию кичәсен өзмәс өчен хәтта паркка пединститут оркестрын чакырырга туры килде. Зәвык һәм яшьләрчә уен-көлке белән үтәсе кичәгә бик күпләрнең эләгәсе килә иде. Тик бу даирә үзе дә шактый киң һәм күпсанлы булып, аның үз шагыйрьләре, рәссамнары, җырчылары, актерлары бар, музыкантлар турында әйтеп торасы да юк, кыскасы, яшь зыялылар җыелган мәҗлескә эләгү шактый четерекле мәсьәләгә әверелде. Әмма кичәгә керү хокукы бирүче бер өстенлек бар, анысы исә джазга мәхәббәтеңнең чынлыгы иде. Табын янында ике яшь инженер Нора белән аның дус кызы янына туры килделәр. Кичә беткәндә генә кунакчыл хуҗа бер читкәрәк чакырып, Мәскәү егетләренә Нораның четереклерәк халәте һәм Ертык Закир турында сөйләп бирде, мөнәсәбәтләрне артык тирәнәйтмәскә киңәш итте.

Итагатьле Марик соңрак кисәткәнме, бәлки, язмыш кушуы булгандыр, әмма озакка сузылган кичә барышында егет белән кыз йөрәгендә очкын кабынып өлгергән иде инде. Ничек кабынмасын, кызлар яшь, чибәр, сөйкемле, һәр нәрсәгә сокланып караучан иделәр. Инженер һөнәре дә сатириклар һәм усал кайнаналар телендә көлү вә сүгенү ләһҗәсенә әйләнеп өлгермәгән, хатын-кыз таифәсендә мыскыллы елмаю уятмый иде әле. Бәлки, кирәсенчә булгандыр. Бүгенге күзлектән караганда, фантастика булып тоелырлык хәл. Юк шул, ул чакларда Оренбургта, ярым татар, ярым рус шәһәрендә Миша, бераз соңрак Жора, татарларда Рөстәм-Рустик, Җәүдәт-Женя булганда уңышка ирешү җиңелрәк, һәрхәлдә, сине башкалардан өстенрәк санарлар иде. Менә шундый гаҗәеп вакытлар иде ул. Маша-Дашалар, Сәрия-Мәрфугалар искелек калдыгы, кызык түгел, ә Жора яисә Рустик булып йөрү үзе бер хыял сыман, инженер һөнәре дә көлке саналмый. Оркестрлар инде Дюк Эллингтон һәм Глен Миллерны уйный, Бунин белән Есенин, Хемингуэй белән Ремарк китаплары кулдан төшми башлаган иде, шул ук вакытта яшь йөрәкләрне җилкендергән Раушенбах хуҗалык иткән сәхнәдән бер-ике адым гына читтәрәк торган җәйге буфетта Форштадтның хуҗасы Төрек Госман сыра чөмерә иде.

Егетләр Марик әйткәннәрне игътибарсыз калдырмады, Кондратов мондый шәһәрләрдәге блатнойларның аяусыз усаллыгын яхшы белә, Мәскәүдә, бигрәк тә Ордынкадагы ышпаналар тормышыннан хәбәрдар иде ул. Алар арасында да үз Ертыклары булып, исеме генә башкача, Шамил икәнлеген дә хәтерли иде. Ләкин барыбер озата киттеләр. Төн буе бергә биегән, күңел ачкан кызларны ялгыз калдырмассың бит инде, аларның кинәт читкә кыяклау сәбәбен дә кызлар дөрес аңламас иде. Беркемнең дә куркак булып күренәсе килми.

Ул кичтә Саня танымаслык булып үзгәрде, хәер, Нораның дус кызы Сталинага карата Марик бернинди тыю сүзләре дә әйтмәгән иде. Һәркайда беренче булырга яраткан егет Сталинаны гына түгел, бөтенесен дә сокландырырга тели иде бугай, Раушенбах янында мәш килүче ир-егетләргә дә эрудициясен, белемен, башка гадәтләрен күрсәтергә, шуның белән үзенең өстенлеген расларга тырышты. Һәм кичә азагына шуңа ирешә дә, кыз-кыркын гына түгел, барысы да аның һәр сүзен йотып бара башлады. Сталина исә Санядан күзләрен ала алмый, авызына кереп китәрлек булып тыңлый иде.

Бер көннән соң алар тагын "Топольләр"дә очраштылар, дөресрәге, тәнәфес вакытында оркестрантлар белән сөйләшеп торганда кызлар җир астыннан үсеп чыккандай алар янында пәйда булды. Бәлки аларның да үз планнары булгандыр. Нораның Булатны ак биюгә чакыруын күргәч, сәхнәдәге Марик бармак янап алды, Нора шаярып кына җавап бирде:

—Нәрсә, синең дустың аркасында хәзер миңа юньле кешеләр белән аралашырга да ярамыймы?

Саня белән Сталина арасында кабынган мәхәббәтне кеше күзеннән яшерерлек түгел иде инде, кызый егетнең бармакларын бер генә минутка да кулларыннан ычкындырмый, аның бу игътибары Кондратовны бөтенләй үсендерә иде.

Нора белән исә барысы да катлаулырак, четереклерәк. Арада, әйтерсең, Ертык Закир корып куйган күзгә күренмәс пәрдә тора, телисеңме-теләмисеңме, аның исеме килә дә чыга, Нора белән Булатка үткен пычак белән кискәндәй әйтелгән ярым шаярулы, асылда җитди һәм куркыныч мәгънәле сүзләр килеп җитә.

—Курыкма, мин сине рәнҗеттермәм, сакларммын,—дип шаярта Нора һәм Булатка сыена.

—Мондый матур исемле кыз янында үлсәң дә үкенечле түгел,—дип җавап кайтарды Булат һәм Нораның яңакларында кабынган алсулыкны абайлап алды.

Шулай да ул кичне Закирның дуслары белән чак кына бәрелеш булмый калды. Еракта ахирәтләрен күреп алган кызларның читкәрәк китүе булды, бер төркем егетләр аларны койма буена кысрыклады. Әгәр дә бу аңлашуның иң киеренке ноктасында Раушенбах килеп чыкмаса, моның ничек тәмамланачагы билгесез иде.

Марик үзе тиешле санаган бер егетне читкәрәк алып китте, мәскәүлеләрнең үзенең дуслары икәнлеген, кызлар белән аның туган көнендә танышканлыкларын, Закир хакында белүләрен, кисәтеп куелганлыкларын, бу очрашуларның исә бары тик башкала егетләре белән интеллигентларча аралашу гына икәнлеген аңлатты. Дусишләр Закирның Нора аркылы джазменнар, бигрәк тә Раушенбах белән

аралашканлыгын беләләр иде, шунлыктан, практикантларны тынычлыкта калдырдылар, ләкин киткәндә янап алырга да онытмадылар:

—Кара аны, Марик, ул-бу булса, Закир алдында үзең җавап тотарсың. Нора хакына ул бертуган абыйсын да кызганмаячак.

Төнлә үзләре бүлмә алган Аренда бистәсенә кайтып барганда Булат көтмәгәндә әйтеп куйды:

—Беләсеңме, Саня, мин Ертык Закирны бик яхшы аңлыйм. Мин дә Нораны башка беркемгә дә бирмәс өчен кулымнан килгәннең барысын да эшләр идем.

—Нәрсә, дускай, гашыйк булдыңмы әллә?—дип сорады гаҗәпләнгән Кондратов.

—Бәлки... Ләкин безне кисәтеп куйган минуттан бирле мин үземне кулда тотарга тырышам. Шөлләдем, дип әйтеп булмый, безнең халыкта шундый ышану бар: читятларныкы барыбер бәхет китерми. Бездә кәләшне балачактан ук ярәшеп куялар һәм алар арасына керү иң зур гөнаһ санала. Андыйны беркем дә аңлый алмас. Монда да шундыйрак хәл. Нора үзе әйтте, Закир аны байтактан, флотта хезмәт иткән чагыннан ук ярата һәм кияүгә чыгарга да тәкъдим ясаган.

—Бигрәк иске карашлы кеше икәнсең, изге диярсең, сөйгәнеңне шулай җиңел генә ташлап китәрсеңме? Миңа калса, мәхәббәт өчен көрәшә белергә дә кирәк. Без әле күреп тә белмәгән Закир әнә нәкъ шулай эшли дә.

—Сүзләреңдә мантыйк бар-барын, әмма без башка кавемнән, без гадәт-йоланы ана сөте белән сеңдерәбез, нәселдән килә торган сыйфат ул,—дип үзенекен сукалады Булат.

—Ә Нораң Сталина шикелле иректе булса?—дип түземсезләнеп сорады Саня.

—Ул чакта бөтенләй башка эш. Синең шикелле баш әйләндереп кенә йөрмәс идем, ике дә уйлап тормый өйләнер идем. Матурлыгын гына кара, фәрештә диярсең, аңа карасам, хәтта башларым әйләнеп китә, моңа кадәр әле минем беркайчан да болай булганы юк иде...

—Әйе, институттагы буялган чәчле кызлар әйтмешли, битараф азиат гүзәл җенес хакында болай сөйли башлаган икән, эшләрең начар синең Булат...

—Шулайдыр ахрысы,—дип җитдиләнеп җавап бирде Булат,—һәм мин язмышны сынап карамаска булдым. Бер атна өйдән чыкмыйча диплом өстендә утырачакмын, ә син Сталина белән йөри бир, ул арада, бәлки, Ертык Закир да кайтыр һәм барысы да үз урынына утырыр. Әгәр минем белән кызыксынса, кая югалуымны сораштырса, берәр нәрсә уйлап табарсың шунда...

Шулай итәргә килештеләр дә.

Бәлки бу вакыйга шушының белән тәмамланыр һәм бүген Булат җанындагы тагын бер гөнаһта казынып, күңел яралары алып утырмаган булыр иде. Әгәр дә өч көннән соң Кондратов кайтып Сталина белән булган төнге сөйләшү хакында әйтмәгән булса, шулай булыр иде дә. Дөрес, ул нииндидер яшерен максат куеп сөйләмәгән. Гадәтенчә Булат әйткәннәрнең барын да Сталинага җиткергән, беркемгә дә чыгармаска вәгъдә алган. Шуннан соң сүзне җыеп кара инде син! Бигрәк тә нииндидер егетнең дустыңа өйләнергә әзер икәнен бел дә, телеңне тыеп кал. Яшь кызлар күтәрерлек йөкмени?! Әгәр дә серне шул ук көнне дустына җиткермәсә гомере буе газапланып яшәр иде. Кызлар холкының андый нечкәлекләрен Кондратов тоемлый аламыни. Хатын-кыз теләсә нинди баш әйләндергеч вәсвәсәгә бирешмәскә мөмкин, әмма кияүгә чыгу турында ишеткәч, аның күңелендә барысының да асты өскә килә, саклык, чамалап эш итү, акыл бизмәнендә үлчәп карау диган нәрсәләр бер дә булмагандай юкка чыга. Хәтта ялгыш кына әйтелгән сүз дә, киная дә аларда йоклап яткан хыялны уята, хыялларында патша сарайларына тиң йортлар калкып чыга, әллә нинди планнар барлыкка килә, алар теләсә нинди елганың агымын кире борырга әзер. Әгәр дә мондый планнар тууга сәбәп булган сүзне әйткән берәр кемсә ул прожектларны күрә калса, һичшиксез, башын тотып күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга чыгып качар иде. Һәм инде моннан соң тәкъдим ясау урынына якындагы ун елга нинди өмет-ниятләр булырлыгы бөртекләп тасвирланган никах шартнамәсе-килешүе тотып килер иде.

Нора белән дә нәкъ шулай булды, әле моңарчы беркем дә керә алмаган йөрәгендә Булаттан башка һичкемгә урын калмады. Ул "Булат" дип пышылдаганда егет күңелендә ут кабынган кебек, аның үзенең дә бу исемне әйткәндә башы әйләнә башлый һәм ул аны көнендә йөзәр мәртәбә кабатлый иде.

Ә бергә буласы тормыш бары тик алсу буяуларда гына гәүдәләнә. Туйдырып

бетергән Оренбургтан, ышпана тулып яткан Форштадттан чыгып китү иң сөендергәне иде. Үзен ул йә Мәскәүдә, йә Ташкентта, йә Владивостокта итеп күз алдына китерә. Кондратов эшкә кайда билгеләүләре мөмкинлеген, хәтта Булатны кафедрада калдыру ихтималы барлыгын да ычкындырып өлгергән иде. Мәскәүне исә ул тоташтан мода йорты дип уйлый, менә кайда колач җәеп булыр иде, күренекле ханымнарга, данлы актрисаларга киемнәр тегәр иде! Мәскәү аның өчен әллә кайдагы, ерак-еapproxтагы шәһәр, буш сүз түгел, аларның өендә башкала турында сүз еш чыга, чөнки чәй белән сәүдә итүче бабасының Ордынкада хәтта үз йорты булган, аны революциядән соң тартып алганнар. Менә ул, имеш, күз явын алырлык матур күлмәк киеп Мәскәү театрларында йөри, кичке реклама утлары балкыган Горький урамында сәйран чигә. Мәскәүнең үзгендәге бу урамны Булат белән Саня илтифатсыз рәвештә Бродвей дип кенә җибәрәләр иде. Тагын күз алдына булачак йорты килеп баса, менә ул Булатның дусларын һәм хезмәттәшләрен кунак итә, алар арасында Сталина белән Саня да бар, имеш. Ни хәл итәсең, ахирәтләрнең андый планнары да бар иде.

Нораның уйлары юк-юк та һаман Булатка әйләнеп кайта, аның танцыга йөрми башлавына әллә нинди баш әйләндергеч сәбәпләр таба. Кондратов томан җибәреп өлгергән, дус кызлар берсеннән-берсе кызганычрак әллә нинди вариантлар уйлап чыгардылар, болар тормыштагыга караганда күбрәк кино күренешләрен хәтерләтәләр иде. Әмма телисеңме-юкмы, сәбәп бар—итагатьле, тәрбияле мәгъшукларның кавышуына колхозда печән чабып ятучы бер усал зат комачаулык итә. Закирның дуслары Булатка янаганнардыр, үтергәнче куркытканнардыр сыман булып тоела, бу хакта хәтта Кондратов та белми торгандыр. Аларның Мәскәү студентын гына түгел, теләсә кемне өркетә алганнарын, Форштадтта гомер кичерүче буларак, ул бик яхшы белә иде. Мондый фараз тагын башка уйлар тудыра, кулын сорарга җыенучы Булат ышпанадан куркып калгандыр, шуңа күренмидер кебек тоела башлый. Эштә чакта исә күз алдында коточкыч күренеш пәйда булды, хулиганнар тарафыннан кыйналып ташланган Булат Арендa бистәсендә ята һәм, табигый ки, бу кыяфәт белән аның күзләренә күренергә кыймый. Көтелмәгән ачыштан ул чак кына елап җибәрмәде, мондый хәл буласын алдан ук чамаламавына үз-үзен битәрләргә кереште.

Эштән иртәрәк китте һәм базарга чапты, егет янына үзең килү никадәр генә гарьлек саналмасын, Булат янына барыбер кереп чыгарга булды. Боларның барысында үзен гаепле саный, очраклылыкка таянырга ярамый, нәрсәдер кылырга, мәхәббәтеңне яклап көрәшергә кирәк дип белә иде. Өйгә кайтуга тавык пешерде, әбисе белән вак бәлешләр ясады, пыяла банкаларга тозлы кыярдыр, кайнатмадыр кебек тәм-том тутырды, озак уйлап тормыйча, буфеттан бер шешә яхшы шәраб алды һәм кичен, танцы урынына Арендага китеп тә барды. Ул үзенең фаразларына шулкадәр нык ышанган иде, күңелендә яраткан кешесен кызгану хисе шулкадәр тирән һәм аянычлы иде, Булатны сау-сәламәт хәлендә күргәч, ирексездән елап җибәрде һәм бик озак тынычлана алмады.

Булат көтелмәгән тансык кунакны үзенчә тынычландырырга кереште, юка инсәләренә ефәк шәлдәй сузылып төшкән чәчләреннән сыйпады, яшьләрен сөртте. Тыела алмыйча үксүдән калтыранган үтә кадерле җан иясен кочагында тоюдан, аның якынлыгыннан исерде, хәтта үзе дә елап җибәрергә әзер иде. Бераздан, тынычлана төшкәч, Нора яшьләрен йота-йота бүген нинди хисләр кичергәнен, аны нинди хәлдә күз алдына китергәнен сөйләп бирде.

Кызлар белән артык күп чуалмаган һәм мондый хәлгә беренче тапкыр тарыган Булат үзе дә Норадан ким дулкынланмаган иде. Кызны кочагыннан чыгармаган килеш җанында инде күптәннән бәргәләнгән назлы сүзләрне пышылдады, һәм алар, мөгаен, Нора күптән ишетергә теләгән мәхәббәттә аңлашу булгандыр да.

Төнлә, шактый соңарып кайткан Кондратов аларны өйалдында, хуҗаның зур җиз самавыры янында тыныч кына гәп корып утырган хәлдә күрде, күзләренең сәер елтыравыннан алар арасында ниндидер бер мөһим нәрсә булганлыгын аңлап алды. Һәм бу чыннан да шулай иде. Алар мәхәббәттә аңлашып, бер-берсенә тугрылыкта вәгъдәләр биреп өлгергәннәр һәм киләчәктә аларны бары тик бәхет кенә көтәсенә чын күңелдән ышаналар иде. Алар Закир турында, һәрхәлдә, бу кичтә башларына да кертеп карамадылар, Нора барысын да үз өстенә алды.

Закир менә-менә шәһәргә кайтып төшәргә тиеш, бу хакта Норага бик тиз җиткергәннәр иде инде. Аерылышканда ул Булаттан "Топольләр"гә килеп йөрмәвен,

Закир белән барысын да җайга салганчы күзгә күренмәвен үтенде, болай да тәшвишләнеп көтүдән изаланып беткән иде. Инде хәзер, барысы да хәл ителгәч, Ертыкны үртәргә ярамый, ачуы чыкса аның ни кыласын белеп булмый, кайчандыр паркта котырынган чагы әле дә күз алдында.

Чабып барган атны туктатыр, янгын телләре чорнаган өйгә ташланыр—бу сүзләр йөрәгендә мәхәббәт уты кабынган хатын-кыз турында әйтелгәндер, андыйларны берниндә киртә туктата алмый, алар бернәрсәдән дә курыкмый. Хәзер инде Нораның Закирны көтеп газапланасы килми, арадагы аңлаешсыз һәм сәер мөнәсәбәтне тизрәк өзеп ташлыйсы килә иде. Мәхәббәт ялкынында сулкылдаган җанның бәргәләнүен аңларга була, шуңа күрә ул дуслары аркылы аның кичекмәстән шәһәргә кайтуын сорады. Икенче көнне кич белән Әхмәтшин "Топольләр"дә пәйда булды да. Сөенеченнән нишләргә белмәгән Нора аңа каршы ташланды һәм бию мәйданчыгыннан алып та китте. Паркта өч сәгать буе, аннан соң Форштадтта, аларның өе янында таңга кадәр сөйләштеләр. Барысын да кичерергә, күрергә туры килде: күз яшьләре һәм ялварулар, түбәнсетү һәм янаулар, үгетләү һәм куркытулар, пышылдау һәм ярсып кычкырып җибәрүләр—берсе дә, берсе дә калмады.

"Бергә булырга язмаган икән, туган абыем бул",—диде Нора һәм аның аяклары астына егылды, гомере буе туганы итеп яратырга вәгъдәләр бирде. Бу кадәр ялыну, ялвару, мәхәббәте хакына теләсә нинди корбаннарга әзер тору кебек хисләргә беркем дә каршы тора алмас иде. Барлык бу хисләр үзенә дә якын һәм таныш булган Закир кызның бу кадәр ялваруын күтәрә алмады, сынды, таң алдыннан ул кызга туганы кебек булырга һәм аны сакларга ант итте.

Бер көн узгач, кара төн уртасында Арендада практикантлар яши торган веранданың ишеген шакыдылар. Соңга калып килгән кунаклар Закир белән Раушенбах булып, аларның моңа кадәр кайдадыр инде бик озак аңлашканнары сизелә иде. Марикның уңайсыз елмаюыннан аның үз ирке белән килгәнлеген дә төшенеп була иде. Кунакларның болай кызуы, күрәсең, ярсулы әңгәмәдән генә түгел, аларның һәркайсының кулында икешәр шешә аракы да бар иде.

—Сеңлемә гашыйк булган кеше белән танышырга килдем,—диде Закир керә-керешкә һәм шешәләрне шартлатып өстәлгә утыртты.

Аның артында калган Марик нindидер ымнар, ишарәләр ясый, куллары белән нәрсәдер күрсәтә, болар барысы бергә "курыкмагыз" дигәнне аңлатырга тиеш иде бугай.

Закир, артында ниләр кылынганны сизгәндәй, кинәт арыган тавыш белән әйтте:

—Әйе, әйе, курыкмагыз, мәхәббәтне йодрык белән тотып торып булмый икән. Давай, стаканнар бирегез дә, мәхәббәт турында сөйләшик, Марик сезне бик укымышлы, белемле егетләр дип ышандырды.

Әллә нинди көтелмәгәнчә сәер төн булды ул, кайберәүләр гомере буена да андый көчле кичерешләрне татый алмый! Закир җаны бәргәләнүгә чыдый алмый, эчендә янартауларның утлы ялкыны белән янәшә бозлы таулар бәрелешә, аның бу хисләрне авызлыклап, кемгәдер сөйлисе, тәүбә-истигъфар кылгандай бушанасы килә, җаны шундый урын эзли, вакыты шундый иде. Арендадагы иске сәүдәгәр йортының верандасы нәкъ шундый җир булып чыкты да.

Бушану кайнар һәм гыйбрәтле булды. Ерак төньякта ялкын телләре чорнаган барак, Форштадтта варисы булып калырга өндәгән Төрек Госман, коткаручысына рәхмәт йөзеннән Нора исемле кәләшенә дип тайгада төлке тун бүләк иткән аучы карт, океаннар гизүче корабның кысан кубригы, "Скорцени" кушаматлы матросның караваты өстенә эленгән фоторәсем, кызның күңелен рәнҗетүче гитара—берсе дә калмады һәм алар җавапсыз калган мәхәббәткә гимн булып яңгырады.

Дипломатлык итагатеннән бихәбәр Ертык бер генә тапкыр да турыдан-туры Булатка мөрәҗәгать итмәде, ләкин алар барысы да аңа сөйләнде, дөньядагы иң кадерле нәрсәсен—сөйгәнен канлы йөрәгеннән аерып алучы, бирелгән анты аркасында аны сеңлем дип атарга мәҗбүр кешене аңларга мөмкин һәм мөмкин дә түгел иде.

Төн бер мизгел шикелле генә тоелды, шешәләр бушады, ләкин аракы алмый иде, сүз һәм хисләр аракыдан көчлерәк булып чыкты, бары тик хисчән Марик кына вакыт-вакыт яшереп тә тормыйча күзендәге яшьләрен сөртеп ала һәм бу кичтә әллә ничә тапкыр кабатланган тостны игълан итә:

—Мәхәббәт өчен!

—...Мәхәббәт өчен...—дип арыган тавыш белән кабатлады Булат Мөэминович.

Кулына стакан тоткан Раушенбах аның күз алдына шулкадәр ачык сурәттә килде ки, әйтерсең болар әле кичә генә булган кебек иде. Ә бит инде моңа утыз ел үтеп тә киткән...

"Канымда сатлыкҗанлык геннары бармы икән әллә?"—дип коты очып уйлап куйды Мәхмүтов, өстенә салкын су койган кебек булды. Инкыйлаб Рәхимовна әтисе хакында аның сатлыкҗан, хыянәтче булганы өчен атып үтерелгәнлеген сөйләгән иде түгелме соң?

Әтисе хакындагы шөбһәле уйлары бераздан күңел тынычлыгы белән алышынды, генетик нәселдәнлек турында сүз дә булырга мөмкин түгел, чөнки аны киресенчә, нәкъ менә тирән ышануы һәм тугрылыгы өчен, башка идеяләргә һәм идеалларга тугры калганы өчен атып үтерделәр дә. Яңа властька тугрылыкка ул ант итмәгән, димәк, моны сатлыкҗанлык дип атап булмый. Ә Сәет Алимханга ул, мөгаен, Коръән тотып ант иткән булгандыр.

Юк, Булат кылган гамәлләренә җиңел аклану табарга теләми иде, бигрәк тә бүген.

"Сатлыкҗан...—дип тагын кабатлап куйды ул тагын бер мәртәбә. Бүген ничәнче кабатлавыдыр инде, анысын үзе дә белми.—Тыныч кына яши бирәсең, йокы бүсәсең, кешеләр, тәгәлрәге, массалар язмышын хәл итәсең, ә ул кешеләрне күргәнең дә юк... күргәнең дә юк..."

Һәм кинәт кенә аңында бүгенге кулланышта сирәк очрый торган сүз—вөҗдан сүзе калкып чыкты, әйтерсең үзе дә сизми Кызыл китапның "В" хәрефе куелган битен ертып алды. Әйе, иләккә салган судай тормышыбызда вөҗдан дигән нәрсә юкка чыкты, комга сеңеп беттемени, һәм аны эзләргә, табарга, хокукларын кайтарырга бик ашкынып та тормыйлар, чөнки барысына да болай җиңелрәк, изелүчеләргә дә изүчеләргә дә, ә инде җаныңда вөҗдан дигән нәрсә булса, тегесе дә, монысы да була алмас иде.

Югалган сүзнең баш миен туктаусыз бораулап торуы юкка түгелдер, кайбер сүзләр күзгә күренерлек төсмер алу сәләтенә ия, алар фоторәсем ясагандагы кебек ачыклана баралар һәм төгәл сурәткә әйләнәләр. Үзенең бөтен аңлы тормышын Булат Мөэминович төрле дәрәҗәләр, вазифалар, орденнар алган лаеклы вә мөхтәрәм кешеләр арасында үткәрде, ләкин бүген бик сирәк кулланылучы вөҗданлы сүзен ул аларның титулларына һәм бүләкләренә кушып әйтә алмый, теле әйләнми, җаны карыша иде. Әгәр дә аңа кемне дә булса чын, асыл мәгънәсендәге вөҗданлы дигән нәзәкатьле исем белән билгеләп үтү хокукы бирсәләр, алар, һичшиксез, Инкыйлаб Рәхимовна һәм аның махсус интернаттагы хезмәттәшләре булыр иде, хәтта блатнойлар Форштадтындагы ялган романтикада үскән Ертык Закир атлы егетне дә кай ягы беләндер шул исемлеккә кертеп булыр иде. Чөнки алар ант, бурыч, намус, сүз бирү, горурлык кебек төшенчәләрне, ул сүзләр туры мәгънәсендә ни аңлатса, нәкъ шул мәгънәсендә аңлыйлар һәм бернинди ташлама, искәрмә ясамыйча кулланалар да иде.

—Вөҗ-дан-лы,—дип куйды Булат һәм бу сүзнең әйтелешендә үк матур, горур яңгыравын абайлап алды. Шуны аңлады, әгәр бүген аңа кем дә булса үзенең бөтен дәрәҗәләрен һәм бүләкләрен исеменә кушылачак шушы сүзгә—бернинди ташлама, аерым хокуклар һәм өстенлекләр бирми торган сүзгә—алыштырырга тәкъдим итсә, ул озак уйлап тормас иде.

Кинәт кенә яңа сорау туды: "Ярар, дәрәҗә һәм дә вазифамны кызганмыйча алыштырдым ди, аннан гына чын вөҗданлы кеше булырмынмы соң?" Артык баш ватуның мәгънәсе калмады, изге китапларда язылган "Бер тапкыр алдасаң..." дигән мәгълүм тәгъбир кылт итеп исенә төшкән иде.

Беренче мәхәббәтенә, Норага хыянәт иткән, аның бөтен тормышын бозып ташлаган кешене вөҗданлы дип буламы? Моннан беркая да кача алмыйсың. Мәскәүдән нинди хатлар яза идең бит!

Ә Закирга карата кылынганны ничек аңлатырга, дөресен генә әйткәндә, син аның тормышын ботарлап аттың һәм үлеменә сәбәпче булдың.

Намус белән, вөҗдан белән әйткәндә, шулай ук Нора язмышына да син җаваплы.

Әле өйләнмәгән, райкомда инструктор булып эшли башлаган чагы иде. Зөһрә Мәскәүдә институт тәмамлап кына килә, шул көннәрдә ул кәтмәгәндә Кондратовтан туйга чакыру алды. Сигез ел буе бергә шатлыкны да кайгыны да уртаклашып гомер кичергән иң яхшы дусты өйләнә иде. Кондратов аның язмышына уңай йогынты ясаган

бик азларның берсе, аның аркасында ул инженер булды да бит. Саня Сталинага өйләнә. Кайчандыр уйнап кына башланган роман шулай итеп никахлашуга килеп җиткән иде.

Табигый ки, Булат туйда Нораны очратачагын төшенде, иске дусты аңа тагын бер талпынырлык, вөҗдан белән эш итәрлек мөмкинлек бирә иде кебек. Юкса, Саня Зөһрәне дә белә...

Юк, соңгы мөмкинлекне файдаланмады, туйга бармады, телеграмма җибәрү белән чикләнде, янәсе, эше күп, сәламәтлек какшап тора, дөресрәге, вакҗанлылык күрсәтте, курыкты ул чагында. Хәзер, намус хөкеменең иң югары кимәлдәге таләпләре яктылыгында фикер йөртсәң, яшьлек дустын да саткан булып чыга. Шулайдыр... Юк, нәкъ шулай, чөнки ике елдан соң ул Кондратовтан тагын бер хат, соңгы хатны алды.

Дөрес, хат Саняның үзенә адресланган булып, аны Оренбургтан Сталина язган иде. Ул кечкенә улы белән туган шәһәрендә кыш үткәрә, ә Саня Ангарада үзен танытачак, данга күмәчәк өченче күперен төзеп ята иде.

Сталина барысын да бәйнә-бәйнә тасвирлаган иде. Төрек Госман ирекгә чыккан, тагын иске гамәлләренә тотынган, Форштадтта яшьләрдән һәм иске дусларыннан яңа банда оештырган. Шулай бервакыт Госман районндагы банкны басмакчы булган да, аларга машина кирәк булып чыккан. Моның өчен иң кулае такси. Закирга әйтеп караган. Әхмәтшин баш тарткан, дуслары белән Төрек: "Әйдә без сине бәйлик тә, машинаңны алыйк, һөҗүмнән соң шәһәрдә ташлап калдырырбыз",—дигән. Закир монысыннан да баш тарткан. Сүз уңаеннан, аңа ун мең сум вәгъдә иткән булганнар.

Талауны чигерә алмаганнар, банктагы шымчылары акча килгәнлеген хәбәр иткән булган, банда ашыга башлый, кулга төшәсе акчаны читкә җибәрәселәре килми. Закир белән килешә алмагач, Госман киткәндә ачуын яшерми, машинаны көч кулланып табачакларын әйтә.

Аларның таксины урлап алып китәчәкләрен, бәлки иптәшләреннән кемнеңдә булса һәлак булачагын Закир берсүзсез аңлап ала. Банданы куып җитеп, Госманны читкәрәк чакыра да әйтә:

—Әгәр дә бүген төнлә берәр таксист һәлак булса, үзеңне дә якты дөнья белән бәхилләштем сана,—ди.

—Тынычлан, Ертык, безгә юеш эш кирәкми,—дип гасабиланып җавап бирә Төрек,—бар, эшләвеңне бел дә, ментларга ычкындырма, артык изге булып кыланасың... вөҗданлы кеше имеш...

—Ничек булдыра алсам, шулай яшим, ә мин әйткәннәрне онытма, мин дә сүзләремне җилгә очырмыйм,—ди Закир һәм машинасына таба китә.

Ике адым да ясарга өлгерми, Госман мәче җитезлеге белән аның артыннан сикерә һәм аркасына, калак сөяге астына, нәкъ йөрәк турысына пычак белән кадый.

Бер сәгатьтән соң Форштадтта Закирның бандитлар утырган машинасы кинодан кайтып килүче Нораның күзенә чалына һәм ул ниндидер яман хәл булганны сизенеп, участковыйга чаба. Тревога буенча өлкәдәге бөтен милицияне аякка бастыралар, Төрек Госманның ниләр майтарып ташларга сәләтле икәне мәгълүм, таң алдыннан шәһәргә керү юлында аларны бөтен табышлары белән кулга төшерәләр.

Закирны күмәргә бөтен Оренбург килә, һәр ике таксопарк шоферлары чистартылган, ялтыратылган машиналарда, сиреналарын туктаусыз кычкырта-кычкырта үзләренең иптәшләрен соңгы юлга озата.

Сталина шулай ук Нораның Закир кабере өстендә ничек өзгәләнүен дә язган иде. Аларның мөнәсәбәтләре якыная башлаган, инде туйга да күп калмаган булган.

Авыр, моңсу хат иде ул, ахырында тагын бер кайгылы хәбәр килеп чыкты.

Закирның үлеменнән соң Нора үз-үзен кая куярга белмәде, дип яза иде Сталина. "Бу каһәрле шәһәр мине ике сөйгәнемнән дә аерды, мин монда кайчан да булса бәхетле була алмам", дип өзгәләнде. Кырыгына, Закирның әнисе рөхсәте белән, "Кичер мине, сөеклем... Нора" дип язып граниттан кабер ташы куйдырган. Кырыгын үткәргәндә дә үзен Закирның хатыны кебек тоткан, ә икенче көнне... юкка чыккан. Хат та, бернинди язу да калдырмаган. Менә ничәнче ай эзлиләр инде.

Сталинаның хатына Кондратов бернинди өстәмә-фәлән язмаган, "Исәнме" дә, "Сау бул" да юк, хат үзе барысын да аңлата иде.

"Сатлыкҗанлыкның эзе гомер буе эзәрлекләп килә".—Моны бүген Булатка раслап

торуның кирәге юк. Күрәсең, хатынынннан алган хатны җибәргәндә Кондратов аларның дуслыгына җеназа укыган көн булган. Моннан соң алар беркайчан да күрешмәделәр, хат алышмадылар, гәрчә бик теләсә, Булат армиядә бергә хезмәт иткән сабакташ дустын Мәскәүдән бик җиңел эзләп таба ала иде, Кондратов танылган кеше, аның исеме матбугатта еш күренеп тора. Ләкин ул Булатка нәрсә дип әйткән булыр иде, синең тормышың тоташыннан вак-вак сатылулардан тора дипме? Ә моны ишетәсе килми…

“Юк инде, нинди генә хәйлә корма, вөҗданлы булу—безнең хакта түгел”,—дип ачынып уйлады Мәхмүтов.

Зөһрәгә өйләнеп, үзен һәм иптәшләрен аны яратам дип ышандырып, ул үзенең беренче хыянәтен ясады. Кемне алдыйсың, йөрәгендә барыбер Нора иде, наз тулы хатлары Оренбургка агылып торды лабаса. Мәхәббәтне үлчәүгә куялармыни, сөйгәнеңнең югары белемле яисә талантлы модистка булуы мөһиммени? Ә инде дөреслек пәрдәсен тагын да күтәрә төшсәң, үлчәү тәлинкәсендә Зөһрәнең белеме басмады, Нора әле унтугызынчы яшь белән генә бара—ул да укый алган булыр иде, их, мәхәббәт өчен ул гына киртә булсамы… башка як тартты, үлчәүдә Зөһрәнең әтисе—югары дәрәҗәдәге партия работнигының йонлач кулы да бар иде шул. Мәскәүдәге даими вәкиллеккә еш кереп йөргән Булат аның юмартлыгы хакында ниләр генә ишетми иде.

Булатның Оренбургтагы элемтәләре хакында белгән Зөһрә кулындагы куәтле коралны бик саклык һәм осталык белән эшкә җикте, тоткан җиреннән сындырырга курыкты, чөнки ул вакытта кияүләрне ачыктан-ачык сатып алмыйлар иде әле һәм… үз дигәненә иреште дә.

Зөһрәнең әтисе кызының ирен райкомга алдырды, хәтта промышленность бүлегендә урын бушаганны да көтеп тормады, үзе исән чагында киявен райком секретаре итәчәген белә иде. Һәм үзенекен итте, кияү балакай белемле, мәнле кеше булып чыкты, яшьлеге белән дә башкалардан аерылып тора иде.

—Син хәзер номенклатура кешесе, гомерең буе обоймада утырачаксың,—ди торган иде югары дәрәҗәдәге кәнәфи биләүче кайнатай тиешле кеше.—Ә күперләр, төзелеш белән әвәрә килүең бер сафсата гына, иң күп дигәндә трест управляющие була алырсың. Төзүчеңең шуннан артык күтәрелер җире юк. Шуннан нәрсә? Үзең шикелле бер малай-шалай, райком инструкторы чакырып алыр да, үзе синнән ике тапкыр яшьрәк булуга карамастан, урын да тәкъдим итеп тормастан, пешереп чыгарыр. Пешерергә сәбәп һәрвакыт табыла ул. Өскә партия линиясе буенча үрмәлә, власть алар кулында булды һәм булыр да. Инженер, хуҗалык эшлеклесе, галим, язучы, артист—болар берсе дә ышанычлы түгел, өметсез, менә авам-менә авам дип торган багана кебек, бары тик номенклатура кадрлары гына кыйммәтле, алар гына бәяләнә.

Бабай тиешле кеше Зөһрә шикелле үк яман чирдән бик иртә үлеп китте, күрәсең, бу аларның нәселендә бардыр. Зөһрәнең хакимият башындагы әтисе шулай иртә вафат булмаса, Булат, мөгаен, бүген республика башкаласындагы кәнәфиләрнең берсендә утырыр иде һәм, табигый ки, Ленин музее филиалы ачылу тантанасында катнашкан һәм карт большевичка йөрәгенә тагын бер яра ясаган булыр иде. Үзенең тарих укытучысы Даниярова белән очрашудан качмас иде бит, кача алмас иде.

Уйлар бер вакыйгадан икенчесенә сикерә, күз алдында бер-бер артлы таныш йөзләр алышына, кешеләр һәм төрле урыннар пәйда була: Мәскәү, Кунцево, институт, солдат казармалары, Кызыл мәйдан, Мавзолей, Сталинны күмү, Оренбург, кара ЗИМ руленддәге Ертык Закир, Форштадттагы элеккеге чәй сәүдәгәренең ике катлы кызыл кирпеч йорты, “Топольләр”дәге джаз, “денди” Раушенбах, Арендада диплом эшен язып бетергән йортның верандасы, Җаек суы, әрәмә, Нора, джаз сөюче Кондратов белән Сталина, илленче еллар ахырында Мәскәүдәге якташлык, Коканд детдомында үткән еллар, Инкыйлаб Рәхимовна һәм аның киресе Әхрар Гыйниятович Гыйниятов, Зөһрәнең аның язмышына килеп кергән әтисе, нишләптер төшләрендә һаман җимерелгән булып күренүче Карасу күпере, гориллага охшаган күрше—менә бүген дә, төн уртасында аның ни уйлаганын тикшереп торырга маташучы милиция башлыгы Халтаев, вакыт-вакыт ул аны янәшәсендә торган кебек хис итә башлый, әмма тора-бара күнекте тагы; Ташкентта Ленин музее филиалы ачылу, анда Данияроваың катнашуы тантанага бөтенләй башка төсмер биреп җибәргән иде һәм Булат Мөэминовичның үзенең тормышы; Истанбулдан кайткан эзже муенса, Миассәрәне

күрәлмый башлаган обком секретаре Тилләхаҗиев; яшереп җыйган миллионнарыннан колак кагучы Раимбаев, полковник погоннары таккан ялган полковник төркемендә нишләптер лейтенант Халтаев килеп чыга; хәзер инде күптән мәрхүм булган, тар бостон костюмлы Төрек Госман—болар бөтенесе дә әллә нинди тыгыз чуар йомгакка әйләнделәр, һәм менә шушы чуар йомгак аның тормышы була да иде инде.

## II БҮЛЕК

*Мамык Наполеоны, Аксай ханына ахалтекин чаптары, Бохара әмиренең алтыны, туган көнгә докторлык диссертациясе, ОБХСС башлыгының догасы, өйгә китереп бирелгән партбилет, дучега охшаган кеше*

Ташкентта инде бик күптәннән булган тантанадан уйлар башкасына—башкалада булмыйча, район дәрәҗәсендә генә узса да киң колачлыгы белән алардан калышмаганына әйләнеп кайтты. Байлыгы, муллыгы, шау-шуы белән ул хәтта аларны уздырып та җибәргән иде бугай. Ул чакта илдә ниндидер ярыш, көндәшлек рухы хөкем сөрә иде—кем теге яки бу чараны затлырак, баерак итеп үткәрә ала. Бәйрәмнәр һәм юбилейлар эстафетасы мәмләкәт буйлап тугыз баллы дулкындай ургылып уза, янәсе, "күрегез, без кемнәр" яисә "без дә төшеп калганнардан түгел", эш белән булмаса, юбилейлар белән шаккаттырырбыз.

Үзенә илле яшь тулган көнне, аның юбилеен районда шулай кумпайтып, шау-шулы итеп үткәргәннәр иде. Дөрес, ул үзе бернәрсәгә дә кагылмады, оештырып йөрмәде. Райком аппараты аңа ярарга теләп, һәркайдагыча артыграк тырышып ташлаган булып чыкты: тау башында ни булса, итәгендә шул булыр, ди бит. Юбилей комиссиясен турыдан-туры Халтаев үзе җитәкләгәнне ул соңрак, газеталардан гына белде. Өлкә газетасында матурлап ретушьланган фоторәсеме белән күләмле мәкалә басылып чыкты, ә район газетасын әйтсәң дә юк. Баш мәкаләсеннән башлап иң соңгы абзацына кадәр аңа багышланган иде, Карасу күперенең рәсеме ярты битне алып тора. Кылган игелекләре хакында укырга да уңайсыз иде.

—Артык төче язылганнар,—диде ул басылган мәкаләләр хакында газета редакторына, тегесе аны шәхсән үзе тәбрикләргә дип шылтыраткач.

Әмма газета эшендә ярты гомерен үткәргән, нинең ни икәнен яхшы белгән карт бүре көлеп кенә куйды:

—Юкка рәнҗетмәгез, теләсә кемне илле яшьлегенә Ленин ордены белән бүләкләмиләр,—дип җавап бирде ул.

"Чыннан да, бер карасаң, теләсә кемгә мондый югары бүләк тәтеми шул",—дип уйлап куйды ул сөйләшүдән соң һәм мәкаләләрнең артык купшы язылуы хакындагы уйлары да юкка чыкты.

Культура йортындагы рәсми өлештән соң кунаклар ишегалдына кайттылар, ул чакта менә бу айванны сүтеп алырга, хәтта ике агачны кисеп ташларга туры килгән иде. Хатынының бер дә кистерәсе килмәгән иде дә, тик Халтаевны туктатып буламыни, монда да ул үз бакчасындагыдай кылана бирде.

Мияссәрә аны яратып бетермәгәнен яшереп тормый иде, шул чакта әйткәне әле дә колакта яңгырап тора кебек:

—Мондый мәрәкәне Халтаев кына оештыра ала, ай саен мәҗлес уздырып шомарып бетте инде, җае гына чыксын... Шул "Волга"сының туган көне генә уздырылмый калгандыр да. Киң күңелле, юмарт кеше имеш, аның мондый мул табыннарны ни өчен оештырганын белмиләрмени, халыкны дуракка санагач та... Йола дигән булып бүләк җыю икәнен сабый бала да аңлый бит. Юкса, ришвәтне ачыктан-ачык биреп булмас иде. Ни генә алып килмиләр аңа. Исләрең китәр... Барысын да капка янына чыгып үзе каршы ала, кемнең ни китергәнен, ничек сулаганын да белеп тора ул.

Кызым сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигәндәй, Булат бу сүзләрнең яшерен мәгънәсенә бик тиз төшенде. Мияссәрә турыдан-туры әйтергә базмыйча, кешеләр синең хакта да шулай уйламасын, дияргә теле иде. Шунлыктан Халтаевны кисәтеп куйды, беркем дә бернинди әйбер дә күтәреп килмәсен, диде. Табигый ки, Халтаев барысын да үзенчә аңлаган һәм "буш кул белән, әмма чиста күңел белән килергә кирәк" дигән күрсәтмә тараткан, ләкин милиция башлыгының гадәтен яхшы белгәнгә,

күпләр моны киресенчә аңлаган, бүләкнең кыйммәтен икеләтә, өчләтә арттырырга кирәк дип кабул иткәннәр. Райком хуҗасы милиция башлыгы аша буш хәбәр җиткертмәс! Ә инде Мәхмүтовның бу мәсьәләдә артык нәзакәтле, таләпчән икәнлеген яхшы белгән Халтаев юбилярның кәефен бозмаслык җайлы юл тапкан. Кунаклар юбиляр янына аның ишегалды аркылы керергә тиеш булдылар, кыенсындырып торган бүләкләреннән шунда арынып чыктылар. Бу исә бөтенесенә дә шулай булырга тиешле булып тоелды.

Юбилейның искә төшүенә мәҗлеснең артык бай, мул һәм купшы булуы гына сәбәп түгел иде. Хәер, анысы да искә алырлык. Өстәлләрдә ниләр генә юк иде… Бөтен көйгә кыздырылган сарык түшкәләре, җаен вә божыр пылавы, тауларда махсус ауланган киек-фәлән ите, күрше буада тотылган форель дисеңме—барысы да бар иде… Иң танылган җырчылар, музыкантлар, хәтта районга янәсе Ташкенттан очраклы рәвештә килеп эләккән ике биюче юбилярга мәдхия укып, җырлап, уйнап, биеп торды… аны шигырь белән дә, җыр белән дә мактадылар, өлкәдәге күренекле кешеләр сынын коюда специальләшкән Заркент ташкисәре бөтен рәвешен китереп 137 номер сугылган гипс сын бүләк итте, кычкырып игълан ясады: 137 номерлы бу сәнгать әсәре киләсе айда республика башкаласындагы сәнгать күргәзмәсенә, бөтенхалык игътибарына тәкъдим ителәчәк, диде. Бераз буталган шикелле итеп, әллә инде игътибарны күбрәк юнәлтер өчен бераз тын торганнан соң, ул күргәзмәгә чит ил кунаклары да киләчәген өстәп куйды. Аның сүзләрен көчле алкышларга күмделәр. Мәхмүтовның үз зурлыгында сын койган ташкисәр нәрсәне күздә тоткандыр, шатлыгы эченә сыймаган кунаклар нәрсә уйлагандыр, нәмәгълүм, бәлки аларга мондый орденлы шәхес бөтен дөньяны шаккаттырырга мөмкин булып тоелгандыр?

Юбилейны ул бүген бөтенләй башка сәбәпләр аркасында искә төшерде.

Якшәмбе көнне иртән, өендәге эш бүлмәсендә Ленин орденын учына куеп, аны сынга ясалганы белән чагыштырып утырганда, әйтергә кирәк, сындагысы чынынннан өч тапкырга зуррак булып, шунлыктанмы гайре табигый һәм законсыз булып тоела иде,—ишеккә кыяр-кыймас кына шакыдылар. Җавапны көтеп тә тормастан, үзен кертмәсләр дип уйлагангамы, ашыгып-кабаланып бусагада бакчачы Хәмракол әкә пәйда булды. Бүлмәгә керүгә үк ул, бер сүз дә дәшмичә, кәнәфидә утыручы орденлы кеше алдына килеп егылды; берни дә аңламаган хуҗа сикереп торды, өстәл яныннан чыгар өчен кәнәфине кузгатырга керешә, чөнки карт аны почмакка бикләп калдырган иде. Гаҗәп тәэсирле күренеш иде бу: буй-буйлы ефәк пижама кигән, түрәләрчә тук чырайлы, кулына Ленин ордены тоткан таза Мәхмүтов, аның артындагы китап шкафында үз зурлыгындагы сын һәм… аның алдына тезләнгән, сәламәләргә төренгән карт.

“Хан йортындагы иртә”… Заркент сынчысы моны, әгәр дә җитәрлек фантазиясе булса, шиксез, шулай дип атар иде.

Карт аның аякларына ябышкан иде, шулай да хуҗа җаен табып бу сәер тоткынлыктан ычкына алды. Картны келәмнән торгызмакчы булды, әмма тегесе кул-аяклары белән җиргә ябышкан, бу мөмкин хәл түгел иде кебек.

—Ялварып сорыйм, зинһар, тыңлагыз…—диде Хәмракол әкә хуҗаның ишектән чыгып китәргә һәм кемнедер ярдәмгә чакырырга җыенуын сизенеп. Халтаевның бакчада кичәге юбилей мәҗлесенә корылган өстәлләрне сүтеп йөрүен күреп алган иде инде ул.

—Торып кәнәфигә утырсагыз гына тыңлыйм,— диде Хуҗа кискен итеп. Ул инде көтелмәгән бу хәлдән айнып өлгергән иде.

Карт җитез генә келәмнән торды һәм юбилярны ишегалдындагы кешеләр чакырып алыр, яисә телефон бүлдерер дип курыккангамы, ашыгып тезәргә керешә:

—Алла хакы өчен минем улымны коткарыгыз, райпотребсоюз базасында склад мөдире булып эшли ул, исеме Рәхмәтулла, аны сезнең күргәнегез дә бар, иң зур склад анда, начальство дефицитны шуннан ала. Зур суммада җитмәүчелек, без аны түлибез, каплыйбыз, тик эшне япсыннар гына…

—Бу суд, прокуратура, ОБХСС, милиция эше, мин аларның эшенә тыкшына алмыйм. Дәүләт милкен әрәм-шәрәм итүчеләрне, җинаятьчеләрне яклавым турында ишеткәнегез бармы?—дип каты итеп җавап бирде ул һәм сөйләшүне беткәнгә санап, ишеккә таба юнәлде, әмма карт көтмәгәнчә җитезлек белән сикереп торды һәм юлны бүлде.

—Сез әйбәт кеше, тамырыгыз яхшы нәселдән, сез әмир шикелле үк бөтен тирәякның хуҗасы, сез ничек әйтсәгез шулай була, мин күп яшәгән, күпне күргән кеше, белеп әйтәм: сезнең сүзегез законнан өстен! Сезнең бәйрәмгә безнең гаиләдән бүләк булсын, бу чын күңелдән, үзегезгә кирәге чыкмаса, балаларыгызга ярар.—Һәм ул көтмәгәндә аңа күн янчык сузды.

Булат Мөэминович кискен генә аның кулын читкә этәрде, янчык картның калтыранган кулларыннан ычкынып идәнгә төшеп китте, келәмгә алтын патша тәңкәләре сибелде.

—Каян алдыгыз моны?—диде йөзе агарып киткән райком секретаре.

Хәмракол әкә келәмгә тезләнеп, бер сүз дә әйтмичә алтын тәңкәләрне җыярга керешге. Тынлык озакка сузылды һәм Булат моның бер-бер провокация булмагаеннан шикләнеп инде Халтаевны чакырмакчы иде, карт тонык тавыш белән сөйли башлады:

—Болар синең әтиең белән миңа яхшы заманнар килгәнче Сәет Алимхан сакларга кушып калдырганнарның бер өлеше, без аның белән бер хезмәттә идек. Синең әтиең Мөэмин түгел, ә Әкбәр-хаҗи, әйбәт кеше иде, мәрхүм, хәтта үлем куркынычы астында да мине сатмады, аның улы мине яклар, канаты астына алыр дип уйлаган идем...

—Мине нишләп Әкбәр-хаҗиның улы дип уйлыйсыз?

—Сез—коеп куйган әтиегез, бер тамчы су кебек, хәтта чигәгездә миңегез дә нәкъ аныкы, тавышыгыз, бөтен килеш-килбәтегез әтиегезнеке. Аннан соң, мин сезнең кайда үскәнегезне, укыганыгызны белештем, барысы да туры килә, мин ялгышмыйм. Әгәр теләсәгез, Сәет Алимханның җәйге сараенда әтиең белән бергә төшкән фоторәсемне бүләк итә алам, әмир сараенда бик яхшы фотограф бар иде, хезмәт хакын ул минем кулдан ала иде...

Мәхмүтов "ә" дә, "җә" дә димәде, ишек яныннан китеп тәрәзә катындагы диванга барып чүмәште. Бакчачы аның каршындагы журнал өстәленә алтын тәңкә тутырылган янчыкны китереп куйды.

—Алып куегыз, минем өйдә ничәнче ел яшисез инде, ришвәт алмаганны белергә тиешсез.

Карт шомартып ялтыратылган өстәлдән алып янчыкны куенына кыстырды. Булат Мөэминович сүзсез генә утыра бирде, ләкин карт бакчачы да чыгып китәргә ашыкмый иде. Ниһаять ул ялынган сыман сөйли башлады:

— Алла шаһит, сезнең күңел яраларын кузгатырга теләмәгән идем, гафу итегез, ләкин үзегез мәҗбүр иттегез... Бөтен кеше дә ала бит, сез дә алсагыз, мин дә дәшмәс идем... Чигенер урыным юк. Улым—иң өлкәне, биш баласы бар...—Карт бәйләнчекләнмичә, ашыкмыйча гына сөйли, әмма Мәхмүтов сизенә, моның артында ниндидер шантаж бар сыман. Моны кем оештырган, артында кем тора? Ленин ордены аның уч төбен яндыра, фикерен тупларга комачаулый кебек. Бер көн дә тагып йөри алмадым, дип уйлап куйды ул. Ләкин егерме елдан артык власть башында утырган кеше буларак, үзен бик тиз кулга алды. Һич көтмәгәндә, кирәкмәгән чакта ачылган серенә ия кеше алдында җебеп төшү ярамас, үзеңне тагын бер кат коткарырга инде Даниярова юк, дип уйлап куйды ул һәм бер карарга килде:

—Мин сезгә ярдәм итәрмен, ләкин минем әтиемне белгәнгә түгел, ә бәлки безнең йортта эшләгән кеше буларак, Зөһрә истәлегенә ярдәм итәрмен, ул сезне бик ярата иде, ләкин... бер шартым бар...

Хәмракол әкә дулкынлануын тыя алмыйча ашыгып әйтте:

—Теләсә нинди шартка да риза...

Кабинет хуҗасы инде хәлне үз кулына алган иде.

—Шартлар мондый,—дип дәвам итте ул.—Улыгыз бурычын каплый, ярты елдан да калмый районны ташлап китә, башка өлкәгә күчә. Дәүләт кесәсенә кулын тыкмаслык итәргә кирәк. Шунлыктан, әрәм-шәрәм итү турындагы документлар минем сейфта сакланыр, икенче кат мин аңа ярдәм кулы сузмам, хәтта үзегезне минем бертуган абыем дип ышандырсагыз да.

Карт кайчандыр әмир сараендагы гадәте буенча ишеккә таба арты белән китте, рәхмәтләр укый-укый бүлмәдән гаип булды.

Булат Мөэминович тормыш сәерлекләре турында уйлап куйды, шатлыгы да кайгысы да янәшә йөри икән. Нәкъ менә бүген бәйрәмне бозарга кирәк бит! Ул үзенең "Мөэмин улы" урынына "Әкбәр улы" дип язылган документлары хакында күптәннән

оныткан иде инде. Карт алдамый, Инкыйлаб Рәхимовна да аңа атасының исемен онытмасын өчен нәкъ шулай дип әйткән иде, ләкин ул аның "хаҗи" икәнлеген, мөселман дөньясында иң мәртәбәле гамәл—Мәккәгә хаҗ кылган кеше булганлыгын беренче тапкыр ишетте.

Иң соңгы мәртәбә ул болар хакында әле институтта укыганда, деканатка кереп, анкетасына төгәллекләр кертергә җыенган чакта Кондратовка сөйләгән иде, әмма иптәше киңәш итмәде. Хәер, соңгы тапкыр Саняга түгел, ә булачак кайнатасы Әхрар Гыйниятовичка сөйләгән икән. Киявенең биографиясендәге шундый факт аның югары урынына зыян китермәсме, дип турыдан-туры сорады. Зөһрәнең әтисе көлеп кенә куйды, киявем шундый дәрәҗәле ата-анадан икән әле, дип сөенде генә. Ә инде боларны ачарга кирәк түгелме дигәч, "Үткәннәрдә казынырга кирәкмәс, күптән инде бала атасы өчен җавап бирми", диде.

Һәм менә хәзер, югары дәрәҗәләргә ирешкән, детдомдагы вакыйгаларны һәм Инкыйлаб Рәхимовнаны оныткан, атасының яңа исеменә күнегеп беткән бер заманда атасын һәм аның кылган гамәлләрен белгән шаһит табылсын әле! Райком секретареның партиягә кергәндә яшереп калдырган мондый фактны теләсә ничек әйләндерә алырлар иде, районда да, өлкәдә дә дошманнары бар, җайга салынган хуҗалыгы келтерәп барган районга кызыгучылар җитәрлек, әзергә-бәзерне йотарга җыенучылар бетмәс.

Ә нишләп боларны партиядән яшергән? Сорауга җавабы да бар анысы, ул бит Зөһрәнең әтисенә бернәрсәне дә яшермичә сөйләп биргән иде, Инкыйлаб Рәхимовнаны искә алырга да онытмаган иде. Әхрар Гыйниятович гади коммунист кына түгел, өлкәдәге барлык коммунистлар өстеннән дә коммунист, обком секретаре, партия съездлары делегаты, депутат. Ләкин хәзер боларга кем генә колак салыр икән, һәр нәрсәгә көче җиткән Гыйниятов бакый дөньяда. Мәхмүтов биографиясендәге фактны яшереп калдырганда Әхрар Гыйниятович яшерен максатны күздә тоткан, чөнки ямьсез кызын Мәскәүдә укыган өметле яшь белгечкә кияүгә бирәсе булган, димәсләрме. Бөтен партияне кайнатаң белән тәңгәл куярга ярамый яравын, әмма ул чакта сереңне Гыйниятовка сөйләү партия алдында җавап тотуга тиң иде, ул мәңгелек, какшамас көч булып тоела иде. Әлбәттә, бакчачы аның кем кияве икәнен белгән, шуңа күрә моңынчы эндәшмәгән дә... кем генә өлкә комитеты секретаре кызының яраткан иренә куләгә төшерергә батырчылык итәр икән.

Булат Мөэминович чын-чынлап курка калды, Гыйниятов катнашыннан башка корып өлгергән бөтен тормышы упкын алдында калды, Ленин орденын да ул хезмәтем белән яулап алдым дип ышана иде. Соңгы егерме елда аның районында үстерелгән каракүл тиресен Европа аукционнарында кулдан йолкып диярлек алалар, бигрәк тә "сур" һәм "антик" дигән төсләрне яраталар. Болар бөтенесе дә аның тырышлыгы аркасында барлыкка килде ләбаса. Һәвәскәр галим, селекционер Эгамбердыевны нәкъ менә ул тапты, канаты астына алды, бөтен җирдә мамык үстерү белән мәш килгән бер заманда каракүл җитештерүне алга сөрде. Үзен югары бүләккә нәкъ менә каракүл тиресе, каракүл сарыклары үрчетү һәм шулардан ил казнасына кергән валюта өчен тәкъдим иттеләр дип саный иде ул.

Һәм хәзер болар барысы да куркыныч астында. Өлкә комитетына барып, сонлап булса да биографиягә ачыклык кертергәме? Мантыйкка сыя кебек, ләкин монда да нәрсәдер җитми, Заркентта өлкә комитетына яңа кеше утыргач, кадрлар сәясәтенең асты өскә килде. Тәхеттәге ханмыни, уңга да сулга да дәрәҗәле вазифалар һәм постлар таратыла, барысы да аңа тугрылыкка ант эчкән кешеләргә. Секретарьның ул җитәкләгән районга күз салгалаганын сизә ул, җае чыкса, төртеп төшерергә дә күп сорамас, әлегә сәбәп кенә юк, халык арасында абруе бар, Күпер Булат дип йөриләр. Болар да аңа мәгълүм, әлбәттә. Юк, Тилләхаҗиевка барырга, әллә кайчангы тарихны сөйләргә ярамас, төрмәгә тыгып куярга да күп сорамас, атып үтерелгән халык дошманының хезмәттәшен еллар буе бакчачы итеп тот та... Алтын турында да әйтеп бирергә туры киләчәк... Аннан Хәмрәкол әкә хәзинәсеннән бер тәңкә дә алмадым дип исбатлап кара... Болай уйларга нигез җитәрлек, яңа обком секретарена ярамаган кешеләрне ничек пычракка буяганнарын күрмәслек түгел.

Шушы көннән, бер үк вакытта сөенечле һәм көенечле көннән башлап Мәхмүтовның күңеленә шик корты белән бергә курку керде, үзенә ышанычы кимеде, әйтерсең, артыннан күзәтү алып барылган кеше иде.

Дөрес, райпотребсоюз склады мөдире Рәхмәтулла җитмәүчелекне тавыш-тын чыгармыйча гына каплап, йортын сатты һәм гаиләсе белән Нәманганга күчеп китте, йола буенча төпчек улы янында яшәп калган Хәмракол әкә элеккечә аның бакчасында эшли һәм күзгә күренмәскә тырыша, хәер, моны эшләү артык кыен түгел, хуҗа бик иртә чыгып китә, соң кайта, ләкин ул бакчачының эшләгәнен сизеп тора иде.

Ярты ел үтте, Хәмракол әкә белән булган вакыйга да онытыла башлады, ул инде Ленин орденын тагып йөри һәм аңа күнегеп килә, шул ук вакытта өстендә нииндидер бәла куеруын да ул сиземли иде. Болар аның үз-үзен тотышында чагылмый калмады, бик тиз кызып китә башлады, тирәсендәге кешеләрнең сүзләре, гамәлләре шик уята, һәркайда мәкер тоемлана иде. Бу үзгәрешләрне беренче булып Мияссәрә абайлап алды, ләкин ире моның сәбәбен арыганлык белән аңлатты, чыннан да, бернечә ел рәттән ял алмыйча эшли иде. Мөгаен, тагын бер-ике ай шулай дәвам итсә, ул чыдап тора алмас, йә өлкә комитетына, йә Үзәк Комитетка барыр, аңлашыр иде… Намуслы кеше буларак, ул чын вөҗдан газаплары кичерә иде. Җитәкче булу бер хәл, гади кеше буларак та ул үзенең икеле-микеле хәлләтен яхшы аңлый. Бу яклардан бөтенләй китеп барсаң, яисә гомумән партия эшеннән баш тартсаң яхшы булыр иде дә бит. Ләкин мондый хәлиткеч адымнан аны нәрсәдер тотып тора, рухын сындыра. Бакчачы язмышының ачык булмавы газаплый, әгәр дә ул өлкәгә яисә Үзәк Комитетка барса, аның хакында да сөйләп бирергә туры киләчәк.Серен ачкан, шул ук вакытта үзенең кем икәнлеген дә таныган диндар картны хөкем кулына тапшырырга туры килер. Хәмракол әкәнең Халтаев кулына барып эләгү ихтималыннан гына да аның чәчләре үрә тора иде. Карт бакчачы аны хыянәтче дип атар, бәддога укыр. Монысы шиксез. Моннан кырык ел элек атасы Әкбәр хаҗи сатмаган, ә менә аның малае…

Шәхси кичерешләр һәм дәүләт алдындагы җаваплылык, бурыч һәм шәфкатьлелек кебек төшенчәләр шулкадәр буталып бетте ки, дөресен генә әйткәндә, ул бөтенләй югалып калды. Ләкин мәсьәлә бөтенләй көтмәгәнчә хәл ителде. Көз җиткән иде инде, мамык җыяр вакыт якынлаша. Шул көннәрдә аны өлкә үзәгенә, пленумга чакырып алдылар. Ел саен була торган гадәти эш һәм Булат Мөэминович Заркентка барып кайтканнан соң тормышында яңа исәп башланыр дип күз алдына да китерә алмый иде. Утырыштан соң аны беренче секретарьның ярдәмчесе эзләп тапты һәм китми торырга, иртәгә иртән беренче янына килергә кушты; мондый очракларда гадәттә сөйләшүнең темасы алдан әйтелә иде, әмма ярдәмче ләм-мим, нинди саннар әзерләп килергә кирәклеген әйтеп тормады, иңсәсен җыерып куйды да китеп барды. Әле монда да ул сөйләшүнең үз шәхесе хакында барачагын башына китермәде, якын көннәрдә Төркиядән каракүл сарыклары сатып алырга җыенучы делегация киләчәге мәгълүм. Чакыруны Истанбулдан сәүдәгәрләр килүгә бәйле дип фараз итте. Беренченең йомшак ягы бар, ул чит ил кунакларын кабул итәргә ярата, хәтта Заркентка турист булып килгән атаклы кешеләр белән аралашу җаен таба. Ә инде рәсми хуҗа сыйфатында чит ил бизнесменнарын кабул итәргә туры килсә, үзәк яисә чит ил матбугатына эләгү мөмкинлеге, табигый ки, алгы планда үзенең берәр алдынгы хуҗалыкны күрсәтеп торуын мәңгеләштергән фото да чыгасы булса,—мин-минлеге чамасыз Тилләхаҗиев танымаслык үзгәрә, өлкә мәшәкатьләрен бер якка себереп кенә ташлый торган иде.

Булат Мөэминович хәтта чакыруга сөенеп тә куйды. Өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлегендә аның җентекләп әзерләнгән язмасы бер еллап ята иде. Саннар, исәп-хисаплар, газета-журнал кисентеләре, фоторәсемнәр белән ныгытылган әлеге язмада ул артык табыш китермәүче мамык хуҗалыгы урынына нәселле ат заводы булдырырга тәкъдим иткән иде. Шулай булса, югары элиталы каракүл сарыклары һәм тире белән дан алган кебек үк, дөнья базарына чиста нәселле чаптарлар белән дә чыгып булыр иде. Бервакыт Мәхмүтов Мәскәүдә очраклы рәвештә генә аукционга эләккән иде, нәселле атларны никадәр яратып алулары, алар өчен астрономик суммаларда акча түләүләре аны шаккаттырды. Өлкә комитетында бу эшкә юл ачуларына шикләнми, чөнки дәүләттән бер тиен дә сорамый, сәрмаясы җитәрлек, ат үрчетүдә тәҗрибәле белгечләр тапты, хәтта йөзләп ат асралучы ферма ачып җибәрергә батырчылык итте. Ахалтекин токымлы чаптар—“Абрек” кушаматлы айгыр һәм гарәп нәселләреннән килүче алмачуар, “Чегән кызы” кушаматы алган нечкә аяклы бия ферманың горурлыгы иде. Эшне буш урында башлап җибәрергә туры килмәячәк.

Беренченең дансоярлеге дә искә алынган иде, ул башка дәлилләр белән бергә, аукционнарның ел саен кайсы илләрдә һәм шәһәрләрдә үткәрелүен санап чыкты;

нәселле ат—сарык түгел, аның белән популяр берәр журналның ялтыравыклы тышлыгына эләгү үзе генә дә ни тора.

Кич буе райком секретаре өйдән үк алып килгән исәп-хисапларын, дәлилләрен барлап утырды, ат заводы турында сөйләшүгә әзерләнде, хәтта Тилләхаҗиевның дусты, бөтен илгә танылган агроберләшмә директоры, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое Әкмал Ариповның нәселле атлар ясатуын да ачыклап өлгерде. Аның Аксайдагы төп хуҗалыгында матурлыкта тиңнәре булмаган атлар асрала, аларның нәсел җебен бөтен дөньяның ат белгечләре исәптә тота икән.

Билгеләнгән сәгатьтә Мәхмүтов өлкә комитетында иде инде, ярдәмче аның килүе хакында шунда ук хәбәр бирде, ләкин аны бик озак чакырмый тордылар. Беренче секретарьның андый гадәтен Булат белә, кайберәүләрне алгы бүлмәдә бишәр сәгать интектерүе хакында ишеткәне бар. Шулай итеп, ул чакырылган кешегә тискәре мөнәсәбәтен сиздерә, алгы бүлмәдә тәмам изрәткәннән соң, сәгатьләр буе газапланып утыруын белмәгәндәй, кабул иткәндә мәрхәмәт күрсәтә икән. Күрәсең, хан сараендагы итагать кагыйдәләре турындагы трактатларны ныклап өйрәнгәндер, дип уйлап куйды Булат, кул астындагылар һәм йомыш белән килүчеләр өстеннән алар шулай шаяртырга яраткан, ди.

Булат Мөэминовичны ул өйлә алдыннан гына кабул итте. Салкынлыгы кыяфәтенә чыккан иде, хәтта кул бирмәде. Шәрекъ йоласы буенча саулык-сәламәтлек, тормыш-көнкүреш, бала-чага хакында сорашуны әйтсәе дә юк. Югыйсә, күрешмәгәннәренә дә байтак иде. Болар инде бик күпне аңлата. Мәхмүтовка ул чыннан да штрафниклар өстәле янынннан урын күрсәтте. Иң почмактагы җайсыз бу урынны авыл районнары секретарьлары шулай дип йөртә имеш. Монысы да билгеле иде. Утырган арада Булат Мөэминович аның өстәлендә үзенең шәхси эше тупланган папканы да күреп алды. Зиннәтле кабинет хуҗасы аны юри шулай күренерлек урынга куйган кебек тоела иде. Һәм Мәхмүтов әңгәмәнең төрек делегациясе турында да, ат заводы турында да булмаячагын аңлап алды. Принципсызлыгың һәм үшәнлегең өчен җавап бирер чак җитте дигән уй йөгереп узды.

Табигый ки, ул беренченең сәер гадәтләре хакында белә, андый хәбәр тиз таралучан. Тилләхаҗиевның гигантомания белән мавыгуы да сер түгел,—бөтен проектлары, тәкъдимнәре киң колачлык, капитал салымнарда үтә юмартлык белән шаккаттыра. Әгәр дә алар чынбарлыктан, кешеләр ихтыяҗыннан аерылмаган һәм кайчан да булса бер тормышка ашарлык булса, Тилләхаҗиевка илдә тиңнәр табылмас иде.

Сүз иярә сүз чыгып, өлкә комитетындагы яшь инструкторлардан берәү яңа җитәкченең фамилиясен атамыйча гына:

—Диванда кырын ятып, баш әйләндерерлек прожектлар корып ятучы Манилов—беркатлы һәм гаепсез җан иясе, ә инде беркем белән дә бүленмәгән чиксез властька ия булып, мәңге тормышка ашмас фантазиясенә миллионнарча кешеләрне һәм дәүләт акчаларын тартучы Маниловлар бүгенге заманның аждаһалары, монстрлары,— дигән иде.

Үтергеч бу холыкнамә беренченең колагына барып ирешми калмаган, әлбәттә. Партия куштаннары тырыша белә ул. Ярты еллап үттеме-юкмы, башбирмәс егетне командировкада чакта кулга алдылар. Ришвәт алганлыгын раслаучы ялган шаһитлары да табылган. Яшь партия работнигының сизенүе дөрескә чыкты, ләкин ул аны үз язмышын күздә тотып әйткән дип раславы кыен.

Элеккеге обком секретаре кабинетында Мәхмүтов еш була, күп башлангычларына хуплау сүзләре ишетә, яклау таба торган иде. Хәзер исә ул кабинетны танымады.

Түрдәге өстәл зурлыгы белән башларны әйләндерерлек иде, шуның өстенә ул чамасыз тәбәнәк: мебель фабрикасы дизайнеры Кәтүкнең Наполеондай кыска буен һәм маршалларча кылануын да искә алган. Кабинет хуҗасын еш кына Кәтүк дип тә, Мамык Наполеоны дип тә, кыскартыбрак Наполеон дип тә йөртәләр иде. Шунлыктан ахрысы, аның өстәленә "Т" хәрефен хәтерләтеп тезеп куелган икенче, озынча өстәл дә тәбәнәклеге белән гайре табигый тоела иде.

Кабинетны күптән түгел генә ремонтлап бетергәннәр булса кирәк, һәрхәлдә, Мәхмүтов мондагы үзгәрешне беренче тапкыр күрә иде. Беренче секретарь аеруча ярата торган әрләүле киңәшмәләрдә мондый өстәл янындагы гарипләрчә тәбәнәк урындыкларга чумышкан кешеләрне күз алдына китереп, ул чак кына елмаеп куймый калды.

Беренче озын буйлы кешеләрне күрә алмый икән, дип тә сөйлиләр (хәер, монысы

гүзәл җенес вәкилләренә кагылмый, имеш), шунлыктанмы, хакимияткә ул килгәч, кыска буйлы җитәкчеләр вазифа баскычлары буйлап бик тиз өскә үрмәли башладылар. Вакытлар узар, махсус рәвештә тәбәнәк ясалган өстәлләр янында бары тик үзенә тиң кешеләр генә калыр, дип ышана иде бугай ул. Мәхмүтовның башында "көфер" уйлар әйләнде дә әйләнде.

Күпер Булатны үзеннән ерактагы почмакка утыртуы да аның физик өстенлеген күрмәү өчен түгел микән әле. Мәхмүтовның Көнбатыш илләрендә кәнсәләрия эшенең оештырылуы, тармакларда җитәкчеләрнең ничек туплануы хакында бер китап укыганы бар. Шунысына игътибар иткән иде, анда күзгә ташланып торган физик кимчелекләре булган кешеләргә югары вазифа, кешеләр, коллектив язмышын хәл итәргә ышанып тапшырулары икеле, чөнки физик яктан кимчелекле икәнлеге аның аңына сеңгән, аны русча "комплекс ущербности" диләр бугай, менә шул нәрсә кул астында эшләүчеләр белән мөнәсәбәттә, димәк, тулаем эш барышында тискәре чагылыш тапмый калмый икән. Китап авторының хаклыгын раслаучы классик мисал аның каршында утыра иде.

Әгәренки Тилләхаҗаевның артык озынга сузылган һәм буталчык монологын әңгәмә дип аңлап булса, үтә дә сәер нәрсә килеп чыкты, чөнки әңгәмә дигән сүз үзе үк анда һичьюгы ике кеше катнашуны күздә тота, ә ул келәмгә чакырылган партиядәшенә авыз ачарга да ирек бирмәде. Үзенең язмышын кулларында тотучы бу кешене тыңлаганда Мәхмүтов ирексездән Муссолинины исенә төшерде, Мәскәүдә укыганда трофейга алынган документаль фильм караганы бар иде. Бер карасаң, аэродром чаклы өстәл янында утырган бу кеше белән дуче арасында бернинди уртаклык юк кебек. Ләкин хикмәте бар икән, тыңлаучылар, толпамы ул, яисә бу очрактагы кебек, аерым бер кешеме, күз ачып йомганчы власть, көч гипнозына эләгәләр, ихтыярны буып куючы сихергә охшаган шушы сәер көч курку һәм буйсыну теләгеннән башканы уята алмый, меңнәрчә кешеләрнең җанынннан, күзләреннән, йөрәкләреннән саркыган курку флюидлары исә аны туендыра, көчен-егәрен арттыра тора. Мәхмүтов шундый халәттә иде.

Беренченең чәчен кырдырып алдырганлыгы да аны дучега охшата төшә иде кебек. Мамык җыйган вакытта ул көннәр буе эсседә була, өлкәнең барлык якларына барып чыга һәм аның мөселман йолаларын шулай җентекләп үтәве, кешеләр күзенә ташланмый калмый; кешенең тышкы кабыгының искиткеч мөһим роль уйнавын, массаларга тәэсир итүен Мәхмүтов яхшы белә иде. Авыл районнарында хуҗалык рәисләре белән кичке ашка ул аксакалларны да чакырта, ашап туйгач, янәсе гадәтенә кергән, беренче булып амин тота икән, дип тә сөйлиләр. Бу исә аксакаллы картлар күңеленә аеруча хуш килә, күзләреннән яшь кенә чыкмый дип сөйлиләр, беренченең мөселман йолаларына тугрылыгы, диндарлыгы хакында сүз шулай тарала.

Хәер, беренченең дингә исе китмәве хакында якын кешеләреннән ишеткәне бар, җанында иманы юклыгын да белә. Менә хәзер карагыз, районнарга чыгар алдыннан махсус кырдырылган баш белән "амин тоту" йоласы халыкка тәэсир итмичә калмастыр шәт.

Мәхмүтов курыктымы соң? Бәлки… Ләкин ул тышка чыкмады, ул үз-үзен тота белә иде. Ул хис иткәнне аңлатырдай сүз дә юк бугай, әмма үз-үзенә танырга теләмәсә дә, ул барыбер куркуга охшаш иде. Өлкә комитетына шәхси чакыру алганда хәзер бик күпләрне хайвани дип әйтерлек курку хисе биләп ала. Әлбәттә, бу кабинетта кайнатасы Гыйниятов утырганда монда демократия, бердәмлек, татулык вә мәхәббәт хисләре генә тантана итә, башбаштаклык очраклары булмый иде дип уйламый ул, ләкин ул чакта нәрсәнең хупланганы, ни-нәрсәләрнең кире кагыласы ачык иде, мәгънәсен тегеләй дә, болай да аңлап була торган башваткычлар яңгырамый иде. Соңрак, Гыйниятовны башка кеше алыштыргач та алар бу кабинетта шактый тәнкыйть һәм әр сүзләре ишеттеләр, ләкин күңелне хайвани курку хисе биләми иде әле, ул хис менә шушы кыска буйлы, терекөмештәй хәрәкәтчән һәм тынгысыз кеше белән бергә килде, аның эш-гамәлләрен, нәрсә уйлаганын аңлап булмый һәм ул күпләр өчен һәлакәткә тиң булып, язмышларының асты-өскә килде. Ул килгәч өлкәдә хуҗа һәм диктаторның берәү генә икәнен, аңа Ташкент яисә Мәскәүнең абруй түгеллеген күпләр сизенеп өлгерде. Биләмәсе артык еракта булганлыктан түгел, сәбәпләре яңа туган вәзгыятькә бәйле иде булса кирәк, ләкин гомерләренең байтак өлешен ерактагы караңгы районнарда үткәргән кешеләр моны аңлап бетермиләр иде.

Шушындый фикергә килгәннән соң (бу исә житмешенче елларда булган хәл) Мәхмүтов ирексездән кабинетта эленеп торган СССР картасына күз төшереп алды. Гаҗәп бит,—дип уйлап куйды ул, шулкадәр зур ил белән сайлап куелган органнар, Совмин яисә ҮК, Госплан түгел, чынлыкта өч йөзләп обком секретаре житәкчелек итә. Реаль власть алар кулында, барысы да үзара таныш, һәркайсы автоматик рәвештә илнең Югары Советына депутат итеп сайлана, Мәскәүдә дә, үз республикаларында да Үзәк Комитет әгъзалары, җентекләбрәк карасаң, аларны тагын закон чыгаручы дистәләрчә органнарда очратып була. Дәрәҗәле постта алар, кайнатасы Гыйниятов шикелле үк, бакый дөньяга күчкәнче утыралар. Анын урынына килгәне белән дә шулай булды, анысы картлыгы аркасында хезмәт урынында ук җан тәслим кылды. Мондый хакимият иң көчле масон орденының төшенә дә кермәгәндер, обком секретарьлары дигән "нәсел"нең куәтенә дөньяда тиңнәр табылмас.

Бервакыт Кәтүк янына ниндидер таләп белән Югары Совет депутаты килгән, дип сөйлиләр. Бик үк игътибар белән тыңламаганны сизенеп, ул берничә тапкыр таләпчән рәвештә: "Мин депутат",—дип кабатлаган имеш.

Ниһаять, кабинет хуҗасы үҗәт кунакны тыңлап гарык булган һәм анын күз алдында шикаятьне ерткалап ташлаган:

—Мин теләгәнгә генә син депутат булдың. Ә хәзер бар, эшкә комачаулама, бүгеннән кулыңда мандатың юк дип саный аласың, икенче чакырылышта башка бер бригадир депутат булыр. Өстеңә ишелеп төшкән бәхеттән файдаланырга акылың житми,—дип кистереп әйткән ди.

Һәм шулай булып чыга да.

Кабинет хуҗасының дучега охшарга тырышуы шикле, үрнәк алыйм дисәң, мисалга ерак барып йөрисе юк, ләкин алар арасында барыбер ниндидер охшашлык бар иде; авыр башын үгездәй аска иеп сөйләвендә дә, пышылдаудан кинәт кычкыруга күчүендә дә, әңгәмәдәшен күз белән бораулавында да тоемлана иде болар; ул кинәт кенә өстәленә текәлеп ката һәм авыз эченнән бу эшкә бернинди катнашы булмагандай нәрсәләр хакында мыгырданырга тотына һәм болар көтмәгәндә бөтенләй яңа ягы белән ачыла, алдарак әйтелгән җөмләгә яки фикергә усал-явыз төсмер өсти иде.

Юк, яңа обком секретаре гади-садә кеше түгел, әгәр куркудан һәм дулкынланудан югалып калмасаң, игътибар беләнрәк тыңласаң, аның фикер йөртүендә алдындагы кешенең шөлләвеннән җим алучы сәер бер эзлеклелек була иде.

Төрлечә аңларга урын калдырып, тыштан караганда эзлексез тоелган мондый сөйләү рәвеше әйткәннәрдән бик җиңел генә баш тартырга урын калдыра, әгәр кирәк булса, аны бөтенләй капма-каршы мәгънәдә үстерергә мөмкинлек бирә, ә инде ул-бу була калса, мине дөрес аңламаганнар, дип барысыннан да читкә китәргә була. Менә шушылар Беренче белән Аппенин диктаторы арасында охшашлык тудыра да иде инде.

Наполеон никадәр генә җирәнгеч тоелмасын, Мәхмүтов аның шайтани таланты барлыгын бәяләми калмады; сөйләшү дәвам иткән саен, гәрчә моның ниндидер уен, камилләштерелгән режиссурасы булганлыгы тоелса да, беренче сөйләгәннәрдә гадәтилек, гариплек, кәпрәю югала; көлке тоелучы аэродром чаклы өстәл, кәрлә урындыклар онытыла, аның Наполеонныкыдай кыска буе да артык күзгә ташланмый башлый. Күрәсең, Беренче болар хакында белә яисә сизенә булыр, шунлыктан ул һәрвакыт озак һәм үз-үзенә нык инанган тавыш белән сөйли, күзләрендә үзенә көлебрәк карауны тоемлаган теләсә кайсы гигантны иблис алымнары кулланып сытып китәренә ышана иде.

Хәзер инде үзгәртеп корылган, сипләнгән кабинетның элеккеге хуҗасының кияве, өлкәдәге иң зур районның җитәкчесе аңа нәкъ менә шундый "көлеп караучы"ларның берсе булып тоела иде. Дөрес, Гыйниятов Кәтүккә беркайчан да начарлык кылмады, киресенчә, кайчандыр партиягә ул тәкъдим иткән иде, әмма үзе белән берни дә эшли алмый, аның кызының ирен кан төсендәге кызыл келәмдә аунатасы, аның ялынганын, ялварганын күрәсе килә. Дәрәҗәле байтак кешеләр анын алдына тезләнеп аунадылар инде, һәм ул аларның берсен дә ирләр өчен аеруча оят булган бу гамәлне кылудан туктатып калмады, киресенчә, сиздерми генә өстәл астындагы сигнал кнопкасына баса һәм кабинетка ярдәмчесе килеп керә иде. Анысы исә кемнеңдер мондый түбәнлеккә баруы киң җәмәгатьчелеккә барып житәргә тиешлеген белә. Ялчы үзенең хуҗасын сүзсез дә аңлый.

Шуның белән бергә, ул аны ахыргача изеп, сытып бетерергә дә уйламый, чөнки

Мәхмүтовны халык ярата, абруе бик зур, хуҗалыгы карап туймаслык. Аның районына кызыккан тугрылыклы кешеләрдән кайсысы гына эшне шулай алып бара алыр икән, чөнки монда буш сүзләр, прожектлар гына җитми, яхшы нәтиҗә дә кирәк... горур Мәхмүтовка кислородны буып кую кабинет хуҗасы файдасына түгел. Аның бары тик җай чыгудан файдаланып, аны бөгәсе, тәлинкә тотканын, үзен аяуны ялварганын күрәсе, шулай итеп, аны үзенең тугрылыклы яраны итәсе килә... тагы, гомере буе бурычлы икәнен сизеп, аның олы җанлылыгын бәяләп яшәсен. Мәхмүтовка кагылышлы материалларны ул кулга очраклы рәвештә генә төшерде, аларны акыллы файдалана белсәң, болар Күпер Булатның язмышын ботарлап ташларга артыгы белән җитәрлек иде.

Әгәр дә Кәтүк тормышын партия карьерасына багышламаган булса, аннан бик тә оригиналь фикерләүче, иң мөһиме, уйларын гадәти булмаганча бәян итә белүче язучы чыккан булыр иде. Шәрекъ Кафкасы дияргә мөмкин булыр иде. Мәхмүтов белән ялгыз калып ул бер сәгатькә якын сөйләште, сөйләшүнең төсмерен үзгәртә-үзгәртә сүзләрдән мәкерле бөҗралар тезде (көченең нидә икәнлеген белгәнлектән, бер генә тапкыр да кәнәфиеннән тормады), тавышында йә янау төсмерләнде, йә булмаса, корбанына котылыр юл күрсәтүче мәгънәви ачыклыклар калдыра килде. Берничә тапкыр кулына шәхси эш теркәлгән папканы алып, аны актарган булды. Сталинга охшарга тырышып, зәңгәр карандаш белән анда ниндидер тамгалар ясады, ләкин бер генә тапкыр да райком секретаренең нәрсәдә гаепләнгәнен тәгаен әйтмәде. Халык дошманы буларак атып үтерелгән әтисе хакында да, Мәхмүтовның чынлыкта чит кеше документлары белән яшәвен дә, үзенең кем улы икәнен белә торып, социаль чыгышын партиядән яшерүен дә сиздермәде. Алтын, бакчачы Хәмракол әкә, кайчандыр Кәтүкнең партия карьерасының юл башында Мәхмүтовка ярдәм кулы сузган элеккеге кайнатасы Гыйниятов турында да сүз булмады.

Алда әйтелгәнчә, җан куырырлык бер генә гамәлен, бер генә фактны искә төшермәсә дә, хәтта аз гына җеп очын чыгармаса да, аның керделе-чыктылы тоелган хисле сөйләмен мәгънәсез үк дип атап булмас иде. Ул җәзага чакырылган кешенең бар үткән тормышын рентгеннан карагандай белгән кыяфәт ясый, үзенең бетмәс-төкәнмәс көче-куәтенә ышандыра, Мәхмүтовның яшәгән һәр көнендәге иң вак күренешләргә кадәр аңа мәгълүмдер сыман тоела башлый. Мондый басым астында түзеп тору сирәкләрнең кулыннан киләдер.

Хәер, соңгы көчләрен җыеп ихтыярын бер йодрыкка туплый алган кунак кына түгел, әңгәмәдәшенә мәкерле ятьмәнең яңадан-яңа җылымын ташлый-ташлый кабинет хуҗасы үзе дә арып беткән иде инде. Аның өстәл астындагы кнопкага басарга әзерләнгән аягы талчыкты, инде берничә тапкыр Мәхмүтов чыдый алмас, менә-менә аягы астына, даны чыккан кызыл келәмгә егылыр һәм ярлыкавын сорап мәлҗерәп төшәр сыман тоелып куйды.

Кәтүкнең оста корылган психологик һөҗүменнән беркем дә исән чыга алмый иде, бу юлы да ул берничә тапкыр инде тантана итәм дип укталып куйды, ләкин борчылу белмәс Мәхмүтов тавыш-тын чыгармады, көтте, ул үзенең нәрсәдә гаепләнүен тәгаен белергә тели иде.

"Каты чикләвек бу!" дип уйлап куйды секретарь һәм яшерен куркыту хисен иң югары ноктасына җиткерергә булды. Очрашу тәмамланганын сиздереп, хушлашканда әйтте:

—Партия алдындагы гөнаһыгызны аңлагансыздыр, дип ышанам, үземә хас принципиальлек белән, сезгә анда урын юк, дип саныйм. Ләкин бу мәсьәләне мин үзем генә хәл итмим, хәер, обком бюросының минем тәкъдимне хуплау гына түгел, алгарак карап, сезгә каршы җинаять эше кузгатуына ышанам. Партия сафларының чисталыгын пычратырга теләүчеләргә сабак булыр! Анда протекционизмга урын юк, аның каршында барысы да тигез, туган-тумачалык та, югарыдагылар белән әшнәлек тә, иске хезмәтләрегез дә коткарып кала алмас.

Кунак хушлашмыйча гына чыгып барганда, ишек янында аны дучега охшаган кешенең тавышы куып җитте:

—Киңәшем бар, Заркенттан бер-ике көн китми торыгыз, мин сезнең мәсьәләне озакка сузарга җыенмыйм.

Мәхмүтов артыннан ишек ябылуга кабинет хуҗасы гасабиланып сигнал педалена басты, шунда ук ишек төбендә битенә мыскыллы елмаю чыккан ярдәмчесе пәйда булды.

—Нигә ыржаясың...—дип усал мыгырданды обком секретаре.—Эчәргә сал, тәмам хәлдән тайдырды, хәшәрәт.

Ярдәмченең күләгәсе түр башында бүлеп куелган якка шуышты. Архитектор искиткеч оста яшереп планлаштырган ял бүлмәсендә күп сыйдырышлы "Розенлев" фин суыткычы тора иде.

Әнвәр Абидович өстәл янынnан торды һәм әле яңа гына тәмамланган сөйләшү хакында уйлана-уйлана киң кабинет буйлап йөренергә тотынды.

—Бер вагон цемент бушаттыммыни,—дип куйды ул караңгы чырай белән һәм аяк киемнәрен салып, идәнгә җәелгән келәм сукмактан ишекле-түрле йөгеренде, аннан соң идәнгә ятып берничә тапкыр күтәрелде. Ул үзенең көче белән горурлана, районнарда бәйрәмдә көрәшкә чыкмый калмый һәм бик сирәк җиңелә, яшьлектәге көчен һәм җитезлеген әле дә булса югалтмаган иде. Ул шулай идәндә үк утырып калды, шәрекъча аякларын бөкләп, җайлап урнашты. Ярдәмчесе аның алдына коньяклы бокал һәм лимон телемнәре салынган җиз поднос китереп куйды. Беренче коньякны аракы эчкән шикелле бер кабуда йотты да комсызланып лимон чәйнәргә кереште, ярдәмчесенә эндәште:

—Син дә арып беткәнсеңдер, звонок булуга чабып керермен, Гыйниятов киявенең идәндә аунавын, селәгәен агызып, балаларын кызгануны ялварганын күрермен, дип уйлагансыңдыр...

Хуҗасының теләгән үтә бер сизгерлек белән тоя белүче ярдәмче бокалны тагын кырыена хәтле тутырды, ялгышырга ярамый, хуҗа салганыңны битеңә сибәргә дә, аты-юлы белән сүгеп ташларга да күп сорамас, "Эчертеп бозасың" дип усалланып кычкыруы гына да ни тора.

Әнвәр Абидович икенче бокалны инде ашыкмый гына, тәмләп, йотымлап кына эчте, коньякның рәтен белә ул, юк-бар нәрсә эчми, сәламәтлек кадерле бит.

Мөгаен аны астан өскә карап утыру туйдырды булса кирәк, кул ишарәсе белән ярдәмчесен янәшә утырырга чакырды, үзе үк аңа салып та бирде.

"Шефка барып җиткән, тагын фәлсәфә сата башлый инде бу",—дип уйлап куйды ярдәмче күңелсез генә.

—Мәхмүтовның күз яшьләрен мин дә, син дә күрә алмадык. Шундый каты мужиклар күбрәк булсын иде, юкса эшләүнең кызыгы бетеп килә. Чак кына кычкыруга ук асларына җибәрәләр, бүлмәдә тын алып булмый башлый.

Бераз кабып алганнан соң кыюланып киткән ярдәмче сүз кыстырырга базды:

—Нигә үзегезне интектереп азапландыгыз? Тыңлаучан судья бар, прокурор сезгә ярар өчен җай чыкканы гына көтеп йөри, эшне башкарыйк та, руслар әйтмешли, концы в воду. Миндә һәркемгә материал бар, сайлап ал гына.—Һәм әйткәннәреннән канәгатьләнеп кычкырып көлеп җибәрде, киң ачылган авызы тулы алтын тешләре ялтырады.

—Синең акылың белән яшәсәм, Йосыфкаем, мин инде күптән төрмәдә утырган булыр идем,—диде хуҗа килешүчән тавыш белән һәм урыныннан күтәрелде.

Ярдәмчесе ашыгып аның туфлиләрен китерде һәм иелеп, күнегелгән җитез хәрәкәтләр белән бауларын бәйләргә тотынды. Әнвәр Абидович исә ашыкмый гына фикер җебен сүтте:

—Булдыклы кешеләрне утыртып бетерсәң, кем эшләр, өлкәне алгы сафка кем тартыр? Син яклаган кешеләр белән, кадерле Йосыф, коммунизм төзеп булмый, гомерең буе нык үскән социализмда яшәмәгәең.

Яңадан өстәл янына барып утыргач та сүзен дәвам итте:

—Мәхмүтовны төрмәгә тыгарга түгел, акыллы итеп кулга ияләштерергә кирәк. Монысы кыенрак булыр, аңладым мин аны, каты холыклы, горур кеше икән. Ә безнең бурыч четереклерәк, сарыклар да исән булсын, бүреләр дә тук булсын, дигәндәй, ул безгә дә тугры булсын, дәүләткә дә хезмәт итсен. Канатлары киселгән кош кирәкми миңа, шунлыктан аның районын тартып алырга ярамас. Халык та аны яклап тау булып күтәрелер... Үзең беләсең бит, Әкмал хан булып, Әкмал хан аның ниндидер бер айгырын ачыктан-ачык тартып алырга җөрьәт итми, ә тегесе акчага риза түгел. Кешеләр җибәреп караган. Зур акча тәкъдим иткән. Мәхмүтов үз сүзендә каткан, мин аны күңел өчен түгел, ә нәселле ат заводы өчен тотам ди икән, янәсе ул ахалтекин атының чын бәясе йөз мең доллар. Әкмал инде бер ел буе котырына, мин аның үзенә илле мең акча тәртәм, ә ул дәүләткә тиясе йөз мең турында баш вата, дип җенләнә.

Хуҗа боржоми салырга ымлады да сүз җебен суза бирде:

—Мин, егетләрең белән бар да, элек ничек эшләгән булсаң, шулай кылан, бушка тартып ал, дип Әкмалны кыздыра торам. Юк, ди Арипов, егетләрем генә түгел, үзем дә Мәхмүтов районыннан исән чыгып ычкына алмам, ди. Халык ярата аны, Күпер Булат дип кенә тора, аның өчен утка да, суга да керергә әзерләр. Ә син Йосыф, шундый бөркетне төрмәгә тыгарга дисең, сатлык судья белән прокурор таптым, дип сөенәсең. Юк, халыкны үртәргә ярамый, ул кемнең кем икәнен яхшы белә…

Ярдәмчесенең борыны салынганын күреп ул килешкәндәй әйтеп куйды:

—Кәефеңне төшермә, Йосыф, кемнеке өстен чыкканын күрер көннәр алда әле, мин шундый нәрсә уйлап таптым, Күпер Булат мәңге очына чыга алмаячак, мичәүдәге ат шикелле булыр да калыр. Син тапкан кәгазьләрнең бәясе әйтеп бетергесез аның, кадерлем.—Һәм сүзне тәмамлап өстәүне кирәк тапты:—Әйдә, тагын берәрне җибәрик тә, өйләдән соң бер җиргә барып ял итеп кайтыйм…—Тансык уй кәтмәгәндә килде булса кирәк, йөзенә хәйләкәр елмаю җәелде, хуҗасына кушылып ярдәмче дә елмая башлады, хуҗасын ул ярты сүздә аңлый шул.

—Бу Күпер Булатың тәки җелегемә үтте,—диде хуҗа һәм коньякны рюмкаларга үзе агызды. Кәефе күзгә күренеп күтәрелде, эчеп куйганнан соң сүз тагын элекке эзенә төште:—Мин дигәнчә килеп чыкса, Мәхмүтовның ул айгырын Ариповка үзем бүләк итәм, сөендерәм әле бер.

—Әгәр барып чыкмаса?—ярдәмченең теленнән бу сүзләр үзеннән-үзе ычкынды, мәкерле сорау бирерга ярардай вакыт җиткәнлеген аңлаган иде ул.

Сорау кабинет хуҗасын кыен хәлдә калдырмады, ул сейфны яба-яба теш арасыннан гына сытып чыгарды:

—Менә шунда синең дусларың, судья белән прокурор кирәк булыр да инде…

Бер-берсеннән канәгать булып алар икесе дә рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр.

Ярдәмче "Варцихи" калдыклары аунап яткан подносны, бокалларны өстәлдән җыеп алды һәм яшерен ишеккә таба юнәлде. Хуҗаның кабинетында андый ишек тә булып, ул турыдан-туры ишегалдына, бакчага алып чыга, алар белән күрешкәнен сиздерергә теләмәгән кешеләрне, табигый ки, хатын-кызларны кабинет хуҗасы янына ул шул ишектән алып керә. Шеф караңгы бер районда секретарь булып эшләгән чорлардан бирле егерме еллап үз янында тоткан ярдәмчесенең уйларын укып баргандай алдан ук чамалый иде.

—Нурматов, чыннан да, Ташкентка, киңәшмәгә китте микән?—диде ул илтифатсыз гына.

—Мин сезнең ни теләгәнегезне алдан ук чамаладым, тикшереп куйдым, хәзер ул республика прокуратурасында милиция органнарында коррупция һәм ришвәтчелек турындагы киңәшмәдә утыра.

—Ул, нәрсә, әллә тәҗрибә уртаклашамы?—Икесе дә тагын көлеп куйдылар, шефның икеләнүен кул белән алып ташладылармыни.

—Нурматов Заркентта булса ни дә, булмаса ни, ул сезгә киртә түгел, берәр вакыт комачаулаганы булдымы!—дип оятсыз елмайды ярдәмче.

—Бозык кеше син, Йосыф,—дип йомшак кына шелтәләгәндәй итте хуҗа.—Ни дисәң дә, туган тиешле кеше бит, минем кем икәнемне онытма, әхлакны, йолаларны сакларга кирәк.

Ярдәмче кызыл келәмгә басмаска тырышып урап үтте һәм кабинеттан чыкты. Кабул итү бүлмәсендәге кешеләргә өйләдән соң обком секретаренең булмаячагын, иртәгә килергә кирәк булырын әйтергәме-юкмы дип чамалап торды һәм иң соңгы минутта вакланып тормаска карар итеп, "Й. С. Юнысов" дип язылган җиз тактачык кадакланган калын ишеккә кереп югалды. Аның аппартаменты шефыныкына каршы гына урнашкан иде.

Әнвәр Абидович туры телефон трубкасына үрелде. Өлкә ОБХСС башлыгы Нурматовка чины буенча туры телефон куелырга тиеш булмаса да, ул куярга кушты, шулай итеп, аны бюро члennарына тиңләде. Бер атуда ике куян эләктерде. Бердән, баҗасының дәрәҗәсен күтәрде, икенчедән, үзенә дә уңайлылык тудырды. Шәрәфәт көне буе шәһәр телефонына ябышып ята, элек аңа беркайчан эләгеп булмый иде, ә бусы һәрвакыт буш, ул туры телефоннарны биш урынга, шул исәптән, хәтта, ванна бүлмәсенә дә куйдырды. Котәргә яратмый ул. Телефон трубкасында Шәрәфәтнең уенчак тавышы ишетелде:

—Заркент әмире әллә үзенең бәтиен оныtып та бетерде инде...

Әнвәр Абидовичның теленнән ягымлы, назлы сүзләр агыла, хәтта тавышы танымаслык булып үзгәрде, ләкин ул бик тиз тормыш чынбарлыгына әйләнеп кайтты һәм ашның әзерме-юкмы икәнен белешеп алды, тискәре җавап ишеткәч, бер сәгатьтән булачагын әйтеп трубканы куйды. Икенче трубка күтәрелде, эчке элемтә телефоны. Обком пешекчесенә төшке ашка заказ бирде һәм канәгатьләнеп кулларын угалады. Ярты сәгатьтән барысы да әйбәтләп төрелгән, машинага чыгарып куелган булыр. Шефны читкә чыгып та ашаткалау гадәткә кергән иде инде.

Ярдәмчесе иртән үк кул куярга бер кочак кәгазь күтәреп кергән, аларның яртысын да карап чыгарга өлгермәгән иде әле, шунлыктан, ярты сәгать эчендә шушы эшне башкарып атмакчы булды. Бер кәгазьгә күз төшерде, икенчесенә, әмма игътибарын туплый алмады, һәр имзаның бәясен яхшы белгәнгә күрә, кызыл папканы бер читкәрәк этәрде. Калып торсын. Горур һәм үҗәт Мәхмүтов белән "сүз көрәштерү" артык арыткан, нервысын чыгарган иде.

Ул биек аркалы кәнәфигә утырды һәм башын артка ташлап каш өстен уарга кереште, кайчандыр бер акыллы кеше аңа биткә шундый гимнастик күнегү ясарга киңәш иткән иде. Массаж тәэсир иттеме, әллә Шәрәфәт белән очрашуны искә алу сәбәп булдымы, баш авыртуы бердән юкка чыкты.

—Шәрәфәт,—дип куйды ул сузып, көйләп әйткәндәй, йөзенә канәгать елмаю җәелде.—Иң матур чәчәгем, иң кадерле хәзинәм минем.—Бу сүзләр артык кычкырып әйтелде. Ул үзенең эш кабинетында утырганын онытып җибәргән иде. Шәрәфәт турындагы уйлары, алдагы очрашу аны күптән обком бинасыннан алып чыгып киткән иде инде.

Шәрәфәт дигәнебез хатынының сеңлесе булып, Хәлимәдән сигез яшькә кечерәк иде. Әнвәр Абидович шәрекъ төшенчәләре буенча шактый соңга калып, утызга җиткәч кенә өйләнде. Аныңчы кояш астында үз урынын эзләде, үз кәнәфиен булдырырга кирәк иде. Аны районда иң күренекле кияү санадылар, сайланса, сайланырлыгы бар иде, Тилләхаҗиевлар белән туганлашырга хыялланучы гаиләләр аз түгел. Илдә коммунизммы, социализммы, дәүләтчелекнең башка берәр формасы булырмы, анысы мөһим түгел, Тилләхаҗиевлар бар, булды һәм булачаклар, чөнки алар ак сөяктән, алар белән туганлашсаң беркайчан да югалмассың. Менә шунлыктан ул, буй-сыны күңелләшерлек булмаса да, гүзәлләрнең гүзәле Хәлимә Касыймовага өйләнә алды. Юкса, районда да, кыз укып йөргән Ташкентта да Хәлимә дип өзгәләнүчеләр аз түгел иде.

Хәлимә ике курс кына бетерә алды да, мәгърифәтле һәм дә власть сөючән ире артыгын рөхсәт итмәде, хатынлык өчен университетның ике курсы да хәттин ашкан дип саный иде ул.

Район социаль тәэминат бүлегендә гади бухгалтер булып эшләүче Касыймовның өч кызының өчесе дә чибәр, аларның кемгә охшап тууы табигатьнең бөек сере, чөнки ни әнисе, ни әтисе матурлык вә буй-сын ягыннан күзгә ташлана торган инсаннардан түгел.

Хәлимәнең апасы Диләрә Ташкентта укыганда әйбәт кенә егеткә кияүгә чыгып, хәзер инде башкалада яши, ире олы галим булып китте.

Хәлимә килен булып төшкән Тилләхаҗиевлар йорты тәэминат бүлегенең тыйнак хисапчысы йортыннан нык аерыла, монда инде бүтән дәрәҗә, бүтән мөмкинлекләр. Үзбәкләрдә туган-тумачалык изге санала, кешегә шул мөнәсәбәттән чыгып бәя бирелә, туган-тумача көч һәм ярдәм чыганагы; монда аңа таянмыйча берни дә эшли алмыйсың. Хәлимәнең сеңлесе, чибәр һәм чая Шәрәфәт көнен дә төнен дә Тилләхаҗиевларда үткәрә башлады һәм бик тиз арада йорттагыларның сөеклесенә әйләнде, хәтта Әнвәр Абидовичның әти-әнисе тагын бер уллары булмаганга аһ итteләр, Шәрәфәт бигрәк тә ошый иде шул.

Хәлимә бер-бер артлы бәби алып кайта башлагач, Шәрәфәт өйдә алыштыргысыз кешегә әйләнде. Бераз соңрак, нәрсәгәдер үпкәли калса, Шәрәфәт Кәтүккә гел шуны искә төшерә торган булып китте, янәсе, әнә синең балаларың минем кулда үстеләр. Хәер, бу чынлыкта да шулай иде.

Акселерация дигән нәрсә эссе якларда да үзенекен итә, инде сигезенче класста укыганда ук Шәрәфәт буй-сыны белән апасын куып җитте. Эштән кайткан чакта ул еш кына Шәрәфәтне көзге янында, апасының киемнәрен киеп караган хәлдә очрата иде.

Андый чакларда да кыз һич кенә дә югалып калмый, телевизордан күргән манекенщицалар шикелле рәвешен китереп боргалана, теге яки бу киемне киеп карый һәм кабат-кабат "Монысы килешәме?"—дип сорый:

Ул моны шул хәтле иркәләнеп һәм көязләнеп, кыю әйтә ки, алдында шәрекъта үскән кыз торганлыгын онытып җибәрәсең. Ә кием-салым аңа, чыннан да, килешә, кызны апасына караганда затлырак, чибәррәк итеп күрсәтә. Әнвәр Абидович күңеленә хилафлык китермичә танырга мәҗбүр:

—Килешә, искиткеч килешә!

Шәрәфәтнең көзге алдында сөйкемле боргалануын ул әле уен дип кенә кабул итә иде. Көннәрдән беркөнне, кыз инде тугызынчыда укып йөри иде, ул төшке ашка өйгә кайтты. Хәлимә бала табу йортында иде. Шәрәфәт җәйге кухняга ап-ак күлмәк киеп килеп керде, аны Әнвәр Абидович узган ел гына Грециядән алып кайткан иде әле. Килеп керде дә сәхнәдәге шикелле аның алдыннан узгач сорау бирде:

—Ничек, мәктәп балында иң чибәр кыз мин булырмын микән?

Һәм нәкъ менә шул чакта ул алдында җиткән кыз басып торганын аңлады да. Хатынына охшаган булса да, ул башка төрле матурлык белән аерылып тора, алар йортында уздырылган вакыт һәм вәзгыять аңа бөтенләй яңа төсмерләр өстәгән иде. Нииндидер европача нәфислек бар икән бу кызда, дип уйлап алды ул һәм чын күңелдән әйтте:

—Әлбәттә, Шәрәфәт, син бүген аккош булып күренәсең,—диде.

—Рәхмәт, Әнвәр әкә,—дип сөенде Шәрәфәт,—минем бик-бик тә сезгә ошыйсым килә,—һәм йөгереп килеп аны үбеп алды.

Чыгып барышлый исә ишек янында туктап калды һәм очынып әйтеп салды:

—Апамның бәхете бар икән, сезнең хатыныгыз булу бәхет түгелмени?!

Тилләхаҗиевларга кунак еш килә; Шәрәфәтнең җитезлеге, чисталыгы, зәвыгы һәм итагатьле була белүе дә ярап куйды.

Аның өстәлгә приборлар куйгандагы төгәллеген, чакырылган пешекчеләргә боерыкны ничек бирүен күреп, Әнвәр Абидович чын күңелдән:

—Синнән башка нишләгән булыр идек,—дип әйтә торган иде.

Кунаклар таралышкач ул еш кына шаярта:

—Шәрәфәт, бүген Әхмәт әкә тагын җанга тиде бит, кодаларны кайчан җибәрик дип кызыксына.

—Аңа кияүгә чыгарга иртәрәк әле, башта укысын,—дип сүзгә кушыла Хәлимә. Хәер, ул да кунакларның сеңлесенә күз төшергәнен чамалый иде.

Әмма бервакыт, икесе ялгыз калгач, сүз тагын кодалар турында чыкты һәм Шәрәфәт уенын-чынын бергә кушып әйтте дә ташлады:

—Менә сезгә мин уйлап та тормыйча кияүгә чыгар идем, ә нефтебаза директоры малае, шуның өстенә, гади авыл малае мине кызыктырмый, балаларымның әтисе сезнең кебек күренекле нәселдән булуын теләр идем.

—Мин бит инде өйләнгән кеше, белгән булсам, көткән булыр идем,—дип шаяртуга шаярту белән җавап бирде ул.

—Булса ни,—диде Шәрәфәт,—икенче хатын итеп алыгыз, шәригать күп хатын алуны тыймый ла!

Әнвәр Абидович шикле яссылыкка күчеп баручы гәпне туктатырга ашыкты:

—Белмәгән нәрсәң юк, шәригать кануннарын да, күп хатынлык турында да беләсең, ә минем идеология работнигы икәнлегемне онытканcың, мине бит икенче көнне үк партиядән чыгарып атачаклар.

—Чыгарсыннар, сез инде болай да бай! Алай булса, мине хатынлыкка алыр идегез,—дип киреләнеп җавап бирде унынчы класста укучы кыз бала.

Бу сәер сөйләшү тәки аның күңеленә сеңеп калды. Ул чакта әле ул үзенең хезмәт баскычлары буйлап шулай текә күтәреләчәген, өлкәдәге кешеләр язмышын хәл итә башлаячагын күз алдына да китерми иде, шунлыктан, хатынының сеңлесенә карата яман уй башына да кереп карамаган иде. Әмма Шәрәфәтнең сүзләре дулкынландырмый калмады. Әйбер сатып алганда, хәзер ул аларны Шәрәфәткә дип тә ала башлады, кызның шатлануын күрү чиксез канәгатьлек китерә иде.

Хәлимә хәтта берничә тапкыр җитди итеп кисәтеп тә алды:

—Сеңлемне шашындырма сана, юкса сезнең өйдә ул бөтенләй үзгәрде, үзен хан кызыдай итеп хис итә башлады.

Ул шаяртып кына куйды:

—Әлбәттә принцесса, хан кызы! Әйдә сөенсен, шатлансын, синең сеңлең ич ул!

Шәрәфәт мәктәпне яхшы тәмамлады, нәкъ шул көннәрдә районга разнарядка килеп төште. Мәскәүнең әдәбият институтына республика квотасыннан бер урын бирелгән икән. Һәм ул нәкъ вакытында булды да. Шәрәфәт журналистка булырга хыяллана, шигырьләр язгалый, район газетасына мәктәп комсомолы эшчәнлеге хакында мәкаләләр биреп бара. Шуның өстенә, аны гөнаһтан еракkарак җибәрү дә хәерле булыр иде.

Әнвәр Абидович чыгарылыш кичәсенә ак түфли алып кайткач, рәхмәт хисләре ташыган кыз аны иреннәреннән шул хәтле кайнар итеп үбеп алды, моңа кадәр аны әле беркемнең дә болай дәртле үпкәне юк иде, менә шунда ул үзенең упкын читендә басып торуын аңлап алды да.

Шәрәфәт укырга китеп баргач ул аны онытты да. Сентиментальлек дигән нәрсә аңа хас түгел, шуның өстенә, сагынып маташырга буш вакыты да калмый иде. Тын алыр ара юк: эш, карьера, гаилә—иртә таңнан чыгып китә, караңгы төшкәч кенә кайтып керә.

Ләкин язмыш тәгәрмәче бөтенләй көтелмәгән борылышлар ясый, кайда нәрсә табачагын, яисә югалтачагын беркем дә алдан белми. Ике еллап вакыт узды. Өлкәдә үткәрелгән ниндидер киңәшмәләрнең берсендә ул иң югарыдагы Түрәнең күзенә чалынган, кыюлыгы, колачлы фикерләве белән яхшы тәэсир калдырган һәм аны озакламый Мәскәүгә, КПСС Үзәк Комитеты янындагы Иҗтимагый Фәннәр Академиясенә укырга җибәрделәр. Бөтенесе бер атнада хәл ителде: августта әле ул мамык җыю кампаниясенә әзерләнеп йөри иде, ә сентябрьдә башкалада лекцияләр тыңлый башлады. Юлга чыгар алдыннан аңа республика хуҗасы үзе хәерле юл теләде, кочаклап үпте һәм яхшы укырга киңәш бирде, "Син безгә кирәк булачаксың", диде. Менә шул чакта Кәтүк эчтән генә аңа тугры хезмәт итәргә, аның өчен гомерен дә җәлләмичә утка да, суга да керергә ант итте. Хәлбуки, аны моннан беркем дә сорамаган һәм тугрылыкта ант иттермәгән иде.

Шулай итеп, Мәскәүдә аларның юллары тагын кисеште. Академиягә китәр алдыннан ул аны бер ел буе диярлек күрмәгән иде, яшьләр нәшриятында практика үткәнлектән, Шәрәфәт каникулга кайтмаган иде. Әнвәр Абидовичның Мәскәүгә укырга киләчәген белүгә үк, ул телефоннан ялынып-ялварып башлыклы, аксыл төстәге дубленка алып килүен үтенә башлады, хәзер шундыйлар модага кергән икән. Кайры тун белән бергә тагы башка чүпрәк-чапрак та алып килде ул, ләкин боларны Хәлимәгә әйтеп, сиздереп тормады, хәләленең көнләшә башлавы да бар иде.

Кәтүкнең моңа кадәр әле бер тапкыр да Мәскәүдә булганы юк иде һәм ике ел эчендә башкалага тәмам иләшеп беткән Шәрәфәт бик кирәк булып чыкты. Булачак идеология работникларын тәрбияләү, укыту белән нигезле итеп житди шөгыльләнәләр, культура программасы бай, театрларга, концертларга, күргәзмәләргә, Кино йортындагы махсус сеансларга йөрергә мөмкинлек бирелә. Әнвәр Абидович Шәрәфәткә бер тылсымчы кебек булды, Мәскәүне шаулаткан теләсә кайсы спектакльгә, премьерага, сәхнә йолдызлары концертына, кинофестивальгә, дан-шөһрәт яулаган чираттагы яңа талант белән иҗади очрашуга билет таба ала иде ул. Шәрәфәт апасының иренә сокланып туя алмый, горурлана һәм академия тәмамлап кайтканнан соң аны нинди биек очыш көтәсен уйлап хыяллана иде.

Яңа елны академиянең тулай торагыннан ерак түгел урнашкан "Пекин" ресторанында каршы алдылар. Зиннәтле залга, бәйрәмчә киенгән кешеләргә күз йөртеп, Әнвәр Абидович бәйрәм итүнең колачыннан, музыка тавышларыннан исерде, язмышның борылышлары хакында уйланды; әле ярты ел элек кенә ул бу хакта уйларга кыймый иде бит һәм иелеп янында утыручы Шәрәфәтнең битеннән үбеп алды. Куе чия төсендәге кичке күлмәк кигән яшь, чибәр, зифа сынлы кыз ир-атның игътибарын магнитлаган кебек үзенә тарта; Әнвәр Абидович исә боларның барысын да күреп, сизеп тора һәм шундый гүзәлнең үзенеке булуыннан горурлана, сөенеп туя алмый иде. Нәкъ менә шушы яңа ел төнендә кыз аның сөяркәсенә әйләнде дә.

Мәскәүдә яшәүнең гайре күңелле яклары да байтак икән. Һич кенә дә акча җиткереп булмый иде. Шәрәфәт белән мөнәсәбәтләрен ул башкаларга сиздермәскә тырышты, һәр курста диярлек якташлары укый, аның тәртибе хакындагы мәгълүматларның үзе мәңге тугрылыкка ант иткән кешегә да барып ирешү ихтималы

бар. Ә ул, кешеләрнең байтак йомшаклыгына күз йомса да, уйнаш кылу дип аталган бозыклыкны кичерми, андый юлда эләккәннәрне усал һәм каты җәзалый да белә. Тотанаклы, әхлаклы кеше буларак, ул кешеләрдә дә шул сыйфатларны югары бәяли иде. Шулай булгач, Кәтүкнең куркыр, шикләнер нәрсәсе күп, ә Хәлимә белән араны өзү турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Шәрәфәтнең тулай торагы еракта, Останкино сөт заводы янында, Добролюбов урамында. Хезмәт хакы тулысы белән таксига китеп бара. Шуның өстенә, күрешү, очрашу өчен "Пекин"нан ерак түгел, Тишино базары янында яхшы бүлмә алырга туры килде. Анысына айга йөз сум китә. Кыскасы, акча… акча… акча…

Укырга киткәнче райком секретаре булып ул өч ел гына эшләп калды һәм кайчан да булса текә күтәреләчәген сизенгәндәй, беркемне дә үзенә артык якын җибәрмәде. Бәлки, тумыштан сак булуы тәэсир иткәндер, ул бары ышанычлы кешеләр, туган-тумача, үз нәселе кешеләре аша гына эш йөртте, кулына кергән хәтлесе тулаем җитеп бара иде. Ә баксаң, башка төрле тормыш та бар икән, монда әллә никадәре акча да җитмәс иде.

Мәскәү аны шушы ачышы белән тетрәндерде; дөньяга күзләре яңадан ачылган кебек булды, нинди колач белән эш итәргә, ниндирәк эшләр майтарырга кирәклеген аңлады ул, ниһаять.

Һәм инде бервакыт район җәмәгать тыныулы идарәсе башлыгы шылтыратып, тормыш-көнкүреш, хәл-әхвәл турында сораштырырга тотынгач, Әнвәр Абидович артык зарланып тормастан, әйтеп ташлады: дустың, милиция башлыгы белән килеп чыксагыз ни була, хәлләремне күреп китәр идегез, кунак итәрмен, театрларга йөрербез. Районга хуҗа булып торган чагында шушы ике әшнә тырышып-тырмашып аның күңеленә юл табарга сәбәп-сылтау эзлиләр иде. Аның читләтеп әйткәнен дөрес аңлаганнар булып чыкты, бер атнадан аспирант Казан вокзалында икесенә бер купе алып килгән якташларын каршы алды, ул кадәр йөк белән Аэрофлот кабул итми икән. Шул көннән башлап Мәскәүдәге тормыш җайга салынды, кунаклар төгәл бер интервал белән килә тордылар, аспирантыбыз почтага да, телеграфка да ышанып бетми иде.

Көтмәгәндә ул тагын бер, шактый нык сизелерлек ярдәм алды. Аеруча шатлануның сәбәбе бүләкнең суммасында түгел, ә кемнән булуында иде. Урнашкан гадәт буенча, һәр курстан соң аспирантлар җәйгә каникулга кайткач Үзәк Комитетка керәләр, һәрвакыт Беренче аларны үзе кабул итә, тормышлары белән кызыксына, Мәскәү яңалыклары, сабакташлары, укытучы-остазлары турында сораштыра. Әнвәр Абидович шундый хисап визиты белән барганда коточкыч дулкынланды, Шәрәфәт турында, районнан кунакларның еш килүе хакында әйткән булсалар, нишләрсең?! Ләкин, курыксаң да, курыкмасаң да бу очрашудан котылып булмый иде.

Беренче аны үзе турында хәбәр бирүгә үк һич тоткарлыксыз кабул итте һәм моны Әнвәр Абидович яхшы фалга юрады, әмма барыбер куркудан һәм дулкынланудан куллары тирләп чыкты, күз кабагы тарта башлады. Аның дулкынлануын кабинет хуҗасы исә шулай булырга тиеш хәл дип кабул итте, мөгаен, моны үз шәхесенең бөеклегеннән, кабул итүнең тантаналы булуыннан күргәндер. Ул һәрнәрсә турында җентекләп, бөртекләп сорашты, аның академияне үтә яхшы белгәнлеге, андагы кайбер нәрсәләр турында аспирантлардан ким хәбәрдар булмаганлыгы сизелеп тора иде. Сораштыру, хәл белешү озаккарак сузылган саен кунакның үз-үзенә ышанычы арта барды, тынычлана төште, димәк, белми, чакмаганнар, сизенмәгәннәр. Табигый ки, бөтен тормыш ваклыкларын сөйләп бирергә беркатлы адәм түгел иде ул, якташлары аркылы күзәтү булу мөмкинлеген сизенә, сизенү генә түгел, бу хакта белә һәм аннан да битәр, тоемлый иде.

Әңгәмәне тәмамлар алдыннан Беренче аталарча җылылык белән сорап куйды:

—Акчаң җитәме? Хәерчеләнеп бетмәдегезме? Белгәнемчә, сезнең гаиләгез зур, дүрт балагыз бар.

Аспирант җиңелчә сагаеп калса да сиздермәде, уйлап та тормыйча җавап бирде:

—Академиядәге ашханә бик әйбәт, иң мөһиме—арзан. Җитә. Мин тыйнак яшәргә күнеккән кеше.—Ул инде партия даирәләрендә "Әти" дип йөртелүче бу кешенең "тыйнаклык" сүзен яратуын, аны бик еш куллануын белеп өлгергән иде.

Җавап, күрәсең, Беренчене канәгатьләндерде, ул серле генә елмаеп куйды да өстәл яныннан торып кабинет буйлап йөреп килде, тәрәзә янына басып, юлның икенче ягында, яр буенда яшеллеккә чумып утырган "Пахтакор" стадионына озаклап карап торды.

Менә шушы минутларда Әнвәр Абидовичның куркудан бала йоннары кабарды да инде.

"Әти" бик озаклап нәрсә турындадыр уйланды, кайвакыт ул кабинетта кеше барлыгын оныткан кебек тоела башлады. Аннан соң өстәл янына килеп утырды, сәркәтиптән чәй сорап алды һәм ягымлы итеп эндәште:

—Кадерле Әнвәрҗан, мин бит сезне Мәскәүгә гыйлем туплар, диссертация яклар, галим кеше булып кайтыр өчен генә җибәрмим. Галимнәр бездә җитәрлек, хәтта артыгы белән, кемгә төртмә, кайсысы фәннәр кандидаты да, кайсысы фәннәр докторы. Җан башына гыйлемле кешеләр саны буенча илдә беренче урынны тотабыз. Минем иң зур теләгем: бергә укыган кешеләр белән дуслашыгыз, якташлык җәмгыятендә, кухнядагы майлы казан янында мәш килеп, пылау пешереп вакыт әрәм итмәгез. Кызганыч, аспирантларның әллә ничә буыны шул баткаклыкка батып калды. Академия ул, минем карашымча, әгәр тарихтан хәтерләсәгез, патша вакытындагы Царское Село лицее, Паж корпусы, Преображенский полк кебек. Үзәк Комитет секретарьлары, шәһәр һәм өлкә комитеты секретарьлары, министрлар, депутатлар, газет редакторлары һәм гаммави информация хезмәте җитәкчеләре шуннан гына чыга. Киләчәктә үз төбәкләрендә дилбегәне кулларына алачак шул кешеләр белән дуслашыгыз, алар белән ныклы бәйләнеш булдыру башкаладагы төп бурычыгыз. Шул максатка сезгә өч ел вакыт бирелә. Дөнья кендекләре белән дуслык аша сез ватанга, аның чәчәк атуына хезмәт итә алачаксыз. Аңладыгызмы?

Артык дулкынланудан, ышанып һәм якын итеп сөйләшүдән кунак телен йоткандай булган иде, ул бары тик баш кына селки алды.

Кабинет хуҗасы чәйне йомрыларга үзе салды һәм ниндидер кнопкага басып әйтте:

—Сабир, кереп чык әле, зинһар, минем янда Мәскәүдән Әнвәр Тилләхаҗиев.

Мәгърур кыяфәтле ир-ат килеп керде һәм кунакка игътибар белән карап алгач, Беренче алдына, өстәлгә юка гына конверт куйды. Сабир атлы бу кеше чыгып итүгә, "Әти" сүзен дәвам иттерде:

—Бу сезгә, Әнвәрҗан, әнә шул бәйләнешне булдыру, ике арада күпер салу өчен. Аны ничек исраф итүегез хакында хисап сорамам, чөнки аны әрәм-шәрәм итмичә акыл белән тотачагыгызга ышанам, сезнең җиңел кулыгыздан һәркайда дусларыбыз ишәйсен. Әгәр үз кулыгыздан гына килми торган берәр эш килеп чыкса, әйтик, укытучылардан яисә аспирантлардан кемдер Сәмәрканд, Бохара, Хива, Ташкент белән танышырга тели икән, бер дә кыенсынмыйча шылтырата аласыз, чакырыгыз, әйбәтләп каршы алырбыз.

Хушлашканда Беренче көтмәгәндә сорап куйды:

—Минем үтенечем сезне кыенсындырмый торгандыр, авырлык китермәстер бит?

—Ышанычыгызны акларга тырышырмын, дәмулла,—диде артык хисләнүдән башы әйләнгән кунак һәм аның кулын үбәргә иелә башлады, әмма Хуҗа ирек бирмәде, иңнәреннән кочып алып, ишеккә хәтле озата килде.

Кабул итүдән, үзенә күрсәтелгән ышанычтан күкнең җиденче катында йөзүче Әнвәр Абидович конверт турында бөтенләй оныткан иде, бары тик кич белән, поездда кайтып барганда гына ул аны исенә төшерде һәм конвертны ачып карады, анда илле мең сум акча салынган саклык кенәгәсе ята иде.

Поездда ул төне буе йоклый алмады, җанында бәйрәм, йөрәге күкрәк читлегеннән сикереп чыгарга җыенгандай ашкынып тибә... ул берничә тапкыр суынып, тынычланыр өчен вагон коридорына чыгып та карады, ләкин тынычлана алмады, сикерәсе, биисе, җырлыйсы килә иде. Ләкин бу шатлык үз карамагына илле мең сум акча алудан гына түгел, аны акча мәсьәләсе борчымый иде инде. Иң мөhиме, ул Беренченең ышанычлы кешесенә әверелде, аның ни бәя торганын ул яхшы белә, Беренче теләсә кемне үзенә якын җибәрми, ә инде үзенекеләрне, хәтта гаепләрне дә, беркайчан да рәнҗеттерми иде.

Әле кичә генә Хәлимә белән очрашуны ул борчылыбрак көтә, үзен гаепле саный иде, әмма инде Беренче белән сөйләшүдән соң, әйтерсең, аның гөнаһларын ярлыкадылар һәм алар бер дә булмаганча гаип булдылар, ул гына да түгел, ул үзенең кулында яклаучы вә саклаучы кәгазь, индульгенция бар дип хис итә, аның киләчәктә булачак гөнаһлары да кичереләчәк дип уйлый, үзен иң югарыдагы дәүләт кешесе итеп тоя башлаган иде. Шунлыктан Шәрәфәт белән мөнәсәбәтләр юк-бар, вак нәрсә булып, аның газаплануларына сәбәп була алмый иде инде. Үзәк Комитет бинасыннан

чыккач ул үзен башка, бөтен кешеләрдән өстә, югары очышта итеп хис итте ки, хәзер аның кылган гамәлләре гади кешелек әхлагы, йолалар һәм гадәтләр кысаларына керми, шунлыктан, ул хатыны алдында да, Шәрәфәт һәм аның әти-әниләре алдында да үзен гаепле санамый иде инде.

Мәскәүдә чагында ул еш кына өен, гаиләсен искә төшерә, сагына, әлегрәк беркайчан да якыннарыннан аерылмаган кеше буларак, күрешү мизгелләрен күз алдына китерә торган иде; әмма "Әти" янында булып чыкканнан соң, моңарчы булган кыйммәтләр: йорт, гаилә, балалар дигән төшенчәләр кинәт әһәмиятен югалттылар. Аның җаны туганнары, балалары һәм хатыны белән очрашуны уйлап бәргәләнми, ул әле үзен һаман Анхор суы буендагы күз явын алырдай ак бинаның бишенче катында хис итә, иңнәрендә Беренченең ышанычлы кулларын, аның җылылыгын тоя иде. Бу хис шул хәтле көчле иде, ул җанына тынычлык таба алмыйча бәргәләнде, түземсезләнеп кичне көтте. Караңгы төшүгә үк мәчеткә китеп барды. Мулла белән алар инде күптән әшнәләнгән иделәр, бу мөнәсәбәтләрне кеше күзенә бик үк күрсәтергә теләмәсә дә, мәчеткә шактый нык ярдәм итеп килде. Ислам диненең асылда райком шикелле үк бер принципларны алга сөрүен сизеп алган иде инде ул. Дин ахирәттә оҗмах вәгъдә итсә, райком исә халыкны якты киләчәк белән ымсындырып тота. Гадирәк итеп әйткәндә, ике рухи остаз бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар иде.

Мулла, бердән, аның шулай соңлап килүенә, икенчедән, райондагы беренче мөселманның артык дулкынланган булуына гаҗәпләнде. Абруен күтәрер өчен мәчеттә аның хакында ул шулай "районның беренче мөселманы" дип сөйли иде. Йола кушканча, мулла кунакны бакчага чакырмакчы булды, хезмәтчеләре дастархан әзерләргә ташланып та өлгергәннәр иде, әмма кунак кул гына селтәде.

—Дәмулла, йөрәгемдә ут кайный, башта бер кешегә мәңге тугрылыкка Коръән тотып ант итәсем килә, аннан соң гына табын янына утыра алырмын, җаным тынычлангач кына,—диде.

Мулла Коръән китерергә кушты. Изге китапны алып килүгә ул кунактан сорады:

—Тугрылыкта ант итәргә сез вәзгыятьтән чыгып мәҗбүрме, әллә моны вөҗдан кушуы буенча эшлисезме?—диде.

—Йөрәк кушуы буенча,— диде кунак дулкынланып.

—Мәслихәт, бик мәслихәт, Аллаһы Тәгалә мәҗбүри бирелгән антны сөйми.

Аспирант ак паласка тезләнде һәм иңнәрендә әле һаман кул җылысын тоеп торган кешегә инанып һәм хыянәтсез тугры хезмәт итәргә ант сүзләрен кабатлады.

Һәм менә нәкъ шул көнне ул гаиләсеннән аерылды да: юк, ул гаиләне туендыру, киендерү, аның ихтыяҗларын кайгырту кебек өстенә йөкләнгән вазифалардан ваз кичмәде, ләкин ниндидер гамәлләре өчен гаиләсе алдында гаепле санап газаплану кебек нәрсәләрне үзе өчен түбәнлек саный башлады.

Мөгаен, яшь һәм чибәр Шәрәфәт, Мәскәү хәлләре, үзен беренче тапкыр кеше арасында Наполеон дип атый башлаулары, еракта калган истәлекле еллар хакында бик озак уйланып утырган булыр иде ул, әмма телефон шылтырады һәм обком пешекчесе ризыкның әзер булуын, яхшылап төреп, машинага кертеп куелуын хәбәр итте. Телефон аны тансык уйларыннан аерды һәм еш кына бер сәбәпсез нәфрәтенә буыла торган Әнвәр Абидович трубканы атып бәрде, хәтта рәхмәт тә әйтеп тормады.

Кызыл төстәге телефон трубкасы урынына килеп төшүгә, икенчесен, ак төстәгесен күтәрде һәм аннан Шәрәфәтнең тавышын ишетүгә мыгырдап куйды:

—Хәзер чыгам…

Аның кәефенең бер сәбәпсез кинәт үзгәрүенә, авызлыкланмаган кыргый дәрткә бирелүенә ияләшеп беткән Шәрәфәт әле ярты сәгать элек кенә гашыйк егетләрне хәтерләтеп күгәрчендәй гөрләгән кешенең мыгырдануына бер дә гаҗәпләнмәде.

Аркасына аждаһа сурәте төшерелгән, укалап чигелгән атлас халатына төренеп Шәрәфәт көзге каршына килеп утырды һәм яхшылап ясатылган чәчләрен рәтләгәндә бер бөртек ак чәч күреп алды, әмма йолкып ташламады, моңсу гына тагын берәү, дип уйлап куйды. Көзге янында байтак бөтерелүенә карамастан, тагын бер кат җентекләп үзенә күз төшереп алды, яңакларына чак кына иннек өстәде һәм ул ярата торган "Черная магия" хушбуен җиңелчә сөрткәләп алды. Башкасын белми һәм белергә дә теләми, монысын исә әрҗәсе белән генә китереп ташлый, әрҗәдә уникешәр төргәк була. Бизәнү-ясануның соңгы сызыкларын тәмам кылгач, ишек янына ашыкты. Әнвәр Абидович көтәргә яратмый. Иркәләп бозылган бала диярсең, һәр нәрсә секундында

булсын. Мин шулай телим, бетте-китте вәссәлам! Калганы минем эш түгел. Кияүгә чыкканнан соң булган һәм гадәти көн үткәрү тәртибен бозып ташлаган бер вакыйга әле дә исендә Шәрәфәтнең. Бер ахирәте янына шигырь укып утырырга дип чыгып кына киткән иде. Кирәк бит, нәкъ шул минутта Әнвәр Абидович аның янына киләсе иткән. Ул өйдә юк! Коточкыч җәнҗал купты ул көнне, котырынуына түзәрлек түгел иде һәм шул вакытта Тилләхаҗиев катгый таләп куйды: моннан соң беркайчан да өйдән чыкмыйсың, теләгән чагымда мин сине күрә алырга тиеш! Ул Ташкентка киңәшмә-мазарга киткәндә, яисә өлкәгә командировкага чыкканда гына Шәрәфәт каядыр йөри ала торган булды.

Нәкъ шул чакта алар өенә туры телефон куелды. Наполеонны якыннан белмәгән кешегә бу мәгънәсезлек булып тоелыр иде, ләкин Шәрәфәт аның үз дигәненә ирешү өчен бернәрсә алдында да туктап калмаячагын белә. Ул елдан-ел тотнаксызлана, түземсезгә әйләнә барды. Бервакыт партия өлкә комитеты пленумы барганда туры телефон шылтырый башлады. Пленумны телевидениедән күрсәтеп торалар, әле биш минут элек кенә Тилләхаҗиев президиумда утыра иде. Телефонны ялгыш җыйдылар бугай, дип уйлап куйган иде. Әмма шылтыратучы чыннан да ул иде, сөйләшүе ягымлы, артык назлы яңгырый иде, Шәрәфәт хәтта шикләнә калды, сорарга мәҗбүр булды:

—Ә пленум ничек?—диде.

Ул исә инде төп чыгышны ясаганлыгын, хәзер сәгать ярымлап өстәмә докладлар тыңланачагын, соңыннан фикер алышу буласын әйтте, кыскасы, күңелсез, ялыктыргыч эш, шуңа күрә аны күрәсе килгән икән.

—Хәзер үк килеп җит, машина җибәрдем, яшерен ишек янында сине Йосыф көтеп торыр.

Ун минуттан ул аның ял бүлмәсендә иде инде. Идеология мәсьәләләренә багышланган пленумнан хәтта кул чабу тавышлары ишетелеп торды. Шәрәфәт һич кенә дә тынычлана, оныта алмады, бертуктаусыз кабатлый бирде: "Шундый мөһим чара синнән башка гына узамы?" Ә ул исә кул гына селкеде: "Әнә Цезарь ниләр генә кыланмаган, башыңа китерерлек тә түгел, мин аннан кайтышмы, пленум карары инде бер атна элек үк әзер иде". Шулай да фикер алышу өлешенә кереп өлгерде һәм коммунистның әхлакый йөзе хакында дәртләнеп, канатланып чыгыш ясады.

Юк, ул көтәргә яратмый.

Шәрәфәт коттеджның ачык верандасына чыгып кына өлгерде, капка төбендә машина күренде.

Алгы бүлмәгә килеп керүгә кием-салымга аерым бер таләпчәнлек белән караучы түрәбез җиңел пиджагын салып Шәрәфәткә тоттырды. Аның холкының һәр чалымын сеңдереп бетергән Шәрәфәт исә һич тә курыкмыйча һәм икейөзләнмичә ягымлы итеп сорады:

—Нишләп йөзең кара болыттай әле, Заркент әмиренең кәефен кем шулай бозды икән?

—Һәрчак бер кабахәте табыла тора, иртән булмаса, төшкә барыбер кәефеңне бозалар,—дип тугарылып китте Тилләхаҗиев.—Синең Мәхмүтов турында ишеткәнең бардыр, өлкәдә иң алдынгы районда...

—Әлбәттә, бар, Күпер Булатны кем белми, бик тә хөрмәткә лаек, мөхтәрәм кеше, диләр...

—Син дә шул ук җырны җырлыйсың... хөрмәткә лаек имеш...—дип үртәде Кәтүк.—Менә шул... кем әле... Күпер Булатың ят элемент булып чыкты, социаль чыгышын партиядән яшереп килгән... Ничәмә-ничә еллар буе качып йөреп кара әле... Ну и кешеләр, партиягә сыланырга гына торалар...

Шәрәфәт гаҗәпләнеп карап торды һәм аның шаяртмаганын аңлагач, кычкырып көләргә тотынды, хәтта кулыннан пиджак төшеп китте.

Шәрәфәт башын җиңелчә артка ташлап, кытай атласыннан тегелгән халат итәкләрен тотып, матур итеп көлә белә. Аның көлүе Наполеонны бөтенләй аптырашта калдырды, кинәт кенә ул тынычланып калды һәм ризалашкандай сорап куйды:

—Кадерлем, әллә мин берәр көлке нәрсә әйттемме?—диде.

Шәрәфәт аны кочаклап алды:

—Әгәр берәрсе сине читтән карап торса, ни сөйләгәнеңне ишетсә көлеп үләр иде! Нәфрәтең шул хәтле чын булып тоелды, Смоктуновскийларың бер якта торсын...

—Әлбәттә, коммунист буларак, чынлап ачуым кабарды, Мәхмүтов кебекләргә

безнең сафта урын булмаска тиеш!—дип янадан кабынып китте ул.

Шәрәфәт көлүген тыя төшеп аңлатып бирде:

—Әнвәржан, ярар, Булат ят элемент, сыйнфый дошман улы да булсын, ди, ләкин син дә гидайлардан түгел, моны бөтен кеше белә ләбаса. Тилләхаҗиевлар—күренекле нәсел, аксөяк дворяннардан, князьләр дияргә мөмкин. Кыз чагымда шул князьлеген өчен яраттым да инде мин сине.

—Чыннан да, үзем турында уйлаганым юк иде,—дип югалып калгандай булды Кәтүк, ләкин үзен бик тиз кулга алды.—Ләкин мин үземнең чыгышымны махсус рәвештә партиядән яшермәдем, әтиемне халык дошманы буларак атып үтермәделәр, Аллага шөкер, узган ел үз өендә үз үлеме белән дөнья куйды. Аннан соң, Тилләхаҗиевлар—алар барыбер Тилләхаҗиевлар булып кала, тапкансың чагыштырыр кеше, Заркентта Мәхмүтовлар идарә итәргә тиеш түгел!—дип әтәчләнде обком секретаре.

—Ярый инде, тынычлан, кадерлем! Вак-төяк өчен кабындың да киттең.—Һәм кочагына алып үбә башлады, аны ничек тынычландырырга кирәген, үзенең өстен көче барын сизә иде ул.

Шул ук мизгелдә Мәхмүтов турындагы уйлары да таралып очты, алар вак һәм мәгънәсез булып тоела башлады, авызыннан арслан үкерүенә охшаш аваз ургылды һәм ул, дөньядагы бар нәрсәне онытып, Шәрәфәтне кулларына күтәрде дә йокы бүлмәсенә йөгерде.

Шәрәфәт юкка гына ычкынырга теләп бәргәләнде, верандада калган ризыклар, аларның суынуы хакында мыгырданды, әмма болар барысы да ясалма кыйлану гына булып, Наполеон аларны колагына да элмәде.

Бер ярты сәгатьтән соң ул төшке аш, верандада калган кәрҗиннәр хакында үзе үк искә төшерде. Шәрәфәт кызыл агачтан ясалган, корабка охшаган биек караваттан җиңел генә сикереп төште. Алар аны шаяртып безнең корвет дип йөриләр дә иде. Чуалып беткән ак җәймәләр, ак атластан сырылган юка юрган, чыннан да, читтән караганда борынгы корветның шәлберәеп төшкән җилкәннәрен хәтерләтәләр иде.

Шәрәфәт алдан ук махсус хәзерләп куйган челтәрле күлмәген киеп алды һәм аның сокланып караганын сизгән хәлдә көзге каршында туктап алды, чәчләрен төзәткәләде, аннан янадан корвет янына килде:

—Аз гына сабыр ит инде, ун минуттан ванна бушый, беләсең бит, бездәй хәерчеләрнең ваннасы берәү генә...

Кәтүк әйтелмәгән, әмма сүз араларына кыстырылган яшерен мәгънәне дә аңлап алды: болар безнең коттеджны да үзеңнеке шикелле заманчага, уңайлыракка алыштырыр вакыт җитте, дигәнне аңлатырга тиеш иде. Ул бу гаделсез сүзләрдән кабынып: "Минем ике ваннам булса, балаларым алтау, җитмәсә, синең әти-әниең дә бездә тора",—димәкче иде, әмма үзен тыеп калды, чөнки зифа сыннан күзләрен ала алмый иде...

Шәрәфәт элеккечә һаман чибәр иде әле, Мәскәү аңа файдага булды, үзен карарга, тәрбияләргә өйрәтте, ашауда нәзберек, диета тота, махсус рәвештә ач утырган чаклары да бар. Гимнастика белән шөгыльләнә иде, хәзер аэробика белән җенләнә башлаган. Вакыты муеннан, "Мин иректә кеше, шагыйрә бит",—дип кенә җибәрә ул яңа танышларына. Юк-юк та машинада җилләнеп кайта, урамга машинага утырып чыкса, түрәләрдән шыр җибәрүче ГАИ хезмәткәрләре дер калтырый башлый. Мәскәүдә чакта аборт ясаткан хатынның бернәрсәдә гаме юк, операцияне өйдә генә ашык-пошык ясагангамы, әллә җиренә җиткереп эшли белмәгәннәрме, хәзер аның баласы булмаячагы ачыкланды. Шунысы да хак, аның кайчандыр бала төшертүе хакында беркем дә белми. Һәрхәлдә, ул үзе шулай дип саный.

—Алла җәзасын бирде аңа!—Иренең сеңлесе белән бәйләнешләрен сизгән Хәлимә генә рәнҗеп шулай дип кабатлап куя. Хәер, еллар узу белән аны гаилә, балалар, тормыш мәшәкатьләре басты, иренең суынуына кул селтәде һәм балалар хакына дип яши бирде.

Наполеон үзе дә аңламый, аны Шәрәфәткә бернинди хатын-кызга булмаганча тартылу хисе били, юкса, комсомолдагы, өлкә башкарма комитетындагы һәм профсоюзлардагы яшь карьеристкалар чак кына сиздерүгә үк сөяркәсе булырга әзер иделәр, ләкин ни уйлаганнарын алдан ук белеп торган кешегә алар кызык түгел иде. Шәрәфәтнең дә аңа тартылганын, аның янында үзен бәхетле хис иткәнен сизә ул,

аны алдап булмый. Яшь хатынга анның назлары тансык һәм кадерле иде. Аларның бер-берсенә карата тыелгысыз дәртендә ниндидер патология дә бар иде сыман, үзе бик ышана торган дустына, врач-психиатрга сөйләгәч, ул да нәкъ шулай диде. Бәлки, чыннан да, шулайдыр. Шәрәфәт әле мәктәптә укыганда, үндүрт яше дә тулмаган чакта төннәрен аларның йокы бүлмәсе янына килеп, ишек аркылы тыңлап торганы, һәр сулыштан, ыңгырашудан, ишетелүче һәр кыштырдаудан ничек дулкынлануы хакында сөйләгән иде.

Ванна бүлмәсендә су туктаганны ишетеп, ул да урыныннан күтәрелде. Шәрәфәт белән аның ире Хәким Нурматовның иркен йокы бүлмәсендә һәркайсының аерым гардеробы бар. Алты ишекле, шомартып ялтыратылган шкаф стенаның сул ягына куелган, мөселман кануннары буенча, ир кеше шул якта йокларга тиеш.

Ул нинди дә булса халат алмакчы булып таныш шкафның ишекләрен ачып җибәрде һәм гаҗәпләнүеннән хәтта сызгырып җибәрде:

—Оһо, бер айда күпме нәрсә китергәннәр,—дип куйды. Анның байтактан Шәрәфәт янына килгәне юк иде, һаман эш чыгып торды, бер-бер артлы комиссия килде, командировкаларга барып кайткалады.

Аны каршы алганда Шәрәфәт кигән халатка ошаганны сайлап алды, монысында да алтын аждаһалар булып, алар кара атласка төшерелгән, үреп ясалган авыр билбавы күнелгә аеруча ятышлы, биленне алтын пута белән буып куйгандай буласың икән.

Халатларның күплегенә гаҗәпләнмәде, монда иң яхшылары, затлылары гынадыр әле, дип уйлап куйды ул. Почмактагы берәр әрҗәдә аларның йөзләп булуы да ихтимал. Үзләрендә дә шундый ук хәл. Нишлисең, халык йолалары, кая барсаң да иңгә чапан салырга гына торалар, ОБХСС башлыгына исә кайчагында көненә өчәрне алырга туры килә.

Кәтүк чуклы билбауны буып куйды да Шәрәфәт шикелле үк көзгедәге чагылышына игътибар белән күз төшерде, күнелен канәгатьлек хисе биләп алды, әмма бәхетле елмаерга әзер иреннәр кинәт куырылып килде, чөнки үзеннән-үзе кесәгә тыгылган куллары һәр ике кесәдән алтын тәңкә тартып чыгарган иде. Патша тәңкәләре! Хәзерге курс буенча һәркайсы ун мең сумга тартучы алтын тәнкәләр!

—Вәт мыштым, вәт хәйләкәр җан, бу да алтын тозлый башлаган икән...—һәм кинәт кенә ачуы ташып чыкты—Нишләп миңа, туганына, үзенә игелек кылган кешегә пычрак кәгазь ташый әле бу! Кайтсын гына, күрмәгәнен күрсәтәм әле мин моның...

Тәңкәләрне нишләтергә микән дип уйланып торды, табигый ки, аларны кесәдә калдыру дигән нәрсә башына кереп тә чыкмаган иде. Миендә туып өлгергән яңа фикердән иреннәренә елмаю кунды һәм ваннага үтешли ул кухняда аш әзерләп маташучы Шәрәфәт янына сугылды. Шыпырт кына аның янына килде һәм аркасыннан сыйпап әйтте:

—Менә сиңа, бәгырькәем, миннән бүләк,—диде һәм берни дә аңламый торучы Шәрәфәт алдында симез учларын ачып җибәрде.

Шәрәфәтнең майга буялган кулларына бирмәс өчен тәңкәләрне кесәсенә шудырды да күңелле сызгыра-сызгыра, ире хисабына аңа бүләк бирүенә сөенеп, коенырга кереп китте.

Озаклап, тәмләп юынды, башында исә Шәрәфәтнең ире—Хәким Нурматов турындагы уйлар бөтерелде.

“Ничек миннән яшереп алтын җыя башлаган әле бу?—дип уйланды Кәтүк.—Ничек батырчылык иткән, нишләп миңа әйтмәгән, минем белән килештермәгән?”

Кайчандыр нәсел-нәсәпсез көчекне—район милиция бүлегендә ыштан төбе шомартучы мескен лейтенантны үзенең туганы, ышанычлы кешесенә әйләндерүе хакында исенә төшерде. Кара сине аны, хайванны, полковник погоннары тагып алгач, яшереп алтын җыя башлаган... Алтынга минем генә хакым бар, алтыннар минеке генә булырга тиеш икәнне белмиме? Тилләхаҗиев фамилиясе үзе үк “алтын” сүзеннән ясалган, “хаҗи” кушымчасы да өстәлгәч, ул минем иң югары нәселдән икәнлегемә ишарәле ләбаса! Кәтүкне һич арттырмыйча “Алтынга согынучы”, “Алтын хөкемдары” дип әйтеп булыр иде, андый кеше үз биләмәләрендә башка берәүгә алтын җыю хокукы бирә аламы?

Мәскәүдә Шәрәфәт белән укуларын бер үк вакытта тәмамладылар алар, ләкин ул кызга тагын ике елга Мәскәүдә калырга киңәш итте, житмәсә, кафедрада урын тәкъдим итәләр, кандидатлык диссертациясе яклау мөмкинлеге дә ачылып тора иде. Аның сүзе—канун, Шәрәфәт каршы килеп маташмады.

Кайткач ул тагын районны җитәкли башлады, ләкин Шәрәфәтне кайдадыр урнаштыру, аңа үз хокукларын да саклап калу кирәклеген беркайчан да онытмады.

Шулай берчакны, район милициясе башлыгы, әле академиядә укыганда танышып, дуслашып өлгергән полковникта кунакта чагында аның башына котылу юлы килде дә. "Кул астыңдагы кешеләр арасында кияү булырлык берәр әйбәт егет юкмы,—дип сорады ул.—Тик бер сыйфаты булу шарт, анысы да булса, саранлык",—диде. Тегесе көлеп кенә куйды, шаярта дип уйладымы, барлык хезмәткәрләренең, картының да, яшенең дә комсызлыкта, карунлыкта аерылып торуларын әйтте. Рәхәтләнеп көлгәннәр иде. Ләкин райком секретареның шаяртмавын сизгәч, полковник җитди итеп уйлап карарга вәгъдә бирде. Өч көннән ул секретарьга бер егетне күрсәтте һәм холкын аныклап бирде: бу егет акча дисәң туган анасын сатып җибәрергә, әтисен буып үтерергә әзер, диде. Шул егет Хәким Нурматов булып чыкты да инде.

Наполеон аны бер айлап диярлек күз уңында тотты, егет аңгыралардан түгел, әмма коточкыч аумакай һәм саранлыкта, комсызлыкта чикләрне белми иде. План өлгереп беткәч, ул Нурматовны чакырып алды һәм әйләнмичә-бәйләнмичә дигәндәй, әйтте дә салды, минем белән туганлашырга теләмисеңме, диде. Нәсел-нәсәпсез лейтенант аптырашка калды, Әнвәр Абидовичның кияүгә чыкмаган сеңелләре юк, барысы да тормышта, бала үстереп яталар, аерып җибәрергә җыенулары ишетелми; секретарьның якын туганнары арасында гарип-гораба да күренми—лейтенант бу нәселдән башка берәр кызга тиң булырмын дип күз алдына да китерә алмый иде.

Аның югалып калуын күреп, кабинет хуҗасы балдызының, ягъни Шәрәфәт Касыймованың Мәскәүдә аспирантурада укып йөрүен, каникулга кайткач егетне күреп ошатып калуын, бу хакта туган буларак үзенә сөйләп бирүен әйтте. Аның да укырга Мәскәүгә бару мөмкинлеген исенә төшерде. ОБХСС работникларының ел ярымлык курслары ачылачак икән. Шәрәфәт белән менә шунда күрешергә мөмкинлек туачак имеш.

Әйе, лейтенант аңгыралардан түгел, дәрәҗәле кешеләрнең сөяркәләрен, йә булмаса азып-тузып йөргән кызларын кул астындагы тыңлаучан кешеләргә аткаруларын, аларга мәңге хәерхаһ булырга вәгъдә итүләрен белә иде ул. Монда да шундыйрак хәл булмагае.

Дөрес, лейтенант Шәрәфәтне белә, бер мәктәптә, параллель класста укыганнар. Мәскәүдән тагын да чибәрләнеп, көязләнеп кайтканын җәй көне күреп, чамалап калган иде, кайсыдыр бер хезмәттәше әйтмешли, ул француз туташларын хәтерләтә башлаган иде. Аның икеләнгәнен сизенеп, кабинет хуҗасы очраклы рәвештә генә ычкындыргандай әйтте: яхшы укысаң, кайткач та район ОБХСС башлыгы булырсың. Нурматов шуннан кимрәккә исәп тотмый да иде, бер атнадан ул укырга китеп барды. Мәскәүдән капитан дәрәҗәсе алып һәм... өйләнеп кайтты.

Менә шул вакытлардан бирле Әнвәр Абидович Шәрәфәтнең ирен һәрвакыт янәшәдә тотарга тырышты; өлкә комитеты секретаре булгач та аңа өлкә ОБХСС башлыгы урынын ышанып тапшырды. Дөресен әйтергә кирәк, Нурматов бернинди кыенлык тудырмый, урынын белә һәм нәрсә хакына мондый дәрәҗәгә, шәфкатькә, бөек мәрхәмәткә ирешүен аңлый иде. Тәртәгә тибү яисә теләсә кайсы мәсьәләдә буйсынмау аның өчен төшемле вазифадан колак кагу гына түгел, хәтта тормышыннан ваз кичү белән дә тәгәлләнергә мөмкин. Ә ул үзен шушы вазифадан башка күз алдына китерә алмый иде инде. Юкса, бик теләсәң, полковникка карата көненә бер генә түгел, өч җинаять эше кузгатып булыр иде.

Халат кесәсендәге алтын турындагы уй бер генә минутка да тынгы бирми башлады. Күпме җыя алды икән бу баҗай тиешле адәм актыгы, бәйдән ычкына башламаганмы?

Шалишь, тәңкәләреңнең иң соңгысына кадәр барыбер алырмын анысы... Өлкәдә алтын ул хәтле күп түгел, тагын бер көндәшкә түзеп торып булмас, дип уйлап куйды Кәтүк һәм кинәттән кәефе дә күтәрелде.

Кайнар душтан соң полковник хушбуйларын тәненә мул итеп сөртеп тә алгач ул ашханәгә килеп керде:

—Эчтә бүреләр улый! Кайда минем зур кашык, диләрме әле?

Әзер табын янында көтеп утырган Шәрәфәт кинәт кенә кулларын чәбәкләп куйды:

—Кара сана, нәкъ кытай мандарины булгансың, салынып төшкән нечкә мыегың гына юк, менә бу вазада нәкъ синең сыңарың димме, игезең димме сурәтләнгән бугай.

Аш бүлмәсенең почмагында борынгы ваза-кувшин булып, анда Кәтүк буйлы

елмаеп торучы кытай кешесе төшерелгән, ул да кырылган башлы, аждаһа сурәте ясалган кара атлас халаттан иде. Шәрәфәт бик нечкә зәвыклы, антиквар әйберләрне яхшы аңлаучылардан. Мәскәүдә укыганда да алар белән кызыксынуы кимемәде, киресенчә, белеме-мәгълүматы тагын да тулыланган иде.

Әнвәр Абидович бер тамчы судай үзенә охшаган сурәтле кувшинны кочаклап алды һәм рәсемгә төшәргә җыенгандай аның алдына килеп басты. Шәрәфәт күрше бүлмәгә йөгерде һәм "Полароид" фотоаппараты тотып керде, тиз генә аны сурәткә төшереп тә алды. Ниндидер бик борынгы рәссам ясаган портретның тач үзе булуыннан обком секретаре таң калды, фоторәсемне кулыннан төшермичә озак сокланып торды һәм "Ничек уйлыйсың, бу чыннан да, император микән?"—дип кат-кат сорады һәм җавабын да үзе бирде:

—Әйе, ошаган, үтә дә нык ошаган. Тик миңа "мандарин" дигән сүз ошамый, кытай богдыйханы, дөресрәге, кытай патшасы дисәк, шәбрәк булыр,—диде һәм алар икесе дә көлеп җибәрделәр.

—Эчәргә бер нәрсә дә куймадыңмы?—диде үзен кытай патшасының сыңары санаган кеше өстәлгә күз төшереп алганнан соң кырыс тавыш белән.

—Эшкә бармыйсыңмыни?—Шәрәфәт сөенечен яшереп калдыра алмады, хисе сүзләренә чыкты.

—Юк, алтын тәңкәм, бармыйм, синең янда кунарга калам, минем дә тугрылыклы подданныйларым кебек тугарылып алырга хакым юкмыни?—Әнвәр Абидович таралып бәйрәм итәргә җыена иде. Шәрәфәт моны бик тиз сизеп алды һәм сервант янына ашыкты, озакламый, кыйммәтле шешәләр тезелгән арбачыкны тәгәрәтеп китереп тә җиткерде. Тилләхаҗиев сирәк укый, укыганда да газетлардан ары китми, анысы да югары посттагы кеше укымый калырга тиеш булмаган язмалардан гына гыйбарәт иде. Әле Мәскәүдә академиядә укыганда аның кулына бер хикмәтле китап эләккән иде. Хәзер төгәл генә хәтерләми дә, әллә тәмле аш пешерү серләре турында идеме ул, әллә югары катлам кешеләренең тормыш рәвешен сурәтләгән роман идеме, шул китаптан укып белгән кадәресе күңеленә мәңгегә сеңеп калды да. Шуны сөйли, теләсә кайсы мәҗлестә шуны таләп итә торган булып китте. Әйтик, тозланган семга балыгына һәм, гомумән, балык янына ак шәраб куела, ит белән киек янына кызыл шәраб, ә кофе эчкәндә ликер белән коньяк муафыйкъ.

Бүген исә обком буфетында нәфис алсулыгы күзне иркәләп торган симез семга балыгы әзерләгәннәр икән, шунлыктан ашны аракы авыз итүдән башладылар. Рәвешен китереп эчеп куйгач, ашыкмый гына анысын-монысын капкаладылар, бары шуннан соң гына сүз үзеннән-үзе алтын тәңкәләргә таба тәгәрәмәсме дип уйлап, ул акрын гына сорап куйды:

—Ничек соң, Хәким бик рәнҗетмиме?

Беркайчан да бу хакта сораганы, кызыксынганы юк, аның өчен ниндидер Хәким дөньяда бармы-юкмы, барыбер кебек иде, һәм көтмәгәндә шундый кайгыртучанлык. Гап-гади кешеләрчә сорау Шәрәфәтне хәтта кыенсындырып куйды һәм ул чын күңелдән җавап бирде:

—Юк, рәнҗетми. Миңа калса, аңа бу эшен ташларга кирәк, юкса аның бик начар бетүе бар.

—Арттырма, ничек дисәң дә, ул миңа туган тиешле булып чыга, мин барында аның башыннан бер генә чәч бөртеге дә төшмәячәк.

—Мин ул хакта түгел,—дип үзенекен сукалады Шәрәфәт,—аны минемчә, берәр җүнлерәк психиатрга күрсәтергә кирәк, акча дигәнең белән акылыннан шаша бугай инде.

—Ничек инде ул алай?—дип кызыксынды кытай патшасы роленә тәмам кереп өлгергән Әнвәр Абидович. Аның күңелен кыбырсып торучы уе төенләнде, ымсындыручы алтын сере дә шунда ятмыймы?

Шәрәфәт исә бөтенләй башка нәрсәне күздә тота иде: аны, чыннан да, өйгә агылучы акча да, алтын да, аларның муллыгы да кызыксындырмый, иренең кыланышы җирәндерә һәм ул шунлыктан тормыштан аерылган, уйлап чыгарылган шигърият дөньясында яши, антиквариат белән мавыгуы да шуннан иде.

—Син беләсең, мин синең эшеңә дә, аныкына да катышмыйм, тәрбиям шундый, син үзең дә шуны хуплыйсың. Элегрәк аның эшкә ни тотып киткәнен, ни күтәреп кайтканын күрми дә идем, иң мөһиме—өс-башы чиста, пөхтә, тамагы тук булсын,

өйдә җайлы-уңайлы булсын. Хатын-кызның төп эше шул дип саный идем. Бер ике еллап булыр, көн саен диярлек өйгә йә портфель, йә "дипломат" тотып кайта, киткәндә куллары буш була. Ирем өстеннән шымчылык итәргә, эшенә тыкшынырга теләмәсәм дә күрми калып булмый. Дүрт йөзләп портфель, "дипломат" җыелгач шаярып кына "Инде безгә галантерея кибете ачарга да була",—дип әйткән идем, ничек сөенүен күрсәгез! Икенче көнне үк ул базардан бер кибет директорын ияртеп кайтты, сөенечемә, димме, бөтен нәрсәне алып та киттеләр, барлык почмакларны, диван асларын чистартып чыктылар. Ләкин барысы да элеккечә калды, көн саен ул берсеннән-берсе яңа, берсеннән-берсе модный "дипломат" яисә портфель тотып кайта. Баштарак мин аның эше шундый, мөһим документлар җыела торгандыр да, шуларны алып кайтадыр, дип уйлый идем. Бу фараз да туры килмәде. Андый шәп "дипломат"ларны әрәм-шәрәм итәргә дәүләт ул хәтле бай түгел лә. Шуның өстенә, әгәр ул портфельләр МВДныкы булса, алар бөтенесе бер иш булыр иде.

Соңрак мин боларны бүләк-мазар, дип уйлый башладым. "Дипломат", портфель дефицит бит. Ләкин ОБХСС башлыгына мең "дипломат" ник кирәк? Монысы инде бөтенләй башыма сыймый. Хатын-кыз кызыксынучанлыгы җиңде, гафу итә күр, кайтып тамак ялгап алгач, кабинетына бикләнеп сәгатьләр буе "дипломат" белән нишләп утыруын караштыра башладым. Кайчагында аны күтәп алып булмый, йә телевизор янында, йә зиннәтле йокы бүлмәсендә ялгызым йоклап калган чаклар да була.

Беләсеңме, ул өйгә акча алып кайта икән бит... Кич буе шуларны карап, ишен ишкә аерып, санап утыра. Майланып беткән берлекләр дә, кыштырдап торучы йөзлекләр дә була. Аларын аеруча ярата. Күргәнем бар. Көн саен шушы яшерен ләззәткә ничек бирелгәнлеген күрсәң икән! Нәрсәдер яза, боза, амбар кенәгәсенә терки. Төн буе нәрсә эшләп утырасың, дип сорасаң елмаеп кына куя: "Хезмәт буенча, кадерлем, болар дәүләт сере, синең ирең дәүләт кешесе, полковник",—ди. Башта хәтта кызык тоела иде, буш вакытларында ни белән шөгыльләнүен күз алдына китереп көлә идем, ул да бит синең шикелле таң белән чыгып китә, караңгы төшкәч кенә кайтып керә, аның өчен шимбә дә, якшәмбе дә юк.

"Дипломат" тотып кайтып кергән көнне син килеп чыксаң, ишекне ачык калдырып гыйшык-гашрәткә бирелсәк тә, ул берни күрмәс иде, акча дигәндә дөньясын оныта ул. Миңа шулай тоела.

Бер ел да үтмәде, өйдәге бөтен почмак, караңгы бүлмәләр, антресольләр, шкафлар тагын портфель, "дипломат" белән шыплап тулды, бусында алардан котылырга инде син ярдәм иттең...

Әнвәр Абидович үткән ел әтисенең җеназасында нинди шәп юл уйлап тапканын исенә төшерде. Күмешергә, мәетне соңгы юлга озатырга килгән кешеләргә кулъяулык, түбәтәй, сөлге яисә күлмәк бүләк итү гадәте бар. Үзендә һәм баҗасында саклanучы чапаннар, портфель һәм "дипломат"лар турында шул чагында исенә төште һәм ул борынгы ханнар шикелле юмартлык күрсәтергә карар кылды. Җеназага килгән һәр кешенең иңнәренә чапан салдылар, һәркайсына "дипломат" яисә портфель тоттырдылар. Табигый, чиннар искә алынды. Кемгәдер парчалы халат белән яшерен кодлы күн "дипломат" эләксә, кемгәдер бүләкнең гадирәге, очсызрагы туры килде. Хәер, обком секретаре белән ОБХСС башлыгына очсызлы әйбер бүләк итмиләр. Әле беркемнең дә мондый бай бүләк таратканы юк иде, аксакаллар әйткәнчә, хәтта Бохара әмире дә ул хәтле булдыра алмаган. Шулай итеп, аның юмартлыгы, әтисенә ихтирамы хакындагы сүз халык арасында бик озак йөрде.

Матәм көнне Тилләхаҗиевлар йортына килгән сигез йөз алтмыш кеше арасында, монысын җентекләп исәпкә алып барганнар иде, кемнәрнеңдер үзе кайчандыр бүләк иткән чапан яисә "дипломат"ны алган булуы да ихтимал.

Шунысын да әйтергә кирәк, күмәргә килүчеләргә бүләк тарату белән бергә, җеназага килгәндә кесәгә конверт кыстырып килү йоласы да бар; түрәләр өчен туй яисә кеше күмү чыгымнар китерми, киресенчә, ул көн ришвәт вә йолымны беркемнән шикләнмичә, ачыктан-ачык җыя торган көнгә әйләнә, курыкмыйча алып киләләр, тапшыралар. Йоласы шундый...

Әнвәр Абидович кайгы уртаклашуларны тыңлап, конвертларны алып торды, баҗасы шикелле аларны санап утыруга кадәр барып җитмәде җитүен, моның ише вак-төяккә аның вакыты юк иде, шулай да хатыны әйтеп куйды, ул көнне йөз мең сумлап акча кергән булып чыкты.

Шуннан соң кеше күмү чыгымлы дип әйтеп кара инде.

—Әлбәттә, серен белгәнемне ачмадым, бары тик минем белән ешрак булуын үтендем, китап укырга, бергәләп телевизор карарга кирәклеген әйттем, ул киреләнеп үзенекен тукый бирде, имеш, син минем өчен дә укы инде, минем эшләр муеннан янәсе. Шунысы сәер, бер еллап булыр инде, хәзер ул "дипломат" яисә портфель тотып кайтмый, әмма дә ләкин барыбер кабинетына бикләнә дә акча санарга тотына, әллә еллар буе җыйган өчлекләрен, берлекләрен алыштырып алды инде… Миңа калса, ул ычкына башлады бугай, яраткан акча номерларын бухгалтер кенәгәсенә язып барса да гаҗәпләнмим…

Менә шунда бөтенесе дә ачыкланды, димәк, баҗасы да аның шикелле үк алтынга күчкән һәм шунлыктан өйгә "дипломат" ташымый башлаган. Әбәт вакытында беркатлырак тоелган сорауны юкка бирмәгән ул. Теленнән исә бөтенләй башка сүзләр чыкты:

—Юкка борчыласың, кадерлем, аның эше чынлап та дәүләти әһәмияткә ия, авыр эш, синнән яшерене дә, серлесе дә булыр, аларны таратмаска имза куеп ант иткән кеше ул. Төннәрен акча санавы да гаҗәп түгел, эше шундый, төрле ертлачлардан, пычрак куллы бәндәләрдән күпме хезмәтсез табышны кайтарып алганнарын күз алдына да китерә алмыйсың. Күрәсең, идарәдә өлгерә алмый торгандыр, шунлыктан эше өйгә ияреп кайта, сездә уңайлы бит, беркем дә комачауламый. Ә "дипломат"лар, портфельләргә килсәк, монысы тәртип түгел, бөтенләй мәгънәсезлек. Мин аңа әйтермен. Мал-мөлкәтне, инвентарьны саклый белергә дә кирәк, син хаклы, кадерлем…

—Юк, мин күзләреннән күрәм, аны психиатрга күрсәтергә кирәк,—дип үзенекен сукалады Шәрәфәт.

Алга таба бу хакта сөйләшү кызыксындырмый иде инде, үзенә кирәкнең барысын да ачыклап өлгерде, сүзне туктатыр өчен ул ризалашкан сыман итте.

Һичшиксез психиатр катнашырга тиешле тагын бер, дөресрәге тагы ике очракны сөйләмәкче булган Шәрәфәт телен тешләп калды, сөйгәненең кәефен тәмам төшерүдән курыкты.

Шаккаткыч хәл иде бу. Бервакыт төнлә уянып китте һәм иренең йокы алдыннан дога укыганын ишетеп алды. Бу көнне дә ул таңга кадәр диярлек кабинетында акча санап утырган иде. Сәер дога булып чыкты ул. Хатыны янына ятар алдыннан ул гадәттә дога сүзләрен авыз эченнән генә мыгырдый һәм Шәрәфәт аны һәркемгә балачактан таныш изге сүзләр дип белеп, артык игътибар итми иде. Ә бу юлы дога сүзләре артык ачык итеп әйтелдеме, әллә игътибары көчлерәк идеме, ул барысын да ишетте.

—И кодрәтле Аллам,—дип пышылдый иде зиннәтле йокы бүлмәсендә ОБХСС башлыгы,—кул астымдагы бу тупракта кибетләр, складлар, базалар, кунак йортлары, кемпинглар, ашханәләр, кафе-ресторaннар, рүмөчнәйләр, сыраханәләр, базарлар, толкучкалар, техник хезмәт күрсәтү станцияләре ишәйсен! Алыпсатарлар, спекулянтлар, фарцовщиклар, валютчиклар, наркоманнар, теш техниклары, бурлар, караклар, фахишә-проституткалар, халык малын әрәм-шәрәм итүчеләр, рэкетирлар, сараннар вә комсызлар, намуссызлар, каруннар, пычрак куллы адәмнәр, ертлачлар һәм гастролерлар, маклерлар, ришвәтчеләр көннән-көн артсын! Комсызланып үз-үзләрен белештерми башласыннар, уяулыкларын югалтсыннар да минем кулга төшсеннәр, минем өчен таласыннар вә һәм дә урлашсыннар иде!

—И Аллаһым, минем белемәләремдә иң кыйммәтле проституткалар яшәсен вә тамыр җибәрсен, йөзәр мең тәңкәләр әйләнүче катраннар ачылсын, наркотиклар вә алтын сәүдәсе чәчәк атсын. Ачыкавыз туристлар килеп тулсын, кесә капшаучыларга һәм дә кооператорларга шатлык өстенә шатлык килсен. Рәхәтләнеп таласыннар, урлашсыннар, алдасыннар, акча кайтарып бирмәсеннәр, үлчәгәндә үз якларына "ялгышсыннар", товарны яшерсеннәр, итәк астыннан вә арткы ишектән сатсыннар. Яшәсен товарның кибүе һәм коруы-югалуы, шәрабка, сырага, сөткә вә каймакка су кушсыннар, колбасага җаннары ни тели, кәгазьме ул, кирза итекме, шуны өстәсеннәр, мин аларны барыбер ашамыйм. Электрон үлчәүләрне ватсыннар, герләрне игәп киметсеннәр, аракы белән келәмнән башлап мебельгә кадәр барлык төр сул товарлар белән сәүдә итсеннәр. Ювелир кибетләрендә алдашу чәчәк атсын, бриллиант урынына ялган пыяла сатсыннар, кибетләрдәге агалтынның яртысы көмешкә әйләнсен.

Кешеләр күбрәк төзесеннәр, фатирларын ремонтласыннар иде, и Ходаем, теләсә кайсы вакытта кереп, гәрчә бу кадакның стенада әле хан заманнарыннан ук тырпаеп торганын белгән хәлдә дә "Моны каян алдың, белешмәң кайда?" дип сорарлык булсын иде.

Җитмәүчелек көннән-көн артсын, барысы-барысы—трусиктан алып сабынга хәтле дефицит булсын! Дефицитны булдыра белүчеләр мәңге-мәңге үз урыннарында утырсыннар, караклар һәм ачкүзләр, шулай ук бер тиенгә ярамаслык товар чыгаручылар яшәсен, читтән әйбер кайтарту, бигрәк тә капиталистик илләрдән импорт дигәнең чәчәк атсын!..

Икенче тапкыр иренең шушылай укынуын Шәрәфәт бер ярты еллап вакыт узгач ишетте, һәм ни гаҗәп, ул аны бер генә ләһҗәсен дә ялгышмый сүзен-сүзгә кабатлады, күрәсең, болар аның чын догасына әйләнгән иде. Психиатр чакырмый кая барасың?!

ОБХСС башлыгы хакындагы сөйләшү табынның ямен җибәрә язды, көтмәгәндә ачылып китүенә үзен гаепле санап, Шәрәфәт Әнвәр Абидович хөрмәтенә чәчәклечуклы тост әйтергә булды; менә шунда инде ул кытай патшасын да, аның бер тамчы судай аңа охшаганлыгын да әйтергә онытмады. Дөрес, Шәрәфәт хакыйкатькә бераз гына хилафлык китерде китерүен, гөнаһы үзенә булсын, чөнки вазада сурәтләнгән кешенең кулында китап иде, вазаны кодалаган кешеләр—борынгы кытай фарфоры белгечләре—анда сарай шагыйре сурәтләнгәнен әйткәннәр иде. Рәсемдә кытай патшасы үзе дә бар иде барын, ләкин ул вазаның почмакка караган ягында булып, артык күзгә ташланмый иде. Әгәр аны борып күрсәтсәң, кытай патшасына охшашлык турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Бу исә сөйгәненең кәефен төшерәчәге шиксез, чөнки инде ул образга кереп алган, юк-юк та шул почмакка күз төшереп ала иде. Үзенең сарай шагыйренә охшаганлыгын белү аңа һич кенә шатлык китермәс, ә бәлки, бөтенләй кимсетер иде.

Ләкин сөйгәнен яхшы беләм дип санаучы Шәрәфәт нык ялгыша иде. Нәкъ менә бүген аның кәефе әйтеп бетергесез яхшы, чөнки баҗасының ел буе күпме алтын тәңкә җыеп өлгергәнен компьютердан да тизрәк санап чыгарган иде, иң тыйнак бәя белән генә дә баш әйләндергеч күп җыела иде алар. Көтмәгәндә күктән төшкән бәхеткә ничек куанмыйсың, ди. Ә инде Шәрәфәтнең көтмәгәндә психиатр турында сүз кузгатуы көткәннән дә артык. Болар бөтенесе дә бер кичтә, бер очрашуда бит әле. Хисләренә чыдаша алмаган Әнвәр Абидович сикереп торып Шәрәфәтне үбеп алды. Аның бу назлы кыйланышын Шәрәфәт үзенчә аңлады һәм күңелендә җылы дулкын күтәрелде, кыскасы, алар икесе дә бәхетле иде.

Шәрәфәт аны тагын бер матур тост белән сөендерде. Эш шунда, алар күрешми торган арада Наполеон Ташкентта докторлык диссертациясе яклап өлгергән иде. Моңынчы алар икесе бер чамада, икесе дә философия фәннәре кандидаты, икесе дә диссертацияләрен Мәскәүдә яклаганнар иде. Әнвәр Абидовичның яңа диссертациясен укып чыгарга да вакыты булмаганлыктан, җаваплы һәм четерекле бу эшне Шәрәфәткә тапшырган иде.

Диссертациядә бернинди ачыш-фәлән, яңалык булмаса да, нык профессионал кулы сизелеп тора иде, шулай да Шәрәфәт мәсьәләнең асылына кагылышлы берничә яңа фикер өстәде, тәкъдим кертте, бераз гына үзгәртә төште һәм материал бөтенләй яңача янгырый башлады, фикерләвендә мөстәкыйльлек чалымнары пәйда булды. Шуңа күрә ул докторлык диссертациясенә үзен автордаш дип тә саный һәм моның белән бик горурлана иде. Апасы белән сүзгә кергәнлектән, диссертация яклаган көнне Шәрәфәт Тилләхаҗиевларга тантанага бара алмаган иде, менә хәзер алар уңышлы яклауны яңадан, тагын бер кат билгеләп үтәләр шикелле килеп чыкты. Үзенең фәннәр докторы икәнен исенә төшерү обком секретаренең кәефен тагын да күтәреп җибәрде, алар икесе дә полковник хакындагы күңелсез сөйләшүне бөтенләй оныттылар. Мәҗлес ахырында, кайчандыр Мәскәүдә өйрәнгәнчә, кофе белән коньяк эчеп утырганда, ул шулхәтле хисләнеп китте ки, чын-чынлап әйтеп салды:

—Теләсәң, туган көненә сиңа да докторлык диссертациясенә заказ бирә алам, Абрам Ильич өлгерер дип беләм, башы шәп эшли аның...—диде.

Шәрәфәт чын күңелдән сөенде сөенүен, ләкин салкын акыллы булып кала белде:

—Хәзер үк килешмәс,—диде ул.—Сездән соң ук ярамас, әллә нәрсәләр сөйли башларлар. Бераз сабыр итик, бер-ике елдан соң бәлки...

Шулай хәл иттеләр дә.

Шәрәфәт өстәл җыештырган арада ул квартир буйлап йөреп алды, сөяркәсе зәвык

белән бөртекләп, табигый ки, аның ярдәме белән җыйган китаплар тезелгән киштәләр янында бөтерелде, ләкин берсен дә кулына алмады, китап тоту теләге юк иде. Зур экранлы "Шарп" телевизоры янында бер өем кассетаны күреп алды. Ялтыравык капларына караганда, аларны полковник әле күптән түгел генә кемнәндер конфискацияләгән булырга тиеш. Чөнки элегрәк аларда "Басф" кассеталары юк иде. Менә фильм карасаң ярый һәм ул телевизор белән видеомагнитофонны тоташтырып та куйды.

Өйдә балалар комачаулый, Хәлимә дә каршы, берничек тә порнографик фильм карый алмыйсың. Ә обком секретарен исә нәкъ шул фильмнар кызыксындыра да иде инде. Уйлап-уйлап та очына чыга алмый, баш вата, бу фильмнарда төшәргә Көнбатышта шул хәтле чибәр хатыннарны каян табып бетерәләр икән? Фильмнарны гадәттә алар Шәрәфәт белән икәүләп карыйлар һәм Кәтүк соклануына, дәртенә чыдый алмыйча, сөяркәсенең тәнен төя-төя кычкыра:

—Кара син бу себеркене, фән кандидаты да түгел, ә ниләр генә кыланмый, высший пилотаж бу, өйрән, өйрән!—дип кабатлый һәм кычкырып көлә башлый.

Аның мондый ачыктан-ачык әдәпсезлеге баштарак Шәрәфәтне уңайсызландыра иде, әмма тора-бара күнекте, күрми-сизми башлады. Өлкәдә һәм республикада хакимлеге үсүдән исергән Наполеон көннән-көн йөгәнсезрәк, тупасрак була бара, беркемнең фикеренә колак салмый, Шәрәфәтнең киңәшләрен дә санга сукмас булып китте. Хөрмәт иткән, табынган бер генә кешесе бар, әмма аның белән сирәгрәк күрешергә туры килә, һәм ул сөекле обком секретареның асыл йөзе турында берни дә сизенми иде булса кирәк.

Биш-алты кассетаны актарып чыкканнан соң ул, ниһаять, үзен кызыксындырган фильмны тапты, ләкин еш кына ирен кötә-кötә Шәрәфәт йоклап китә торган тирән велюр кәнәфине уңайсыз санап, телевизорны йокы бүлмәсенә, үзләре корвет дип атаган караватт янына тәгәрәтеп алып китте. Алар киноны урын өстенә ятып карый торганнар иде.

Аның дәртләнеп чакыруына колак салып, бер ун минуттан йокы бүлмәсенә Шәрәфәт килеп керде, әмма фильмны караудан баш тартты, чөнки ире белән бер өч тапкыр, ахирәт хатыны белән ике тапкыр караганы бар иде инде. Сәбәбе дә табылды, ул богдыйханны яхшылап сыйларга җыена, шунлыктан өй лагманы белән сарык кабыргасыннан сумса пешерергә кирәк икән. Тәмле тамак, ашарга ярата торган кеше буларак, Наполеонга бу фикер бик хуш килде. Сыйланырга икән сыйланырга. Әмма Шәрәфәтне кухняга теләмичә генә җибәрде.

Ун минут та үтмәде, ул телевизорны сүндерде, янында чибәр хатын булмаганда секс фильм карау кызык түгел, дәрт кузгалмый икән. Шуның өстенә әллә каян гына Күпер Булат турындагы уйлары калкып чыкты, аларны читкә куарга теләсә дә, котыла алмады. Хәер, уйлар аның турында ук түгел, аны күбрәк Әкмал Арипов кызыккан Абрек кушаматлы ахалтекин айгыры борчый иде. Әлбәттә, Аксай ханы Мәхмүтовка йөз мең доллар чыгарып та сала алган булыр иде, контрабанда валютасы җитәрлек, алтын тәңкәләр дә бирә алыр иде, ләкин Мәхмүтов дәүләт казнасына керәсе акчалар турында уйлый, яшел доллар белән Микулай патша акчалары аңа бар ни дә, юк ни. Юкса, Сәет Алимханның бакчачы Хәмракол саклап яткан хәзинәсен күптән кулга төшергән булыр иде.

Ул айгыр—айгыр гына түгел, чистый Алланың кашка тәкәсе булды, нәкъ шул ат Аксай ханы белән мөнәсәбәтләрнең өзелүенә китерергә мөмкин. Әллә ничә тапкыр читләтеп аңлатырга тырышты лабаса, имеш Абрек синең биләмәләреңдә, димәк ки, көч куллан, Күпер Булатны гына буйсындырыр хәлең юкмы.

Әкмал Арипов белән ачуланышасы килми, икесе дә бер мичәүдә, Югарының ышанычлы кешеләре булганлыктан гына да түгел. Сәбәпләре байтак аның. Арипов баш әйләнгеч тизлектә көчәйгәннән-көчәя бара, кайбер мәсьәләләрдә "Әти"гә аңа караганда да зуррак йогынты ясый. Юкса, агропромышленность берләшмәсе җитәкчесе иң зур өлкәнең обком секретаре белән янәшә куярлык түгел кебек, әмма барысы да киресенчә иде шул. Ә инде акча мәсьәләсендә Әкмал хан белән ярышу бөтенләй мәгънәсезлек булыр иде.

—Мин—Крез, ә син—хәерче,—дигән иде бервакыт салып утырганда Аксай ханы. Салмыш баштан әйтелсә дә, бу сүзләр Наполеонның бәгыренә кадалды һәм ул тырышып-тырмашып алтын җыярга тотынды. Бүген очраклы рәвештә кулга төшкән

Сәет Алимхан казнасының калдыкларына баҗасы җыеп өлгергән алтыннарны да кушып карады, инде үзеңне хәерче дип санамаска да була, әмма да ләкин, аңа Аксай Крезы белән бил алышырга иртәрәк иде әле.

Аксай ханыннан бер Әнвәр Абидович кына шүрләми, хәтта "Әти" үзе дә аның һаман үсүче йогынтысыннан, бетмәс-төкәнмәс мин-минлегеннән шикләнә башлаган иде, Әкмал ханны күзәтебрәк торырга кирәк дигән фикерне дә ул әйткән иде. Әгәр Әкмал хан партия эшендә булса, "Әти" аны үз янында, Ташкентта тотар иде, йә булмаса берәр мөселман иленә илче итеп җибәрер иде; үз янында көндәш яисә көчлерәк кеше барлыкка килүен сизенүгә ул һәрчак шулай итә, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителә, аларга күз-колак булу җиңелрәк, ә хәзерге хәлдә Арипов тормышында нәрсә дә булса үзгәртергә соң иде инде. Ул республикада үз ханлыгын булдырды, монда хәтта "дәүләт эчендәге дәүләт" дигән сүзләр дә туры килеп бетми. Аны күзәтү мөмкинлеге юк, Аксайга килүче һәм китүче юлларны тоташы белән буып куйды, көнен дә, төнен дә каравыл каланчаларында башларына милиция фуражкасы кигән сакчылар тора. Менә шунлыктан аның белән дуслыкны югалтырга ярамый, Аксайга илтүче бердәнбер юл ябылырга мөмкин, менә шуннан соң аның нәрсә эшләргә җыенуын белеп кара инде, сиңа каршымы, әллә хәтта "Әти"нең үзенә карата бер-бер этлек ясарга җыенып ятмыймы? Никадәр генә хәйләкәр һәм мәкерле булмасын, табын янында төшереп алгач, ул да пар чыгара һәм кайбер нәрсәләрне ычкындыра иде. Колак сала һәм сүзне оста алып бара белергә генә кирәк.

Юк, аңа чиста токымлы атлар яратучы белән берничек тә сүзгә керергә ярамый, гәрчә бөтенесе дә шул кире беткән Мәхмүтовка барып терәлсә дә, ул аңа теләсә кемгә боерган кебек, атыңны Әкмалга бир дә, тавыш-тыныңны чыгарма дип әйтә алмый иде. Кайбер кемсәләргә тел кыймылдату да кирәк булмас иде, сиздер генә, атын үзе үк Аксайга илтеп бирер, Арипов белән бер табын янында утыруны дәрәҗә санар иде әле. Күпер Булатның ни әйтәсе алдан ук билгеле, ат заводы дигән сылтау табар, дәүләт мәнфәгатьләрен искә төшерер, ул гынамы, байның нәфесен нигә авызлыкламыйсыз, партия алай кушмый дип тә җибәрер. Бәлки аны шуның өчен ярата да торганнардыр? Ни генә эшләсәң дә, бер генә юл кала: Мәхмүтовны сындырырга, куркытырга, Заркент сараена хезмәт иттерергә кирәк, шунда гына айгыр мәсьәләсе дә үзеннән-үзе хәл ителер.

Аның тормышы белән айгыр тормышын тигезләргә, араларына тигезлек билгесе куярга! Кинәт кенә башына килгән шушы усал һәм явыз уйдан ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде, үзенең үткен акылына сокланып туймады. Аның көлгәнс хәтта кухняга барып ишетелде һәм сумса пешерергә суган чистартып йөрүче Шәрәфәт кытай патшасына охшарга омтылучы кешенең кәефе күтәренке булганга сөенеп куйды.

Әйе, болгавыр заманнар килеп житте, дип уйлануын дәвам иттерде обком секретаре, түрәләр кесәләренә агылучы җүләр акчадан исерде, баш бирмәскә маташалар. Хәтта Югарыдагы абзый үзе да күпме мамыкны өстәп язганнарын белмидер, тикшерерсең бар, барысы да сабырсызланып көзне—дәүләт казнасыннан акча агыла башлаячак чакны көтә, көрәп кенә өлгер. Халык та тик ятмый, ризасызлар артканнан-арта, беренче кар төшкәнче халыкны кырда тоту, мәктәп һәм балачак дигән төшенчәне онытып баручы сабыйлар, өлкәннәрне дә, нарасыйларны да кырып килүче сары чире, тирәлекне агулаган бутифос, рәнҗетелгән, үзләрен һәм балаларын алда ни көткәнен белмәгән һәм шунлыктан үзләренә кул салучы, үз-үзләрен тереләй яндыручы яшь хатыннар турында Мәскәүгә бәйнә-бәйнә язып торалар. Кышлакларда көзге туйлар башланган көннәрдә коточкыч тере факеллар дөрли башлый, ләкин, Аллага шөкер, ул хатлар "Үзегез тикшерегез" дигән тамга сугылып Ташкентка әйләнеп кайталар. Һәм тикшерәләр дә, баш бирмәсләрне, телен тыймасларны камчы белән ярырга да күп сорап тормыйлар, моннан кире өстән жалу белән йөрмәсләр. Кояшлы яклардагы бәхетле тормыш хакында зарланып йөрмәскә сабак булыр.

Кәтүкнең чынлап торып ачуы кузгалды, дусты—Аксай ханы өстеннән шикаять белән йөрүләре генә җитмәгән, Мәскәүгә чаклы чапкын җибәргәннәр. Дөрес, Ташкенттан, Үзәк Комитеттан комиссия җибәртүгә ирештеләр ирешүен. Шуннан да югары сикерә алмадылар. Ариповның көч-куәтен, миллионнарының мөмкинлекләрен беләләрмени алар. Шикаятьне тикшерүгә җитдирәк кыяфәт бирү өчен комиссиягә Үзәк Комитет кешеләре белән бергә республика Югары Советыннан да вәкилләр кертелде, аны депутат Бузрук Бекхуҗаев җитәкләде. Нәкъ менә ул соңгы нәтиҗәне

чыгарды да инде. Бөтенесен дә ялган һәм яла ягу дип таптылар. Комиссия фикеренчә, Социалистик Хезмәт Каһарманы, Югары Совет депутаты Әкмал Ариповтан да яхшырак хан, ягъни мәсәлән, председатель юк та һәм булырга да мөмкин түгел икән. Бөтен илгә данлыклы шундый кеше кул астында эшләү бәхете тәтегәнгә халыкка куанырга вә һәм дә сөенергә генә кала. Аксай ханына шушындый карар чыгарту җинелләрдән булмады анысы. Караны ак, акны кара дип күрсәтү өчен республика прокуратурасының сатлык тикшерүчеләренә байтак маңгай тире түгәргә туры килде.

Хөкүмәт комиссиясенең мондый карар чыгаруын ишеткәч дехканнардан берсе "Карга карганың күзен чукымый",—дип куйган булган. Табигый ки, бу сүзләрне Әкмал ханга җиткерми калмаганнар, анысы шул ук төнне үз куллары белән дехканның телен кисеп алган. Хөрмәтле кешеләрне моннан кире үләксә белән туенучы кошка тиңләрлек булмасын, дигән.

Юк, халык бик борчымый Кәтүкне. Ул түзәргә өйрәнгән инде, киләчәктә дә түзәчәк, баш күтәрә калсалар, аның кулында никадәрле көч! Һәр эшләүчегә ике милиционер туры килә... Аның җанын икенче бер нәрсә кимерә, мамыктан кергән миллионнарны имеп симергән һәркем юрганны үз ягына тарта, үзен акыл иясе, олы кеше дип исәпли башлый. Әнә Әкмалны гына ал... Элеккеге трактор бригадасы хисапчысы, шыр надан кемсәне элек кем белә иде, ә хәзер министрлар, обком секретарьлары аның аягы астында ауный.

Кара Түбә обком секретарен кара, үзен әллә кемгә куеп, Ташкенттан рөхсәт тә сорап тормыйча, Кара Түбәдән Мәскәүгә, Ленинградка авиарейслар ачып җибәргән. Халыкка уңайлы булсын өчен, дип уйласагыз, нык ялгышасыз, болар барысы да Беренчегә "Без дә төшеп калганнардан түгел" дип әйтү өчен. Авыр самолетлар кабул итәрлек беренче класслы аэропортны ике елда төзеп кара әле! Соңгы очрашуларның берсендә "Әти" моңсу гына "Мондый мин-минлек яхшыга илтми", дип куйган иде. Акыллы кеше, төпле сәясмән фикере белән Кәтүк тулысынча килеште. Кайчандыр аңа тугрылыкка Коръән тотып ант иткән өчен генә дә түгел, ул аңа чыннан да чын күңелдән һәм барлык вөҗүден багышлап хезмәт итә иде.

Кара Түбәнең партия әйдаманы үзен шулхәтле көчле адәм итеп сизә икән ки, хәтта зур бер эшчеләр коллективы алдында чыгыш ясаганда болай дигән имеш: "Мин сезнең киләсе елга социалистик йөкләмәләрегезне алдым, анда сез обкомга мөрәҗәгать иткәндә мине "безнең Ленин" дип атагансыз. Тыйнак түгел бу, иптәшләр, партиячә түгел, дөрес, хезмәт массалары белән эшләвемне шулай бәяләвегез мине чиксез горурландыра". Болар да Югары агайның колагына килеп ирешкән иде. Обком секретареның бу сүзләре көчле алкышларга күмелгән дип тә сөйлиләр. Табигый ки, үрнәкне коммунистлар үзләре биргән. Сизмәмешкә салышып кына халык теленә кертеп җибәрелгән "безнең Ленин" сүзе үзе дә Беренчегә үч итеп эшләнгән, аны алдый алмассың.

Дөресен генә әйткәндә, Наполеонга хезмәттәшләре арасында ыгы-зыгы кирәк түгел, киресенчә, бердәмлек, татулык файдалырак, чөнки аның максаты—"Әти"нең хакимиятен ныгыту, моның өчен кайчакта "Басмачы" дип йөртелүче Әкмал Арипов белән дуслык та ярап тора. Аксай ханын Кара Түбә секретаре белән талаштыра алсаң, "Әти" сөенми калмас иде дип тә уйлап куйды Кәтүк. Ләкин моңа өмет юк дәрәҗәсендә, хыял гына булып кала. Дөрес, Ариповны Мәскәүдән килгән комиссия кулы белән юк итеп була иде булуын, әмма Бекхуҗаевның нәселле атлар яратучыны ни өчен һәлакәттән саклап, яклап калуы аңлашылып бетми. Бу нинди гамәл, Беренчегә үч итеп эшләнгәнме, әллә киресенчә, аның үтенече буенчамы?

Бәлки, тылсымчыга тиң эшмәкәр, аның "җиде кат рентабельлеккә" ирешкән хуҗалыгы турында татлы ялганны юкка чыгаруның Шәрекъ көзгесе булган, бар нәрсә гөлбакчага һәм хуш искә күмелгән, һәр кешесе туйганчы пылау ашап, Әндиҗан полькасын биеп рәхәттә яшәгән Республика турындагы мифка да зыян китерәчәген аңлаганнардыр?

Бәлки Ташкент вә Мәскәүнең һәркайда ярылып яткан башбаштаклыкны, колбиләүчелекне күрмичә, азау ярган деспотның ялган казанышларына мәдхия җырлаучы танылган язучыларын, журналистларын җәлләгәннәрдер, юкса боларны күрер өчен бай табын янынан торып Аксайның беренче очраган тыкрыгына гына борылырга кирәк иде...

Бәлки "Әти" үзе дә шөлли башлагандыр, картайды бит инде, кайчагында хезмәтләреннән файдаланган булса да, Әкмал нукерларыннан курыкмаслык түгел.

Болары барысы да тик фаразлар гына, чынбарлык исә барыбер табышмак булып, сер булып кала бирә. "Әти"нең үзеннән бу хакта турыдан-туры сорап булмый.

Әгәр минем кулымда булса, ике дә уйлап тормыйча Ариповны Мәскәү кулы белән тар-мар иткән булыр идем, дип уйлый ул. Аның шикелле кешеләр моннан алтмыш еллар элек, басмачылар хәрәкәте вакытында, Җунаид хан белән Курширмәт курбаши халыкны кан калтырап торган заманнарда кирәк иде. Хәзер башка замана, башка ысуллар...

Шул арада кайберәүләр өчен бөтенләй яңа мөмкинлекләр ачылды, республикага Леонид Ильичның кияве, МВД генералы юл сапты. Булсын даладагы Кара Түбәдә, булсын зыялы Бохарада, булсын изге Хорезмда, булсын теләсә кайсы өлкәдә—һәркайда генералны патшадай күреп кабул иттеләр. Ничек шулай булмасын, Ташкентта аны чит ил делегациясе башлыгын кабул иткәндәй, иң югары рангта, барлык дипломатик хөрмәт билгеләре белән каршылыйлар, хәрби парад та, пионерлар котлавы да—берсе дә калмый. Халыкны урамнарга меңәрләп куып чыгаралар, Үзәк Комитетның тантаналы утырышын "кияү" килгән көнгә туры китереп, залда һәм президиумда күренүен аягүрә басып каршы алалар, кул чаба-чаба күпләрнең куллары суелып бетә. Һәрбер өлкә хуҗасы бүгенге һәм киләчәктәге мәнфәгатьләре хакына аның белән дуслашып калырга тырыша, кем белә, бәлки, аның аркылы Мәскәүнең үзенә туры юл салып булмасмы дип өметләнә.

Ул чакта Кәтүк җайлы моментны ычкындырды, яшь хатыны белән килгән генералны Кара Түбәдәгедән кимрәк кунак итмәсә дә, ачыктан-ачык дуслык тәкъдим итеп маташмады, үзен эре һәм бәйсез тотты, шуның белән кунакны гаҗәпләндерде дә бугай. Генералны ул баҗасы Нурматов шикеллерәк итеп күз алдына китерә, үтә файдалы рәвештә өйләнеп алган, йонлы кулдан файдалана белүче шома егет дип уйлый, аның вакыты үтәчәгенә шикләнми һәм бабасы түрдә утырганда гына власть башында булачагын аңлый иде. Мәскәүдә үзенең дуслары җитәрлек, академиядә бергә укыган иптәшләре текә генә күтәрелеп киттеләр. "Әти"нең киңәшләре һәм ярдәме ярап куйды. Сабакташларының киләчәге өметле, алар республикада кемнең кем икәнен яхшы чамалыйлар, кемгә таянырга икәнен беләләр. Җае гына чыксын. Ә инде кияү балакай хет генерал-полковник булсын, министрның беренче урынбасары исәпләнсен, барыбер артык ышанычсыз тоела, җитди түгел кебек иде...

Леонид Ильичның кияве килеп киткән саен республикада кадрлар алышына башлый, кемнедер алалар, кемнедер куялар, мөһим урыннарга үз кешеләр үрмәли, хәтта Югары агайның иске аркадашы эчке эшләр министрын да икенчелрәк урынга кысып төшерделәр.

Бәлки "Әти" аларга үч итеп Әкмал ханны үстергәндер дә, шуңа күрә аны Мәскәүгә йотарга ирек бирмәгәндер? Көтелмәгән бу уйдан хәтта сискәнеп куйды. Барысын да алдан күрә белүче кеше буларак, "Әти" мондый мөмкинлекне дә күздә тоткандыр, әлбәттә, МВД өчен ул нукта да, йөгән дә була ала. Юкса, аларның кулы артык озынаеп китте түгелме?

Юк, ул фетнә күтәрергә азапланучыларны якларга тиеш түгел, каратүбәлеләр, бохаралылар, җизаклылар һәм теләсә кайда сүзләре үтүчән ташкентлылар кебек юрганны вакытыннан элек үзеңә таба тартырга ярамый. Әкмал Арипов үрнәге дә аңа килешеп бетмәс. Аксай ханы өлкә, хәтта иң көчле ыру һәм якташлык вәкиле дә түгел, ул мин-минлеге белән көчле, ул барыннан да элек үзен алга этәрә. Нәсел җебе белән кызыксынучыларга "мин Аксак Тимер төбеннән" дип кенә җибәрә, властька, кодрәт иясе булырга, байлыкка омтылу шуннан, кан исе аны куркытмый, киресенчә, тагын да дәртләндерә генә.

Барысын да яңадан "Әти кул астына тупларга кирәк, киткәндә үзенең варисын билгеләп китәрлек булсын, шулай гаделрәк булачак, һәркемнең өмете бар лабаса! Шулай булганда ул үзенең мөмкинлекләре күбрәк һәм өстенрәк икәнлеген чамалый иде. Ул укымышлырак, белемлерәк, нәсел тамырлары тирәнрәк, Мәскәүдә укыган, башкала белән ныклы элемтәләре бар, фәннәр докторы... Һәм барыннан да элек рухы белән "Әти"гә якынрак. Моңа ул бер кәррә дә шикләнми иде.

Катлаулы, берсеннән-берсе мөһим уйлар җанга тынгы бирми, карап бетерә алмаган секс-фильмны да, Шәрәфәтне дә, махсус әзерләнүче кичке ашны да, хәтта баҗасының алтыннарын да онытып җибәрде, нәкъ менә аның караватында җәелеп ятуы исә башына да кереп чыкмады. Чөнки күз алдына әллә каян гына тагын Булат Мөэминович килеп басты. Аны нишләтергә инде, дип сабырсызланып уйлап куйды ул. Аның абруен, халык арасындагы исемен нишләп үз максатларымда файдаланмыйм соң әле

дигән уй калкып чыкты. Мәсәлән, Мәхмүтовны "Әти"гә тәкъдим итеп була ич, ул исә караклыкка һәм намуссызлыкка кереп батмаган кешегә урын таба белер, кайчагында андый кешеләр дә кирәк була.

Мәскәүдәге даими вәкиллек бинасында узган кышкы озын кич исенә төште. Аспирантураны тәмамлап өйгә ашкынган бер мәлне Югары агай белән бик тә күңелле итеп, бик озак гәпләшеп утырганнар иде алар.

Нинди уңайдан икәнлеге хәзер инде анык кына исендә дә калмаган, шундыйрак фикерне "Әти" дә әйткән иде бугай һәм менә шул фикер хәзер нәкъ вакытында искә төште һәм Булат Мөэминовичны төрмәдән саклап калды да бугай.

"Урыслар аристократларын инкыйлаб чорында юкка чыгардылар, гражданнар сугышында кырдылар,—дигән иде ул йомшак бәрхет сыман тавышы белән,—анысыннан да, монысыннан да исән калганнарны төрмәләрдә, лагерьларда черттеләр, йә булмаса чит илләргә чыгып китәргә мәҗбүр иттеләр, алардан калган балаларның ике буынына белем юлын яптылар. Без аларның тәҗрибәсен искә алырга һәм үзебезнең аксөякләргә, зыялыларга мәрхәмәтле булырга тиешбез".

Мәхмүтовны төрмәгә илтеп тыксаң, остазның киңәшен тотмаган, аның ихтыярын бозган булып чыгасың түгелме соң? Шуның өстенә, әгәр дә ул Мәхмүтовның әтисе аксөякләрдән икәнлеген, утыз бишенче елда атып үтерелгәнлеген, шулай итеп гаиләнең, тулы бер ыруның юкка чыгарылуын, ярты гасыр үткәч шундый ук тарихның яңадан кабатлануын да ишетсә, ачуының чиге булмас. Әйе, бигрәкләр дә ямьсез килеп чыгасы икән шул. Моның өчен "Әти" баштан сыйпамас.

Башка берәр нәрсә уйлап табарга кирәк булыр, дип фикер йөртте ул, һәм шулай итеп, якын көннәрдә Булат Мөэминовичка каршы җинаять эше кузгату дигән мәсьәлә көн тәртибеннән төшеп калды. Аннан соң нәрсә буласы да ачык түгел, чөнки Наполеонның кәеф дигән нәрсәсе артык тиз үзгәрүчән иде.

Бүген аның бары тик җанга якын күңелле хәлләр турында гына уйлыйсы килә иде. Мәхмүтов белән озакка сузылган авыр сөйләшү артыгы белән җиткән, бөтен көннең ямен җибәрде, тәмам чыгырдан чыгарды, каһәр суккыры...

Шул чакта кухнядан Шәрәфәтнең җырлап җибәргәне ишетелде. Аның тавышы күңелгә хозурлык бирә торган матур яңгырашлы, саф һәм чиста иде. Апасыныкы да шулай. Бу сыйфат гомумән Касыймовлар нәселенә хас. Тирә-якта моны белмәгән кеше юк. Димәк, бүген Шәрәфәтнең кәефе әйбәт. Кунарга калып яхшы иттем ахрысы, дип уйлап куйды Кәтүк. Кырык якта кырылып яткан эш дигәнең барыбер бетмәс ул. Ял итә белергә дә кирәк. Күңеле тагын йомшарып китте. Тискәре вә үҗәт Күпер Булат белән сүз көрәштерүгә дә карамастан, көн бүген искиткеч матур иде.

Эх, "Әти" мине үзенең варисы итеп билгеләсә иде, дип тагын татлы хыялларга чумды ул. Беренче эшем итеп картаны кисеп турар идем, өлкәләр санын кыскартырга кирәк булыр, дүрт-биш булса артыгы белән җиткән. Генерал-губернатор Кауфман берүзе идарә иткән бит әле, хәзерге элемтә чаралары да, юллары да, автотранспорты да, авиациясе дә булмаган, барлы-юклы бер кәнсәләрия барысына өлгергән. Бохара әмире Сәет Алимханны гына алып кара. Ярдәмчеләре бармак белән санарлык кына. Җитмәсә, нинди тугрылыклы булганнар. Аның казнасыннан калган хәзинәне нәфесенне сузмыйча ярты гасырдан артык саклап кара әле. Шундыйларны җыйсам, мәгънәсе күбрәк булыр, көндәшләр дә кими төшәр. Ә инде Коръән тотып тугрылыкка ант итәрлек биш-алты кешене барыбер табармын мин. Ник тапмаска!

Сәет Алимхан кәнсәләриясе исенә төшүгә уйлары әмир казнасы калдыкларына күчте. Тугрылыклы яраннары хан алтынын алып килгән көнне искә алырга да күңелле иде шул. Яшьтән хан сараенда үскән ниндидер Хәмрәкол дигән кеше саклап яткан икән ул алтынны. Әмир алтыны турындагы хәбәргә ышанырлык түгел иде, шунлыктан ул Хәмрәкол әкәне кичекмәстән алып килергә әмер бирде һәм аны өч сәгать үтүгә Күпер Булат районыннан китереп тә җиткерделәр. Өлкә комитетында киңәшмә барган чак иде, барысы хакында да хәбәрдар Йосыф сәер йөкнең килеп җитүе хакында белгертте. Киңәшмәне ашыгыч рәвештә туктатырга, эш күплекне сылтау итеп, барысын да озатырга туры килде. Ул гына да түгел, ярдәмчесенә ул сәркәтипне кайтарып җибәрергә, ишекләрне бикләргә кушты. Ял бүлмәсендә хатын-кызлар белән "шаяргалаганда" да болай кыланмый иде.

Күз алдында алтын, коточкыч күп алтын пәйда булуга ул игътибар һәм итагать белән каршы алырга җыенган карт турында бөтенләй онытты, аны озатырга ашыкты.

Тыңлавы да ярым-йорты гына булып, бер колактан керде, икенчесеннән чыкты, ул берни дә хәтерләми иде. Соңыннан Йосыф барысын да бәйнә-бәйнә бөртекләп, җентекләп сөйләп бирде. Ул чакта барлык уй-теләге алтын белән бәйле, тизрәк алтын белән япа-ялгызы каласы килә иде. Баштарак, алтын ялтыравыннан күзләре томаланмаган чакта, ул Хәмрәкол әкәне юмарт бүләкләрмен, ике-өч йөз тәңкә акча бирермен дип уйлаган иде, хәтта хисләренә тыела алмыйча акча янчыгына да тыгылган иде, әмма иң соңгы мизгелдә барысыннан да ваз кичте һәм Йосыфка аксакалның тамагын яхшылап туйдырырга, аны шәхсән үзенә илтеп куярга кушты, шулай итеп, бу кичкә ярдәмчесеннән дә котылды.

Ялгызы калгач, капчыкны идәндәге келәмгә бушатты һәм телсез калды. Баш әйләндергеч матур, искиткеч манзара иде бу. Кабинет хуҗасының моны беркемнең дә күрә алмавына хәтта эче пошып куйды, чөнки аның алдында дөньядагы иң гүзәл композиция—күз явын алырлык кызыл келәмдә саф алтын өелеп ята иде. Рубенс, Гойя, Модильяни, Рафаэль, Тициан, "Мона Лиза", "Джоконда", "Тугызынчы вал", "Нарат урманында таң ату", реализм, кубизм, модернизм, импрессионизм кебек нәрсәләрең чүп! Менә кайда ул чын импрессионизм, реализм, поп-арт. Болар күзне генә иркәләп калмый, җанны җылыта, назлый, кочагына чакыра. Алтын үзе дөньядагы иң югары, иң камил сәнгать ул!

Дөньядагы иң гүзәл шедеврлар да аның җанын, бәгырен черегән күн белән эчләнгән шушы иске капчыктан коелган нәрсәләргә караганда көчлерәк дулкынландыра алмас иде.

Йә Хода! Бу манзара шулкадәрле көчле тәэсир итә иде ки, аяклары аның ихтыярыннан башка бию хәрәкәтләрен сорый башлады һәм ул кызыл келәм өстендә тау булып ялтырап яткан алтын тәңкәләр һәм зәркәнле зиннәтләр өеме янында котырып бии башлады. Аның әле беркайчан да, бер генә туйда да бу кадәр дәртләнеп, үз-үзен онытып биегәне юк иде. Ул тәмам хәле беткәнче биюдән туктый алмады, ә инде буыннары арып хәлсезләнгәч, алтын өеме өстенә ауды һәм аны кочагына шудырырга тотынды. "Болар минеке, минеке!" дип тамагын киереп кычкырасы килде, әмма авыз ачылмый, ул биюдән тәмам хәлдән язган иде.

Ул кичне Кәтүк бик озак эштән китә алмый утырды. Дөрес, бернәрсә дә эшләмәде эшләвен, әмма алтын янында ятудан, аны бер җирдән икенче җиргә күчереп куюдан да татлырак, рәхәтрәк нәрсә юк иде, тәңкәләрдән манаралар ясап карады, келәм уртасында юллар тезде, шушы матурлыкка сокланып туя алмады, бу кадәр зиннәтне һич кенә дә капчыкка кире тутырып сейфка яшерәсе килми иде. Төннәр буе акча санап утыручы баҗасы Нурматовны да шунда гына аңлый башлады—бу бик сирәкләргә эләгә торган татлы ләззәт, җан рәхәте икән.

Еракта калган ләззәтле кичне ул шулкадәр ачык итеп күз алдына китерде ки, хәтта колагында бер учыннан икенчесенә коелучы алтын тәңкәләрнең чыңы ишетелгәндәй булды. Аһ алтын чыңы! Дөньяда аннан да гүзәлрәк бүтән бер чың бар микән? Ул хәтта тирә-юньдәге башка тавышларны ишетмәс өчен күзләрен йомды, колагында алтын чыңыннан башка бер авазга да урын булырга тиеш түгел иде. Шушы халәтендә йоклап киткәнен дә сизми калды.

Аккош мамыгы тутырылган кытай мендәрләрендә елмаеп төш күреп ятучы кешенең колагында алтын чыңы яңгырый, күз алдында берсеннән-берсе сәер күренешләр алышына башлады. Имеш, менә ул обкомдагы ял бүлмәсеннән эш кабинетына чыгып килә, өстендә полковник Нурматов гардеробыннан алынган алтынлы, укалы халат, билендә ефәк билбау, күкрәгендә өч Ленин ордены янәшәсендә Шәрәфәт шаяртып Гертруда дип йөри торган Социалистик Хезмәт Героеның өч алтын йолдызы. Алар янында депутат значогы. Монысы инде теләсә нинди Гертрудалардан да югарырак бәяләнә, чөнки тормышның болгавыр баткакларыннан бары тик ул гына коткара ала да, шуңа күрә аны калкавыч дип атыйлар да. Андый асыл шәһадәтнамәне бер генә илдә дә, бер генә сенаторда яисә конгрессменда да таба алмассың, шул бик иске, кадими заманнарда казынсаң гына инде. Бу инде чын-чынлап кытай патшасының саклагыч бөтие—пайцзасы!

"Исәнмесез, мин сезнең яңа патшагыз",—ди ул һәм бюрога җыелганнар алдында түбәнчелек белән баш ия.

"Долой!—залда күк күкримени.—Безгә богдыйханнар, мандариннар кирәкми! Яшәсен конституцион иреклəр!"

Әнвәр Абидович ОБХСС башлыгының зиннәтле халатына күз төшерә һәм киемсалымы белән нәрсәдер бутаганын аңлап ала, тынлыктан файдаланып залга кычкыра:

—“Иптәшләр, борчылмагыз, мин хәзер”,—ди һәм күз ачып йомганчы ял бүлмәсенә кереп югала.

Бу юлы инде ул өстенә парчалы халат киеп, башына кардан да аграк чалма чорнап килеп чыга. Маңгаенда исә “Төн хакиме” дип язылган, моңа кадәр әле беркем дә күрмәгән, каратларын санап бетергесез күләмдәге алмаз балкый имеш.

“Бүгеннән башлап мин Заркент өлкәсен Заркент әмирлеге дип үзгәртергә булдым һәм мине хәзер “бөегебез”, “сез галиҗәнаб” дип йөртүегезне сорыйм...”

Кабинетта тагын коточкыч тавыш куба, мондыйны аның әле бер генә бюро утырышында да күргәне юк иде.

“Бетсен самодержавие! Безгә ханзадәләр кирәкми! Азатлык! Демократия! Коры закон!”

Кәтүкне залдан җил күтәреп алып киттемени, әмма залдагылар тынычланырга да өлгермәде, ул партиядәш иптәшләре алдында яңа кыяфәттә пәйда булды.

Яшькелт-кызыл төстәге мундир белән ак панталон кияр өчен бераз уңайсызрак иде, җитмәсә, ботфорт кунычлы итек тә кыса кебек, әмма ул өчпочмакны хәтерләтүче баш киемен төшеп китмәсен өчен кырыеннан тотып (ни дисәң дә, күбрәк түбәтәй кияргә күнеккән кеше), каты адымнар белән якын һәм газиз тоелучы өстәле янына атлады һәм әмер биргәндәй тавыш белән кычкырып җибәрде:

“Заркент өлкә комитеты бюросын ачык дип белдерәм”.

Аэродром хәтле өстәл янында утыручылар сызгырырга, яман тавышлар белән кычкырырга керештеләр.

“Монархияме? Юк! Карточкалар системасы һәм талоннар бетсен! Халыкка спирт! Сине Корсикага!” Беркайчан да тавышы ишетелмәгән өлкә социаль тәэминат бүлеге мөдире барысын да уздырып кычкыра иде.

Бер аягына аксый төшеп, өчпочмаклы баш киемен култык астына кыстырып, башында әлбәттә Нәманган түбәтәе иде, ул яңадан киемен алыштырырга чыгып китте. Бу юлы инде ул костюмны җентекләбрәк сайларга булды. Муен астыннан ук эләктерелгән китель, хәрби галифе, кәҗә күненнән эшләнгән йомшак күн итек таптаман гына булып чыкты. Мондый кием киеп йөрүчеләрне хәтерли иде әле ул һәм табигый ки, үзен бу киемдә бик тә уңайлы, җайлы хис итә башлады.

Әмма ул чыгып бер генә сүз әйтергә дә өлгермәде, элек-электән таныш вә дус иптәшләре тагын әлләниләр кыланырга тотынды. Ул залга уйланган кыяфәттә, уң кулын күкрәгенә, кителенең өченче төймәсе янына куйган хәлдә килеп керде.

Җиңел промышленность бүлеге мөдире—авыр гәүдәле, тыны кысылып интегүчән кеше урак-чүкеч төшерелгән кызыл байракны болгый-болгый кычкырырга тотынды:

“Хәзер нинди заман икәнен белмисезме! Тәрәзәгә күз салыгыз! Галифе белән хәрби френчка кайту юк! Яшәсен Карден, Хуго Босс, Зайцев белән Адидас!”

“Ярар сана,—дип килеште ул.—Минем әле тагын бер мөмкинлегем бар”. Күрәсең, элекке бюро утырышында сүз куешкан булганнардыр.

Ул яңадан ял бүлмәсенә, үзенең гардеробы янына чыкты һәм аннан “Дормей” фирмасында тегелгән ачык соры төстәге, күзгә күренер-күренмәс нечкә генә зәңгәр буй-буйлы гап-гади инглиз костюмын алды. Бу фонда чия төсендәге тыйнак депутат значогы матуррак, яктырак булып күренә иде.

Һәм идәненә кызыл келәм җәелгән иркен кабинет шунда ук танымаслык булып үзгәрде дә куйды. Монда бөтенесе дә гадәти, таныш, якын иде. Аның күренүен аягүрә басып, көчле алкышлар, мәрхәбә тавышлары белән каршы алдылар. Аларның һәркайсыннан әллә нинди җылылык бөркелә иде. Һәр җыерчыгына тикле таныш йөзләрдә елмаю, теләктәшлек балкый, әле ярты сәгать элек кенә диярлек аларның матбугат иреге, ирекле сайлаулар, хокук системасын үзгәртеп кору, ниндидер конституцион мөмкинлекләр, гарантияләр, кыскасы, җүләр кеше дә әйтмәслек ниндидер башка таләпләр кычкыруына ышанырлык та түгел иде.

“Башлыйк, иптәшләр”,—диде ул катгый тавыш белән һәм тәбәнәк урындыгына утырды. Нәкъ шул мизгелдә уянып та китте...

Кухняда Шәрәфәт җырлый, идәндә аждаһалы, әмма инде кесәсеннән алтын тәңкәләре алынган халат аунап ята... Һәм Әнвәр Абидович тынычланып калды.

Ә бу вакытта Булат Мөэминович кунак йортының шыксыз бүлмәсендә ята һәм билгесезлектән интегә иде. Күпме генә уйланмасын, ул үзенең никадәр куркыныч, икейөзле, принципсыз кеше белән бил алышканлыгын башына да китерә алмый иде әле.

Наполеон куркытып алырга теләгән һәр нәрсә аны чынлап та тәшвишкә төшерде, обкомнан ул бик каты дулкынланып, борчылып чыгып китте. Ни дисәң дә, өлкә хуҗасы теләгәненә ирешкән иде инде.

*Ахыры киләсе санда.*

---

## *Бер сорауга—бер җавап*



**Мәхмүт Гәрәев,**
армия генералы,
Россия Хәрби Фәннәр
академиясе президенты

***Мәхмүт абый, Бөек Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм итүдән сез канәгать калдыгызмы?***

*Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм итү зур колач белән бик тә тантаналы төстә үткәрелде. Илледән артык дәүләтнең җитәкчеләре Җиңү көнен бәйрәм итәргә Мәскәүгә килүне муафыйк күргән. Бик мөһим нәрсә бу. Җиңүгә хәлиткеч өлешне нәкъ менә Советлар Союзы, безнең ил, безнең халык, безнең Кораллы Көчләр керткәнлекне тану.*

*Тантаналы парад шәп булды. Куәтлерәк хәрби техника узса да ярый иде үзе, тәэсир тагын да артачак иде. Ләкин бу кадәресе оештыручыларның үз эше инде.*

*Кайбер нәрсәләрнең ветераннар күңеленә хуш килмәвен дә әйтим әле. Җиңү бәйрәме белән котлаулары, олылаулары шәп. Ләкин бит бу бәйрәмне каршылаганда, 9 майга кадәр күпме ялган, яла, бозып күрсәтү булды. Телевидение, радио аша, газета-журнал битләреннән ташкын булып агылды болар. Безнең җиңү мыскылланды, аның мөһимлеге шик астына куелды.*

*Минемчә, күбрәк түрәләр бәйрәме булды бу. Асылда ветеран оешмалары җитәкчеләре, хакимият әһелләре җыелып бәйрәм иттеләр, ветераннарның, гади гражданнарның күпчелеге читтә калды. Игътибар-хөрмәт, бигрәк тә җирле хакимиятләр тарафыннан, җитәрлек булмады.*

*Шунысын да әйтим инде: өстенлекләрне акчалаштыру һәм башка шуның кебек эшләрне Җиңү көненә хәтле генә булса да кичектереп торырга кирәк иде. Олы бәйрәм алдыннан шундый эш эшләү хакимият белән гражданнар, ветераннар арасындагы мөнәсәбәтләрне кискенләштерде. Моның күңелсез тәэсире бәйрәмнән соң да тиз генә җуелмас әле.*



Бикә
Рәхимова

## КҮҢЕЛ ИГҮЧЕЛӘР

### Ни кыйммәт?

*Галәм эчендә уйсигез мең галәм.*
Мөнәҗәттән.

Йолдызыңны кабыз үз күңлеңдә—
Күктәгесе безнең гамәл түгел...
Бушлыкларга киткән—бушка киткән,
Җир йөзендә уртак гамьгә түгел...

Безнең язмыш бары Җирдә генә,
Аллы-гөлле уты бездә генә...
(Күңелеңнең керсезлеге, агы—
Ул чагыла бары күздә генә...)

...Бармы Күктә безнекедәй Җирләр?
Тереклек итәдер бит игенчеләр?..
Бездәгедәй эзлисеме икән?—
Табыламы Күңел игүчеләр?..

### Бездән мирас

*Толымнарын талга биреп торган,*
*Тынып калган җилкәй ни көтә?..*

Сабыйлардай—язлар көтеп яшәгән чак.
Кайчан гына идек әле үзебез—яз?!
Чәнечкеле үткер еллар бәгырь телде:
Җәрәхәттән саркый кайнар, яралы наз...

---

Бикә РӘХИМОВА *—шагыйрә, публицист; "Сәрвиназ", "Иделләр Казанында", "Мәрхәмәт" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ташуларны без китердек, сулар түгел.
(Бигрәк инде шикләнүчән сезнең күңел...)
"Без" дигәндә безнең буын минем телдә—
Гөл калдырып китүчеләр янган көлдә.

Яндырдык та, яктырттык та дөньяларны...—
Яңа тормыш китерештек илгә-көнгә.
Чәнечкеле булып чыкты үсентебез,
Инде карап яшәгез сез—шушы гөлгә.

...Безне гафу итмәс сәбәп... юктыр сезгә...

## Печән өсте

Болын шаулый, болын гөрли—
Авылда печән өсте.
Чалгы ярышлары бүген—
Йә, кемнәр чыгар өстен?

"Гали пәкесе"—чалгылар
Пакуста көй сыздыра,
Егетләр егәрен сынап,
Күктә кояш кыздыра.

Кыз-кыркын өя күбәгә,
Баскалап кәс-кәс кенә,
Йөзе-күзе, елмаюы
Иш булган—чәчәк кенә...

Һәркем бүген үз ярының
Җиңеп чыгуын тели...
Күпергән ипидәй пакус—
Кискәннәр телем-телем...

Җиңүче күп, җиңелүче
Булмый печән өстендә.
Печән өстен яратабыз
Ярыштырган өчен дә.

...Безне әйдәгән байрак та
Яшел болын төсендә...

## Бармасам...

Урманның гайрәте искиткеч,
Шаулый да ярсый ул, диңгездәй,
Сына ич, бетә ич, дигәндә
Тына ул, нәкъ иске нигездәй.

Күлкәем, тартасың күңелне
Көзгеңнең тылсымы беләнме?
Гөлдери камышлар эчендә—
Көзгенең иясе көләме?..

Кырларга бак инде, әйт инде,
Келәмнәр тукыган кай ара?
Болынны, кырларны әйләнеп,
Урманнар кайтаваз кайтара.

Һәммәсе сөйкемле, ягымлы:
Урман, кыр, күлләре чакыра.
Гүяки чаптарым әйдәкли—
Күңлемдә чакырып чаң тора.

Ак җаным чакыргач тылсымга,
Талпыну кирәксез түгелдер...
Бармасам, урман-кыр ухылдап,
Күлнең дә сулары түгелер...

## Чәч бөртеге

Истәлеккә алып чәч бөртегең,
Нигә генә куйдым саклауга!..
Тынычлыгың минем белән киткән—
Чәч бөртегең синең сак булган.

Тынычлыгың киткән минем белән...
Әллә рухың миңа күченгән?
Нәкъ синдәй мин хәзер исәрлектә,
Сизәсеңме шуны үзеңнән?

Ерак калган таңнар балкыш кына,
Кулларымны сузсам, сузмасам,
Сагышланмас идем бу кадәрле,
Язмыш киртәләрен узмасам.

Чәч бөртегең җылы учларымда,
Кагылмасын аңа җил генә...
Үтенергә, үкенергә мәңге
Хатын-кызга кала гел генә...

## Эзләмәскә

Сою сәбәпләрен эзли-эзли,
Карурманга барып керермен.
Адашырмын, чыгалмастай булып,
Бәгыремне меңгә телермен.

Кулларыңның ялгыш кагылуы
Җаннарымны нигә эретә...
Кош баласы җиргә егылгандай—
Чак ялгышсаң, шул да әрнетә.

Утлар эчеп, сулар сибеп кенә
Дәвам иттерүме тормышны?
Бу хәятне кемдер яратмас та,
Без белгәнме башка тормышны?..

Яратуның сәбәпләрен безгә
Эзләмәскә, искә алмаска...
Җир дә шулай: сусап яңгыр көтә,
Кояш-уты кирәк алмашка.

## Чирмешән

Без яшь чакта Чирмешәнем
Ярсу, уйнак иде,
Дулкыннары уйдык-уйдык,
Нәфис уймак иде.

Ярларында төрле бизәк:
Кызыл, сары иде...
Без барасы юллар ерак,
Ерак, ары иде...

Кайтып төштем әле менә,
Төштем Чирмешәнгә.
Риза очрасам да бары
Әрем—ак җәмшәнгә.

Әрем генә түгел, комы,
Сары комы көткән—
Елап юган комын сибеп,
Елга мине көткән.

Көтә-көтә, бик зарыгып,
Суның хәле киткән:
Салмак җәелгән дә ага,
Уйнаклыгы беткән.

## Бәхет

*Бик күп кешеләрнең бәхете*
*Бер кешедән тора, диләр.*

Нинди җилләр алып очыргандыр,
Хәтеремдә минем киткәнем.
Омтылып, бер җан күреп мин кайтам,
Тик юк әле кайтып җиткәнем.

Көтәләрдер мине, көтәләрдер,
Көткәннәре бары мин генә.
Төшләренә кереп гел йөдәтәм,
Эзләр салам адәм миенә.

Фаллар ачып, эзләп чыгучылар
Төшәрләрме икән эземә—
Йөрәгеңне ачып укымасаң,
Укыганың бары сүз генә.

Юллар табып, эзләп килүченең
Исемнәре булыр Биктүзем.
Күрешүләр шундый күңелле бит,
Гел очрашу көтәм мин үзем.

## Күңел киңлегенә чакыру

Ак пәрәвез оча, көн яктыртып.
Көзләр ерак әле… алданыйк…
Көз яфрагы пешкән кавын кебек,
Алтынлыкны мактап дан алыйк.

Көзләр ерак әле… бик якын да,
Уңышлардан тулса келәтең.
Бер еракка китеп, бер якында
Уңышсызлык кемгә теләдең?..

Күңелеңә әллә ниләр булды,
Килгән кебек чүлгә корылык.
Ак пәрәвез сарган көзне чакыр,
Басып алса тирән сорылык.

## Дәүләт тотмый...

Дәүләт тотмый тел тотуы,
Аһ, кыен, төшенгәнгә.
Аңлыйм аны, беләм аны
Үз башыма төшкәнгә.

Себердән килгән уртак тел,
Себер киттең бәйләнеп.
Себер китсәң дә үлмәдең,
Кайттың исән әйләнеп.

Йөз төрле татарны хәтта
Бер төрле кавем иттең.
Җилдә җилгәргән бөртектәй,
Бербөтен халык иттең.

Бөтенлегең китә алмас
Тешен кайрап торучы.
Үз ашын үзе ашасын,
Мулдан салып борычын.

...Дәүләт тотмый тел тотуы,
Аһ, кыен, төшенгәнгә.
Аңлый аны, белә аны
Үз башына төшкәннәр.

## Тезгенсез уйлар

Зәңгәр күктә синең кояш яна,
Яначак ул, сүнми, сүнмәс тә.
Яшьли сөйгәннәрнең хатирәсе
Җирдә кала мәңге сүнмәскә.

"Колагымда сәгать йөри,—диеп,
Сагайттың да минем күңелем,—
Һавалардан,—дидең, кояш булып,
Якты нурлар булыр түгелим".

Бөдрә чәчең синең җилгә оча—
Тал чуклары әнә, күрәмсең?..
Җаның йөрде минем тирәләрдә,
Җаннар кайта очып, күрәсең...

Эзләрең дә синең ярылып ята,
Хәтта комнар күмми, ишелми...
Килеп кенә үзең керерсең күк,
Колак кебек сакта... ишегем.

Арка-тәнгә мамык шәлдәй иңеп,
Җылы куя идең, сарылып...
Үкенечле ярлар юлда һаман,
Яшәү кала бары сагынып.



## Шәүкәт Гаделша

# ТУГАН ЯКТА—УК АТКАНДА...

***

Себер диләр аны. Себер...
Бу әүвәлге исемме?
Иң борынгысы, иң чыны,
Тылсымлысы дисеңме?

Көзән тәнен җыергандай,
Тубыл суы тартыша:
Ярны ашап үзгәртсә дә,
Көче җитми тарихка...

Яшен түгел, күктә чатный
Карагайлар тамыры.
Рәхмәт инде: менә тагын
Сукмый исән калдырды.

И, Ходаем, ниемә соң
Безгә мондый игелек?
Болай да бит, тавыш-тынсыз,
Күп авыллык кимедек.

Йолдызлыкта безнең йолдыз
Бардыр, яна, дисеңме?
...Бабайлар дөрес кушканмы
Бу киңлеккә исемне?!

### Черки

"Тиен күзенә тидерә алам—
Халкыма аннан ни файда?
Атка йөгән кидерә алам—
Халкыма аннан ни файда?

Аю-бүре аулый алам—
Халкыма аннан ни файда?
Төлкеләрне алдый алам—
Халкыма аннан ни файда?"—

---

Шәүкәт ГАДЕЛША (1949) —*шагыйрь; "Ярык мөгез", "Сөмән кадыйм", "Аучы җыры" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Уйлана шулай яшь аучы,
Утырып төпкә, аланда.
“Файда булырмы халыкка?”—
Күзләре кысык һаман да.

...Ә черки? Черки шат, бик шат
Яшь аучы уйда сүнгәндә:
Иң илаһи ләззәт тоя
Ачу катыш кан эчкәндә.

## Сөнге сабы

—Балта тагып билеңә,
Кая киттең бик иртә?
—Кирәк иде яшь каен
Сиртмәлеккә—бишеккә...

Күктә ничек киртләнер?—
Әйтмәдем мин дөресен:
Озак ятып чормада
Чергән сабы... сөңгенең.

И урманкай—яшел төн!
Менә тагын килдем мин.
Әүвәл—Алла, аннан—син!
Башка дусны белмим мин.
Кансыз Ермак явыннан
Бабаларны яшердең;
Ачлык, афәт килгәндә
Тере сулар эчердең.
Син булганда җир—ышык.
Син булганда без—исән.
Киметмәмме ямеңне?—
Сөңге саплык мин киссәм...
...Каеннарның тәненә
Куркам балта төртергә:
Кеше каны җылысы
Тузларыннан бөркелә.

Сөңге сабын бабайлар
Бу тирәдән кистеме;
Чормаларда черүен
Сизеп-белеп киттеме?

Чаба гына күрмә дип,
Тыз-быз килә борындык.
Бер уйласаң, ниятем—
Куркырлык шул, куркырлык.

...Минем ачу—ачумы?—
Суына ул иртәгә.
Җирнең газиз агачын
Нигә әрәм итәргә?

—Кая сиртмә? Нигә буш
Син кайтасың урманнан?
—Сайлап кына куйдым тик,
Онык әле тумаган...

## Минем уй

Кичә чыбык иде, бүген—ботак.
Кичә чыпчык кунды, бүген—шонкар.
Кайчан имән булып калкыр да, ул
Ботагына давыл бәйләп куяр?

## Дулана

Дулый, ярсына, чайкала,
Күрсә мине, дулана:*
Үзенә үпкә тотканга
Ошамыйм бит мин аңа.

Җансыз агачка сылтаулар
Түгел дә бит егетлек...
Дулана сынын күрүгә
Җан сызлый, кителер күк.

...Тимер көбәле явызлар
Туган якка үткәннәр.
Дуланадан бабаларым
Җәяләрен бөккәннәр.

Уклары, терәп атып та,
Ул көбәне тишмәгән:
Шул дулана үзәгенең
Көч-куәте җитмәгән...

...Кан төсе белән күзләрен
Тора балкып дулана.
Дөм чарасызлыктан гына
Бәйләнәм бит мин аңа...

***

Тилгән оча һавада,
Әйләнә ул биектә.
Ук аталар малайлар
Җитә алмасын белеп тә.

Кире төшеп шул уклар
Югалалар үләндә.
Укны чукый чебешләр
Төшкән җирен күргәндә.

Ни уйлыйдыр тилгәннәр
Җәя укны типкәндә?
Ни уйлыйдыр чебешләр
Уклар "тып-тып" төшкәндә.

Ни уйлыйдыр малайлар
Җәя җебен тартканда?
...Мин дә бергә ук атам
Туган якка кайтканда.

---

*Дулана — дүләнә; агач исеме. Себерчә. (Боярышник.)

Ачуларны йомшарта
Күккә төбәп ук ату.
Әфсен булып тоела
Укны күздән югалту.

Ни турында уйлыйм мин
Уклар очып киткәндә?
Мин куркак, әйтермен тик,
Ахырзаман җиткәндә.

Тик, татарның җирләрен
Кайтарсалар иртәгә,
Мин әзермен, буйга—ук
Атып, үлчәп китәргә.

Ничә көн ничәмә ук
Атып, эзләп барасы?!
...Түгел ул сиңа, түгел
Тилгән—чебеш арасы...

## Чып—чын

Һаман да—шул Мәскәү... Һаман—
Шул якларда туа ялган...

Менә бу чал урман—чып-чын.
Менә бу ак томан—чып-чын.

Себер татары да—чып-чын.
Аның хыялы да—чып-чын.

Саз буенда, сабый сыман,
Күзләремне кат-кат йомам.
Туган ягым, син дә куан,
Җанымда юаныч тоям:
Күчем* кача белеп качкан,
Кайтыр, чыгар берәр кайчан...

Әйтер безгә Мәскәү һаман:
"Чеп-чи ялган бит бу. Ялган!"

*Күчем—Себернең соңгы ханы.



**Камил Кәримов**

# МИН ӘНИГӘ БИК КИРӘК!..

ХИКӘЯ

Ышанмыйм...

Нигә әле көндәлек язу гашыйклар эше генә булырга тиеш? Минем, зур абыемнар кебек, кемнедер сагынып, төннәр буе йоклый алмыйча изаланып, аерылышу газаплары кичергәнем юк. Чөнки мин әлегәчә яратып караган кеше түгел. Яшемә күрә ашыгасы да юк. Ләкин соңгы көннәрдә никтер көндәлек язасым килә. Абый әйтә, көндәлек яздыра торган өч сәбәп бар, аның берсе—зур югалту, икенчесе—хәвеф, өченчесе—билгесезлек, шушы өч авырлыкның берсен татып карамыйча кеше көндәлек яза алмый, ди. Ни өчен яратуны да сәбәп итеп алмыйсың дип сораган идем, көлде генә, мәхәббәтнең өч сәбәпкә дә катнашы бар, ди.

Мин көндәлек язарга телим, тик сәбәбен белмим әле, бәлки минем өчен югалту белән хәвеф һәм билгесезлек өчесе бергә буталгандыр?..

Безнең Дустайда утыз гына моржа утырып калган. Әле мин туганда гына да ике йөзләп иде диләр. Ышанмыйм. Шул кадәр кеше каян килсен ди ул Дустайга? Әгәр булган икән—кая соң алар? Үлеп беткәннәр дияр идең—үз-үземне хәтерли башлаганнан бирле авылыбызда ике генә кеше үлде, алары да хәвеф корбаннары. Берсен Әфганстанга хезмәт итәргә киткән жиреннән табутка салып кайтардылар, икенчесенең гәүдәсен тапмадылар, Әгерҗедән кайтышлый буранга юлыгып адашкан диделәр. Ә безнең якта адашкан кешене эзләп таба алганнары юк әле. Чөнки ерганакларда кыргый этләр өере яши. Әллә кайлардан күчеп килмәгән ул этләр. Күрше-тирәдә күпме авыл таралып беткән. Калага киткән хуҗалары этне үзләре белән ияртә алмыйлар. Менә шуннан калган инде ул безнең якларда кыргый этләр. Бүредән дә хәтәррәк ди алар. Бүре хет уттан курка. Ә бу этләр, гомер буе кеше тирәсендә яшәгәч, уттан да, чурттан да, кызыл төстән дә, мылтыктан да курыкмыйлар ди.

Кич житеп, кояш офыкка сеңнер жай эзли башласа, тәрәзәдәге бозлар калыная, ишек тупсасына кагылган эшләпәле кадакны бәс сара, өй эчендәге жылы кисәк тартыла. Шулчак бер-бер артлы мичләр ягыла. Утыз моржадан ургылып-ургылып төтен чыга. Яхшылабрак санап карасаң тагын унбишләп моржа бар әле. Аларыннан илле градуслы суык килсә дә төтен чыгасы юк. Күптән кеше яшәми инде ул өйләрдә. Китеп беткәннәр. Хуҗаларының кайсы

---

Камил КӘРИМОВ (1950) – *прозаик; «Сакау куке», «Үзеңне бел», «Ком сәгате», «Өй артында шомыртым» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ижаунын корыч кою заводында, кайсы атом электр станциясе төзи, кайсыберләре Түбән Каманың химия заводына урнашып калган. Минем абый да, Әфганстаннан исән-сау кайткач, тиешлечә ял да итмичә, КамАЗга китеп барды. Абый әйтә, кайда фатир тиз бирелсә—адәм баласы бәхетен шуннан эзли, ди. Ышанмыйм! Югалган әйберне генә эзләп була. Бер дә белмәгән калаларда эзләп йөргәнче, шул бәхетне авылда гына эзләп карарга иде. Югалса да шушында гына югалгандыр...

Ул өйләрне без җәй көне дә суык өйләр дип йөртәбез. Уен белән мавыккан чакта мажара эзләп тә кермибез, ташландык бакчаларында кыргыйланып үскән кура җиләген дә ашыйсы килми, хуҗасы булмагач, алмаларын да урлавы кызык түгел. Кызганыч өйләр алар. Дөрес, икешәр моржалы кешеләр әлеге салкын өйләрне утынга сүтеп яга торалар. Абый әйтмешли, өй өйне ашый.

Без Дустайның соңгы малайлары...

Җиденче класста укысак та, безне нәниләрне чакыргандай: бәпкәчем, кил әле дип дәшәләр. Кызыграк сүз ычкындырсак, башыбыздан сыйпап, аркабыздан сөяләр, йоклый алмыйча интексәк—берәр конфет бирәләр. Азрак булышыйк дип, балта-пычкыга тотынсак, кулыбыздан алалар. Уйнап калыгыз, янәсе, эшне үзебез генә җинәрбез. Уен якшәмбе көнне генә тәти ул мина. Башка вакытны мин юлда—Дустайдан Табылдыкка йөреп укыйм. Яшьтәшләр белән авылда ял көнне генә күрешәбез.

Үзебездә укыганда рәхәт иде лә ул...

Безне—ягъни Дустайның унбиш малай-шалаен—тугыз укытучы укыта иде, аның да берсе директор булып исәпләнә. Директор тарих дәресләрен алып бара. Калганнары өчәр төрле фәннән керә. Әйтик, Зәет Сәетович рус теле һәм әдәбияты дәресләрен берүзе үткәрә. Калган укытучыларга да фәннәр җитәрлек, чөнки мәктәбебез сигезьеллык дип атала.

Бар иде рәхәт чаклар... Ялгыш, дәрескә килми калсак, әти-әнине мәктәпкә чакыртып тору юк, укытучылар үзләре көненә икешәр тапкыр хәлне белеп торалар, шул унайдан калган дәресләрне дә аңлатып китәләр. Мин әле салкын тиеп авырган очракларда терелеп беткәч тә берәр атна урын өстендә ауный торган идем, рәхәт ич—иртүк торып интегә-интегә мәктәпкә йөгерәсе юк, дәресләренне әзерлә дип йодәтмиләр, ормыйлар-сукмыйлар. Сигезенче классны тәмамлап шәһәргә чыгып качканчы шулай яшәргә исәп. Ата-аналар җыелышын да мәктәптә үткәрү юк, әйтәсе сүзләре булса, өй саен йөреп, укытучылар үзләре килеп әйтә торганнар иде.

Мәктәптәме?

Әгәренки берәрсе безгә ошап җитмәгән сүз әйтсә, куйган билгеләре белән ризалашмасак, йә дәрестә сөйләшеп утырырга рөхсәт итмәсәләр өйгә кайткач әтигә генә әйтәсе... Шулай, безнең якларда сигезьеллык мәктәпләрнең үз законнары бар... Әле без—малайлар, җыелып киңәштек тә, укырга галәттәгечә иртәнге сигезгә түгел, ә тугызга йөрергә дигән карарга киллек...

Тик рәхәтебез озакка бармады...

Ел ахырында алты агайне сигезне тәмамлап бөтен эшне бозды. Житмәсә, яңа уку елында беренче класска килерлек бер бала да юк иде. Әйтәм ич, бүтән малайлар юк безнең Дустайда—иң соңгылары без... Шулай итеп, укытучылар белән тугызга-тугыз калдык. Мәктәбебез беренче классыз гына эшли башлады. Безгә игътибар тагын да артты, һәр укучы исәптә, класс саен берәү генә без, күккә генә чөймиләр. Иртән килүебезне мәктәпнең баскыч төбенә чыгып көтеп торалар. Хәл-әхвәлне, әти-әниләребезнең, күрше-күлән, туган-тумачаларыбызның исәнлеген сорашалар, бәйрәмнәрдә конфет-прәннекләр белән сыйлап чәй куеп эчертәләр. Бервакыт, кызык өчен генә, парталарның утыргычы каты, көне буена бик ардыра, дигән идек, икенче атнаны ук районнан ялтыравыклы язусызу өстәлләре кайтарттылар, укытучылар бүлмәсендәге тугыз йомшак утыргычны безгә бирделәр, ә үзләренә сайгактан озын эскәмия ясаттылар...

Кемдер каядыр исемен күрсәтмичә генә жалу язган да һич көтмәгәндә комиссия килеп төште.

Укытучыларыбызны күрсәгез—Ижау базарында акча янчыгын югалткан Әгерҗе хатыннары шикелле тыз-быз йөгерештеләр. Безне шундук өйгә куып кайтардылар. Урамга чыккач, сигезенчедә укучы атаманыбыз аңлатып маташты. Ана ышансаң... Имеш, мәктәбебез иртәгәдән "башлангыч" дип йөртеләчәк; ике баланы укытырга бер генә укытучы калачак. Дүртенчедән алып сиге-

зенчегә хәтле класслар—ягъни без—Табылдыкка йөреп укырга тиешләр икәнбез. Дустайда калган ике малайлы ике классны житәкләү хокукы өчен укытучылар арасында "классовый" көрәш бара, имеш...

Ышанмыйм...

Атаманнын күп сүзе хак булды. Икенче көнне үк безне машинага төяп Табылдыкка илтеп куйдылар. Комиссияне әйтәм, һич югы бер генә ел—мин сигезне бетергәнче генә түзмәделәр. Хәзер шулар аркасында жиде бала алты чакрым йөреп укы инде... Үзебез дә сизмичәрәк калдык. Әгәр алданрак белгән булсакмы—без ул сигезенчене бетергән малайларны үгетләп, классларында берәр ел кучми кала торган итә идек.

Безнен Дустайдан киткәнне генә көткәннәр—мәктәбебез бинасы фураж складына әверелде. Ә башлангыч дип үзгәртеп аталган Дустай мәктәбе суык моржалы өйләрнен берсенә күчте.

Укытучыларыбыз кайсы-кая чәчелеп бетте. Математика укытучысы кибетчене эшеннән алдыртып анын урынына калды, физигыбыз комиссияләр үтә торгач, икенче группалы инвалид таныклыгы алып пенсиягә чыкты, татар теле укытучысы яна фураж складына мөдир һәм каравылчы булып урнашты. Калганнары гаиләсен ияртеп төрле шәһәрләргә туган-тумачалары тирәсенә чыгып китте. Араларыннан берсе генә—рус теле укытучысы Зәет Сәетович кына, безнен белән Табылдыкка йөриячәк, укырга түгел инде, укытырга. Мин анын сигезенче класста укып йөргән чакларын хәтерлим әле, ул чагында алар безнен—октябрятларнын вожатыйлары булып йөриләр иде. Кайту белән жыр укытучысына өйләнде. Хәзер бер кечкенә бәбиләре бар. Жырлап кына яшәп яталар...

Баштагы мәлне Табылдык мәктәбенен беренче дәресенә барып өлгерер өчен без сөт машинасы янына жыела идек. Сөт заводына барышлый ул безне алып китә, кайтышлый алып кайта. Сентябрь айларында әллә ни юл газабы күрмәдек. Иртәнге дүрттә уяныргa да өйрәндек, ферма яныннан кузгалганда көн яктысы машина кузовындагы сөт бидоннарын санарлык кына була әле. Без менеп утырган бидонда иртәнге сөт жылысы Табылдыкка барып житкәнче суынмый, йөзгә салкынча жил бәрсә дә тунарга ирек бирми. Хәер, безнен Әгерже юлларында әллә ни жилләнеп барырлык түгел. Машинабыз бер чокырдан чыгып икенчесенә төшкән чагында, савымчылар ныклап беркетмичә йокы аралаш кына япкан капкачлардан сөт бөркелеп чалбарыбызны, ә кызларнын итәкләрен юешли. Шунысы бар, без Табылдык мәктәбенә килеп төшкәндә дәресләр башланырга өч сәгать вакыт кала, ике класска бүленәбез дә чишенеп чалбар, итәк киптерәбез. Чалбар кипкәнне көтеп без йокыга китәбез. Табылдык малайларынын аяк тавышларыннан уянып чак киенеп өлгерәбез. Алар класска килеп керүгә: сездән көтүдән кайткан сыер исе килә дип, жанга тияләр. Көн саен көлүләренә түзәрбез анысы, интернатта кунып укырга гына кушмасыннар.

Октябрь аена кергәндә рәтләребез сирәгәйде—сонгы ике кызыбыз Әгерже-дәге апалары янына китеп утыз бишенче мәктәпкә кергән. Авылга каникул вакытларында гына кайтачаклар икән. Ике малаебызны Ижаудагы туганнары үз янына алган. Без Зәет Сәетовичка иптәшкә нибарысы өч бөртек кенә калдык.

Сөт машинасы өстендә ачык жыелыш үткәреп, өчебез дә уртак бер карарга киллек—тан йокыларыбызны әрәм итеп сөт машинасы белән чиләнмәскә, велосипед белән йөрүгә күчәбез.

Табылдык белән Дустай арасындагы алты чакрымны нибарысы ярты сәгатьтә үтеп, йокыны өч сәгатькә озынайттык. Экономияләнгән вакыт ярап куйды, йокы белән булышмыйбыз, укудан сон кайтырга бик ашыкмыйбыз—Табылдыкта көн дә кич кино күрсәтәләр. Киноны без "жиденче дәрес" дип йөртәбез, юкса Дустаебызга гомергә кино килгәне юк, теләгән кеше киногa да, концертка да, жыелышларга да Табылдыкка йөри.

Көннәр янып торган шәм кебек — күзгә күренеп кыскара хәзер.

"Жиденче" дәрестән сон гел карангыга калабыз. Кыргый этләр очрамагае дип шүрлибез. Зәет Сәетовичка гына сиздермибез. Интернатта яшәү мәсьәләсендә сүз һаман ешрак чыга. Ашау мәсьәләсе генә куркыта, интернатта ашханә ризыгы шул, беләбез анын ни икәнен! Узган елны Әгержегә слетка баргач, тимер юл вокзалындагы ашханәгә кереп тамак ялгаган идек— икенче көнне мәктәпкә бара алмадык, шомырт суы эчә-эчә көч-хәл белән котылдык... Ә өйдә—көн саен таба ашы!

Зәет Сәетович үгетли үк башлады:

—Үз кадерегезне үзегез белмисез, интернатлары менә дигән! Сезнең көн саен кайтып-китеп йөрүегезне яна директор миннән генә күрә. Имеш, сез миңа ышанып кына юлга чыгасыз икән, әгәр иптәш булмаса Табылдыкта каласы икәнсез. Үзегезне кызганмасагыз, мине кызганыгыз хет. Өемдә хатыным белән күкрәк баласы тилмереп көтеп ятканда, сезнең аркада интернатта куныш кала алмыйм ич инде мин!

Малайларның җелекләре җебеде, кызганудан пырыш-пырыш борын тарталар.

Мин Зәет Сәетовичны сүз белән якларга теләдем:

—Калыйк интернатта, рәхәтләнеп йокларбыз, туйганчы кино карарбыз, өйдәгеләр дә сагыныбрак көтеп торырлар...

—Табылдык кызына күнелен төшкәч, сина шул гына кирәк инде,—дип, Зәет Сәетович алдында авызымны ябып куйдылар.

Бу малайларга һич серенне сөйләрлек түгел икән. Кайтарып әйтергә җаен гына көтәләр.

Күнелен төшкәч дигәннәре, Алсинә инде ул. Күрше класстан.

Шулай бервакыт галәттәгечә, җыйнаулашып Табылдыкта кино карарга булдык. Карын ачкан чак иде, үч иткәндәй, киносы да кызык түгел—фильм башында ук җыелышка җыелганнар иде, иң соңгы кадрында гына таралыштылар. Нииндидер премияне алмыйча әрләшеп беттеләр. Күнелсез инде безгә, боргаланып утырабыз. Сул ягыма унбиш, уң ягыма егерме борылганмын. Егерме беренчесендә ни күрим: Табылдык кызы Алсинә бөтенебезгә үч иткәндәй, экранга карап утыра, селкенми дә! Ул экранга, ә мин аңа карап, егерме беренче борылышымда катып калдым, Алсинәне күреп карын ачуым да онытылды. Залдагы экран яктысында китап укырга була. Тукта, нишләп шулай һуш китмәле тоела соң әле бу кыз? Мин маңгай чәчләрен артка тарап, толымнарын баш чүмеченә өеп куйган кызларны яратам. Аннан, мина сөт кебек ак чырайлылар түгел, күбесенчә кара тутлылар ошый. Кызларга кечкенә, печтик, яки төймә борын килешми шикелле, минемчә алар күтәртмә борынлы булсалар матуррак күренәләр. Күз мәсьәләсендә бәхәсләшергә җыенмыйм, беләм, кара чәчле кызларга коңгырт күз килешә. Менә шушы мин теләгән сыйфатларның барысы да бар Алсинәдә! Узган ел зур сабантуйда, күргәнием мин аны, алай ис китәрлек түгел иде ул. Карасана, ничек тиз үсә бу кызлар, житмәсә үскән саен матурланалар... Әгәр бүген мажаралы яки берәр сугыш турындагы кино булса, мин тәки Алсинәне күрмичә кала идем. Менә ни өчен кирәк икән ул кызыксыз кинолар...

Юлда кайтканда шатлыгымны уртаклашкан идем шул, әгәр кайтарып әйтәселәрен белгән булсаммы?..

Өчәү идек, Табылдык интернатына күчкәч берәү калдым. Теге ике малай Можга дигән кечерәк бер станциягә туганнары янына киткән, шунда ук училище да бар ди. Тиздән әти-әниләре дә күчеп китәселәр ди. Минем китәр җирем юк шул. Абыем әле тулай торакта гына яши, ана ышанып җәһәннәмгә олагасым килми. Сигезне бетергәнче түзәргә инде...

Табылдык интернатында мина утыз алтынчы урынны бирделәр. Бөтенебез бер бүлмәдә, кызлар ничәүдер, белмим әле, санамадым, алары күршедә. Төрлебез төрле авылдан җыйналсак та бер мәктәптә укыгач, читсенеп-ятсынып тору юк икән ул. Килгән көнне үк җыйнаулашып кәрт суктык. "Исәр" калганнар җиңүчеләргә урын җәйде. Иң соңгы "исәребез" мичтәге кисәү башын саклапга калды, юкса кисәүле килеш япсан бүлмәгә сөрем исе чыга. Ә инде янып беткәнен көтеп калакларны ябарга онытсаң бөтен җылы урамга очып бетә. Шуңа күрә соңгы "җуләрнең" эше бик тә җаваплы, имеш... Ышанмыйм!

Кичке ашка, итсез генә дөге боткасы белән яртышар кружка сөт каплап куйгач, караватларга таралыштык.

Минем моның ише пружиналар өстендә йоклаган юк иде, кибет одеяллары ябынмаганга да биш былтыр. Матрасы җиде түмгәкне корамалап җыйган сыман. Хәер, таралып китәрлек түгел—караватның пружиналары салынган, яту белән матрасның җиде кисәге бергә өелә. Мендәрне аңламадым—никтер баш тәгәрәп төшә. Сүрүен ачып карасам—механизаторларга кул сөртергә бирә торган төрле төстәге бер төенчек мамык. Тәмам йокы качты.

Өйдәге үрдәк мамыгыннан тутырылган ястык, үзебез сырган түшәк, ялтыр

тышлы калын юрганыбызны күз алдыннан җибәрмичә сәгатьләр буена интеккәч кенә йокыга кителгән.

Ике авыл арасында ләмәк ерып йөргән эзләребезне калын кар каплады. Якты көн озын тәнәфес хәтле генә калды. Дәресләр беткәндә караңгы төшә башлый.

"Яшисез рәхәттә, ата-анагыз яныгызда түгел, җаныгыз ни тели шуны эшләп тик ятасыз, абзар-кура җыештырасыгыз, утын турыйсыгыз, бала карыйсыгыз да юк",—дип, Табылдык малайлары безгә кызыгалар. Ә без — интернатныкылар, аларга кызыгабыз. Әти-әни хөрмәтендә яшәп, үз рәхәтләренең кадерен үзләре белмиләр.

Кич житүгә тәрбияче әби мич ягасым бар, дип, өенә кайтып китә, аны төнге унберләрсез көтәсе дә юк. Шул арада интернатның асты-өскә килеп ала, колхозның йөри алырдай нинди техникасы бар—һәммәсе безнең тирәгә җыела. Табылдык егетләре безнең бүлмәгә кереп тула. Күрше бүлмәдән кызларны чакырып чыгарырга, яисә хат кисәге тапшырырга кушалар. Үзебезгә кирәкмәгәннәрен чакырабыз инде. Кичтән үк, бик күп итеп хәйләләр табып куябыз да үзебезнең арадагы малайлар кызыгып йөргән кызлар хакында сүз кузгалса тотлыкмыйча гына ялганлыйбыз: "Көне буе ютәлләп тора иде; туганнарына утырмага китте; эче авырта бугай; кичләрен өйдә утырмаган өчен әтисе килеп пыр туздырып китте..." һ. б.

Табылдык егетләре безне мич авызы тирәсенә җыеп тәмәке тарттыралар. Мин катышмыйм әле, Алсинә белән күрешеп сөйләшмичә торып, тәмәкегә өйрәнмәскә булдым—бәлки ул исен сөймидер?!

Алмаш-тилмәш тәмәке суырган арада әллә ниткән мәзәкләр сөйләп алалар. Мәзәкләрен тыңлыйм, анысының исе юк. Мин дә берне сөйләдем...

Әгерженеке берәү хатынын ияртеп Казанга барган. Базарда йөргәндә адашып хатынын югалткан. Агай аптырап калмый, якында гына бер милиционер була, шуның янына килә дә: "Ярдәм итә күр, зинһар, хатыным югалды",—ди. "Ярар, эзләрбез,—дигән милиционер,—хатыныңның портреты нинди?"

Агай портрет сүзен аңлап житкермәгән. Шуннан соң милиционер үзенчә аңлатмак булган: "Әйтик, менә минем кызым чем-кара чәчле, бит алмасында мине бар, керфекләре озын, елмайганда ияк очына мәхәббәт чокыры чыга, биле нечкә, гәүдәсе..." Абзый аны ахырынача тыңлап бетерә алмаган: "Иптәш милиционер, әйдә лутчы синең кызны гына эзлик",—дип җавап биргән.

Мин сөйләп бетергәч берсе дә көлмәде, чөнки мин тәмәке тартмыйм. Кемдер: "Әйдә, лутчы синең Алсинәне генә эзлик",—дип өстәп куйган иде, әй тотындылар көләргә!.. Ирексездән киендем дә Алсинәләр өй түренә киттем...

Кызны күреп булмас инде, анысы хак, өй түрләрендә башкалар юк микән, шуны гына беләсем килә... Һәй, мондый суыкта кем йөрсен соң? Тынычланып кайтыр юлга борылган идем, баскан җирендә кар шыгырдатып Алсинә килә... Ул инде, билләһи ул—иңендә чиләк-коянтәсе. Мин аны куркытмас өчен баганадагы лампочка яктысына килеп бастым. Ул да яктыга сыешып кына тукталып калды.

—Нихәл, Алсинә?

—Исәнмесез, Баязитов...

Әгәр, нишләп йөрисең дип сораса, оятымнан көртлек кебек карга чумам хәзер. Алдан ук җавап эзлим, Алсинәнең чиләгенә бозлар эленгән, мамык шәленең янак тирәсен бәс сарган.

—Ярый,—ди бу,—болай да чиләгемә боз утырды, Болын чишмәсенә барган идем.

—Ай-һай, бигрәк еракта бит соң ул сезнең Болын чишмәгез. Бүреләр өне янында, курыкмыйсыңмы?

—Нәрсәдән куркыйм ди, интернат ачканнан бирле бүреләр безнең авылдан качып беттеләр инде алар... Син, Баязитов, дәрес әзерләмичә нишләп урамда йөрисең әле?

—Менә, геометрия китабы кирәгие, шуны эзләп чыккан идем. Үземнеке авылда онытылып калган.

—Хәзер, көтеп тор, алып чыгам, мондый суыкта китап эзлим дип капка санап йөрмә.

Әллә инде китапны куенында йөрткәнме? Икенче чиләге капкаларыннан кереп өлгермәде:

—Баязитов, мә!—дигән тавыш ишетелде.
—Сау булып тор, Алсинә, рәхмәт инде, син булмасан, иртәгә геометриядән,—дип вакытны сузмакчы булам.
Ә ул:
—Хушыгыз, Баязитов,—дип капкаларын ябып та куйды.
Төне буе Алсинәнең геометрия китабын укып чыктым. Йә тумбочка өстендәге лампочка янып төшәр, йә үзем сүнәм... Үзем сүнгәнмен. Җәелмәгән урын өстендә киемнәр белән эреп киткәнмен. Уяныргa ашыкмый идем әле, көтмәгәндә йөземә мендәр килеп төште. Мин аны-моны абайламыйча тотып аткан мендәр дә кемгәдер тиде бугай, аны да кемдер ай-вайлап бүтәнгә тотып орды. Ул арада әле бер, әле икенче якка әллә ничә мендәр очты—кемгә һәм ничек тисә дә барыбер инде, тик мендәр очуы гына дөрес булсын. Күпләребез мендәрен югалтып уеннан чыга барды. Минем кулда да буш сүрү генә калган иде, шуна күрә, эш юктан эш булсын дип, ишек янында сакта тордым. Иртәнге мичкә ягарга утын күтәреп кергән тәрбиячебезне күргәч малайларга кычкырдым-кычкырдым—тик ишетмәделәр.
Соңгы мендәр, утын күтәреп кергән тәрбияче әбине бәреп екты. Уен кырт өзелде, шау-шу көне буе тукталмас кебек иде—бер мизгелдә тынлык урнашты. Һушына килгәннәребез мендәребезне тутырырга дип ашык-пошык идәннән мамык җыя башлады. Мин ары чаптым бире чаптым, әмма мендәр сүрүемә салырга бер уч мамык тапмадым. Куркудан чамасыз күп төйгәннәрдер—мина калдырмаганнар.
Әбиебез чәчелгән утынын да җыймыйча чыгып китте...
Сырмаларыбызның эчен йолыккалап мендәр тышларын бераз кабартсак та җәзадан котылып булмады—минем ише биш малайны бер атна буена киногa җибәрмәскә, урамга чыгармаска, дип әмер бирелде.
Бердәмлек дигән нәрсә көчле бездә, анысы. Ни өчен әле “мендәр сугышы” өчен бишебез генә җавап тотарга тиеш ди?.. Калганнарыбыз да урамга чыкмас булды. Бер кич утырабыз, ике кич утырабыз бик астында... Өченче көнне Муса Җәлилнең Моабит шигырьләрен кычкырып укыйсы килә башлады.

> Соңгы җырым палач балтасына
> Башны куйган килеш языла...

Без, малайлар, ялгыз гына йөргәндә ничава болай. Ә инде бер тирәгә җыйналсак, әллә кайдан арабызга маймыл килә дә керә, керә дә безне үрти, этлеккә өйрәтә, котырта, әтәчләндерә.
Бер атна буе йозак астында уйланып яткач шундый нәтиҗәгә килдем—холкыбыз-фигылебезгә караганда уку елы беткәнче интернат сакларга туры киләчәк безгә... Әле алда нинди җәзалар көткәнен кем белгән?! Хуш, тимер караватым, сау бул, буш мендәрем, газиз башкайларымны сина бүтән салмам...
Хәзер, Зәет Сәетовичка ияреп, көн саен чаңгы белән килеп-китеп йөрим.
Расписаниеләрдә физкультура гел беренче сәгатькә куела, минем ике авыл арасын килүем дәрескә чутлана, өйдән берәр сәгать соңрак чыгарга була дигән сүз.
Вакыт кына житми.
Зәет Сәетович артыннан йөгереп барам, анардан калышмаска тырышып кайтам.
Алсинәләрнең өй түрен таптарлык та ара калмый.
Ул кыз гел күз алдымда минем.
Кайсы гына дәрескә керсәм дә: һәр кагыйдә, формула, закон һәм теоремада Алсинә бар! Әгәр укытучы, эндәш сүзләр җөмлә уртасында ике яктан да өтер белән аерыла дисә, мин Алсинәне кино карап утырган жирендә ике як күршесеннән зур өтерләр белән аерып куям. Формула дигәннән $A^2 + B^2$ дигән формула охшый мина—Алсинә плюс Баязитов—матур яңгырый, әйеме? Квадратларыбыз ничек буладыр, анысын иркенләбрәк уйлап карыйсы бар. Закон мәсьәләсендә Алсинә теләсә кайсы законга да сыя. Физиканың соңгы дәресләрендә гел Архимед законнарын күз алдыма китереп утырдым. Алсинә зур сыеклыкка—Түен елгасының киң төшенә сикереп төшә, ә як-якка Алсинә зурлыгындагы дулкыннар йөгерешә... Җәй генә житсен, ул дулкыннарны туйганчы кочарбыз әле. Жирнең тарту көче турында Ньютон бер дә юкка гына баш

ватмаган, дөрес бит, әй, Алсинә булган җир мине гел үзенә тартып тора... Ә геометрия! Ул гел Алсинә турында гына язылган бугай. Һәр теорема да дөп-дөрес исбатланган... Ике нокта арасында бер генә туры сызык үткәреп була... Әйе шул, Алсинәләр өе белән интернат арасында бары тик минем сукмак кына булырга тиеш. Исбатларга кирәксә, теләсә кайсы егеткә исбатлап күрсәтермен... Алсинәне ныграк белер өчен тизрәк укыйсым килә.

Ә әлегә, тәнәфес саен юк сәбәпне бар итеп: җиденче "А" пунктыннан җиденче "Б" пунктына барып җитәргә, кара-каршы бәрелешмичә һич югы янәшәсеннән генә булса да үтеп китәргә!

Ә беркөнне кояш чыкмады...

Ишегалдында капканны эзләп табарлык түгел—буран күзне сылый. Көчхәл белән Зәет Сәетовичларның өй түренә барып бастым. Дөресен генә әйткәндә, мин бүген аның: "Мондый буранда юлга чыгып тормабыз",—дигән сүзен ишетер өчен килгән идем. Дөнья хәлен белеп булмый, дигәндәй, әни мине кызганып озата килде. "Шушындыйлар итеп интегепләр алган белемеңнең игелеген күрергә язсын", ди. Мәҗбүри уку хакында башкача ни әйтәсең инде...

—Син кал,—ди Зәет Сәетович,—мондый буранда дәрескә килми калсаң да гаеп түгел. Мина карама—мин эш кешесе, әгәр буран чыккан саен прогул бирә башласаң коммунизмны кем төзер?!

Мин өйдә калыр идем дә, тик Зәет Сәетовичны юлга үзен генә чыгарасым килми. Аннан Алсинәләр ни әйтер? Әле буранның тиз генә басылып куя торган гадәте дә бар. Классташлар икенче кыш җиткәнче үртәп йөрерләр: аяз көнне бураннан куркып өендә калган, дип.

Әнинең күз яшьләре юеш карга әйләнеп күз төбенә ягыла, әйтерсең мине соңгы юлга озата... Түзмәдем, чаңгыларымны салмыйча гына әнием янына килдем дә аны кочаклап күз төбендәге тозлы кар бөртекләрен үбеп алдым... Ник болай сагышлы соң ул бүген?..

Зәет Сәетовичның чаңгысына тагылып дигәндәй барам, аның пырыш-пырыш борын тартканы ишетелә, үзе сирәк-мирәк кенә артына борылып мине барлый. Дустайны чыгып текә тауны менүгә буран тагын да көчәйгән кебегрәк булды, битне кычыткан белән чаккан шикелле итә, туры карап барырлык түгел. Ичмасам, ботинкам чаңгыдан чыгып интектерә. Аны яңадан эләктергән арада Зәет Сәетович ун-унбиш метр киткән була. Көчкә куып җитәм үзен. Чаңгы ычкынган саен, укытучы кешегә: "Туктагыз инде!"—дип, һаман кычкырып та булмый.

Зәет Сәетович юлны ничек чамалыйдыр—анысы башка сыймый. Мин ияреп барырга риза... Бераздан ул да туктап калды.

—Кайсыбызның сәгате дөрес? Минеке нишләптер тугыз тулып килә,—диде ул аптырап.

—Минеке дә шулай.

—Кызык, әллә кайчан Табылдыкка килеп җитәргә тиеш идек бит инде без.

—Адаштык микәнни, абый?

—Әллә куркасың?

—Юк, кире кайтып китик, интегеп йөрмик, дип кенә әйтүем.

—Кайтыр юлыңны таба алгач, адашу буламыни ул?!—диде Зәет Сәетович елмаеп.

Аның елмаюы мина да көчте.

—Себердә яшәмибез лә, абый, барыйк та барыйк, берәр авылга чыгарбыз әле. Тик басып торгач буран куенга керә.

—Өермә буран кешене бер тирәдә бутап йөртергә дә мөмкин. Юлны турырак тотарга тырышыйк.

Кузгалып биш-ун минут киттек микән, тагын чаңгым ычкынды. Бу юлы икенче аяктан... Үземчә тиз генә каптырган кебек идем... ул арада чаңгы эзе күмелгән, Зәет Сәетович юкка чыккан. Кайсы якка киткәнен чамалап адымнарымны тизләттем. Барам да барам, ә укытучым һаман саен күренми. Ярты сәгатьләп бара торгач, кычкырып та карадым... Тик җавап бирүче генә юк.

Минем сәгать белән тагын ике сәгать атлый торгач, сыерлар кычкырган тавыш ишетелде! Сөенечтән тәнемә яна сауган сөт җылысы йөгерде;

Мин бер генә өйне күрдем—ишегаллары капкасыз, йөзлегенә буяу тимәгән тәрәзәләре җирдән хәтсез биектә—буй җитәрлек түгел, түбәләре такта... Башка

йортларны күрерлек түгел, шулай да чит авыл икәнен әллә каян тоеп торам.

Чаңгы таягы белән үрелеп кенә тәрәзәләрен шакыган идем, өй эченнән аңлаешсыз мыгырдаулар ишетелде. Хуҗаның озак чыкмавыннан сабырсызланып өйләренә кереп киттем. Тыштан ап-ак мамык өеменә охшап торса да, өй эче яңгырдан каралган такта түсендә иде.

Безнең Дустайдан сигез чакрымда гына Ямиташ авылы барлыгын ишетеп белә идем, тик монарчы барып күргәнем юк иде. Күрдем...

Ар җиңгие белән көч-хәл аңлаштык: ул татарча, мин арларча белгәннәремне әйтә торгач шунысын аңладым, биш өй аркылы гына мәктәпләре бар икән.

Мәктәп сүзен аңлап алу белән бөтен арганнарым гәүдәмне берьюлы басты... Керосинкада җиңгинең чәе кайнап чыкты. Күмер түсенә кергән чуеннан, тавыкларга дип пешерелгән бәрәңгене калай мискәгә салып, өстәл өстенә китереп куйгач, миңа көч керде. Кыстаганнарын да көтмичә бәрәңгегә ябырылдым.

Ямиташның мәктәп дигәннәре, бездәгечә, утынга сүтеләсе бер өй иде. Бер өйдә ике малай укып утыра. Укытучылары мине бәрәңге белән сыйлаган җиңгидән дә картырак. Фамилиясен Вахрушева диде. Чәче аксыл кызгылт төстә, алсу йөзендәге шадралары ясмык төйгән куна тактасы шикелле. Елмайганда кисәк кенә егерме яшькә яшәреп киткәндәй була. Аның белән русча сөйләштек. Әлеге ар малайларының берсе өченчедә, берсе дүртенчедә укый икән. Вахрушева түти: "Утыр әйдә, сине дә укытам",—ди. Утырып сумкам эчендәге карны бушаткач, көндәлегемә бүгенге мажараларны яздым да куен кесәмә салып куйдым.

Мин караңгы төшкәнче үзебезгә кайтып китәм, бераз хәл генә керсен дә... Зәет Сәетович кайтып минем юклыкны әйтсә, әнием нишләр? Дустайның кайсы якта икәнен чамалыйм, юлны туры тотыбрак атлармын. Буран басылганны көтсәң, бәлки ул өч көнсез туктамас.

Көндәлегемне язып, Вахрушева белән хушлаштым да тагын чаңгыларымны кидем. Көпшәк карга чаңгылар нык батса да эзем калмый, шундук буран күмеп бара. Шунысы рәхәт—җил унаена атлыйм. Бер сәгать чамасы үткәч, чаңгыларым җинеләйгән кебек тоелды—тау төшәм. Бу—ике авыл арасындагы олы ерганак иде.

Кинәт ерганак төпкеленнән кыргый этләр өргән тавыш ишетелде. Алар күбәү—бик күбәү иделәр һәм тавышлары миңа иярде. Күңелем котылгысыз хәвефне сизенеп, буранны бөтенләй тоймас хәлдә идем. Этләр өрүе һаман саен якыная бара. Аларның кешегә үчләре бар. Кыргый этләрдән котылырмын димә! Безнең якта адашкан кешене эзләп тапканнары юк әле. Бу этләргә кемнәр генә юлыкмаган һәм тагын кемнәр юлыгыр икән? Алар мине куып килә. Әгәр кар өстендә чаңгысыз калган булсам, мине ике сикерүдә куып җитәрләр иде инде. Ерганак яры текәләнде бугай—чаңгыларымны тыяр хәл юк. Аягымда чак басып торам. Менә, чаңгымның берсе көрткә төртелде, икенчесе читкә каерды. Мәтәлеп китеп кулбашым белән бер агачка килеп бәрелдем. Агач! Кочагыма сыярдай гына каен агачы мине үзе күтәреп алды бугай. Кәрлә, кәкре, карт каен гына булсаң да нинди көчле син каеным! Әнә ул этләр минем сумкамны ботарлый. Китапларымны, буран алып китте. Көндәлегем генә куен кесәмдә калды... Каен төбендә кыргый этләр өрә, әле ярый, табигать сезне агач башына менәргә өйрәтмәгән... Сез минем егылып төшкәнемне көтеп котырасыз. Тәнемдә кан җылысы бар чагымда мин бу каенны кочагымнан чыгармам. Мине өйдә газиз әнием көтә, мин әнигә бик кирәк, мин аның соңгы улы.



**Рәшит Гариф**

## СӨЙЛӘДЕ ҖИЛЛӘР

***

**Яшел болын... Шушымы соң
Шәһре Болгар урыны?
Тургайларның күп гасырлык
Әллә сагыш җырымы?**

**—Саумы, Болгар!—дип әйтүгә
Кисәктән исте җилләр.
Бездән озын-ерак чорның
Төенен чиште җилләр...**

**...Шул мизгелдә Болгарымда
Кешнәшеп чапты атлар.
Соңардым ничә гасырга—
Кемнәр соң илне саклар?**

**Ишетәм: елый сабыйлар,
Идел-йорт камалышта.
Сызгырып оча сөңгеләр,
Кан буяла кылычка.**

**...Ялмады ялкын каланы—
Әйләнде хәрабәгә.
И Ходам! Мондый вәхшәтне
Күрсәтмә берәүгә дә.**

**Сөйләгез, җилләр, сөйләгез
Болгарның соңгы көнен.
...Өйрәнеп үссен оныклар
Якларга туган җирен.**

Рәшит ГАРИФ (1933) — *шагыйрь, прозаик, публицист; "Кояш чыгар алдыннан", "Инану", "Көт мине, Гөлчәчәк" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Болгарымда дога кылам—
Җитте өйлә намазы...
Колагыма җил пышылдый—
Ерак бабам авазы.

## Кабул кыл...

Иртән дә күрдем, кичен дә
Төркем-төркем халыкны:
Ил картлары—түбәтәйле,
Әбиләр—ак яулыклы...

Яшел чирәм—намазлыкта
Укыйлар изге дога.
Тыңлар өчен азан моңын
Болгарда Кояш чыга...

Сибелгән кичке җилләрдә
Бу илнең кайгы-зары...
...Үсә монда чирәм генә—
Шушыдыр зиратлары...

## Бөркет авазы

Басып торам таңда Казансуның
Кыртлач-кыртлач текә ярында...
Иске Казан монда җәйрәп яткан—
Ерак тарих бүген каршымда...

Офыкларны бизәп кояш чыккан,
Илләр белән илләр кавышкан.
Су буенда кичен нугай углы
Казан кызы белән танышкан...

Уйларымны кинәт бөркет бүлде,
Аваз салып күкләр катыннан.
Нигә икән шулай өзгәләнә,
Очып килгән монда кай яктан?

Торып-торып тагын кычкыра ул,
Чакыра күк мине ярдәмгә.
Туздырылган оясынмы эзли,
Ни әйтергә тели адәмгә?

Нинди газап борчый бу бөркетне?—
Югала да кайта әйләнеп.
Җир йөзеннән нигә юкка чыккан
Иске Казан—шанлы пайтәхет?

Кош авазы бәгыремне өзә...
Илен җуйса, кем дә зарланыр.
Халык, димен, уяулыгын җуеп,
Бөркет хәлләренә калгандыр.

Ул бөркетне нинди газап борчый,
Нинди кайгы шулай тетрәткән?
...И татарым, синең бар тарихың
Кара кандай ага йөрәктән.

## Сагыну

Исендәме ул язгы төн?—
Йолдызлар балкып янды.
Шул чакның сүнмәс бер уты
Күңелдән янып калды.

Күңелдә мәңгегә калды
Шул яз сандугачлары.
Сөйләшеп яфрак ярдылар
Төн буе агачлары.

Уянды авыл, уянмас
Кебек тоелган иде.
Борнаган нәни үләннән
Чыклар коелган иде.

Кая ул сөйләшеп тую
Төннәрнең кыскасында.
Иң кирәклесе турында
Сүзне башладык кына.

Кулыңнан алырга кыймый
Тордым бер бала сыман,
Күкләргә ашарлык булып
Шул якты карашыңнан.

Шундый төн, шундый табигать
Җанымны сихерләде.
Авыр—ул төннең кабаттан
Булмасын белүләре.

## Ышанам

Лирага

Упкынга очтым дигәндә
Суздың миңа кулыңны.
Бордың да куйдың Кояшка
Минем барыр юлымны.

Ышандым сиңа. Аңладым
Мин ихлас сүзләреңнән.
Дөреслеген ул сүзләрнең
Укыдым күзләреңнән.

Сулып барган йөзләремә
Алсу төс кабат кайтты.
Сиңа булган ышанычым
Артты, тагын да артты.

Мин ышанам син булганда
Канатым сынмасына,
Иртәгә дә шат елмаеп
Кояшым чыгасына...

Адаштыра алмас безне
Куе карурманнар да.
Бергә булсак, югалмабыз
Зәмһәрир бураннарда.



## Хәнәфи Бәдигый

# ЯРАН ГӨЛЕ

### Әнкәйләргә бүләккә

Торасы иде бит сезгә
Рәхмәтләр укып кына,
Затлы сүзләрдән бүләккә
Келәмнәр тукып кына.
Матур көйләр язасы иде
Илаһи авазлардан.
Бүләк булсын иде сезгә
Сандугачлы язлардан.
Бөтен матур чәчәкләрне
Сезгә бирәсе иде.
Их, күзләрегездә фәкать
Шатлык күрәсе иде.
Гел изгелек кыласы иде
Сезнең хакларны хаклап.
Көрәшәсе иде фәкать
Сезнең хаклыкны яклап.
Җир-ана дигән сүзләрне
Һәркем аңласын иде.
Балалар Ходай хакына
Сезне тыңласын иде.
Тыңламаганнары күп шул:
Ана хакын ташладылар:
Йөзләрегезгә кызыллык
Китерә башладылар...

Сызылып алсу таң атканда,
Кичен кояш батканда,
Дисбе төймәләрен тартып,
Намазлыкка басканда,
Шатлык эчләрендә яшәп,
Имин булсагыз иде,
Балам тәүфыйклы булсын дип,
Дога кылсагыз иде.

Хәнәфи БӘДИГЫЙ (1941) — *әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты; "Абага чәчәге", "Күңел ялкыны" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Онытылган дисбе

Дисбе төймәләре акты
Ак җеп буйлап,
Чишмә булып акты
Туктаусыз.
Тормыш-язмышлардан
Зарланмыйча,
Уфтанмыйча акты,
Сыктаусыз.

Күпме изге теләк,
Ялварулар
Әйләнде шул дисбе эчендә.
Үзе өчен генә түгел,
Әйләндерде әнкәй
Безнең өчен дә.

Яу кырында калган
Ир-этигә,
Җиде буын әби-бабайга,
Ярлыкауны,
Оҗмахларны сорап,
Ялварды ул фәкать
Ходайга.

Ә бервакыт,
Мәңгелек юлдашы,
Онытылып калгач,
Авылда,
Шул җәйдәге кебек
Борчылганы
Булмагандыр
Һичбер давылда.

Кайтып эзләсәм дә,
Тапмадым бит,
Буш кул белән килдем
Әйләнеп.
—Хәерлегә булсын,
Ярар,—диде
Һәм тормады
Һичбер бәйләнеп.
Фани дөнья белән
Бәхилләшеп,
Мәңгелеккә китте
Шул җәйдә.
Ә юлдашы исә
Качып калган—
Уйламаган
Аулак бер чөйдә.

Ак җәсәден аның
Озатканда,
Җил елады,
Ятып, юл буйлап.
Дисбе төймәләре,
Сыктый-сыктый,
Минем кулдан акты,
Белмим, ни уйлап?

## Төш

Юраган, юралмаганы бар
Без күргән төшләрнең.
(Йөргәне—җитәлмәгәне бар
Шул йөргән төшләрнең...)

Сак кына кадерләп алгандай,
Үсемлек төшләрен,
Оста юрады әнкәйләр
Балачак төшләрен.

Сөйләтә җай белән, күргәнчә,
Шул татлы төшләрне.
Алайса, ашарсың, дигәндәй,
Бавырсак, төшләрне.

Чатаклык булганда, тыңлагач,
Азакта—төш беткәч;
Туктата, сөйләрсең, дип кабат,
Хәтерләп, төш җиткәч.

Кабатлап сөйләгәч, әйтә иде:
—Мәгънәле төш хәзер.
Икенче, төш күрсәң, хәтерне
Көчәйтә төш, бәгырь.

—Хәтерлә, уяу бул,—ди иде,—
Күргәндә төшеңне.
Яхшыга юрарга онытма
Күргән бер төшеңне.

Кайчакта әле дә, ялгышып,
Мәгънәсез төш күрсәм,
Шул чакта, хәтерләп, әнкәйне,
"Төшемне өшкерәм".

## Вакыттан кыйтга

Вакыт елгадай ага,
Тамчы булып та тама.

Кирәк түгел аңа яр,
Һәртөрле яр—аңа тар.

Сала алмассың савытка,
Йә булмаса—су, утка.

Челтери чишмә булып,
Сайрый ботакка кунып.

Йөрәк булып та тибә,
Сабый булып та имә.

Булмый аны йөгәнләп,
Игә килми игәүләп.

Хәер, үзе йөгәнли,
Һәммәбезне игәүли.

Агыла көй булып та,
Тузгыла көл булып та.

Сатылмый ул акчага,
Үстерелми бакчада.

Вакыт узар кайда да,
Узсын ул тик файдага.

Бүлеп бирелгән безгә
Төгәл—Ләүхелмәхфүздә.

Бүленгән итагатьләп:
Минутлап һәм сәгатьләп,

Атналап, айлап, еллап,
Тик бирелми кабатлап.

Син аны узалмыйсың,
Артка да калалмыйсың.

Кеше әзли, нигезли,
Вакыт барын тигезли.

Ике дөнья арасы—
"Ә" дигәнче барасы.

Вакыт—Ходай кулында,
Без—кол Аның юлында.

Вакыт безгә—еш—җитми,
Аның һич исе китми.

...Карасаң бер—галәмгә,
Вакыт узмас әрәмгә.

Вакыт узгач, күчәр әз,
Төялешеп арбасына
Мәңгелеккә күчәрбез.

## Яран гөле

Тәрәзәләр нуры, яран гөле,
Сагынасыңмы туган илеңне?
Мин юатыр идем, гөлем, сине,
Әгәр белсәм серле телеңне!

Исми бездә йомшак диңгез җиле,
Зәңгәр киңлекләр дә күренми.
Бер кабынган сөю, сагыну хисе
Сулар сибеп кенә сүрелми.

Тәрәзәләр нуры, Кейптаун гөле,
Сагынасыңмы туган илеңне?
Мин юатыр идем, бәгърем, сине,
Әгәр белсәм назлы телеңне!

## ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШ

*Бу исталек язмалары кемгәдер аерым бер кешенең карьера биографиясе генә булып тоелырга мөмкин. Шулай караганда да оялырлык түгел үзе: карьера да шәп, биография дә кызыклы гына. Ә инде бу берәүнең гомере татарның үткәнендә эз калдырган шәхесләрдән, XV гасырдан ук сузылган шәҗәрә җебенең дәвамы булуын уйласаң, язманың мәгънәви кыйммәте нык арта.*

*Назиф әфәндене хезмәт биографиясен аңлау өчен дә аңа ошбу шәҗәрә аша күз салырга кирәк икән. Яңа гына институт тәмамлаган яшь-яшь егет катлаулы шартларда ничек итеп үзеннән күп өлкәннәрнең, тәҗрибәлерәкләрнең ихтирамын казана? Үсеш баскычлары аша ничек шулай йөгереп-атлап үтә алган ул? Совет мәктәбе һәм совет вузы биргән белем-тәрбия тәэмин иткәнме моны? Нигә алайса шундый ук мәктәптә укып, автор белән бер үк институтны тәмамлаган кешеләрнең язмышлары башкачарак корыла?*

*Хикмәт, бәлки, тирән вә көчле тамырлардадыр. Буыннан-буынга тапшырылган кан аша, нәсел үзенчәлекләре аша Гираят бинең олпатлыгы, Хәсәннең үҗәт тырышлыгы, Нугайбикнең гайрәтлеге, Миргарифанның яңалык һәм хезмәт сөюе, Мөҗәһиднең булдыклылыгы, еллар-гасырлар аша сузылып, аңа гел ярдәм күрсәтеп торадыр. Җитәкче кеше өчен һич тә артык булмаган күркәм йөз-чырай белән олпат гәүдә—монысы инде һичшиксез әби-бабалары бүләге.*

*Совет чорында безне шәҗәрә җебеннән кисеп калдырырга, хәтерне корытырга тырыштылар. Тамырларыннан өзелгән бер дүңгәләк—җил-үлән сыман җил уңаена теләсә-кайсы тарафка тәгәрәргә әзер милләттәшләребез азмы безнең?*

*Назиф Мирихановның кечкенәдән үк шәҗәрәләренә ялгануы, соңрак аны мөмкин кадәр шәбрәк, фәнни кимәлдә өйрәнергә омтылуы, соңгы егерме елын Мәскәүдә яшәп тә, татар рухлы балалар үстерүе сокландыра.*

*Инде шунысын да әйтик: Назиф Мөҗәһидән улы Мириханов хәзер—татар язмышының алгы сызыгында. Ул—Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы Вәкиле.*

*Биографик язмасын укучыларыбызга тәкъдим иткәндә, без аны авторның "Нәсел" дигән икенче бер хезмәтеннән өземтәләр белән "сипләргә" булдык.*



**Назиф Мириханов**

## ХЕЗМӘТ ТӘМЕ ЯКИ ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ

### Бер кәлимә кереш

Тормыш дигәнең ул—буыннар алмашыну, буыннар диалогы, өлкәннәрнең яшьләргә үз тәҗрибәләрен тапшыруы. Әмма һич төкәнмәс кыенлыклар нәкъ менә аталар һәм балалар, өлкәннәр һәм яшьләр арасында туа. Хәзер, фәнни-техник

алгарыш, глобальләшү һәм реформалар чорында ошбу каршылыклар аеруча үткенләште. Өлкәннәр, ничек кенә тырышмасыннар, тормыш көенә, үзгәртеп корулар адымына житешә алмыйлар, һәм дә яшьләр аларны аңламый башлый. Яшьләр исә заманга хас бөтен нәрсәне шундук эләктереп алалар һәм киләчәккә... шөбһәләнеп карыйлар.

"Хезмәт тәме"н язу теләге балаларым һәм туганнан туган кардәшләрем үсеп житеп, мөстәкыйль юлга аяк басканда, мөнәсәбәтләр акыл өйрәтү, вәгазь уку рәвешендә корыла алмый башлагач туды. Начар заманнар булмый, дип әйтәсе килде үзләренә. Чынлыкта бары безнең заман, безнең тормыш кына бар. Беркем дә үзенә асыл дәвер сайлап ала алмый. Бер тәгаен заманда үз гомеренне тиешенчә, жиренә житкереп яшәү өчен мәңгелек кагыйдәләрдән чыгып эш итәргә кирәк. Ягъни адәм заты бары тырыш хезмәт аша, үзенә салынган сәләтне гамәлгә ашыру аша гына яшәешен тәэмин итеп, үз шәхесен ача ала.

Шул җәһәттән караганда, минемчә, һәрбер кешенең, бигрәк тә ир-атның тормышы, тәҗрибә буларак, яшьләр өчен кызыклы һәм гыйбрәтле.

*ШӘҖӘРӘ ЖЕБЕ*

*Без кемнәр соң? Без каян килгәнбез?—Бәләкәй чактан ук кызыксындыра башлаган сораулар бу. Шулар белән Миргарифан бабама[1] да тынгылык бирмәдем. Хәер, мондый сораулар аның күңеленә хуш килә торган иде, йөзләре үк балкып китәр иде. Шундый мәлләрдә ул мине, читән тарантаска утыртып, Чалпы[2], Карповка[3] авыллары тарафына, күпер аша Ыкның икенче ярына—аръякка, әрәмәлек-тугайларга алып чыга иде, бабаларыбыз рухы сеңгән урыннарны күрсәтеп, тарих томаны белән өртелгән заманнарны бәян кыла торган иде. Көймәдә ау карарга барганда да күп нәрсәләрне минем яшь хәтергә уйдырып калырга тырышыр иде. Мин бөтенесен дә аңлап та житкермим, әлбәттә, бәләкәй башымда төрле-төрле исемнәр, атамалар, вакыйгалар болгана, бутала башлый, әмма бер өлеше барыбер дә хәтер киштәләрендә урнашып кала инде.*

*Шул рәвешле, нугай бие Гираяттән алып аның шаңлы токымы Нугайбиккә кадәрге чорны колачлаган, Гираят би шәҗәрәсе дип атап йөртелгән шәҗәрә барлыгын кечкенәдән үк белә идем инде мин. Нугайбикнең оныгының оныгы булган Миргарифан бабам, ягъни әтинең әтисе, үзенә мәгълүм нәрсәләрне терки барып, шәҗәрә агачының үз тармагын үстергән. Төрки халыкларның белемле катламнары өчен элек-электән килгән галәти бер эш бу. Бабаларыбызны, нәсел шәҗәрәңне белү мәдәнилек билгесе булып саналган. Бер-берсе белән танышканда алар иң әүвәл нәсел-нәсәбен сорашканнар...*

## Юл сайлау

1966—69 еллар.

Балачакта мин сәяхәтләр турында хыяллана идем. Шуңа күрә дә киләчәк тормышымны геологлар, эзләүче-эзләнүчеләр арасында күрә идем.

Үсә төшеп, хәрби комиссариатларда ел саен комиссия үтә башлагач, андагы офицерлар, физик күрсәткечләремә карап, мине хәрби училищега керергә кыстый башладылар. Римат Райханов[4] белән без Юрий Гагарин укып чыккан Оренбург очучылар мәктәбенә керергә ниятләдек. Үрнәге бар иде. Бу—безнең урамның Нил Гафиуллов, хәрби очучы булып алгач, ул һәр җәйне авылга матур хәрби формадан кайтып төшә торган иде. Диңгез авиациясендә хезмәт иткән Нил абый сөйләвенчә, аларның самолетлары, умарта кортлары ояларыннан чыгып очкан сыман, диңгез өстенә тау куышындагы аэродромнан очып чыга икән.

Римат миннән бер класс алдарак укыды, шуңа күрә Оренбургка минсез генә китеп барды. Училищега ул Чапаев академиягә кергән кебегрәк имтихан тота: турникта күтәрелүне дә (11 тапкыр кирәк), пресс тотуны да (18 секунд)—бирә. Ә менә математиканы тапшыра алмый. Без физик нормативларны каяндыр белеп алган идек, шуңа күрә алдан ару гына шөгыльләнгән дә идек. Төп сынау шул дип уйлап, фәннәргә тиешенчә әһәмият бирмәгәнбез...

[1] Мириханов Миргарифан Мирихан улы (1903—1977)
[2] Татарстанның Азнакай районы
[3] Башкортстанның Бакалы районы
[4] Исем-фамилия үзгәртелгән

Дингез флотында сигез еллап хезмәт иткән дингезче әти[1] исә мине Нахимов хәрби-дингез училищесына керергә күндерде. Хезмәтен тәгәлләгәч, аңа офицер исеме бирмәкче һәм хәрби академиягә укырга җибәрмәкче булалар. Сугыштан соңгы елларда гадәти хәл була бу. Әти исә баш тарта, туган ягына, сөйгән кызы янына кайтып, авыл хуҗалыгында механик булып эшли башлый. Әмма гомере буе үзенең дингездә үткән яшьлеген сагынып искә ала торган иде.



*Назиф әти-әнисе белән. 1954 ел.*

1967 елның язында, хәрби училищега керү өчен кирәкле документларны сорап кәгазь килеп төшкәч, өйдә әни[2] катнашында "консилиум" үтте. Әни безнең планнарны пыран-заран китерде дә куйды. Хәер, минем мона әлләни кәеф кырылмады үзе. Күз житкәч, тыныч кына тугызынчы класска укырга киттем.

Өлкән классларда укыганда әтинең эшенә дикъкатьләбрәк күз сала башладым. Бу вакытта ул инде "Татсельхозтехника"нын Тымытык филиалы житәкчесе иде. Җәйге каникулда Индус Әгъләметдинов белән МТСка (машина-трактор станциясе—"Сельхозтехника"ны халык шулай искечә атап йөртә иде) эшкә кердек. Һәркайсыбыз, рамнан башлап, тар чылбырлы бер Т-38 (КДП) тракторы җыйды. Мотордан тыш бөтен агрегатлар, узелларны да үзебез җыйдык, хәтта тизлек тартмасын да. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, мин тартманы җыйганда детальләрне бутаганмын, тракторым алга барасы урында—артка, артка барасы урында алга таба хәрәкәт итә иде. Кабинаны алып куеп, тартма эчен механик ярдәмендә җыясы булды. Шул рәвешле мин әти һөнәрен үзләштерә башладым. Әтине "Сельхозтехника"да ихтирам итәләр иде. Хәтта куркалар да иде үзеннән. Әти техниканы искиткеч шәп белә, иң катлаулы төзексезлекләрне дә шундук сизеп ала, моторның яисә башка бөтен агрегатларның да "чиренә" "диагнозны" тавышы буенча гына куя. Мин авыл хуҗалыгы институтының механика факультетында укып чыгып әтинең "фирма"сына кайту, аның эшен дәвам итү фикеренә күнә дә башлаган идем инде. Династия була бит, кызык! Әмма, безнең планнар әнигә мәгълүм булгач, алар бу юлы да чәлпәрәмә килде. Әни, бөтен авыл механиклары да эчкечеләр бит алар, эшләре дә кызыксыз, дөнья бетереп запчасть эзләп чабудан башлары чыкмый, дип ярып салды. Тагын бер авыл хезмәткәре гаиләсенең җәфа чигүен теләмим, дип тә өстәде әле.

Кем булыйм соң инде алайса? Берәм-берәм һөнәрләрне күздән кичерәм. Завод эше батмый—көн дә бер капкадан кереп түбә астында, һаман бер хәлдә кыймылдыйсың. Әле тегендә, әле монда йөреп ачык һавада эшләсәң иде ул. Нинди эш була ала соң бу? Төзелеш була ала!—Калак кагу белән чокыр казудан гайре берни аңламаганга төзелеш мәйданнарындагы ыгы-зыгы мина олуг тәртипсезлек булып тоелса да. Ниятемә әти белән әни дә каршы төшмәделәр.

Ул чакта авиация институты белән химия-технология институтына керү мактаулы, төзелеш институты исә икенче сортлы уку йорты сыман иде, безнең авылдан ул заманнарда анда кереп укучы булмады. Иң гаҗәбе шул тагын: безнең якта пыр тузып нефть чыгарып яталар, һәркайда вышкалар тезелеп киткән, факеллар дөрләп яна, шәһәрләр төзелә. Нефтьчеләрнең шөһрәтле чагы. Бу һөнәрнең романтикасы төзүченекеннән һич ким түгел инде югыйса. Шулай да нефтьче булу уе башыма да кереп карамады. Олылардан да ничектер андый киңәш бирүче булмады.

Институтка укырга керергә йөк машинасы әрҗәсендә күрше малае Миргазимов Мирмәхмүт[1] белән (без аны Мәхмүт дип кенә йөртә идек) икәү бардык. Беренче кичне Чистайның Колхозчылар йортында кундык. Шул төнне үк Мәхмүт яшь хатынын өзелеп сагына башлады. Ул 10 нчы класста укыганда үзеннән ничәдер яшькә өлкәнрәк, озын тәнәфестә "чибурики" (ачы камырдан ясалган "пончиклар"ны

---

[1] Мириханов Мөҗәһидән Миргарифан улы (1927 – 2001)
[2] Мириханова (Нәбиуллина) Мәфрүзә Миңнулла кызы (1926)

шулай дип атап йөртә идек) сатучы буфетчы кызга өйләнгән иде.

Казанда Фәнис абыйларда тукталдык, ул гаиләсе белән Оренбург трактында, Кабан күле буендагы авыл өенең яртысын биләп яшәп ята иде. Мәхмүт документларын авыл хуҗалыгы институтына бирде дә минем белән яшәп калды, аның бүтән барыр җире юк иде. Әмма, хатынын сагынып кара сагышларга батканга, имтиханнарга җүнләп әзерләнә алмады бахыр. Өстәл янында утырганда кинәт үксеп җибәреп чабып чыгып китәр иде дә, Кабан яр буенда бердәнберен үйлап моңланып, сагышлы җырлар җырлап йөрер иде. Көннәрдән бер көнне Мәхмүтебез, имтиханнар башланганны да көтеп житкермәстән, авылга кайтып китте. Язмыш кочагына ыргылды... Армиядән соң ул хатыны белән аерылышты алар.

Мин имтиханнарга бердәнбер китап буенча әзерләндем. "Татарча-русча сүзлек" дип атала иде ул. Пифагор теориясен һәм гомумән татар мәктәбендә үзләштереп, ВУЗга керү өчен кирәк булган бөтен гыйлемне сүзгә-сүз тәрҗемә иттем, сүзләрне русча әвәләп чыгарырга өйрәндем. Фәнис абыйның хатыны Зәгъфүрән апа, минем хәлемә кереп, әйтелешне, басымнарны дөресләргә ярдәм итте. Файдасы гына бик сизелми иде шул.

Математиканың язмачасын жинел тапшырдым. Телдән дә уңды эш, чөнки анысын да язып тапшырдым. Урысча аңлыйм бит, фикерне кәгазьгә дә төшерә алам. Сөйләгәндә исә акцент коточкыч була. Өстәвенә, "приставкалар, предлоглар, родлар" һәм кушымчалар да гаҗәеп рәвештә бутала... Физиканы бик җайлы бирдем, татар укытучысы туры килде чөнки, гравитация законын туган телебездә бәян иттем. Рус телендә иншаны (изложение), хаталар аз булсын дип, ярты битлек кенә итеп яздым. Яшь гвардияче Сергей Тюлениннең фашист штабы урнашкан мәктәпне ничек яндыруын кып-кыска җөмләләр белән тасвирлап бирдем. Алдылар институтка.

24 августта авылда мина унҗиде яшь тулуны һәм укырга керүемне бәйрәм иттек. Әти-әнигә йөргән кызым Розаны күрсәттем. Көтелмәгән хәл булмады инде бу, кинодан кемнең кемне озата кайтканын авылда бөтен кеше дә белеп тора бит.

Икенче көнне мине, яшь-яшь студентны, Казанга озаттылар. Ун яшьлек сеңлесе Әлфияне житәкләп автобус станциясенә Роза да килеп житте, истәлеккә гәзит кисәгенә төрелгән фоторәсемен бүләк итте.

Яшьлек бураннары тузгып торган дүрт елдан Роза минем хатыным булды.

### *ШӘҖӘРӘ ЖЕБЕ*

*Көннәрдән бер көнне Миргарифан бабамны, табигый ки, Нугайбиккә кадәрге бабаларыбыз кем булган соң, дигән сорау биләп алган. Моңа жавапны ул өлкән нәселдәшләребездән тапкан. Нәсел агачыбыз төпкә таба менә болай бара икән бит: Нугайбик—Хәсән—Урсай—Жияш—Истангол—Сарыбай—Бүләк—Аккуз—Арслан—Алганчы—Куганчы—Гираят. Нәсел жебенең Нугайбиктән безнең замангача дәвамы менә болай: Нугайбик—Сәлтәш—Әхмәтхан—Мирихан—Миргарифан—Мөжәһидән.*

*Шәҗәрәбез башында торган Гираят би Нугай урдасының бер нәсел-ыруы башы булган: Ул XV гасырда, Имән калада (булачак Уфа) гомер кичергән. Чын исеме—Гирәй, куплек санны белдергән "ят" кушымчасын өстәп, "Гирәят" дип дәшү—олылау билгесе. Бу ыруның ораны (тотем)—бүре, тамгасы—күз, ыру агачы—юкә, ыру кошы—каз булган.*




## Студентмын

1969-74 еллар.

Баштагы курсларда укуым рус сөйләм телен үзләштерүгә кайтып калды. Семинардагы беренче чыгышымны тыңлаганда группадашларым тәгәри-тәгәри көлде. Мин исә шуннан соң дәшмәс булдым. Бик озак ачылмады минем авыз.

[1] Исем-фамилия үзгәртелгән

Семинар дәресләреннән зачет өчен һәр тема буенча язма рефератлар тапшырам. Имтиханнарны да телсезләрчә генә бирәм. Укытучының соравын ишетүгә шатыр-шотыр яза башлыйм. Мине һәм тагын берничә татар студентын рус теле буенча факультатив дәресләргә йөрергә мәҗбүр иттеләр. Русча авыз тутырып өченче курста гына сөйли башладым.

Баштарак булачак һөнәремнең нидән гыйбарәтлеген һич чамалый алмадым, укыганыбыз югары математика, КПСС тарихы, фәнни коммунизм, физика иде, ягъни гомуми үсеш өчен кирәкле фәннәр. Өченче курстан специальләшү китте: төзелеш механикасы, төзелеш материаллары, бераз соңрак төзелеш эшен оештыру керә башлады. Ләкин һөнәребез барыбер дә чамаланмый иде әле. Формулалар, исәп-хисап, схемалар, сызымнар—уку тек уку инде. Хәтта Зәй ГРЭСында, КамАЗда, эшче булып, геодезия буенча практика үтү, төзү-монтаж идарәсенең эшчәнлеген документлар буенча өйрәнү дә төзүчелек тойгысын уятмады әле.

Төзелеш тәмен тату дүртенче курсны тәгалләгәч кенә насыйп булды. Мине химия-технология институтының бер отрядына мастер итеп җибәрделәр. Отряд командиры, Марс атлы егет, Мөслим районының Түбән Табын авылында механик мастерскойлар һәм терлекчелек фермасы салуга шартнамәләр төзеп кайтты. Мин исә, заказчының биредәге вәкиле Нурулла абый белән килешеп эшләп, төзелешне оештырырга тиеш идем.

Проект төзелеш башланганчы эшләнеп бетәргә тиеш булса да (заказчы вазифасына керә бу), ул юк иде. Аны көтеп торырга вакыт та юк иде инде. Кырык кешелек отряд, мәктәп бинасында урнашып, эш көтә иде. Максат—ике ай эчендә мөмкин кадәр күбрәк акча төшерү. Һәрхәлдә, башка отрядларныкылардан ким булмаска тиеш. Шундук төп көчне Ыкның аръягындагы тауга, таш карьерына җибәрдек. Егетләр бер таннан икенче таңга кадәр эшлиләр. Кувалдалар, ломнар белән ватып, трактор арбаларына төп стена материалы булачак ташны төйиләр. Борынгы Рим коллары хезмәтен хәтерләтә иде бу күренеш. Эштән кайтуга ятакка ава иде егетләребез... Ашатуын шәп ашаттылар үзләрен. Колхоз ит белән бәрәңгене җәлләмәде, отряд кызлары, кыен шартларда эшләп тә, кулинария сәнгатенең иң югары үрнәкләрен күрсәттеләр. Иртәнге ашны өлгертер өчен аларга иртәнге өчтә, таң әтәчләре белән үк торырга туры килә иде.

Өч көн дигәндә мастерскойларның проекты әзер иде инде. Әүвәл колхозга ни кирәген ачыкладым, шуны кәгазьдә гәүдәләндердем, тиешле кешеләр белән килештереп, колхоз рәисеннән раслаттым. Шуннан соң отрядның бер өлешен нигез салуга куйдык. Фермага исә проект хаҗәт булмады. Асылда бу хан заманында салынган стеналарны һәм түбәне янарту—капиталь ремонт ясау иде. Колхоз прорабы безне койма тоту, һәйкәл штукатурлау кебек башка төрле эшләргә дә җәлеп иткәли иде.

Керәсе акчаны чамалап карагач, уйга калдым. Аз чыга иде. Өстәмә договор буенча күрше Туйгилде авылында "Трудовик" хуҗалыгы өчен гараж салу да хәлне җинеләйтми иде. Исәп-хисабымны командирга күрсәттем. Ашыгыч рәвештә төшемлерәк эш—шабашка эзләргә кирәк иде. Марс үзенең командирлык вәкаләтләрен миңа күчерде дә, мин шәһәрләр һәм авыллар буйлап "озын акча" эзләп киттем.

Мөслимгә, зона отрядыбызга да сугылдым. Аның командиры, миннән ике-өч яшькә генә олырак, төптән юан чыккан, әмма шактый елгыр егет, мине әтисе өендә кабул итте. Үзләренең йорт-кураларын, хуҗалыкларын күрсәтте. Бар да төзекныклы иде. Мина бигрәк тә умарталары һәм умартачылык җиһазлары ошады. Бу командир кинәшен тотып, Минзәләгә юл тоттым. Ремонт-төзелеш идарәсе башлыгы, кызыл чырайлы, зур гына борынлы урыс, дустанә кабул итте үземне. Сөйләшеп-гәпләшеп алдык, объектларны карап кайттык, шартнамә да төзеп ташладык. Кичен ул мине өенә алып кайтты. Хатыны белән икәүләп җыйнак кына бер фин өендә яшәп яталар икән. Кыстый-кыстый сыйладылар, икесе дә мина ничектер җәлләп, баласытып карап утырдылар.

Берничә көннән Минзәләгә остарак егетләребездән торган ике бәләкәй бригада белән килеп төштем, аларны РСУ салырга тиеш булган ике хосусый кирпеч йорт төзергә куйдым.

Аннары Азнакайга, булачак бабаем Газизулла Хикмәтулла улы Кәрамуллин янына китеп бардым. Бу вакытта ул колхозара төзелеш оешмасына (МСО) җитәкчелек итә иде. Уразай авылындагы терлекчелек комплексының түбәсен ябуга шәп кенә шартнамә төзедек.

Г. Кәрамуллин—колхоз[1] рәисе чакта, 1964 елны безнең авылда Н. С. Хрущевның

үзен каршылаган кеше. Бабайга хәзер сиксән тулып килә, бездә, Мәскәү кырыенда дачала яши ул. Әби (Һидая апа) 1989 елны дөнья куйды.

Ниһаять, отряд иң кулай сандагы бригадаларга бүленде, эш гөрләп бара башлады. Ләкин мина мәшәкать артты гына. Әледән-әле чыгып торган мәсьәләләрне хәл итү өчен туктаусыз Мөслим, Минзәлә, Азнакай арасында йөреп торырга туры килә иде. Төзүчеләр бәйрәме көнендә минем янга, Түбән Табынга Роза килде. Икәүләп күрше Мәллэтамак авылына барып, Бәдерлехәят апаның (әтинең апасы) хәлен дә белеп кайттык.

Август азагында отрядның төп өлеше, командир белән бергә, Казанга кайтып китте. Мин исә сентябрьгә кадәр төшемле эштәге бригадаларыбыз янында калдым. Вакыт тиз үтте. Әмма эшнең кыены һәм хәтәре алда иде әле. Отряд эшләгән бөтен жирләрне йөреп чыгып, исәп-хисап ясыйсы һәм ышанычнамә нигезендә бөтенебез өчен акча аласы бар иде. Каешка кынлы ауч хәнжәрен астым да, ошбу җаваплы миссияне үтәүгә керештем. Минзәләдән машина туктата-туктата кайтканда төнлә, портфель тулы акча белән Түбән Табынга кадәр 15 чакрымлап араны пычрак ерып җәяү үтәсе булды.

Казанда мине түземсезләнеп отряд көтә иде. Командирга портфельне һәм исәп-хисап кәгазьләрен тапшырдым да иң якын торган ятакка аудым. Уянмый озак кына йоклаганмын.

Аннары "Татарстан" ресторанында банкет ясадык. Бергә эшләгән егетләр рәхмәт сүзләрен мул яудырды. Бик тә рәхәт булып китте үземә. Гомеремдә беренче тапкыр эшемнең нәтиҗәсеннән чын канәгатьлек тойдым. Отряд җан башына шактый гына акча эшләде, бу инде әлеге сезонда безгә иң яхшы биш отряд арасына эләгүне тәэмин иткән нәтиҗә иде.

Мин үземә тигән акчадан әти-әнигә яна радиола сатып алдым, без бәләкәй чактан ук калган "бер күзле" "Иртыш" нык "картайган" иде инде. Казан авиация институтының икенче курсында укыган энекәш Назилга да бераз кием-салым алдым.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Казан ханлыгы яулап алыну һәм Нугай урдасының таркалуы Көньяк Урал һәм Идел аръягының этник картасы нык кына үзгәрүгә китергән. Нугайларның төп өлеше көньякка—Иделнең Түбән агымына һәм Төньяк Кавказ яны далаларына күченә башлаган. Хәтта Кырым ханлыгының дала өлешенә дә барып урнашкан алар. Бу күченүләр бигрәк тә XVI гасырның икенче яртысы—XVII гасырның башында көчәя. Ырынбур далалары аша Ык елгасына таба Гираят бинең өлкән улы Куганчы ягыннан оныклары һәм оныкларының балалары да күчеп килә. Ык елгасы үзәненә беренче тапкыр алар хәзерге Дияш[2] авылы тирәсенә килеп чыга. Авыл Истәнгол улы Жияш (Джияш—Дияш) исемен йөртә булса кирәк. Сонрак алар шундагы Коры елганың сул як ярына күчеп утыралар.*

*Бу җирләрне патша соныннан Петербург бояры Карповка бүләк итеп бирә. Карпов монда Воронеж губернасы крестьяннарын күчереп утыртып, Усы, Николаевка, Потемкино һ. б. авылларны сала. Алпавытның үзәк утары Карповкала[3] була.*

## Эшкә билгеләнү

1973-74 еллар.

Алдагы хезмәт эшчәнлегемә бик житди карый идем мин. МТСның участок механигы булган, бер таңнан икенче таңгача өйгә кайтып кермәгән әти образы балачактан күз алдымда торгангамы, гомумән ир-атны муеннан эшкә күмелеп яши торган зат дип белә идем.

Дүртенче курсны тәмамлау белән өйләнәм дип алдан ук хәл кылып куйдым. Диплом язганда кыз-кыркынга вакыт әрәм итмәм, институтны бетерүгә гаилә атлы ныклы нигезем булгач, бөтен көчемне эшкә бирермен, янәсе. Ләкин кемгә өйләнергә менә? Беренче мәхәббәтемнән дә көчле хис табылмады. Бик дөрес адым иде бу. Роза тормышымда ирешкән иң зур уңышым булып чыкты. Калган бөтен уңышларым-казанышларым шактый дәрәҗәдә аңа бәйле булды.

Диплом проектын эшләгәндә, уку отличнигы буларак, мина металл

[1] Азнакай районы "Авангард" колхозы, Тымытык авылы
[2] Башкортстанның Бакалы районы
[3] Башкортстанның Бакалы районы авыллары

конструкцияләре кафедрасында калырга һәм аспирантурага керергә тәкъдим иттеләр. Тулай торакта бүлмә һәм аена туксан сум стипендия гарантияләнә иде. Мин диплом житәкчемә рәхмәт әйттем, практикадан башка теория берни дә түгел ул, фәнгә, бәлкем, төзелештә 2-3 ел эшләп алгач әйләнеп кайтырмын, дидем. Эшкә туган якка якынрак "бүленәсем" килә иде. Азнакайга ук кайта алмый идем, чөнки әти белән бабай район оешмаларында житәкче урыннарда эшлиләр, әтинең энесе Легендар Мириханов исә—райбашкарма рәисе урынбасары. Алар минем хезмәт биографиямә йогынты ясый алалар һәм ясарга атлыгып торалар иде. Колхозара төзелеш оешмасының баш инженеры яки төзелеш профтехучилищесы директоры вазифасыннан башларга тәкъдим итте алар. Мин исә моны һич теләми идем. Тормышта бөтен нәрсәгә мөстәкыйль рәвештә ирешәсем килә, үзегез кебек—гади механик, авыл советы хезмәткәре, тракторчы булудан башлап, дип жавап бирдем. Болай дип тә өстәдем: бер тирәдәрәк яшәрбез, ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә күрешеп торырбыз, әмма сез минем эшкә катышмассыз.

Мина кулай шартларны тәэмин итә алырлык шәһәр Әлмәт булып чыкты. Әлмәттән килгән "сатып алучы"—"Татнефтегазстрой" берләшмәсе вәкиле мине деканат аша эзләп тапты. Без комиссия утырышына кадәр булачак эшемнең шартлары турында жентекләп сөйләштек, ягъни телдән генә хезмәт контракты төзедек... "Сатып алучылар" дип институт тәмамлаучыларны эшкә билгеләү алдыннан оешмалардан килгән кешеләрне әйтәләр. Төзелеш белгечләре житми иде ул чорда, чөнки бөтен ил олы бер төзелеш мәйданына әйләнгән иде. Мәскәү янына, Ленинградка, Ташкентка, Балтыйк буена эләгү бәхет санала иде. Шәп урыннарны әйбәт укыганнар сайлап ала. Эшкә бүлү комиссиясенә чират укудагы уртача баллга һәм жәмәгать активлыгына карап төзелә иде. "Кызыл" диплом иясе буларак мин ошбу рейтингта алдагылар арасында идем. Шуна күрә минем Әлмәткә ризалашуым комиссия әгъзаларын бераз гажәпләндерде дә әле.

Август азагында, мин хәрби сборда булып кайткач, без, ягъни мин һәм жиденче ае белән барган Роза, Әлмәттә "Татнефтегазстрой"ның кадрлар бүлегенә килеп кердек. Кабинет хужасы безне якты чырай белән каршы алды, документларны кабул иткәч, сентябрьдәге ялыбызны тынычлап уздырасыбызны әйтте. Мәсьәләләрнең шулай тиз хәл ителүенә сөенеп, үзебез яшәячәк шәһәр урамнарын бераз карап йөрдек тә, әти-әниләр янына Тымытыкка, бәрәнге һәм чөгендер алышырга кайтып киттек.

Сентябрьнең жылы бер көнендә, хәтта ул совет заманы өчен дә фантастик булып тоелган, телеграмма килеп төште Әлмәттән: "Приезжай получения "квартиры". Ләкин бу—чынбарлык иде. Тулай тораклагы яшәү мәйданын тапшырганлыкка белешмә алыр өчен тиз генә самолет белән Казанга барып кайтып, авылга "хрущевка" йорттан ике бүлмәле квартир ачкычларын тотып кайттым.

Бабай (Г. Кәрамуллин) ышанмады, аның эш "Волга"сында, әти белән өчәүләп, төнгә каршы Әлмәткә китеп бардык. Татарның тотып карамыйча күнеле булмый бит. Картлар (ул чакта илле дә тулмаган булган әле үзләренә) квартирның астын өскә китереп карап чыктылар. Төн уртасындагы дөбер-шатырга күршеләр чабып чыккан, бер очтан таныштык та үзләре белән.

Бераздан күчендек. Студент чемоданнарын, туй бүләкләрен һәм дә әни калерләп жыеп барган Сабантуй бүләкләрен колхозның йөк машинасына төядек. Өлкән классларда укыган чаклардан башлап көрәштем, соңгы елларда авылда батыр да калган идем. Студент чакта классик көрәш буенча Татарстанның югары уку йортлары жыелма командасында булдым, республика даның бөтенрусия ярышларында якладым.

Роза белән бар милекне таратып салдык. Көнкүреш өчен иң кирәкле нәрсәләрне якындагы хужалык кибетендә сатып алдык. Шулай итеп, беренче көнне эшкә үземнең "жиһазланган" квартирымнан киттем мин.

*ШӘЖӘРӘ ЖЕБЕ*

***Жияш улы Урсай (1698 елда дөнья куя) Карпов утарыннан ераккарак—Ау Кырласына күчеп утыра, яңа авыл Урсай[1] дип атала башлый. Урсай бабайга Исхак, Бики, Кыдрач, Минай һ. б. типтәр ыруглары да килеп кушыла. Тора-бара Урсай авылының урыны үзгәрә. Беренче зиратның Тымытык юлындагы "Читән күпер" янында булганлыгы мәгълүм.***

[1] Татарстанның Азнакай районы

## "Мастер"—"оста" дигән сүз

1974-75 еллар.

Теләгемне искә алып, мине сәнәгать (промышленность) төзелешенә, 6 нчы трестка, аннан 43 нче төзү-монтаж идарәсенә җибәрделәр. Анда исә кадрлар бүлеге мөдире, зур зәңгәр күзле, аксыл чәчле ханым, мина иртән иртүк бөтен башлыклар җыела торган идарә базасына барырга тәкъдим итте.

Базада сәгать алтыда башланган эш бүлешүне (разнарядканы) идарәнең баш инженеры П. Сычев үткәрде—башлык ялда чак икән. Соныннан ул мине үзенең УАЗигына утыртып конторга алып китте. Анда баш инженер үзе, производство-техник бүлеге башлыгы һәм кадрлар бүлеге мөдире минем белән сынау гәбе (собеседование) үткәрделәр. Кызыл тышлы дипломымны ачып карагач, мине утырып эшләргә түзем, кәгазь белән эш итәргә ярата торган кеше дип уйлап, конторда калырга кыстадылар. Мин исә биш ел эчендә кәгазьдән гарык булганымны, аспирантурадан да шунын аркасында качуымны, бары төзелеш мәйданында гына эшләргә теләвемне әйттем. Баш инженер диплом эшемнең темасын сорады да, янә фургонга утыртып объектка алып китте.

Бу—Әлмәт спираль җөйле торбалар заводы, кыскартып әйткәндә, "спираль" иде. Мине монда мастер итеп билгеләп, прораб карамагына бирделәр. Ул исә мине сагаеп, көндәш күреп кабул итте. Баксаң, салуга хирыс, эше дә аксый икән. Сөйләшкәндә күзгә туры карамый бу, биеп торган юртак кебек түземсезләнә, сүз беткәнне дә көтмичә, төзелеш мәйданы буйлап чираттагы әйләнешенә ыргыла... Аны урынында туры китерүе читен, эзләү дә файдасыз. Сукмагына басып көтәргә кирәк: каршына үзе килеп чыга ул.

Прораб миңа бернинди эш-вазифа да йөкләмәде, сызымнарны өйрәнергә кушты. Мин көннәр буе вагончыкта утырам, өем-өем яткан сызымнарны, рәтен-чиратын тапмыйча, актарам да актарам. Әледән-әле монсу күз карашымны тәрәзәгә төбим. Төзелеш миннән башка гына бара. Ул мина мохтаж түгел!

Шулай бер атналап вакыт үтте. Ниһаять, култык астына папка кыстырып, кырыс чырайлы участок башлыгы килеп чыкты. Ул шундук хәлне аңлап алды, мина зур булмаган бер градирня[1] төзүне йөкләде.

Бу объектта өч кеше градирняның төбен бетонлап ята иде. Боларга да кирәк булып чыкмадым, мина бер генә сораулары да юк иде. Өсләрендә тормас өчен градирняның сызымнарын өйрәнергә китеп бардым. Төзелеш мәйданындагы барлык эшче төркемнәрне карап эшләткән бик тә тәҗрибәле бригадир В. Кильдюшев бу объектка да әледән-әле сугылып китә иде. Минем эшчеләр белән мөстәкыйль рәвештә аралашуымны һич өнәмәде ул. Бригадир бөтен нәрсәне дә үзе хәл итә, шул рәвешле мине артыкка чыгара иде. Бер тапкыр Кильдюшев, булачак градирня янында озаккарак тукталып, сызымны тегеләй дә, болай да боргалап карый башлады. Эшчеләр өмет белән ана текәлделәр. Килешмәгәнчә артык озакка сузылды бу. Аннары бригадир теләр-теләмәс кенә вагончыкка юнәлде, кергәч, искитмәгән кыяфәт белән сызымны өстәлгә ыргытты да, анда нәрсә сурәтләнгәнне аңлатып бирүемне таләп итте. Градирня төбендәге чокырчыкның опалубкасы сызымына теше үтмәгән икән бахырның. Бу конструкциянең хикмәтен һич читенсенми аңлатып бирдем үзенә. Соңрак Василий Федорович белән мондый аралашулар ешайганнан ешая барды.

Күпмедер вакыттан прорабны эштән алдылар. Объект минем өстә калды. Тәртипсез рәвештә өелеп яткан металл конструкцияләрне маркалары буенча аерып тиздек, төп корпусны монтажлау өчен әзерлек эшләрен башлап җибәрдек. Шактый зураеп киткән бригадасын эшче төркемнәргә һәм сменаларга бүлеп, В. Кильдюшевка аларны иң кулай рәвештә эш урыннарына беркетергә ярдәм иттем, моңа ул үзе дә сөенде. Завод төзелешенә участокның яна башлыгы Наум Моисеевич Штейман килгәли башлады. Безнең институтны ике ел элек кенә тәмамлаган иде ул. Яхшы хәтерлим үзен, бокс ярышларында ару гына чыгыш ясый торган иде. Беренче көннәрдән алып безнең арада әйбәт мөнәсәбәт урнашты.

Октябрьдә кызым Чулпан туды.

Әлмәт торба заводы СССР нефть-газ төзелеше министрлыгының иң мөһим

[1] Градирня—кабат куллану өчен су суыту корылмасы.

объектлары исемлегенә кертелде. Эшче көч, материаллар белән тәэмин итү яхшырды, зур житәкчеләр килү ешайды. Шул көннәрдә биредә тагын бер мастер, институтта минем белән бер курста укыган Илдар Володкин эшли башлады. Бу Әлмәт егете каладашы Рәмзия Хәйруллинага өйләнгән икән (Рәмзия дә безнең курсташ). Шуннан соң ул да Түбән Камадан Әлмәткә кайтырга ниятләгән. Илдарның безнең идарәгә, безнең объектка эләгүе очраклы хәл булса да, монда беренче кат очрашканнан соң без бер-беребезгә беректек. Әле хәзер дә бергә-бергә гомер итәбез.

Шул арада объектта эш тәмам кызды. Өч смена эшлибез, әледән-әле планеркалар үткәрелеп тора. Төзү-монтаж идарәсе башлыгы Евгений Иванович Подлипский көн саен килә, трест управляющие Виктор Алексеевич Алютов белән "Татнефтегазстрой" берләшмәсенең башлыгы Владимир Николаевич Зиновьев та шактый еш килеп чыга башладылар. Ара-тирә хәтта Мәскәүдән министр урынбасары, элекке "Татнефтегазстрой" берләшмәсе башлыгы Марат Хәйретдинович Хөснетдинов та килеп төшә иде.

Үз планы-ние буенча үз көенә иплəп кенә эшләргә күнеккән участок башлыгыбыз мондый вәзгыятьтә тәмам югалып калды. Бездән бөтен булган ресурсларны да кырыс графикны, оператив кинәшмәләрнең карарларын үтәүгә туплау сорала иде. Наум Моисеевич исә бар нәрсәне үзенчә эшли. Һич кирәкмәгәнгә Подлипский белән низагка керә. Планеркаларда исә кабул ителгән карарларны үтәү сроклары өзелгән өчен нәкъ менә идарә башлыгына эләгә, шунлыктан аңа күрсәтмәләрен турыдан-туры мастерларга бирүдән башка чара калмый. Эш көйләнә... Көннәрдән бер көнне идарә башлыгы Штейманны прораб итеп күчерү һәм участок башлыгы вазифасын башкаруны миңа йөкләү турында приказ чыгарды.

Шулай итеп, минем мастерлык "эпопеям" нибары биш айга сузылды, прораблыкны сикереп үтеп, төзелеш участогына житәкчелек итә башладым.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*XVII гасыр азагында Гираят би ыруы вәкилләренә патша грамотасы белән Көнчыгыштан—Ык елгасы, төньяктан һәм көнбатыштан—Мәллә елгасы, көньяктан Коры елга белән чикләнгән жир биләмәсе бирелә.*

*Урсайның олы улларыннан берсе Хәсән төпләнү өчен ике елга кушылган, бик тә матур һәм бай табигатьле урынны сайлап ала. Яңа авылны (1704), уйсу урында булганга, "Җәлпәк (Чалпак[1])" дип атыйлар. Вакыт үтү белән, әйтергә җайлы рәвештә, "Чалпы"га әйләнә ул.*

*Патша указы жирле феодаллардан игенчелекне үстерүне таләп иткән. Шуңа карамастан, Чалпыга нигез салучылар бөртекле ашлык игү өчен урынның аз өлешен генә (жан башына 50 дисәтинәдән) тәгаенлиләр, төп мәйданны исә ау жирләре итеп һәм елкы көтүләре өчен болыннар итеп калдыралар.*

*Хәсән бик тә уңган һәм сәләтле кеше була. Аның иген кыры бик шәп эшкәртелә. Шуңа уңышны да мул бирә. Иген культураларына "теше үтмәгән" авылдашлары жирләрен Хәсәнгә биләләр. Ул баеганнан байый. Аның иген мәйданы тора-бара 2 мең дисәтинәгә житә һәм укытылган агроном житәкчелегендә эшкәртелә. Чалпы халкы авылның беренче басуын әле дә "Хәсән басуы" дип атап йөртә. (Хәзер бу басу аша Азнакай—Чалпы юлы үтә.) Уңган сәүдәгәр буларак, Хәсән тирә-яктагы сәүдәне дә үз кулында тота. Кәрван белән ерак шәһәрләргә ярминкәгә еш йөри торган була.*

## Участоклы да булдым

1975-77 еллар.

Участокта дүрт бригада, прораблар һәм мастерлар, нормачы һәм табельчы—жәмгысе йөздән артык кеше эшли.

Наум Штейман үзгәрешне бик авыр кичерде. Икенче көнне үк начальнигым урынына утырып аңа эш кушу, күрсәтмәләр бирү миңа да жиңел түгел иде. Ахыр чиктә Наум түзмәде, "Оргтехстрой"га күчте. Әмма бәйрәм көннәрендә, наряд япкан көннәрдә Илдар Володкин белән без аны шул "кәгазь эшле" конторда эзләп табып, өчебезгә бер шешә алып аулаграк берәр урында кәефләнеп утыра торган идек.

Күпмедер вакыттан мин Володкинны прораблыкка тәкъдим иттем. Яшь мастерлар да килде, эш гөрләп бара башлады. Гомеремдә беренче мәртәбә дәүләт

[1] XIX гасырга караган Самара губерна статистика мәгълүматларына "Чалпак" булып кергән.

планы, матди хисап тоту дигән нәрсәләргә тап булдым. Субподрядчылар белән мөстәкыйль рәвештә көн саен киңәшмәләр үткәрә башладым. Бу хәл Подлипскийның күңеленә хуш килде, миңа ышанычы артты, объектка сирәгрәк сугыла башлады. Кичләрен көн нәтиҗәләре һәм идарә башлыгына сораулар белән конторга үзем килә идем. Әкренләп безнең участок трестта иң яхшылар арасына керде.

Эшем киеренке һәм авыр да, кызыклы да иде. Иртән 5 тә торам, $6^{30}$ да идарә базасында разнарядка, $7^{30}$ да, эшчеләрнең төп вахтасы килгәнче, мин инде объектта булам. Өйгә икенче сменаның оешып эшли башлавына ышангач, төнге 11 ләрдә генә кайтам. Аяклар гүли, ут яна, Роза аларга юеш сөлге урый.

Төннәрен икътисад, идарә итү, эш психологиясе, яисә төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре һ. б. буенча китаплар укыйм. Шунсыз булмый—эш тәҗрибәсе алга бик күп сораулар куя. Институт белеменең база гына булып торуын һәм эш тәҗрибәсендә бик аз кулланылуын чын-чынлап әнә шул чакта аңладым мин. Документларымны Казан финанс-икътисад институтының читтән торып уку факультетына җибәрдем, аспирантурага керү турында уйлый башладым, әмма эшне һәм укуны бергә алып бару мөмкин түгел иде. Шулай да эшемә кагылышлы катлаулы мәсьәләләргә караган махсус әдәбият укуны гадәткә керттем. Ял көннәрендә сызымнар өйрәндем, техник чишелешләрне камилләштердем, рационализаторлык тәкъдимнәрен заказчы белән килештерүгә әзерләдем.

Рационализаторлыкка әүвәлге "кырыс" участок башлыгым Н. Гордеевтан өйрәндем мин. Ике ел эчендә утызлап тәкъдимемне гамәлгә ашырып, "Татнефтегазстрой" берләшмәсенең иң яхшы рационализаторы исемен алдым.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнгәч, миңа Әлмәт шәһәр комсомол комитеты секретаре булырга тәкъдим иттеләр. Әмма мин баш тарттым.

Күп тә үтмәде, берләшмәгә чакырып, Алабугага, механикалаштырылган эшләр идарәсенә (УМР) баш инженер булып күчәргә тәкъдим иттеләр. Ләкин тресттан җибәрмәделәр, үзебезгә кирәксең, диделәр. Сонрак трестның партком секретаре чакырып алып, үсәчәк кадрлар резервында икәнемне һәм партиягә керергә тиешлегемне әйтте. Шулай итеп, мин КПСС әгъзалыгына кандидат булдым.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Нугайбик (1736—1802) Хәсән байның зарыгып көтеп алган бердәнбер улы. Нугайбик исеме Идел-Урал төркиләрендә сирәк очрый. Этник составы гаять чуар булган төбәктә яшәгән Хәсән бай шуның аша нәселләренең Нугай токымыннан икәнлеген күрсәтергә теләгәндер инде. Исемнең малай туган елны Ык буенда Чалпыдан ерак түгел салынган Нагайбәк кирмәненә[1] нисбәтән кушылу ихтималы да бар. Кирмән нугайларның бер кавеме булган нагайбәкләр казак хезмәтен башкарган урында салына.*

*Хәсән үзенең улына европача белем бирергә тели. Рус телен үзләштергәч, Нугайбик дворян балалары һәм патша чиновниклары укыган Самара гимназиясенә керә.*

*Соңыннан Нугайбик әтисенә хуҗалык эшләрендә ярдәм итә башлый. Берничә ел рәттән сәүдә кәрваннары белән ерак шәһәрләргә бара. Старшина әтисе кул астындагы территорияләрдән салым җыю системасын эшли, губерна түрәләре белән бәйләныш булдыра. Әтисенең вафатыннан соң ясаклы татарларның старшинасы итеп ул билгеләнә (ягъни район администрациясе башлыгы итеп, өязләр һәм волостьлар ул чакта булмый әле). Старшина, салым җыюдан тыш, хокук саклау, суд эшләрен башкару, хөкем карарын гамәлгә ашыру һ. б. белән дә шөгыльләнә, ягъни тулы властька ия була.*

## Абзагыз инде баш инженер

1977-78 еллар.

Апрельнең кояшлы бер матур көнендә Е. Подлипский, объектка килгәч, үзенең җитәкче урынбасары булып трестка күчәчәген, төзү-монтаж идарәсендә үзгәрешләр булачагын, миңа баш инженер урыны тәкъдим ителәчәген әйтте.

Мин исә яңа вазифама әзер түгел булып чыктым. Түрә эшенә яраклы киемем

[1] Хәзер Башкортстанның Бакалы районындагы Нагайбәк авылы.

юк икән бит. Монарчы киеп йөргән прораб тужуркасы белән ямаулы чалбар һәм кирзы итек "житәкче иптәшкә" килешми иде инде. Кешелеккә кия торганы исә артык яшьләрчә иде. Роза, бар булган акчаны учлап, Мәскәүгә китеп барды, аннан кримплен костюм һәм берничә күлмәк белән галстук алып кайтты.

Шул рәвешле 25 яшемдә мин чын түрәгә әйләнә башладым. Үз кабинетым да, машинам да барлыкка килде. Элекке баш инженер Сычев мине беренче көнемдә конторга алып килгән бортлы машина миңа күчте (әржәсен бераздан "буханка"га—микроавтобусныкына алыштырдым)... Кабинетка мәктәп тактасы элеп куйдым, акбуры да табылды. Һәм, озакка сузмыйча, фәнни-техник советта персоналны укыту һәм аттестацияләү; шунарчы бездә кулланылмаган, үзем дә менежмент турындагы китаплардан гына укып белгән эш—кадрлар резервын үстерү өчен тест сынавы; төзелешнең үзкыйммәте, рационализаторлык, эш вакытын жую, механикалаштыру һ. б. мәсьәләләрне карый башладык. Яңа эш мине мавыктырып, баш-аягым белән йотып алды.



*Назиф Мириханов гаиләсе белән. 1979 ел.*

Инде туганлашып беткән торба заводы төзелешенең штаб башлыгы да булдым. Участок башлыгы итеп үз урыныма И. Володкинны тәкъдим иттем. Эш шактый көйле бара башлады.

Әлмәт шәһәр партия комитеты инструкторы Ф. Х. Мөхәммәтшин белән танышуым да шул чакларда булды. Ул мине шәһәр суүткәргеченең безгә тапшырылган өлешен салу мәсьәләсе буенча чакырып алды. Фәрит Хәйрулловичка әле ул чакларда ук хәлгә керергә тырышу, гаеп эзләүдән битәр куелган бурычны үтәргә ярдәм итәргә омтылу, теләктәшлек хас иде. Сонрак ул сәүдә министры, премьер-министр булды, хәзер —Татарстан Дәүләт Советы Рәисе.

Мине исә хезмәт баскычында тагын бер адым көтә иде. Моны бер гадәттән тыш хәл дә тизләтте. Төзү-монтаж идарәсенең яңа башлыгы, аның урынбасары һәм инженер-техник хезмәткәрләр төркеме ОБХСС дәгъвасы буенча хөкем ителеп, "химия"гә—жәзаны шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр үтә торган урынга элэктеләр. Идарә белән житәкчелекне үземә алып, эш барышында яна команда туплыйсы булды.

*ШӘЖӘРӘ ЖЕБЕ*

*Милли азатлык алуга өметләнеп, 1773 елнын ноябрендә Нугайбик Пугачев восстаниесенә кушыла һәм анын полковникларыннан берсе була. Уфа каласын штурмлауда, "адаш" кирмәнне—Нагайбәкне алуда катнаша. 1774 елнын 15 гыйнварында Нугайбик Хәсәнов[1] һәм Аренкул Әсәев житәкчелек иткән ике мен кешелек төркем бер атусыз Зәй кальгасын ала. Ничәдер көннән патша гаскәрләре килеп житкәч, фетнәчеләр Нугайбәк кирмәненә чигенәләр. Әмма март башында аны да калдырып китәргә мәжбүр булалар. 10 октябрьдә әлеге төркем Эстәрлетамак янында генерал Ларионов тарафыннан тар-мар ителә. Ставка мәгълүматларына караганда, атаман Нугайбик Хәсәнов эзсез юкка чыга.*

*Фетнә бастырылып, еллар үткәч, шау-шу сүрелә төшкәч, Нугайбик авылына кайтып керә һәм 1802 елны вафат була. Ул Чалпы авылынын иске зиратында жирләнгән. Нугайбикнен тугыз улы була: Яркәй, Ярмөхәммәт, Шәмсетдин, Хөрмәкәй, Сәлтәш, Шамбаз, Морадым, Габделвахаб һәм Котлызаман.*

## Идарә белән идарә итәм

1978-80 еллар.

Идарә (СМУ) башлыгы булып алгач, бернинди кыенлык та сизмәдем. Беренче көннәрдән үк трест житәкчесе В. Алютовнын ярдәмен тоеп тордым. Безнен мондый мөнәсәбәтләргә башка кайбер идарә башлыклары көнләшеп тә куя торган иде. Бигрәк тә В. Тифуня. Трестта лидерлык ул житәкчелек иткән 38 нче төзү-монтаж

[1] Фетнәгә кагылышлы тарихи документларда Нугайбек Асанов.

идарәсеннән безнең 43 нче идарәгә күчә башлагач, аеруча сизелде бу хәл. “Тифуня” фамилиясенә килгәндә, ул Виктор Александровичның бабасының исеме-аты “Ти-Фун-Ли”дан ясалган. Кытай токымыннан булуы Виктор Александровичның йөз-чыраена да үзенчәлекле бер ямь биреп тора... Безнең үзара мөнәсәбәт бер-беребезне ихтирам итүгә корылган әйбәт көндәшлек иде. Сонрак, трест житәкчесе булгач, мин Виктор Александровичны үз командама алдым. Ростовка күчеп киткәнче ул үзенең зур оештыру осталыгына ия булуын Ярославль өлкәсендәге газ куу компрессор станцияләрен төзүдә тагын бер кат күрсәтеп алды әле.

Илдар Володкин исә безнең төзү-монтаж идарәсенең баш инженеры итеп билгеләнде. 1нче участок башлыгы булып Наум Штейман да кайтты. Әмма, үзен минем остазым һәм дусты дип санаганга, мин тәкъдим иткән кырыс “хакимият вертикален”ә, таләпчән-эшлекле мөнәсәбәткә күнә алмады. Күпмедер вакыттан, одессит буларак, Урта Азиягә, хатынының әти-әниләре янына күченде, “үзгәртеп кору” башлангач исә АКШка, совет заманнарында ук хат алышып торган туганнары янына китеп барды ул.

1979 елның апрелендә улыбыз Илнур туды.

Эшкә яна төсмер өстәлде: партия һәм совет органнары, кайчакта исә партия өлкә комитеты белән үк бәйләнешкә кереп алулар. Иләшү җәһәтеннән монысы иң катлаулысы иде. Бер тапкыр шулай, партиянең шәһәр комитеты бюросында, каты куллы беренче секретарь В. Борисов тәкъдиме белән, район колхозларына шефлык ярдәме күрсәтү срокларын өзгән өчен дип, чак кына эштән очырмадылар үземне. Шул ук утырышта минем алдан гына хисап тоткан 42 нче төзү-монтаж идарәсе башлыгы В. Вилдановны алдылар да әнә. Мине торгызгач, бюро әгъзалары, башкарма комитет рәисе Геннадий Кыямович Беляев белән “Әлмәтнефть” нефть-газ чыгару идарәсе башлыгы Ринат Гыймадиевич Галиев (“Гыймаделисламович” дип аны партиянең шәһәр комитетында беренче секретарь булгач атап йөртә башладык) яклап чыгыш ясадылар. Күпчелек тавыш белән шелтә чәпәделәр үземә. Алга таба мондый көтелмәгән хәлләргә юлыкмаска тырыштым.



*Н. Мириханов—“Таткомплектмонтаж” трестының баш инженеры. 1980 ел.*

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Нугайбикнең тугыз улыннан Хөрмәкәй—кантон, ягъни кантон[1] башлыгы була. Аның улы Шәңгәрәй (1792—1878) дә кантон була. Бай яши, тегермән тота, урман били. XIX гасырның беренче яртысында Нугайбикнең бу буыны Россиянең дворян катламына күтәрелә.*

*Шәмсетдин дә, аның улы Хәлил мулланың Габделфатих углы да—ахун, Хәлил уллары Сабир белән Шәкүр—мулла булалар, Фатих безнең якларда беренче булып үз тегермәнен эшләтеп җибәрә.*

*Ярмөхәммәтнең оныгы Ибраһим (Мөхәммәдъяр улы), Бохара мәдрәсәсен тәмамлагач, Чалпыда мулла була.*

*Сәлтәш Нугайбик улы, ягъни бабамның бабасының этисе, 1790 елны Чалпыдан Урсайга күчеп утыра.*

*Котлызаман токымыннан бүгенге көндә Әлмәттә көн күреп ятучы авылдашларым “Елховнефть” нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ) башлыгы, ТР Дәүләт Советы депутаты Ардинат һәм атаклы табип-галим Айрат Нугайбековларны әйтеп үтәсем*

---

[1] 1798—1864 елларда Россия империясенең көньяк-көнчыгышында (хәзерге Татарстанның Көнчыгыш районнарында, Башкортстанда, Оренбург өлкәсендә, өлешчә Ульянов, Саратов, Самара өлкәләрендә башкорт-мишәр казакларының 12 кантонга бүленгән һәм Оренбург генерал-губернаторына буйсынган территориаль идарә системасы булган).

*килә. Урсайда туган Тымытык мәктәбе укытучысы Нугайбекова Ганжә апаның улы, ТР Югары суды коллегиясе әгъзасы, юстиция генералы мәрхүм Галим Абдуллаев та Котлызаман тармагыннан иде.*

## Адресым—Советлар Союзы

1980-81 еллар.

Вакыт үтү белән "Татнефтегазстрой"ның Татарстаннан читтә башкара торган эш күләме нык кына артты. Нефть кудыру станцияләре һәм магистраль үткәргечләрдә газ-компрессор станцияләре кору өчен "Таткомплектмонтаж" тресты оештырылды. Мине шул трестның баш инженеры итеп чакырдылар. Шулай итеп, 28 яшьтә бөтенләй башка тормыш башланды. Шул замандагы "Мой адрес—Советский Союз" дигән җырдагычарак, 2-3 мең чакрым юл үтүләр, шул арага ресурсларны күчерүләр, озакка сузылган командировкалар гадәти хәлгә әйләнде. Объектларыбыз географиясе Уренгойдан—Ярославль өлкәсенәчә, көньякта Волгоград өлкәсе һәм Краснодар краенача араларны колачлый иде. Трест карамагында арендага алынган АН-2, ЯК-40 самолетлары һәм вертолет бар. Без берьюлы унике нефть кудыру һәм алты газ-компрессор станциясен төзүдә катнашабыз. Трест махсус механикалаштыру идарәләрен, производство-техник комплектлау идарәсен, блоклы-комплектлы җайланмалар заводын һәм Түмән өлкәсе Ноябрьск шәһәрендәге 3 нче төзү-монтаж идарәсен дә кертеп, жиде төзелеш оешмасын эченә ала. Эшләүчеләр саны өч мең кешегә житә. Түмәндә һәм Сургутта штаб-квартираларыбыз бар.

Баш инженерның эше бик тә кызыклы: объектларны блок-комплектларга бүлеп, заводта ясап, төзелеш мәйданында җыеп кору; хезмәтне вахта-экспедиция ысулы белән оештыру; яна технологияләр куллану һ. б. Павел Федорович белән эшне бүлештек без. Ул күбесенчә компрессор станцияләрен төзүгә җитәкчелек итте. Мин исә насос станцияләреннән кайтып кермәдем. Кирәк булганда бер-беребезне алыштыра да идек.

Әмма мине монда озак тотмаска уйладылар. "Удмуртнефтегазстрой" трестын җитәкләргә тәкъдим иттеләр. "Татнефтегазстрой" башлыгының кадрлар буенча урынбасары В. Хужиәхмәтов белән Ижевскига очтык. Трестта, партия өлкә комитетында булдык. Шәһәр үзәгендә биреләчәк квартирыма кадәр күрсәттеләр. "Сынау гәбе"нә Мәскәүгә чакыртып алдылар. Министрның кадрлар буенча урынбасары бу эшкә күнелем яту-ятмавын яшерми әйтеп бирүемне сорады. Мин элекке эшемнең ошыйрак төшүен, Ижевскига күчәргә атлыгып тормавымны, тәкъдимне ихтыяҗ туганга, кирәк булганга гына кабул итәчәгемне әйттем.

Башка төрле сәбәпләр дә булган, күрәсең. Август аенда, гаиләм белән Кырымның Судак шәһәрендә ял итеп ятканда, берләшмә башлыгы В. Зиновьевтан тиз арада кайтып җитәргә боерган телеграмма килеп төште. Кара дингез буена "Жигули"да килгән идек, кайтканда машинаны җан-фәрман кудым: Әлмәткә тәүлек ярымда кайтып җиттек. Баксан, минем башлыкны башка эшкә күчерәләр икән. Трест белән җитәкчелек итү мина калды.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Нугайбик улы Сәлтәшнен уллары: Ачуак, Шәйморат, Әхмәтхан (бабамның бабасы), Шәймөхәммәт, Гәрәйша, Жиһангир, Мирхәйдәр.*

*Әхмәтхан мулла була. Аның уллары: Мөслахетдин, Михрихан (Мирихан)—бабамның әтисе, Мөхәммәтхан, Касыймхан, Мияссәр.*

*Мирихан (1853—1914) мулла һәм сотник (берничә авылның хакиме) була. Чалпы мәдрәсәсен тәмамлый. Шактый алдынгы карашлы кеше була ул. Авылда беренче велосипедны ул сатып ала, авыл халкын шаккаттырып, беренче булып ул җилдерә. Улы Миргарифанга мөселман белеме бирү белән чикләнмичә, күрше авылдагы тарих, география, физика, математика да кергән рус мәктәбендә дүрт класс укыта.*

## Трест җитәкчесемен

1981-85 еллар.

29 яшьтә трест кадәр трестны җитәкләү бер уйлаганда мине монарчы күрелмәгән катлаулыклар даирәсенә чыгарырга тиеш иде. Әмма минем эштә берни дә үзгәрмәде. Командировкаларга еш йөргәнлектән, без трестның элеккеге җитәкчесе белән

“хуҗалыкта” чиратлап калып, бер-беребезне бик тә көйле алыштыра идек. Әмма кайбер 45-50 яшьлек идарә (СМУ) башлыклары һәм аппаратның бүлек башлыклары минем белән әтиләрчә-абыйларча, җилкәдән кагулы, санламауга якын торган мөнәсәбәт урнаштырмакчы иделәр. Барып чыкмады. Тиз арада, бик тә тәэсирле дисциплинар-психологик алымнар кулланып (берничә кеше эштән дә алынды), кайберәүләр белән беркадәр үзара юл куешып, төгәл-анык эш мөнәсәбәтләре урнаштырылды. Коллектив алдында торган бурычларны шунсыз үтәп чыгып булмаячак иде.

Тиздән берләшмә җитәкчесе В. Зиновьев СССР нефть-газ төзелеше министрлыгының Идел буе һәм Урал буенча Баш территориаль идарәсе башлыгы булып Казанга күчте. Хәзер исә ул РФ ягулык-энергетика министрлыгы институтларының берсендә ректор, зур һәм бердәм гаиләсе белән Мәскәүдә яшәп ята. Безнең трестның баш инженеры булып исә күпмедер вакыттан Илдар Володкин эшли башлады.



*Мирихан улы Миргарифан төзегән шәҗәрәнең бер өлеше.*

КПСС үзәк комитеты партия өлкә комитетларына Уренгой—Ужгород, Сургут—Полоцк кебек магистраль торба үткәргечләрен төзүчеләргә ярдәм күрсәтергә кушты. (Шул җәһәттән КПСС-ның Төмән, Свердлов өлкә комитетларына киңәшмәләргә дә баргаларга туры килде.) Шушы күрсәтмә нигезендә объектларны ягулык, җирле төзелеш материаллары белән тәэмин итүдә һәм трассада эшләүчеләрнең көнкүреш мәсьәләләрен хәл кылуда әлләни кыенлыклар чыкмады. Бары тик объектив кыенлыклар гына бар иде: суыклар, табигать һәм һава шартлары, кайбер очракларда кешеләргә хас йомшаклыклар Эш режимы—сугыштагы кебек: тәүлекнең буеннан буена киеренке хәлдә буласың. Мәскәү әледән-әле бөтен трассаны колачлаган селектор киңәшмәләре үткәреп тора, һәр бәләкәй генә гаеп өчен дә җавап тотасың.

Кырыс производство шартлары кадрларны чыныктыра, көчлеләр, сәләтлеләргә тиз арада үзләренең оештыру осталыкларын ачарга мөмкинлек бирә, зәгыйфьләр исә чыдамыйча китеп баралар иде. Мина Түбән Новгород өлкәсендәге газ куу компрессор станциясендә өч айлап кайнашырга туры килде. Шулчакны бер монтаж идарәбезнең участок башлыгы Илшат Сәфәргалиевне беренче тапкыр эш кызуында күреп сокландым. Сәфәргалиев бераздан бу идарәнең баш инженеры итеп куелды.

Безнең трассалар Татарстан территориясе аша үтмәде. Шуна күрә республика җитәкчелеге белән алыш-бирешебез юк диярлек. Партиянең Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре булып өлгергән Ринат Гыймаделисламович Галиев безгә, “оча торган” монтажчыларга, теләктәш иде.

Татарстан өлкә комитеты безгә аяк чала алмый, әмма хаклы рәвештә кече ватанны да онытмауны таләп итә иде. Өлкә комитетының икенче секретаре Леонид Максимович Смагин безнең трестка Казанда “Новинка” дигән күргәзмә комплексын төзүне йөкләде. Бу эшне без ярты елда башкарып чыктык: беренче субайны 1984 елның февралендә сугып, кызыл тасманы 7 ноябрьдә кистек.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Әтиемнең әтисе—Миргарифан бабай Мирихан улы тимерче дә, тегүче дә, умартачы да, балыкчы да, балта остасы да, столяр да,—житмеш төрле һөнәр иясе иде. Өстәвенә, мулла вазифасын да үтәде. Ягъни Урсай авылында иң кирәкле кеше иде.*

*1918 елны авыл аша үтеп барган кызыл гаскәрләр 16 яшьлек Миргарифанны олаучы итеп алып китәләр. Мәләкәс янында чигенгәндә аклар кулына эләгә ул, әмма сорау алганнан соң жибәрәләр тагын. Утлар-сулар кичеп авылга кайтканда анда аны инде һәлак булган дип уйлыйлар. Ишек алдына исән килеп кергән улын күреп, әнисе һуштан язып егыла. Миргарифан, әтисеннән мирас булып калган терлеген һәм милкен тапшырып, колхозга беренчеләрдән булып керә, шуның өчен кулаклар тарафыннан кыйнала. Кадаклы күсәк белән кыйныйлар аны, канга баткан гәүдәсен дә, күсәкне дә читән янындагы кычытканлыкка ташлап китәләр. Өч көн дәвамында жаны кыл өстендә тора. Кемнәр кыйнаганын белә бабай, үзе ихтирам иткән, туган тиешле кешеләр була алар. Әйткән очракта каты җәзага тартылачакларын да белгәнгә, бу эшне йомып калдыра ул. Миргарифан бабай күмәк эштән баш тартып, колхоз тимерчелегендә эшли башлый, авыл һөнәрчесенә әйләнә.*



*Авторның бабасы Миргарифан Мириханов. 1971 ел.*

## Мәскәү, Академия

1985-87 еллар.

Биш елга якын трест житәкчесе булып эшләгәч, министрлык минем кандидатурамны СССР Министрлар Советы каршындагы Халык хужалыгы академиясенә ике елга укырга жибәрергә тәкъдим итте.Кинәшер өчен әти янына кайттым. Ул, һич икеләнеп тормыйча, укырга киңәш итте, кайчандыр үзе шундыйрак тәкъдимнәрдән баш тартып соңыннан үкенгүен оныта алмый иде ул. Бөтен формаль шартларны да үтәдем: партиянең шәһәр комитетында, өлкә комитетында булдым, үзәк комитетта "сынау гәбен" уздым.

Мәскәүгә күчеп килгәндә кызым Чулпанга—11, улым Илнурга—6, үземә 33 яшь иде.

Уку баш шүрлегемдә еллар дәвамында тиешле бер тәртип белән урнашкан бөтен нәрсәнең астын өскә китерде. Житмәсә, илдә "үзгәртеп кору" башланды. Үткән заманнарны хурлау китте, безнең баштан узган авыр эш-хезмәткә дә "торгынлык" дигән тамга сугылды" Академиядә безгә лекцияләр укыган А. Абалкин, А. Аганбегян, Г. Попов, П. Бунич кебек танылган галимнәр үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтү мөмкинлеге алдылар. Бик тә кызык иде бу. Семинар дәресләре аеруча жанлы уза торган иде.

Ике ел үтте дә китте. Укуны мин яхшы нәтиҗә белән очлап, халык хужалыгында, макроэкономикада идарәче буларак "кызыл" диплом алдым.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Бөек Ватан сугышында, иптәшен сугыш кырыннан алып чыкканда, Миргарифан бабамның уң кулы яралана—автомат пулялары бармак сөякләрен чәрдәкләп бетерә. Балачакта бабай мине гарип бармаклары белән куркыта торган иде. Алар балык тоту өчен көйләнгән, ди торган иде: сөяксез имән бармак—кармакка иләп кенә суалчан кидертер өчен, үзе дә кармак рәвешендәге урта бармак—балыклы кәржин тоту өчен, янәсе.*

*60 нчы еллар азагында, совет власте дингә элеккечә үк каты тормый башлагач, бабайны, революциягә кадәр мулла булган, мәдрәсәдә дини гыйлем алган кешенең малаен, авыл халкы мулла итеп йөртә башлый. Бабай Коръәнне яттан белә, таң тишегеннән торып радиодан гарәпләрне тыңлый, намазын калдырмый, уразасын тота, жомга көннәрне мәчеттә вәгазь укый. Билгеле инде, авылда никахлашу да, женаза да,—бер генә дини йола да ансыз үтми торган иде.*

## Янә эшкә билгеләнү

Министрлыкның кадрлар бүлеге мине уку төгәлләнергә ярты ел кала чакыртып алды. Чыгышым белән мөселман булуымны, башка төрки телләрнең татар теленә охшашлыгын истә тотып, Урта Азиядәге өч берләшмәнең берсенә җитәкче булып китәргә тәкъдим иттеләр. Бу—Төрекмән (Ашхабад), Актүбә (Казакъстан) һәм Урта Азия (Ташкент) нефть-газ төзелеше берләшмәләре. Мин исә, шагыйребезнең мәгълүм шигырь юлларын әйтеп ("Рус түгелмен, ләкин россиян мин"), баш тарттым. Телләребез охшашлыгы да, совет чорында онытылган дин уртаклыгы да Урта Азия оешмаларындагы мөнәсәбәтләрнең үзгәлегенә тәэсир итә алмый иде. Алар минем яшәү гамәлләремә, эш стилемә һәм алымнарыма һич кенә дә туры килми иде. Теләгемне тагын бер кат кырт кисеп әйттем. Яна эшем Татарстанда, бер дә юкта Башкортстанда булсын иде, дидем. Мина исә, бу республикаларда кадрларга ихтыяҗ юк, диделәр. Күпмедер вакыттан соң Саратовтагы "Приволжскнефтегазстрой" берләшмәсендә баш инженер урынын тәкъдим иттеләр. Мин ризалык бирдем, кайчандыр татар шәһәре (Сарытау) булган Саратов Татарстаннан 700 чакрымда гына, ял көннәрендә кайтып та килергә мөмкин.

Диплом вакыты җиткәндәрәк мине министр В. Чирсков дәшеп алды. Кадрчылар алдан кисәтеп куйдылар: министр теләгенә каршы киләмәвең хәерле. Чирсков сүзне "Саратовка барасың киләмени?" дигән сораудан башлады. Мин исә әлеге мәсьәләнең хикмәтен төшендереп бирдем. Җавап итеп Чирсков үзенең Саратовтан икәнен, әмма мина анда бару кулай түгеллеген әйтте. Илдә зур үзгәрешләр көтелгәнен аңлатты. Министрлык концерн итеп үзгәртеләчәк икән, аппаратта эшләүчеләр саны ун тапкыр кимеп, булачак концерн аппаратына башлыча производство җитәкчеләре җәлеп ителәчәк икән. Мине чакыруы да нәкъ шул сәбәпле булган. Квартир мәсьәләсен ярты ел эчендә хәл кылырга вәгъдә бирде. Шулай итеп мин Мәскәүдә калдым.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Миргарифан бабайның биш улы (Мирхафизан, Мөҗәһидән, Багис, Легендар, Фәнис) һәм өч кызы (Бәдерлехаят, Галия, Әминә) бар.*

*Мирхафизан абый (1925-43)—ике метрга якын буйлы чибәр пәһлеван, сөйләгәндә бөтенесен дә авызына каратып торкан комсомол активисты, авыл кызларының кумиры була. Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган дип исәпләнә. Сугыштан кайтып килүче солдат, авылыбызга сугылып, чын хәлне сөйләп бирә. Хафиз Мириханов разведка взводы командиры була. Бер тапкыр, "тел" алган чакта, алар отрядының эзенә төшәләр. Хафиз төп төркемгә әсирне штабка илтеп җиткерергә боера да, үзе берничә иптәше белән эзәрлекләп килгән немецларны тоткарларга дип бәрәңге бакчасында ятып кала. "Тел"не алып киткән разведчиклар автомат тавышларын озак ишетәләр әле. Бераздан тавыш тына...*

*Багис абый (1929)—Миргарифан бабабызның туган авылы Урсайда калган берләнбер улы. Механизатор, бригадир, колхоз рәисе урынбасары булып эшләде.*

*Легендар абый (1939-89)—нәселебездәге тагын бер пәһлеван, сабантуйлар батыры иде (Миргарифан улларының бөтенесе дә сабантуйларда мәйдан тота,—көрәштә һәм гер күтәрүдә ярыша иде). Армиядә авыр атлетика буенча спорт остасы була. Тракторчыдан башлап Азнакай районының Вахитов исемендәге совхозлар берләшмәсе генераль директоры булуга ирешә. Гомере азагында Әлмәт районында совхоз директоры иде, хәзерге вакытта Мәмәт авылында аның исемендәге урам—Мириханов урамы бар.*

*Фәнис абый (1945) КХТИны тәмамлаганнан соң Пермьдә хәрби заводта эшләп пенсиягә чыкты. Хәзер Казанда яши.*

## Министрлык

1987-91 еллар.

Министрлыкның Баш фәнни-техник идарәсендә аның җитәкчесе дә, тулаем диярлек мәскәүлеләр һәм себерлеләрдән торган коллектив та мине ничектер битараф рәвештә, хәтта ки сагаебрак та каршы алды. Озын һәм авыр күнегү-җайлашу чоры башланды. Зур аппаратка хас кырыс режимлы эш шартлары, бетмәс-төкәнмәс субординация-координация уены, линиядәге җитәкче ия булган мөстәкыйльлек-

хөрлек һәм тагын кайбер башка өстенлекләрне җую минем өскә берьюлы ишелеп төште. Илдәге гомуми вәзгыять хәлне тагын да четерекләләндерде. Гаммәви мәгълүмат чаралары бөтен бәлаләрнең дә башын "эзләп таптылар": министрлыклар, гадәттән тыш үзәкләштерү һәм икътисадны идарә итүнең тармакчыл төре икән бу. Чиновникларны "министрлык күселәре" дип кенә җибәрәләр иде.

Мин моңа күнмәдем, көрәштем. Житәкче урынбасары буларак үземнең юнәлеш буенча фәнни-техник советларда чыгыш ясадым, журналларга мәкаләләр яздым, тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен энәсеннән җебенә кадәр тикшереп кенә кабул иттем. Әмма тарих тәгәрмәче объектив рәвештә сызылган юлдан тәгәри иде инде. Министрлык хәлсезләнгәннән-хәлсезләнә барды, чөнки бюджеттан финанслау кими, аппарат берөзлексез кыскартыла иде. Бу бетмәс-төкәнмәс газапка СССР таркалу чик куйды: союз күләмендәге бөтен министрлыклар, шул җөмләдән, нефть-газ министрлыгы да, шул мизгелдә үк җан тәслим кылдылар.

Министр безне актлар залында җыйды да, министрлыкның гамәлдән чыгарылуын игълан итте. Хөкүмәт "Нефтегазстрой" концернын оештыру турындагы тәкъдимне хупламаган, "Роснефтегазстрой" акционерлык ширкәте һәм төрле-төрле ассоциацияләр корырга карар ителгән. Министрыбыз "Роснефтегазстрой"ны житәкләүдән баш тарткан һәм "Внештрубопроводетрой" тышкы икътисади берләшмәсе (ассоциациясе) президенты булган. Мин менә шушы берләшмәнең төзелеш фирмасы директоры итеп чакырылдым.

Министрлыкта эшләгәндә минем тәкъдим белән Әлмәттән Мәскәү янына, төзү-монтаж идарәләр башлыклары булып В. Малышев, И. Сәфәргалиев, А. Чекордов, А. Шәмсетдинов күчтеләр. Ягъни без "Татнефтегазстрой"ның Мәскәүдәге рәсми булмаган өлеше кебегрәк тормыш итә башладык.

*ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Мөҗәһидән Миргарифан улы—минем әти. Таза гәүдәле булганга, аны 1943 елны 16 яшендә үк армиягә алалар. Ул чорда яшьләрне саклый башлыйлар инде, әтине дә сугышның алгы сызыгына җибәрмиләр. Ул һәлак булганнарны күмә, прожекторчы була, механик-машина йөртүче һөнәрен үзләштерә, Кара дингезне миналардан арындыра, махсус бүлектә эшләп, дезертирлар аулый. Авылга 1951 елны, 8 елдан соң гына кайтып керә.*

*Ул вакытта район үзәге булган Тымытыктагы МТСка механик булып урнаша. Беренче мәхәббәте Мәфрүзәгә өйләнеп җибәрә. Бер-бер артлы балалар дөньяга килә: Назиф (1952)—мин булам, Назил (1955), Фәйрүзә (1958), Наил (1962).*

## Ярык торба янында

1991-93 еллар.

Без, министрлыкның элекке чиновниклары, көтмәгәндә-уйламаганда базар шартларында торып калдык. Дәүләт планы да юк, бюджеттан финанслау да. Теләсә ничек акча эшлә дә, җаның теләгәнчә яшә! Бик тә кызык иде бу. Без, оптимизм тулып ташкан хәлдә, "Внештрубопроводстрой" ассоциациясе исеменнән чит ил партнерлары белән бетмәс-төкәнмәс очрашулар, сөйләшүләр башлап җибәрдек.

Подольскида, бер фәнни-тикшеренү институты базасында канадалылар белән бергәләп обой житештерә торган завод—"Декор" акционерлык ширкәте, Краснодарда швед җиһазында агач эшкәртү цехы ачып җибәрдек. Америкалы партнерлар белән Мәскәүнең "Чайка" дигән ачык бассейны урынында кунакханә комплексы төзү, "Москва" кунакханәсен үзгәртеп кору буенча тендер алды тәкъдимнәрен әзерләүдә катнаштык. Бу һәм башка шундый проектлар гамәлгә ашыру җәһәтеннән артык четерекле булып чыкты һәм бернинди нәтиҗә дә бирмәде. "Чайка"ны сүтеп күпкатлы кунакханә салырга Мәскәүнең архитектура советы рөхсәт итмәде, "Москва" кунакханәсен ишүгә бары 2004 елны гына тотындылар.

Чит ил партнерлары белән уртак оешмалар корган "Татнефть" үрнәгендә "Татнефтегазстрой" катнашында инглизләр белән уртак ширкәт төзү омтылышы да булды. Әмма илдә тиз инвестицияләр җәлеп итү барып чыкмады. Безнең эшчәнлек бер алтын бөртеге табар өчен тонналап ком юдыртуга ошый башлады. Юридик затларга тышкы икътисади эшчәнлек белән мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнергә рөхсәт иткән закон оешма директорларының кызыксынуын арттырды, аларның

узләренең дөньяны инләп-буйлап йөриселәре, чит ил партнерлары белән эш йөртәселәре килә башлады.

Ассоциациябезнең төп эш нәтиҗәсе кимегәннән-кими барды.

Безнең эшчәнлек сәүдә-арадашлык гамәлләренә кайтып кала башлады. Илдә бөтен юньле нәрсәгә кытлык булу, Россиягә товар кертүдә Социалистик илләрнең үзара ярдәмләшү советы (СЭВ) илләре өчен кайбер ташламаларның сакланып калуы халык куллануы товарларын, азык-төлекне, югары басымга чыдамлы металл торбаларны һ. б. күпләп куярга мөмкинлек бирә иде әле үзе. Бу өлкәдә ару гына эшләдек.

Тора-бара базар тулылана барып, конкуренция артып, сәүдә терминалларына ия профессиональ күпләп сатучылар пәйда була башлады. Сайларга кирәк иде: шушы юнәлештә шомарыргамы, әллә... Дөресен әйткәндә, табышы булса да сәүдә эше күңелемә ятып бетми иде.


Менә шул чакларда тармак коммерция банклары ачу модага керде. Академиядә бергә укыган сабакташым, РФ "Госкомнефтепродукт"ы рәисе урынбасары Ю. Данилов "Нефтепродукт" банкын җитәкли башлады һәм урынбасары итеп мине чакырды.

Әлбәттә инде, Даниловның тәкъдименә күндем мин. Иң авыры шул булды: нефть-газ төзелеше тармагында егерме еллап эшләү дәверемдә беренче тапкыр үз теләгем белән бүтән эшкә күчерүне сорап гариза язарга туры килде.

### *ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

*Урсайда туган әниебез Мәфрүзә әтигә чыбык очы туган тия. Аның әнисе Бибиһаҗәр Нугайбик токымнары Урсайдан күчеп китеп салган Яңа Урсай[1] авылы кешесе Әхмәтшәкурның кызы. Бибиһаҗәр әби (1903—1998) белән аның ире Миңнулла (безнең бабай)[2] бергә Урсай авылында тигез озын гомер кичерделәр.*

*Миңнулла бабай беренче бөтендөнья сугышында әсир төшеп, дүрт ел Австрия алпавыты плантацияләрендә эшли. Брест солыхыннан соң әсирләрне алмашкач, Кызыл армиягә эләгә. 1922 елны, ниһаять авылга кайтып житсә, аны ишелергә торган бүп-буш өй каршылый. Әти-әнисе һәм сигез энесе-сеңлесе 1921 елгы ачлыктан үлгән була. 1938 елны агротехник Миңнулланы колхозның орлык бәрәңгесе черегән өчен халык дошманы дип төрмәгә утырталар. Фин сугышы башлангач, Ватан алдындагы гаепне кан белән аклау өчен ирекле рәвештә сугышка җибәрүләрен сорый ул. Фин кампаниясеннән соң япон-*



*Оныклар барда шәҗәрә өзелмәс! 2005 ел.*

*нар белән булган Хәсән күле сугышына эләгә. Гаебе акланып авылга кайтуга ике ай да үтми, Бөек Ватан сугышы башлана.*

*Миңнулла бабай бу сугышта башта разведка взводында була, "тел" алган өчен "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләнә ("Башына бер тондырдым, капчык кидердем, җилкәгә салдым да, кайтып житкәнче чаптым да чаптым"). Сталинныкыдай кәттә мыеклы, озын буйлы, көчле-гайрәтле ир-ат иде бабай: Шул озын буе аркасында чак кына теге дөньяга да китеп бармаган. Траншеядан иелеп-сыгылып йөрүдән гарык булып, бил язып алыйм дип тураюы була, снайпер пулясы уң янагыннан кереп, юл уңаенда азау тешләрен дә коеп, сул янагыннан чыга. Госпитальдә ятканнан соң аны саперлар отделениесе командиры итәләр. Отделение кышлаклардан җыелган, русча бер авыз сүз белмәгән үзбәкләрдән гыйбарәт була. Бабай боерыкларын татар телендә индерә. Төзиләр-сүтәләр, миналарны*

---

[1] Башкортстанның Бакалы районы
[2] Нәбиуллин Миңнулла Нәбиулла улы (1898 – 1987)

*зарасызландыралар, күперләр шартлаталар. Сапер бер генә тапкыр ялгыша диләр. Миннулла да бер тапкыр ялгыша—минага баса. Бер аягы өзелгән хәлдә җир астыннан казып алалар аны. Госпитальдә наркозсыз-нисез аркылы пычкы белән аягын кискәндә йөрәге тибүдән туктый. Салкын сарайда анга килеп, үзен мәетләр арасында күргәч, яман акырып җибәрә. Күпне күргән санитарлар аны ис китмичә генә "якты дөньяга" кучереп куялар.*

*1943 елны Миннулла америкaн протезын шыгырдатып авылга кайтып төшә. Протезга күнегә алмый, үзенә җайлап агач аяк ясап кия. Протез исә, без бала-чага күнеленә шом салып, озак еллар чоланда асылынып торды.*

*Бабай 1945 елгача колхоз рәисе була, сонрак агротехник булып эшләде. Пенсиягә чыккач, ун ел рәттән алачыкта колхоз арбалары өчен тәгәрмәч сукты. Без алачыкка килеп анын күз иярмәс тизлек белән эшләгәнен күзәтеп торырга ярата идек.*

## Банк

1993-98 еллар.

Идарә рәисе урынбасары буларак мина филиаллар челтәрен, банк катнашында төрле юнәлештә фирмалар һәм инфраструктура булдыруны, инвестиция эшчәнлеген, кучемсез милек белән операцияләрне, кредит алган эшмәкәрләрнен бизнес планнарын тикшерүне, зур завод, оешма җитәкчеләре—VIP клиентлар белән багланыш тотуны йөкләделәр.

Эш тагын мине баш-аягым белән йотып алды. Яңа даирәне үзләштерү, хисапсыз очрашулар, берсе икенчесенә ялганган командировкалар...

Дәүләт структуралары тарафыннан оештырылган банк буларак, без дәүләткә хас бөтен үзенчәлекләрне дә йоктырган идек. Бу хәл үзен сиздерми калмады.

Кризис билгеләре нефть промышленносте үзгәртеп корылгач, ягъни тармаклар юк ителеп, нефтьне чыгарудан алып сатуга кадәр бөтен процессларны да эченә алган, вертикаль рәвештә берләштерелгән, интеграция ясалган нефть компанияләре оештырылгач сизелә башлады. Безнең кендек анабыз—нефть продуктлары дәүләт комитеты җан тәслим кылды, гамәлгә куючыларыбыз—"Нефтепродукт" берләшмәсенең республика һәм өлкә берләшмәләре яна оешкан төрле-төрле нефть компанияләренә таралышып беттеләр. Аларның күпчелеге (безнең устав фондының 37 процентын да эләктереп), "Сиданко" компаниясе карамагына күчте. Әмма "Сиданко" безне танырга теләмәде, аның "ОНЭКСИМ" атлы банкы бар иде инде. Без беркемгә дә диярлек кирәкмибез булып чыктык.

Сонрак банкара кризис һәм дефолт үз эшләрен эшләделәр. Безнең банк акчасының зур гына өлеше "Аэрофлот", "ВББ", "Эскадо" банкларында терәлеп калды. Мин ликвидация комиссиясендә кердем, һәм үзем өчен төп бурыч итеп Әлмәт филиалы клиентлары белән исәп-хисап ясауны билгеләдем, ягъни үземне туган Татарстаным белән тоташтырган күпернең януын теләмәдем. Максатка ирешелде—бурычын аерып чыгарып, филиалны "Зенит" банкына саттык. Әлмәттә ул филиал хәзер дә әйбәт кенә эшләп ята.

1997 елны кызым Чулпан кияүгә чыкты.

Ликвидация комиссиясендә чакта ук яна эшкә дәшүләр булды. Шулардан иң мөһимнәре: "Зенит" банкына Татарстан белән эш алып баручы идарә рәисе урынбасары итеп; Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы Вәкиле урынбасары итеп.

Мин соңгысын сайладым.

### *ШӘҖӘРӘ ҖЕБЕ*

***Гираят би шәҗәрәсенең дөреслеге һәм Н. Мирихановның нәселе турында чыганак экспертизасы нәтиҗәсеннән:***

*Төрки-мөселман халыкларының шәҗәрәләре фәнни әйләнешкә XVIII гасырда кертелде, алар тулы кыйммәтле тарихи мәгълүмат чыганагы дип карала...*

*Гираят би шәҗәрәсе берничә вариантта сакланып калган. Аларның кайберләре археографик экспедицияләр вакытында Татарстанның көнчыгышында (Азнакай районы) һәм Башкортстанның көнбатышында (Бакалы районы) табылган... Вариантларның барысына да буыннарны санау, исемнәрне язу һәм теркәлгән затларның өлкәнлек дәрәҗәсен күрсәтүдә уртаклык хас, беркадәр орфографик*

*үзгәлекләр мондый төр чыганаклар өчен котылгысыз дип санала, һәм бу хәл генеологиянен чынлык дәрәҗәсенә тәэсир итми. Шул ук вакытта Гираят би шәҗәрәсенен Н. Мириханов гаиләсендә саклана торганы күп өлеш кинрәк тә, тулырак та. Беренчедән, ул хәзерге замангача житкерелгән, икенчедән, фәнгә мәгълүм башка версияләрдән аермалы буларак, анда Гираят бинен үзенен элгәрләре дә санала. Шәҗәрәнен бу вариантынын төп өлеше Гираят бидән алып Нугайбикнен улларына каләрге вакыт аралыгында архив вариантлары белән тәнгәл килү генеологиянен Гираят бинен элгәрләренә караган өлешенә дә ышанып карарга мөмкинлек бирә...*

*...Бәян ителгән барча дәлилләрдән чыгып, без Гираят би шәҗәрәсе Н. Мириханов нәселенен чын тарихын чагылдыра дип саныйбыз. Гираят би нәселе исә Чыңгыздан булмаган, аристократик рангка инде урта гасырларда ук ирешкән төрки нәселләренен берсе дип каралырга тиешле...*

**В. ТРЕПАВЛОВ,**
*Россия Фәннәр академиясенен*
*Россия халыклары тарихы һәм*
*милләтара мөнәсәбәтләр үзәге житәкчесе,*
*тарих фәннәре докторы.*

## Вәкиллектә

Шулай итеп, 1998 елда мин Тулы хокуклы Вәкилебез Ф. Мөхәммәтшиннын урынбасары булдым. Фәрит Мөбарәкшович белән ул әле Россия Федерациясенен Тышкы эшләр министрлыгында эшләгән чакта ук татар "Зыялылар" клубында танышкан идек. Шул вакыттан бирле үзара әйбәт, якын мөнәсәбәт һәм хезмәттәшлек урнашты. Хәзер Ф. Мөхәммәтшин Россия Федерациясенен Үзбәкстандагы Илчесе.



*М. Шәймиев, Ю. Лужков кебек олуг затлар янында Н. Мириханов та һич артык түгел. 2003 ел.*

Эшкә билгеләнүгә кадәр Татарстаннын Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйруллович Мөхәммәтшин белән ныклы сөйләшү булды. Әлбәттә инде, ул чакта да, бер елдан сон, мине Вәкил итеп билгеләгәндә дә карарлар бары Татарстан Президенты М.Ш. Шәймиев тарафыннан кабул ителде.

Бөтен үткән гомерем һәм хезмәт биографиям хәзерге эшемә әзерлек булган сыман тоела мина. Янә туган Республикам белән ялгаган язмышка рәхмәтлемен.

*Тормыш хронологиямнән: Вәкиллектә эшләү дәверендә улым Илнур өйләнде, оныкларым Тимур, Сәлим, Камил дөньяга килделәр. Гомер буйлап бару дәвам итә...*

⁂

*Дискуссия: “Безнең заман герое”*

**Алсу Шәмсутова**

# “ТАРИХ ТАНЫЙ—ИҖАТЫНА ҖАННАРЫН САЛГАННАРНЫ...”

“Безнең заман герое” дискуссиясе кысаларында язылган мәкаләләрне карап чыккач, “әйтелгән фикерләрдән дә артыграк итеп тагын нәрсә хакында язып була инде?!” дигән сорау да туып куя. Чөнки тәнкыйтьчеләр һәм галимнәр күрсәткән уңай яисә кимчелекле якларны бүгенге татар әдәбияты җирлегенә күчереп, “салкын” акыл белән үлчәгәч, аларның фикерләрендә сүз сәнгатенә карата куелган заман таләбенең катгыйлыгын да, гади укучының өметен дә тоясың. Үз агымына салмак кына агып яткан әдәбият өчен бик тә кирәк иде мондый фәнни-тәнкыйди бәхәсләр.

Ләкин шул ук вакытта дискуссияне оештырганда әдәбияттагы безнең заман героен күрсәтүне таләп итеп, язучыларның теге яки бу әсәр җирлегендә укучы өчен әйтергә теләгән кыйммәтле күрсәтмәсен—ИДЕЯСЕН истән чыгармадылармы икән дигән фикер туа. Ни өчен дисәң, дискуссиядә катнашкан күпчелек авторлар нәкъ менә герой-каһарманны эзләү, сурәтләү, әсәрнең телен анализлау белән мавыгып, укучыга нинди рухи азык бирүен дәлилләү юлына киләләр дә төшәләр, ә әдәбият-сәнгатьнең бүгенге милли-иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтән чыгу юлын күрсәтү бурычын (ә бу, минемчә, әсәр идеясенең үзәге) игътибардан читтә калдыралар.

Минемчә, әсәрләрнең идеясе генә анда тудырылачак геройның холкын, эш-гамәлләрен, аның аша укучыга бирелергә тиешле рухи-гамәли үрнәкне тәэмин итә. Әгәр дә әсәрнең укучыга нәрсә житкерергә тиешлеге алдан билгеләнмәгән икән, теге яки бу тарихи, иҗтимагый вакыйганы күрсәтү генә, аның фаҗигалелеген дәлилләү генә укучыны яңа фикерләргә, үз тормышын үзгәртү юлында нәрсәдер эшләргә этәрми. Мин бүгенге прозадагы күпчелек әсәрләрне укыйм да, үзем көткән менә шушы “җилек”нең (стерженьның) булмавын тоям. Ярый бер ике әсәрдә генә шулай ди, ә бит дистәгә якын роман-повестьның шушы характерда булуы мондый әсәрләрне инде укыйсы килмәү теләген көчәйтә генә. Чөнки мин аларның күбесендә үзем өчен рухи азык та, тормыштагы ситуацияләрдән чыгу юлын да, милли горурлыкны ныгытучы очкын да, милләт буларак үземне, гаиләмне һәм баламны сакларга өйрәтүче үгет-нәсихәт, күрсәтмә дә таба алмыйм. Ә бит әдәбият “өйрәтергә”, тәрбияләргә тиеш. Әллә инде аның шушы вазыйфалары без күрми калган яңа вазифаларга алышынганмы?!

Үткән тарихны “сагынып” язылган бер типтагырак романнардан, совет идеологиясенең татар милләтен эчүчелеккә, рухи кризиска китереп җиткерүен тасвирлаган дистәләрчә повестьтан “арып”, аптырагач, дөньяның ирреаль моделен тудырырга алынган, тормышны онытып торырга ярдәм иткән постмодернистик, сюрреалистик әсәрләргә “чумасың”. Әмма татар әдәбиятының сәнгатьчә үсешен, бер баскычка алга омтылышын дәлилләгән мондый әсәрләр, безнең заман кешесен “прототип” итеп кенә биргән әсәрләр кебек үк, укучыга “канатланып яшәргә”

ярдәм итә торган идеяне бирә алмый бит. Татар әсәрләренен сирәк укылуынын сәбәбе дә менә шунда ятмыймы икән?! "Безнен заман герое" дигән дискуссияне оештыруның бер максаты да менә шушының белән бәйле түгелмени?!

Идеяләре "ялкынлы" ук булмаса да, яшәү рәвешен алыштыру кирәклеген яки татарның инкыйразын тәртеп күрсәткән мондый әсәрләр юк түгел: прозада да, поэзиядә дә, драматургиядә дә бар андыйлар. Әмма... Әмма хикмәт мондый әсәрләрнен ничек пропагандалануында, укучы тарафыннан кабул ителүендә, сәхнәдә куелу-куелмавында.

Минем үзем өчен рухи азык, ныклы идея биргән әсәрләрнең берсе Фәүзия Бәйрәмованың "Алыплар илендә" повесте булды. Әсәрнең корылышына ук татар укучысына милли-рухи үлүдән (инкыйраздан) чыгу юлын күрсәтү омтылышы салынган. Геройларны типиклаштырып (Сәлим, Жиһангир, Рәйханалар—безнен татар тормышының, авылының типик вәкилләре!) бирү, яки төп герой булган кечкенә малайның дин юлына кереп китүе (кемгәдер гадәттән тыш, тормышта була алмаслык хәл кебек кабул ителергә дә мөмкин), Коръән аятләрен, мотивларын үзенчәлекле сурәт тудыру алымнары аша әсәр жирлегенә "чигеп" бару—болар барысы да язучының әйтергә теләгән идеясен укучыга житкерергә булышлык итә.

Автор "Бөтен кайгы-хәсрәтләрегез динсез яшәгәннән" дигән фикерне әсәрнең үзәге итеп алып, аның тирәсендә динсезлек-жаһилият тормышын һәм иманлы геройларның яшәү максатын тасвирлауга нигезләнгән сюжет сызыгын кора, геройларның фикерләрен шушы яссылыкта бәрелештерә, шуның аша татар өчен мөһим булган "Татарны ничек саклап калырга" дигән идеяне яктырта. "Син... динне, Коръәнне өйрән, анда бар нәрсәгә жавап бар. Болай, Аллаһ язган тарихны әйләнеп үтеп, ...ялгыш юлга кереп китәргә мөмкинсез. *Дөнья шуна да күп сорауларга жавап таба алмый инде, күп нәрсәләрне хәл итә алмый, чөнки жавапны Аллаһ китабыннан эзләмиләр...*" (ассызык безнеке.—А.Ш.) дигән хакыйкәи, асыл фикер безнен татар тормышында кин таралган: "Ә син нишләрсен ул намазын белән, әйтик, мәктәптә, дәрес вакытларына туры килгәндә? Көлдермә үзеннән! Менә бабай булгач, бәлки, мин дә укырмын әле... Ә хәзер яшәп калырга кирәк" дигән фикер белән каршылыкта ачыла. Кызганычка каршы, татарның күпчелеге шушы соңгы фикердә тора. Аллаһның барлыгын, берлеген тануга без күпвакыт ниндидер тетрәнү, фажига кичергәч кенә ирешәбез. "Бу каралык эчендә ак булып калу бик авыр шул. Бик авыр".

Адәм баласының Жирдә бернәрсәдән дә курыкмавы анын көчлелеген исбатламый, киресенчә, яшәеш, үзенен ни өчен тудырылышы хакында онытуын дәлилли. Бернәрсәдән дә курыкмау әдәп-әхлак кагыйдәләренә төкереп карауга, жинаятьчелеккә, бозыклыкка илтә. Хәтта, ижтимагый законнар да куркытмый кайчак кешене. Ф.Бәйрәмова әсәрдә "Ни өчен?" дигән сорауны конкрет күрсәтмәсә дә, аңа жавапны кат-кат тәкърарлый. "Кеше бәндәдән түгел, Аллаһтан курыкса гына хәрамнан тыелачак... Үлемнән курку, авырудан курку, кешедән курку вакытлы гына булырга мөмкин. Аллаһтан курку кирәк. Аның каргышыннан, ачуыннан курку кирәк. Һәм ул әйткәнчә яшәү кирәк...".

Повестьның үзәгендә Аллага сыену мотивы ята, шуның белән бергә *Аллаһның жәзасы мотивы* да килеп керә. Имансыз, динсез яшәгән, исереклеккә, зинага, хәрамга батып беткән бәндәләргә авырулар, хәтта эчкечелек үзе дә, аның белән бәйле фажигалар да "Алланың жәзасы булырга да мөмкин, намазсыз, догасыз яшәгәнгә..." дигән фикерне куәтли. Жәза мотивы әсәрдә давыллы төн эпизоды, йортларның жимерелүе, яшен сугу вакыйгалары аша дәлилләнә.

Аллага сыену мотивы аша Ф.Бәйрәмова барлык укучыларның да иң мөкаддәс соравы булган һәм татар әдәбиятының төп мотивларыннан берсе саналган *бәхетле булу мотивын* да ачып бирә: "Сез Аллаһ кушканча яшәмисез, бөтен бәхетсезлегегез шуннан", "Аллаһ кушканча яшәмәсән, бәхетсез буласын икән... Юк икән, бу дөньяда үз белдегең белән яшәргә тырышсаң, әйләнәсең дә шул бәхетсезлегенә килеп чыгасын икән"(!).

Повестьта күрсәтелгәнчә, бәхетсезлек хәрамнан тыелмаудан, "билгеләнелгән чикне" узудан башлана. "Ниндидер бер чикне үтсә, ...Камил үзе дә исерек әтисенә охшый башларга мөмкин иде. Бу чик шундый нечкә иде, Камилә сөйләгәннәр шундый кызыктырырлык иде, Камил бу дөньяның авырлыгыннан, каралыгыннан

инде яши башлаганчы ук шундый туйган иде. Әтисе кебек булырга ана бер адым ясау житә иде...".

Әмма Ф.Бәйрәмова татар халкын "басып алган" бозыклыкның сәбәпләрен дә игътибардан читтә калдырмый. "Халык өметсезлектән эчә, гаделсезлеккә жавап итеп эчә, үз жиренә үзе хужа була алмаганга гарьләнеп эчә". Димәк, чарасызлык, ягъни "Нишләргә?" дигән сорауга жавап таба алмау татар милләтен тормыш чигенә китереп житкергән. Ф.Бәйрәмова, "халыкка ярдәм итәргә кирәк" дигән максатны күз алдында тотып, үз әсәре мисалында шушы чарасызлыктан чыгу юлын күрсәтә. Бәхеткә илтүче юлларның берсе итеп намаз уку, һәрвакыт Аллаһны истә тоту кирәклеге әсәрдә кат-кат ассызыклана.

Аллаһны оныткан, дөресрәге, бар дип тә белмәгән кавемнен язмышы борчып кына калмый авторны, ул әлеге күренешнең ахырын күрәзәчелек итә. "Нух пәйгамбәр көймәсе" романында иманын саклап калган һәм күпмедер елдан кабат туган жиренә әйләнеп кайта алган Әтил карт үз илендә татарлардан исән калган берләнбер вәкил була: "Бу илдә аның инде теле дә, дине дә, нәселе дә калмаган иде... Бу илнең инде үзенең дә көннәре санаулы гына калып бара иде...". "Бозык кавемнәрне Аллаһы тәгалә юк итте" дигән Изге Коръәннән үк килә торган һәм Гаяз Исхакыйның "Ике йөз елдан соң инкыйраз" әсәренең нигезенә салынган кисәтү Ф.Бәйрәмованың бу әсәрендә фәлсәфи мотивка кадәр үстерелә.

Ф.Бәйрәмованың соңгы чор прозасы тормыштагы гадәттән тыш вакыйгаларның "очраклылыкмы, могжизамы" икәнен дәлилләүгә ярдәм итә: "...Болар берсе дә очраклы түгел иде. ...вакыйгалар берсе артыннан берсе чылбыр кебек тезелеп киләләр, бер нәрсәгә икенчесе сәбәпче була. Иң мөһиме—хәтта иң авыр кебек тоелган бәла-казалар да кешенең үзен саклап калдыруга юнәлтелгән була...". "Бу вакыйгаларның, кешеләрнен, сәбәпләрнен артында зур илаһи көч торганлыгын, бу эшләрнең барысы да Аллаһ эше икәнлеген" һәр татар укучысына, ниһаять, аңлатучы табылды! Ниһаять, татар укучысына Жир тормышының уен яки театр түгел, ә "гыйбадәт" икәнен, безнең барыбызның да Тудыручыбызны "тану өчен" "бер Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелгән", "бу дөньяны бары тик иман гына коткарачак" икәнне аңлаткан иманлы, анык идеяле әсәр дөнья күрде!

Шигърияттебездә бармы соң мондый идеяле һәм шул идеяне укучыга илтүче лирик геройлар? Татар поэзиясенең бүгенге торышын яктырткан З.Мансуров *("Каләмебез илаһи антка тугрымы?", Казан утлары, 2004, 7-сан)* һәм И.Вәлиуллин *("Яңа маяклар эзләгәндә", Казан утлары, 2004, 8-сан)* үзләренең язмаларында үзгәртеп кору һәм аннан соң булган демократик-анархистик ижтимагый торышны, милли активлыкны чагылдырган шигырьләрне барлыйлар. Әмма алар күрсәткән әсәрләрнең лирик каһарманы дискуссия таләп иткән "заман герое" булуда бәхәс уята, чөнки бу әсәрләрнең авторлары үрнәк герой бирүдән битәр, минемчә, агымдагы хәятның теге яки бу вакыйгасын (ягъни теманы) сурәтләүне үзмаксат иткәннәр.

И.Вәлиуллин поэзиядә яшәеш фәлсәфәсе турындагы шигырьләр аз дигән карашта тора. Шөкер, бүгенге шагыйрьләрнең ижатларында нәкъ менә кешенең Жирдәге билгеләнеше, яшәү максаты, Илаһият турындагы шигырьләр шактый. Өлкән буын шагыйрьләре И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Зөлфәт, Х.Әюпов, Н.Гамбәр генә түгел, ә яшьләр—Л.Янсуар, Р.Аймәт, Г.Вәлиева, Ч.Зариф ижатында да дөньяга карашны, язучының үз миссиясен аңлауны чагылдыручы көзге булып торалар алар.

Айдар ага Хәлим үзенең татар әдәбиятын "жиз иләк"тән үткәргән "Сез беләмсез кая барганны?" мәкаләсендә *("Казан утлары", 2005, 1,2 саннар)* бүгенге көндә язылучы әсәрләргә ныклы бер үзәк—Иман кирәк дигән карашны күтәреп чыга һәм аны кат-кат тәкърарлый: "Илаһияты, иманлылыгы сурәтләнми калгач, ничек итеп илаһи, иманлы милләт тәрбияләргә мөмкин?" Моның белән килешмичә калган кеше бик аздыр. Авырткан жирнең нәкъ өстенә басып әйтә А.Хәлим, Коръән аятьләрендә еш кабатлана торган, һәр заман өчен көн тәртибендә кала килгән, әмма һәр чорда да бик азлар гына ишетә, уйлана торган *"Кая юл тотасыз?"* дигән фәлсәфи-метафорик сорауны татар язучысы һәм укучысы алдына ачыктан-ачык куя. Ә бу сорау адәм баласыннан—Язучымы ул, Укучымы—АКЫЛ һәм РУХИЯТ яссылыгында фикер йөртүне таләп итә.

Бер язмада татар әдәбиятының иман яңартуын күрсәтергә теләптер, ахыры, Р.Зәйдулла әсәреннән "...Без—имансыз түгел. / Ул күз яшьтә, аккан каннарда"

дигән өзек китерелгән иде. ("Бисмилла" дигән бу шигырьдә Р.Зәйдулла бүгенге көн татар вәкиленен әйтергә теләгәнен житкергән, әсәрнең идеясе анда ачык чагыла, күпчелек татар менә шулай уйлый). Язманың авторы шушы юллар белән татар шагыйрьләренең А.Хәлим әйткән Иман юлына басуынмы, әллә әдәбиятыбызда иманлылыкның ныгуынмы дәлилләргә теләгән икән?!. Әмма, болай дип бары тик совет идеологиясендә тәрбияләнгән һәм дин кысаларына керергә теләмәгән яки керә алмыйча жәфа чиккән бүгенге татар кешесе генә әйтә ала. Инде бер гасырга якын имансыз яшәргә күнеккәнлектән үз-үзен тынычландыру өчен әйтелгән сүзләр түгелмени бу?! Әгәр дә әлеге юлларның мәгънәсен ачыклый китсәң, кызыклы гына фикер сөреше туа. Житмеш ел буе хәрам ашап, хәмер-аракы эчеп үскән буынның күз яшендә һәм канында нинди Иман булсын ди?! Алардан да шул ук хәмер, дуңгыз ите, тозлы нефть суы исе килә түгелме?! "Бу халык иле белән үк Хәрамга баткан!" дип дөрес әйтә Зөлфәт.

Язучы һәм шагыйрьләрнең үзләре инде оныта башлаган (әллә бөтенләй белмәгән дәме?!) Илаһи билгеләнешен (шагыйрьләрне "Пәйгамбәрләр" дип атый!) искә төшерү жәһәтеннән, бүгенге татар тормышын һәм андагы "каһарманнарны" чагылдыру, укучыга тәэсире ягыннан Зөлфәтнең "Сынавы микән?" дигән шигыре бик дә актуаль һәм чынбарлыкка туры килеп тора.

Иблис корган бу илнең
Яшәве—хата!
Фәрештә төшеп кунардай
Урын юк чакта,
Кешелекнең ак намустай
Пакъ көннәреннән
Мәңге кот кунмас бу илгә
Пәйгамбәр иңгән...

"Безнең заман герое" кысаларында тәнкыйтьче һәм галимнәрне борчыган, алар җавап таба алмый азапланган "Ни өчен бүгенге әдәбиятыбызда сәнгатьчә эшләнеше түбән" булган, зиначылыкны, көч куллануны сюжет сызыгының әйдәп баручы доминантасына әвереллерелгән әсәрләрнең күбәюенә шушы ук әсәрендә Шагыйрь бик дөрес итеп җавап та бирә.

Пушкин кирәкмени ана?—
Пугачев кирәк!
Ургылсын кан бугазлардан.
Жир торсын тетрәп!

---

Ничек аңласын шагыйрьнең
Илаһи утын!

"Рәхәт үлем" дигән шигырендә Зөлфәт укучыны уятырга теләп, "Үз-үзеннең мескенлеген таныл, / ***Курыксаң да, уянсана, халык!***" дип дәшеп карый. Әмма фикерле укучыны мондый чакыру, өндәүле юллар түгел, ә:

Кем бу милләт—тәмугъ учагына
Ыргытасы коры утынмы?

—дигән билгеләмә сискәндерә. Ни өчен "фикерле укучыны" дидек, чөнки иманы юк укучыны тәмугъ белән куркытты̆ң ни дә, Хисап көне белән кисәттең ни! Ул су басудан, Жир тетрәүдән дә түгел (чөнки алары да Ходайдан), ә кешедән ким яшәүдән курка!

Димәк, татар укучысы уянсын дисәң, сискәндерерлек итеп "кычкырырга" кирәк. Харрас Әюпов кебек. **"Ачыгыз капка"** (1991) дип исемләнгән шигырендә автор бер татар вәкиле исеменнән һәм бер татар кешесе өчен генә сөйләми. Күпләрнең жаны татар теле, татарның киләчәге турында әрнегәндә, Х.Әюпов милләтнең уллары - кызларының битараф "күңел ишекләре"н дөбердәтеп, "Ачыгыз капка" дип "кычкырып йөри":

Туган телегез торадыр
Бөрешеп чатта.

"Кешелеген җуйган" бу кемсәләр "дәвернең хәтәр җилләре куырган чакта", нәкъ безнең татарларча итеп, "бикләнергә өлгергәннәр житешеп алдан". XX гасыр башында бөек шагыйребез Тукай татар халкын битарафлык, мәнсезлек йокысыннан уятырга теләгән кебек, Х.Әюпов та "уяныгыз ла тизрәк" дип җан ачысы белән кычкыра.

"Ачы-ы-ы-гыз".—Татарның туган телен һәм моның йөртүче ***рухы*** кирәксез, кадерсез булып урамда (чорлар арасында) ятим кала түгелме соң?! "Ятим калган йөрәк" төшенчәсендә әнә шул милли рухны чамалау авыр түгел:

Беркайчан бирмәгез Моңны,
Бирмәгез ятка...
Йөрәкләрегез урамда...
Ачыгыз капка!

Кем әйтмешли, монда бары "психологик кичерешләр" генә түгел, монда фикер орлыгы. Мондый әсәрләр туа икән, димәк әле татар халкының инкыйраздан котылу мөмкинлеге бар.

"Безнең заман герое"н эзләү максатыннан башланган бу дискуссия агымдагы әдәбиятның уку өчен кызыклы булуын гына түгел, ә киләчәге хакында да уйланырга мәҗбүр итә. Килер буыннарга үзенчәлекле образлар тудырган, яңа төр сурәтләү алымнары кулланган гына түгел, ә милли ИДЕЯне яктырту максатыннан милли лидер-герой тудырган, милли үзаңны үстерә, милли горурлыкны ныгыта торган әдәби әсәрләр барырга тиеш. Инде бүген әдәбиятка альтернатив булган сәнгать төрләре, төгәлрәге кино сәнгате артык активлашып, укучыны гел үзенә "каратып тота". Фильмнары үзләренең мавыктыргыч булулары белән дә, динамика ягыннан да аерылып тора. Бүген сәнгать белән кызыксына торган яшьтәге балаларны гасырның тагын бер ачышы—Интернет та үзенә суыра. Менә шулардан аерып алырлык, һәм дә детектив-коточкыч фильмнарда булмаган рухи азыкны бары тик әдәбият, югары дәрәҗәдәге сәнгать әсәре генә бирә. Шундыйлар гына татар әдәбиятын дөнья әдәбияты дәрәҗәсенә күтәрә ала. Мондый әсәрләрдә, беренчедән, образлар сәнгатьчә югарылыкка күтәрелгән булырга тиеш. Икенчедән, әдәбият яшәсен, аны яшьләр укысын дисәк, аңа сәнгать әсәре буларак мәктәптән үк мәхәббәт уятырга, аны аңлый белергә өйрәтергә кирәк.

Ә бүгенгене реалистик тасвирлауга корылган әсәрләрнең күбесендә геройның әнә шул сәнгатьчә югарылыкка күтәрелеп җитмәве, әсәрдә тәрбияви функциянең, зәвыкне үстерү өчен алынырга тиешле фәлсәфи, экзистенциаль характердагы чигенешләрнең булмавы күзгә ташлана. Ә бит әдәби әсәрләр өлкән апалар һәм агайлар укысын өчен генә түгел. Бүген язган әсәрләрне авторлар киләчәктә дә укылуын телиләрдер, шәт. Киләчәктә аларны нәкъ менә мәктәп һәм югары уку йортларында өйрәтәчәкләр бит. Ә белем бирүдә исә әсәрне реалистик планда язылган, укучыга җинел аңлашыла дип һәм бүгенгене тасвирлаган дип кенә, аның сәнгатьчәлелек ягына игътибар итмичә генә сайлау дөрес түгел. Хәзерге мәктәпләрдән күп вакыт әсәрнең эчтәлеген сөйләүдән ары китә алмаган, аның идея-эстетик кыйммәте хакында, язучының фәлсәфи карашлары турында берни әйтә алмаган укучылар килә. Аннары бүгенге әдәбиятны укыту-өйрәтү аның агымдагы процесс булуы белән дә катлаулана. Димәк, без бүгенге әдәбият хакында сөйләшкәндә, иң беренче нәүбәттә, әнә шуны төп фон итеп куярга һәм әдәби әсәр каһарманын эзләүне дә шуның белән бәйләргә тиешбез. Шушы фикерләрдән соң әдәбиятыбызның өченче төре—драматургия тудырган милли идеяле, үрнәк яки гыйбрәтле каһарманлы әсәрләрне барлауга күчәсе килә.

Хәзерге татар драматургиясе тематик яктан да, проблемалар ягыннан да үсә, баеп тора. Драматургиягә әледән-әле яңа исемнәр, яңа әсәрләр өстәлә бара. Бу хакта драматургия белгече, галим Азат Әхмәдуллин "Илдә барган кискен вакыйгалар эчендә драматургия жанры да үз урынын табарга, сәхнәне заманча әсәрләр белән тәэмин итәргә омтыла",—дип язган иде *(Казан утлары, 2004, 7-сан)*. Ләкин тема яңалыгы гына әдәбиятны үстерә алмый бит әле. Монда һаман да сүз сәнгатенең башкарган вазифалары (эстетик, тәрбияви, идеологик) зарур булып кала. Бу вазифалар беренче чиратта әсәрләрдә сурәтләнгән, төп ИДЕЯ һәм аны ачуга хезмәт итүче **геройлар** белән турыдан-туры бәйле.

Соңгы егерме ел эчендә язылган сәхнә әсәрләрендә татарның бүгенге вәзгыяте белән бәйле булган һәм без көткән унай герой (ә ул әйдәп баручы булырга тиеш бит) күренми. Монда да Д.Заһидуллина әйткән "унай герой югалу тенденциясе" *(Казан утлары, 2004, 10-сан)* чагыла. Безнең игътибарга бүгенге драматурглар фикерле, кыю идеяле әсәрләр түгел, ә күз яшенә яки көлүгә корылган мелодрама һәм комедияләрне күбрәк тәкъдим итәләр. Әмма алар арасында үзләренең кискен милли идеясе белән сискәндерә торган пьесалар да бар. Андыйлар татарның киләчәгенә оптимистик ышаныч тудыру аша түгел, ә милләт яшәешенең антиутопиясен бирүләре белән тетрәндерәләр.

Шундыйларга мисал итеп **Ризван Хәмид** иҗатын атыйсы килә. Ул татар сүз сәнгатенең үзенчәлекле геройлар галереясенә кызыклы гына ачышлар, яңалыклар алып килгән драматург. Аның иҗатында маңкортлыгы белән татар милләтенең киләчәгенә нокта куярдай Гәрәй-Гаррилар, туганнары-нәселе рухына үз принциплары биеклегеннән карый торган һәм тормышта үзе төзегән канун буенча яши торган Илсурлар, "милләтнең хәтере" булып кына калган Нәүхәбәрләр аерылып тора.

Геройларны ачу, алар аша татар укучысына әйтергә теләгән идеясе ягыннан ***Р.Хәмиднең "Актамырлар иле" трагедия-реквиемы*** игътибарга лаек. Бу әсәрне югары уку йортында гына түгел, ә мәктәп балаларына да укытырга, шул рәвешле аларны "үле җаннар" булудан саклап калырга кирәк. Әйе, әсәрнең "реквием" дип аталуы да бер сәерсенү тудыра. Ни өчен әле трагедия генә түгел, ә "реквием"? "Реквием" үлгәннәргә багышлап иҗат ителә торган әсәр. Шуның белән автор алдан ук укучысына "үлгән милләт"нең тарихын сурәтләячәген кисәтеп куя түгелме?

"Актамырлар иле"ндә бер татар нәселе мисалында татар халкының җыелма образы тудырыла. Хода һәм Тәңре дигән мифик образлар яктылыгында Мөштәри карт аша татар халкының кайчан, ничек һәлакәткә дучар булуы сөйләнелә. Мөштәри картның буынын схематик рәвештә тасвирлап, шуны ачык күрергә мөмкин: өлкән буыннан ерагайган саен татар токымы бетә, деградацияләнә, әсәрдәгечә әйтсәк, "киләчәк буынга тапшырыласы рухи мирас тапшырылмый кала", аны тапшыруны һәм кабул итеп алуны кирәк дип санаучы да юк.

Рухи мирасның җимерелүе Мәрәс буыныннан башлана, ул үзенә ата-анасы баглаган өметне акламый. Автор монда Мәрәс, Гарри кебекләрне тәрбияләүдә бары ата һәм ана җаваплы дигән фикерне басым ясап әйтә. "Гарри"ларның тууында да татар хатыннары—Фаягөлләр—сәбәпче. Бәкер кебек кеше талап аракы эчеп йөрүче, Фаягөл кебек үз баласын тугач та чүплеккә аткан ! бәндәләрдән туган Гәрәй-Гарри милләтнең өмете, нәсел тудыручысы булган татар кызын—Фәридәне—ата-бабалары кабере өстендә көчли. Үз әнисен һәм туган телен кулланмаган Гарри өчен кызларның сафлыгы ни дә, зират һәм кабер ташы ни! Татарның бүгенге вәкилләренең асылын ачу өчен кулланылган бу беренче эпизод булса, алга таба әсәрдә тагын бер метафорик эпизод тудырыла. Гарри үз баласын имезергә дип ана дуңгыз астына куя. Әсәрдә бу—чәчләр үрә торырлык икенче момент. Бу эпизодтан берничә ассоциатив фикер туды. Беренчедән, ничә буын татар кешесе "дуңгыз сөте имеп", хәрам ашап-эчеп, үсмәдемени?. "Дуңгыз сөте имү" монда руслашуга да ишарә кебек яңгырый. Гүя, татар рухын мондый мәсхәрәләүгә дучар итмәс өчен, автор әнә шул рухи имгәктән туган баланы дуңгыз астында калдырып үтертә. Шуның белән дуңгыз сөте эчеп үскән "үле җанлы татар" үрчеткәнче, андый баланың юк булуы хәерле, дигән фикер үткәрелә. Автор бу хакта болай ди: *"Ата-бабаларының телен һәм динен оныкларына тапшыра белмәгән бәндәләр синең заманда да җитәрлек иде. Хакыйкать аларның барлыгында түгел. Андыйлар күзгә күренеп кубәя—менә кайда хакыйкать"*. Бу әле әсәр язылган 1989-1990 елларда әйтелгән сүзләр. Мондыйлар хәзер дә кимемәде Татар илендә. Киресенчә, Көнбатыштан кергән тискәре йогынтылар нәтиҗәсендә һәм "үзгәртеп кору" дип исемләнгән, социалистик стройдан капиталистик формациягә күчү чорында, балаларына ашар өчен акча эшләү белән мәшгуль булып, аларга юньле тәрбия бирә алмаган, һәм дә милли тәрбиядән шактый ук ерак киткән, аны оныткан аналар кулындагы мондый "гаррилар" елдан ел үрчи генә бара. Автор бик матур итеп *"Ә бит кешене юлга чыгарып җибәргәндә юнәлешен күрсәтәләр"*,—ди. Менә шулар хакында сәхнәдән күреп гыйбрәт алырлык әсәрләр кирәк, бу проблема һаман актуаль булып кала бирә. Уйлатырлык кына түгел, ә

еларлык фаҗига—гасыр вакыйгасы бу "Гаррилар". Киләчәктә "тере мәет" булган мондый татарлар *"атасынын баш сөяген тустаган ясап аракы" эчмәсен*!

Ризван Хәмиднең герой концепциясен үстерүгә өлеш керткән һәм шулай ук кабатланмас характеры белән аерылып торган тагын бер каһарманы хакында сөйлисе килә. Ул—***"Каен жиле"*** драмасындагы Илсур образы. Аны *маргиналь герой* (ягъни үзе яшәгән мохиттән читләшкән, аның кануннарын кабул итмәгән, үзенчә яшәргә дигән фикергә килгән герой) дип атарга булыр иде.

Әлеге герой хакында уйлаганда шуны истә тоту сорала: аның турында туган илендә нинди фикер, хатирә яши дә, ул белгән, аның белән эшләгән кешеләр ни сөйли? Шушы ике якны чагыштырып, драматург Илсур шәхесенең асылын ачыклый, кешенең үзеннән соң калган эзе хакында уйлануга этәрә. Автор экзистенциаль бу проблема хакында шактый катлаулы фәлсәфә бирә алган. Илсурның яшәү принцибы шуннан гыйбарәт: үзенә якын кешеләргә бурычлы булмас өчен алардан вакытында аерыла белергә кирәк, аларны онытырга, үзенне дә оныттырырга кирәк. Бары шулай итеп кенә иҗтимагый сферада тамыр җәйгән "туган-тумачалык" күренешенә нокта куеп була, дип саный ул. Аның белән бергә эшләгән,аралашкан кешеләрнең дә Илсур позициясендә торулары ачыклана, әйтерсең, бу бер эпидемия, йогышлы авыру! Бәлки, чыннан да авырудыр мондый бәндәләр, аларда җан авыруы, рух авыруы тамырлангандыр? Ләкин аларның фәлсәфәсендәге беркадәр хаклылыкка күз йоммаган хәлдә, Илсур ишеләр белән тулысынча килешеп булмый. Мәсәлән, сине якты дөньяга китергән анаңа һәм атаңа бурычны акча белән түләп бетереп буламы икән?! Алар баланы әнә шулай үз бурычын түләр, рәхәтлектә йөздерер өчен үстерәләрме икән?! Әгәр шулай дип уйлаучылар булса, вакыйга катлаулана. Андыйларга гаилә, бала, ата-ана да кирәкми. Әмма асылда баланың ата-анага булган бурычы—ул рухи вазифа, ягъни нәселенең якты исемен, тарихын киләчәк буыннарга тапландырмыйча илтеп җиткерү, милли үзбилгеләнешне саклап калу, ата-ана теләнә тугры хәлдә шундый ук милли хисле балалар тәрбияләү. Менә яшәүнең асылы, максаты кайда!

Илсур кебекләр бары үзләре хакында гына уйлап, тормыш авырлыкларыннан, сынауларыннан җинел генә котылырга телиләр. Алар, имеш, "яшәү принципларын сынаган һәм башкача яшәү кирәк дигән фикергә килгән" (Юрзин). Аларнын яшәү принцибы гади: кызык булмаса, башлаган эшне ташларга, фатир, гаилә дә кирәк түгел. Гадел һәм Гортензия, Гадел һәм Юрзин арасында барган кызыклы фәлсәфи бәхәсләрдән һәр укучы үзенә күрә бер нәтиҗә ясый ала. Әмма Илсур кебек үз мәнфәгате белән генә яшәүчеләр дә елдан-ел күбәя бара. Аларнын санын милли билгеләнешен, яшәү бурычын белмәү арттырмыймы икән? Ә бит аларча яшәп кенә коллык психологиясен җимереп булмый.

Ризван Хәмид әлеге әсәрендә Илсурга карата мөнәсәбәтен ана образы аша ача. Анасы, Илсур утырткан каен төбендә улын көтә-көтә моңаеп, эчтән генә сыза-сыза да, бердәнбер көнне каенны кисеп аудара! Үзенә җан биргән, төн йокыларын калдырып үстергән иң изге, кадерле кешесен егерме ел буена бер генә тапкыр да кайтып күрмәгән улыннан анасы үләр алдыннан ваз кичә, аның хакындагы хатирәне дә җимерә.

Әсәр тетрәндергеч дәрәҗәдә камил, фәлсәфи, тәэсирле. Илсур образы да каршылыклар аша бөтен тулылыгы белән ачылган.

Драматургиядә милләт фаҗигасен ачу ягыннан **Туфан Миңнуллин** тудырган геройлар да гыйбрәтле. Соңгы егерме елда гына да аның шушы планда иҗат ителгән, әмма бер-берсен кабатламый торган образлар галереясе тагын да тулыланды. Болар—Гөлфинә белән Дилемма /*"Әниләр һәм бәбиләр"*/, Вера белән Дания /*"Илгизәр плюс Вера"*/, Миләүшә /*"Хушыгыз"*/, Сәет /*"Шәҗәрә"*/, Әнисә /*"Сөяркә"*/ һ.б. Һәркайсынын реаль җирлеге бар, ягъни мондый типларны тормышта күреп торабыз.

Туфан Миннуллин үзгәртеп коруга кадәр үк милли фаҗигане яктыртырга алынган әдипләрнең берсе булды. Аның милләт киләчәген хатын-кызның роле, ананын гаиләдәге урыны белән бәйләп биргән идеяләре Гаяз Исхакыйнын *"милләт анасы"* концепциясе белән авазлаш, шунын бүгенгедәге үстерелеше булып яңгырый. Шушы җәһәттән Т.Миннуллиннын *"Әниләр һәм бәбиләр"* әсәренә күз салыйк. Андагы хатын-кыз образларын берничә типка аерып булыр иде. Шушы типларга бәйле рәвештә уңай һәм тискәре сыйфатларны куллана алабыз. Милләт анасы дәрәҗәсенә

кадәр күтәрелгән, бүгенге хатыннарга, кызларга да үрнәк булып торырлык Гөлфинә образы автор житкерергә теләгән идеяләрнең унайларын яктыртса, Гөлфинәнең капма-каршысы булган, бүгенге тормыш шартларында тәрбияләнгән, рухи имгәклек мисалы булган Дилемма образына исә автор хатын-кызның милләт алдындагы бурычының үтәлмәве турындагы мөһим фикерләрне туплаган.

Т.Миңнуллинның милләт язмышын реаль планда чагылдырган "Илгизәр плюс Вера" драмасындагы геройлар чынбарлыкны калку чагылдыруы ягыннан әһәмиятле. Әлеге фажигада гаеп Верада түгел, гаеп монда катнаш никахка ризалык биргән Данияда! Әлбәттә, тормышта мәхәббәт дигән нәрсә милләтне дә, яшь аермасын да сорап тормый. Шушы планда геройлар тарган фажига дә фәлсәфи характер ала. Ана буларак Вераны гаепләп булмый, чөнки ул үзе тапкан һәм үзе үстерәчәк балага үзе теләгән исемне бирә (Иван дип), һәм бу исем анын да, баласының да милли рухын ачык чагылдыра. Балага ана телен бирергә теләүдә дә гаепләргә хакыбыз юк аны. Юкка мени ул "ана теле" дип атала. Уйланырлык нәрсә, баш ватарлык нәрсә монда тирәнрәк—ничек итеп катнаш никахтан туган балада татар рухын булдырырга, татар телен сендерергә? Мөмкин эшме бу? Автор әлеге сорауны ачыклау өчен символик өянке образын кертә. Ул ике гаилә—ике милләт арасына чик булып тора, шул чик жимерелсә, алар арасында ихтирам һәм тигезлек бетә. Ике милләт арасында бер-берсен яратучылар элек тә булган, монда соңгы сүзне өлкәннәр әйтергә тиеш.

Туфан Миңнуллин яңа тип герой тудыру ягыннан бүгенге әдипләрдән беркемне дә, хәтта тормышның үзен дә кабатламый. Ул хәятның нинди икәнен күрсәтә дә, тормыштагы авырлыклардан ничек исән-имин, рухи яктан изелмичә чыгу юлларын табарга өйрәтә. Шундыйларга матур мисал итеп *"Эзләдем, бәгърем, сине"* драмасын атарга кирәк. Нурсинә кебек тумыштан гарипләр хакында әле татар әдәбиятында бер генә язучының да мондый тетрәндергеч әсәр ижат иткәне юк иде. Монда ике гарипнең бүгенге рәхимсез тормышта бер-берсен саклап калуы, бер-берсенә рухи терәк булуы яктыртыла. Автор менә шушы тетрәндергеч, әмма күбебезнең уена да кереп карамаган чынбарлыкны чын мәгънәсендә прожектор уты белән яктырта. Димәк, бүгенге драматургия без яшәгән чорның иң актуаль якларына да күз сала, аны заманча итеп, сәнгать әсәре дәрәжәсендә яктыртырга омтыла.

Айдар Хәлим үзенең "Сез беләмсез кая барганны?" дигән язмасында "Татар язучысы *...милләтебезгә большевизм китергән коточкыч бәлаләрне бар тирәнлеге белән ачып салырга*, шуның белән бергә милли автономия демагогиясе белән *алданган татар большевигының кан кычкырган фажигасен* нәфис сүз, образлы сурәтләү—художестволы гәүдәләнеш аша күрсәтеп бирергә тиеш иде",—дип яза. Менә шундый милли фажигане ачуга матур мисал итеп, **Данил Салиховның "Чукрак"** пьесасын атарга кирәк. Туган ягымда, туган жиремдә тигезлек төзим дип атасын, абыйсын большевистик принципларга алыштырган, халыкны тук, тигез, бәхетле итим дип йөргән, әмма бик күп гафу итмәслек хаталар ясаган Нуриәхмәтнең асылынып үлүе мисалында автор татар халкы тарихында 1917 елдан соң булган вакыйгаларның гадәти драматизм белән генә дә сугарылмавын, моның котылгысыз бер фажига икәнлеген сәнгатьчә раслаган, татар халкының деградацияләнүен, мескенләнүен, нигезе жимерелүен, иң аяныч хәлгә, кабәхәтлеккә кереп китүен "йөрәктән кан саркытырлык итеп" гәүдәләндерә алган.

Әсәрдәге *геройларның* холкы, гамәлләре, язмышы (Нуриәхмәтнең, Мөбарәкнең, Гөлйөземнең, Галимжанның) һәм татар авылының котылгысыз рәвештә упкынга таба баруы большевикларның ялгыш, ялган, мәкерле сәясәте тозагына эләгүен ачу *идеясенә* хезмәт итә.

Автор бүгенге рухи имгәклекнең башын 1917 елгы революция, аннан соңгы "кызыл террор" еллары белән бәйләп бирә. Авызыннан аракысы, сүгенү сүзе китмәгән, атасына, анасына нәфрәт белән, имгәк дип караган "Мөбәрәк"ләрнең тамыры шуна ялгана. Мәчетләрне жимереп, гөнаһсыз яшь, саф кызларны көчләп йөргән, акыллы, эшчән кешеләрне "кулак", "халык дошманы" дип атып үтергән яки Себергә сөргән, үзләре исә яза, укый белмәгән, эшләргә яратмаган, әмма боерык биреп, кешене мыскыллап тәм таба торган Арыслан, Батыржан, Галимжаннардан башлана ул. Боларның кылган гамәлләреннән ил елый, матур яшәргә хакы, көче булып та, мөмкинлек таба алмаган хатыннар, ирләр елый,

алардан сәламәт, бәхетле булып туган, әмма бәхетсез яшәргә мәҗбүр ителгән, язмышлары каргышка төренгән Мөбәрәк кебек балалар елый. Кычкырып еламаса да, җаннары елый!

Әсәрдә татар милләтен кабәхәтлек юлына алып кереп киткән вакыйгалар күпләп һәм прожектор уты белән яктыртылгандай ачык күрсәтеләләр. Әмма Д.Салихов бүгенге татар тормышы унай якка үзгәрде дигән караштa тормый. Моны без мәдрәсә бетергән, Коръәнне яттан белгән муллалар урынына Совет чорында яшь кызларны көчләп, халыкны зар елатып йөргән, хәзер исә авылда иң белемле мулла булып саналган (!), азан алдыннан стаканлап аракы эчкән, дин гыйлеменең кирәклеген дә тоймаган, чалма-чапан киюне җиткән дип санаган муллалар хуҗа булуында, һәр өйдә Мөбәрәк кебек рухи имгәк үстергән, аракыны имезлек кебек суырган, мәчет, намаз хакында уйлап та бирмәгән татар авылы образында күрәбез. Әсәрдә тирән фәлсәфә кычкырып тормаса да, әнә шул җан өшеткеч күренешләр аша автор укучыга-тамашачыга уйланырга мөмкинлек бирә.

Данил Салихов иҗатында актуаль темалар күтәрелә, мөһим проблемалар куела, аларга уйландырырлык җаваплар, чишелешләр тәкъдим ителә. Иң әһәмиятлесе: аның геройлары үзләренең характерлары белән башка бер генә драматургта да кабатланмыйлар.

Данил Салихов иҗатында тормышның фаҗигалелеген күрсәтүне максат иткән әсәрләрдән "Туй күлмәгем—соңгы бүләгем" пьесасын атарга кирәк. Аның сюжет сызыгы гади кебек: авылдан шәһәргә килгән Сәрия исемле кыз нахак гаеп аркасында кешеләргә ышанычын югалта... һәм үз-үзенә кул сала. Сәриянең, авыл кызының, күнел сафлыгына басым ясап, аны гаиләсе, тәрбиясе белән бәйли автор. Сәрия кечкенәдән әнисез кала, әтисе белән икәү генә үсә. Бу күренеш аның күңеленең тиз җәрәхәтләнүчән булуын, кешеләрдән ярдәм, терәк, җылы сүз көтеп яшәвен һәм үзенең дә эчкерсез, тугры, гадел булуын формалаштыра.

Алдау, мәкер, ялганга корылган бу дөньяга Сәрия махсус каршы куела. Һәм, әлбәттә, әсәр махсус рәвештә аның фаҗигале үлеме белән тәмамлана. Бу үзенә күрә әсәрдәге геройларга (Миләүшә, Лилия, Дамир) гына түгел, ә укучыга карата да кулланылган *катарсис* (аларның күңелен, рухи дөньясын сафландыру) алымы.

Үзләрен зур, җитди дип санап йөргәннәрнең Сәрия кебек гадел, саф җанлы кешеләргә карата фикере менә нидән гыйбарәт: "Ни өчен яхшы булып кыланасың? Нигә мине матур сүзләрең белән каһәрлисең? Син бит бу сүзләрне чын йөрәгеңнән әйтмисең". Әлеге юллардан антик чор трагедияләрендә тасвирланган Изгелек һәм Явызлык көрәше кайтаваз булып яңгырый кебек. Дөрестән дә, Д.Салихов иҗаты, дөресрәге аның трагедиягә һәм драматизмга нигезләнгән әсәрләре, фәлсәфилек белән сугарылган.

Д.Салихов драматургиясендә беренче карашка гадәти элемент булып тоелган, әмма драма әсәренең үсешен, динамиклылыгын тудыруда төп рольне үтәгән конфликтның үзенчәлекле куелышына игътибар итми булмый. Нәкъ менә конфликтның куелышы һәм хәл ителеше пьесадагы геройларның характерын ачуда мөһим роль уйный. Бу әсәрләрдә вакыйгалар бер төп герой тирәсенә генә тупланмаган. Анда берничә төп (ягъни тигез хокуклы) герой бар. Мәсәлән, "Өрәк" драмасында Хафиз да, Илсур да мөстәкыйль һәм бер-берсенә буйсынмый торган шәхесләр. Әмма аларның асылын тоткан юлы, тормыш максаты ачыклый. Хафиз кебек юктан гына харап ителгән егетләр татар авылларында еш күренә. Әхлак, гаделлек кануннарын укучыларның аңына сендерергә тиешле укытучыларның да шаһитларны акчага сатып алуы милләтне тотып торган гаделлек, сабырлык баганасының черүенә ишарә.

Д.Салихов иҗатындагы икенче төр конфликт геройлар арасындагы каршылыкларның һәм килешмәүчәнлекләрнең сәбәбен ача. Персонажларның эчке дөньясына яшеренгән яки тышкы гамәлләрдә чагылыш тапкан мондый каршылыклар вакыйгаларның үстерелешен тәэмин итә. Мисал өчен, "Яшьлек хатам—йөрәк ярам" пьесасында каршылык Гөләндәм белән Әхмәт арасында, Әбүзәр белән аны үстергән һәм харап иткән мохит арасында барса, "Туй күлмәгем—соңгы бүләгем" әсәрендә ул Сәриянең җәмгыять белән тышкы каршылыгын тәшкил итә. Әсәрләрдә төп вакыйгалар баш герой тирәсендә тупланып куера.

Мондый пьесалардагы геройлар арасында ачыктан-ачык көрәш юк, көрәш хәтта

башка геройлар арасында да күренми. Мәсәлән, "Узып барышлый" драмасындагы Шәйхулла Фәния-Флоридлар белән көрәшми. Әмма алар арасында каршылык зур. Шәйхулла алардан игелекле ярдәм, мөнәсәбәт көтә, әмма алар картны алдыйлар. Шәйхулла кеше хокукларын сакларга тиешле милиционерлардан да ярдәм көтә, ин аянычы—татар фамилиясен йөрткәненнән гаделлек көтә, әмма тапмый.

Кайбер очракта яшерен, кай очракта ачыктан-ачык күренеп торган каршылыклар әсәрнең гомуми драматик атмосферасын тудыралар. Әйтик, "Бәйрәмгалинең сыер тышавы" комедия дип билгеләнгән. Асылда, татар кешесенең вакпануын, "колхоз" дигән монстрның матди байлык белән бергә авыл кешесенең мөстәкыйль фикер йөртүгә сәләтен, хөр холкын суырып алуын, аны фикерсез шамакай, дөньядан артта калган "бичара" ясавын "күз яше аралаш" көлү алымы белән тәнкыйтьли автор. Татар авылларында мескен хәлдә калдырылган меңнәрчә колхозчының жыелма образы кебек кабул ителә бу герой. Шуңа да без әлеге әсәрнең асылында житди драматизм ята дип әйтә алабыз. Әсәргә аз-азлап яки ташкын булып бәреп кергән комедия алымнары, романтик рух һәм дә сентименталь сыйфатлар гына әсәрнең драматизмын яшерә алмый, шул рәвешле "икенчел" мәгънә (подтекст) тудырыла. Ул исә үз чиратында (әсәрдә ачыктан-ачык каршылык булмаса да) әсәрнең эмоциональ киеренкелеген тәэмин итә.

Бүгенге драматургиядә ***тагын бер кызыклы герой тибы*** яшәп килә. Бу— татарның якты рухын мирас итеп саклый килгән, аны киләчәк буыннарга тапшырырга тиешле, әмма алар өчен кирәксезгә әйләнгән Нәүхәбәрләр *(Р.Хәмид "Олы юлның тузаны").*

Әлеге әсәр каһарманны бирү һәм символиклык ягыннан гына түгел, жанры җәһәтеннән дә үзенчәлекле. Әсәр бер генә каһарманнан тора. Драматургиядәге "өч берлеккә" Ризван Хәмид тагын дүртенче берлекне дә—герой берлеген дә—өстәп жибәргән. Нәүхәбәр карчык—үткәннән бүгенгегә жибәрелгән мирас кебек, аның хәтерендә гасырның бөтен вакыйгасы, шул чор кешеләре хакындагы хатирәләр саклана. Нәүхәбәр белән бергә бүгенгегә мирас булып татар жаның, хатын-кыз халәтен, ир-ат холкын ача торган көнкүреш әйберләр килеп житкән. Аларның һәрберсенең тарихы бар. Димәк "хәтер" бар дигән сүз. Нәүхәбәр карчыкның улы янына шәһәргә китәргә жыенуы— бүгенге татар кешеләре арасындагы бәйләнешнең өзелә баруын ачыкларга ярдәм итә.

Ризван Хәмид тудырган геройлар үзләренең кабатланмас характеры белән дә, сәнгатьчәлелек ягыннан камиллеге белән дә аерылып тора. Геройларның һәр эш-гамәле алдан уйланылган, нәтижәсен алдан күрелгән.

Татар милләтенең бүгенге хәлгә калуын күрсәтү ягыннан **Илдар Юзеевның "Ак калфагым төшердем куллан"** драмасын әйтми үтү мөмкин түгел. Әсәр моңа кадәр әле без татар драматургиясендә күрергә күнекмәгән геройларны керту белән кызыклы булса, алар аша милләтнең асылын ачу ягыннан да кыйммәтле. Татар халкы вәкилләренең чит илләргә чыгып китүе нәрсә белән бәйле? Автор Тайфур, Жак, Ратмир Зәкиевский образлары аша өлешчә әнә шул сорауга да жавап бирә. Талантлы, хөр фикерле, мөстәкыйль карашлы кешеләрнең Совет илендә кала алмавы, читтә исә туган туфрагын, газиз ана телен сагынып, үзенә урын таба алмыйча һәлак булулары, илдә калганнарының милләтчелектә гаепләнүдән куркып, хәтта үз туганы белән дә милли мәсьәләдә сөйләшә алмавы—болар барысы да татар халкының таралу, бетә бару баскычлары. Әсәрнең *идеясен* матур образ—*ак калфак образы* бер фокуска төйнәп тора. Әсәрдәге геройлардан без Жакны (Габделхак Ишмуллинны), Сафия Нурханны рухи хәзинә сакчылары кебек кабул итәбез. Шәмсияләр, Акчуриннар исә "югалган жаннар", "үле жаннар" дип тамгалана ала.

Драматургиядә тудырылган образлары ягыннан **Рөстәм Мингалим** ижаты да кызыклы. Аның "Өченче бүлмәдә эт яши", "Тау астында илле бүре" кебек әсәрләре бүгенге тормышта гына туа алган геройларны туплаган. Беренче әсәрдәге геройлар мисалында безнең—бәхеткә омтылган адәм балаларының—үз бәхетләрен жимерүе тасвирлана. Райан һәм Гөлия кебекләрне мин "гөнаһлы герой"лар тибына кертер идем. Аларның ***гөнаһы***—якын кешесенең жан тынычлыгын бозуда, урлауда, аның өметен сүндерүдә, ышанычын алдауда. Гәрчә әсәр бик пессимистик рухта башланып китсә дә, автор укучыга мондый ситуациядән чыгу юлы бер генә түгел икәнен, бер-беренә ышану булганда гаиләне саклап калып булуын дәлилли.

Гөнаһлы бәндәләр тибын бүгенге драматургия күпләп бирә. Шулай да **Зөлфәт**

**Хәкимнең "Шайтан куентыгы"** әсәрендәге кешеләрнең бер-берсе алдында кичерә алмаслык гаепле булуы, бер-берсенең тормышын, өметен, язмышын җимерүе аерылып тора. Матди байлыкка корылган, көнчелек, явызлык чәчрәп торган, рухи нигезе җуелган бүгенге тормышка бу әсәрдә матур хыяллар, бәхетле көлүләр, онытылмаслык вәгъдәләр тулы балачак дөньясы каршы куела. Менә шушы ике дөнья яктылыгында Рәзим һәм Фәнзиләнең фаҗигасе киң һәм тирән мәгънә ала. Зурая барган саен күңелдә балачак яктылыгы кимеп, өшеткеч һәм котырткыч салкын керүне автор "шайтан алу" дигән гыйбарә аша ача. Бу—авторның ачышы. Әсәрне психологик һәм фәлсәфи яктан тирәнәйтәсе урыннары булса да, ул тамашачыны һәм укучыны бер-беренә мәрхәмәтле, ягымлы, изге теләктә булу кирәклеге турында уйлануга этәрә.

Әйе, бүгенге драматургия геройлары тормышның актуаль мәсьәләләренә игътибарны юнәлтә, без онытткан яисә белмәгән, маргиналь дип санаган кешеләрнең ни уйлавын, ни кичерүен, ничек яшәвен ача. Мондый әсәрләрне укыган саен кыю фикерле, яшәеш турында уйландыра, яшәү мәгънәсе хакында фәлсәфи фикерләре ярылып ята торган әсәрләр—татар драматургиясенең ирешкән биеклеген саклап кала ала торган әсәрләр—күбрәк иҗат ителсен, алар татар укучысын һәм тамашачысын үзенең асылы һәм рухи кыйбласы хакында уйланырга ныграк этәрсен иде дигән теләк көчәя.

XXI гасыр татар әдәбиятына, шул исәптән татар язучыларына да зур бурычлар йөкли: моңа кадәр тудырылган әсәрләрне, образларны, хәтта сурәтләү телен дә кабатламыйча яңа идеяле, яңа әсәрләр, яңа каһарманнар тудыру, дөньякүләм аренага чыгарлык әсәрләр язып милли әдәбиятыбызны башка әдәбиятлар дәрәҗәсендә "презентацияләү". М. Әгъләмов "Яңа гасыр керә" дигән шигырендә:

> Яңа гасыр керә...
> Бар ышаныч—
> Шул дәвердә
> яшәр яшьләрдә,

—дигән иде. Ләкин ул яшьләрне ышанычны акларлык итеп, югары идеаллар үрнәгендә тәрбияләү кирәк бит әле. Әдәбият—әнә шундый көчле идеологик һәм тәрбияви корал. Унбиш елга якын әзерлек чорын үтеп, икемеңенче елга чыккан татар язучылары, минемчә, үткәнгә һәм фанилыкка үтә нык ябышкан. Моның өчен иҗатчыны гына гаепләү дөрес булмас, чөнки, "заманы шундый—оптимизм рухыннан мәхрүм", диярләр күпләр. Әлеге фикер белән нигездә килешкән хәлдә, язучыларның артык "пессимистик карашлары" белән ризалашасы килми.

Һәркемгә мәгълүм: әдәбият бит ул "күзгә" генә түгел, ул бит СҮЗ СӘНГАТЕ! Сурәт тудыру гына түгел, сүз белән дәвалау, яшәргә өндәү сәнгате! Вакыйгалар да анда пычрак рухлы, пессимистик тенденцияле фани дөньяны кабатлау аша бирелергә тиеш түгел, алар да иҗат ителергә тиеш. Геройлар да анда "тудырылсын", ә тормыштан "сикертеп" кертелмәсен! Ә "иң башта чынбарлыкны дөрес чагылдыруны максат итеп, безнең язучылар үзләренең иҗат фантазияләрен "эшләтергә" иренәләр. Каләм тибрәтүченең максаты, Р. Фәйзуллин язганча: "Иҗат итеп, Дөньялыкта / бакый булып" калумы? Язучы бит ул яңаны, яңа дөньяны тудыручы. Ни өчен әле сәнгатьнең башка төрләреннән булган музыка һәм рәсем сәнгатендә композиторлар һәм рәссамнар чын-чыннан "иҗат итү" белән шөгыльләнә дә, ни өчен безнең язучылар яңа формадагы, бер-берсен кабатламый торган әсәрләрне сирәк тудыра? Сынлы сәнгатьтә дә реализм ысулына нигезләнеп иҗат итүчеләр бар, әмма танылган рәссамнар арасында реализм кысаларына ябышып ятучыны күрмәссез сез.

Совет чоры әдәбиятын тормышны "революцион үсештә" сурәтләүдә, ягъни тормыштан аерылган булуда гаеплиләр. Ул чорда язылган әсәрләр яшәү фәлсәфәсе турында уйларга этәрмәсә дә, укучыны яшәргә, көрәшергә *(монда нинди максат өчен икәне мөһим)* илһамландырды, җәмгыятенә һәм чорына бәрабәр рәвештә ничек яшәргә кирәклеген күрсәтте, унай идеал бирде.

Тормышны турыдан-туры күчереп тасвирлауның да ике башлы таяк икәнен истә тотарга кирәк. Бит әсәрләребездә нәрсә сурәтләнгән—укучы тормышта шуны кабатлый. Моны телеэкраннардан бертуктаусыз барган сериаллар, фильмнар

мисалында гына да күрергә була.

Татар әдәбиятында инде тенденциягә әверелеп беткән тагын бер момент бар. Бу—үткән белән артык мавыгу, аны анализлау, "яраларны ялау". Әйе, милли тарихнын фажигалелеген, шәхес культынын күпме асыл татар зыялыларын "ялмап йотуын" истә тоту кирәк. Һәр татар нәселендә фажига ята. Әмма мондый әсәрләр күбәйгән саен изгелекнең кадере генә китә. Укучынын *(матур әдәбият әсәрендә генә булса да)* киләчәкне якты бояларда күрәсе килмиме?! "Юраган—юш килә" диләр, бәлки, теге яки бу әсәрдә яктыртылган матур милли киләчәк тормышка да ашып куяр! Димәк, үткәннәрнең гыйбрәтле сәхифәләре яктылыгында язучыларыбызга татарнын якты киләчәген фаразларга, тормышта булмаса да, әдәби әсәрдә үрнәк итеп куярлык унай герой тудырырга вакыт житте түгелме?! Монын өчен Талант белән бергә, Батырлык, Кыюлык һәм тагын бер кат ИДЕЯ кирәк. Шундыйлар гына тарихта кала. Халык шагыйре Равил Фәйзуллин әйтмешли:

Тарих таный—ижатына
Жаннарын салганнарны,
максат-идеалы өчен
фидаи янганнарны,
үзләренчә үзгә дөнья
тудыра алганнарны!

---

## *Реплика*

"Казан утлары"ның 4 санында (2005) Сәгыйдулла Хафизовның "Кайда безнең рыцарьлар?!" дигән язмасы басылган. Анда мондый сүзләр бар: "Т. Миңнуллинның "Сөяркә" драмасында Хәбир мөлкәткә генә түгел, хатынга һәм сөяркәгә дә ия... Безнең заман драматургы исә мут Хәбирне хәзрәткә алып барып сөяркәсе Мәдинә белән никахлаштыра да, вәссәлам, сарык та исән, бүре дә тук... Т. Миңнуллин дәлилли белә инде ул, теләсә, киллерны да аклап драма язар".

Шунысы мәгълүм булсын: "Сөяркә" дигән пьесада Мәдинә исемле персонаж юк. Икенчедән, мин әсәремдә беркемне дә беркем белән никахлаштырмадым. Андый күренеш юк пьесада.

Сәгыйдулла иптәшкә киңәшем: теге яки бу әсәр турында сүз әйткәндә ул әсәрне укып чыкмаса да, кулына тотып карасын иде.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

Дания Заһидуллина

# ТАТАР ПРОЗАСЫНДА ЯҢА РОМАНТИЗМ

Татар әдәбиятында XX гасыр башында гына формалашкан һәм Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев кебек күп авторларның иң камил әсәрләре белән мәйданга чыккан романтизм юнәлеше (методы) 1917 елдан соң гүя үги кыз хәленә төшә. Бер яктан, реализмны—бигрәк тә социалистик реализмны—официаль язу рәвешенә әверелдерү омтылышы башка юнәлеш һәм агымнарны түбәнәйтү хисабына бара. Икенчедән, марксистик-ленинчыл фәлсәфә, гомумән, романтизм юнәлеше мөрәҗәгать итә торган идеалистик агымнарны дошман күрә. Нәтиҗәдә, иҗат юнәлеше буларак романтизм совет әдәбият белеме тарафыннан яңа тормыш төзүчеләр, коммунизмга баручылар өчен файдасыз, бай сыйныф вәкилләренең үткәнне сагынып елаулары төсендәрәк тәкъдир ителә башлый. Матбугатта исә романтик әсәрләргә ике төрле караш күзәтелә: йә аларны күрмәмешкә салыну, яки ниндидер юллар белән реалистик әсәр калыбына тартып кертү.

Ләкин моңа карап XX гасыр татар әдәбиятында романтизм юнәлеше яшәүдән туктамый. Әйтергә кирәк, нәкъ менә шушы юнәлештә иҗат ителгән әсәрләр татар әдәбияты өчен милли, шәркый тоелучы күп кенә алымнарны саклап кала, яңадан-яңа әдәби тәҗрибәләр мәйданы булып тора. Инде соңрак, әдәбият белеменең "җете кызылы" уңа төшкәч, романтик әсәр авторын "дошман" дип атау куркынычы юкка чыккач, бигрәк тә 1980 еллардан алып, романтизм яңадан күтәрелеш кичерә. Алай гына да түгел, яңа стиль тенденцияләре белән байый. Шуңа күрә XX гасыр ахыры романтик әдәбиятын берничә төркемгә бүлеп тикшерү зарур.

Бер яктан, классик романтизм традицияләрен дәвам итеп язылган әсәрләр бар. Без аларны саф романтик *(рус әдәбиятында, яңадан калкып чыкканга, неоромантизм, ягъни яңа романтизм дип атау яши)* әдәбият буларак карыйбыз. Мисалларга күчик.

Ф. Садриевның "Кыргый алма әчесе"ндә романтизмның төп хасиятләре күзгә ташланырлык. Төп сюжет сызыгын Вилданның үз эчендәге каршылык барлыкка китерә: ул—эгоизм, үз-үзенне ярату. Вилданның Әнвәрәне һәм үз-үзен яратуы арасында бәргәләнүе, шул сәбәпле мәхәббәтен югалту тарихы артистлар мохитендә тасвирлана. Ярдәмче сюжет сызыклары өчәү: Вилдан—Әнвәрә сызыгы, бусы—мәхәббәт тарихы; Әнвәрә—Мансур сызыгы, монысы—гаилә тарихы; Әнвәрә—Нәсимә сызыгы исә— дуслык тарихы. Әлеге ярдәмче сюжетлар, бер яктан, Әнвәрә һәм Вилдан характерын тирәнрәк ачарга ярдәм итә, икенче яктан, ике төрле тормыш моделе төзүдә катнаша. Әнвәрәгә гашыйк булса да, Вилдан аны тамашачының яратуын кичерә алмый: йә мин, йә сәхнә дип шарт куя. Мәхәббәт хакына корбан таләп итү—беренче модель, ул мәхәббәтнең юкка чыгуына, ике кешенең бәхетсезлегенә китерә. Мансур исә, киресенчә, яраткан кешесе мәнфәгатьләрен беренче планга куя *("Эре гәүдәле, бит очлары алланып торган бу егет театрга килеп эшкә урнашкач та кешеләр өчен жанын ярып бирергә әзер торуы белән һәркемнең игътибарын жәлеп итте")*. Әнвәрә белән Нәсимә дуслыгында да шушы сыйфат төп рольне үти. Нәтиҗәдә икенче модель—мәхәббәттә үз-үзенне "онытып", башка кешене ярату, аны аңларга һәм сакларга тырышып яшәү варианты пәйда була.

Язучы бу әсәрдә чын мәгънәсендә гүзәл ике романтик тип иҗат итә. Аларның талантлы һәм хис кешеләре (артистлар) итеп уйлануы, чыннан да матур кешеләр

кебек тәкъдим ителеше татар романтик әдәбияты өчен традицион. Әнвәрә—ялкын, ут. *“Күбәләктәй жинел гәүдәле, һәрчак көләч, жырга-биюгә дигәндә чәчрәп торган Әнвәрә театрга кояштай балкып килеп керде.” “Әнвәрә бер басасы урынга биш басты, ул сөйләшмәде—сайрады, ул эшендә тир түкмәде—һәр күзәнәге белән ләззәт дингезендә йөзде...”*. Намуслы, сизгер күнелле һәм хис белән яшәүче кызның холкы, әлбәттә, мәхәббәт һәм яраткан хезмәте арасында сайлау ноктасына куелганда, сәхнәдән баш тарта алмавын ышандырырлык итеп аңлата. Әнвәрә—талантын башкалар белән уртаклашып яшәү өчен яратылган кеше.

Вилдан исә аның капма-каршысы. “Әйтерсең лә, аның гәүдәсе гәүдә түгел, тәп-төз биек багана; гүя һәммәсе дә күренмәс туры сызык белән тигезләнгән: текә кин мангай белән бер сызыкта ятучы кылыч борын, юка иреннәр, уйчан йөзе, аксыл-соры чәчләре, шундый ук кашлары”. Салкын, кешеләрдән читтәрәк, аларга югарыдан карап яшәүче Вилдан да язучы тарафыннан чын мәгънәсендә талант иясе итеп сурәтләнә. Артист һәм моңлы тавышка ия жырчы, рәсем остасы да булган Вилдан талантын үзенең эгоистлыгын канәгатьләндерүгә файдалана, һәрчак беренче, сәхнә түрендә берүзе булырга омтыла. Вилдан—татар әдәбияты өчен традицион булмаган романтик тип, дия алабыз.

Повесть әдәби алымнар белән баетылган, алар әсәрнең ассоциатив мөмкинлекләрен арттыралар, ана фәлсәфи тирәнлек өстиләр. Исемгә чыккан кыргый алма повестьның башында ук, метафора булып китерелә. *“Чия зурлыгындагы сап-сары алмалар ботакларны сырганак урынына каплаганнар иде. Вилдан ике алма өзде дә берсен Әнвәрәгә бирде, икенчесен үзе капты. Алма бик каты иде, авызында бераз әвәләп йөрткәннән соң, Әнвәрә аны урт тешләре белән чытырдатып кысты, әчелегеннән күзенә яшьләр бәреп чыкты.*

*—Әче булса, төкерегез,—диде Вилдан.*

*—Йотам әле, өлешемә тигән көмешем,—диде Әнвәрә...”*

Кыргый алма, беренче чиратта, кешенең холык-фигылен символлаштыра. Аның әчесе—Әнвәрәгә дә, Вилданның үзенә дә житәрлек була. Шул рәвешле, метафора Вилдан характерына да, аларның үзара мөнәсәбәтләренә дә, мәхәббәт тарихына да бәя бирә.

Метафора югалмый, әсәрдә тагын ике тапкыр кабатлана. Вилданның шау чәчәктәге алмагач сурәтен өенә алып кайтып стенага ябыштыруы, ә инде соңгы вакыйгадагы манзара—кар каплаган ботакларда алмаларның коелып бетмәгән булуы—сурәтне психологик бәя чарасына әверелдерә.

Тагын бер метафора—Вилданның, кызга шарт куйганнан соң, альбомга ясап киткән рәсеме: *“анда бөркеткә охшаган ап-ак кош очып бара, ә бер аягына елан чорналган иде...”* Кош—егетнең үзен, ә елан—аның эгоистлыгын символлаштыра, рәсемнең башкача аңланылу мөмкинлеге дә калдырылган.

Повестьта төп урынны дүрт геройның эчке дөньясын, кичерешләрен, характерын сурәтләү алып тора. Әсәрнең буеннан-буена геройлар үз-үзләрен һәм башкаларны бәялиләр. *“Мин беренче булырга гына риза”*, ди Вилдан. *“Оныт тәкәббер Вилдан Бакировны”*, ди Нәсимә. Мондый бәяләмәләр әсәрнең буеннан-буена озата бара.

Әсәр хисләр тарихы кебек, бер сулышта укыла. Ул геройларның бай эчке дөньясы хакында сөйләп бара—шуның белән кыйммәтле дә. Әсәр ахырында капка төбенә чыккан Әнвәрәнең яшь егетләр белән сөйләшүе исә (эротик, порнографик диикме) урынсыз янгырый. Бәлки, язучы биредә көлү элементы, жинелчә юмор кертергә уйлагандыр? Ләкин югары кимәлдә язылган әсәр тукымасында бу күренеш артык: күңел аны кабул итәргә теләми.

Әсәр ахырында язучы геройларын тагын бер кат сыный: алар алмагач янында очрашырга сүз беркетәләр. Әнвәрә мәхәббәте хакына баш тартырга әзер икәнлеген күрсәтә. Ләкин Вилдан үзен үзгәртерлек көч таба алмый. Соңгы вакыйга тагын бер кат авторның фикерен ассызыклый: мәхәббәттә бәхетле булыр өчен, үзең хакында түгел, яраткан кешең турында уйларга кирәк. Үзеңне артык ярату бәхетсезлеккә, үкенечкә китерә.

М. Вәлиевнең “Качу” повестенда да төп каршылык нәкъ романтиклардагыча: хыял һәм чынбарлык арасында. Романтик герой Билалның үз эчендәге шушы

каршылыкны чишүе, көчле кеше позициясенә килү тарихы төп сюжет сызыгын хасил итә. Вакыйгалар да шуңа яраклаштырып сайланган. Повесть Билалның, "барысыннан берьюлы котылу, качу өчен" поезд көтүе белән башланып китә. Барысы дигәндә, шәһәр тормышы, барып чыкмаган гаилә, кайчандыр бик яратып та, хәзер мәгънәсен күрми башлаган эш күздә тотыла. Хәзергә бер айга ял йортына китеп баручы Билал яңадан элекке тирәлегенә әйләнеп кайтмаска тели.

Әсәр икенче заттан—Билалның уй-фикерләре, хис-мөнәсәбәтләре үсешен күзәтеп бару кебек язылган. Аң агышы алымы, вакыт-вакыт автоматик язуга мөрәҗәгать итү әсәрнең тирән психологик повесть булып чыгуын тәэмин итә. Язучы төп каршылыкны повестьның буеннан-буена, Билал игътибар иткән әйберләргә кагылышлы уйланулар төсендә ияртеп бара. Герой күңелендәге хыял һәрвакыт чынбарлык белән чагыштырыла. Үзанализ хыял белән чынбарлыкны капма-каршы ике чик кебек ерагайта. Мәсәлән, китү күренеше: *"Үз-үзенә нык ышанган кыяфәттә, горур һәм бәйсез адымнар белән вагон баскычына менеп баруын тасвирлый иде бит аңа хыялы... Кинодагычарак итеп... Ә менә чынлыкта, үз башыңа төшкәч, алай горур булып кылануы кыен икән шул... Тиздән килеп житәчәк поезд да әллә нинди, йөрәккә ят нәрсә шикелле тоела. Элекке заманнарда, ичмасам, моның ише вакытларда пар ат җигеп, кибиткаларга утырып киткәннәр... Алар, әлбәттә, аерылу сагышына чумган кешенең әз генә булса да күңелен күтәргәндер, ялгызлыкта калган җанына юаныч булгандыр..."*

Романтизм юнәлешенә мөрәҗәгать иткән һәр язучының хыялда "качу" урыны, идеалы була. М. Вәлиевтә ул—табигать, табигыйлек. *"Аларның, адәм балаларының, хәзер чын тормыш белән, үзләрен табигый зат буларак канәгатьләндерә алырдай тормыш белән яшиселәре килә... Алар чынлыкта, табигыйлеккә бик тә, бик тә сусаганнар"* дип, язучы моның гомумән кешегә хас омтылыш булуын ассызыклый. *"...Бөек табигыйлек монда... Яшәүнең иң ышанычлы, иң тотрыклы ысулы булган табигыйлек"* дип, табигать белән гармониядә яшәү кеше өчен иң дөрес-камил яшәеш варианты кебек шәрехләнә. Билал табигатьтә үз кичереш-халәтенә аваздашлык таба, табигать кочагында яшәгән кешеләрне идеаллаштыра. Бер үк вакытта табигатьне аңлау, ярату, аның матурлыгын күрә белү һәркемгә дә тәтеми торган сыйфат кебек тәкъдим ителә. Шушы җәһәттән, язучы кешеләрне табигый һәм цивилизациягә җайлашкан төркемнәргә аера. Соңгыларына мисал итеп, Билалның хатыны һәм Александр Петрович китерелә.

Ләкин бу төркемдәгеләр арасындагы аерма табигатькә мөнәсәбәт белән генә чикләнми. Рухи хөрлек һәм тарлык, чикләнгәнлек сыйфатлары игътибар үзәгенә куела. Моны Билал яңа директор хакындагы уйларында ачыклый: *"Билалның инде күп мәртәбәләр сынаганы бар: яңа директор сыман кешеләрнең эш өчен, халык өчен, бүтәннәр өчен бервакытта да ушлары китми. Алар беркайчан да үз өсләренә зур җаваплылык алмыйлар; беркайчан бер генә мәсьәләдә дә беренче булмыйлар; беркайчан, бер генә мәсьәләдә дә кистереп җавап бирмиләр... Һәм алар, андый кешеләр, беркайчан тулысынча ачылып, күңел төпкелендәге уйларын бүлешеп сөйләшмиләр. Алар һәрчак сак, уяу, куркучан. Менә шушы сыйфатларны үзләрендә булдырырга тырышу теләге аларны, гомумән, чикләнгән, сай фикерле натурага әйләндерә. Күпмедер вакыттан соң, аларны әнә шул эчке һәм тышкы тормозлары—үзләрен гел тыеп, туктатып яшәүләре—рухи тарлыкка, чикләнгәнлеккә китерә..."* Шуңа охшаш фикерләр Галиягә һәм Александр Петровичка кагылышлы күренешләрдә дә гел ассызыклана. Икейөзлелек, ышанычсызлык, салкынлык, кешелексезлек, җансызлык, шатлана һәм тормышның тәмен-рәхәтен тоя белмәү сыйфатлары икенче төркемгә карата билгеләнә һәм алар җәмгыять кануннарына буйсыну сәбәпле барлыкка килгән гариплек кебек аңлатыла. Ләйсирә белән сөйләшкәндә, язучы Билалдан бу хактагы фикерләрен әйттерә. Менә бер өзек: *"Хәзер кеше үз кыланмышларын табигать белән, аның мәңгелек һәм гаять көчле кануннары белән ризалаштырмыйча эшләргә өйрәнеп килә... Ул бары тик җәмгыять кануннарын гына санга сугарга ияләнгән хәзер... Ә болай итү, минемчә, тирән һәм зур ялгышка китерергә мөмкин. Ни өчен дисеңме?! Менә ни өчен. Чөнки кеше—җәмгыять продукты гына түгел әле ул! Ул—табигать продукты да әле! Табигый*

*кануннар да искә алынырга, санга сугылырга тиеш!"*. Һәм бу сүзләр әсәр тукымасында язучының субъектив идеясе булып аңлашыла. Алар ярдәмче сюжет сызыкларында ныгытыла.

Төп сюжет сызыгындагы каршылык романтизмның үзәк сыйфатларыннан берсен: ике төрле тормыш моделе тергезүне (двоемирие) бик гади һәм табигый башкарып чыгарга ярдәм итә. Билалның хыялындагы һәм чынбарлыктагы хәлләр укучыга турыдан-туры күрсәтеп бирелә. Яраткан кеше, гаилә, башкаларга файда китерүче эш, табигать белән гармониядә үтүче тормыш хыял-идеалда кала. Чынбарлык бөтенләй башка, ул Билалны үзеннән, үзе җавап таба алмаган сораулардан качарга мәҗбүр итә. Повесть ахырында кире кайтырга карар кылу, ана кадәр булып үткән хәлләр геройның көчле кеше позициясенә килүен: ягъни идеалны чынбарлыкка якынайту өчен көрәшәчәген белдерә. Билал—нечкә күңелле һәм рухи байлыкка омтылучы кеше—көрәшчегә әверелә. Шулай итеп, романтик геройның күңелендә тарткалашкан капма-каршылыклардан, кешенең үз эчендәге көрәш-тартыштан, рухи дисгармониядән котылу варианты табыла.

Билал гаиләсе таркалу тарихы беренче ярдәмче сюжет сызыгы хасил итә. Ул язучыга тагын бер субъектив идеяне белдерергә булыша: кеше өчен мәхәббәт-гаилә иң зур терәк, яшәү мәгънәсе була ала (*"Ә менә адәм баласы өчен, ныклап уйлаганда, боларның берсенең дә артык әһәмияте юк икән... Тып-тыныч кына калып уйланган чакларында үзенең пар канатлы икәнен тою гына кирәк икән ана..."*), һәм киресенчә. Бу материалда, классик романтизмдагыча, бала культы тудырыла. Билалны кире гаиләсенә кайтырга мәҗбүр итүче көч тә—бала бәхете. Повестьта ата-бала мөнәсәбәтләре җылы һәм самими сурәтләнә. Балага мөнәсәбәттә ир шактый ук сентименталь, ә инде ата һәм баланың дөньяга карашы арасындагы охшашлыкка игътибар юнәлтеп, әйтерсең, язучы табигый кешеләрнең киләчәге хакында сүз алып бара, бу киләчәкнең бүгенгеләрдән корбан таләп итүен искәртә.

Мәхәббәт сызыгы Ләйсирәнең бәхетле уртак киләчәккә ышанмыйча китүе белән тәгалләнә. *"Гаилә турында гына уйлап, аның өчен генә яши алмыйсың син... Синең күңелеңә, рухыңа артык зур киңлек, иркенлек кирәк! Нииндидер зур яшәү, киң колач белән, канатлы яшәү кирәк сиңа..."* дигән сүзләр романтик геройга бәхетне гаиләдән түгел, башка өлкәләрдә эзләргә кирәклекне дә, Галия белән тормышлары барып чыкмауда Билалның гаебе булуны да искәртә.

Аерым бер сюжет барлыкка китергән, эш урынындагы каршылык исә ретроспекция алымы белән, искә төшереп тергезелә. Архитектор Билалның коллектив белән бергәләп сәнгать сарае проектын әзерләве, әлеге хезмәтнең каршылыкларга очравы романтик яссылыкта ачыла. Биредә иҗтимагый детерминизм юк. Каршылыкны китереп чыгаручы яңа директор—язучы аерып чыгарган, табигый булмаган кеше. Каршылыкның чишелүе дә шәхси—хезмәттәшләре язган хат белән бәйле булып чыга. Киткәндә, Билал "аның күңелен, җанын аңлап бетерүләренә шикләнде" дип искәртелә, хат исә нәкъ менә аңлап язылган булып чыга. Бу текстта Билалның ни өчен көрәшчегә әйләнергә тиешлеге дә шәрехләү таба. Дөньядагы прогрессны китереп чыгаручы көч—көрәш ул, диелә. Бу фикер әсәрнең сонында Билал уйлары булып тагын бер кат янгыратыла: *"Әйе,—дип уйлап куя Билал,—алга барганда һава да сафланып китә шул! Сулыш алуы да җиңеләшә!... Автобуста гына түгел, тормышта да, җәмгыятьтә дә шулай! Алга бару кирәк! Алга таба хәрәкәт кирәк! Димәк, көрәш кирәк!"*. Күпмедер күләмдә социалистик реализм лозунгларын хәтерләтсә дә, әсәр буенча күзәтелеп барган аң үсеше Билалның шушы ноктага килүенә ышандыра.

Гомумән, язучы кабатлаулардан бик оста файдалана. Сәнгать сараеның үзенчәлеге—табигый тирәлеккә яраклашкан булу—ярдәмче сюжет сызыгын язучының табигыйлек фәлсәфәсе белән кушып җибәрә. Төп идея тагын бер кат хат текстында әйтелә: "Алар—көчле кешеләр—үзләре ошатмаган яшәү рәвешен ташлап, калдырып качмыйлар. Алар әнә шул яшәү рәвешен үзләре теләгән якка таба үзгәртү өчен көрәш ачалар!" Василий Петрович хикәяте дә Билалның эшендәге сынауга аваздаш. Мондый мисалларны тагын да китерергә мөмкин булыр иде.

Геройлар һәм вакыйгалар бирелешендәге охшашлык та автор концепциясен

үстерүгә хезмәт итә. Мәсәлән, купеда очраган Нина рухи яктан Билалның игезәге: аның гаилә тарихы Билалныкы кебек үк. Мондый янәшәлек Билал кичергәннәрнең күпләр өчен уртак халәт булу мөмкинлеген белдерә. Моннан тыш, автор үз фәлсәфәсен: кешеләрдәге төрлелекне, кайберәүләрнең рухи камилләшүгә, икенчеләрнең матди байлык туплауга омтылып яшәүләре хакындагы фикерне—Нина сүзләре аша җиткерә.

Билал, чын мәгънәсендә, романтик герой амплуасында. Эчке дөньясы бай, башкалардан да күпне таләп итүче (язучы аны Нинадан максималист дип бәяләтә), тормышны интуитив, сиземләп танып-белүче, хис-кичерешләргә бай шәхесне язучы бала белән чагыштыра. Моны вакыйгалар катламында да кабатлый: салам эшләпә хакындагы күренеш табыш булып чыккан. Шулай ук язучы Билалның икеләнүләренә аерым игътибар бирә. Мәсәлән, ул купега килеп кергән героен болай бәяли: "Мин монда да артык кеше, ахрысы..." дигән уй иде ул. Моңа кадәр бер генә җирдә дә үзенә иплe, җайлы урын таба алмаган нечкә җан биредә тагын бермәлгә шик-шөбһә дулкыны арасында калды". Вакыйгалар үскән саен, Билалның үз-үзенә ышанычы арта. Ул бәхетле булуның төрле вариантларын "ача". Иртәнге кояш аңа матур-тыныч иртәнең бәхет икәнлеген аңларга ярдәм итә. Кызы аерым-аерым эпизодларнын "кешелек бәхете" бирүен төшендерә. Кешеләр арасындагы рухи якынлыкны тоеп рәхәтлек кичерү Нина белән очрашу мисалында күрсәтелә. Башкалар бәхетенә сөенеп бәхетле булу Василий Петровичның Ләйсирә белән алар өчен сөенүен күргәннән соң билгеләнә.

Ф. Садриевның "Кыргый алма әчесе", М. Вәлиевнең "Качу" повестьлары татар әдәбиятында саф романтик кимәлдә язылган әсәрләрнең яңача яңгыравын, бу агымның тагын да яңа әсәрләр бирер мөмкинлекләре бар икәнлекне, аеруча кеше психологиясен тирән ачу ягыннан әһәмиятен дәлилли.

1970-80 еллар чигендә М. Галиев тә лирик башлангычны романтик юнәлештә калкытып куюга ирешә. Нәтиҗәдә, татар прозасы тәэсирлелеге, әсәрләрдә тудырылган тормыш моделенең һәм кеше күңеленең матурлыгы ягыннан һич тә шигърияттән калышмаган эпик әсәрләр белән байый. Аларда яшәү мәгънәсе, кеше кыйммәте, сәнгатьнең тормыштагы урыны-роле кебек күп кенә сораулар фәлсәфи яссылыкта күтәрелә.

"Ак абагалар" повесте иң элек форма эзләнүләре ягыннан игътибарны үзенә тарта: романтик структураны лирик өстәмәләр, фәлсәфи уйланулар белән баетып, язучы аны күпмедер үзгәртүгә ирешә. Хәтта әсәрнең эпик таләпләрдән ерагайган сюжет-композиция бирелеше дә шушы форма-сөйләмнең лирик-эмоциональ көченә буйсындырылган кебек тоела.

Повестьны җыеп торучы үзәк—язучы тарафыннан уйлап табылган һәм автордан аерып куелган хикәяләүче, романтик герой. Саф романтизм таләпләренә туры килгән сәнгать кешесе, талантлы, матурлыкны күрә белүче, башкаларга һәм үз-үзенә карата артык таләпчән (максималист). Әсәр геройның уйлары, хәтерендә сакланган мизгелләрне яңартуы, кичерешләрен искә төшерүе кебек язылган. Төп сюжет сызыгы буларак, шушы геройның күңелендә барган үзгәреш-хәрәкәт аерылып чыга. Ул бер каршылыкның чишелешкә омтылуы белән түгел, бәлки герой күңелендәге гомуми канәгатьсезлек, яшьлектә үз-үзен һәм тормышны танып белергә омтылу кебек билгеләнә: *"Орлыкны гомер буе учта йөртеп буламыни. Аны иртәме-соңмы туфракка чәчәргә кирәк. Чәчтеңме—орлык юкка чыгу бәрабәренә үсенте дөньяга килә... Димәк, ул вакыттагы үсмер чактан бүгенге мингә кадәр ничаклы үзгәреш, югалту, табу"*. Ялгышлар, каршылыклар, кайгылар аша герой хакыйкатьләр ача, нәтиҗәләр ясый. Язучынын максаты—шушы юлдан баручы геройның күңел тәрәзәләре нәфислеген, алардагы ак абагалар: гамь-борчулар, соклanулар һәм тирән кичерешләр—чагылышын укучыга җиткерү, күрсәтү кебек тоела. Студент егет Данияриның башкалар белән мөнәсәбәтләрен искә төшереп—үсмерчак хәлләрен, әтисен югалтуын, укудан китәргә мәҗбүр булуын, авылдагы тормышын өзек-өзек сурәтләү исә ярдәмче роль уйный.

Субъектив фикер төсендә, яшь вакытта күңелләрендә балалык самимилеген, чисталыгын саклап кала алганнарның рухи байлыкка, фикер камиллегенә омтылып

яшәүчеләргә әверелүе әйтелә. Бу фикер тулы характерлар буларак ачылган Гейдельберг һәм Фирзан "тарихлары" ярдәмендә кабатлана.

Вакыйгалар катламы мәхәббәт өчпочмагын: Данияр—Айрүзә мөнәсәбәтләренең төгәлләнүен, Данияр—Динара мөнәсәбәтләренең ачыклануын колачлый. Ике сызык та сер томанына төрелгән, Айрүзә белән Данияр арасындагы беренче саф хисләрнең сүнү сәбәбе дә төгәл генә күрсәтелми. Яшьләрнең төрлелеген *("Син җир кешесе түгел, Данияр. Минем гади генә авылда, гади генә бер өйдә тыныч кына яшисем килә", ди Айрүзә)* ассызыкласа, хәтта мәхәббәт (тормыш) кануны кебек гомумиләштерсә дә, лирик катламның ретроспектив сурәтләнеше, Айрүзә белән танышу, мәхәббәт туу мизгелләрен искә төшерү, Факия образы белән килеп кергән хатирә башка сәбәпләр булуны искәртеп, ярдәмче сюжет сызыгын тирәнәйтә. Динара белән танышлык та аның ярату икәнлеген аңлау ноктасыннан гына тасвирлана. Шушы серлелек кеше өчен газиз, әһәмиятле, тормышта тирәк булырлык хис итеп сурәтләнгән мәхәббәтнең (автор аны изге сүзе белән дә еш атый) сак якын килүне, ике кешедән дә акыл һәм аңлау таләп итүен искәртә.

Язучы мәхәббәтнең бары тик рухи омтылышлар белән яшәүчеләр кичерә торган хис булуын да калкытып куя. Лениза һәм Нигъмәт образлары, алар арасындагы мөнәсәбәтләр шуна иллюстрация төсен ала. Мәхәббәт—иҗат, сәнгать кебек бәяләнә. Шушы иҗатның "барышы" күздән кичерелә, сере һәр кешенең мөнәсәбәтләрне матурлап кабул итүендә табыла: *"Динараның йөзенә якыннан текәлеп карыйм. Гаҗәп, ул чынлыкта гел мин күзаллаганча түгел икән бит. Күрәсең, мин аны күңелемнән үземчә иҗат итәм. Идеал образга якынайтам. Үзгәртәм. Үземнән матурлык өстим. Үземчә ачам. Минсез ул сүнеп калыр иде кебек. Акыл хәрәкәтеннән тыш, кайдадыр тирәндә сирпелеп киткән бу уйларга аек нәтиҗә ни? Бәлки, бу— яратудыр? Мин аның һәр хәрәкәтеннән, һәммә сүзеннән үземдәге сыйфатларны эзлим түгелме. Мин анардан күпмедер дәрәҗәдә үземне тапсам, ул миннән—үзен... бәлки, шулдыр яратуга таба адым..."*.

Лирик катлам текстта графика ярдәмендә үк аерып куелган. Ул, геройның уйлары һәм хис-кичерешләр үзгәреше сурәтләнгән кисәкләр кебек, повестьның буеннан-буена чәчелеп урнашкан. Бу өлешләрдә Данияр күңеленең матурлыгы, дөньяга чиста күзләр белән караучы кешенең тормышны бер могҗиза, сер йомгагыдай кабул итүе аңлашыла. Лейтмотив булып, ак абага символы янадан-яна яклары белән ачылып-ялтырып бара. Беренче лирик өстәмәдә ул туры мәгънәсендә—тәрәзәгә төшкән кар бизәкләре булып та, Данияр кар ыргыткан күңел тәрәзәләре—Айрүзә хисләре төсендә дә, бәхетне белдереп тә *("Абагалар арасыннан дөньяга бәхетле күзләр төбәлә. Синең күзләр—ак абага чәчәкләре...")* килә. Абагаларны мәхәббәт символы кебек аңлау мөмкинлеге дә калдырылган: Динара белән бәйле лирик өстәмәдә ул шулай шәрехләнә. Повестьны башлап һәм йомгаклап килгән кайма Данияр күңелендәге бизәкләр вариантын калкыта.

Повестьта фәлсәфи катлам әһәмиятле урын били. Ул ике канатлы. Бер яктан, повестьның буеннан-буена кеше күңеленең, хисләренең, акылының, омтылышларының бөеклеге ассызыкланып бара. Даниярның үзен бәйсез, ирекле тотышы (Нигъмәт белән бәрелешү, Самат Ихсанович белән сөйләшүләр, Бекс Әбҗәлилович белән бәхәс) автор идеалы төсен ала. Хәтта геройның аңлап бетермичә, аң төпкеленнән калкынган сурәт ярдәмендә үз-үзен бәяләве дә кеше кыйммәте кебек гомумиләшә: "Мин түгәрәк мәйданга килеп чыгам. Мәйданны уратып алган каеннар бер җайга чайкалыша. Уртада кин инсәле имән, үзе иелгән. Инсәсенә яткан кар—гүя сөлге. Бу—Сабан туе. Көрәш мәйданы. Мәйданда ялгыз көрәшче, ялгыз ир-егет. Урман тирәнлегеннән яңгырап тавыш килә: —Соңгы кө-рәш-че, соң-гы ир!! Соң-гы көрәш-че-е-е!". Тормышта кеше үзен "соңгы көрәшче, соңгы ир" итеп тоярга тиеш дигән фикер ачыклана.

Тормыш кешенең үз-үзен күрсәтү-таныту теләге аша аңлатыла: "Бихисап йолдызлы океан эчендә шулкадәр кечкенә син... Ләкин кеше гасабиланып күккә карап кычкырмый, үзенең зурлыгын исбат итәргә омтыла". Әчке көрәш тормышны алга җибәрүче көч дәрәҗәсенә куела: "Кешедә тирәннән күтәрелгән, каннан килгән кыргый ярсулык актарылып чыга да бөтен кирталәрне җимерә,

ахры. Үз ирегең ярып чыга!". Кешенең табигатьтән аермалы ягы да шушында дип раслана: "Ә менә кеше... кеше үзендә "мин" барын ача. Хәтта үз-үзе белән дә гомер буе көрәшеп яши".

Үлем вакыйгасына бәйле, экзистенциаль фәлсәфәнең төп кануны әйтелә: "Вакыт чикләнгән. Яшәү ул—әкрен-әкрен үлә бару". Шуңа каршы, Данияр төшенгән антиномик хакыйкать табыла: "Яшәү, димәк, әкрен-әкрен туа бару, үзеңнән соң да яшәр өчен...". Сент-Экзюпериның әлеге фикере эпиграфка чыгарылу аның әсәрдә фокус икәнлеген искәртә. Димәк, повесть яшь кеше—Даниярның "әкрен-әкрен туа", үз-үзен аңлый баруы, шәхес булып житешүе, тормыш һәм кеше хакыйкатьләрен ачуы турында.

М. Галиевнең "Алтын тотка" повесте романтик әдәбият үз күрә торган тагын бер өлкә—тарихка кагылып үтә. "Ак абагалар"дагы кебек үк, әсәрне берләштерүче үзәк булган хикәяләүче-герой күңелендәге үзгәрешләр төп сюжет җебен суза. Ул үзгәрешләр тарих һәм бүгенге мәсьәләләренә дә карый. Иске өй һәм аннан истәлек булып калган алтын тотка Марат өчен үткән белән бүгенгене бер җепкә бәйләргә, бер ишек белән тоташтырырга ярдәм итә. Хыял һәм чынбарлык каршылыгын тоеп яшәүче герой бүгенгедән—үткәнгә, үткәннән—бүгенгегә күчә торган "алтын тотка"лар белән очраша: мәхәббәт, дуслык, мәрхәмәт һәм иҗат алар.

Марат—романтик буларак тулы ачылган образ. Сәнгать кешесе, матурлыкка сокланып яшәүче, туган җире дә булмаган—җир белән күк арасында дөньяга килгән 21 яшьлек егетнең авыруы да үзенчәлекле: заманча ялтыравыклы шома мебель өстенә кунган тузаннан аллергия анда. Бу чир дә, күрәсең, бер яктан, Маратның үткәндәге кыйммәтләрне әһәмиятле санап яшәүче булуын, икенче яктан, яңа заманның кешеләргә өр-яңа проблемалар алып килүен искәртә.

Иске йорт төрле холык-фигыльгә ия, төрле язмышлы кешеләрне бер түбә астына сыендыра. Бу повестьта һәр кеше—каршылыклы, үзенең эчке каршылыгы бер үткен проблеманы калкытып куярлык итеп сурәтләнгән. Хыянәтче тибы Лопес милләтне, исемне һәм телне алыштыру проблемасын бөтен тирәнлегендә, тарих дәрәҗәсендә күтәрергә мөмкинлек бирә. Проблема Марат исеменнән формалаштырыла: *"Чыпчык булып туа, үскәч, сандугачка әйләнми, көчек көчек булып туа, үскәч, сарыкка әверелми бит. Кеше бер милләт вәкиле булып туа, үскәч, үз теләге белән икенче милләт кешесенә әйләнә. Табигыйме бу?"*. Проблема исемгә, милләткә хыянәт—остазга хыянәт кебегрәк үсеш ала, хыянәтчеләрнең үз мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүчеләр булуы ассызыклана.

Повестьта лирик башлангыч көчле, мондый өлешләрдә сынландыру әһәмиятле урын били. Әсәр Казан белән сөйләшү кебек башланып китә дә, лирик кереш "Шәһәрнең дә югалган үз Атлантидасы бар..." дигән җөмлә белән тәгәлләнә. Әсәр иске йорт—шул Атлантида хакында бәян итә. Мотив Марат белән Мастер күзәткән үле утрауда калкып чыга. "Бу—минем Атлантидам", ди Мастер. Повесть аваздаш җөмлә белән тәгәлләнә: "Һәркемнең күңелендә үз Атлантидасы бар...", шушы гыйбарә янадан бер кат һәр геройга әйләнеп кайтырга, алар күңелендәге югалган өметләрне, бәхетләрне... барларга мәҗбүр итә, мәгънә чикләрен киңәйтеп җибәрә.

Повестьның иң матур һәм тәэсирле өлеше—рәссам Сирин язмышы, аның картинасын шәрехләү, Анна белән мәхәббәтләре һәм соңгы хат. Саф романтик геройлар итеп бирелгән Анна—Сирин мәхәббәте яшьләрдә: Мастер белән Диләрәдә, Марат белән Айсылуда кабатлана. Яратуга сәләтне генә түгел, иҗат эшенә талантлылыкны, киң күңеллелекне, матурлыкны күрә белүне дә өлкәннәрдән "алып китүчеләр" алар. Картина повестьта символ вазифасын башкара, чор тудырган кыйммәт төсендә кадерле. Аның өч ноктадан өч төрле күренү мөмкинлеге, "сере" художникның үзенә дә билгесез була. Шушы серне Анна ача, рәсемне саклап кала. Шул рәвешле, язучы иҗат эшендә мәхәббәтнең роле зур булуны искәртә. Ә инде рәсем туу халәтен сөйләтү иҗат эшенең—илаһи, логик кануннар белән генә аңлатып булмас бөек эш икәнлегенә ишарә ясый.

Анна—Сирин сюжет сызыгы повестька сентименталь рух алып килә. Хат тексты бирелү, Маратның Мансур белән дуслашуы, Анна белән Сириннең гомер ахырында күрешә алмавы хикәяләүче герой күңелендәге үкенечле уйлар ярдәмендә

тирәнәйтелә. Повестьның бу вакыйгалары романтизмның хәзергедә югала башлаган кыйммәтләрне үткәннән эзләү мотивын дәвам итә.

Соңгы еллар татар прозасында башка тенденцияләр алга чыккан, синтетик характерлы әсәрләр дә языла. Аларда олы мәхәббәт һәм җәмгыятьнең кешегә дошманлыгы тарихлары кушылып, романтик реализм хасил итә.

М. Кәбировның "Мәхәббәттән җырлар кала" повестенда тормыштагы, кешеләр күңелендәге матурлыкны сурәтләү сокландыргыч, ул вакыт-вакыт күздән яшь чыгарыр ноктага җиткән сентиментальлек белән кушылып китә. Традицион шәркый әдәбияттагыча матур, изге, корбанчыл мәхәббәт романтик сюжет катламында гына түгел, детальләрдә дә ассызыклана. Егетнең исеме Таһир булу—аллюзия алымы—менә искәрмә ясый. Урыны-урыны белән Гөлзилә күңелендәге уй-хисләрне "аң агышы" алымы ярдәмендә сурәтләү психологизмны тирәнәйтә. Чын мәгънәсендә матур мәхәббәт тарихында сөйгәненең өчен батырлыклар эшләү дә, ниндидер хыялларны тормышка ашырудан баш тарту да, үлемгә бару да урын алган. Иң әһәмиятлесе шул: реалистик катлам ярдәмендә алар барысы да укучыны ышандыра!

Реалистик катламда тарихи вакыт 1990 елларны үз эченә ала, вакыйгалар вакыты 4-5 ел белән билгеләнә. Иҗтимагый бәя берничә яссылыкта бирелә: егетләрне сугышка җибәреп, аннан соң алар язмышыннан йөз чөеручә; ришвәт, тән сату, аракы сатуга кереп баткан; тормышта кешегә үз сәләтен файдаланырга, үз мөмкинлекләрен эшкә җигәргә юл бирми торган җәмгыять булуы ассызыклана. Болар проблема төсендә куелып, берничә ситуация-мисалда күзәтелә.

Иҗтимагый мотивлашкан булса да, гомумкешелек проблемасы итеп куелганнары да күп. Мәсәлән, Гөлзилә—Фәүзия мөнәсәбәтләре кайгылы кешенең башкаларга да авырлык китерүен билгели. Гыйльман—Гөлзилә, Гыйльман—Таһир каршылыгы теләсә нинди коллективта явыз, үзеннән көчсезләрне җәберләп тәм таба торган кешеләр булуны искәртә. Саимә карчык—Гөлзилә каршылыгы кешеләрнең үзара ышанычы мәсьәләсенә кагыла һ. б. Әсәр тукымасына геройлар монологы булып килеп кергән проблемалар да бар, алар автор фикере булып аңлашыла. Мәсәлән, милләтнең бүгенге хәле һәм киләчәге проблемалары комендант Нәфисә тарафыннан әйтелә: *"Татар булып яшәү авыр бездә. Әнә шул татарлыкны яшерү өчен урысча сөйләшә, урысча киенә, урысча эчә алар. Һәм соңгы чиктә барып теләләр дә—алар ни урыс була алмый, ни татарлыгын югалта." "...Халык ул—масса, сарык көтүе белән бер ул. Халыкны шәхесләр күтәрә, шәхесләр бөек итә. Ә без бүген тулай торакның сәрхуш татарлары, урысча сүгенгән, урыска табынган татарлары өчен түгел, ә шәхес булырлык татарлар өчен көрәшергә тиешбез".*

Аерым бер очракларда проблемаларның хикәяләүче монологы кебек бирелеше дә очрый. Мәсәлән, акча артыннан куу хакындагы өлеш шундыйлардан.

Реалистик катламдагы хәл-вакыйгаларны да язучы романтик алымнар ярдәмендә бәяләп бара. Әсәр Кыям абзый җыры белән башланып китә һәм шушы җыр булачак вакыйгаларның характерын билгели: "Алмаларын җәлли тормыш, Җаннарыма таш ора". Шушы уңышлы табылган, эчке мәгънә катламына алып кереп китә торган башламнан соң, Кыям белән бәйле мотив юкка чыкмый. Әсәр сонында язучы аның җырларын Гөлзиләдән җырлата.

Җырга һәвәс Кыям турында сөйләгәндә, автор аны "стандарт булмаган" герой дип тамгалый. Әсәр барышында очрашкан башка геройлар: Гөлзилә яки Таһир да, комендант Нәфисә һәм Ришат белән Гүзәл дә—шулай ук стандарт булмаган, талантлы, якты кешеләр. Ләкин талант—автор аңлатуында якты кеше булу өчен иң кирәкле сыйфат түгел. Әхмәт Сабиров, Нурияләр мисалында әхлакый якның әһәмиятле булуы күрсәтелә. Төп героинядагы мәхәббәткә тугрылык сыйфаты югары күтәрелә. Язучы Гөлзиләне ике мәртәбә: тән сату юлы белән укырга керергә кызыктырып һәм сөйгәнен аякка бастыру яки карьера ясауны сайлау алдына куеп сыный. Шушы сынауларны үткән кыз, әйтерсең, халыкка моң таратырга фатиха ала.

Әсәрдә язучының осталыгы күп кенә элементларда күренә. Бу повестьта сүз-образлар белән эшләү, аларны хисси-психологик тирәнлеккә ирешү чарасы кебек куллану матур тәэсир калдыра. Автор сүз-образларны антиномия формасында

урнаштырырга ярата. Мәсәлән, *"Гөлзиләнең иреннәрендә бәхетле елмаю, ә керфекләрендә ачы күз яше ялтырап китә"* дигән мисалда "бәхетле елмаю" һәм "ачы күз яше", бер яктан, Гөлзиләнең эчке халәтен ача. Икенче яктан, сәнгать ярдәмендә, халыкка хезмәт итеп бәхеткә ирешү һәм шәхси бәхетсезлек, аларның бер-берсен алыштыра алмавы хакындагы нәтиҗәгә китерә.

Бу повестьта геройлар бирелеше дә үзенчәлекле: алар үсеш-үзгәреш эчендә сурәтләнеп, еш кына әсәр дәвамында капма-каршы характер булып аңлашыла. Ягъни язучы геройлар бирелешендә еш кына көзгеле композиция алымына мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, Әхмәт Сабиров Гөлзилә исеменнән сокланып, хәтта идеал дәрәҗәсенә менгерелеп күрсәтелә башлый. Әсәр дәвамында аны аңларга һәм акларга тырышу, хәтта өлешчә кызгану күзәтелә. Бу герой белән соңгы очрашуда аның чын йөзе ачыла: бозык, куркак, үчле икәнлеге мәгълүм була. Гөлзилә күңелендә аңа карата уянган нәфрәт хисе укучыныкына әйләнә.

Повестьта аерым геройларның психологик "пары" бар. Нурия—Әхмәт Сабировның шундый игезәге итеп уйланылган һәм әхлакый-фәлсәфи гомумиләштерү ясарга мөмкинлек бирә: бер тапкыр хыянәт иттеңме, бер тапкыр "ярамый" чиген атлап чыктыңмы—кирегә юл юк! Бу чиктән соң аска төшәргә, түбән тәгәрәргә генә мөмкин!

Әсәрдә экзистенциаль моментлар да көчле. Таһирның тиролек, җәмгыять, үз-үзе белән көрәштә үлемнән башка юл таба алмавы, Гөлзиләнең ялгызлыкка дучар булуы, илаһи мәхәббәтнең кавышу белән тәгәлләнмәве сагыш, үкенеч хисләре уята. Ләкин романтик башлангыч гомуми фәлсәфи фикернең оптимистик килеп чыгуына китерә. Тормыш никадәр генә авыр, пычрак булмасын, ул барыбер матур, аның нигезендә барыбер башкаларга файдалы булу омтылышы ята, "күз яшьләре" янында бәхетле елмаю бар", диелә сыман. Талантлы, хөр, экспрессив геройлар, табигать һәм тиролек матурлыгы, төп геройлар тирәсендәгеләрнең рухи байлыгы әсәрдә яратып сурәтләнә. Кеше, тормыш, яшәеш хакында сүз алып барганда, традицион романтик прозадагы шикелле үк, автор яктылык һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык антитезаларына якыная.

Шушы ук структурадагы әсәр—Ә. Салахның "Соңгы вальс" повесте да романтик һәм реалистик сюжет сызыкларының янәшәлегенә корылган. Биредә төп герой Газиз тормышындагы берничә көнгә сыеп беткән романтик мәхәббәт һәм ретроспекция ярдәмендә тасвирланган, Чернобыль фаҗигасенә бәйле, кеше-җәмгыять каршылыгының үзгәреш тарихы бар.

Романтик сюжет сызыгы мәхәббәтнен—тирән хисләр кичерү, аңлашу, үзара хөрмәт булуын раслый. Газиз—Айсылу мөнәсәбәтләре бик кыска вакытлы бирелә, ләкин язучы аны чын мәгънәсендә соклангыч, идеаль гашыйклык дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли. Бу тарихтагы каршылык—Айсылуның Газиз вальска чакыргач баш тартуы һәм Газизнең икенче көнне Айсылуны читләтүе—бер фикерне белдерә: чын мәхәббәтнең кыска вакытлы ләззәт эзләү белән уртаклыгы булмаска тиеш! Бу Айсылуның аңлатмасында да күренә: "Мин бит теге кичне сезне бер карт җилбәзәк, танышыр өчен генә чакыра, дип белдем".

Реалистик сюжет сызыгы Чернобыль хакыйкатен укучыга җиткерү белән үк кыйммәтле. Иҗтимагый проблемалар аша, язучы җәмгыятькә тәнкыйди бәя бирә. Бу сюжет сызыгы—җәмгыятьнең кешене алдап үлемгә китерү тарихы ул. Бу фикер сүз катламында да гел кабатлана. "Безнең илдә, гомумән, кеше хакын хаклау, кеше кадерен белү юк", ди Газиз. Хикәяләүче дә автор фикерен белдерә: *"Каһәр төшкән Чернобыль җирендә Газиз үзенә күрә ачыш ясады: элек һәр адымда "Все—во имя человека, все—для блага человека" дип шапырынган бу совет, бу урыс җирендә бер изге гамәл дә, бер иман да юк икән бит. Барысы да шапырынкы ялган. Һәр җирдә—алдашу, һәр адымда—мәкер, икейөзлелек. Кеше тормышы, кеше язмышы ике тиенгә дә тормый бу башбаштак илдә."* Һәм повестьта күрсәтелгән таҗиклар, Чернобыльдә, Әфганда һ. б. кайнар нокталарда һәлак булучылар язмышы шушы идеягә иллюстрация булып килә.

Җәмгыятьне тәнкыйтьләү көчле бирелеп, ул кеше кыйммәте җуелу, алдашуның нормага әверелүе, дәүләт мәнфәгатьләренең кеше мәнфәгатьләрен исәпкә алмавы

кебек өлешләрдән җыела. Гаепне язучы 1917 елдан соң формалашкан системада күрә. Ни өчен Чернобыльгә китүен Газиз болай аңлата: *"Без бит теге еллар тәрбиясен алып үскән балалар. Патриотизм, интернационализм... Ил өстенә куркыныч килгән, тар муенлы чүлмәккә утыртылган пәри бөкене бәреп чыккан да, котырына хәзер. Мин бармасам, башканы алып китәчәкләр..."* Бу сүзләр кеше кыйммәтен, мәнфәгатен арткы планга чигерүнең иң зур хата, ялгыш булуын раслый.

Дәүләт ихтыяҗы алга чыккан тормыш моделен кеше ихтыяҗы беренче планда торган модель белән "алыштыру" мөмкинлеге барлана. Иҗтимагый үзәкнең эшчәнлеген, Чулман елгасы буендагы атом электр станциясен төзүгә каршы халыкны күтәрүне сурәтләү кешеләрнең, берләшеп, дөньяны үзгәртә алырына ышаныч булып яңгырый.

Газизнең романтиклык сыйфатын язучы, беренче чиратта, аның башкаларга ышануында, үзеннән битәр, бүтәннәр ихтыяҗларын кайгыртуында күрә. Сәнгать кешесе, архитектор итеп сурәтләнгән Газиз—бер үк вакытта аек акыллы, көчле характерлы, көрәшче дә. Заманга яраклаша алмавы, җәмгыятьтәге кануннарга түгел, гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тотып яшәве Газизне үз тирәлегендә—калкытып, изгеләштереп күрсәтергә ярдәм итә.

Повестьта милли проблемалар чагылыш таба. Әсәр башында ук, чит җирләрдәге һәм Чулман буендагы кешеләрне чагыштырып, герой нәтиҗә ясый: "Үз җирен, үз кешеләрен, үз телен". Алга таба, Тансык Сарачевка кагылышлы вакыйгаларда, татарларның телен, милләтен җую проблемасы күтәрелә. Язучы аны глобальләштерә, милләтне югалтуның—деннән язу, иманны сату икәнлеген ассызыклый.

Экзистенциаль фәлсәфә ялгызлык төшенчәсенә бәйләнә. Әсәрдәге һәр герой—ялгыз, бу сүз катламында да кабатлана бара. "Тирәнрәк уйласаң, кеше тумыштан ук ялгыз, көчсез, ярдәмгә мохтаҗ, мескен ул" дигән сүзләр төп геройдан да әйттерелә. Шушы фонда вальс—мәхәббәт символы гына булып калмый, кешеләрнең ялгызлыктан котылу юлы дәрәҗәсенә күтәрелә. Бергәләп—сокланырлык бию күрсәтергә, бәхетле яшәргә мөмкин, бергәләп—җәмгыятьтәге фаҗигаләргә каршы торырга, иҗтимагый бәлаләрдән котылырга була дигән субъектив идея шулай ук романтик рухта.

XX гасыр ахыры татар әдәбиятында романтизмның төрле төсмерләр белән баеп калкып чыгуы, барыннан да бигрәк, милли әдәбиятны камилләштерү, хыялыйлыкны, эмоциональлекне арттыручы алымнарны гамәлгә кертү омтылышы белән билгеләнә. Яңа романтизм субъективлыкны көчәйтә, җәмгыять яки коллектив проблемаларыннан шәхес һәм яшәеш проблемаларына күчә баруны аңлата. Характер буларак тулы ачылган романтик геройларны тасвирлауда хис һәм фикер көчеш-үзгәрешләрен үзәккә кую психологизмны тирәнәйтә, зәвыклы укучыга юнәлтелгән булу әсәрләрнең үзенчәлекле уйланыш-эшләнешен тәэмин итә. Нәтиҗәдә, романтик юнәлеш күп кенә фәлсәфи һәм иҗтимагый проблемаларны тәэсирле, саф реализм кысаларында ачып булмас дәрәҗәдә нечкә, күптөрле ассоциацияләр тудырырлык дәрәҗәдә күтәрү мөмкинлеге бирә.

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***КЫЙЛЬ ВӘ КАВЕЛ (КАУЛ, КАЛЬ)*** *г.* — Юк-бар сүзләр, имеш-мимешләр. Китапларда гадәттә цитаталар алдыннан кулланыла торган гыйбарә ("әйтерләр, әйтәләр" мәгънәсендә). // *Инан, биллаһи, сүзем, дәгелдер кыйль вә кальләрдә.* Габделҗәббар Кандалый. *Тәмам вокзал эчендә кыйль вә каль, җаң вә җәдәл, дәгъва вә гауга, кайда барырга белер хәл юк.* Гали Чокрый, "Хаҗнамә" кулъязмасыннан. Аллаһы Тәгалә мәкруһ күргән нәрсәләр булыр: 1)*дин вә дөнья өчен кирәге булмаган кыйлкал; 2)күп сөаль; 3)урынсыз җирдә мал заигъ итү.*

***КЫЙТГА*** *г.* — Континент, дөнья кисәге; нәрсәнең дә булса кисәге, өлеше, детале; парча (әдәби). // *Сәгать (механизмы) кыйтгалары.*
Күплек саны шәкеле — *кыйтгат.*

***КЫЙЫН*** *бор.төр.* — Җәзалау, газаплау; газап, җәза. Бүгенге татар телендә *кыйналу (кыен алу), кыен аша(т)у* кебек сүзләр шушы мәгънәгә барып тоташалар. Борынгы төрки телдә *кыйынчы*-газаплаучы, җәллад, палач мәгънәсендә йөргән. Газаплау урынын, зинданны *кыйынлык* дип атаганнар. // *Чөнки ул ач күзлелектән күп кыен алган иде...* Г.Тукай.

***КЫРЫК ТАРТМАЧЫ*** *тар.* — Вак сатучы, асламчы. Каргалы якларында Казаннан капчык күтәреп килгән вак сәүдәгәрләрне *күтәрәмчеләр* дип атаганнар. *Тубалчылар* дигән исемнәре дә булган.
Тагын кара: ***АСЛАМЧЫЛАР, КЫРЛАЙЛАР.***

***КЫРЫК ТӨЕН ТӨЙДЕРҮ*** *тар.* — Кешене сөйдерү яисә биздерү өчен эшләнә торган ырым-сихер догасын укый-укый җепкә санап төеннәр төйнәүдән гыйбарәт хорафат.

***КЫЯФӘТНАМӘ*** *гф.* — Физиогномика, *фирасәт.* II гасырда яшәгән грек галиме Палемон (гарәпчәдә: *Ифлимун*) нигез салган фән. Аның "Кешенең чыраена карап уку" ("Кыяфәтнамә") дигән төп хезмәте гарәп теленә тәрҗемә ителә һәм популярлык казана.
Кешенең килеш-килбәтенә карап холкын-фигылен белү кагыйдәләре еш кына мәкаль-әйтемнәргә тартым һәм уены-чыны бергә булган бу кагыйдәләр вакыты белән теге яки бу кешене төсмерләргә ярдәм итәргә дә мөмкин. Мәс., "Ала күздә акыл булмый, майлы күздә ягым булмый", "Алан-йолан кешедә өмет юк" (ялт-йолт каранган кеше турында), "Бармагы озын һөнәрче булыр", "Ирене юка кеше усал булыр", "Кече казан ташучан, кечек кеше ачучан", "Күзе очлы угры булыр", "Эче карангының йөзендә нур булмас" кебек галәмәтләрдә халыкның тормыш тәҗрибәсе чагыла һәм аларга психологик аңлатма табарга мөмкин.

***КЯТИБ*** *г.* — Язу белән шөгыльләнүче, секретарь. *Кәтиб* рәвешендә язу да очрый ("*кәтиб фәрештә*"). // *Кятиб ул-куттаб* — кятибләр кятибе, баш секретарь ("генсек" — "генеральный секретарь" кебегрәк). Бу термин тарханлык ярлыгында очрый.
*Кятип* язылышы да бар.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елның 1нче санында.*

***КЯФЕР, КЯФИР*** *г.* — Аллаһыны бар дип танымаучы, мөселман динендә булмаган кеше, көфер итүче. Кайбер чыганакларда кяфирләр икегә бүленеп карала: беренчеләре — "*кяфир инкяр*"лар, ягъни Аллаһы Тәгаләне инкяр итүчеләр, ә икенчеләре — "*кяфир жөһуди*"ләр (йәһүдиләр?), ягъни Аллаһы Тәгаләгә ышаныш җитмәүче хаерсез кяфирләр. Телдә *китаби кяфирләр* дигән сүз дә бар (христианнар һәм йәһүдиләр). *Мәҗуси кяфирләр* — мәшрикъләр, аларга каршы җиһад игълан ителә.

Суфилар бер мизгелгә Аллаһыны онытып, башка бер нәрсә турында уйлап алуны "кяфир" диләр ("Суфичылык серләре").

*/ / Кеше чын дисә ул батыйль сүзне, Булыб кяфир кара кылгый йөзене.* Таҗетдин Ялчыгол.

Электә мәдрәсәләрдә *"Кяфер мү сән, мөселман мү сән?"* дигән сорау биргәч, шәкертләр иман шарты буенча: "Әлхәмде лиллаһи мөселманмен", — дип җавап бирергә тиеш булганнар.

*Кафир, көфер, кәфер* язылыш һәм әйтелешләре дә очрый.

Төрек телендә шушы ук мәгънәдәге "гәур" (рус телендә — "гяур") сүзе баштарак зәрдәшт динен тотучыларга карата кулланылган, аннары гомумән барлык имансызларга нисбәт ителә башлаган. "Гавер" сүзе Габди шигырендә дә очрый: "Мөселманнар сабыр кылың: Авыр булды бу дәвер; Һәр ни булса алладандир, Димәгез кяфер, гавер!"

Күплек саны шәкелләре: *кяфирун (кәфирун), көффар.*

***ЛАШМАН ХЕЗМӘТЕ, ЛАШМАНЧЫЛЫК*** *тар.* — Петр патша тарафыннан Казанда 1718 елда Каспий һәм Идел флотилияләренә кораблар төзү өчен оештырылган адмиралтиягә беркетелгән крәстиәннәр хезмәте. *Лашман* — немец сүзе, "урман эшчесе" дигәнне аңлата. Казандагы Татар бистәсе халкының да күпчелеге шушы адмиралтиягә теркәлә. Рус флотын төзү өчен урман кисеп ташу эшләренә җаваплы итеп чукынудан баш тартканнары өчен утарларыннан һәм биләмәләреннән мәхрүм ителгән татар морзалары беркетелә. Соңрак аларны гомумән "казна крәстиәннәре" катламына кертәләр. Лашманнар Кукмара, Шәмәрдән якларында аеруча күп эшләгән, чөнки кораб төзү өчен яраклы төз наратлар шул тирәләрдә мул булган. И.А.Износковның 1885 елга караган мәгълүматлары буенча, Олы Әлдермеш авылы Лашман дип тә теркәлгән, бу исә авыл халкының лашман хезмәте белән шөгыльләнгән булуы турында сөйли.

Бу вакытларда халыкка имән агачы кисү тыела, әгәр берәүнең имән агачы кискәне беленсә, ул каты җәзага тартыла.

1718—1719 еллардагы халык санын алу мәгълүматлары күрсәткәнчә, лашманчылык хезмәтенә Казан, Әстерхан, Нижгар, Воронеж губерналарыннан 11205 йорт, җәмгысе 56113 кеше тартылган. Лашманнар көненә 5-7 тиен алып коточкыч авыр шартларда эшләгәннәр һәм бу хезмәттә төп авырлык рустан башка халыклар җилкәсенә төшкән. Шул ук вакытта рус хакимиятләре лашманчылыкка алу сәясәтен башка милләтләрне христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәте белән бергә үреп алып барганнар. 1748 елның 7 декабрендә чыккан указ буенча, христиан динен кабул иткән крәстиәннәр лашман хезмәтеннән азат ителгәннәр. Дөрес, вакыты белән лашманнардан солдатка алу булмый, шуңа күрә лашман хезмәте аерым гаиләләр өчен "мәгъкуль саналган" (Ш.Мәрҗани).

Лашманчылар гөруһы арасында морзалар вә биш кораб ясап бирергә акчасы җитә торган Бурашев шикелле сәүдәгәрләр дә булган. Казан сәүдәгәре Бурашевның 1783 елның 4 апрелендә Петербургка кенәз Вяземскийга язган хаты билгеле. Бурашев хатын: "Сез, гали кенәз, лашманчы татарлар өчен бу хезмәтнең мөһлик һәм зарарлы икәнен беләсез" дип башлап китеп, урман кискән чакта үлүчеләр һәм кул-аягы зәгыйфьләнүчеләрнең күплегеннән, бу эштә яшь буыннар күбрәк хезмәт иткәнлектән, рекрут алганда солдатка яраклы яшьләрнең бик аз чыгуын әйтеп китә. "Лашман бәетләре"ннән Идел буе крәстиәннәренең озак вакытларга Урал-Себер урманнарына да җибәрелүе күренә.

Күптән түгел филология фәннәре кандидаты Эмиль Вәлиев тарафыннан мәшһүр казанлы Гавриил Петрович Каменевның (1772-1803) шагыйрь һәм журналист Максим Иванович Невзоровка (1763-1827) язган хаты табылды. Бу хатта лашманчылар турында

тарихыбыз өчен мөһим мәгълүмат булганга, аннан өзек китерәбез (Эмиль Вәлиев тәрҗемәсе нигез итеп алынды):

"Мөхтәрәм әфәнде Максим Иванович!

Казан палатасыннан алынган лашманнар турындагы мәгълүматны сезгә хәбәр итәм.

Петр I идарәсе вакытында лашманлыкка христиан динен кабул итүдән баш тарткан татарлар алынган һәм алар кораблар төзү өчен адмиралтия конторасы билгеләгән урманнарны кисүче эшче буларак файдаланылганнар. Мәрхүм императорның 1799 елның 16 декабрь указына кадәр алар чукынмаган йомышлы татарлардан (чөнки христиан динен кабул иткән татарлар керәшен татарлары дип аталганнар) гына торган һәм бишенче сан алуга кадәр 112653 җан булганнар. Ә указ басылганнан соң аларга тагын Нижегородск, Казан, Сембер, Саратов, Вятск, Оренбург губерналарында яшәүче татар, чуаш, мордва, башкорт, ар, чирмеш һ.б. халыклар да кушылып, барысы бергә 609664 кә җиткәннәр...

Лашманнар хезмәте түбәндәгедән гыйбарәт булган. Алар, Адмиралтия чиновниклары күрсәткән һәм тамга салган, кораб төзергә яраклы имән, нарат агачларын кисеп, бүрәнәләрне Идел, Зөя, Вятка, Сура елгасындагы пристаньнәргә чыгарып куйганнар. Якындагыларына аларны күтәреп, ерактагыларга ат белән ташыганнар. 1 октябрьдән эшкә керешкән җәяүлеләр 18 декабрьгә кадәр, бәйрәм һәм ял көннәрен дә кертеп, өзлексез урман кисканнәр. Ә атлылар исә киселгән урманны ташып бетергәнчегә тикле эшләгән. Хезмәтләре өчен көненә җәяүлегә 20, атлыга 40 тиен түләгәннәр. Ике кеше тәүлеккә 4 сажинлы 14 агач кисеп чистартсалар, ат белән эшләүче һәр атка 15 поттан ким бүрәнә төямәскә тиеш булган.

Әйтергә кирәк, "лашман" сүзе гади халыкта кулланылмаса да, "лаш" — бирергә, "мән" — кеше дигәннән барлыкка килгән. Казна палатасы һәм указларда исә алар "эшче халык" дип йөртелгән. Белмим, мәскәүлеләргә "лаш" сүзе танышмы икән, бездә ул бернинди нигезсез салынган, артык салым дигәнне аңлата. Әйтик, акча алыштырганда салымны күп түләдем яисә ул салымны күп ала дип сөйлиләр бездә."

Шул заманнарның күңел тетрәндерерлек ядкярләре булып "Лашман бәетләре" калган. Ихтимал, михнәт күрү мәгънәсендәге "Лаеш шулпасы эчү" сүзе дә лашманнардан чыгып таралгандыр. Халыкта авыр урман эшләрендә эшләүне *"лашман тарту"* дип атаганнар.

Ш.Мәрҗани язганча, 1859 елларда лашман хезмәте (атлысы булсын, җәяүлесе булсын) бетерелә.

***ЛӘГЫЙНЬ*** *г.* — **1**.Каргыш. Мәрхәмәтсез, юньсез затка карата әйтелә. // *Ләгыйнь Иван* (Явыз Иван-патша турында). **2**.Куылган, сөрелгән. // *Бер заман, иңмәс борын Иблис ләгыйнь, Торды инсан ал да гөл, син дә мин.* Ш.Бабич.

***ЛӘЙЛӘТ ӘЛ-МӘГЪШУШ*** *г.* — Тәртипсезлек кичәсе, "капшау төне". Урта гасырларда Багдадта христианнарның олы пост алдыннан була торган бер бәйрәм кичәсе. Хатыннар ирләр төркеме белән аралашып бетә торган бу кичәдә мөселманнар да катнашканнар. Бу вакытта һәркем үзенең кулына тулы ирек биргән.

***ЛӘЙСӘН ЯҢГЫР*** — Моңа Нәкый Исәнбәттә мондый аңлатма бирелә: "Ләйсән — көньякларда 23 нче марттан 3 нче майгача 40 көн эчендә яуган язгы җылы яңгырлар. Бездә исә күбрәк беренче күкрәү белән яуган җылы яңгырны ләйсән диләр". Р.Төхфәтуллин ләйсән яңгыр "кар китеп бетәр-бетмәстә" ява, "иң бәрәкәтле, файдалы яңгыр санала, игенченең беренче шатлыгы," — дип яза. Татарда ләйсән яңгыр турында "нисан ява" диләр. "Ләйсән суын җиде ел сакласаң, энҗегә әверелә имеш" дигән сүз дә бар. Соңгысында *ләйсән-сәйлән-энҗе* күчеше сиземләнә кебек.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Мансур Хәсәновка 75 яшь*

# ФИДАКАРЬЛЕК

Татар милләте ерак тарихның хәзерге зиһен күзе дә шәйли алмастай томанлы чытырманлыкларыннан алып бүгенгәчә исән-сау яшәп килә һәм алдагы елларга да матур-матур ниятләр кора дип әйтәбез икән—без ихтыяри-мәҗбүри рәвештә ул гаять озын тарихи юлның якты маяклары булуын да уйлыйбыз. Һәрбер чорда милләтнең күренекле шәхесләре яшәвен һәм иҗтиһат кылуын да күз алдына китерәбез.



Бүген без белгән күренекле шәхес—Татарстан Фәннәр Академиясе Президенты, филология фәннәре докторы, академик Мансур Хәсән улы Хәсәнов—һичшиксез, әнә шундый могтәбәр затларның берсе.

М.Х. Хәсәнов 1930 елның 25 июнендә Татарстанның Зәй районы Бегиш авылында туа. Шул авылда урта мәктәпне тәмамлый һәм 1945 елда Алабуга китапханә техникумына укырга керә, аннары Зәй районының Поповка авылында китапханәдә эшли.

1950-55 елларда М. Хәсәнов—Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты студенты. Ул университетны "бик яхшы" билгеләре белән генә тәмамлый. Аннары—"татар әдәбияты" белгечлеге буенча аспирантура һәм кандидатлык диссертациясе яклау. Шул ук елларда М. Х. Хәсәнов "Татарстан яшьләре" газетасы редакторы һәм университетның тарих филология факультеты деканы урынбасары булып та эшләп ала.

Берникадәр вакыт лектор вазифаларын башкарганнан соң, 1961 елда М.Х. Хәсәновны КПСС Татарстан өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире итеп раслыйлар. Ә аннары ул шул ук оешманың фән һәм югары уку йортлары бүлеген җитәкли. 1971 елның маенда исә аны Татарстан Министрлар Советы Рәисенең урынбасары итеп, 1984 елда беренче урынбасары итеп билгелиләр.

1991 елда Татарстан Фәннәр Академиясе оеша һәм аның беренче президенты итеп М. Х. Хәсәнов сайлана. 1993 елдан башлап ул бер үк вакытта татар энциклопедиясе Институтын да җитәкли.

Партия өлкә комитетында (10 ел) һәм соңрак республика Министрлар Советында (21 ел) озак еллар эшләү дәвамында Мансур Хәсәнович республиканың мәгариф, фән, мәдәният, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт, социаль тәэминат тармакларына җитәкчелек итә. Бу елларда республика әлеге тармакларда эшнең торышы буенча ил күләмендә алдынгылыкны тота, күп мәртәбә күчмә байраклар яулый.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның 90 еллыгы хөрмәтенә Арча районының Тукай-Кырлай авылында төзелгән мемориаль комплекс бөтен республика халкы өчен истә калырлык вакыйга булды. Бу елларда шулай ук Казан дәүләт мәдәният институты (хәзер мәдәният һәм сәнгать академиясе), Чаллыда педагогия институты, Волгоград физкультура институтының Казан филиалы ачылды. Күп кенә тарихи шәхесләргә һәйкәлләр салынды (М. Вахитов, И. Шишкин һ. б.).

Татарстан хөкүмәтендә үтә җаваплы вазифаны уңышлы башкару белән бергә Мансур Хәсәнович фән өлкәсендәге актив эшчәнлеген дә туктатмый. Казан дәүләт университетында ул 16 ел буе фәнни педагогик эш алып бара, татар әдәбияты тарихы буенча лекцияләр укый, Татарстан тарихы буенча махсус курс алып бара,

күплэгэн кандидатлык диссертацияләренең һәм диплом эшләренең фәнни җитәкчесе була. 1974 елда ул профессор итеп раслана.

Мансур Хәсән улы Хәсәновның фәнни эшчәнлегендә түбәндәге юнәлешләрне аерып күрсәтергә мөмкин.

Иң борынгы дәверләрдән алып безнең чорларгача булган татар әдәбияты тарихын (Кол Гали, Мөхәммәтьяр, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, К. Тинчурин һ. б. лар иҗатын) өйрәнү.

Татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның әдәби мирасын фәнни өйрәнү буенча М. Х. Хәсәнов бигрәк тә тырышып һәм нәтиҗәле шөгыльләнде. Билгеле булганча, бу әдипнең исеме һәм әдәби мирасы 1937-1955 елларда тыелган иде. М. Х. Хәсәнов аның исемен халыкка кайтару һәм Г. Ибраһимовның иҗатына, фәнни хезмәтләренә, сәяси эшчәнлегенә объектив бәя булдыру юнәлешендә гаять күп хезмәт куйды. М. Хәсәновның бу әдипкә багышланган монографияләре, күп санлы мәкаләләре, фәнни хезмәтләре бар. 1971 елда СССР Фәннәр Академиясенең Көнчыгышны өйрәнү Институтында уңышлы якланган докторлык диссертациясе дә Г. Ибраһимов иҗатының Октябрь революциясеннән соңгы дәвердәге эволюциясенә багышланган. Бераздан Мәскәүнең "Фән" нәшриятында, ә аннары Казанда күп мәртәбәләр басылган бу китап Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнгән иң тирән, тулы хезмәт булып тора һәм ул милли әдәбиятларны, Россиядәге милли-азатлык хәрәкәте һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүче студентларга ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. М. Х. Хәсәнов шулай ук Г. Ибраһимовның 8 томлык әсәрләр тупланмасын (1974-1987 еллар) әзерләү һәм бастыру эшенең башлап йөрүчесе һәм турыдан-туры җитәкчесе булды.

М. Х. Хәсәнов татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә һәм пропагандалауга зур өлеш кертте, 1976, 1986 елларда шагыйрьнең 90 һәм 100 еллык юбилейларын үткәрү буенча хөкүмәт комиссиясен җитәкләде.

Галимнең Кол Гали, Ф. Әмирхан, Г. Камал, К. Тинчурин иҗатларына багышланган махсус хезмәтләре бар. 1984-89 елларда ул, автор һәм редколлегия әгъзасы буларак, алты томнан торган татар әдәбияты тарихын булдыруга зур көч куйды.



*Мансур Хәсәнов һәм Марсель Сәлимҗанов. 70 еллар.*

М. Х. Хәсәнов милли мәктәпләр өчен укыту программалары төзүдә актив катнаша, ул—урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслеге авторларыннан берсе.

М. Х. Хәсәнов әдәбият белеменең методологик проблемаларын эшкәртү, иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихын, милли мәгариф һәм педагогика тарихын өйрәнү белән актив шөгыльләнә. Әлеге темаларга багышланган фәнни конференцияләрдә ул саллы фәнни докладлар белән чыгышлар ясый һәм матбугатта мәкаләләр бастыра. М.Х. Хәсәновның милли мәдәният корифейлары С. Сәйдәшев, Р. Яхин, Б. Урманче, Х. Әбҗәлилов һ. б. лар тормышына, иҗатына багышланган фәнни мәкаләләре, докладлары бар. Ул шулай ук татар халкының милли азатлык көрәше күренекле эшлекләре М. Вахитов, М. Солтангалиев исемнәрен мәңгеләштерү, аларның тормышларын һәм эшчәнлекләрен пропагандалау буенча да күп көч куйды.

Үтеп киткән XX гасырның сиксәненче елларында бездә милли яңарыш проблемаларын өйрәнү хәрәкәте көчәеп китте. XIX-XX гасыр чигендә яшәп иҗат иткән Ш. Мәрҗани, С. Максуди, Г. Исхакый, Р. Фәхретдинов, М. Бигиев һ. б.лар турында фәнни җыентыкларда, газета-журналларда Мансур Хәсәновның байтак мәкаләләре дөнья күрде. Хәзер автор әлеге темага багышланган күләмле монографиясен тәгаллләп кылә һәм ел ахырына кадәр бастырып чыгарырга җыена.

Татар милләтенең язмышында Казан шәһәре һәм аның тарихы әһәмиятле урын тота. Әгәр дә безнең галимнәребез соңгы елларда Казан тарихын өйрәнүдә яңа методологик принциплар эшләгәннәр һәм аны уңышлы куллана башлаганнар икән— бирегә М. Х. Хәсәновның роле гаять зур. Татарстан Фәннәр Академиясенең тарих

институты, Казан, Мәскәү, С. Петербург һәм чит илләрдәге 20 ләп фәнни үзәк галимнәре белән берлектә, Казан шәһәре администрациясе ярдәмендә Казан шәһәренен нигезләнү вакытын ачыклауга багышланган, яна археологик тикшеренүләр, тарихи чыганаклар кин кулланылган 5 халыкара конференция уздырылды. Бу фәнни форумнарның житди карарлары нигезендә Россия Президентының 2005 елда Казан шәһәренә 1000 ел тулуны билгеләп үтү турындагы Указы кабул ителде.

М. Х. Хәсәнов эшчәнлегенә бәйле тагын шундый мөһим якны билгеләп үтәргә кирәк: үзебезнен республикада Фәннәр Академиясе төзелү нәтиҗәсендә соңгы елларда фәнни ачышларны тормышка ашыру—житештерү өлкәсендә куллана башлау процессы нык жанланды. Академия Президенты буларак М. Х. Хәсәнов аны даими рәвештә игътибар үзәгендә тотты.



*М. Вәлиев, Г. Ахунов, М. Хәсәнов, С. Хәким, Р. Миңнуллин, Г. Бәширов, Н. Арслан.*

Татарстан хөкүмәтендә озак еллар эшләү дәверендә М. Х. Хәсәнов республиканың күренекле шәхесләре юбилейларын югары дәрәҗәдә үткәрү өчен гаять күп көч куйды. Казанда, Мәскәүдә уздырылган әлеге тантаналы кичәләрнең күбесендә ул истә кала торган һәм тирән эчтәлекле докладлар белән чыгышлар ясады.

Классикларыбызның бай мирасын дөньяга чыгару өлкәсендә дә М. Х. Хәсәнов даими эш алып бара. Ф. Әмирханның 4-томлыгы аның житәкчелегендә әзерләнде һәм дөнья күрде, Г. Исхакыйның 15-томлыгы басылып ята.

М. Х. Хәсәновның Казанда һәм Мәскәүдә басылган 5 монографиясе, Казан, Мәскәү, АКШ, Лондон, Әнкара басмаларында дөнья күргән күп санлы фәнни мәкаләләре бар.

Аның житәкчелегендә 5—докторлык, 10 кандидатлык диссертациясе яклаңган. Хәзерге вакытта аның шәкертләреннән тагын 9 яшь галим докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якларга жыена.

Югары дәрәҗәдәге дәүләт һәм фән эшлеклесе булу белән бергә М. Х. Хәсәнов республиканың һәм Россия Федерациясенең ижтимагый-сәяси тормышында да актив катнашты. Ул 27 ел буена Татарстан Югары Советы депутаты булды, озак еллар буена Югары Советның мәгариф, фән һәм мәдәният комиссиясен житәкләде.

М. Х. Хәсәнов 1971 елдан 1992 елга кадәр әдәбият-сәнгать өлкәсендә Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре Комитетын житәкләде, ә 1993 елдан башлап республика Президенты каршындагы фән һәм техника буенча дәүләт премияләре Комиссиясен житәкли.

М. Х. Хәсәновның дәүләт эшендәге ижтимагый-сәяси, фәнни тармаклардагы озак һәм нәтижәле эшчәнлеге күп санлы дәүләт бүләкләре:

IV дәрәҗә "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" ордены (2000 ел), ике Хезмәт Кызыл Байрагы Ордены (1966, 1986 еллар), Халыклар дуслыгы ордены (1980 ел), "Мактау билгесе" ордены (1971 ел) һ. б. белән билгеләп үтелде.

Редакциядән:

**Журналыбызның могтәбәр авторы булган юбилярны олы бәйрәме белән кайнар котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, ижади уңышлар, озын гомер телибез!**

# ИШМИ ИШАН КАПКАСЫ

Үзенең эшчәнлеге белән халкыбыз тарихында билгеле бер эз калдырган тарихи шәхесләр бихисап. Атаклы Түнтәр мәдрәсәсендә 43 ел дәверендә рәис булып торган Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов тә шундыйларның берсе. Әмма аның тормышы һәм эшчәнлеге бүгенгәчә тиешенчә өйрәнелмәгән, "ак тап" булып кала бирә. Булган мәгълүматлар да аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген гаять берьяклы, гадәттә тискәре итеп кенә күрсәтәләр. Алардан чыгып фикер йөрткәндә, әлеге шәхес безнең күз алдыбызда карагруһ консерватор, дини фанатик, һәртөрле прогрессив үзгәрешләргә һәм янарышка каршы торучы һәм патша жандармериясенең яшерен агенты булып кына килеп баса. Без кичергән катлаулы совет чоры башкача уйларга мөмкинлек калдырмый иде шул—син "кызыл", йә "ак", башкача була алмыйсың. Хәтта әле 1999 елда гына дөнья күргән "Татар энциклопедик сүзлеге" дә (рус телендә) И. Динмөхәммәтовның эшчәнлеген менә шулай бәяли: "...писал доносы в царскую охранку, последствием которых стали аресты прогрессивных татарских деятелей и закрытие некоторых новометодных медресе ("Буби" и др.)... Автор книг по мусульманскому богословию". Мәкаләнең башына Г. Тукайның балачагыбыздан таныш шигъри юл чәпәп куелган:

Ишми ишан капкасы,
Нарат кына тактасы;
Нарат булмый нәрсә булсын,
Бары да донос акчасы.

Гавамның бу шәхескә тискәре карашы Тукайның әлеге шигырь юллары белән генә дә чикләнми, әлбәттә. Аның турында Ф. Әмирхан, Ш. Мәржани һәм башка күренекле кешеләребез дә аңа карата үзләренең тискәре фикерләрен белдереп калдырганнар. Ә, югыйсә, тарихка һәм әдәбиятка "Ишми ишан" исеме белән кереп калган Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов киң колачлы, тирән белемле шәхес булган. Ул гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән, үзенең мәкаләләрен һәм китапларын, нигездә, гарәп телендә язган. Ул Коръәнне, хәдисләрне һәм фикхны тирәнтен өйрәнгән, зур дин белгече булган. Ул—оста һәм абруйлы имам, тәҗрибәле педагог. Ул ялкынлы публицист, бәхәсче-полемист, фикер иясе—философ. Боларның барысы өстенә ул әле үз иманына тугрылыклы һәм аны эзлекле яклаучы һәм пропагандалаучы идеолог та. Хәзрәт үзенең оппонентларының фикерен тирәнтен өйрәнгән, ул чорда Рәсәйнең ислам дөньясы өчен куркыныч көчкә әверелгән христиан миссионерларының (Н. Ильминский, Л. Канашевич, С. Головатский) хезмәтләре һәм эшчәнлеге белән якыннан таныш булган. Ул үзенең фикерләрен ачык итеп, ышандырырлык аргументларга нигезләп, кискен итеп шул чорның матбугат чаралары аша җәмгыятькә җиткерә белгән.

Ишмөхәммәт хәзрәт XIX гасыр ахырында—XX гасыр башында кайнап торган, эзләнгән, буталган татар дөньясы тормышында актив катнашкан, җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында барган рәхимсез көрәшнең үзәгендә булган. Шушыны әйтү генә дә аның үз халкының язмышына, аның киләчәгенә битараф булмаган, үз кыйбласыннан бер вакытта да тайпылмаган аек фикерле шәхес булганлыгын икърар итәргә этәрә. Казан арты төбәгендә аның турында берсеннән-берсе кызыклы

риваять-сүзләр йөрүе дә юкка гына түгел. Аны "олы ишан", "дан мулла", "дәү мулла" дип атаганнар, имеш, ул Дәүләт Думасы депутаты булган дип әле дә сөйлиләр (билгеле, ул депутат та, ишан да булмаган). Түнтәр авылында яна мәчет төзелгәч, авыл халкы бертавыштан ана шәех Ишмөхәммәт Хәзрәт Түнтәри исемен бирде. Шулай икән, бу шәхеснең тормышы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге ныклап өйрәнүгә, ачыклауга лаек, аның шәхесе тирәсендәге тиешсез ябышкак имеш-мимешләр алып ташланырга тиеш. Ислам диненә, аның изге асылына каршы ачыктан-ачык һәм оятсыз рәвештә алып барыла торган һөҗүм вакытында бу бигрәк тә кирәк.

Бу урында "Мәйдан" журналының 2003 елның 8 санында бирелгән шагыйрь Разил Вәлиев белән әңгәмәсендә олы галимебез академик Миркасыйм ага Госмановның бер фикерен китерү урынлы булыр дип саныйм: "Тарихи вакыйгалар чыганакларда, галәттә, бер яктан гына яктыртылган була. Чөнки кешеләр дә булып узган вакыйгаларны, фактларны бер ягыннан гына күрәләр. Шуна күрә, тарих дөресрәк яктыртылсын өчен, ул төрле яктан, төрле кешеләр тарафыннан өйрәнелергә тиеш. Бары аннан соң гына гаделрәк нәтиҗә чыгарылырга мөмкин".

Ишмөхәммәт Казан губернасының Мамадыш өязе Югары Сөн авылында авыр тормышлы гаиләдә туган. Туган елы да, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге кебек үк, төгәл тәгаенләнмәгән—берәүләр 1843 елны, икенчеләре исә 1849 елны атыйлар. Малай бераз үсеп, кул астына керә башлау белән әтисе Нәкыйп аны татар дөньясында мәшһүр исеме булган Түнтәр мәдрәсәсенә китерә. Мәдрәсәгә бу чорда Бохарада һәм башка ислам үзәкләрендәге мәшһүр мәдрәсәләрдә укып төпле-нигезле белем алган, күп еллар дәвамында Бохара, Кабул, Кандаһар, Лахор кебек ислам мәркәзләрендә яшәгән һәм эшләгән киң карашлы, инде зур галим һәм мәгърифәтче булып танылган Гали ишан җитәкчелек итә. Сүз уңаеннан әйтеп китик, әлеге "Татар энциклопедик сүзлеге"ндә мин аның исемен тапмадым, кызганыч. Гали ишан белән якын элемтәдә булган Шиһабетдин Мәрҗани аны "мәшһүр имам һәм башкаларга үрнәк укытучы" дип югары бәяли.

Гали ишанның белем һәм тәҗрибә эстәп дөнья гизгәннән соң нәкъ менә Түнтәр мәдрәсәсенә кайтуы очраклы хәл түгел. Бүгенге көнгә ике йөз елдан артык тарихы булган бу уку йорты татар дөньясында киң танылган данлы мәдрәсәләрнең берсе булган. Ул чорның күп зыялылары балаларын шушы мәдрәсәдә укытуны өстен күргән. Монда ерак Оренбург, Уфа, Омск, Төмән якларыннан килеп укучы яшьләр күп булган.

Гали ишан мәдрәсәгә 1829—1874 еллар дәвамында 45 ел җитәкчелек итә. Ишмөхәммәт менә шундый олпат шәхеснең шәкерте була. Мәдрәсәне тәмамлагач, остазы аны шушында укытучы-мөгаллим итеп калдыра. Димәк, ул үзенең шәкертендә киң фикерле шәхес буларак үз күнеленә хуш килерлек сыйфатлар күргән. Һәм шәкерт остазының ышанычын аклый, хәтта ул Гали ишаннан соң мәдрәсәнең җитәкчесе булып кала. Һәм 43 ел буе җитәкчелек итә. Шушы ике олпат шәхес җитәкчелек иткән 90 елга якын дәвердә укыту-тәрбия эшендә гасырлар буена ныгып килгән ислам традицияләрендәге дини кануннарга зур әһәмият бирелә.

Казан артының күп авылларында И. Динмөхәммәтов мөдәррислек иткән Түнтәр мәдрәсәсендә укып чыккан муллалар имамлык итә. Алар дин нигезләрен тирән белүләре, ислам әхлагына тугрылыклары, иманлы булулары белән халык ихтирамын казаналар. Минем туган авылым Мөнингәргә, бертуган Бубыйлар өстеннән булган процесс белән бәйләп имамлыктан Әхмәтгәрәй Зарифов ахун читләштерелгәч, Түнтәр мәдрәсәсеннән Ишмөхәммәт хәзрәтнең иң яраткан шәкертләреннән берсе яшь-яшь Мотыйгулла Зыятдинов имам булып килә. Ул 1967 елда үзенең үлеменә кадәр авылның имамы булып тора. Динебез өчен иң караңгы елларда да, нинди генә җәфалаулар, эзәрлекләүләр булуга карамастан имамлыгын ташламый, үз иманына турылыклы булып кала, барлык җәбер-золымнарны лаеклы рәвештә кичерә. Хәзрәт авылның иң хөрмәтле кешесе була. Аны юк ителүдән дә әнә шул халыкның яклавы, хөрмәте саклап кала.

Әле китерелгән мәгълүматлар үзләре генә дә Ишмөхәммәт хәзрәтнең шәхесенә югары бәя бирергә, мөгаллим-мөдәррис буларак аның талантын танырга җитәрлек нигез түгелмени?

Түнтәр мәдрәсәсе 1918 елның көзендә ябыла. Төрле елларда аның бинаалары мәктәп, аның интернаты, мондагы күмәк хуҗалыкнын ашханәсе, склад итеп һәм башка максатларда файдаланыла, кадерсезләнә. Шулай итеп, татар халкының иманын чарлауга бәя биреп бетергесез өлеш керткән Түнтәр мәдрәсәсе яшәүдән туктый. 1999 елда бу мәдрәсәнең 200 еллыгы халкыбызның күп зыялылары катнашында, район хакимияте химаялегендә зур итеп билгеләп үтелде. Бүгенге көндә мәдрәсә биналарының берсендә бу шанлы авылның тарих музее оешып ята. Авыл халкы укытучы, изге җанлы шәхес Рәфхәт Зарипов житәкчелегендә гаять күп мәгълүмат һәм экспонатлар туплады. Музейда Түнтәр мәдрәсәсе, Гали ишан, Мөхәммәтнәҗиб Түнтәри, Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов һәм башка шәхесләр турында да киң мәгълүмат алырга мөмкин.

Мәдрәсә ябылу белән аның мөдәррисе Ишмөхәммәт хәзрәт тә кулга алына һәм өяз үзәге Малмыжга китерелә. Ул яшерен суд белән (бәлки анысы да булмагандыр!) үлем җәзасына хөкем ителә. Хөкем карары 1919 елның 8 маенда җиренә житкерелә—70 яшьлек Ишмөхәммәт хәзрәт үндүрт мөселман һәм бер носари рухание белән бергә атып үтерелә. Шунысы игътибарга лаек, Мәскәүдәге ФСБ архивында да, Киров өлкә дәүләт архивында да, Малмыжда да Ишмөхәммәт хәзрәтнең хөкеме һәм җәзалануы хакында мәгълүматлар табылмаган. Үз эшләрен эшли белгән кызыл җәлладлар!

Югарыда Ишми хәзрәт турында халык арасында күпсанлы риваятьләр йөрүе турында әйткән идек инде. Шундыйларның берсендә атып үтерелгән хәзрәтнең җәсаден Себер юлы буенда Малмыжтан ерак түгел урнашкан Борнак авылы кешеләренең төнлә яшереп алып кайтып, Борнак авылы зиратына җирләүләре турында сөйләнә. Бәлки чыннан да шулай булгандыр. Ничек кенә булмасын, бу риваять халыкның шушы олы шәхескә нинди олы хөрмәт белән караганын барыннан да тирәнрәк итеп раслый торган саллы дәлил. Халык үзенең изгесен хыялында булса да олылап, кадерләп, хөрмәтләп җирләгән!

Инде әйткәнемчә, Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовның тормышы катлаулы, каршылыклы, үзенчәлекле, аның эшчәнлегенә дә бәяне төрле яктан бирергә нигез бар. Калимчеләр һәм җәдитчеләрнең ана биргән бәясе дә шуның өчен тамырдан капма-каршы. Кадимчеләр фикеренчә, ул "хакыйкый исламның яклаучысы, Рәсәйдәге ислам дөньясында ул олы ихтирамга лаек", аны "Дин вә мәгыйшәт" журналының нәшере Мөхәммәтвәли Хөсәенов белән бер дәрәҗәгә куялар, "мөселманлыкның терәге" дип атыйлар. Җәдитчеләр исә аны "урыс хакимияте ярдәмендә прогрессив алымнарга каршы көрәшүче" дип гаеплиләр, "Дин вә мәгыйшәт" журналы хезмәткәрләренең барысын да "Ишми әләкчеләре" дип атыйлар, хәзрәтнең үзенә "ишәк", "фанатик", "самодержавие агенты" дигән ямьсез ярлыклар тагалар, кимсетәләр (куштырнак эченә алынган өземтәләр "Хезмәт" газетасының 1998 елгы 20-22 саннарыннан алынды).

Октябрь инкыйлабыннан соңгы елларда меңнәрләгән динчеләребез юк ителә, төрмәләрдә газаплана, сөргеннәргә сөрелә. Алар арасында җәдитчеләр дә, кадимчеләр дә, яңалык тарафдарлары да, аның дошманнары да бергә була. Аерма шунда гына—Ишмөхәммәт хәзрәт корбаннарның ин беренчеләреннән. Ә бит моны "яңалыкка омтылу" дулкынында хакимияткә килгән җәлладләр эшли. Күренә ки, уйланырга сәбәпләр житәрлек монда. Җәмгыятебездәге бүгенге халәт, бүгенге сәясәт тә ул елларда барган фикер көрәшенә, аның актив тарафдарларына, аларның кыйблаларына аеграк карарга этәрмимени?! Җәмгыятебезнең имансыз калуының сәбәпләрен дә әнә шул чордагы фикер көрәшеннән эзләргә кирәк түгелме?

Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов тирән белемле дин галиме. Аның ислам дине мәсьәләләренә багышланган дистәләгән китаплары, брошюролары нәшер ителгән. Билгеле, алар Октябрь инкыйлабына кадәр басылган. Нигездә, алар гарәп телендә язылган. Алар инде югалып беткән, саклангannары да киң катлау укучыларга ирешмәгән. Аларны барлау, туплау, тәрҗемә итү һәм бастыру бик тә зарур. Бу җәһәттән республикабыз хөкүмәтенең танылган динчеләребезнең хезмәтләрен аерым серия белән чыгару турындагы карары хуплауга лаек һәм тизләтүне таләп итә.

Аның фикерләү даирәсе киң, активлыгы гаять югары. Шул заман татар дөньясына

караган бер генә мәсьәлә дә аның игътибарыннан читтә калмый: уку-укыту, яшьләр тормышы, хатын-кыз һәм аның җәмгыять тормышындагы урыны, медицина-дәвалау, театр-сәнгать, җәмгыять күренешләре, шәхес һәм җәмгыять. Еш кына аның фикерләре кискен, усал, хәтта тупас. Ул фикерләрен дәлилле белә. Ул—кыю, ачык. Әлеге фикерне ул барыннан да алда, беренчеләрдән булып әйтә. Ул битараф кеше түгел. Шуна да еш кына таяк, аның юан башы анарга төшә. Әнә шул кискен килешмәүчәнлеге аның җәдитчеләр тарафыннан төп дошман итеп кабул ителүенә китерә дә инде.

1909—1918 елларда Ишмөхәммәт хәзрәт "Дин вә мәгыйшәт" журналы белән актив хезмәттәшлек итә, аның актив авторы була. Мин аның шушы чорда басылган җиде дистәдән артык мәкаләсе белән таныштым. Мәкаләләрдә хәзрәтнең үз заманының фикер иясе, бәхәсче-полемист, пропагандист булуы ярылып ята. Мәкаләләрендә ул киңәш итә, сорауларга җаваплар бирә, ислам нигезләрен аңлата, аларга карата үз фикерләрен белдерә, уйлана, бәхәсләшә, кемнәрнедер яклый, кемнәрнедер гаепли, тәнкыйтьли... "Ураза һәм ифтар бабында шәригать үлчәве" *(1910 ел, 8 сан)*, "Туганнар соравына ярдәм итәргә омтылу". *(1910 ел, 10, 11 саннар)*, "Борынгы хәдисләрдә осталыкның үлчәве" *(1910 ел, 15 сан)*, "Дәлилләү беренче эш" *(1914 ел, 19 сан)*, "Миграж" *(1914 ел, 23 сан)*, "Сөннәт әһелләре һәм җәмәгать ике дөньяда да шәһадәтчеләр" *(1914 ел, 26, 27 саннар)*, "Коръәнне рухи мәгънәләре буенча бүлү" *(1914 ел, 36 сан)*, "Пәйгамбәрләрнең солтанына чын күңеле белән ышанучыларны Аллаһы Тәгалә ярата" *(1916 ел, 11 сан)* кебек күп санлы мәкаләләрендә динебезнең четерекле мәсьәләләре аңлатыла, әхлак мәсьәләләренең киң спектры күтәрелә. Нинди генә чыгышын алма, аның кыйбласы бер—изге динебезнең пакьлеген саклау, ислам әхлагының өстенлеген раслау.

Инде әйтелгәнчә, Ишмөхәммәт хәзрәтнең "Дин вә мәгыйшәт" кебек "искелек терәге" булган журналга язышуын да гаеплиләр. Әмма шушы ук журналда, кайчагында аның белән бер үк санда, шул ук Түнтәрдән бик тә алдынгы карашлы саналган җәдитче Мөхәммәтнәҗиб Түнтәри язмаларына да юлыгасың. Башка җәдитчеләрнекенә дә...

И. Динмөхәммәтовның җәдитчеләр белән принципиаль каршылыгы иң элек аның балаларны укытудагы яңа, бәхәссез бик тә кирәкле һәм вакытлы яңа методларга мөнәсәбәтендә чагыла. Үзенең күп мәкаләләрендә ул ачыктан-ачык яңа укыту алымнарын күтәргән җәдитчеләрне ачы тәнкыйтьли. Мәсәлән, "Икамәт әл-борһан" ("Дәлилләр китерү") исемле брошюрасында ул болай дип яза: "Яңа методчылар шайтан партиясендә торалар". Ул "аваз методы ахыр чиктә исламның бетүенә китерәчәк" дип кисәтә, яңа методның авторларын Коръәнне танымаучылар, күп Аллаларга табынучылар дип гаепли. Динмөхәммәтовның бу фикерләренә егерменче гасыр башында Санкт-Петербургта нәшер ителгән "Мир ислама" журналы да игътибар итә *("Мир ислама", 1912 ел, 7 сан)*. Әмма хәзрәтнең бу мәсьәләгә багышланган язмаларының киң спектры белән танышкач шуны аңлыйсың—аны яңа методларның тормышка ашуыннан битәр шулар нәтиҗәсендә дин нигезләрен укытуга игътибарның кимүе, аларны өйрәнүгә битарафлык, сүлпәнлек туу мөмкинлеге куркыта һәм борчый. Белгәнебезчә, бу борчылу һич тә урынсыз булмый. Сүз уңаеннан искәртеп китик, Түнтәрнең үзендә үк, хәзрәтнең янәшәсендә яңа ысул белән укыткан мәдрәсә эшләп ята, соңгы чорда аның үзенең ике улы да шушы мәдрәсәдә укый!

Ишмөхәммәт хәзрәт яңа уку методларын тәнкыйтьләүдән алга китеп носарый диненә карата да үз фикерен белдерә: "Христиан дине үзгәрүчән, ул әзлекле түгел, ә ислам дине бервакытта да үзгәрми". Хәзрәт кяфергә охшарга тырышуны, аларча киенүне кире кага: "Кем кяфернең баш киемен, бигрәк тә картуз кия—ул мөртәт, дин юлыннан чыккан кеше". Бу сүзләре белән ул европачылыкның ахыр чиктә соң дәрәҗәдәге бозыклыкка китерәчәген кисәтә *(өземтәләр Татарстан Үзәк Дәүләт архивының 199 фонды, 1 тасв., 786 эш, 82-84 битләрдән алынды)*.

Шуннан ук алынган түбәндәге өзек гыйбрәтле: "Әгәр дә кяфер дип белеп аның киемендәге кеше ялгыш үтерелсә, үтерүчегә бернинди дә җәза бирелергә тиеш түгел, чөнки аларны *(кяфер киемен киеп йөрүчеләрне—Р. М.)* үтерергә ярый". Әле генә

халкын, аның иман сафлыгын кайгыртып вакытлы һәм бик урынлы кисәтүләр язган хәзрәтне монда инде без чын мәгънәсендә сукыр фанатик итеп күрәбез. Ни кызганыч, анысы да хас булган шул бу шәхескә.

Ике караш, ике агым арасындагы фикер каршылыклары еш кына чын физик бәрелешләргә дә китергән. Шул чор газета-журналларында, архив тупланмаларында андый мисаллар аз түгел. Мәсәлән, 1908 елда Түнтәрнең үзендә дә кадимчеләр белән җәдитчеләр арасында шундый бәрелеш килеп чыккан һәм анда җәдитчеләр, яңа метод тарафдарлары нык кына кыйналганнар *(Татарстан Үзәк Дәүләт архивының 199 фонды, 1 тасв., 785 эш, 11 бит)*.

Җәдитчеләр белән көрәштә хәзрәт иң каты чаралар кулланырга чакыра: "Без яңа методчыларга каршы дүрт юл белән көрәшергә тиеш:

а) аларны дошман итеп кабул итәргә;

б) алар белән ашамаска һәм эчмәскә;

в) аларның эшләренә һәртөрле комачау итәргә;

г) әлбәттә, безгә аларга өйләнергә ярамый".

Динмөхәммәтов шәхесенең каршылыклылыгы менә шушы мисалларда бөтен тирәнлеге белән ачыла да инде.

Сүз дә юк, җәдитчеләрнең И. Динмөхәммәтовны патша жандармериясе агенты дип гаепләве дә нигезсез булмаган. Татарстан Республикасы Үзәк дәүләт архивыннан табылган материаллар да моны раслый. Мамадыш өязе урядникгы П. Проковьевка, Вятка губерниясе жандарм идарәсе ротмистры В. Будогосскийга язган хәбәрләрендә ул Идел буе "панисламистлары" эшчәнлеге хакында мәгълүмат бирә. Ул күп кенә танылган Казан муллаларын һәм башка җәмәгать эшлеклеләрен панисламизм хәрәкәтенең җитәкчеләре, башлыклары дип атый. Андыйлар исемлегенә хәзрәт Рәшит Ибраһимовны, Садрый Максудыйны, аның абыйсы Һади Максудыйны, Галимҗан Барудины, Габдулла Апанаевны, Йосыф Акчураны, Галимәрдән Топчыбашевны, Сөләйман Аитовны, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйларны кертә. Шулай ук Ишмөхәммәт хәзрәт шушы кешеләрнең җирле йомышчылары-үтәүчеләре исемендә тагын 50 кешене атап китә. Алар арасында Түнтәр авылының кайбер муллалары да бар. Исемлектән Мамадыш, Лаеш, Цивильск, Царевококшайск, Чистай, Казан, Спас, Алабуга, башка бик күп өязләрнең динчеләре дә төшеп калмаган. Ишмөхәммәт хәзрәт фикеренчә, аларның гаебе шунда, "...барлык бу муллалар балаларны нindидер яңа ысул белән укыталар, яшьләр арасында "урыс патшасы" хакимлегеннән чыгарга һәм төрек составына кушылырга дигән коткы тараталар". Күрәсез, монда инде хәзрәт дин сафлыгы өчен генә сызланып калмый, үзенең сәяси гаепләүче роленә кереп киткәнен абайламый да кала.

Бертуган Бубыйларны гаепләү процессында да Ишмөхәммәт хәзрәтнең һәм аның тарафдарларының кулы уйнаганы билгеле. 1911 елда атаклы яңа методлы уку йорты булган Иж-Бубый мәдрәсәсенең ябылуы да алар "ярдәме" белән башкарыла. Дөрес, төп скрипканы монда Иж-Бубый мәдрәсәсенең үзендә, бертуган Бубыйларның үз кул астында оялаган аларның шәхси дошманнары уйный. Иж-Бубый мәдрәсәсе мәгърифәтчеләрен И. Динмөхәммәтов: "Коръәндә әйтелгән—кем Коръән һәм шәригатькә каршы бара, ул хакимияткә каршы бара. Коръәнгә каршы чыгучы укытучылар да хакимияткә каршы баручылар",—дип гаепли.

Бертуган Бубыйлар процессына бәйләп башка төбәкләрдәге күп кенә прогрессив дин эшлеклеләре дә эзәрлекләнә. Минем туган авылым Мөнингәр мәчетенең имамы ахун Әхмәтгәрәй Зарифов та берничә ай Сарапул төрмәсендә утыра, аның указы алына һәм ул имамлыктан читләштерелә. Югыйсә, ул тирән белемле, алдынгы карашлы, халыкның ихтирамын казанган имам була. Юкка гына авыл халкы аны әле дә, йөз елга якын вакыт узуга карамастан, изге итеп искә алмас иде.

Күренә ки, халкыбызның зыялылары арасындагы төрле фикер каршылыклары патша хөкүмәтенә рус булмаган халыкларны буйсындыруда, аларның сәяси аңы үсешен тоткарлауда зур табыш булган, зур осталык белән файдаланылган.

Шуна да И. Динмөхәммәтовның бу эшчәнлеге Вятка губерния жандарм идарәсе тарафыннан бик унай бәяләнә, хәзрәт бу идарәнең ышанычлысы санала.

"И. Динмөхәммәтов дини фанатик булса да, аның фанатизмы татар һәм рус халыкларының бергә яшәвенә зыян китермәде һәм татарлар Рәсәйдә һәрвакыт хакимияткә карата тугрылыклары белән бүтән халыклардан аерылып тордылар",— дип раслый полиция департаменты *(Татарстан Үзәк Дәүләт архивы, 199 фонд, 1 тасв., 795 эш, 83-84, 92-93 битләр).* Шулай шул, бәлки шуна да кадере юктыр татарнын Рәсәйдә!

Җәдитчеләр, киресенчә, "Ишми ишан"ның жандармерия белән эшләгәненә капма-каршы бәя бирә. "И. Динмөхәммәтовнын шушындый "эшчәнлеге" аркасында халыкта таркалу, бер-берсенә карата ышаныч кимү, бер-берсенә дошман булу арта" дип билгелиләр. Исемнәре күрсәтелмәгән бер төркем динчеләрнең Ырынбур мөселманнарының диния нәзарәтенә язган мөрәҗәгатендә исә менә мондый юллар бар: "Үзенең һөнәре буенча ул халыкка тынычлык һәм яктылык китерергә тиеш, ә хәзрәт, киресенчә, ана коткы һәм караңгылык тарата. Кешеләргә хакыйкать сөйләү урынына, ул аларны боза" *(Оренбург өлкә дәүләт архивы, 21 фонд, 2 тасв., 618 эш, 11 бит).* Мөрәҗәгать итүчеләр Ишмөхәммәт хәзрәтнең эшчәнлеген тикшерергә чакыралар.

Ырынбур өлкәсе дәүләт архивында бер кызыклы документ саклана. Анда 1913 елда Киев шәһәрендә булып узган мөселман яшьләре җыелышы хакында сүз бара. Шушы җыелышта, башка күп актуаль мәсьәләләрдән тыш, кайбер ортодоксаль дин әһелләренә карата террор актлары оештыру турында да сүз кузгатыла. Һөҗүмгә дучар буласы кешеләр арасында Г. Баруди, Ф. Мөхетдинов кебек билгеле исемнәр бар. Вятка губернасының Малмыж өязеннән анда Ишмөхәммәт хәзрәт исеме дә кергән. Билгеле булганча, мондый актлар гамәлгә ашмый кала. Әмма бу мисал халкыбыз тарихының гаять гыйбрәтле шушы чорында идея һәм фикер каршылыкларының никадәр кискен, ситуациянең никадәр киеренке һәм фаҗигале булганлыгын аңларга ярдәм итә кебек.

Хакыйкать һәрвакыт каршылыкларда, бәхәсләрдә туа бит ул. Шушы бәхәс-каршылыкларның, эзләнүләрнең һәрдаим үзәгендә булган Ишмөхәммәт хәзрәт тә әнә шул хакыйкатькә бару юлларын табышкан, катлаулы һәм каршылыклы тормыш юлын үткән шәхес итеп бәяләнергә хаклы.

**Рөстәм МӨХӘММӘТШИН,**
*тарих фәннәре кандидаты.*

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# А

**АЛГА** (псевд., чын фамилиясе Бачков) Александр Егорович (14.11.1913, Сембер губ.-сы, Буа өязе Кошки-Новотимбаево а.—15.6.1977, Чабаксар ш.), шагыйрь, тәрҗемәче, әдәбият тәнкыйтьчесе, Чуаш АССР ның халык шагыйре (1970). Башлангыч белемне туган авылында—чуаш мәгърифәтчесе И.Я.Яковлев мәктәбендә ала. Яшьли ятим кала, 1922 елдан Казанда, ятимнәр йортында тәрбияләнә, 1938 дә Казанда Чуаш пед. техникумын тәмамлый, укытучы булып эшли. Соңрак Чабаксар ш.ендә Чуаш пед. ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945—50 дә "Ялав" ("Байрак") әдәби ж-лының баш мөхәррире булып эшли, 1960—67 елларда Чуаш АССРның Язучылар берлеге рәисе. 40 тан артык шигырьләр, поэмалар һәм повестьлар җыентыклары авторы. Беренче шигырьләре "Утам" ("Адым", 1931) альманахында урын ала. "Шывармань" ("Су тегермәне", 1935) легендасы беренче чуаш операсына нигез итеп алына. А. иҗатында Татарстанга һәм Чуашиягә аерым әсәрләр һәи шигырьләр, поэмалар цикллары багышлана ( "Идел белән Зөя арасында", "Ватанда", "Идел дулкыннары", "Сөйгән җирем", "Минем якташларым"). Чуаш теленә Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан шигырьләрен тәрҗемә итә. Кызыл Байрак, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, 1нче һәм 2нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы, "Мактау билгесе" орденнары б-н бүләкләнә. 1950—67 дә Чуаш АССР ның ЮС депутаты.

Әсәр.: Мои земляки. Чебоксары, 1959; На новой Волге. М., 1962; Солнечное утро. Чебоксары, 1973; Хамăръялсем. Шупашкар, 1983.

Әд.: Краткая литературная энциклопедия. М., 1962. Т.1; Чувашские писатели: Библиограф. справ. Чебоксары, 1964; БСЭ. 3 изд. М., 1970. Т.1.

*В.П.Станьял.*

**АЛЕШКОВ** Николай Петрович (26.6.1945, хәзер Яр Чаллы ш.енә кергән Орловка а.), шагыйрь. М. Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1982). "Знамя коммунизма" ("Коммунизм байрагы", Яр Чаллы ш.), "Гвардеец труда" ("Хезмәт гвардеецы", Оренбург өлкәсе Новотроицк ш.), "На боевом посту" ("Хәрби постта", Мәскәү) г-таларында эшли. 1972 елдан КамАЗ төзелешендә: матбугат үзәге җитәкчесе, "Камэнергострой" Җитештерү берләшмәсенең йортлар төзү комб-тында инженер-диспетчер. 1976—86 да Кама төбәгендәге яшь язучыларны туплаган "Орфей" әдәби оешмасын җитәкли. 1989 елдан янә журналист хезмәтендә "Время" ("Вакыт"), "Бизнес-класс" ж-лларында эшли. Беренче шигырьләре матбугат битләрендә 1970 еллар уртасында күренә башлый. "Бәхетле итеп исеңдә тот мине" ("Запомни меня счастливым", 1983) җыентыгына сугыштан соңгы балачак, Кама төбәгенең гүзәл табигате турындагы, "Орёл боҗрасы" ("Орловское кольцо", 1988) җыентыгына кече ватаны булган Яр Чаллы шәһәре төзелүе, сугыштан соңгы буынның язмышы, экология проблемалары хакындагы шигырьләре кергән; "Лимит" (1993) җыентыгында публицистик шигырьләре тупланган. "Ерак болыннар" ("Дальние луга", 1995) җыентыгы шагыйрьнең күп елларга сузылган әдәби эзләнүләре, классик рус поэзиясе традицияләренә мөрәҗәгать итүе нәтиҗәсе. Рус теленә Г.Тукай, Р.Вәлиев шигырьләрен тәрҗемә итә.

Әд.: Сафин М. Дней горизонт становится светлее // Аргамак. 1997. N 12; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*Б.А.Канеев.*

**АЛИШ** Абдулла ( Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) (15.9.1908, Казан губ., Спасс өязе Көек а.—25.8.1944, Германия), язучы. Казан җир төзелеше техникумын тәмамлаганнан соң (1930), мелиоратор булып ТАССРның Минзәлә кантонында, Казгрэс (ТЭЦ N1) төзелешендә эшли. Беренче әсәрләре 1929 да "Яшь ленинчы" г-тасы битләрендә басыла. 1934 тә "Техника" ж-лының җаваплы сәркатибе булып билгеләнә. 1937—41 дә "Пионер каләме" ж-лы редакциясендә, ТАССР радиокомитетында эшли, Казан пед. ин-тының кичке бүлегендә укый. Башлыча балалар

өчен яза. Беренче "Отряд флагы" җыентыгы 1931 дә чыга. "Якты күл буе" (1933) повесте, "Дулкыннар" (1934) исемле хикәяләр җыентыгы , "Илгиз белән икебез" (1940), "Минем абый" (1940) исемле шигырьләр җыентыклары А.ны балалар язучысы итеп таныталар. А.Әхмәт белән берлектә "Күршеләр" (1934), "Йолдыз" (1935) пьесаларын яза. А.ның "Капкорсак патша" (1934), "Чуар тавык" (1936), "Нечкәбил" (1937 ), "Сертотмас үрдәк" (1937), "Койрыклар" (1937) исемле әкиятләре зур популярлык казана. "Әкиятләр" (1937), "Ана әкиятләре" (1941) җыентыкларына кергән әкиятләре образлы тел б-н, татар фольклоры традицияләренә нигезләнеп язылган. Аларга шигъриятлелек һәм хикмәтлелек хас. Әкиятләр күп мәртәбә татар һәм рус телләрендә басылалар. 1941 нең июленнән А. фронтта. 12 октябрьдә Брянск ш. янында чолганышта калып, әсирлеккә эләгә. "Идел-Урал" легионы эчендә М.Җәлил җитәкчелегендә эш алып барган антифашистик оешманың актив әгъзасы була: антифашистик эчтәлекле листовкалар яза һәм аларны әсирләр арасында тарата; легионерларның тоткынлыктан качуын, аларның кораллы чыгышын оештыру эшләрендә катнаша. 1943 тә яшерен оешманың эше ачыла. А. башка җәлилчеләр б-н бергә 1944 нең 25 августында гильотинада җәзалап үтерелә. Аның әсирлектә язган шигырьләр блокноты, күп куллар аша үтеп, шулай ук әсирлектә булган Н.Терегулов кулына килеп эләгә. Ул шагыйрнең 15 шигырен күчереп ала. Алар, соңыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, "Три поэта-воина" (1979) җыентыгына керәләр. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә. 1996 елда ТР Язучылар берлеге балалар әдәбияты өлкәсендәге казанышлар өчен А. исемендәге премия булдыра.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1969; Болтливая утка. К., 1970.

Әд.: Краткая литературная энциклопедия. М., 1962. Т.2; Шакир С. Абдулла Алиш: Тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*Р.Ә.Мостафин.*

**АЛКАЕВ-ЧҮПРӘЛЕ** Вәлиулла (19 йөзнең 2 нче яртысы), дин эшлеклесе, шагыйрь. Тумышы б-н Сембер губ. Буа өязенең Түбән Чүпрәле авылыннан дип уйланыла. Туган авылы мәдрәсәсендә һәм Казанда Зәңгәр мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем ала. Аннан туган авылында имам булып тора, балалар укыта, әдәби иҗат б-н шөгыльләнә. Сатирик шигырьләр һәм мәдхияләр язган. Гали Рәхимдә сакланган зур кулъязма архивы утызынчы елларда юкка чыга. Иҗаты һәм тәрҗемәи хәле аз өйрәнелгән. Гали Чокрыйның "Мәдхе Казан" (1889) исемле китабына кушымта итеп басылган 4 шигыре билгеле.

Әд.: Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985, Т. 2.

*М.В.Гайнетдинов.*

**АЛКАЕВА-ЧҮПРӘЛЕ** Мәхбүбә (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрә. Тумышы б-н Сембер губ. Түбән Чүпрәле авылыннан дип уйланыла. Вәлиулла Алкаев-Чүпрәленең туган сеңлесе. Шигырьләре халык арасында кулъязма нөсхәләрдә таралган, күбесе югалган. Үз заманында экспромт шигырьләр остасы булып танылган. Иҗаты да, тәрҗемәи хәле дә аз өйрәнелгән. Бер шигыренең фрагменты 1925 елда Г.Рәхим һәм Г.Гобәйдуллин тарафыннан матбугатта игълан ителә.

Әд.: Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925.

**АЛЛАҺИЯР СУФИ** (1616, кайбер чыганакларда—1630 тирәсе, Үзбәкстанның хәзерге Кәттәкурган шәһәре янында булган Минкаль дигән төбәк—1713, кайбер чыганакларда—1723, Искәндәрия ш., Мисыр), суфи шагыйрь. Төрки һәм фарсы телендә язган. Таҗетдин Ялчыголның "Рисаләи Газизә" (1795) китабында һәм К.Насыйриның шуңа таянып язган "Мәҗмугыль-әхбар" ("Хәбәрләр җыелмасы", 1859) әсәрендә бәян ителгән риваяти мәгълүматларга караганда, А.С.Бохара шәһәрендә яшәп иҗат иткән. Ата-бабаларының төп чыгышы Идел буеннан дип уйланыла. Олыгайган яшьтә А.С. хаҗ сәфәренә чыга, барышлый Идел буенда, Казанда, Болгарда була, кардәш-туганнары б-н күрешә. Әмма ул Мәккәгә барып җитә алмый, Искәндәрия шәһәрендә вафат була. Төп әсәрләре: "Сөбател-гаҗизин" ("Гаҗизләргә терәк", нәшере К., 1802), "Морадел-гарифин" ("Укымышлыларның максаты", нәшере М., 1858), "Мәсләкел-мөттәкыйн" ("Тәкъвалар юлы", нәшере К., 1899), "Мәхзәнел мотыйгыйн" ("Күндәмнәрнең хәзинәсе"). Нигездә суфичылык рухында, Алла гыйшкына мәдхияләр җырлау мак-

саты б-н язылган бу әсәрләрдә социаль мотивлар, шәхес иреге, рухи азатлык идеяләре дә яңгыраш таба. "Сөбател-гаҗизин" поэмасы исә, шигъри бизәкләре, эмоциональ тәэсирлелеге аркасында, 19 йөз татар поэзиясенә үрнәк булып хезмәт итә, 40 тан артык басмасы дөнья күрә. А.С.әсәрләре күп кенә татар язучыларының иҗатына сизелерлек йогынты ясый. Мәс., татар галиме һәм язучысы Таҗетдин Ялчыгол "Сөбател-гаҗизин" әсәренә шәрехләр язып, "Рисаләи Газизә" китабын иҗат итә. Шул исемдә ул мөстәкыйль әсәр буларак халык арасында киң таралыш таба. 19 йөз һәм 20 йөз башы аралыгында әсәрләрнең һәр икесе татар мәктәп һәм мәдрәсәләрендә төрки телдән ярдәмлек сыйфатында файдаланылган.

Әсәрләре: Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк). К., 2000.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 т.; Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). К., 1999.

*М.В.Гайнетдинев.*

**АЛМАЕВ** Мәхмүт Садретдин улы (24.8.1874, Сембер губ., Сызрань өязе, Сайман а.—27.8.1907, Оренбург ш.), шагыйрь, журналист, полиграфия белгече. Казанда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлый, Истанбул ун-тында укый, Германиядә полиграфия эшенә өйрәнеп кайта. Ана теленнән тыш, гарәп, төрек, рус, француз, немец телләрен яхшы белгән. Казанда бертуган Кәримевләр, 1905 елдан Оренбургта "Кәримев, Хөсәенев һәм К" ширкәте типографияләрендә техник җитәкче булып эшли. 1906—07 елларда Оренбургта сатирик "Чүкеч" ж-лы мөхәррире. "Урал" г-тасын чыгаруда Х.Ямашевка булышлык итә. Мәхмүт Фуад һ.б. тәхәллүсләр б-н чорның көлке ж-лларында, "Вакыт" г-тасында язышa. Татар шигъриятендә революцион поэзия юнәлешен башлап җибәрүчеләрдән берсе. ("Төрмәдән" шигыре 1907). "Агъладым", "Тиҗарга" ("Сәүдәгәргә"), "Аһларым", "Дума һәм хөкүмәт" һ.б. исемдәге шигырьләре мәгърифәтчелек, азатлык, гыйсъянчылык рухы белән сугарылган. Публицистик мәкаләләрендә дөньяви фәннәр укытыла торган татар мәктәпләрен ачу мәсьәләләрен күтәрә. "Сиксән сигез фикрә" ("Сиксән сигез хикәячек", 1902), "Талчукчылар китабы" (1908) исемле җыентыклар авторы. А. турындагы язма һәм басма материаллар ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивында саклана.

Әд.: Гыймадиев Ү. Сатира коралы белән. К., 1977; Мәхмүт Алмаев [Г.З.Рәмиев] // Мирас. 1998. N 4.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**АЛМАЗОВ** Җәвад Диндар улы (1916, Казан губ-сы, Чистай өязе Чиртуш а. — 23.3.1979, Ташкент ш.), тел галиме, текстолог, археограф. Смоленскта пед. ин-т тәмамлый (1939). 1934-42 елларда Ташкентта халык мәгарифе белгечләренең квалификациясен күтәрү ин-тында рус теле укыта. Бер үк вакытта Ташкенттагы Шәрекъ кульязмаларын өйрәнү ин-тында белем ала. 1943 тә Үзбәкстан ССРның халык мәгариф комиссариаты каршындагы методик бюро директоры, 1944-46 да Ташкент фин.-экон. техникумы директоры. Экстерн рәвешендә Ташкент юридик мәктәбен тәмамлый. 1947 дән алып Сәмарканд пед. ин-тында, 1948-53 тә Үзбәк ун-тында, 1953-55 тә Хорәзм пед. ин-тында, 1958-61 дә Казан ун-тында укыта. Төп хезмәте — Кол Галинең "Кыйсса-и Йосыф" поэмасын өйрәнү (поэманың 17 вариантын чагыштырып, аның критик текстын төзи һәм аны рус теленә тәрҗемә итә). 1960 елда Мәскәүдә 25 нче халыкара шәркыятче галимнәр конгрессында "Кыйсса-и Йосыф — болгар-татар ядкаре" ("Кысса-и Юсуф — булгаро-татарский памятник") дигән доклад белән чыгыш ясый. Бүгенге укучыга 20 йөз башы татар шагыйрәсе Г.Сәмитова иҗатын ача, аның шигъри җыентыгын басмага әзерли (1965). 1961 елдан Ташкентта яшәп эшләде.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Галим һәм шагыйрь Җәвад Алмаз // Мирас. 1996. N 12.

**АЛМАТАВИ** Лотфулла, к. *Өммәти-Алматави.*

**"АЛТЫ БАРМАК КИТАБЫ"**, төрек галиме Мөхәммәд ибне Мөхәммәд Чыкрыкчызадәнең (вафаты 1623) дини-дидактик әсәре. Китапның исеме авторның кушаматы (Алтын Бармак) б-н бәйле. Шул исем б-н әсәр киң таралыш алган, автор биргән исем ("Дәлаилел-нөбүвәт Мөхәммәди вә шәмаилел-фөтүвәт Әхмәди"— "Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә вә Әхмәднең затлы сыйфатларына дәлилләр") әкренләп онытылган. Китап фарсы галиме Мөхәммәд әл-Фәрәхинең (Муин-Мискиннең) "Мәгарижун-нөбуа" ("Пәйгамбәрлек баскычлары") исемле трактаты нигезендә язылган. Әсәр кереш өлеш, дүрт бабтан һәм хатимәдән (йомгаклау бүлеге)

тора. Кереш өлештә Аллаһыга, Мөхәммәд пәйгамбәргә традицион мактау сүзләре әйтелә, Коръәннән аятләр, хәдисләрдән өзекләр китерелә. Төп текстта пәйгамбәрләр тормышыннан вакыйгалар сөйләнә, сәхабәләрнең һәм авторга замандаш галимнәрнең Мөхәммәд пәйгамбәр турында, аның кылган гамәлләре хакында бәяләмәләре, уй-фикерләре санап кителә. Китап шулай ук тарихтан, педагогика һәм башка фән тармакларыннан да күп кенә мәгълүматларны үз эченә ала. 18—19 йөзләрдә "А.б.к."ның кульязма нөсхәләре Идел буе, Урал төбәкләрендә киң таралган була. Беренче типографик басмасы Казанда 1861 елда дөнья күрә, аннан соң да күп мәртәбәләр басыла.

*Әд.*: Катанов Н.Ф. Алты Бармак китабы (книга Шестипалого) // Деятель. 1899. N 10; Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. К., 1922; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 *т.*; Гәрәев Ф.М. "Алтын бармак" китабы // Гуманитарные науки: проблемы аспекты изучения. К., 1997.

*Ф.М.Гәрәев.*

**АМИДИ** (Гамиди) Шәриф (чын исеме Хәсән ибне Хөсәен ибне Мөхәммәд әл-Хөсәени әл-Хәнифи, ш.у. "Татар Али әфәнде" исеме б-н дә билгеле) (?—1523 б-н 1544 еллар арасы, Амид ш., хәзерге Диярбәкер ш., Төркия), төрки телле шагыйрь һәм тәрҗемәче, мәмлүкләр Мисырында дәүләт эшлеклесе. Солтан Кансух әл-Гаури вакытында (1501—17) диван сәркәтибе булып хезмәт итә. Солтан тәкъдиме б-н 1501—10 елларда Фирдәүсинең "Шаһнамә" поэмасын фарсыдан төрки телгә тәрҗемә итә ("Төрки Шаһнамә"). Тәрҗемәгә пролог һәм эпилог рәвешендә өстәп язган текстында 15—16 йөзләрдәге мәмлүкләр Мисырның идарәчеләре, илнең мәдәнияте, Каһирә шәһәренең топографиясе турында мәгълүматлар бирә. "Төрки Шаһнамә"нең кульязма нөсхәләре С.-Петербург, Душәмбе, Каһирә, Лондон, Вена шәһәрләре китапханәләрендә саклана. А. үгет-нәсыйхәт рухындагы тарихи язмаларны үз эченә алган "Нәфаис-сел-мәҗалис әс-солтанийә" ("Солтан киңәшләре энҗеләре") җыентыгы, газәл, мәдхия жанрларындагы аерым шигырьләр авторы буларак та билгеле. А. иҗаты төрки телле халыклар поэзиясенә, ш.и. татар поэзиясенә мәгълүм дәрәҗәдә йогынты ясаган.

*Әд.*: Исламов Р. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: Язма мирас, мәдәни бәйләнешләр. К., 1989; Zajaczkowski A. Turecka wersja Sah-name z Egiptu Mameluckiego // Prace Orientalistyczne. Warsz., 1965. T. 15; Bursali Mehmed Tahir bey. Osmanli Muellifleri. Ist., 1972. 2 cilt; Ozkirimli A. Turk edebiyati Ansiklopedisi. Ist., 1998. 4 cilt.

*Р.Ф.Исламов.*

**"АНА БЕЛӘН УГЫЛ ДАСТАНЫ"**, татар әдәбияты ядкәре. Бернична кульязма нөсхәсе буенча билгеле. Бер нөсхәсен 1920 нче елларда З.Ә.Максудова таба; соңрак М.Х.Бакиров тарафыннан өйрәнелә. Аның фикеренчә, дастан Болгар дәүләте дәверенә карый. Дастанның тагын кульязма өч нөсхәсен 1980 елларда М.И.Әхмәтҗанов Әлмәт һәм Лениногорский р-ннарыннан табып ала. Шулар нигезендә галим дастанның тәнкыйди җыелма текстын булдыра. М.И.Әхмәтҗанов ядкәрне 17—18 йөзләргә нисбәтли һәм туу урыны итеп Касыйм ханлыгын саный. Эчтәлеге б-н дастан ислам мифологиясенә нигезләнгән һәм үгет-нәсыйхәт характерында иҗат ителгән. Әсәрдә тәгълим-тәрбия һәм әхлакка кагылышлы төрле мәсьәләләргә җавап бирелә. Тел-стиль ягыннан дастан 17 йөзнең әдәби ядкәре "Дәфтәре Чыңгызнамә"не хәтерләтә. Дастанның кульязма өч нөсхәсе ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының текстология һәм кульязмалар бүлегендә, берсе ТРның Милли музеенда саклана.

*Әд.*: Яхин А.Г., Бакиров М.Х. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәзәкләр, бәетләр). К., 1979; Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. К., 1999.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Мәсьәләгә бер караш*

# ЭНЦИКЛОПЕДИК "ЭТ БОРЧАГЫ"

Узган елның ноябрь урталарында телевизордан "Большая Русская Энциклопедия"нен (БРЭ) беренче томы чыгуы турында хәбәр ителде. Татарчага аны "Зур Рус Энциклопедиясе" дип тәрҗемәләсәң, төрлечә анларга була: энциклопедия зурмы, әллә рус зурмы? Мона кадәр кулланышта йөргән "Большая Советская Энциклопедия"дә (БСЭ) әле ни әйтсәң дә, барлык совет халыклары рәтендә без татарларның да урыны һәм өлеше бераз төсмерләнә иде кебек. Ә монда, ачык, анлаешлы итеп язылган: "Большая Русская..."

Менә шуңа күрә Президентыбыз Указы белән булдырылган Татар Энциклопедиясе Институтында безнең татар галимнәребез дә җиң сызганып эшкә керештеләр, һәм әйтергә кирәк, аларның хезмәт җимешләре дә инде күз алдында; Рус энциклопедиясенең беренче томы белән бер үк вакытта татар энциклопедиясенең дә беренче томы дөнья күрде.

Әмма шунысын искәртеп куясы килә; безгә өлгерлектә, ягъни сан ягыннан түгел, ә сыйфат ягыннан калышмаска иде. Ана кадәр, әле 2002 елда гына галимнәребез "Татар энциклопедия Сүзлеге"н иҗат итеп өлгергәннәр иде. Бу турыда профессор Ф. Ганиевнең "Ватаным Татарстан" газетасында мәкаләсе дә басылып чыкты *(2003, 26 июль).*

Күз күрде, кулга тимәде дигәндәй, бу "көтеп алынган хезмәт"не (Ф. Ганиев аны шулай дип атый) бер генә районда да очратып булмый. Ул хәтта иң зур мәдәният учагы булган Республика Милли китапханәсенә дә җибәрелмәгән икән.

Энциклопедиянен беренче томына керешкәнче, әнә шул Сүзлекне китапханәләр аша халык игътибарына куеп бераз җилгәрсәң, фикерләр алышсаң, андагы кайбер хаталардан арынырга, алга таба эшне фәнни нигездәрәк корырга мөмкинлек ачылыр иде.

Ә хаталар анда шактый еш очрый һәм аларның кайберләренә Ф. Ганиев тә үзенең мәкаләсендә кагылып узган. Ана барыннан да элек, үсемлекләр аталышында баш сүз итеп рус телендәге исемнәрне куллану ошамаган... Һәм бу юнәлештә үрнәк итеп ул сиксәненче елларда чыккан "Татар Теленең Анлатмалы Сүзлеге"н тәкъдим итә.

Безгә калса, киресенчә, үсемлекләрнең русча исемнәрен телгә алмыйча, татарча һәм латинча терминнар белән генә эш итү, анда киткән хаталарның төп сәбәбе. Үсемлекләр аталышы татар телендә фәнни системага салынмаган. Шулай булгач, андагы тотрыксыз, килде-китте исемнәрне Энциклопедик сүзлектә баш сүз итеп кую—сәнәк белән суга язып кую кебегрәк була түгелме? Рус сүзләреннән башка, татарча-латинча тәрҗемәдә генә бирелгән Энциклопедик Сүзлек кемгә исәп тотып, кем өчен язылган? Язганда ук хатасыз яза алмаган латинча терминнарны анлап, яки дөресләп укырлык бездән—татарлардан, хет берәр кешене табып булырмы?

Хәер, элгәре Ф. Ганиев үрнәк итеп күрсәткән "Татар Теленең Анлатмалы Сүзлеге"нә күз төшерик. Калын-калын өч томнан торган бу хезмәт, сүзлектән бигрәк татар язучыларының төрле әсәрләреннән алынган цитаталар җыентыгын хәтерләтә. Фәнгә кагылышы булмаган бу әдәби цитаталар, үзләрендәге хаталарны да өстәп, сүзлектәге төп хаталардан игътибарны читләштерергә ярдәм итә. Мәсәлән: "Тиле нарат—урта пояста үсә торган агач—тис". *(III том, 106 б.)* Бу тәрҗемәдә анын үз хаталары да бик житкән. Беренчедән, тис дигән агач булмый, тисс дигән агач кына бар. Ф. Ганиев редакциясендә 1984 елда чыккан Русча-Татарча сүзлекнен беренче басмасында ук төшеп югалган "с"ны алдагы еллардагы басмаларда эзләп караучы булмаган һәм ул шул гарип исеме белән Анлатмалы сүзлеккә дә барып кергән. Икенчедән, тисс—наратка тәрҗемә була алмый; алар—икесе ике семьялыктагы үсемлек, ләбаса. Өченчедән, тисс—субтропик үсемлек, ул урта пояста үсә алмый.

Советлар иле таркалгач, Россиядә тисс кыргый хәлдә үсә торган хәзер бер генә урын калды. Ул да булса, Сочи шәһәре янындагы уникаль тисс-самшит урманлыгы (Тиссо-самшитовая роща).

Мәнә шуларга матур әдәбияттан эзләп алып, берәр цитата өстәсән, әлеге санап киткән хаталар югалып, онытылып калган кебек була:

*("Ул тайга! Ул тиле нарат дип йөртелгән дәү наратлар, колач житмәс иманнәр!" Г. Әпсәләмов.)* Күрәбез, Г. Әпсәләмовтан алынган хаталар тагы да гыйбрәтлерәк. Тиле наратның нинди агач икәне анда әйтелмәгән, ә мәнә тайгада колач житмәс иманнәрне очрату, монысы инде, әкияткә сыймаслык могжиза! Тайгада имән үскәнне кайчан күргәнегез бар?

Сүзлекнең мәгънәви эчтәлеген бутаудан башка әһәмияте булмаган бу әдәби цитаталарны Ф. Ганиев картотек база дип атый. Сүзлектә алар өч миллионга житә икән.

Өч миллион! Моның өчен бөтен татар әдәбиятын айкап чыгарга кирәк. Күпме хезмәт куелган! Маймыл хезмәте...

Әле сез арышның нәрсә икәнен беләсез микән? Аны белү өчен башта Сүзлеккә кертелгән 8 авторның моңа кагылышлы әдәби "шедеврын" укып өйрәнергә кирәк. Сигез цитата! Шуларның берсенә генә күз салыйк: *("Эти белән икәүләп, ике зур арба арыш төяп, хәзрәтнең ындырына алып барып, кибәнгә салып, дога кылдырып кайта идек". М. Гафури.)* Бу цитата Сүзлекне бутаудан башка нинди аңлатма өсти соң? Кибәнгә арышны түгел, арышның көлтәсен салалар. Димәк, хәзрәткә алар ике арба арыш түгел, ә арыш көлтәсе алып барганнар. Көлтә сугу технологиясе узган гасырның 40 нчы еллар ахырында ук гамәлдән чыкты. Шулай булгач, мондый анахронизм белән Сүзлекне чүпләүнең кемгә кирәге бар?

Мәнә шундый сигез цитатаны укып өйрәнгәч, инде беләбез: "Арыш-орлыгын онга әйләндереп, кара икмәк пешерүгә китә торган башаклы үсемлек" була икән. Әмма монда арыш ыругының кайсы семьялыкка керүе, һәм аның нинди төрләрне берләштерүе турында бер сүз дә әйтелмәгән. Аннан соң, нигә кара икмәк кенә? Аннан ак икмәк пешерү технологиясе дә күптән билгеле. Арышның кулланышы күп төрле. Моны без Сүзлекнең үзендә, шул ук битеннән укып та күрәбез. Анда "Арыш мае—аракы"—дип язылган. Мәнә сина мә! Күрәбез, житен, көнбагыш, рапслар кебек үк, арыш та майлы культуралар рәтенә керә икән ләбаса!

"Арыш мае" дип язылган аракы кибетләре яныннан узганда, мин туган телебез өчен оялудан башымны аска иеп, аяк астына карап узам. Каян килә бичара татарга шундый шомакайлык, икейөзлелек; Аракы дигән хәрам ризыктан Ходаем, үзең сакла, тик, без мөэмин-мөселманнарыңны арыш маеннан гына аерма!

Органик химиядә дөньякүләм шөһрәт казанган Бутлеровлар, Арбузовлар, Гыйлем Камайлар белән бер республикада яңәшә гомер итеп яткан бичара татарлар спиртны майдан аера белмәсеннәр, имеш.

"Эт жиләге" дигән үсемлек нинди була икән? Минем шуны әле дә булса белә алганым юк. Ф. Ганиевнең 1984 елда чыккан сүзлегендә: "паслен—эт жиләге" дип язылган. Әмма "паслен"—бу бит әле үсемлекнең ыруг исеме генә. Андый төрдәге үсемлек була алмый. Шуңа төр исеме дә кушып, тулы исемдә "паслен сладко-горький" дип әйтсәң, анысы—саескан жиләгенә әверелә, имеш.

Ә мәнә Аңлатмалы Сүзлектә исә, шул ук "эт жиләге—белладонна" дип тәржемәләнгән. Һәм, һәрвакыттагыча, шуңа карата әдәби цитата: *("Заһит вак кына жимешне төртеп күрсәтеп: "исемен белмим",—дигән иде. Мин: "Эт жиләге",—дип аңлаттым". М. Шабаев).* Эт жиләге дип М. Шабаевның нинди жимешне атаганын каян беләсең. Белладонна дигән андый үсемлек бездә генә түгел, гомумән, дөньяда юк. Ул "Красавка белладонна" дигән үсемлектә төр компоненты буларак кына катнаша. Итальян теленнән тәржемәдә белладонна—"чибәр туташ" (прекрасная дама) дигәнне аңлата. Кыргый хәлдә красавка белладонна Татарстанда гына түгел, Россия жирлегендә дә очрамый. Дару чималы буларак, аны Краснодар, Ставрополь якларында культурада (чәчеп) үстерәләр. Фәнни телдә ул атропа белладонна (Atropa belladonna) дип йөртелә. Атропин дигән кыйммәтле даруны мәнә шушы үсемлектән ясыйлар да инде.

Сүзлектәге барлык хаталарны да санап чыгу—колач житмәслек эш. Алар анда иксез-чиксез. Бигрәк тә: "Кукуруз—берөйлеләр семьялыгындагы үсемлек",

"карабодай—ике өлешлеләр семьялыгындагы үсемлек" дигән "ачыш-табышлар"ны укыганда, боларны юри көлеп, мыскыл итеп язганнардыр дигән фикер туа. Дөньяда андый семьялыкларның юк икәнлеге ботаниканы өйрәнә башлаган бишенче сыйныф укучыларына да билгеле бит.

Әйтик, "кыяк үлән—кыяклылар семьялыгыннан, терлек ашатуга китә торган күпъеллык чүп үлән—осока" дигән аңлатма үзе генә дә ни тора?! Бернинди эчтәлеге булмаган җөмләгә шул кадәр тыгызлап-чуарлап хата тутыра алу тагы кемнең кулыннан килә. Курәннәр семьялыгындагы осока ничек итеп кыяклылар семьялыгына барып кергән соң? Житмәсә, әле ул терлек ашатуга китә торган күпъеллык чүп үлән дә икән.

Кызганычка каршы, 2002 елда чыккан Татар Энциклопедия Сүзлегендә дә шуңа охшаш хаталарны очратырга була һәм аларның күбесе, кулланышта үзен аклаган халыкара фәнни терминнарны икъкрар итеп, Ф. Ганиев хуплый торган кушма сүзләргә алыштырудан килә.

Кушма сүз дигәч тә... ныклап карасаң ул үзе болай кушма сүз дә түгел. Ул, 18 гасыр урталарында ук мәшһүр Карл Линней тәкъдим иткән бинар кагыйдә буларак, исемнән һәм сыйфаттан торучы сүзтезмә. Аерма тик шунда гына; К. Линнейның бинар аталышында флористик системаның соңгы ике буыны—исем буларак ыруг һәм сыйфатны билгеләүче төр исемнәре күрсәтелсә (әче әрем, кара әрем, тәбәнәк әрем, ат кузгалагы, вак күзгалак һ. б.), ничә гасырдан соң Ф. Ганиев тәкъдим иткән, "Кушма сүзләрдә" исә, ыруг һәм төр дигән төшенчәләрнең исе дә сизелми (тал үләне, тавык үләне, каз үләне, шайтан таягы, куян тубыгы, бака яфрагы һ. б.).

Милләтнең сөйләм теле—аның культура дәрәҗәсенең күрсәткече. Ә культураны тиешле югары дәрәҗәдә тоту—аны карап, тәрбияләп торуны таләп итә. Игенчелек культурасы түбән булса, мәсәлән, кырларны чүп баса, уңыш кими. Нәкъ шуның кебек. Әлеге ике урынлы кушма сүзләр дә, үсемлекләр терминологиясендә артык балласт булып (күп сүз—чүп сүз), флористик системаны тәртипкә салуда уңайсыз киртә булып тора.

Җәй уртасы—Питрау көннәре житсә, болын-кырларны бизәп, биек сабакларда тирбәлүче, гажәеп серле, алсу-кызыл төстәге эре чәчәкләр ачылып китә. Юкка гына аны халык телендә "бояр гөле" дип атамаганнар. Аның калган ыругдаш төрләре, кайсы—"тырнак гөле", кайсы—"песи борчагы" исемендә йөри. Әмма болар фәнни атама була алмыйлар, чөнки анда үсемлекнең ыруг һәм төр исемнәре күренми. Мондый очракта руслар һәм башка алдынгы милләтләр аның халыкара терминга әверелгән латинча исемен, мальва (Malva) сүзен кулланалар. Ә нигә соң әле безгә дә шулай эшләмәскә? Безнең милләт алардан киммени? Юк икән шул. Мальваның матур исемен кушма сүзгә алыштырганнар; аннан "эт борчагы" ясаганнар. Менә шуннан соң инде халык телендә "тырнак гөле" дип йөртелгән "бөдрә мальва"ны "бөдрә эт борчагы" дип атарга тиеш булабыз. Тик монда нидер аңлашылып бетми; эт бөдрәме, әллә борчак бөдрәме?

Икенчедән, тырнак гөле дигән үсемлектән "эт борчагы" ясагач, бу семьялыкта янадан андый исемдәге үсемлек калмый. Шулай булгач, бөтен семьялыкка исем бирүче "мальва" сүзен бетереп, аны "тырнак гөлчәләр семьялыгы" дип атау, туган телебезгә фәкыйрьлектән, зәгыйфьлектән башка нәрсә бирә соң?

Ниһаять, өченчедән. "Эт борчагы" дигән сүзтезмәдә баш сүз булып (ыруг исеме) "борчак" сүзе килә. Шулай булгач, бу үсемлекнең исемен "эт" сүзендә түгел, ә "борчак" сүзендә урнаштырасы була. Ә монысы, үз чиратында, мальвалар семьялыгын кузаклылар семьялыгына кушып, бөтен флористик системаны бутауга китерә.

Энциклопедик Сүзлектә "Тиле торма" исеме күзгә төртелеп тора. Торма ыругының латинча исеме—Raphanus. Димәк, тиле торма дип, төр исемен дә кушып тулы исемдә әйтсәк, ул Raphanus raphanistrum булырга тиеш. Сүзлектән шуны барлыйм дип карасаң, анда "Тиле торма—к. Сарыбаш" дип куелган, ягъни, сарыбашны карарга кушкан. Ә анысын эзләп тапсаң, йә Ходаем!: "Сарыбаш—Erysimum" дип язып куйганнар. Менә сина мә! Менә сина Raphanus raphanis урынына Erysimum!

Ә Erysimumның нәрсә икәнен беләсез микән? Ул бит бөтенләй башка ыругтагы русчасы желтушник дигән шундый нәүмиз бер үсемлек. Аның нәрсә икәнен әле

ботаникага бераз якынрак торган агрономнарның да ишеткәннәре юк.

Ә тиле торма—безнең җирләрдә игенченең теңкәсенә тигән иң әрсез чүп үләннәрнең берсе. Аның белән контактта булмаган, хәтта авызында татып карамаган бер генә кеше дә юктыр, мөгаен. Карабодай боткасы ашаганда, авызыңда 3х5 миллиметр зурлыктагы каты салам кисәгедәй чүп тоеп, телең белән аралап алсаң, тиле торма орлыгы менә шул булыр. Карабодай чәчүлегендә кыен аерылучан чүп үлән буларак, ул, чистарту, җилгәрү, хәтта ярма ясау технологиясе бусагаларын исән-имин узып, аш өстәленә кадәр менеп утыра.

Беребез дә аңламаган латинга үрелгәнче, башта "тиле торма"ның русчасы "дикая редька" икәнен ачыкласаң, сүз дә юк, мондый акылга сыймаслык хаталарга энциклопедик сүзлектә урын калмас иде; "Тиле торма—к. Сарыбаш" дип читкә тайпылмыйча, туры гына: "Тиле торма—дикая редька—Raphanus raphanistrum" дип язылган булса, нинди унышлы тәрҗемә булыр иде. Үсемлекләрнең рус телендәге әзлекле тәртипкә салынган терминологиясен күрмәмешкә салынып, беркем дә аңламаган латинга үрелү, күрәбез энциклопедик Сүзлекне нинди аяныч хәлгә куйган.

Туган телебездә күпчелек үсемлекләр исемсез йөри. Гадәттә, аларны чәчәкләре төсе буенча аерым төркемнәргә бүлеп, гомум исемнәрдә атап йөртәләр: сары чәчәкле булса—сарыбаш, ак чәчәклесе—акбаш, күк чәчәкле—күкбаш һ. б.

Ә менә араларында матур гына, фәнни кулланышка яраклы исемдәгесе булса, без татарларны менә шунысы тынгысызлый. Мәгънәсез яңа исемнәр эзләп тагып, анысын да бутап бетерәбез. Бакча-паркларда киң таралган куаклы агач сәрвинең борынгы матур исеменә ни җитмәгән? Фәнни кулланыш өчен дә ул бик уңайлы. Юк бит, Энциклопедик Сүзлеккә кертү өчен, күрәсең, хәзерге телдә әйткәнчә "крутой" исем кирәк булган: аңа "кузаклы тал" дигән яңа исем кушканнар. Әмма, моның нинди буталчыкларга китергәнен уйлап караучы булды микән? "Кузаклы тал" дигән сүзтезмәдә баш сүз, ягъни ыруг исеме "тал" сүзе була. Бу исә аны кузаклылар семьялыгыннан алып, таллар семьялыгына күчерү, һәм шуның белән бөтен флористик системаны бутап бетерү дигән сүз. Инде болай да үтә ишле булган таллар семьялыгына, тагын кузаклы тал гына җитмәгән иде.

Без латин телен өйрәнмәгән халык, аны аңлау түгел, рәтләп укый да белмибез. Үсемлекнең татарча һәм русча исемнәрен ачыкламаган килеш, таныш булмаган латинга кереп китү—нәрсәдән бу; саксызлыктанмы, тыйнаксызлыктанмы? Җитмәсә, әле алар дөрес кенә итеп язылган булса икән. Китапта күзгә төртелеп торган "Barlarea" (дөресе; Barbarea-сурепка), "Poluopyrum" (дөресе; Polyqonum-горец, кырлач), "Faqupyrum " (дөресе; Faqopyrum-гречиха, карабодай), "Bromus inermies" (дөресе; Bromus inermis костер безостый, кылчыксыз кындырак) кебек төгәлсезлекләр без татарлар өчен бәлки игътибарга алмаслык вак-төяк булып тоеладыр. Ә югарырак даирәләрдә, Халыкара мәйданда, нәкъ менә шундый гаепсез, гади хаталар, көлке объекты буларак, озаграк гомерле булучан.

Хәзерге вакытта русларның һәм татарларның рухи тормышында җаваплы чор: һәр икесендә милли энциклопедияләр языла. Һәр икесе аның беренче томын инде чыгарганнар. Татар энциклопедиясенең беренче томын әлегә күргән юк. Күңелне борчыган нәрсә шул: сынатмаска, калышмаска иде. Калышмаска дигәнем—ашыкмаска, кабаланмаска иде. Эш тизлектә түгел, ә сыйфатта. Кирәк чакта руслар энциклопедиясенә карап, аннан тәҗрибә алып эшләү дә зыян итмәс иде. Әнә, узган гасырның 60-70 елларында чыккан Зур Совет Энциклопедиясенә генә күз сал. Утыз томнан торган әлеге җыентыктан, теләгән һәр сорауга тулы җавап табып була. Инде менә 35-40 ел дәвамында актарып, аннан бер генә хата тапкан кеше дә юк. Менә ничек булырга тиеш ул Энциклопедия!

**Фоат ВӘЛИЕВ,**
*биология фәннәре кандидаты.*

# БУ ХАТЛАР—
# ЗАМАН КӨЗГЕСЕ

СССР Язучылар Союзының "Дубулты" дигән иҗат йортында таныштык без аның белән. Татарстан телевидениесенең әдәби тапшырулар редакторы Әминә ханым Сафиуллина белән Рига култыгының юаш дулкыннарына карап яр буенда сөйләшеп утырабыз. Ерак та түгел какча гәүдәле, саргылт чәчле бер ханымның безгә карап-карап алуына игътибар иттек. Моны ул үзе дә сизде һәм яныбызга килеп утыргач:

—Гафу итегез, сез татарлар түгелме?—дип сорады.

Милләттәшебезне очраттык, дигән куанычлы уй килде күңелгә.

—Әйе. Сез кайдан буласыз?—дип, сорауга каршы сорау белән җавап бирдек без.

—Днепропетровскидан мин, Любовь Михайловна,—диде ул.—Сугыш вакытында Татарстанның Актаныш районында эвакуациядә булдым. Күктәкә авылында. Классташларым да, яшәгән йортымның хуҗалары да бик игътибарлы иде. Татарчага тиз өйрәндем. Хәзер менә, сөйләшер кеше булмагач, оныта башлаганмын.

Шул көннән алып без эштән буш вакытларны Любовь Михайловна белән бергә үткәрә торган булдык. Үзенең дә балалар язучысы икәнен белгәч, тагын да якынаеп киттек. Кайтыр вакыт җитеп аерылышканда мин аны кунакка чакырдым.

Казанга Наталья Петровна Никулина дигән дусты белән килде. Шагыйрә, филология фәннәре кандидаты, китап нәшриятының бүлек мөдире Никулина да бик ошады безгә.

Өйгә кунак килсә татар мәҗлес җыя бит ул. Мин дә аларны дусларым белән очраштырдым.

Иш ишен таба дигәндәй, филология фәннәре докторы Йолдыз Нигъмәтуллина (Галимҗан Нигъмәтинең кызы) белән Натальяның сере аеруча килеште.

Кунакларым Күктәкә авылына да барып кайттылар. Любовь Михайловнаны анда онытмаганнар икән әле. Классташларының да кайберләре белән күрешкән ул. Авылның матурлыгына, кешеләрнең мөлаемлыгына, бала-чаганың шуклыгына Наталья да сокланып кайтты.

Шулай башланды безнең дуслык. Менә шуннан китте инде хат, китап алышу, иҗат сөенечләрен һәм көенечләрен уртаклашу.

Үзгәртеп кору кәсафәте башланган еллар иде бу. Күп нәрсәне аңлап бетермибез. Күрешәсе, сөйләшәсе, фикер алышасы килә. Арада йөргән хатлар гына бераз күңелне баса. Бер хатында Любовь Михайловна китап чыгаруның кыенлыгы турында язган. Бездә бу хәл бик үк сизелми әле. Татарстан хөкүмәтенең үзгәртеп коруга әкренләп керү сәясәте өнебезне алырга бик юл куймый иде. Анда, Украинада, кинәт искән җил тузан өермәсен кубара да башлаган икән инде, хатлардан шул сизелә. Любовь Михайловна бер хатында болай дип яза:

*"Мин элеккечә нәтиҗәле эшләмим инде. Юкка тырышам кебек. Нәшрияттагы кульязмамның да язмышын белмим. Бар да нык үзгәрде. Үткәндәге җитешсезлекләрне тәнкыйтьләп язган әсәрләр генә басыла. Аларның геройлары да—хыянәтче, карак, алдакчы. Минем язганнарда, үзегез беләсез, алар юк. Бу турыда яза алмыйм мин. Андый китапларның файдалы булуына ышанмыйм. Ләкин бу бит минем фикер генә. Ул күпләрнең фикеренә каршы килә. Ни өчендер мин кешене уңай мисаллар ярдәмендә тәрбияләргә кирәк дип уйлыйм. Яхшы кешеләр явызларга караганда тыйнаграк бит, алар күзгә бик үк ташланмыйлар. Ә явызлар оялып тормый.*

*...Июль башында Наталья белән съездда булдык. Күп кенә кызыклы чыгышлар тыңладык. Элекке председатель Завгородный эштән азат итүне сорап гариза биргән. Украина Язучылар союзы җитәкчесе итеп Мушкетны сайладык. Киевта тынычлык, шәһәр бик матур, чиста. Урамнарны көненә берничә тапкыр юдыралар. Урамда халык күп, яшьләр күп. Ә менә балалар аз, барын да лагерьларга җибәргәннәр. Ләбибә Фаизовна, чакыруыгыз өчен рәхмәт. Наташа белән шатланып барыр идек, эштән бүленә алмыйбыз.*

*Сездә булган көннәрне бик еш искә төшерәбез. Әле күптән түгел бу сәяхәтебез турында прозаиклар секциясендә сөйләдем... "Кәләш" дигән повестем татар телендә басылып чыгу уңаеннан җыелган идек. Бу китапның (тәрҗемәчесе Венера Ихсанова. Л. И.) сездә чыгуына әле дә булса ышанып җитә алмыйм. Битләрен актарам, өзекләрен укыйм— күңелем шатлык белән тула. Бу китап Күктәкәгә барып җиттеме икән? Миргазиян (Күктәкә кешесе, мәктәптә бергә укыганнар, хат алышып торалар икән. Л. И.), русчасын укыдым, дип язган иде.*

*Ләбибә Фаизовна, Саҗидә Сөләйманова турындагы истәлекне язмый калмагыз. Моның белән шагыйрь буларак та, кеше буларак та аның җанын ачачаксыз.*

*Сезнең һәм безнең дусларга, Венерага ихлас сәламемне тапшырыгыз.*

*Л. М. 30. 6. 86."*

***

Күрешкәндә Саҗидә турында җылы сүзләр күп булгандыр, ахрысы, Наталья Никулина да Саҗидәне искә ала. Мин аңар дустымның китабын җибәрергә вәгъдә иткән идем. Шуны искә төшерүе.

*"...Саҗидә Сөләйманова китабын җибәрермен дигән вәгъдәгез өчен зур рәхмәт. Үкенечкә каршы, мин аның кайбер шигырьләре белән генә таныш. Шуларны гына укыганда да аның зур шагыйрь икәне чамалана. "Азат хатын" журналында Саҗидә турында язмагызны һәм бергә төшкән рәсемегезне күрдем. Укый алмадым алуын, шулай да шатландым. Саклармын мин аны.*

*Венера Фаизовнага изге теләкләремне тапшырыгыз.*

*Хөрмәт белән, Наташа."*

***

Белмим, бу изге эш кайдан, ничек башлангандыр? Йолдыз Нигъмәтуллинаның Натальяны Татарстан Фәннәр академиясенең утырышына чакырган көннәрдә булуы да ихтимал. Килешү буенча, Наталья анда чыгыш ясарга тиеш булган. Ә ул эшкә бер алынса, җиренә җиткерә торган кеше. Татар шигъриятен мөмкин кадәр өйрәнми калмас. Аларны украин теленә тәрҗемә итү идеясе дә шул көннәрдә тугандыр дип уйлыйм. Ул елларда китап чыгару бик үк авыр түгел иде әле. Файдалы яки кызыклы әсәр генә булсын. Наташа нәшриятта бүлек мөдире дә бит. Китапның кирәклеген дәлилләп алгандыр. Инде өмет чынга әйләнә башлагач, ул бөтен барлыгы белән эшкә тотынып, җигә алган кадәр мине дә җикте. Хат арты хат язып, сорауларына җавап ала торган булды.

Кулымда шундый хатларның берсе:

*"Хөрмәтле Ләбибә апа!*

*Мин җавап язмауда рекорд куйдым бугай инде. Кичерегез. Көне буе мәшәкать эчендә! Кульязмаларны нәшриятка тапшыру, яңалары белән танышу, ашыгыч эшләр... Болар мине аклый алмый, билгеле.*

*Коллегаларыгызның адресларын җибәргәнгә зур рәхмәт. Дөрес, мин аларны шунда ук безнең язучыларга тапшыра алмадым. Икесе дә иҗат командировкасына киткән иде. Берсе әле хәзер дә өйдә юк. Өйгә кайтканына Сибгат Хәкимнең адресын бирдем. Ләкин ул да әле авыру сәбәпле, ныклап эшкә тотына алмый. Шуның өстенә, аның кечкенә генә сере дә бар. Эшләнгән тәрҗемәләренең матбугатта басылып чыгуын көтә. Шуннан соң гына Сибгат Таҗиевичка иҗат отчеты белән күренергә тели булса кирәк. Мин моны Сезнең үзегезгә генә әйтәм.*

*Балтыйк буеннан кайтуыма татар шагыйрьләре антологиясе турында зур гына радиотапшыру эшләргә җыенабыз. Бу беренче карлыгач булачак. Шуннан соң вакытлы матбугатыбызда аерым чыгышлар планлаштырабыз.*

*Антология 1984 елның әзерлек планына кертелде инде. Исеме әлегә "Світи мені, Чулпан-Зоря" ("Свети мне, Чулпан-Звезда")—Муса Җәлил шигырендәге образ. Әлегә шартлы исем. Планга кергәндә китапның исеме кирәк бит. Хәзер кульязма нәшриятта инде. Тиздән чыгару планы кабул ителәчәк һәм кульязма художникка биреләчәк. Баш художник антология турында сорашты инде.*

*Ләбибә Фаизовна, кульязмада Ләис Зөлкарнәевнең шигырьләре бар. Биографик белешмәдә туган елы гына күрсәтелгән. Кыен булмаса, языгыз әле, китаплары бармы*

*аның, бәлки чыгарга әзерләнәдер? Яки вакытлы матбугатта күренгәлидер. Язучылар Союзы әгъзасымы ул?*

*Үзем "Азат хатын"га дигән шигырьләремне әзерләп бетерә яздым. Ялдан кайткач җибәрермен. Ә хәзер мин Юрмалада. Эшлим, ял итәм, гәрәбә җыям, экскурсияләргә йөрим.*

*Венера Фаизовнага, кызыгыз Әлфиягә, Әминә ханымга, Җүәһирә апага, Йолдызга күп сәламнәр.*

*Хөрмәт белән, Наташа".*
*12/IX—82."*

***

Наташа мине штатка алды, ахры, дип елмаеп куям. Хат арты хат яза. Антологиянең язмышы үзенең дә бөтен барлыгын биләп алды бугай. Моның нинди зур, җаваплы эш икәнен үз җилкәсендә тоймаган кеше генә белмидер. Хат аша хәбәрләшү дә күп вакытны ала. Якын ара түгел бит. Наташаны аңлыйм мин. Кулымда менә тагын бер хаты. Антология турында яңа хәбәр юкмы икән дим. Булмыймы соң!

*"Хөрмәтле Ләбибә апа!*

*Сезне, Әлфияне 8 Март бәйрәме белән тәбрик итәм. Яхшы сәламәтлек, шат көннәр, кояш, чәчәкләр, илһам телим.*

*Татар шагыйрьләренең сувенир антологиясен эшләүне дәвам итәбез. Шигырьләрнең яртысын тәрҗемә иттеләр инде. Бу көннәрдә нәшрият директоры эшнең барышы белән кызыксынды. Киевтан, һ. б. шәһәрләрдән тәрҗемәләрне алдык. Кайбер шагыйрьләр Днепропетровскидагы каләмдәшләргә шулкадәр дә ошады ки, шәхсән танышасылары килә. Сезнең ярдәм кирәк булыр, ахры, аларга. Әллә Язучылар союзына мөрәҗәгать итәргә микән? Ничек яхшырак булыр, киңәш итегез әле. Сүз Сибгат Хәким белән Зиннур Мансуров турында бара. Аларның иҗаты безнең шагыйрьләрне нык кызыксындырды.*

*Шушы арада кульъязмаларның украин варианты тәмам әзер булыр дип уйлыйм. Ә аннары инде—нәшрият эше.*

*Сәлам белән, Н. Н."*

***

Эштән кайтышлый китап кибетенә керми узып китә алмыйм. Нинди дә булса бер яңалык күрәсең анда. Керүгә Г. Тукайга багышланган альбомга күзем төште. Зур форматтагы, яшькелт-зәңгәр төстәге тышлыклы бу китап—Мөхәммәт Мәһдиевның фәнни эше. Шагыйрь әсәрләреннән үрнәкләр, мәшһүр рәссамнәребезнең картиналары, фоторәсемнәрдән торган ошбу басма татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән. Минем аны дусларыма җибәреп мактанасым килде. Федор Шаляпин турындагы шундый ук китап белән икесен Наташага җибәрдем. Озак та үтмәде, сөенечле хат килде.

*"Кадерле Ләбибә Фаизовна!*

*Шундый кыйммәтле бүләкләр җибәрүегезгә нинди генә рәхмәтләр әйтим! Йөрәгемдә булган барлык хисләрем Сезгә омтыла. Белсәгез икән (Сез моны үзегез дә сизәсездер) минем өчен нәкъ менә бу ике китапның нинди кадерле булуын! Тукай һәм Шаляпин! Бөек Тукайның иҗаты белән мине беренче тапкыр Зәки Нури таныштырды. Мәктәптә укыганда аның белән хат алыша идем. Шул вакыттан башлап, Габдулла Тукай исеме миңа бик якын. Мин аның күп шигырьләрен беләм һәм яратам. Бигрәк тә "Шүрәле"не. Ләкин шундый зур күләмле, тулы эчтәлекле басмасы миндә юк иде әле. Сезгә зур рәхмәт, мең мәртәбә рәхмәт. Ә Шаляпин иҗаты белән әтием кызыксына иде. Шаляпинга кагылышлы бөтен нәрсә икеләтә кадерле миңа. Аның Казан дәверендәге тормышын аз беләм. Рәхәтләнеп укырмын инде.*

*Шаляпинда да, Тукайда да тиңсез мәгънә тирәнлеге, рухи бөеклек бар, аларны уйласаң үзең дә сафланып каласың.*

*Кадерле Ләбибә Фаизовна, миңа нинди зур шатлык китерүегезне, бәлки, үзегез дә сизмисездер. Ә без монда Сезнең турыда борчыла башлаган идек инде. Сездән бик озак хәбәр булмады бит. Мин открытка җибәргән идем. Хат язарга да җыендым. Любовь Михайловна Пицундадан язарга булды. Хәбәр бирүегезгә бик шатмын.*

*Сезгә шәп сәламәтлек, зур иҗат уңышлары телим. Венера Фаизовнага күп сәлам. Барсы өчен дә зур рәхмәт Сезгә, кадерле, сөйкемле кешем.*

*Үбеп, Наташа".*

***

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 40 еллыгына багышлап Мәскәүдә СССР Язучылар Союзының Балалар әдәбияты советы җыелган иде. Төрле республикалардан килгән язучылар дулкынландыргыч чыгышлар ясады. Мин дә Муса Җәлил белән Абдулла Алиш батырлыгы турында сөйләдем. Кулымны кысып рәхмәт әйтүчеләр булды.

Пленар утырыштан соң "Поклонная Гора" дигән музей- һәйкәлгә чәчәкләр салырга бардык. Киевтан килгән украин шагыйре Тамара Агранасьевна Коломийец автобуста яныма утырып, сүз ара сүз киткәч, Сез Наталья Петровна Никулинаны беләсезме, дип сорады. Белү генә түгел, аның Киевта чыгачак китабына рецензия дә язган икән әле. Бик талантлы, үзенчәлекле шагыйрә, дип әйтте.

Казанга кайткач, Коломийецның сүзләрен Наташага яздым. Сөенче аласым килгән иде. Сөенечкә каршы ул да сөенечле хәбәр салган.

*"Кадерле Ләбибә Фаизовна!*

*Сезгә кечкенә генә бүләк—татар антологиясенең сувенир китабын җибәрәм. Безнең уртак хезмәтебезгә Тукай һәм Җәлил ватанында нинди бәя бирелер дип, борчулы уйлар белән салам аны. Бу китапның язмышы үз китапларымныкыннан да кадерлерәк тоела һәм мин укучыларның, матбугатның (игътибар итсәләр) фикерләрен бик көтәм.*

*Узган хатыгызда Сез бу китапны күбрәк алырга теләвегезне әйткән идегез. Киевтан кала безнең өлкә китап базасына мөрәҗәгать итәргә кирәк, диделәр. Бу юл уңышлы булырмы, белмим. Ләкин сорап карарга кирәк. Адресы болай: 320035, Днепропетровск, 35. Суворов урамы, 55. Өлкә китап базасы. Баш товаровед Дыбко Н. И.*

*Нәшриятыбызның Татарстан Язучылар союзы идарәсенә мөрәҗәгать итәргә җыенуын да беләм.*

*Үзем Сезгә һәм Г. Ахунов иптәшкә бирәр китап җибәреп торам.*

*Хөрмәт белән, Н. Никулина".*

***

Казан белән Днепропетровск арасы ерак булса да, арада йөргән хатлар күңелләрне якынайтып өлгергән иде инде. Бу шәһәргә кагылышлы кечкенә генә хәбәрне дә, кайчан белүемә карамастан, дусларым белән уртаклашмый кала алмыйм.

Бер көнне кульязмалар арасыннан "Комсомольская Правда" газитенең 50 елларда басылган саны килеп чыкты. Сугыш вакытында Днепропетровск шәһәрендәге комсомол яшьләрнең фашистларга каршы көрәше турында язылган хәбәргә тап булдым. Йөрәкләрендә үч алу хисе кайнаган, ләкин аяусыз көрәштә тәҗрибәсез бу яшьләрнең күбесе һәлак була. Шул батырлар белән бергә татар кызы Фатыйма Гафурова белән татар егете Мәхмүт Калинкинның да яшь гомере өзелә.

Әлеге хәбәрне кабат укыгач, күп еллар элек кичергән хисләребез яңарды. Мәхәббәт һәм яшьлек җырчысы Илдар Юзеев, батыр милләттәшләребезгә багышлап, "Фәрит—Фәридә" дигән героик-поэма иҗат иткән иде. Бер хатымда шул турыда Натальяга да яздым. Җавап хатында ул әлеге хәбәремә мөнәсәбәтен белдергән.

*"Кадерле Ләбибә Фаизовна!*

*Хатыгызга бик озак җавап бирә алмадым. Гафу итегез, зинһар. Мин хәтта моның сәбәбен дә аңлата алмыйм. Шигырьләремә игътибарыгыз өчен Сезгә һәм Венера Фаизовнага зур рәхмәт. "Азат хатын"ның бу кадерле санын түземсезлек белән көтеп алырмын.*

*Сугыш елларында безнең шәһәрдә яшәгән татар патриотлары турындагы хәбәрегез нык дулкынландырды. Бу вакыйгага әйләнеп кайтырмын әле мин.*

*Любовь Михайловна белән икәүләп Сезнең "Держись, Акробат" дигән китабыгызны эзләп таба алмадык. Без аның турында "Китап күзәтү"дән белгән идек. Билгеле, ул китапның дөнья күрүе безнең өчен үзе генә дә зур шатлык. Русчага тәрҗемә ителгән китапларыгызны күрербез дип өметләнәбез.*

*Минем бу җәем җимешсез булды. Вакыт җыен вак-төяк белән үтте. Күзен*

*Дубултыга баргач эшләрмен дип уйлыйм. Эшлисем бик күп күзе. Мөмкинлекләр генә җитеп бетми.*

*Җәмгысе шул гына. Изгелектә калам.*

*Хөрмәт белән, Наташа.*
*10/VIII."*

***

Бу дөнья шундый катлаулы, чуар. Шатлык белән кайгы янәшә йөри. Әйтерсең лә алар кеше йөрәген әсир итәргә ашыгып, берсен-берсе куып йөгерә. Наташадан "Моабит дәфтәре"нең украин телендә чыккан икенче басмасын (анда шигырьләрнең оригиналы да бирелгән) алып сөенергә дә өлгермәдем, Сибгат ага Хәкимнең вафаты турында кайгы уртаклашу хәбәре килде. Курск, Ржев тирәләрендәге каты сугышларда катнашкан солдат-шагыйрь, күренекле җәмәгать эшлеклесе, яшь шагыйрьләрнең кумиры, Тукай һәм Горький премияләре лауреаты Сибгат агага багышланган антология чыгу уңаеннан шактый хәбәрләшкән идек. Без монда, Казанда, бу авыр хәлдән айнып та өлгермәдек, Натальядан хат килеп төште.

*"Литературная газета"дан зур шагыйрь, хөрмәтле Сибгат Хәкимнең вафаты турында белгәч, тирән кайгы кичерүемне әйтми кала алмыйм. Үзен күреп белмәсәм дә, шигырьләрен укып мин аның эчкерсез, шәфкатьле, кешелекле, олы шагыйрь икәнен аңлаган идем инде. Аны якыннан белгән кешеләрнең кайгысын уртаклашам.*

*Хөрмәт белән, Наташа".*

***

Бөтен кайгы-хәсрәтләре, мәшәкатьләре, зур һәм кечкенә шатлыклары белән тормыш дәвам итә. Украинадагы дусларым ничә еллар күп көч куеп, тырышып эшләгән антология дә кулга керергә тора. Кызганыч, аны Сибгать ага Хәким генә күрә алмады. Ә Днепропетровскидан хатлар һаман килә.

*"...Хөрмәтле Ләбибә Фаизовна!*

*Һәрвакыттагыча җылы хатыгызны алдым.*

*Безнең антология әкренләп эшләнә. Сигнал нөсхәсе дә кулга керде. Күз алдына китерәсезме, Муса Җәлил шигыре белән ачылган бу аксыл-зәңгәр тышлы китапны кулыма алгач нинди хисләр кичерүемне аңлыйсызмы? Хәзер Киевтан Днепропетровскига тираж килүен генә көтәсе калды. Ә ул бер-ике айдан килергә дә мөмкин. Бу турыда Союзда әйтми торуыгыз дөрестер дә бәлки. Көтелмәгән шатлык булсын ул. Антология басылып чыккач, Киевның "Книга Почтой" магазины аша да алырга мөмкин булыр. Кирәк булса, без дә ярдәм итәрбез. Бераз борчылам да үзем. Китап Днепропетровскида басылса җайлырак буласы иде, аның каравы Киевта сыйфат әйбәт.*

*Любовь Михайлованың "Шатлыгым минем" дигән китабы чыгып ята. "Кәләш"нең дәвамы. Шуның кебек үк матур язылган (хәер, аның ничек язуын Сез үзегез дә беләсез бит).*

*Менә шундый яңалыклар бездә. Антология магазинда күренүгә хәбәр итәрмен.*

*Венера Фаизовнага Любовь Михайловнадан күп сәлам. "Кәләш"нең уңай рецензия алуына без дә шатландык.*

*Хөрмәт белән, Наташа.*
*10/X-84."*

***

Тормыш никадәр генә чуалчык булмасын, дусларымнан күңелле генә хәбәрләр дә килеп тора. Наталья, мәсәлән, бер хатында Днепропетровск сәнгать музееның 80 еллыгы, икенчесендә язучылар оешмасына 60 ел тулу, өченче бер хатында диварга ясаган рәсемнәре белән дөньяга танылган Петровка мастеры Федор Панкога багышланган тантаналар турында язган иде. Ә шәһәрдә беренче тапкыр туган тел бәйрәме үткәрүләрен нинди горурлык белән белдергән. Без үзебез күп еллар буе 26 апрельдә шигырь бәйрәме үткәрәбез. Шагыйребез Габдулла Тукай туган көн ул. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә зур уңышлар казанган иҗатчылар Г. Тукай бүләген ала. Шул көнне гәзит-журналларыбыз Г. Тукайга багышлап язган шигырьләр белән чыга. Шагыйрь һәйкәле янында шигъри

митинг үтә. Кичен Опера һәм балет театрында зур тантана белән шигърият кичәсе үткәрелә. Боларның барсы турында тәфсилләп язган хатым анда сакланадыр әле.

Мин үзем дә Натальяның Тарас Шевченко тууга 180 ел тулу көнен тасвирлаган хатына "Сакларга!" дип куйганмын бит. Менә ул хат.

*"...9 мартта Тарас Шевченконың 180 еллыгын бәйрәм итәбез. Украинаның барлык шәһәр һәм авылларында зур тантана белән үтәчәк ул. Әле күптән түгел генә Днепропетровскида Бөек Кобзарьның исемен йөрткән театр каршына яңа һәйкәл куелды. Әлегә кадәр Днепр уртасындагы паркта аңар бер һәйкәл куелган иде инде. Җәмәгатьчелек шәһәр уртасында да һәйкәл булырга тиеш дип тапты. Биредә төрле тантаналар үткәрергә җайлы. Минемчә, сөекле шагыйрьгә бик уңышлы һәйкәл булдырылды. Нева яр буенда, коллыктан азат ителү таныклыгын тотып, Днепр турында уйланып утыра кебек ул. Һәйкәл каршында, театрның биек стенасы буйлап, ватаныбызның атаклылары Григорий Сковорода, Иван Франко, Леси Украинка, Владимир Винниченко, Васил Стус бюстлары тора.*

*Шулай итеп, барлык кыенлыкларга карамастан, җәмәгатьчелек һәм сәнгать кешеләренең тырышлыгы белән шундый зур эшнең эшләнүе күңелне күтәрә. Менә шул гына.*

*Сезгә изге теләкләр белән, Наташа.*
*4/III –94."*

***

Ә кыенлыклар көннән-көн үзен сиздерә тора. Төшкә дә кермәгән хәлләр, чынбарлык булып, алдыбызга килеп басты. Илне бүлгәләп, аерым-аерым дәүләтләр ясадылар. Минем украин дусларым чит ил кешесе булып калды. Барып-килеп йөрү түгел, хат алышу да кыенлашты. Натальяның соңгы хатын укып утырам.

*"Кадерле Ләбибә Фаизовна!*

*Тәбрикләү хатымны алгансыз икән. Мин бик шат. Язуыгызга караганда, сезнең республикада көнкүреш хәлләре яхшырак икән әле. Бездә тормыш көннән-көн кыенлаша. Экономика кризиста. Бар нәрсәгә дә, шул исәптән фатир хакларына да бәяләр арта. Дөрес, хезмәт хаклары да, пенсияләр дә артып тора. Ләкин бәяләрнең туктаусыз күтәрелүе җиңеллек китерми. Эшмәкәрләр үзләрен уңайлы сизә. Капитализмга кире кайту халыкка бик кыйммәткә төшәр, ахры.*

*Мәдәният өлкәсендә дә шундый ук кыенлыклар. Китап чыгаруның үз читенлекләре. Кәгазь һәм акча җитмәве сизелә. Полиграфик чыгымнар бик югары.*

*Язучылар оешмасы шундый ук кыенлыклар кичерә. Өлкә язучылар оешмасын бинасыз калдыра яздылар. Ярый әле өлкә хакимияте бушлай ике бүлмә бирде. Бөтен көчкә Язучылар союзын сакларга тырышабыз. Бердәнбер таяныр урыныбыз бит ул.*

*Литфонд тәмам бөлде. Ярдәме аз. Любовь Михайловна белән Сезгә баруыбызны бик еш искә төшерәбез. Гаҗәп бит, нинди арзанчылык булган. Шундый ерак юлга чыгып та, литфонд биргән акчага йөреп кайтканбыз. Андый эшләр хәзер мөмкин түгел инде.*

*Любовь Михайловна әкренләп эшли. Бик матур фантастик хикәяләр яза. Экология темасына язылган повесте шәһәр гәзитендә басылды.*

*Кадерле Ләбибә Фаизовна! Сездән килгән хатларга һәрвакыт шатмын. Китабыгыз басылып чыгуын телим.*

*Хөрмәт белән, Наташа.*
*19/IX-94."*

***

Инде чит ил булып калган Украинага хатлар җибәрү авырайды. Элемтә чаралары кыйммәтләнде, бүлешерлек яңалыклар да юк кебек. Кайда да бер хәл. Ике дөнья—бер морҗа, дигән бит безнең халык. Ярый әле хатлар сакланган. Дусларымны сагынганда укып утыргалыйм.

**Ләбибә ИХСАНОВА**

# ЧЫН ХИКӘЯЛӘР

Соңгы елларда үзенең кызыклы романнары һәм повестьлары белән күпләгән укучыларны сөендергән, прозадагы иҗади казанышлары өчен *("Каргышлы этаплар" романы, 1999 ел)* Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясенә лаек булган Рәфкать Кәраминең матур гына хикәяләре дә бар икән, ләбаса! Аларның күбесе "Өзелгән чәчәк" исеме белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан (2002) җыентыкта урын алган.




*"Урман эченнән ялгыз юлаучы атлый. Машиналар, атлар йөреп такырлаган киң юл булса да, ул саргылт туфлиләре белән кипкән үләннәрне, коелган яфракларны таптап, аяк астында шарт-шорт сынып калучы корыган агач ботакларына басып, юл читеннән бара бирә".*

Әлеге китаптагы "Кәккүк тавышы" дигән хикәя әнә шулай башланып китә. Биредә, без китергән өзектә, бары тик ике генә җөмлә, әмма игътибар белән укыган кеше өчен анда күп мәгънә, тирән эчтәлек ята.

Автор хикәясен "урман эченнән" дип башлый—димәк, сөйләмгә кереп киткәндә үк безнең игътибарны урманга—зур серләр тупланган урынга—юнәлтә. Шул ук вакытта кеше күңелен гел дә үзенә тартып, гел дә ымсындырып торган серле мохит, тиз генә аңлап бетерү мөмкин булмаган үзенчәлекле бер дөнья бит әле ул урман! Әсәрнең кереш өлешендәге әлеге җөмләләр алда буласы хәлләргә бик мәгънәле ишарә сыман кабул ителә. Аннары инде "ялгыз юлаучы" дигән гыйбарә бирелә, анысы шулай ук безнең күз алдында тәэсирле күренеш тудыра. Бу сүзләрне хәтта хикәянең икенче исеме итеп тә куеп булыр иде кебек.

Алга таба автор әлеге ялгыз юлаучының киң юлдан түгел, ә юл *читеннән* баруына игътибарны юнәлтә. Һәм шул ук вакытта *кипкән* үләннәр, *коелган* яфраклар, *корыган* агач ботаклары да искә алына… Ә болары инде укучы күңелендәге ялгызлык, моңсулык, нәрсәнедер юксыну тойгысын тагын да көчәйтә. Хикәянең әле генә укылган исеме "Кәккүк тавышы" дип куелган булгач әлеге тойгы бермә-бер үсә.

Менә шушындый тирәннән уйланылган һәм нечкә сәнгать чаралары белән язылган кереш өлеш, ягъни матур башлам безнең күңелләрне, зиһенебезне бер темага, эчтәлеккә көйләп куя. "Ә ул тема нинди соң?" дигәндә без озак еллар буе читтә йөреп менә хәзер үзенең туган авылына кайтып килүче Нәгыйм язмышын күз алдыннан үткәрәбез. Башта бер-бер артлы өч хатынга өйләнгән, аннары аларның һәрберсендә ятим балалар калдырып авылдан чыгып качкан Нәгыймнең—озак вакыт авырып үлгән әнисен дә күмәргә кайтмаган Нәгыймнең—бүгенге хәлен без хикәянең тәүге юлларында күп төрле ишарәләр, образлы кинаяләр аша сизенгән булсак, әсәр эченә кереп киткәч тә автор сәнгатьчәлекнең ышанычлы юлын ташламый. Хикәя героеның хәзер нинди күңелсез хәлдә—ялгызак булып калуын—тормышчан һәм реалистик сурәтләнгән эпизодлар аша ача ул.

*"—Гөлнисаның олы кызы,—диде карчык, юлдашының, туктап, чишмәгә төшеп киткән кыз артыннан бирелеп карап торуын күргәч."*

*"Гөлнисаның олы кызы? Димәк, ул минем кыз була бит. Әйе, чат әнисе. Нәкъ*

Рәфкать Кәрами. Өзелгән чәчәк: Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 224 бит.

*Гөлнисаның яшь чагы. Ә нигә соң бу карчык аны Гөлнисаның олы кызы диде. Нигә синең кызың дими?"*

Нәгыймнең менә шушындый уйлары укучыга инде тиешле нәтиҗәне—бу әсәре белән автор әйтергә теләгән фикерне шактый тирән итеп сеңдерә. Димәк, Нәгыйм качып йөреп үзенең олы бәхетен—балалар атасы булу шатлыгын да—югалткан. Аны олы тормыш белән бәйләүче җеп, яшәеш белән бәйләүче үзәк тамыр өзелгән. Хикәянең баш өлешендәге моңсулык, ялгызлык мотивлары ахыргы өлештә яңадан кочәя һәм әлеге бәхетсез герой күңелендә, колагында кәккүк тавышы—ялгызлык символы булган кәккүк авазы—булып яңгырый.

Рәфкать Кәраминең бу китабында тагын "Өзелгән чәчәк" дигән кызыклы хикәя дә бар. Әлеге жанрның танылган осталары А. Чехов һәм Ә. Еники сыманрак башлап китә ул әсәрен автор: *"Өченче звонок чылтыраганда күп тиражлы газета редакторы Закиров буфетта бик тәмләп сыра эчә иде."* Хикәядә төп геройларның берсе булачак менә бу кешене без беренче мәртәбә әнә шунда—буфетта—күрәбез, сыра эчкән чагында. Ә бит ул бирегә әдәби-музыкаль кичәгә дип килгән… Ләкин бераздан ачыкланганча: Закиров бирегә ирексездән генә килеп эләккән икән шул—редакциядәге икенче хезмәткәр командировкада булу, һәм бүгенге кичә турында язардай бүтән кеше табылмау аркасында гына!

Ә кичә барышында аңа бер яшь ханым белән танышу бәхете дә елмая—алар хәтта икенче өлешкә калмыйча, танышлыкларын дәвам итү өчен янәшәдәге бакчага ук чыгып китәләр… Чираттагы бер очрашуда исә әлеге ялгыз ханым аны өенә үк чакыра, чөнки ул әдәбият-сәнгать кешеләренә бик тә мөкиббән икән…

Әсәрнең ахыры болай бетә. Ләйсирә исемле теге ялгыз ханым вәгъдәләшкән көнне өендә Закировны көтеп утыра: бер сәгать, ике сәгать көтә ул аны… *"Ә бу вакытта Закиров—эштән кайтышлый юл уңаенда бажаларына сугылган хөрмәтле кунак—кухняда, өстәл янында, бик тәмләп сыра чөмерә һәм баудан гына алган майлы чехонь балыгының койрыгын кимерә иде".*

Әнә шулай итеп, хикәя Закировның сыра эчүе белән башланды һәм шуның белән тәгәлләнде дә. Димәк, әсәр эчендә булып узган хәлләр: яшь ханым Ләйсирә белән мавыгу да, аның белән әллә нинди "югары материялар", әдәбият-сәнгать хакында үтә кызыксынып сөйләшкән булып кылану да—боларның берсе дә Закиров өчен мөһим дә, кирәк тә түгел икән! Аның алары Закиров дигән әлеге бәләкәй генә бер түрә кисәгенең зыялы булып күренергә тырышуы, үзенчә бер битлек киюе генә икән!

Рәфкать Кәрами бер карауга гади генә булып күренгән әнә шундый эпизодларда кешенең кем икәнлеген, нинди икәнлеген ачып бирүче характерлы сыйфатлар таба һәм аларны укучы хәтерендә калдырырдай итеп сурәтләп бирә белә.

Ул вакыйга-күренешләрне дә әллә каян, югары сфералардан яки без белмәгән хыялый ераклыктан түгел, ә көндәлек яшәеш-көнкүрештән таба. Менә мисал өчен "Төче миләш" дигән чагыштырмача кечерәк күләмле хикәя. Даниал исемле бер ир, хатыны сүзен тыңлап, малаен музыка мәктәбенә укырга бирмәкче була. Ләкин, директор хатын әйтүенә караганда, мәктәптә инде урыннар бүленеп беткән. Димәк, Даниал алдында хәзер гаять тә четерекле проблема килеп туды—ул үзен, үзенең булдыклылыгын раслый аламы-юкмы?

Һәм максатка ирешү өчен кешенең мескенләнүе, ялынуы, әлеге директор алдында түбәнсенүе башлана. Менә шушындый психологик халәт хикәядә бик тә нечкә һәм төгәл сәнгать чаралары ярдәмендә ачыла. *"Башын түбән игән миләш агачы яныннан узганда ул түзмәде, үрелеп бер кызыл тәлгәшне тартып алды. Юл аркылы чыкканда авызына капкан ике миләшне трамвай рельсына төкерде. Алар бик төче иде. Ә урманда, иркендә үскән агачларның җимешләре ачы була."*

Мескенлеккә төшкән Даниалның эчке портретына бик тә төгәл штрих, деталь бу. Ул да бит малаен кешегә кызыгып кына, хатыны сүзен тыңлап кына музыка мәктәбенә бирергә уйлаган иде. Ягъни бүтәннәргә ияреп, ныклап уйламыйча эшләнгән эш иде ул. Ә нәтиҗәдә төче миләш сыман килеп чыкты! Ягъни табигать ялгышлыгы кебек!

Бүгенге тормышта күпләр килеп эләгә торган әнә шундый реалистик ситуация

алыну, аның ышандырырдай һәм кеше күңеленә тәэсир итәрдәй булып сурәтләнүе нәтиҗәсендә хикәя истә кала, уйландыра, гыйбрәтле гомумиләштерү ясардай уйлануларга алып килә. Гомумән, китаптагы хикәяләрнең күпчелеге реальлеге, чынлыгы белән ота, укучы күңелен яулый. Биредә үзебезнең классыгыбыз, хикәяләр остасы Әмирхан Еникинең шул хакта әйткән фикере тагын бер мәртәбә искә төшә. *"Мин үз башымнан кичкән яисә кемнән дә булса ишеткән чын вакыйгалар турында гына язам"* дигән иде ул бер әңгәмәсендә.

Р. Кәраминең бу китабына кергән "Йомыш" дигән хикәяне укыган чагында да бүгенге яшәештә еш кичерелгән шундый гыйбрәтле кичерешләр яңадан баш калкыта, хәтергә килә.

Хикәянең баш герое сәгать буе чират тора-тора, кабул итү бүлмәсендәге секретарьшага йомышын кат-кат аңлата-аңлата, ниһаять, югарыдагы бер түрә янына үтеп керә. Ә теге түрәнең нинди мәшәкать диген? Менә ул моның алдында бер дустына шылтырата:

*"—Роберт Фердинандович, ничек хәлләр? Миндә дә. Бу атнада бер ял итеп аласы иде. Гаилә белән. Ухага чыгып кересе... Әйе, стерлядка... Хатының Клара бит әле? Аңа да ял булыр..."*

Язучы Р. Кәрами менә шушы кыска гына өзектә бүгенге түрәләрнең чын йөзен ачып бирердәй сүзләр таба, аларның яшәү рәвешләрен күрсәтә. Боларга халык та, милләт тә кирәкми! Боларга синең җитди йомышың да—колак яныннан исүче йомшак җил кебек кенә! Ә алар өчен беренче урында: шәхси иминлек, күбрәк байлык туплау, җылы урында утырганда күңелле итеп яшәп калу!

Ләкин түбәнлеккә төшсә дә хикәя герое мондый хәл белән килешеп яшәргә теләми шул. Әсәрне тәмамлаучы менә бу юлларда хәзерге тормышта изелеп яшәүче күпләрнең эчке халәте, кискен фикере чагыла:

*"Ишектән чыккач та юл аркылы гына Җәлил торуын беләм. Һәйкәлгә карамадым. Оят. Шундаен гаҗизлеккә төшә-төшә теләнеп йөр, имеш. Ә Җәлил гадәтенчә, горур. Ул безнең кебек мескен түгел. Чәнечкегә уралса да, башы—горур. Кичер, туган, без фәкыйрьләреңне. Әллә өйрәттеләр, әллә үзебез күнектек: түрәләргә бил бөгеп, баш иеп керәбез. Ишекләрен аяк тибеп кенә ачасы урынга..."*

Менә бу юлларда чиновникларга—"халык хезмәтчеләренә"—карата гади халык вәкилләренең типик уй-фикерләре бик тә калку чагыла. Ә әдәбият шуның белән көчле дә бит ул: тормыш-яшәеш сулышын дөрес күрсәтүе белән, кешеләрнең эчке дөньяларында нинди хәл-әхвәлләр булып ятуын, анда нинди "җимешләр" өлгереп килүен дөрес итеп, тәэсирле итеп күрсәтү белән көчле чын әдәбият!

Бу китапта без үрнәк алырдай матур, яхшы һәм якты күңелле геройлар да күп. Мисал өчен "Якты елмаю" әнә шундыйлардан берсе. Аның төп герое Касыйм ага үзенең хатыны белән бәхәс вакытында зур горурлык хисе кушып болай ди: *"Минем шәкертләрем арасында ике композитор, өч җырчы бар, шуларның берсе бөтен илгә танылды. Бу азмы? Ә күпме музыкант тәрбияләдем мин?! Ничәмәничә кешене музыкага гашыйк иттем! Туган көнем җитсә, котлаулар почта тартмасына сыймый..."*

Ә инде "Шофер хатыны", "Куллар, куллар..." дигән хикәяләрдә ирләре белән бергә тормыш, яшәү авырлыгын кичергән татар хатыннарының мәгърур образлары тасвирлана. Әлеге хикәяләр гаять зур тәрбияви көчкә ия, аларда үрнәк герой образлары бар.

Китапта мәхәббәт турында да хикәяләр күп. "Җепшек кар ява", "Хуш, ак каен" һәм "Өзелгән чәчәк" шулар арасында иң уңышлылары дип санала ала.

*"Сәгать сигезенче ун минут китте. Ә Кифая һаман юк та юк. Җитмәсә, эч пошырып җепшек кар ява. Биткә, керфекләргә сылана, колак тишегенә тула. Җиле дә, үч иткәндәй, ник бер минут туктап торсын. Әле уңнан, әле сулдан бәрә."*

Мәхәббәт темасына багышланган "Җепшек кар ява" исемле хикәя әнә шундый күренешне тасвирлау белән башланып китә. "Кәккүк тавышы" дигән хикәягә ничек кереп китүне без инде күреп үткән идек. Анда *"кипкән үләннәр"*, *"коелган яфраклар"*, *"корыган агач ботаклары"* дигән гыйбәрәләр безне ялгыз кәккүк язмышына дучар булган бер кеше фаҗигасе белән очрашуга әзерләде.

Биредәге табигать күренеше укучыга нәрсә хәбәр итә соң?

*"Ирек ничәнче кабат инде биш катлы йортны әйләнеп чыкты..."* дип дәвам итә автор хикәясен. (Ләкин бу җөмләдәге бер кечкенә кимчелекне җәя эчендә генә искәртеп үтик: "ничәнче кабат" түгел, ә "ничәнче кат" кирәк! Чөнки "кабат" сүзе ул үзе үк берничә мәртәбә кабатланган эш-хәрәкәтне белдерә).

Аның көткән кызы Кифая өенә кайтмый да кайтмый... Егет белән кыз арасындагы әлегә тотрыксыз булган, җепшек кар шикелле мөнәсәбәтне белгертә икән әлеге күренеш. Һәм чыннан да: Кифаяны көтә-көтә өй тирәли йөргәндә егет икенче бер кыз белән танышып китә, әзрәк сөйләшеп йөргәч алар тагын да очрашырга сүз куешып аерылышалар...

Кечкенә генә күләмле менә шушы хикәя мәхәббәт темасына, аның нечкәлеген, тиз үзгәрүен, шуңа күрә сак мөнәсәбәт кирәклеген күрсәтүгә багышланган бер музыкаль әсәр шикелле тәэсир итә. Ул уяткан хис-кичерешләр күңелдә озак вакыт уйнап, дулкынланып тора—тере килеш яши! Бу, әлбәттә, хикәяченең үз максатына ирешүе, укучы күңелен яулап алуы турында сөйли.

Китапның икенче өлеше яшүсмерләргә багышланган һәм ул "Ихлас күңелем" дип атала. Бүлекне ачып җибәргән "Кәкре багана" хикәясе нәкъ менә яшүсмерләргә хас булган психологик халәтне төгәл бирүе белән игътибарга лаек. Төзелешкә электрчы булып эшкә килгән яшь Илһамның бер дә сер бирү теләге юк, үзен һәр эштә дә оста, тәҗрибәле итеп күрсәтәсе килә аның. Ләкин менә электр баганасына менәр чират җитә, шунда инде әлеге "калай әтәч"нең кем икәне ачык күренә: аның тез буыннары калтырый башлый, башы әйләнә, хәтта багана үзе дә кәкре булып күренә аңа... Көч-хәл белән багана очына хәтле менеп җитә ала тагын. Әмма төшүе тагын да кыенрак икән, ләбаса... Һәм, ахыр чиктә, Илһам дигән егетебез кикриген шиңдерергә—чынлыкны танырга мәҗбүр була:

*—Каюм абзый, син ачуланма инде, бу минем беренче багана иде.*

Шулай итеп әлеге "калай әтәч"нең тавышына да кешеләрчә аһәң килеп керә, үзе дә тормыш тәҗрибәсе ала. "Эшкә өйрәнү дә, кешеләр арасында яшәргә өйрәнү дә әнә шундый сабак алудан башлана ул" дип әйтә сыман биредә автор үзенең менә шушындый чын хикәяләре белән.

Ә "Шагыйрь" дигән кечкенә генә күләмле икенче әсәр исә укучыны бөтенләй бүтән типтагы егет белән таныштыра. Мәктәптәге иптәшләреннән яшереп кенә шигырьләр язган ул... Кайчагында тегеләр рөхсәтсез алып укысалар бик уңайсызланган, оялган да—чөнки аның иң садә, иң саф хисләренә кагылалар ич... Ләкин, барыбер, аңа авылда "Шагыйрь" дигән исем тагыла. Бирегә командировкага килгән автор аның белән танышырга тели, ләкин җавап аяусыз була шул:

*—Юк бит ул хәзер,—диде Мөхтәр. —Былтыр көз көне үлде ул...*

Эш ничек булган: бу шагыйрь егет көзге бозда уйнап йөрегәндә бата башлаган ике баланы судан тартып чыгарган икән... Әнә шул чагында үзенә салкын тидергән, авырып бераздан үлеп тә киткән...

Хикәядә әлеге яшь шагыйрьнең нинди шигырьләр язуы күрсәтелми, бәлки алар бөек әсәрләр булгандыр, бәлки яза башлаган кешегә хас өйрәнчек кимәлдә булганнардыр алар. Ләкин әсәргә "Шагыйрь" дигән исем кую һәм әлеге ситуацияне тасвирлау биредә киңрәк мәгънә ала. Безнең илдә чын шагыйрьләрнең ни өчен бик иртә үлүләренә җавап бирелә бу әсәрдә. Чын шагыйрьләр алар, әлеге әсәрдәге яшь егет кебек, һәрчак кешегә ярдәмгә ашыгалар шул! Алар өчен кешеләр, ил, халык мәнфәгате һәрчак иң беренче урында була. Алар әнә шул олы һәм изге максатка фидакарьләрчә бирелгән, тулысынча гомерләрен багышлаган була. Безнең илдә шагыйрьләрнең һәм, гомумән, фидакарь җаннарның иртә үлүләре иң элек әнә шул асыл максат, асыл билгеләнеш белән аңлатыла.

Югары максатларны, саф әхлакны һәм рухи батырлыкны, матурлыкны мактаган менә шушындый әсәрләре белән Р. Кәрами яшьләр күңеленә, әлбәттә, якты юл сала. Бу бүлектәге "Кушаматлы Әбүзәр", "Әдрән диңгез буенда", "Кышлак" дигән хикәяләр дә үзләренә зур тәрбияви тәэсир көче салынган булулары белән әһәмиятле. Бүген безгә менә шуның кебек матур әдәбият әсәрләрен тәрбияви максатларда файдалануны көчәйтү турында гына ныграк уйларга кирәк.

Китапның өченче бүлеге “Бераз гына елмаеп-көлешеп алсак та ярар” дип исемләнгән һәм аңа, исеменнән үк күренгәнчә, юмористик әсәрләр тупланган. Р. Кәрами дигән бу авторыбыз юморда да кызыклы гына әсәрләр иҗат итә ала икән бит! Бигрәк тә аның “Рәфкать Кәрами мәзәкләре” дип бирелгән кыска күләмлеләре аеруча уңышлы килеп чыккан. Аларда реаль кешеләр, чын вакыйгалар елмаю кояшы турында балкытып бирелгәч аеруча истә кала. Ә инде “Дустым өйләнә” дигән хикәя юмордан бигрәк сатирага тартым булып чыккан. Кибет директоры кызына өйләнергә йөргән егет кисәгенең үтергеч көлү утына килеп эләгүе ул әсәрдә чыннан да сатирик чаралар ярдәмендә ачылган.

Р. Кәрами хикәяләрендә нинди җитешсезлекләр күзгә ташлана соң?

Китапка кергән берничә хикәянең эчтәлеге белән дә, хәтта язылу рәвеше белән дә гадәти очеркны хәтерләтүен әйтми үтү мөмкин түгел. “Бер очрашу” белән “Гөрләвекләр ага челтерәп” әнә шундый тәэсир калдыра. Җитмәсә әле аларда тема, эчтәлек яңалыгы да юк.

Аннан соң Р. Кәраминең байтак кына хикәяләрендә рус сүзләренең урынсыз кулланылуы эчне пошыра. Менә 10-биттән бер өзек: *“...чөнки график буенча аларның отделениесе дежур торырга тиеш иде”*. Шәһәрнең янгын сүндерүчеләре турындагы шушы җөмләне: *“...чөнки бүген аларның кизү тору чираты иде”* рәвешендә чын үзебезчә сүзләр белән язарга мөмкин ич инде, югыйсә!

Яисә менә 69-биттә: *“Аркаларына каеш белән ранец аскан бәләкәйләр мәктәп формасыннан”* дип яза Р. Кәрами. Биредә ранецны—биштәр, ә форманы мәктәп киеменнән диярргә була иде.

Ә бит нигездә Р. Кәрами халыкчан һәм матур әдәби телдә яза. Мәсәлән, 6-биттә бер герой: *“—Югалды ул, Асия Кәбировна, башы-аягы белән юк”*—дип әйтә икән, биредә инде аның холкы, темпераменты ачык чагыла.

Яисә менә 61-биттән тагын бер мисал. Ир белән хатын икесе ике җирдә эшли, әлегә ике җирдә торып яталар. Шушы хакта хикәядә болай әйтелә:

*—Болай ике казан асып яшәү кыендыр бит...*

Мондый үрнәкләрне Р. Кәрами әсәрләреннән күп китереп булыр иде.

Ә гомумән алганда, Р. Кәрами хикәяләреннән тупланган “Өзелгән чәчәк” исемле бу китап хәзерге тормыш һәм безгә замандаш булган кешеләр турындагы җитди уйлануларга, күзәтүләргә бик бай. Китапны тулаем укып чыккач мондый нәтиҗәгә киләсең:

—Әйе, хәзерге тормышта кешеләргә эш-хәрәкәт мөмкинлеге бик тә артты. Шуңа күрә тирә-юнебездә активлык, динамизм да көчәйде. Һәм шул ук вакытта, әлеге тенденция нәтиҗәсе буларак, кешеләрнең үзара бәрелешләре, конфликтлар да арта бара. Рухи-психологик яссылыкта да, иҗтимагый-социаль планда да күбәя бара әлеге бәрелешләр.

Ләкин әнә шундый чорда яшәп тә, шундый ситуациядә калып та, аннан рухи һәм әхлакый яктан саф-пакъ килеш чыга алган, вөҗданнарын керсез саклый алган матур күңелле һәм батыр рухлы кешеләр бар. Бүген әнә шундыйлар үзләренең сафлыгы, батырлыгы белән хөрмәтләп баш иderә. Без аларда—аларның бүгенге яшәешендә—үзебезнең алдагы иманлы юлыбызның башын, башлануын күрәбез.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

*Әбрар Кәримуллинның тууына 80 ел*

# ТАТАР ФӘНЕ ТАРИХЫНДА ЭЗЕ ТИРӘН

*Әбрар Кәримуллин—күренекле татар галиме, китап белгече, библиограф, филология фәннәре докторы (1978), Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1992), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1987), Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1991), Кол Гали исемендәге халыкара бүләк лауреаты (1995).*

*Бөек Ватан сугышында катнашып, I дәрәҗә "Ватан сугышы" ордены, "Батырлык өчен" медале һәм башка күп медальләр белән бүләкләнә.*

*1953—1964 елларда Казан дәүләт университеты китапханәсенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары, 1964 елдан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзер ТФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) гыйльми хезмәткәр булып эшли.*

*Фәнни һәм публицистик хезмәтләре исемлегенә 700гә якын хезмәт керә. Алар арасында татар китабына, татар һәм төрки халыклар тарихына, мәдәниятка, библиографиягә, топономикага, этнографиягә һәм башка мәсьәләләргә багышланган китаплар, монографияләр, мәкаләләр, белешмә басмалар һ.б. бар.*

*Әбрар Кәримуллин чит илләргә еш чакырыла. Ул төрле халыкара фәнни конференцияләрдә һәм конгрессларда катнаша, күп кенә халыкара оешмаларга кабул ителә, бернечә тапкыр "Елның атаклы кешесе" дип билгеләнә. Ана шәрәфле "Маркиз оф Туран" исеме бирелә, чит илләрдә басылган энциклопедик сүзлекләрдә аның турында материаллар басыла.*

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Татарстанның Саба районы Чәбия-Чүрчи авылында дөньяга килә.



Булачак татар академигының белем юлындагы беренче адымнары туган авылындагы бер классы мәктәптә башлана. Беренче сыйныфны тәмамлаганнан соң, аңа 4 чакрымдагы Ике Басу Арташ, бишенче сыйныфтан 9 чакрымдагы Татар Икшермәсе мәктәбендә укырга туры килә. Урта белемне ул 1941 елда Саба урта мәктәбендә алып чыга. Колхозда тракторист ярдәмчесе булып эшкә керешүгә, сугыш башлана. Аның педагогия институтына укырга керү, география укытучысы булу турындагы хыяллары чәлпәрәмә килә. Ә.Кәримуллин башта Нырты шифаханәсендә бухгалтер, соңыннан Олы Арташ авылында башлангыч мәктәп укытучысы булып эшли.

1943 елның 7 гыйнварында ул Кызыл Армиягә чакырыла. Хәрби курсантлар училищесын тәмамлагач, миномет төзәүчесе сыйфатында фронтка җибәрелә. Курск дугасындагы сугышларда, Украинаны, Венгрияне, Чехословакияне, Румынияне азат итүдә катнаша. Аннары Ерак Көнчыгышка япон милитаристларына каршы сугышка озатыла. Монголия, Кытайдагы үлем далаларын, Хинган тауларын кичә. Өч тапкыр яраланган, контузия алган егет 1947 елда гына туган авылына кайта.

Җиде елга сузылган тәнәфестән соң белемен күтәрү теләге Ә.Кәримуллинны Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Сугыш

гарасатын тыныч тормыш михнәте алыштыра. Укыган чакта үзен матди яктан тәэмин итү өчен ана тимер юлда һәм елга порты причалларында йөк ташырга, урам җыештырырга, кешеләргә утын кисәргә, ә җәен төзелештә эшләргә, урман кисәргә туры килә.

Ә.Кәримуллин бик тырышып укый. Беренче сессияне үк "бишле"ләргә генә тәмамлап, күтәренке стипендия ала, дүртенче курстан исемле стипендия дә ала башлый.

1953 елда Әбрар Кәримуллин университетны тәмамлап, Казан дәүләт университетының Фәнни китапханәсендә эшли башлый. Анда Ә.Кәримуллин унбер елдан артык хезмәт итә— китапханәчедән алып директорның фәнни эшләр буенча урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.



*Сулдан уңга: Разил Вәлиев, Мирфатыйх Зәкиев, Минтимер Шәймиев, Әбрар Кәримуллин. Казан, Татарстан халыклары корылтае. 1992 ел, май.*

Университет китапханәсендә эшли башлаган яшь белгечкә китап тарихын өйрәнергә туры килә. Дөнья халыкларының һәм татар халкының язма мәдәнияте, китап байлыгы белән күбрәк таныша барган саен ул үзе укып чыккан университет курсларында бу елларда татар халкының тарихы, мәдәнияте, әдәбияты, матбага эше, сәяси фикере, аның Рәсәй һәм дөнья тарихындагы урыны хакындагы белемнәренең хакыйкатькә туры килмәгәненә төшенә.

Күп гасырлар дәвамында тупланган рухи байлыкны эзләп табу, аның белән танышу, фәнни өйрәнү, файдалану эшендә иске язулы татар китапларының китапханәдә тулы каталогы булмау зур кыенлыклар тудыра. Шунлыктан, Ә. Кәримуллин беренче эш итеп иске татар китапларының каталогын төзү эшенә керешә. 1945-1960 елларда аның җитәкчелегендә гарәп язулы татар китапларының тасвирламасы кириллицага күчерелеп, яна каталог төзелеп бетә һәм укучыга тәкъдим ителә.

Шушы ук елларда Ә.Кәримуллин тарафыннан татар теле һәм тел белеме, әдәбият тарихы, әдәбият белеме, тарих, фольклор буенча фәнни-библиографик күрсәткечләр төзелә һәм аларның кайберләре аерым китап булып басылып та чыга. Күп кенә студентлар һәм укытучылар өчен алар даими кулланма булып киталәр.

Болардан тыш, университет тарихына караган хезмәтләр, аңа багышланган мәкаләләр күрсәткече, якланган диссертацияләр күрсәткече һәм башка тасвирламалар төзелә.

Шулай итеп, Әбрар Кәримуллин тырышлыгы белән Казан университетының фәнни китапханәсендә зур фәнни-тикшеренү һәм нәшрият эше башлана. Ул илебезнең археографлары, тарихчылары арасында, фәнни мәгълүмат үзәкләрендә югары бәя ала.

Чит илләрдәге фәнни оешмалар белән сугыш елларында тукталган китап алмашу эше дә янартыла. Китапханә Европа, Азия, Америка, Австралия илләрендәге югары уку йортларының 200дән артык китапханәсе белән элемтәләр урнаштыра. Алар белән китап алмашу эше җайга салынып, китапханәгә бу илләрдән меңнәрчә басмалар алына.

Университет китапханәсендә 11 ел эшләп, Ә.Кәримуллин үзен җитәкче һәм фәнни-тикшеренү эшен оештыручы, археограф, библиограф, китапханә белгече итеп таныта.

Ул бу мәсьәләләр буенча үзәк һәм җирле матбугатта чыгышлар ясый, дистәләрчә

фәнни һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, бәяләмәләр, китап гыйлеменә караган фәнни хезмәтләр яза, "Татарика" библиографиясен булдыру, планлы рәвештә кульъязмалар фондын тасвирлау эшен дә алып бара.

Галим фәнни эш белән генә чикләнми, күп кенә фәнни-популяр мәкаләләр дә яза, студентлар арасында китапчылык белеме, китапханә тарихы, китап фондлары, аларны туплау мәсьәләләре, каталоглар системасы, китап сайлау, китап белән эшләү кагыйдәләре, диплом һәм диссертацияләрдә библиографияне бирү тәртибе һәм башка темаларга лекцияләр дә укый.

Әмма, 1963 елны "Әдәби җыентык һәм альманахлар библиографиясе: 1917—1960" дигән китабына Ленин-Сталинга багышланган шигырь җыентыкларын керткәне өчен ана җитди гаеп ташлыйлар. Татарстан Өлкә партия комитетының махсус, чираттан тыш җыелган бюросында Әбрар Кәримуллин "сәяси яктан житлекмәгән" кеше буларак шелтә ала һәм китапханәнең директор урынбасары вазыйфасыннан азат ителә. Әбрар Кәримуллин өстендә болытлар күптән куера башлаган була. Аны үзе төзегән библиографияләргә репрессияләнгән галим-әдипләрнең хезмәтләрен кертүдә һәм революциягә кадәр чыккан татар басмаларын мактауда да гаеплиләр.

1964 елның декабрендә СССР ФАнең Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих институты Әбрар Кәримуллинны кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә ала. Монда ул "Татар сәхнәсе (1917—1967): Әдәбият күрсәткече" дигән хезмәтен тәмамлый. 1968 елда "Татарларда матбагачылык туу һәм татар филологиясе буенча яңа чыганаклар" дигән темага аспирантурасыз, фәнни житәкчесез, институтның планына да кертмичә, кандидатлык диссертациясе яклый.

1971 елда диссертация аерым китап булып, "У истоков татарской книги: от начала возникновения до 60-х годов XIX века" исеме астында басылып чыга. Китап үзебезнең илдә һәм чит илләрдә дә зур бәя ала. Галим биредә, татар матбагачылыгының тарихын яктырту белән беррәттән, китап белемендә беренчеләрдән булып, басма сүз тарихын өйрәнүдә зур әһәмияткә ия булган милли китап теориясен эшли. Әбрар Кәримуллин раславынча, китапның теле, авторның милләте, әсәрнең китап булып басылган урыны һәм башка сыйфатлары—аның кайсы халыкка хезмәт итүе белән берлектә каралырга тиеш. Автор тарафыннан милли китапның берьюлы берничә халыкның, бигрәк тә кардәш халыкларның, уртак байлыгы булу ихтималлыгы нигезләнә.



*Беренче рәттә сулдан уңга: Әбрар Кәримуллин, Мөхәммәт Мәһдиев; икенче рәттә сулдан уңга: Нил Юзиев, Равил Фәйзуллин, Миркасыйм Госманов, Разил Вәлиев. Казан, 1991 ел.*

Әбрар Кәримуллин 1970 елда XX йөз башы татар китабы тарихы буенча докторлык диссертациясен тәмамлый. Монография 1974 елда аерым китап булып басылып чыга *(Татарская книга начала XX века.—Казань, 1974)*, бик күп белгечләр тарафыннан югары бәя ала. Әмма диссертация буларак галим аны бары тик 1978 елда гына яклый ала. Бу диссертация дә институт планына керми, эштән буш вакытта языла. Институт планы буенча галим библиографик күрсәткечләр төзү эшен дәвам итә. Шундыйлардан татар фольклоры һәм фольклористикасының 300 еллык үсешен чагылдырган библиографик тасвирламаны күрсәтергә була *(Татар фольклоры: Аннотацияләнгән әдәбият күрсәткече: (1612—1981).—Казан, 1993)*.

Докторлык диссертациясен яклаганнан соң, 1983 елда аның "Реформалардан

соңгы Россиядә татар китабы" дип исемләнгән яңа монографиясе *(Татарская книга пореформенной России.—Казань: Татар. кн. изд-во, 1983.—320 с.)* басылып чыга. Шулай итеп, автор татар китабының революциягә кадәрге чорын яктыртуны тәмамлый. Галимнең әлеге хезмәте, элек язылган ике китап белән бергә, татар китабының килеп чыгышы, халыкның укый-яза белү дәрәҗәсе, татар халкы әдәбиятының, мәдәниятенең, мәгарифенең Рәсәй тарихында тоткан урыны хакында яңача фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Әлеге хезмәтләр нигезендә хәзер югары уку йортларында татар басма китабының тарихы укытыла. Галимнең шуннан соң язылган хезмәте татар китабының революциядән соңгы чорына багышлана. Ул 1989 елда басылып чыга *(Становление и развитие татарской советской книги: 1917—1932 гг. Очерки о ведомственных и кооперативных издательствах Татарской АССР).*



*Әбрар Кәримуллин улы Шамил белән.*

Шул ук вакытта ул тарих, әдәбият, мәдәният, археография, топономика, библиография буенча тикшеренүләрен дәвам итә. Татар, башкорт, үзбәк, казакъ, кыргыз халыкларының китап бастыру эше һәм бу өлкәдәге үзара элемтәләре хакында хезмәтләр яза.

Әбрар Кәримуллин күпкырлы галим булса да, гомере буе китап тарихы, библиография мәсьәләләрен үзәккә куеп эшли. Шул рәвешчә, халык хәтере булган китап язмышы—Ә.Кәримуллинның үз язмышына әверелеп яши. Китапка багышланган хезмәтләре аша ул татарның үзаңын үстерүгә сөйләп бетергесез зур өлеш кертә. Шулай да халкыбыз язмышына кагылышлы бер генә мәсьәлә дә аның игътибарыннан читтә калмый. Ул—татарның тарихын торгызу эшендә дә үзеннән зур өлеш керткән галим.

Татар халкының исемен һәм җисемен ачыклауга багышланган монографиясе татар һәм рус телләрендә өч тапкыр басылып чыгу, чит илләрдә япон һәм гарәп телләрендә дөнья күрүе үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли *(Татарлар: исемебез һәм җисемебез.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1991).*

Галим халкыбыз язмышын кайчакта һич көтелмәгән яклардан яктыртуга ирешә. Аның төрки телләр һәм майя, инк, ацтек, сиу-хока, аймара индеецлары телләре арасындагы генетик уртаклыкны ачкан тикшеренүләре—шуның ачык мисалы. Әлеге хезмәт 1995 елда аерым китап булып басылып чыга *(Прототюрки и индейцы Америки: По следам одной гипотезы.—М.: Инсан, 1995).*

1996 елда басылып чыккан "Язмыш, язмыш" дигән китабы да авторның үз халкы язмышына багышланган. Монда чит илләрдә яшәгән милләттәшләребезнең гыйбрәтле язмышлары һәм үзебезнең Татарстандагы милли-мәдәни, фәнни, әдәби һ.б. проблемалар яктыртыла.

Әдип чит илләрдә төпләнеп яшәгән татарларның эшчәнлеген сурәтләүдә дә милләтебезнең асыл сыйфатларын ачып бирүгә ирешә. Хезмәт сөючән, намуслы татар халкы вәкилләре бер вакытта да югалып калмаган, үзләрен бары яхшы яктан гына күрсәткәннәр, телләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен саклап калганнар, мәчетләр, мәктәпләр ачканнар, сәүдә иткәннәр, газета-журналлар чыгарганнар; галимнәр, дәүләт эшлеклеләре булып үсеп җиткәннәре дә аз булмаган.

1997 елда Ә.Кәримуллинның татар теле тарихы, аның бүгенгесе, киләчәге мәсьәләләренә багышланган "Тел—милләтнең сакчысы" дигән китабы басылып чыга. Татар телен яклауга, саклауга, үстерүгә, камилләштерүгә, аңа мәхәббәт тәрбияләүгә багышланган бу хезмәт гаҗәп актуаль проблемаларны күтәрә, аларны гамәлгә ашыру өчен кулланма да булып тора.

Галимнең 2000 елда дөнья күргән "Без тарихта эзлебез" дигән китабында, исеменнән үк күренгәнчә, татар халкының тарихына, мәдәниятенә караган материаллар тупланган. Биредә автор татар халкының милли азатлык, тигез хокуклылык,

мөстәкыйльлек өчен көрәшен фәнни-публицистик рухта яктырта.

Халкыбызның мәшһүр галиме кайсы гына өлкәдә эшләсә дә, тапталган такыр юлдан бармый. Аның һәр хезмәтенә янача караш хас. Шуна күрә алар галимнәрне генә түгел, киң катлам укучыларны да җәлеп итә.

Әбрар Кәримуллин, халкыбызның кыю улы буларак, иҗтимагый хәрәкәттә дә актив катнаша. Ул Татарстанның суверенитетын ныгыту, татар милли хәрәкәтен тергезү юлында зур эш алып бара.

Сүзен халыкка җиткерү өчен әдип вакытлы матбугаттан киң файдалана. Ил агасының газета-журнал битләрендә басылган берсеннән берсе үткенрәк, гаять әһәмиятле мәсьәләләрне күтәргән күпсанлы мәкаләләре халыкка тарихыбызны, бүгенге хәлебезне ныграк аңларга ярдәм итте. Аларның күпчелеге әле бүген дә актуальлекләрен югалтмыйлар.

Халкыбызның олуг галиме Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 75 яшендә—2000 елның 18 сентябрендә арабыздан китеп барды. Аның җәсәде туган авылы Чәбия-Чүрчи зиратында җирләнде.

Ә.Г.Кәримуллин 1991 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр диярлек Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә гыйльми консультант булып та эшләде. Китапханәчеләргә аның исеме аеруча якын һәм кадерле. Хәзерге вакытта Милли китапханәнең аерым бер бүлмәсендә Әбрар Кәримуллинның шәхси китаплары коллекциясе саклана. Әлеге коллекциядә татар, башкорт, рус, төрек, инглиз телләрендә басылган 4 меңнән артык китап-журналлар тупланган. Монда китап белеме, китап тарихы, тел белеме, әдәбият, тарих, татар теле, халык иҗаты һәм башка мәсьәләләргә караган фәнни хезмәтләр, монографияләр, дәреслекләр, сүзлекләр урын алган. Алар арасында татар халкының атаклы мәгърифәтчеләре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри хезмәтләре, күренекле галимнәр В.Бартольд, И.Крачковский, В.Ключевский, Л.Гумилев китаплары, Әбрар ага Кәримуллинның замандашлары—М.Зәкиев, Ф.Гарипова, Р.Әмирханов, Я.Абдуллин, С.Алишев, М.Әхмәтҗанов һәм башка бик күп галимнәрнең әсәрләре бар. Коллекциядә, Гомәр Хәйям, Низами, Нәваи шигырьләре кебек Көнчыгыш шигърияте үрнәкләре белән беррәттән, татар әдәбияты җәүһәрләре—Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Г.Утыз-Имәни, Г.Кандалый, Г.Тукай, Г.Исхакый, Н.Исәнбәт һәм башка бик күп татар әдипләренең әсәрләре саклана. Коллекциянең иң әһәмиятле өлеше—әлбәттә, Ә.Г.Кәримуллинның үзе язган хезмәтләре. Бу искиткеч зур хәзинәне Әбрар ага Милли китапханәгә үзе бүләк иткән иде. Аның вафатыннан соң, академикның хәләл җефете мөхтәрәмә Кинтә ханым тарафыннан коллекция кулъязмалар, фоторәсемнәр, хатлар, галимнең шәхси әйберләре белән тулыландырылды. Халкыбызның олы, кабатланмас шәхесе, милләтебезнең асыл бөртеге булган Әбрар Кәримуллинның күпкырлы, бай, затлы мирасын барлау, фәнни өйрәнү, аның тормыш һәм иҗат юлын чагылдыру, татар халкы тарихында алган урынын билгеләүдә әлеге коллекция-архив зур әһәмияткә ия. Бу китапларны ул укыган, өйрәнгән, файдаланган, аларга галимнең күз нурлары сеңгән. Күбесенә үзенең мөнәсәбәтен белдергән шәрехләр, өстәмәләр, искәрмәләр, бәяләмәләр язып калдырган. Хәзер Әбрар аганың китапханәсе фондын исәпкә алу, аны фәнни эшкәртү, электрон каталогын төзү эшләре алып барыла, коллекциягә кергән китапларның басма каталогы да нәшер ителәчәк. Киләчәктә Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә Әбрар Кәримуллинның китапханәсе, архивы, шәхси әйберләре тупланган музей-бүлмә булдыру күздә тотыла. Бөтен гомерен китапка, китапханәләргә багышлаган олуг затның музее нәкъ менә китап йортында—Милли китапханәдә булу үзе бер яхшы фал дыр.

*Мәкаләне Татарстан Республикасының Милли китапханәсе хезмәткәрләре* ***Ирек Һадиев*** *һәм* ***Наҗия Асылкаева*** *әзерләде.*

Әбрар
Кәримуллин

# ТАТАР БАСМА КИТАБЫ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН*

Милли басма китап барлыкка килгәнче бездә мең елдан артык кулъязма китап гамәлдә булган, ерак Болгар дәүләте чорларында ук барлыкка килгән мәктәп-мәдрәсәләр эшләгән, безнең эрага кадәр үк язуыбыз булган, борынгы бабаларыбыз Ханбалыктан алып Кенәр атауларына хәтле ил-җир гизгәннәр, дөнья халыклары казанышларын үзләштергәннәр, аларның үз ачыш-табышлары да күп халыклар арасында танылган... Бу һәм башка матди, мәдәни факторлар халкыбыз тормышында, аның тарихында гаять зур роль уйнаган, аның үсеш двигателен тизләтүче көч булганнар... Менә шушы факторларны белми, өйрәнми торып, халкыбызның тарихын азмы-күпме объектив ачып бирә алуга мин ышанмыйм.

Тормышыбызга тирән үтеп кергән китап дигән могҗизага без шул кадәр ияләшкәнбез, аңа сулаган һава, эчә торган су кебек гадәти нәрсә итеп кенә карыйбыз. Бу бөек могҗизаны уйлап табу өчен кешелек дөньясына дистәләрчә мең еллар кирәк булган. Без ияләшкән басма китапка хәтле таш китап, агач китап, сөяк китап, тукыма китап—нинди генә китаплар булмаган. Мондый китапларны язу өчен күп вакыт, зур көч соралган, аларны куллану да җиңел булмаган. Китапны җиңеләйтү, аны язуны гадиләштерү, файдалануны җайлау өчен кешеләр гасырлар буе яңа ысуллар эзләгәннәр. Шул тырышлыклар нәтиҗәсендә алар папирус, пергамент һәм, ниһаять, кәгазь уйлап тапканнар.

Дөрес, мондый материалларга язылган китап та арзан булмаган. Урта күләмдәге китапны күчереп язу өчен айлар, еллар сарыф ителгән, ул зур игътибар, тырышлык сораган, авыр хезмәт саналган.

Кешелек тарихы алга атлаган саен информациягә, белемгә, аралашуга мохтаҗлык үсә барган. Кешеләр үзләренең ачыш-табышларын, тәҗрибәсен теркәп баруны җиңеләйтү юлларын эзли торгач, хәрефләр җыеп китап басу ысулын уйлап тапканнар. Шулай итеп китап басу барлыкка килгән һәм шул заманнардан китап үзе дә ике төрле исем алган: беренчесе—кулъязма китап, ә икенчесе—басма китап.

Китап басу өчен иң беренче төп шарт—язу, графика—бездә иң кимендә V–VI гасырларда ук булган. Китап басу өчен икенче төп шарт—халыкның китапка булган ихтыяҗы. Укый-яза белүнең киң таралуы өчен ул халыкта уку-укыту системасының гамәлдә булуы кирәк. Безгә билгеле: чын мөселман булу өчен кешенең укый-яза белүе мәслихәт саналган. Шуңа күрә ислам динен кабул итү белән бездә мәктәп-мәдрәсәләр барлыкка килгән. Мәктәп-мәдрәсәләрнең саны арта бару белән Болгарда, Казан ханлыгында китап язу белән шөгыльләнүчеләр күбәйгән.

Идел-Урал буйларында кулъязма китап ни хәтле киң таралмасын, аңа мохтаҗлыкны канәгатьләндереп бетерә алмаганнар. Безнең бабаларыбыз дин,

---

* Мәкалә "Китапка хитаб: Татар басма китабының 270 еллыгына багышланган фәнни-практик конференция материаллары" китабыннан (Казан: ТКН, 1994. – Б. 9–21.) кыскартып алынды.

сәүдә, илчелек эшләре белән Шәрекънең Бохара, Каһирә, Истанбул һәм Сәмәрканд кебек мәдәният үзәкләренә, Һиндстанга, Кытайга һәм гарәп илләренә еш йөреп торганнар, бу сәяхәтләрдән кульязма китаплар алып кайтканнар.

Хәреф җыеп басылган беренче татар китабын ачыклау, барлау максаты белән эзләнә торгач, 1612 елда Лейпцигта татар телендә басылган бер китапка тап булдым. Ул эчтәлеге белән татар теле грамматикасын, татарча-латинча, латинча-татарча сүзлекне эченә алган әсәр булып чыкты. Аның авторы— Лейпциг университетында төрки-татар телен укыткан профессор Иероним Мегисер (1555—1618) икән. Бу китапның ярты өлеше татар телен өйрәнү өчен басылган татарча текстлардан тора, алар һәм андагы сүзлекнең татарча өлеше гарәп хәрефләре белән татарча басылганнар. Ләкин мин моны беренче татар милли китабы дип санау ягында түгел. Ни өчен? Чөнки китап чит илдә басылган, авторы да чит ил кешесе. Ул Европада татар телен өйрәнү өчен чыгарылган, Европа укучылары арасында гына таралган. Дөрес, аның сүзлеген төзүдә татар кешесе дә катнашкан. Әмма, моннан чыгып кына, аны татар милли китабы дип атау бик үк дөрес булмас.

Беренче татар милли басма китабы 1722 елда, иске стиль белән 15 июльдә, Әстерханда басылып чыккан икән. Аның шактый кызык тарихы бар. 1722 елда Петр I Персиягә каршы яу белән чыга. Бу походның максаты Һинд океанына чыгу өчен юл ачу, бу юлдагы территорияләрне басып алу була. 106 мең кешелек гаскәр Төньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк Кавказга, Каспийның көньягына басып керә, Персиягә аяк баса. Яуга тупланган гаскәр яугирләренең 30 меңе, ә икенче чыганакларда күрсәтелгәнчә, 50 меңе татар солдатларыннан торган. Бу поход өчен көймәләр Казан янындагы Бишбалта бистәсендә эшләнгән. Аларны төзүчеләр, төзелеш өчен агач кисүчеләр татар кешеләре, татар лашманнары булган. Петр I, сугышлар җәелгән төбәкләрдә яшәүче мөселман халыклары арасында үзенә теләктәшлек табу йөзеннән, аларны алдау өчен "Манифест" яздыра һәм аны татар телендә бастырып, ул якта яшәгән татарлар, нугайлар, карачайлар, кумыклар, азәрбайҗанлылар, фарсылар арасында тарата. Билгеле булганча, бу чорда Шәрекъ илләре белән аралашу өчен дипломатия теле буларак татар теле кулланылган. Бу "Манифест"ны татар телендә басу өчен махсус басмаханә оештырыла. Ул көймәгә урнаштырыла. Шушы йөзмә басмаханәдә "Манифест" татар теленең югары стилендә басылып та чыга. Аны татарчага Петр I нең яшерен советында тылмач, соңыннан Рәсәйнең Иранда илчесе булып эшләгән Тәфкилев дигән бер татар зыялысы тәрҗемә итә. Аның текстын җыю өчен басмаханәгә грамоталы татар солдатлары җибәрелә. Биредә аларны хәреф җыеп китап басу серләренә басмаханәнең директоры Дмитрий Кантемир өйрәтә. Ә ул Петр I нең якын киңәшчесе, чыгышы белән кырым татары була.

Күреп үткәнебезчә, "Манифест"ны татар кешесе тәрҗемә итә, аның текстын басмаханәдә татар кешесе җыя, шрифтның рәсемнәрен дә Д.Кантемир ясый, типографиядә аны басучылар да татарлар була. "Манифест"та Петр I "Иран патшасы җирендә юлбасарлар күп, алар минем дустым Иран патшасына начарлыклар эшлиләр, менә шуңа мин аңа ярдәм итәргә булдым, шул максаттан бу хәрби походны оештырдым",—дип күз буйый. "Манифест" басылып чыккач, аны татар солдатлары безнең төбәкләрдә яшәүче халыклар арасында да тараталар. Димәк, бу "Манифест" татар укучысына да барып җитә. Шуңа күрә без бу "Манифест" басмасын татар басма сүзенең беренче үрнәге дип саныйбыз. Дөрес, шул ук вакытта ул урыс полиграфиясе продукциясе дә булып санала ала. Бу йөзмә басмаханәдә татар телендә башка китаплар басылуы хакында да мәгълүматлар бар, ләкин без хәзергә ул китапларны китапханәләрдә таба алмадык. XVIII гасырда Русиядә гарәп шрифтлары белән китап басу очраклары әле аз була.

1727 елда Төркиядә гарәп шрифтлары белән китап басу эшенә торекләр керешәләр. Безнең бабаларыбыз шушында чыккан беренче китаптан алып, барлык Төркия басмаларын да Идел буйларына алып кайтып торганнар. Ләкин бу юл белән генә уку йортларының һәм халыкның китапка булган ихтыяҗын канәгатьләндереп бетерә алмаганнар. Менә шуңа күрә безнең бабаларыбыз XVIII йөзнең урталарында ук үзләре китап басу, типография ачу эшенә керешеп карыйлар. Ләкин Русия законнары буенча урыс, гомумән, христиан булмаган халыкларга басмаханә ачарга, китап басарга рөхсәт ителмәгән. Татарларның пайтәхеткә язган үтенечләре җавапсыз кала биргән.

Татарларның Пугачев хәрәкәтендә актив катнашуын бик яхшы белгән Әби патша яңа шартларда татарларның бу үтенечләрен өзлексез кире кагып килү юньлегә илтмәячәген аңлый башлый; аларга типография ачарга рөхсәт итмәсә дә, берзаман үзе Петербургта Коръән бастыру эшенә керешә. Шулай итеп, татарларның авызын капламакчы була. Татарларга Коръән дә, уку китаплары да, башка төр китаплар да кирәк, шуңа күрә алар, бер Коръән белән генә чикләнмичә, Әби патша исеменә өзлексез "прошение"ләр язып торалар, үз кешеләрен җибәреп карыйлар. Ләкин Екатерина II аларга барыбер типография ачарга рөхсәт бирми.

Екатерина II вафат булгач, тәхеткә Павел I утыра. Татарлар аңа да мөрәҗәгать итәләр. Павел I Казанга килгәч, татар муллалары, зыялылары һәм сәүдәгәрләре аңа шул ук үтенеч белән керәләр. Бу үтенечне Бохара әмире, кыргыз-кайсак ханы да яклап чыккач, Павел I гә чигенергә урын калмый — 1799 елда татарларга Казанда бер типография ачарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була.

Ниһаять, шушы Указ нигезендә Казанга китап басу өчен шрифтлар, машиналар, башка төр җиһазлар кайтарыла. Ошбу эш белән Петербургта отставкадагы татар прапорщигы Габделгазиз Бурашев шөгыльләнә. Казанда беренче басмаханә — татар басмаханәсе ачылуы һәм бирәдә 1801 елда татар китабы басыла башлавы шушы фидакяр затның зур тырышлыгы һәм җитәкчелеге белән нык бәйләнгән. Бер-ике ел эчендә Г. Бурашев үз хисабына — вә нашир, вә типограф буларак — дистәгә якын китап бастыра. Алар арасында бик борынгыдан безнең халыкта популяр булган "Устуани китабы" (авторы — Мөхәммәд Устуани, 1607—1662), "Пиргули китабы" (авторы — Мөхәммәд Пиргули, 1538—1573), Аллаһыяр Суфиның "Сөбәтел-гаҗизин", мең еллар буенча татар мәктәбе дәреслеге саналган "Әлифба иман шарты белән" һәм башка әсәрләрне күрәбез.

Бу басмаханәгә Петербургтагы "Азиат" типографиясеннән Хәмзә Мамышев, Гали Рәхмәтуллин һ. б. осталар кайта. Алар — Г.Бурашев җитәкчелегендә Казанда XIX гасырның беренче яртысында дөнья күргән китапларның төп өлешен үз куллары белән җыйган, редакцияләгән, татар милли китабына юл ачкан каһарман китап осталары.

XIX гасырның иң ахыргы елларында Оренбург, Петербург һәм Казанда берәр татар типографиясе барлыкка килүгә карамастан, татарларга типография ачу 1905 елның 17 октябрь манифестына кадәр рөхсәт ителмәде. Манифест чыгу белән бер-ике елда Оренбург, Уфа, Петербург, Казанда бер-бер артлы татар басмаханәләре барлыкка килә башлый. XX йөз башында бары бер Казанда гына да дистәдән артык татар басмаханәсе ачыла. Әмма ихтыяҗны бу типографияләр канәгатьләндерә алмый. Алар белән беррәттән Казандагы барлык урыс хосусый типографияләре дә XX йөз башында татар наширләре заказларын үтәү белән мәшгуль булалар. Болар өстенә татарлар яшәгән күп кенә төбәкләрдә (Әстерханда, Троицкида, Томскида, Самарада, Омскида, Семипалатинскида, Стәрлетамакта һ. б. шәһәрләрдә) дә татар типографияләре, нәшриятлары барлыкка килә. Татар басмачылыгының тулы географиясе әле тулысынча өйрәнелмәгән. XX йөз башында татар телендә газета-журнал басу

Новосибирскида, Магаданда, Донбасста һәм Находкада да булуы билгеле.

Әгәр XIX гасырның урталарында 40–60, гасыр ахырында 60–170 әр татар китабы басылып килсә, 1905 елгы революциядән соң елына 400–500 әр исемдә китап дөнья күреп тора. Инде XIX йөз ахырында ук татар китабының гомуми тиражы 2 миллионга җитә, ә XX йөз башында бу күрсәткеч 3 миллионга якынлаша.

Революциягә кадәр чыккан татар китабының исемлеге, безнең исәпләүләр буенча, 15 мең данәгә якынлаша. Инде күреп үткәнебезчә, татар китабының үсү мөмкинлеге гаять зур булган, аның алдындагы чикләүләр шул хәтле рәхимсез, киртәләр зур булмаса, бу күрсәткечнең тагын да югарырак үрләячәгенә ышанмый мөмкин түгел.

Күпме соң ул 15 мең китап? Нәтиҗә ясап әйткәндә, революциягә кадәр татар китабы үзбәк, казакъ, азәрбайҗан, төрекмән, нугай һәм кумыкларның һәммәсе чыгарган китапларга караганда утыз мәртәбә артык булып чыга. Русиядә чыккан китаплар исемлеге буенча татар китабы урыс китабыннан тыш, бары латыш китабыннан гына калыша, ә тиражы буенча аннан да алда тора.

Татар китабы күп фәннәрне эченә алган, эчтәлеге белән күпкырлы, энциклопедик бай булган. Татар китабының күп басылуыннан без милләтебездә грамоталылыкның ни дәрәҗәдә югары торганлыгын да билгели алабыз. Революциягә кадәр үк чит ил сәяхәтчеләре һәм урыс галимнәре татарлар укыйяза белү буенча урыслардан, хәтта Австро-Венгрия империясендәге халыклардан да өстен торалар, дип язып калдырганнар икән, моның хаклыгын татар китабы басылу масштаблары да ачык раслый.

Татар китабы эчтәлегенең энциклопедик күпкырлы булуыннан чыгып, без татар укучыларының белем дәрәҗәсен дә шактый төгәл билгели алабыз. Милли китаплар аша татар укучысы дөнья фәненең төп уңышлары, дөнья халыклары тарихы, кешелек тудырган рухи байлыклар белән шактый ук яхшы таныш булган.

Милли басма сүзебезнең, өч гасырга якын тарихы, бай мирас чыганагы, халкыбыз тарихының көзгесе булуына карамастан, моңа кадәр игътибардан читтә калуы гаять аяныч хәл. Язу, әлифбалар алмаштыру аркасында, басма сүзебезнең кадере бетте, аның күп өлеше көлгә әйләнде, мәңгегә юкка чыкты, яндырылды, җиргә күмелде, суга салынды. Татар халкының хәтере кыскара баруы милли мирасыбыз хәзинәсе булган китапка карашыбызга, аңа булган салкын һәм саксыз мөнәсәбәткә дә нык бәйләнгән.

Милләтне милләт итеп саклап калыйк, аны үлемнән коткарыйк дисәк, без милли китабыбызны коткару өчен дә көрәшергә тиешбез. Чөнки ул—халыкның милли аңын саклаучы, уятучы, аны тәрбияләүче гаять көчле корал да.

*Котлыйбыз!*

# КҮПКЫРЛЫ ИҖАТЧЫ



Әнәс Хәсән улы Хәсәнов 1935 елның 23 июнендә Татарстан АССРның Спас (элеккеге Куйбышев) районы Көек авылында туган. 1954 елда Куйбышев педагогия училищесын, 1959 елда Казан педагогия институтын тәмамлаган.

1959—1972 елларда ул Казан телевидениесе студиясендә башта балалар өчен тапшырулар редакциясендә редактор, өлкән редактор, аннары иҗтимагый-сәяси программаларның баш редакторы булып эшли. 1972—1974 елларда Ленинград югары партия мәктәбенең матбугат, телевидение, радио бүлегендә укый.

Партия мәктәбен тәмамлап кайткач, 1984 елга кадәр өлкә комитетының мәдәният бүлегендә инструктор булып хезмәт итә. 1984—1988 елларда—ул Татарстан китап нәшриятының баш редактор урынбасары, 1988—1990 елларда "Татарстан" ("Татарстан коммунисты") журналының җаваплы секретаре.

1991 ел башында Ә. Хәсәнов Татарстан Югары Советы секретариатының өлкән консультанты, ә берничә айдан Татарстан Республикасы Президентының матбугат үзәге җитәкчесе итеп билгеләнә. Бирелә сигез елдан артык эшләгәннән соң, яше олыгаю сәбәпле, Ә. Хәсәнов Президентның матбугат архивы мөдире булып күчә. Ул әле дә шул эшендә.

Әнәс Хәсәнов — күпкырлы иҗатчы. Телевидение студиясендә эшләгән елларында ул балалар һәм яшүсмерләр өчен "Тылсымлы телевизор күрсәтә", "Синең беренче китапларың", "Әйдәгез, искә төшерик", "Безнең календарь", "Матурлык дөньясында", "Мәктәп программасына ярдәмгә", "Әйберләр каян килә", "Язучы сүзе" кебек дистәләрчә тапшырулар цикллары оештырып, аларда яшь буынны әхлакый, эстетик, физик һәм хезмәти тәрбия проблемалары күтәрә.

1997 елда Түбән Кама шәһәр драма театры Ә. Хәсәновның "Әти диясем килә" исемле пьесасын сәхнәләштерә.

Ә. Хәсәнов киносценарист буларак та билгеле. Аның сценарийларына нигезләнеп "Тайгада шәһәрләр үсә" (1964), Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиевкә багышлап "Мин кешеләрне яратам" исемле татар һәм рус телләрендә тулы хронометражлы төсле документаль фильмнар төшерелгән.

Әнәс Хәсәнов шулай ук тәрҗемә өлкәсендә хезмәт куйган язучы. В. Софроновның "Пешекче", А. Макаенокның "Туган туфрак", В. Черныхның "Кулда власть булгач", Г. Данаиловның "Вөҗданың ни әйтер" исемле пьесаларын уңышлы тәрҗемә иткәне өчен Ә. Хәсәнов 1978 елда Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Дипломы белән бүләкләнә. Илебезнең төрле киностудияләрендә иҗат ителгән егермедән артык нәфис фильмны татар теленә тәрҗемә итеп, республикабыз экраннарына чыгарды.

Язучы Р. Мостафин белән берлектә ул "Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев" исемле китап язды һәм аны үзе үк татарчага тәрҗемә дә итте. Шушы хезмәтләре өчен алар республика журналистлары берлегенең Х. Ямашев исемендәге бүләгенә лаек булдылар.

Профессиональ тәрҗемәче булу белән бергә, ул үзе дә киң мөстәкыйль иҗат белән шөгыльләнә: "Яшьли табылган бәхет" исемле документаль повесть, нәниләр өчен атап язылган "Бабай" исемле проза әсәре әнә шуңа мисал булып тора. Республика газета-журналларында аның әледән-әле шигырьләре, хикәяләре дөнья күреп килә. 2003 елда аның "Җырым — ал җилкән" исемле шигырьләр китабы укучылар кулына барып иреште.

1980 елдан Ә. Хәсәнов Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Ул "Хезмәттәге батырлыгы өчен" медале, СССР телевидение һәм радио комитетының, Татарстан Республикасының мактау грамоталары белән бүләкләнгән. Аңа Татарстан Республикасының 1 классны баш дәүләт киңәшчесе дәрәҗәсе бирелгән, ул Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру Академиясенең мөхбир-әгъзасы итеп сайланган. Мәдәният һәм матбугат өлкәсендәге уңышлары, халыклар арасында дуслык һәм хезмәттәшлекне ныгытуга керткән өлеше һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Ә. Хәсәнов 2001 елда Дуслык ордены белән бүләкләнде.

Соңгы елларда Ә. Хәсәнов Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиевнең "Татарстан тотрыклы үсештә" исемле биш томлыгын нәшер итү өстендә күләмле эш алып бара.

Ә. Хәсәнов 1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# УЙЛАТА ДА, ЕЛМАЙТА ДА...



"Әй катлаулы гомер юллары..." Шагыйрә Мәрзия Фәйзуллина "Тик синә гына" (2004) исемле китабының бер бүлеген әнә шулай атаган. Күңелендә шигырь уты дөрләсә дә, шигърияткә катлаулы, урау юллар аша килә ул. Хәер, гомерен иҗатка багышларга теләгән, әдәбиятка бирелгән кешегә, нинди генә тармакта эшләсә дә, язылачак әсәрләренә нигез—күңел байлыгы,—бәлки, әнә шул тормыштан алган тәҗрибәләр аша да киләдер әле ул. Бер генә нәрсә дә юктан бар була алмый. Ләкин инде барны, булганны үстерү өчен максатчанлык, тырышлык кирәк.

1930 елның 11 июнендә Арча районы Шушмабаш авылында крестьян гаиләсендә туган кыз урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казанда төрле оешмаларда эшли. 1946-1956 елларда—халык судында секретарь, милиция бүлегендә инспектор, Татарстан китап нәшриятында бухгалтер булып эшләгәннән соң, балалар өчен "Салават күпере" (1955) исемле китабы дөнья күргән М. Фәйзуллина, нәниләр дөньясын тагын да ныграк аңлар, аларга якынрак булыр өчен 1956 елда балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә урнаша. Әйтергә кирәк, аның бу гамәле матур нәтиҗәләр дә бирә башлый, иҗаты күзгә күренеп үсә, активлаша, нәниләр өчен бер-бер артлы "Чәчәкләр сәгате", "Ике йөрәк", "Зур дулкыннар", "Гөлнар мәктәпкә бара" исемле шигырь китаплары дөнья күрә.

Әдәбият серләрен ныграк үзләштерү нияте белән ул читтән торып М. Горький исемендәге Мәскәү Әдәбият институтына укырга керә (1958-1964) һәм диплом эше итеп "Балалар өчен шигырьләр" кульязмасын тәкъдим итә. 1963-1965 елларда М. Фәйзуллинаның Детгиз, "Малыш" нәшриятларында рус телендә "Цветочные часы", "Стихи", "Пропала кошка" исемле өч китабы чыга. Тәнкыйтьче В. Дементьевның "Октябрь" (1963 ел, № 11), балалар язучысы С. Баруздинның "Наш современник" (1964 ел, № 9) журналларында басылган язмаларында, шулай ук күренекле балалар шагыйрәсе Агния Барто РСФСР Язучыларының II съездында ясаган чыгышында М. Фәйзуллина иҗатына югары бәя бирәләр.

Чыннан да, М. Фәйзуллина шигърияткә, бигрәк тә балалар шигъриятен баетуга үзеннән шактый өлеш керткән шагыйрә. Нәниләрне уйлата да, елмайта да аның шигырьләре. Бер караганда гади генә тоелсалар да, тирән мәгънә, балаларга кирәкле булган тәрбия чарасы алымнары бар ул шигырьләрдә.

Шулчак бал корты безелдәп:
"Чәчәкне ө-з-ззз-мә!—диде.—
Сезгә тәмле бал җыярга
Кирәк ул без-з-з-гә",—диде.

М. Фәйзуллинаның кайбер әсәрләре рус, украин, үзбәк һәм башка телләрдә дә басыла. Балалар әдәбиятындагы хезмәтләре өчен ул Татарстан хөкүмәтенең Мактау грамотасы (1980) белән бүләкләнә. 1965 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Редакция коллективы юбилярларны олы бәйрәмнәре белән котлый, аларга озын гомер, иҗат уңышлары тели.**

## «Казан утлары» архивыннан



Сәнгать әһелләреннән бер төркем: сулдан уңга— Айрат Арсланов, Габдулла Шамуков, Фәйзи Йосыпов, Фәхри Насретдинов. Алма-Ата шәһәрендә гастрольдә. 1962 ел.



Язучы Локман Бадыйкшин һәм шагыйрь Леонид Топчий. 1965 ел.



Татар язучылары Гариф Ахунов (арттагы рәттә, сулдан бишенче), Мәрзия Фәйзуллина һәм Габдрахман Минский (алгы рәттә, сулдан өченче, дүртенче) шахтерлар арасында. Ворошиловград өлкәсе (Донбас). 1972 ел.



*Казан университетының татар бүлеге каршындагы әдәби берләшмә утырышыннан соң алынган фоторәсем. Алгы рәттә, сулдан уңга — Нил Юзиев, Гомәр Бәширов, Равил Фәйзуллин (берләшмә җитәкчесе), Шамил Маннапов... Артта, уңнан беренче Әдхәт Синугыл. 1964 ел.*



*Скульптор Фарис Фәсхи. 2001 ел.*



*Шагыйрь Мөнир Мазуновның "Татарстан кооператоры" газетасының мөхәррире булып эшләгәндә хезмәттәше, журналист Ренат Галәвин белән төшкән фоторәсеме. Казан. 1968 ел.*

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Әнвәр Хәйри



Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллин (Әнвәр Хәйри) 1947 елның 2 декабрендә Татарстанның Аксубай районы Шәрбән авылында туа. 1966 елда Норлат районының Колбай-Мораса урта мәктәбен тәмамлый. 1967-1973 елларда Казан университетының тарих-филология факультетында укый. Аңа мәктәптә һәм университетта уку елларында вакытлыча төрле эшләрдә төрле вазифалар башкарырга туры килә: урман кисүче, тракторчы, мәктәп укытучысы, музей хезмәткәре... Югары белем алганнан соң, 1974-91 елларда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә хезмәт итә. 1991-95 елларда "Мирас" журналында җаваплы эшләрдә эшли. Бер ел чамасы Казандагы "Синдикат" акционерлар җәмгыятендә "Рухи яңарыш" фонды директоры булып эшләгәннән соң, 1996 елда Татарстан Милли китапханәсенә эшкә чакырыла һәм бүгенге көнгәчә анда сирәк китаплар һәм борынгы кулъязмалар бүлегендә баш фәнни хезмәткәр булып хезмәт итә. 1970 елдан башлап, төп эше белән бер үк вакытта: Казан дәүләт университетында, Казан дәүләт педагогия университетында, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында, Татар укытучылар белемен күтәрү институтында һәм башка уку йортларында гарәп телен, иске татар телен, ислам дине тарихын, халык медицинасы һәм халык педагогикасы тарихын укыта.

Ә. Хәйри—бөтен табигате белән фән кешесе; ул—текстолог та, тәрҗемәче дә, язучы да. XIX—XX гасыр татар мәгърифәтчеләренең һәм әдипләренең күптөрле китаплары аның тәрҗемәсендә басылып чыкты. Аларның саны берничә дистәгә җитә. Авторның үз китаплары өчәү: Алар—"Шәһри Бану—Шәрбән кыйссасы", "Ислам дине бәйрәмнәре", "Ризаэддин Фәхреддин әсәрләрендә тәрбия—әхлак мәсьәләләре". Ш. Мәрҗанинең "Мөстафадел—әхбар..." (1989), Р. Фәхреддиннең "Болгар вә Казан төрекләре" (1993), шул ук галимнәрнең хәзерге телгә күчерелгән әсәрләреннән—"Ислам дине—нинди дин?", "Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр", "Нәсыйхәт—1", "Нәсыйхәт—2", "Нәсыйхәт—3", "Тәрбияле бала", "Әһле гыяль", "Шәкертлек әдәпләре", "Укыту кагыйдәләре", "Тәрбияле ана", "Тәрбияле хатын", "Гаилә"; шуларга өстәп, К. Насыйри, М. Бигиев, З. Камали, Г. Ибраһимов, Г. Акыш, Г. Сөләйман, Низаметдин, М. Йортыши, М. Хөсәен һәм башка мәгърифәтчеләрнең һәм әдипләрнең хезмәтләре Ә. Хәйри тарафыннан тәрҗемә ителеп матбугатта басылдылар.

Соңгы вакытта Әнвәр Хәйри милли тарихыбызга караган иң борынгы һәм иң беренче язма чыганак булып торучы—922 елда Идел буе Болгар дәүләтенә ислам динен рәсми дәүләт дине итеп игълан итәргә килгән илчелекнең җаваплы сәркәтибе Әхмәд Ибне Фазланның сәяхәтнамәсен төп нөсхә кулъязмасының факсимель күчермәсеннән турыдан-туры борынгы—классик гарәп теленнән бүгенге татар һәм рус телләренә тәрҗемә итеп, фәнни эшкәртеп матбугатка әзерләү белән мәшгуль.

Әнвәр Хәйри, шулай ук, актуаль темаларга гыйльми очерклар һәм публицистик мәкаләләр язу белән дә шөгыльләнә, Татарстан радиосының "Балкыш" тапшыруында һәм "Яңа гасыр" радиосында даими рәвештә тәрбия—әхлак мәсьәләләренә багышланган чыгышлар ясый.

1991 елда Татарстан ССР Югары Советы Указы белән мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен Әнвәр Хәйригә "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

1999 елда күпьеллык нәтиҗәле фәнни—тикшеренү һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге өчен ул "Татарстанның атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исемгә лаек булды.

2004 елда милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен аңа Республиканың Каюм Насыйри исемендәге премиясе бирелде. Шул ук елны ул Халыкара Мәгълүматләштерү академиясенең мөхбир әгъзасы итеп тә сайланды.

Татарстан Язучылар берлеге 2005 елның 31 мартында уздырылган утырышында, Кабул итү Коллегиясенең карарын раслап Әнвәр Хәйрине Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итте.

---

*Безнең календарь*

## ТУГРЫЛЫК

Г. ХАЛИТНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Гомере буе әдәбият фәненә хезмәт иткән, бөтен ижади эшчәнлеген әнә шул олуг максатка юнәлткән татар галимнәренең берсе ул—Гали Халит. Аның әдәбият тарихына һәм теориясенә караган күп санлы хезмәтләре, әдәбиятыбыз классиклары Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал, М. Фәйзи, Һ. Такташ ижатларына багышланган тирән эчтәлекле мәкаләләре озак еллар буена әдәбият сөючеләрнең игътибарында булачак.

Гали Халит (Гали Мөхәммәтгали улы Халитов) 1915 елның 26 июнендә Татарстанның Тәтеш районы Үтәмеш авылында туа. Авылда башлангыч белем алганнан соң, 1930 елда Казанга килеп, педагогия техникумында, аннары педагогия институтының тел-әдәбият факультетында укый. Институтны тәмамлагач 1942 елның көзенә кадәр Арча педагогия училищесында әдәбият укыта.

1942 елның октябреннән башлап Гали Халитнең язмышы озак еллар буе Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты белән бәйле. Башта әдәбият секторына житәкчелек итә, ә 1966 елдан ул шул ук секторның өлкән гыйльми хезмәткәре вазифасын башкара. 1948 елда Г. Халит М. Гафури ижаты буенча кандидатлык диссертациясе, ә 1968 елда "Татар әдәбиятында ижат методы проблемалары (1905-1932)" дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

Тел, әдәбият һәм тарих институтында озак еллар эшләү дәверендә Г. Халит әдәбият тарихын системалы рәвештә тикшеренү алып бара. Аны иң беренче чиратта XX йөз башы татар әдәбияты кызыксындыра. Шулай ук, ул әлеге чорда татар әдәбияты мәйданында күренекле урын тоткан әдипләрнең ижади үзенчәлекләрен өйрәнү буенча нәтижәле эшли.

Илленче еллардан башлап Г. Халит татар әдәбиятының совет чорын, бигрәк тә егерменче еллардагы әдәби хәрәкәтне өйрәнүгә игътибарын юнәлтә. Г. Халитнең татар әдәбияты тарихына багышланган мәкаләләре үзәк матбугатта, СССР Фәннәр Академиясенең М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты хезмәтләрендә еш басыла.

Г. Халитнең "Халык шагыйре Тукай" (1939), "Мәжит Гафури ижаты" (1941), "Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре" (1948), "XX йөз башында татар әдәбияты" (1954), "Шагыйрь, чор, герой" (1971), "Яңа гасыр поэзиясе" (1979), "Тукай и его современники" (1966), "Герои, рожденные революцией" (1967), "Поэзия дерзаний" (1980) һ. б. китаплары бар.

Гали Халит Татарстанның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

1993 елда вафат булды.

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## КҮЗ ЯШЬЛЕ ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

Ватан сугышы тәмамлануга 60 ел. Инде күп гомер үтеп, буыннар алышынса да, бездә 9 май көне зур бәйрәм—Җиңү көне итеп үткәрелеп килenә. Бу бәйрәм Россиядә быел аеруча зурлап, бөтенхалык бәйрәме итеп билгеләнеп үтелде. Тантаналарда катнашу өчен Мәскәүгә дөньяның төрле кыйтгаларыннан иллеләп ил башлыгы килде. Бәйрәмнең үзәк каһарманнары, әлбәттә, сугыш ветераннары булды.

***

Бәйрәм тантаналары Татарстанның һәр шәһәрендә, бистәсендә һәм авылында шаулап узды. Сугыш һәм тыл ветераннарына иң җылы сүзләр әйтелде, май аеның матур чәчәкләре һәм кыйммәтле бүләкләр бирелде.

Тантаналарның зурысы, әлбәттә, башкалабыз Казанда узды. Президент Минтимер Шәймиевнең Казан Кремлендә республика ветераннар оешмалары активистларына Татарстан Республикасының "Фидакарь хезмәт өчен" медален тапшыруы шуларның берсе булды. Бүген республикабызда 25 меңнән артык Ватан сугышы ветераны яши. Шулай ук сугыш чоры авырлыгын кичергән тыл хезмәтчәннәре дә шактый әле. Бу иҗтимагый оешмалар аларның мәнфәгатьләрен кайгырту белән шөгыльләнә. Болар—ветераннар (пенсионерлар), "Татарстан Геройлары", сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары, Бөтенроссия ветераннар-инвалидларның республика бүлеге һ. б. Аларның житәкчеләре—Социалистик Хезмәт Герое И. Мостюков, Н. Тимашова, генерал-майор Ә. Юлашев, Ә. Камалов Президент кулыннан бүләкне беренчеләрдән булып алдылар.

Бу тантанада Президент аппараты житәкчесе Ю. Камалтынов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков катнашты.

***

"Казан Кремле" музей-тыюлыгында, элек юнкерлар училищесы урнашкан бинада ике елга сузылган әзерлек эшләреннән соң Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы ачылды.

Аны ачуда Президент Минтимер Шәймиев катнашты, 407 квадрат метр мәйданда сипләү эшләре алып баруда зур ярдәм иткән "Нижнекамскнефтехим" берләшмәсенең генераль директоры В. Бусыгинга, республикабызның Милли музее житәкчесе Г. Мухановка, әлеге изге эштә катнашкан башка оешмаларга рәхмәт белдерде.

Музей-мемориал экспозициясенең нигезен Милли музей материаллары, "Кар десанты", "Ватан" оешмалары, "Хәтер китабы" редакциясе тапкан табылдыклар, Ватан сугышы ветераннарының шәхси архивында сакланган хатлар, листовкалар, хәрби киемнәр, орден, медальләр һ. б. тәшкил итә. Һәм, әлбәттә инде, экспонатларның күбесе—сугыш мәхшәрен үткән якташларыбыз М. Сыртланова, М. Девятаев, Г. Сафиуллин, М. Җәлил, Ф. Кәрим һ. б. тормышы турында сөйләүче истәлекләр.

***

Бәйрәм тантаналарының иң истәлеклесе, билгеле, 9 майда Ирек мәйданында узган хәрби парад булды. Казан гарнизоны частьләре, хәрби училищелар курсантлары марш астында узды. Тантанада катнашучыларны Җиңүнең 60 еллыгы белән Президент М. Шәймиев тәбрик итте. Бәйрәм трибунасында Премьер-министр Р. Миннеханов, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Президент аппараты житәкчесе Ю. Камалтынов, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, республиканың башка житәкчеләре, хәрби эшлеклеләр булды.

Аннары бәйрәм Җиңү паркында дәвам итте. Бирегә тантаналы шартларда Дан аллеясы, Җиңүне якынайту өчен тылда зур хезмәт куйган хатын-кызларга багышлап һәйкәл ачылды. Ә кичке сәгать 10 да башкала күген 60 артиллерия залпы, фейерверклар балкытты.

## ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

Инде икенче ел 26 апрель—Тукай туган көн—республикабызда Туган тел бәйрәме итеп уздырыла. Шул уңай белән

Татарстан Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева тәбрикнамә игълан итте. Анда болай диелә:

"Туган тел—буыннар арасындагы һәм гасырлар аша халыкны бербөтен итеп туплый торган җанлы һәм какшамас бәйләнеш. Тел халыкның тарихын, аның мәдәниятен, әдәбиятын һәм сәнгатенең үсеш юлын чагылдыра. Телгә мөнәсәбәт тулаем җәмгыятьнең һәм һәр кешенең белем һәм әхлакый өлгергәнлек дәрәҗәсе турында сөйләүче күрсәткечләрнең берсе булып тора.

Соңгы елларда Татарстан Республикасының барлык халыклары телләренә ярдәм һәм аларны үстерү буенча икенче дәүләт программасы тормышка ашырыла. Әлеге программаның төп максаты—туган телне саклау, шулай ук, дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләрен үстерү өчен шартлар тудыру. Татарстан Республикасы Хөкүмәте җәмгыятьнең телләр культурасын үстерүгә, милли-мәдәни байлык буларак телгә цивилизацияле мөнәсәбәт булдыруга төрле яклап ярдәм итә.

Борынгы башкалабыз Казанның 1000 еллыгына әзерләнгән көннәрдә без горурлык хисе белән туган ягыбыз территориясендә телләргә карата сабыр һәм түземле мөнәсәбәт тәрбияләү өчен күп көч куйган, тел белгечләре-галимнәр һәм тел-әдәбият укытучылары тырышлыгы белән бүген дә үз традицияләрен дәвам иттерүче Казан лингвистика мәктәбе казанышларын искә алабыз. Тупланган бу тәҗрибә мәдәниятләрнең бер-берсенә тагын да тирәнрәк үтеп керүенә, Татарстанның Россия төбәкләре һәм чит илләр белән хезмәттәшлеген киңәйтүгә ярдәм итә.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән барлык татарстанлыларны—фән һәм мәдәният эшлеклеләрен, әдипләрне, уку йортларында укучылар һәм укытучыларны һәм аларның ата-аналарын бу матур бәйрәм—Туган тел көне белән тәбрик итәм. Бу көн телләрнең үсеше һәм чәчәк атуы өчен көчләребезне берләштерү, мәдәни күптөрлелекне, туган җиребездә тынычлыкны, татулыкны саклау һәм бер-беребезне ихтирам итү символына әйләнсен!"

### ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган Шигърият бәйрәме быел Туган тел бәйрәме буларак та республикабыз күләмендә зурлап үткәрелде. Шушы уңайдан мәктәпләрдә, мәдәният сарайларында, театрларда, музейларда, күргәзмә залларында күп төрле чаралар оештырылды. Тукайның туган көне татарлар күпләп яшәгән чит төбәкләрдә дә билгеләп үтелде.

26 апрель көнне иртән бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләре Яңа Бистә зиратында Г. Тукай һ. б. күренекле шәхесләрнең каберләрен, шулай ук үзәк мәдәният һәм ял паркында Һ. Такташ, Г. Камал, Ф. Әсгать, Ш. Әхмәдиев каберләрен зиярәт кылды. Аннары М. Җәлил, Г. Державин, М. Горький һәйкәлләренә чәчәк салынды. Башкалабыз үзәгендәге Г. Тукай һәйкәленә чәчәк салуда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, республиканың башка җитәкчеләре, халык депутатлары катнашты.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда оештырылган төп тантанада сәламләү сүзе белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин чыкты, Рәссам З. Гыймаев, шагыйрь Р. Мингалим һәм композитор Ш. Шәрифуллинга Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелү турында Татарстан Президенты Указын игълан итте. Яңа лауреатлар исеменнән рәссам З. Гыймаев чыгыш ясады.

Шигъри бәйрәмне күренекле шагыйрь Р. Гаташ алып барды. Анда танылган каләм әһелләре Ш. Галиев, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин, Х. Әюп, М. Мирза, А. Хәлим (Чаллы), Л. Шагыйрьҗан, Ф. Гыйззәтуллина, С. Гәрәева, К. Булатова (Әлмәт), И. Гыйләҗев (Азнакай), Р. Гозәеров (Алма-Ата), Н. Алешков (Чаллы), С. Муллагали, Л. Газизова, Ф. Тарханова, Н. Сафина, Л. Лерон, Р. Аймәт, Х. Бәдигый, Л. Янсуар, Л. Гыйбадуллина, Т. Алдошин һ.б.лар үзләренең шигырьләрен укыдылар. Тантанада күренекле сүз остасы А. Арсланов, җырчылар З. Сәхәбиева, Р. Маликов, Р. Сәхәбиев, И. Биктаһиров, А. Габдинов, скрипкачы М. Әхмәтов, баянчы К. Сатиев чыгыш ясады.

Шигърият бәйрәмендә Татарстан Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, мәдәният министры И. Тарханов, Казан шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары Ә. Тутаева, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р. Вәлиев катнашты.

Бәйрәмнең икенче өлеше тулаем Туган телгә багышланган иде.

Соңгы елларда Г. Тукайның туган көне Балтач районында да киң билгеләп үтелә башлады Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин җитәкчелегендә бер төркем каләм әһелләре бөек шагыйребезнең Сасна Пүчинкәсе зиратында җирләнгән әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберенә чәчәкләр салды, шигърият сөючеләр белән очрашуларда катнашты.

Күп еллардан килә торган гадәт буенча, Шигърият бәйрәме эстафетасын 27 апрельдә Г. Тукайның туган төбәге Арча районы кабул итте. Казаннан килгән бер төркем әдипләр район үзәгендә, Кушлавыч авылында булдылар һәм, әлбәттә, Тукай-Кырлайдагы музей-йорт алдында үткәрелгән шигъри митингта катнаштылар.

### БЕР МЕҢ КУНАК КИЛӘ

24 июньдә Кол Шәриф мәчетен ачу тантанасы була. Аны ачуда дөньяның төрле почмагыннан 1 мең кунак катнаша алачак. Диндәшләребезнең калганнары исә республиканың баш мәчетендәге вакыйгаларны Ярминкә мәйданында зур монитордан карап тора алачак. Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхакый ТР мөселманнарының Диния нәзарәте пленумында әнә шулай дип хәбәр итте.

ТР мөселманнарының Диния нәзарәте Кол Шәриф мәчетен ачу тантанасына мөселман дәүләтләреннән (Төркия, фарсы култыгы илләре) рәсми вәкилләрнең, БДБ илләре һәм Россия мөфтиләренең килүен көтә. Кунаклар Чаллыда, Әлмәт, Түбән Кама, Болгар һәм Чистай шәһәрләрендә күренекле урыннар һәм бирердәге халыкның тормыш-көнкүреше белән танышачак. Алар Казанның мөселман уку йортлары биналарына урнаштырылачак.

### ӘТИСЕ БҮЛӘГЕН КЫЗЫ АЛА

2 нче Удар армиянең ветераннар советы исеменнән әлеге армиянең "Отвага" газетасы редакциясендә эшләгәндә каләме белән дә, корал белән дә фашистларга каршы көрәшкәне өчен патриот-шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилгә биреләсе "2 нче Удар армия ветераны" дигән Мактау билгесе аның кызы Чулпан Җәлиловага тапшырылды.

Герой-шагыйрьнең 100 еллыгын каршылауга багышланган чара Мәскәүнең Советлар Союзы Маршалы Л. Говоров исемендәге 167 нче мәктәбендә узды. Монда бернечә ел инде 2 нче Удар армиянең Дан музее эшли. Анда Муса Җәлилгә багышланган экспозиция аерым урын алып тора.

Очрашуда Мәскәү шәһәре татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, генерал-полковник Рәсим Акчурин, "Җәлил Мәскәүдә" дигән юбилей җыентыгын әзерләү буенча эш төркеме әгъзасы Шамил Кашшаф һ. б. катнашты.

### "ЯҢА СӘЙЯРЧЕЛӘР" МӘСКӘҮДӘ

Мәскәүдә, Композиторлар йортының Зур залында Казанның 1000 еллыгына багышлап "Яңа сәйярчеләр" ("Новое передвижничество") фестивале кысаларында Татарстан Композиторлар берлеге рәисе, халыкара конкурслар лауреаты, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, композитор Рәшит Кәлимуллинның иҗат концерты узды.

Концерт алдыннан Россия Композиторлар берлеге Рәисе Владислав Козенин, сәнгать белгече, Мәскәү консерваториясе профессоры Всеволод Задерацкий, Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Алмаз Фәйзуллин, Мәскәү төбәге Татар милли-мәдәнияте мохтарияте президенты Рәсим Акчурин чыгыш ясады.

Композитор Рәшит Кәлимуллин әсәрләре төрле фестивальләрдә еш яңгырый. Күп кенә әсәрләре тәүге тапкыр танылган чит ил музыкантлары тарафыннан башкарылды. Кыскасы, дөнья күләмендәге көебезне, мәдәниятебезне халыкка танытучы, пропагандалаучы булып тора ул. Әлеге концерт программасы композиторның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләреннән төзелгән иде.

Концертта Татарстанның халык артисты Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге "La Primawera" оркестры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфия Җаппарова җитәкчелегендәге "Хыял" хоры, кларнетчы Артур Мөхәммәтшин һәм Татарстанның халык артисты Мөнир Якупов та катнашты.

### МӘСКӘҮДӘ—ТАТАР ҖЫРЫ ФЕСТИВАЛЕ

Мәскәүнең "Кузьминка" өлкә сәнгать йортында "Туган як моңнары" дип аталган татар җыры фестивале үткәрелде. Анда Мәскәү, Екатеринбургтан, Татарстан һәм Чуашия республикаларыннан, шулай ук Россиянең башка төбәкләреннән килгән коллективлар катнашты.

Быелгы фестиваль Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 60 еллыгына багышланган иде. Анда халкыбызның яраткан җырлары, сугыш еллары, тынычлык темасына язылган әсәрләр яңгырады.

### СҮЗ ОСТАЛАРЫ ЯРЫШЫ

Казанның Габдулла Тукай исемендәге музеенда нәфис сүз осталарының V республика конкурсына йомгак ясалды. Арча педагогия көллиятенең I курсы студенты Данияр Хәбриев, шулай ук Тәтеш, Алабуга һәм Бөгелмәдән килгән югары сыйныф укучылары Виолетта Федотова, Ирина Митрофанова һәм Илмир Әхмәтовлар җиңүчеләр булып танылды һәм премияләргә лаек булды.

Быел ярышта республикабызның 38 районы һәм шәһәреннән 5 яшьтән 55

яшькә кадәрге 150 дән артык кеше катнашты,—диде жюри рәисе, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе өлкән укытучысы Флера Хәмитова.—Быелгы бәйге Казанның меңьеллыгына һәм Бөек Жиңүнең 60 еллыгына багышлап үткәрелде.

### АРХИВЛАР ЖУРНАЛЫНЫҢ ЯҢА САНЫ

"Гасырлар авазы—Эхо веков" фәнни-документаль журналының чираттагы саны дөнья күрде. Ул Жиңүнең 60 еллыгына багышланган рубрика белән ачыла. Монда әле күптән түгел генә яшерен саналган архив документлары һәм шул чорда яшәүчеләрнең, шаһитләренең хатирәләре нигезендә республикабызның сугыш елларындагы тормышы тасвирлана.

Тормыш юллары Татарстан белән бәйле Советлар Союзы маршаллары Л. Говоров, В. Чуйков, И. Якубовский хакындагы язмалар аеруча игътибарны жәлеп итә. Мәжмугада акдемик Индус Таһировның 1991 елны Татарстандагы август вакыйгаларына багышланган язмасының ахыры бирелгән. Кытайдагы Россия эмигрантларының, XX йөз башында Урта-Көнчыгыш Азиядәге төрки-татар мөһажирләренең тормышы, беренче татар операсы "Сания" турындагы язмалар да шактый кызыклы.

Бу санда кушымта рәвешендә Россия дәүләт борынгы актлар архивының татар мәчетләре хакында XVII гасырга караган уникаль документы урнаштырылган.

### ОПЕРА ЖЫРЧЫСЫНА 90 ЯШЬ

Республика жәмәгатьчелеге 1 май көнне К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында ТАССРның халык артисты, танылган опера жырчысы Усман Әлмиевкә 90 яшь тулуны билгеләп үтте. Артистны юбилее белән дуслары, күп санлы хезмәттәшләре кайнар котлады.

Усман Әлмиев 1940—1950 елларда опера театрында барлык татар спектакльләрендә диярлек төп партияләрне башкарган шәхес.

Хәзер ул ТР театр эшлеклеләренең ветераннар берлеге советы рәисе.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре һәм күп еллар буе нәтижәле эшләгәне өчен язучы **Рәфкать Кәраметдин** улы **Кәрамиевкә** (Рәфкать Кәрами) Россия Федерациясе Президенты Указы белән "Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

### МИЛЛӘТЕБЕЗ ӨЧЕН КУАНАБЫЗ

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен, Мордовия Республикасы башлыгы Указы нигезендә, шагыйрь һәм публицист **Тангалычев Камил Абдулла** улына "Мордовия Республикасының атказанган язучысы" дигән мактаулы исем бирелде.

Камил Тангалычев 1968 елда Мордовиянең Ельников районы Акчеево (Күгеш) авылында туган. Жиде китап авторы. Шигырьләре һәм публицистик мәкаләләре соңгы елларда Татарстан матбугатында басылып тора. Быел журналыбызның 4 санында аның бер цикл шигырьләре дөнья күрде. Бүгенге көндә ул Мордовиядә мондый дәрәжәле исемгә лаек булган язучыларның иң яше санала.

***

### РӘХМӘТ ХАТЫ

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне һәм Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре хакына күпьеллык нәтижәле хезмәте өчен шагыйрь, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты **Әхмәтжанов Роберт Вәли** улы Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар әдәбияты зур югалтуга дучар булды: 4 нче май иртәсендә каләмдәшебез—күренекле мөхәррир-әдип, шагыйрь, тәнкыйтьче, “Казан утлары” журналының фән һәм сәнгать бүлеге редакторы Наис Гамбәр (Наис Гыйммран улы Гамбәров) илле сигезенче яшендә кинәттән вафат булды.

Наис Гамбәр 1947 елның 25 августында Мөслим районы Бүләк авылында туа. 1966 елда Урәзмәт урта мәктәбен тәмамлагач, район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1969—1974 елларда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлауга, өметле яшь әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче буларак, Татарстан китап нәшриятына эшкә чакырыла, анда китап редакцияләү культурасының зур мәктәбен узып, тәҗрибәле мөхәррир булып җитешә. Шул ук вакытта көндәлек матбугатта тирән эчтәлекле, шигъри телстиль белән аерылып торган фәһемле әдәби тәнкыйть мәкаләләрен, китап күзәтүләрен бастырып килә. Бу җитди әдиплек сыйфатлары аның “Татарстан яшьләре” газетасында һәм “Татарстан” журналында мөхәррир булып эшләгәндә, аеруча “Казан утлары” редакциясендә җаваплы сәркәтип, бүлек редакторы вазифаларын башкарганда ачык күренде: ул күренекле мөхәррир-әдип булып абруй казанды. Соңгы елларда “Рухият” нәшрияты белән дә иҗади элемтәдә булды, дистәләгән язучыларыбызның китапларын дөньяга чыгарырга булышты. Әдәбият үсешендәге хезмәтләре өчен ул “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исемгә лаек булды. Шагыйрь буларак Наис Гамбәр үзенең нечкә тоемлы фәлсәфи лирикасы белән танылды: аның һичкемне кабатламаган үзенчәлекле шигырьләре “Баш очымда Кояш” (1991) һәм “Күзләрем яфрак коя” (2001) исемле китапларында тупланып, дөнья күрде.

Каләмдәшебез, якын дустыбыз Наис Гамбәр исеме күңелләрдә гел сакланыр. Хуш, якты күңелле, затлы әдип!

*“Казан утлары” редакциясе.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Авыл сабантуе. Рәссам **М. Самакаев** эше.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Дамир Гыйсметдин**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Рашат Низами. **Тормыш трамвае:** шигырьләр, поэма.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—238 б. Тиражы—2000 данә.

Шагыйрь Рашат Низаминың бу яңа китабында, элегрәк язылган шигырьләре белән бергә, соңгы елларда иҗат иткән яңа әсәрләре, шул исәптән "Ике мөһаҗир" дип исемләнгән сәяси поэмасы урын алган. Поэмада төрки дөньяның ике олуг шәхесе Назыйм Хикмәт һәм Гаяз Исхакый язмышлары бәян ителә.

Шагыйрь иҗатында лирик фәлсәфи, образлы фикер йөртү, рухи-әхлакый кыйммәтләрне зурлау юнәлеше өстенлек итә. Шул ук вакытта шигырьләр гади, ачык аңлаешлы булуы белән дә характерлы. Җыентык авторның "Энҗе бөртекләрен эзләгәндә" дигән кереш сүзе белән ачыла. Анда шагыйрь үзенең иҗади кредосын билгеләп, фикерләре белән уртаклаша.

Китапның редакторы—Р. Корбан, рәссамы—А. Матвеева.




Рәмис Аймәт. **Айның аръягында**: шигырьләр.—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2005.—191 б. Тиражы—1000 данә.

Рәмис Аймәт—татар поэзиясендә үз урынын яулый баручы талантлы яшь шагыйрьләребезнең берсе. Аның "Шомырт чәчәкләре" исемле беренче китабы 2000 елда дөнья күргән иде. "Айның аръягында"—авторның икенче китабы. "Тоткындагы ирек", "Яратканга", "Мин әле тумаган", "Давыл тынлыгы" бүлекләрендә шагыйрьнең, нигездә, лирик-фәлсәфи шигырьләре урын алган. Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин язган. "Рәмис шигырьләре үлем-яшәү, мәхәббәт-хыянәт, хыял-чынлык, галәм-кузәнәк, җир-күк, җәннәт-тәмуг, рыя-ихласлык, мәңгелек-мизгел кебек категория-төшенчәләр турында янә кайтып уйланырга мәҗбүр итте", диелә анда.

Китапның редакторы—Л. Гыйззәтуллина, рәссамы—Р. Сәйфуллина.

Индекс 73210



Дамир Гыйсметдин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)